ISSN 0206–4189

# Казан утлары

7.2004



Индекс 73210

# Tatarstan Respublikası Prezidentı
# UKAZI

## «Tatarstan Respublikasının xalıq şağire» digən maktawlı isem birü turında



Tatar ədəbiyatın üsterügə zur eleş kertkən eçen şağir, publitsist, ədəbi tənkqitçe **Xarisov Renat Məğsüm ulına (Renat Xarisqa)** «Tatarstan Respublikasinin xalıq şağire» digən maktawlı isem birergə.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV.**

*Qazan, Kreml', 18 may, 2004 yıl.*
№ УП-350.

# Tatarstan Respublikası Prezidentı
# UKAZI

## «Tatarstan Respublikasının xalıq şağire» digən maktawlı isem birü turında



Tatar ədəbiyatın üsterügə layıqlı eleş kertkən eçen şağir, prozaik, dramaturg, publitsist, **Bayanov Əxcən Fətxelbayan ulına (Əxsən Bayanğa)** «Tatarstan Respublikasinin xalıq şağire» digən maktawlı isem birergə.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV.**

*Qazan, Kreml', 18 may, 2004 yıl.*
№ УП-382.

# Казан утлары
# Qazan utları

*2004*

**7**

**(981)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*



*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Ихтыяр Гаязов, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**


---


✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**


Айдар ХӘЛИМ. Кылганнар чәчкә атканда. Хикәяләр. .... 5
Наис ГАМБӘР. Яшәү агачыннан – Шәҗәрәңнән... Шигырьләр. .... 42
Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН. Айбиби. Тарихи роман .... 46
Фәйрүзә МӨСЛИМОВА. Алтын алма белән хушлашу. Шигырьләр .... 102


**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**


Фаил ШӘФИГУЛЛИН. Хикәяләр .... 107


**ФӘН**


Солтан ШӘМСИ. Күк капусы ачылса... Тарихи-фәлсәфи бәян .... 114
Гаяз ИСХАКЫЙ. Ислам мәмләкәтләрендә .... 145
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .... 159
Гөлнар БАЗАРОВА. Сайадиның "Дастаны Бабахан" әсәрендә язмыш мәсьәләсе. 164


**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**


Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Үрнәк геройлар сагындыра .... 132
Зиннур МАНСУРОВ. Каләмебез илаһи антка тугрымы? .... 138


**ХӘТЕР**


Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Фидакарьлек .... 124
Әнвәр ДАВЫДОВ. Сайланма тәрҗемәләр китабыннан .... 127


**КИТАП КҮЗӘТҮ**


Миргазиян ЮНЫС. "Шигырь язып кына яшәп булмый" .... 169

Коръән татар телендә. .... 175


**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**


Фоат МОРТАЗИН, Миннур САФИУЛЛИН, ГҮЗӘЛЬЯР. Шигырьләр .... 182

Бер сорауга бер җавап .... 184
Котлыйбыз! (Чыңгыз Мусинга 70 яшь) .... 185
"Казан утлары" архивыннан .... 186
Берлекнең яңа әгъзалары .... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан .... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман М. ХАБИБУЛЛИНА "Айбиби"; рассказы А. ХАЛИМА, стихи Н. ГАМБАРА, Ф. МУСЛИМОВОЙ.
"Из сокровищницы татарских рассказов": рассказы Ф. ШАФИГУЛЛИНА.
"Наука": С. ШАМСИ. "Когда откроются Звездные Ворота"; Г. ИСХАКИ. "В исламских странах"; А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации"; статья Г. БАЗАРОВОЙ "Проблема судьбы в дастане Тахир-Зухра".
"Дискуссия "Герой нашего времени": статья А. АХМАДУЛЛИНА "Тоскуем по положительным героям"; статья З. МАНСУРОВА "Преданность к высоким целям".
"Память": статья Т. Галиуллина к 85-летию А. ДАВЫДОВА.
"Книжное обозрение": рецензия М. ЮНУСОВА на книгу Р. Шагиевой.
Коран на татарском языке.
Творчество читателей.
Из фотоархива журнала.
Новые члены Союза писателей.
На наших обложках: фотоэтюд М. ГАЛИЕВА "Горы Азнакая"; поэт Дж. СУЛЕЙМАН.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

Prose and poetry: Novel by M.KHABIBULLIN "Aibibi;" Stories by A.KHALIM, verses by N.GAMBAR, F.MUSLIMOVA.
From treasury of Tatar stories: Stories by F.SHAFIGULLIN.
Science: S.SHAMSI "When star gates open"; G.ISKHAKI "In Islamic countries"; A.TIMERGALIN. "Dictionary of nation"; article by G.BAZAROVA "Problem of destiny in dastan Tahir—Zuhra".
Discussion "Hero of our time: article by A.AHMADULLIN "We miss positive heroes"; Z.MANSUROV'S article "Fidelity to high purposes".
Memory: article by T.Galiullin to A.DAVIDOV'S 85-anniversary.
Books review: M.JUNUSOVA'S review of R.Shagieva's book.
Al Quran in Tatar language.
Creativity of our readers.
From photoarchive of magazine.
New members of the Union of writers.
On our covers: M.GALIEV'S photo-etude "Mountains of Aznakaj"; Poet Dzh. Suleiman.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 17.06.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8114. Заказ Э—447
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.

# Çəçmə əsərlər
# Чәчмә әсәрләр



## Айдар Хәлим

## КЫЛГАННАР ЧӘЧКӘ АТКАНДА

*Баязиттан Мөхәммәт ага Рәфиков истәлегенә*

I

Халык телендә "шадра тастымаллык" дип аталган тукымадан, кулдан, эре атлатып тегелгән һәм әле беренче генә киелгән ак күлмәк, кызыл кижеле кыска киндер ыштан белән өстен-башын бөтәйтеп алган һәм шул ыштаны белән болдырдан барлык ихатаны кызыл әләм кебек кызарткан Канәгать, тәкате бетеп, ачык ишеккә кычкырды:

—Озак мыштырдыйсың, инәй!

—Әй, шушыны!—Мич арасында ни сәбәпледер озаграк азапланган инәсенең өзгәләнгән тавышы ачык ишек аша тышка саркылды.—Бер нәрсәне теленә алсаң, нәкъ атаң мәрхүм кебек, өзмисең дә куймыйсың... Уттай эш өстендә бала-чага җаена тырай тибеп йөрергә, мин дә инде, юләр!.. Башына тай типкән, дип шул минем ишеләр турында әйткәннәрдер инде!..

Инәсенең "уттай эш өсте" дигәне бер яктан бигүк дөреслеккә килеп тә бетмидер кебек. Әле авылда печән өсте тәмамланмаган, урак өсте башланмаган бер чагыштырмача тыныч аралык. Канәгатьнең ике абзасы да печәндәләр. "Салучин яланы"нда. Куна ятып эшлиләр. Инәсенең "Бәрәңге төпләрен күмеп бетергәч тә, сине Минзыя түткиләргә Жидегәнгә алып барам",—дигән нәзере бар иде шул. "Түткигә илтәсе кәҗә мамыгым да киезләнеп бетә инде",—дип тә өстәде. Менә ул, нибары сигезе тулып, тугызга чыгып килгән Канәгать Сибгатуллин абзагыз, берүзе дип әйтерлек, уналты сутый бакчаны күмдереп чыкты. Монда, әгәр күрергә теләсәң, һәр бәрәңге төбендә анын күз алмалары тәгәрәп ята. Кичләрен, калхуздан бушанган араларда аңа инәсе белән өлкән абзыйлары да ярдәм иткәләште, әлбәттә. Инәсеннән зур ярдәм көтү оят иде. Ул бит—уразада. Көне буе янган кояш астында авызына кәтрә азык, бер йотым су алмыйча, балавыздай эреп, телләрен аркылы тешләп, иреннәрен җир кебек чатнатып кайта ул. Кайтып кергәндә йөзеннән гүя парә-парә чеплә ялкыны коела да, шул ялкыннан капкага, бар ихатага, йорт-җиргә ут каба. Аны кызганудан Канәгатьнең җылыйсы, тагын да ныграк тырышып эшлисе килә башлый. Кайтып керә дә инәсе, ичмасам, утырып та тормыйча, тагын да шул бәрәңгесенә, йә булмаса башка бихисап дөнья

*Айдар ХӘЛИМ (1942) – шагыйрь, прозаик, публицист; күпсанлы китаплар («Милли шигырьләр», «Татар вакыты», «Яңа Сагыш китабы» һ. б.) авторы. Чаллыда яши.*

мәшәкатьләренә тотына. Ничекләр генә түзә, ә?!..

Уразадагы кешегә көне буе үз төкреген дә йотарга ярамый, ди бит. Хәтта төкрек тә Аллаһы Тәгаләнеке, ди.

Бер сорарга иде—нигә тота икән ул үзен җәфалап шул ураза дигәннәрен?

Бәрәңге җирен казу, аннан орлыкны утырту, озак та үтми бакчаны басып киткән билчән, эт эчәгесеннән арындыру, бәрәңгене утау-йомшарту, төпләрен күмү, казып чыгару, чүпләү, эресен-эрегә, вагын-вакка аерып-бермтекләп, кышкылыкка базга салу өчен Канәгатьнең күргән җикләре! Туфракта иске орлыктан яңа бәрәңге үрчетү аңа күктә яңа йолдыз үрчетү белән бердер кебек. Йолдызлар да күктә нәкъ шул казандагы бәрәңге кебек ярмаланып кайныйлар сыман. Бакчадан шалтырап карбазына сикереп төшкәнче алар чынлап та йолдыз бәясенә басадыр, билләһи.

Бәрәңге—татарның тормыш әлифбасы, әйе, әлифбасыдыр ул. Әле генә беренче сыйныфны тәмамлаган Канәгать "Әлифба"ның нәрсә икәнлеген бик яхшы белә. Сан-сыйфат, кушу-алу, бүлү-тапкырлаулар шул "Әлифба"дан башлана. Бар, син авылда бәрәңгесез яшәп кара!.. Их, бу ачлыклар! Язгы аклы-карада чабатаңда бер пот балчык өстерәп, туң җирне казып-чокып, кияргә чабатаң да булмаса, бозлардан бозларга яланаяк, йолдыздан йолдызга сикергәндәй сикереп, салкынның утлы өермәсендә табаннарны пешерә-пешерә черек бәрәңге эзләп үтә бит аларның көннәре тәмам карага, тау, болын яшеленә басканчы. Их, яшелләнә башлаган тау борынына аяк басу, беренче юаларны авыз итү өчен ялан аякларны карбозда өттерә-өттерә шул тауларга чабып менүләр!..Их, инәләре—ятим хатыннар, абзыйлары—ятим малай, үсмерләрнең, эшкә киткәнче һәм кайткач, өмәләр ясап, җыйнаулашып шул җирне казып чыгып, туфракны йөрәк җылысы белән җылытып, бәрәңге орлыгын чәчүләре, җир астыннан яшел борау кебек боргалана-боргалана борынлап чыгуын көтүләр, аннан аларны якты күздән үткәзеп, чүпләрен кулдан утап, ике, өч, теләсәләр, көчләреннән килсә, ун кат китмән белән эшкәртеп, йомшартып, төпләрен күмдереп чыгулар!..

Канәгатьнең иң канәгать чагы—бәрәңгенең Канәгать турында онытткан, аның барлыгын-юклыгын тәмам хәтереннән чыгарып, чәчкә аткан, бераздан ачык бизәкле тукыма кебек шау чәчкәдә утырган чагы. Бу чорда бәрәңгенең күзгә күренмәс күзләре нииндидер мәхәббәт томаны белән томанлана, ниндидер сөрмәле рәшә белән өртелә. Бер карасаң, бәрәңге чәчкәләре бишектә ятып, имезлекләрендә ипекәйләре бетеп елаган сабыйларны хәтерләтәләр, икенче карасаң, гүя барлык бакча, һәр бәрәңге куагы, укытучылары Гаяз абый кебек зең-зең килеп, аклы, зәңгәрсу, күкшел-көрән, шәмәхә мандолиннарда зеңгелди! Бакча—җырлый! Канәгать белә: тирән күзле бәрәңгеләр бары тик зәңгәр чәчкә генә ата. Их, ул чәчкәләрнең зифа көязлеге, иркә сылулыгы, үзләренә генә хас серкәле һәм тиз уалучан матурлыгы! Канәгатьнең мондый сирәк, зифа чәчкәләрне хәтта Кралов урманнарында да күргәне булмады. Аның бәрәңге чәчкәләрен Балкызның чәчләренә кадыйсы килеп китте. Балкызны кем дисезме?

*Бар инде шунда бер кыз,*
*Исеме аның—Балкыз,—*

дип шигырь дә чыгарган иде әле ул. Бергә укыйлар. Беренче сыйныфны бергә тәмамладылар алар.

Хак булса, бәрәңге чәчкәсенең хатын-кызны тагын да матурайта торган шаукымы да бар, ди. Хак булса, Әби-патша җәй көннәрендә, бәрәңге чәчкә аткан чорда, үзенең сарай җарияләренә чәчләренә бәрәңге чәчкәләре кадап килергә куша торган булган, ди...

Исе юк бу чәчкәләрнең. Исләрен тойыйм дип иснәсәң, аклы-көмеш серкәләре борын очынны гына серкәли. Аның каравы, баздагы бәрәңгенең үзенчәлекле исе бар, базда озаграк булсаң, агуланырга да мөмкин. Шуңа күрә базда озак мыштырдарга, андагы бәрәңге исен иснәргә яратмый

Канәгать. Әмма бәрәнге исен яратмаса да,бүгенге көндә, дөрес, аларнын базларында кызык өчен генә иснәп карарлык та бәрәнгеләре юк.

Кәҗә майларын чыгарганчы эшләде быелгы җәйдә Канәгать. Гел-гел кояш астында булып, шунысын анлады: бәрәнге бакчасында шәүлә дә, күләгә дә була алмый икән. Анда син үзенә-үзең шәүлә дә, күләгә дә. Анда йә якты, йә карангы. Йә эссе, йә салкын. Әйе, күзләренә күренә, төнлә төшләренә кереп йөдәтә ана бу бәрәнге төпләре! Быелгы җәе дә бик коры килде шул. Янгыр бөтенләй диярлек яумады. Туфракка кизәнү белән китмән астыннан туфрак түгел—пырхылдап коры тузан оча, тузан! Җир анын инәсенен иреннәре кебек чатнады. Урыны-урыны белән ат тояклары, арба тәгәрмәчләре төшеп китәрлек булып ярылды. Күптән түгел котырып янгыр яуды, көеп саргайган таулар да яшелләнеп китте, бәрәнгеләр дә көч-хәл алды.

Инәсен көткән малай болдырдан тагын бер тапкыр бакчасына күз ташлады һәм горурланып куйды: тере кәртинкә инде, кәртинкә! Шау чәчкәдә. Кем бакчасы дигәндә ул "Мин—Канәгать абзый бакчасы!" дип кычкырып тора. Бәрәнгеләрнен һәр төбе анын күз яше, анын тир тамчысы белән сугарылган. Алар сонлап яуган янгырлар белән бергә анын күз яше һәм анын тир тамчысында да чәчкә атканнар. Һәм ул—күрегез!—инәсе белән Җидегәнгә кунакка бәрәнгеләре котырып чәчкә аткан чакта бара!..

Чәчкәләре коелгач, бакча куе-яшел төскә кереп, күп балалы аналар сыман монсулана. Гүя Бәрәнге Анасы балалары белән аерылышуны сизенә. Канәгать бу аралыкны өнәп тә бетерми. Бу чорда анын үзенә дә күнелсез булып китә. Әйе, атна-унбиш көн үтми, бәрәнгеләрнен канатларын каера-каера, төбе-тамыры белән актара, яшь, бала бәрәнгеләрен ашый да башлыйлар. Канәгатьнен мондыйларны яткырып камчы белән суктырасы килә. Хәер, ул анлый: болар барысы да юклыктан гына. Күпләр, чоланнарында умачлык оны, базларында ашка салырлык та бәрәнгесе,чөгендере калмаганнар, шулай иртә, әле чәчкәдә килеш, керешә бәрәнге төпләрен ботарларга. Чыга, чынлап еласан, сукыр күздән дә яшь чыга, дигәндәй, чыпчык күкәе кадәр булса да бәрәнге малайлары чыккалый инде шунда.Анын өлкән абзыйсы Галәветдин бакчаны болай тота-каба гына ботарлаттырмый. Быел ул энекәшләренә юан уклау гына күрсәтте: "Менә, чамалыйсызмы, кардәшләр? Әгәр чамаламасагыз, кардәшләр, сыртыгызда шарт сындырачакмын. Шунысын чамалагыз, кардәшләр!"

Абзыйлары ана һәр иртәдә боерып кына китәләр: "Менә сина, энекәш, утыз ызан. Хет көл, хет үл—без кичен кайтуга күмелгән генә булсын." Ә ашарга? Ашарга ни... шул бакча башындагы чөгендер яфрагыннан пешерелгән боламык инде. Бар гаилә шул боламыкта гомер кичерә. Канәгать еларга да иткәндәй итә, әмма елап ни майтарасын? Әтиләре сугышта ятып калды. Уртанчы абзыйлары исә үткән кышнын ачлыгында кинәт кенә үлеп китте. Аны духтырга алып бара алмадылар, духтырлар үзләре дә килмәде. Бабайлар "Сукыр эчәк түгел микән бу?" дип кырык ясин чыкканнан сон, тан алдыннан китте дә барды. Менә анын әле кигән кызыл ыштаны да шул абзыйсынын җеназасында хәергә килгән байлык...

Җәйнен тимерне дә эретеп агызырлык чилләсендә башын ат башыдай эре, салкын суда чылатылган әрекмән яфрагы белән каплап алды да күмде дә күмде ул бәрәнге ызаннарын. Күз аллары томалана, башлары әйләнеп, күнелләре уйный башласа, берәзгә гына күләгәгә кереп торды. Моны малайга кырык дәрәҗәле эсседә иген басуы утаган инәсе өйрәтте.

Менә шундый тырышлык белән үтәп чыга торган булды ул абзыйларынын көндәлек боерыгын. Бер тапкыр, өч кенә ызанны күмеп житкермәгән өчен өлкән абзыйсы кече абзыйсына "Сугып очыр син аны, елмаеп барып төшсен!"—дип кенә җикерде. Салып очыруын очырмады аны кече абзыйсы, әмма арка сыртына берничә тапкыр каеш белән тамызды. Канәгать анлый: анын абзыйлары ифрат та әйбәт кешеләр, алар шул дөнья кытлыгыннан гына шулай дәҗжалланалар. Юклыктан, ярәтудан, бары

яратудан гына тәпәләп алалар. Әнә бит, Галәветдин абзыкае кичә кич, ягъни ул бәрәнгеләрне күмеп бетергән кичтә, Кыяметдиннәрдән алып торган гармунын тышка чыгарып, тупсага утырды да, Канәгать энекәшен "гетти-гетти-геттигә"гә биетте, аннан күкрәгенә дәһи Сталин төшкән Җиңү мидалын да такты. Ул мидал әле дә малайның күкрәгендә. Күрәсезме сез? Анда нәрсәкәй язылганын ул укып та бирә ала: "На-ше дел-ло пр-ра-вое мы поб-бед-дил-ли..." Аның белән бергә җиз мидал да Җидегәнгә бара, димәк ки.

Әле инәсенә Җидегәнгә барасы ял көнен дә бригадир Лотфыйдан шул абзыйлары даулашып алып бирде. "Безнең шундый тырыш энекәшебезне Җидегәнгә алып барып кайт!"—диделәр дә эшкә киттеләр.

—Сиңа гүләйт тә, гүләйт инде...—Инәсе сөйләнә-сөйләнә өйдән чыкты. Тупсадан төшкәндә кинәттән туктады да кире күтәрелә башлады.—Тукта, балам!.. Чак-чак кына ишегебезне бикләмичә дә китеп барганбыз бит! Биклик! Бикләми буламы? Бар, берәр нәрсә алып бир!..

Канәгать болдырдан җиргә сикерде дә, утынлыктан каен чыбыгы алып бирде.

Инәсе келәне элдереп, божрасына чыбыкны тыкты.

—Менә булды. Бөтенләй юк ише түгел. Дус бар—дошман бар, дигәндәй...

Сөйләнә-сөйләнә алар канатлары хуҗасыз калтаеп, икесе ике якка чалшаеп торган урыс капка аша урамга чыктылар да, кисәк кенә уңга борылып, ат юлы янәшәсендәге такыр сукмак буйлап киттеләр.

Ниһаять сәяхәткә чыгу шатлыгын кая куярга белмәгән Канәгать инәсен күздән кичерде. Нишләп шулкадәр дә матур икән ул? Аның әллә түгәрәк иякләре, күзләре, бит алмалары, әллә атламнары матур, моны аерып кына әйтә алмый малай. Матур инде, бик матур. Бары шул гына. Инәсенә нәрсә кисә дә кып итеп кенә тора. Нишләп шулай икән ул? Алкаларын, чулпыларын тагарга да, көмеш беләзекләрен кияргә дә онытмаган. Шул алка-беләзекләреннән бүген бөтенләй нурланып, матурланып киткән. Гүя басудан көеп, йөзеннән кисәк-кисәк кояш көекләре коелып кайткан уразалы Минсылу, калхузчы Миңсылу түгел, ә бәлки Айдан төшкән Зөһрә кыз! Гүя балтырган, кузгалак, кычыткан, чөгендер яфрагы кебек урман-ялан, бакча үләне белән түгел, ә бәлки гөбернатырлар, янараллар ашый торган затлы ризыклар белән тукланган ханбикә-солтанбикә!

Ничек түзә икән ул? Телләре кибеп, эштән кайткач та, ул "авыз ачарга" ашыкмый, авыз ачар сәгатен көтеп, Канәгатьне иявртә дә Өязе буена китә. Улын сакка куя да, берәр "кеше-кара күренсә, тамак кырырсың", диеп ат күмелерлек таллыклар, зәһәрләрен коеп утырган чәчкәле кычытканнар, ат кузгалаклары артында яшеренеп, агымсуы аяк йөзенә генә чыгып торган елгада су коена. Ничек коена? Аннан, көне буе сусыз торып-торып, ничек итеп йотым су да капмыйча, шул суның эчендә... су керергә мөмкин икән ул, ә? Аны уразасы шундый түзем булырга өйрәтәме?

Әйе, чынлап та матур шул аның инәсе. Малай тәртәдәге инәсе янында уйнаклаган колын кебек, икенче якка сикерәңнәп чыкты да, тагын бер тапкыр карап куйды: инәсе беркайчан да киенми-ясанмый. Буянмый. Махсус елмаймый. Әмма гел генә елмаеп торган кебек. Бу елмаю аның йөзеннән йоклаганда да китми. Менә әле дә аның йөзендәге кояшлы сагыш, кояш челләсе кунакка гына кия торган вак яшел чәчкәле күлмәгенә, нәзек билбавына, хәтта ап-ак йон оеклары, елтыр кәвешләренә кадәр төшеп яктырткан. Чәчләрен ипле генә итеп уртадан аерып үргән дә, кара төрткеле ак яулыгын сыерчыклатып, алкалы колакларын тышта калдырып бәйләгән. Чәчүргечләрдән төшкән дүрт чулпысы атлаган саен зең-зең итеп аваз салып куя...

Инәсе кулындагы ап-ак болытка охшап кабарып торган зур төенчектә исә кәҗә мамыгы. Анысы да капма-каршы чалынып ак яулыкка төйнәлгән. Аларның Чибәркәй дигән мамык кәҗәләре бар. Күзләре зәп-зәңгәр. Ул абзардан чыгу белән бөтен ихатага ямь керә. Мамыгы да зәңгәрсу, дөресрәге, күкшел-зәңгәр. Канәгатьләр белән бергә укыган Балкызның да күзләре

шундый күкшел-зәңгәр бит. Ул да сугыш ятимәсе. Канәгатьнең, ярый әле, инәсе бар. Әмма картинәсе, картатасы юк. Балкызның янында инәсе юк, әмма картинәсе, картатасы бар. Аның инәсе кайдадыр еракта, бик еракта урман кисеп, турф чыгарып йөри диме шунда...

Әнә, Йомры Гариф малае Әгъләметдин читәннәренә зур колаклы сары самавыр булып асылынган да, Канәгатьне күзәтә. Алар авылда бердәнбер булып ел да шәмәхә шалкан чәчәләр. Әнә, аның шалкан ашап күбенгән корсагы да самавыр корсагына охшаган. Ә бәрәңгеләре әле һаман да чүп эчендә утыра икән.

Сизә Канәгать, тегенең беләсе килә.

—Кая барасың, әй?

Белми торсын әле. Канәгать аның каршыннан башын да бормыйча, керфеген дә какмыйча үтеп китә.

—Беркая да бармыйм әле, әй.

Шулай үтеп китәргә хакы бар. Бәрәңгесен күмдереп бетерсен ин элек. Күкрәгендә мидалы да юк. Шадра тастымаллыктан тегелгән ак күлмәк тә, тезгә генә житеп торган кызыл ыштан да тәтеми анарга. Аннан, Канәгать аталы балаларны бик өнәп тә бетерми. Әллә ак күмәч ашаганга әллә нинди төссез алар. Менә Әгъләметдин дә шундый. Ат кунасына йөрми. Үпкәчел. Үпкәләтсән, идән себерерлек итеп иренен салындыра...

Баш очыннан гына "Кая пар-рас-сыз?" дигәндәй пырылдап чыпчыклар өере үтте.

Өязенең аргы ягында ихатасыннан Бәдигыльямалның Кыяметдине дә атылып килеп чыкты. Чыкты да, телен йотып, катып та калды. Канәгатьнең дусты ул. Аларның күреге пышкылдап тын чыгарган тальяннары бар. Авылда бердәнбер гармун. Галәветдин абзыйсының авылны биеткән гармуны аларныкы бит инде. Кайвакыт абзыйлары Кыяметдиннәргә йә бакчаларын казыша, йә урманнан коры-соры утын төшерә дә, тегеләр шул хакка аңа берничә көнгә гармуннарын биреп тора.

—Кая барасың, әй?

—Тогочка,—дип җавап бирде эре генә Канәгать.

"Тогоч"—"теге оч" дигән сүз. Канәгать сизенә, монысының да кызыл ыштан турында беләсе килә. Монысы да күпне белми торсын әле. Тиз картаер, югыйсә. Шушы бер сүзле җавап белән әңгәмәне ябып, Канәгать юлын дәвам итте. Әмма үсүзле Кыяметдиннең бәйрәмчә киенеп, инәсе белән каядыр китеп барган Канәгатьне озаграк сөйләштерәсе, нинди йомышка чыгуын белеп каласы килә иде, күрәсең.

—Ыштаның котлы булсын, әй.

—Ыштан түгел, чалбар,—дип җибәргән була бу юлы Канәгать.

—Барыбер инде...

—Бер дә барыбер түгел,—дип җавап бирә Канәгать. Аннан дусты Кыяметдинне кызганып, өстәп куя.—Коллык, әй. Сиңа да бирсен Ходай.

Шулай диде дә—борынын күтәреп үтеп тә китте. Бар, тот син хәзер Канәгатьне.

Сәбәхетдиннәр күпере кырыннан үтеп, читән казыклары, кычытканнар эченнән чалыш-полыш тырпаеп торган ихата буйлап Жидегәнгә таба юл алдылар.

Аңа юлда инәсе белән рәхәт тә, читен дә. Инәсе аны талгын адымнары белән тоткарлап килә.

Авыл кырыена житеп, оч-очларындагы тишекләреннән сүс көлтәсе сыман аксыл төтен чыгарып янып яткан күмер һәм эзбиз базлары янына житкәч, кызурак барасы, кем әйтмешли, тупсадан тизрәк түргә үтәсе килгән, кыскасы, бәрәңге бакчасыннан гайре башка бернәрсә күрмәгән һәм киң дөньяны тизрәк танырга хыялланган малай, күкрәгендә кайнаган хисләргә урын табарга теләп, йөгерә башлады.

Йөгерә торгач, таныш өянкеләре белән каршылаган Өязе үзәненә дә килеп житте. Юньләберәк караса: куш өянкеләрнең елгадан чыгып торган юан тамырлары төбенә тешләре белән килеп кадалган тимер тырмалар

һәм тиякләре-ниләре белән ат дирбияләре аунап ята. "Кичә Нәгыйм абзый тырмадан атлары дулап китеп тырмасыз кайткан, дип сөйләгәннәр иде, хак икән,"—дип уйлап алды малай. Бу тырма, тияк-дирбияләрне нигә һаман килеп алмыйлар, калхузга кирәк түгел микән ни?

Елга үзәне буйлап бераз өстәрәк каяндыр югарыдан гөбертәп ишелеп төшкән су тавышы билгеләп алды аны. Әйе, анда, бераз өстәрәк, шарлама бар. Канәгать чуерташлар өстеннән чорлый-чорлый агып яткан агымга керде. Суы тубыкка житкәч ул нишләптер туктап калды. Ары таба барса да елганың тирәнлеге шуннан артмый артуын. Һы, шәүләсе күренми! Төшлеккә житкән кояш астында казык кебек туры торган гәүдәнең шәүләсез булуын белә ул. Көлемсерәп куйды. Һы, монда да төшке бәрәңге бакчасындагы кебек шәүлә юк икән!.. Шәүләсез кояш!.. Кинәт ул аяк чәлтерләрен төрле яклап нәрсәнендер кымтый, кытыклый башлавын тойды. Караса—йөзләгән вак балык челбәрәләре аның балтырларын сырып алганнар да, инәләренең корсагы астыннан имчәк эзләгән сукыр песи балалары кебек, кечтеки авызлары, борыннары, мыеклары белән аны кымтыпмы кымтыйлар, капшапмы капшыйлар! Челбәрәләрне тотарга теләгәндәй хәрәкәт ясап, казыктай туры гәүдәсен сындырып, су өстенә аз гына бөгелгәндәй-иелгәндәй итте—шәүләсеннән өреккән челбәрәләр елт итеп юкка да чыктылар. Гажәп бит: әле генә туры булган гәүдәсе аз гына иелү белән шәүләгә әйләнде һәм бер нинди явызлык, бернинди гамәл кылмаган килеш тә тере жаннарга курку салды. Тере жаннарның бер гаепсезгә анардан куркулары аның үзен шөбһәгә төшерде. Шәүләнең бу сыйфаты малайны шаклар катырды. Адәм баласының кушылган эшне эшләми калдырып та шәүләгә сылтау, шәүләнең еш кына дәлилсез өркетү, үзеннән үзенне куркыту мөмкинлекләре аны киләчәктә гомере буе борчый һәм кайгыларга сала торган чыганакка әйләнәчәген ул белми иде әле...

Әгәр ул балык тотарга теләсәме? Әнә теге, әле анардан югарыдагырак агымда шаулап, аска гөбертәп сикереп төшкән шарламадан кочак-кочак (Үз-үзе белән сөйләшкән малай сизмәстән колачларын жәеп жибәрде!) "Менә болай кочак-кочак тота алачак!" дигән гыйбарәдән кәефе килеп, пырхылдап көлеп жибәрде. Әйе, бу оч малайлары түбән очныкылар кебек балыкны кармаклап азапланмыйлар. Әнә шул шарламага баралар да, ыштаннарын-күлмәкләрен салып, шарлама астына керәләр һәм су агымы ясаган казанга кулларын тыгалар да...

Шул манзараны күз алдына китергән малай агымсуда чаптыр-чоптыр килеп югарыга таба атлый башлады...

Елгасы кечкенә, тавыш-тынсыз акса да, шарламасының тавышы ифрат та зур гаугалы һәм галәми иде. Агым биредә чынлап та чиләк, казан сыман чокыр хасыйл иткән. Күрәсең, югарыдан сикергән агым суны меңләгән куыклар белән богырдата, өстәмә һава, азык микъдары белән баектыра, нәтиҗәдә бу һава һәм азык балыклар өчен аеруча уңай шартлар тудыра. Ике биек яр арасында бикләнеп гөбердәгән шарлама якынайган саен тавышы колакларын тондыра барды һәм менә ул, ниһаять, килеп житте. Жиңнәрен култыкларына кадәр сызганды да, биеклектән үзләренчә урра кычкырып аска сикергән агымсулар шарламасының казанына кулларын тыкты...

Судан жылы тереклек исе аңкый.

Һава куыклары чыгарып кайнаган һәм дыңгычлап вак балык белән тулган казанга кул тыгарлык та түгел, теләсән, андагы балыкны сабы шартлап сынганчы яссы көрәк белән төяргә мөмкин иде. Кушучында чүмәшкән вак балык боткасын ул бармаклары белән сөзеп кояшка чыгарды. Анда тирә-якка сикерешә-сикерешә терекөмеш балыклар уйнаклый!..

Малайның аларны сөттә-йомыркада куырасы килде. Әмма бүген мондый мөмкинлеге юк шул. Иртәгә килеп китәр әле. Теләсә, табасы белән сөзеп тә чыгарыр, куырып та ашар.

Канәгать кушучында калган балыкларны су өстенә сипте дә, урыны-урыны белән чылана төшкән күлмәген юеш кулы белән сыйпаштырып, кире куш өянке тарафына атлады. Әнисе аны калдырып китә күрмәсен тагын.

Өязенең түбәнге агымында эре балыклар да бар, алар бары тик шәһәрдән кайткан матур кармакларга һәм бары чикерткәгә генә каба. Канәгать берничә тапкыр үзе ясаган тимер чыбык кармаклар белән селәүченгә кармак салып карады—бар, тиз генә каба ди синең тупас тимерчыбык кармагыңа эре балык, ыжламадылар да.

Инәсе кичүгә җитеп кенә килә икән.

Әле генә "кочак-кочак" балык тоткан малай оекларын, елтыр кәвешләрен кулына тотып, яланаяк кичү кичкән, инде хәзер яр буендагы орылы акташта киенеп утырган инәсенә куанычларын җиткерергә ашыкты:

—Инәй, ә, инәй!

—Нәрсә?

—Безнең Өязе нинди зур елга, әйеме?

—Таптың тагын елга! Елга димәсәң, хәтере калыр...—Нииндидер уйлар белән борчылган ана йөрәксеп сөйләп китте.—Үлеп яткан кешенең каны кадәр генә типченеп ята инде шунда... Нәкъ үзебез кебек. Ни эше корысын, ни үзе корысын...

Канәгатькә бу бер дә ошамады.

—Юк, елга! Безнең Өязе—елга ул!

Уңына-сулына карамыйча аякларына оекларын киеп, бөтәеп утырган инәсе, улының хәтерен калдырырмын дигән уйны уена да китермичә, борын астыннан гына мыгырданды.

—Монда килеп утырган ата-бабаларыбызны әйтер идем... Тәүбә вә әтәүби иляһым!.. Жире—сазлык, елгасы—ни үлми, ни терелми. Чумып чыгарлык бер чоңгылы юк... Кем әйтмешли, ага шунда кибәр-кипмәс, сүнәр-сүнмәс...

—Безнең Өязе—барыбер зур елга!—дип кычкырып җибәрде малай чын-чынлап үпкәләгән аһән белән.—Диңгез ул, дәрья ул!..

—Дөресе, инеш инде ул, улым,—дип җибәргән хатасын төзәтергә тырышты инәсе.—Башка якларда мондый инешләрне чишмә дә, кизләү дә диләр.

—Юк, ниткән чишмә, ниткән кизләү ди ул?!—Канәгать үз дәлилләре белән "һөҗүмгә" күчте.—Сезнең чишмә һәм кизләүләрегездә балык үрчеми. Аларның суы суык. Безнең Өязе җылыкай. Шуңа күрә кочак-кочак балык! Әйдә, күрсәтәм!..

—Ярар, синеңчә булсын...

## II

—Әссәламәгаләйкемнәр!..

Аваз килгән якка борылсалар—Миңлегазиз бабай. "Чишмә Башы" Миңлегазиз карт. Үлән яшеле йоккан чабаталарын исәпләмәгәндә, кигән киеменең барысы да актан. Изүе сулдан калдырылып тегелгән озын, тир тозында, кояш нурында һәм кер селтесендә төсләре, хәтта кайчандыр кара булган буйлары, тӧрткеләре, бизәкләре дә ашалып, агарып беткән киң җилкәле, җилпуч итәкле житен күлмәге дә, озын тулаоекларына кыстырып киелгән, күп юудан җилсенеп, уңып беткән киң төпле ыштаны да, күзенә кадәр батырып киелгән киез эшләпәсе дә, мөселманча калдырылып түгәрәкләнгән сакал-мыеклары, хәтта курысы суеп төшерелгән юкагач юл таягы да актан иде аның. Ул гынамы? Сул кулын сугышта төптән өздергән, яраланып, тезеннән каткан уң аягын исә ничектер читләтеп, ярымтүгәрәк ясап атлаган картның гадәттә җилфердәп торган буш җиненең очына бүген нииндидер елтыр кыллары белән буранлап торган үлән бәйләнгән. Канәгатьнең уйлавынча, ил буйлап хәл белеп йөрүче Хозыр Ильяс нәкъ менә шушы Газиз бабасы кебек булырга тиеш иде.

—Исәнме, Газиз бабай!—дип сәламләде аны малай.

—Вәгаләйкемәссәлам, Миңлегазиз абзый!—диде инәсе.

—Кая юнәлдегез болай, Минсылу карендәш?—Кояшка алды белән торган карт кулларын каш өстенә куйды.—Карамалы базарына түгелдер бит? Малайны да иялтеп, димен.

—Кая ди инде ул безгә базар юлларын таптарга, Миңлегазиз абзый,—дип инәсе зарлангандай итте.—Сатарга малыбыз, мал алырга хәлебез юк. Менә Җидегәнгә барасы иттек әле. Агылыйга тагылый...—инәсе аңа ымлап, сүзендә бераз арттырып та җибәрде.—Җыландай телләремне чыгарып әйттем—калмый бит. Ярар, ураза бәйрәме алдыннан бераз дөнья күреп кайтсын...

—Ә-ә-ә, менә монысы мәслихәт, бик мәслихәт!.. Савaплы юлга чыккансыз, карендәш! Монавы уч төбендә генә торган Җидегәнне дә күрсәтмичәме?—Карт инәсенең фикерен күтәреп алды.—Хәзер бит аларның башлары башакланган, йомрыланган чаклары... Хәер, Канәгать улымның башы болай да йомры инде аның, ә?—Ул кеткелдәп көлде.—Кара әле, Миңсылу карендәш, малаең бит бакчагызны ничек кенә тиз арада китмәнләп чыкты, ә? Олылар эшли алмаган эшне, ә? Шундый тырыш кешегә Җидегән кадәр Җидегәнне күрсәтми диме?—Ул Канәгатьне күкләргә чөеп мактарга тотынды.—Кулымнан килсә, мин аңа Мәскәү Кремлен дә күрсәтер идем әле... Укытырга кирәк аны, Миңсылу карендәш! Соңгы тавыгыңны сатып булса да укытырга кирәк. Әфисәр булсын!.. Димнәмир, акбәкәт булсын!.. Быррач, палищщик* булсын!.. Күр дә тор, зур кеше чыгачак аңардан. Аның йомры башы, ишетәсеңме, Мәскәү Кремле сәгате кебек тек-тек итеп тора!..

Карт колагын җилгә куйгандай итеп, тагын да кеткелдәде, исән кул яссуы белән дөпелдәтә-дөпелдәтә Канәгатьнең аркасыннан сөйде.

Аның белән бергә вак чуерташлар өстендә дереллдәп таягы да кеткелдәп көлде.

—Рәхмәт, Миңлегазиз абзый. Анысын инде кистереп кенә әйтеп булмый. Аттан ала да туа, кола да туа, дигәндәй... Менә аталары гына...

Инәсенең тавышы өзлекте.

Карт бугазыннан "кых" дигән аваз чыгарып, карашын түбән төшерде.

—Син үзең каян киләсең соң?—диде инәсе ниһаять тамагындагы төерне йотып җибәргәндәй итеп.—Болай иртәләп...

—Иртәләп, дип... Сәхәр ашадым да, урманга киттем. Печәнлектә бераз чабасы җирем калган иде... Шунда мендем дә, сабах намазымны укып, тәпәлисе печәнне тәпәләп бетердем, иншалла. Аннан...—Карт эчендәген әйтәлмәгән төсле тыелып торды.—Аннан нәрсә... минекен беләсез, шул чишмәләр инде... Печән өстендә йөрергә бөтенләй форсат тимәгән иде... Атна-ун көнгә бер барып күренмәсәм, ташлар басып киткәндер, җылап яталардыр кебек. Шуларны карап кайтып килешем...

Картның җиң очына бәйләнгән сәер ефәк үлән бәжраларыннан кояш нурларында элҗе-мелҗе килеп көмеш коела иде. Малайның бу хакта сорыйсы килгәнлеген сизгән кебек, Габделгазиз бабай үзе үк аңлатырга керешә.

—Кылган бу. Ата-бабалардан исән калган үр кылганы. Сирәктән сирәк кылганнар. "Көмеш кылган" дип аталалар. Чәчкә атканнар, балакайларым. Кылган үләненең киткән хәтерне кире кайтара торган шифасы бар, дигән борынгылар...

—Һы!—диде Канәгать аптырап.

—Кылган чәчкә ата мени ул, Миңлегазиз абзы-ы-ый?—диде сузып инәсе.

—Ата шул. Дөрес, сирәк чәчкә ата. Елына карап. Аллаһы Тәгаләнең бар нәрсәсе дә могъҗиза бит: явымлы елларда кылган чәчкә атмый, ә менә быел җәйдә нибары бер яңгыр булды—чәчкә аткан... Бар далага зеңгелдәп көлеп утыралар!..Еллар хәерле булыр, Ходай кушса!.. Савытка куям мин аларны. Тәрәз төбенә...

—Ә кая аларның чәчкәсе?—дип сорады күңеле һаман тынычланмаган Канәгать.

—Бәй менә шушы бәжра-бәжра булып айдарланган көмеш кыллар кылганнарның чәчкәсе була да инде...

* Землемер—җир фәне белгече. Адвокат (латин.)—мәхкәмәдә хөкем ителүче якны яклаучы юрист. Врач—табиб. Полесник—урманчылык белгече. (Автор искәрмәләре.)

—Һы. Кызык икән.

—Бер очратканда сорап калыйм әле, Миңлегазиз абзый,—диде инәсе жилдә уйнаклаган кылган сабакларыннан күзен алмыйча.—Шул чишмәләрне караганың өчен силсәүиттән берәр өлеш чыгармыйлармы? Берәр пот иген бирмиләрме, труттин булса да куймыйлармы, диюем...

—Түли!.. Таптың тагын!..—Карт тагын да таягы белән бергә кеткелдәп көлде.—Чишмәләрне караган өчен налук салмасалар, ярый әле!.. Аллаһәппәргә йөрим. Аннан, бирәсе бурыч өчен түләү сорап йөреп булмый бит. Табигатькә дә күз-колак кирәк. Сугыш та бетте, сазлык киптерәбез дип тугайларга, чишмәләргә, иген мәйданы арттырабыз, ялгызак агачларны төплибез дип урманнарга каршы һөҗүм башланды. Бер кулым, бер аягым исән чакта, хет чишмәләрне караштырып калыйм, ичмасам. Барысының да авызларын ихаталап алдым. Тын юлларын кинәйттем. Абайлыйсызмы, мондый коры елда да Өязедә су кимеми? Мул гына бит, ә?

Карт таяк очы белән су агымында уйнады.

Канәгатьнең эчендә нәрсәдер "елк" итеп куйды.

—Өлеш, дигәннән. Чыгардылар... Кхе-кхе... Шунсына да куанам. Элек минем нинди генә кушаматларым юк иде—Карун Газиз, Ялгызак Газиз, Гарип Газиз, Аяксыз Газиз, Чатан Газиз, Чулак Газиз... Чишмәләрне сөрдерү, малдан таптатудан туктыйк дип күп чәпчи торгач, үземә "Чишмә Башы Газиз" дигән ләкабне дә өстәп чәпәделәр дә куйдылар!..—Бабалары бу юлы таягын гәүдәсенә сөяп, исән кулы белән яшьле күзләрен сөртә-сөртә рәхәтләнеп, ләззәтләнеп көлде.—Тегеләре, "Чулак Газиз"ләре онытылды! "Чишмә Башы Газиз" генә калды. Халыкка рәхмәт, халык һәйбәт безнең!..

Карт сөйләгәнне малай йотлыгып тыңлады. Аның күзләре ялкынлана, бит алмалары алсуланып яна иде. "Чишмә Башы Газиз" кушаматын ишеткәне булса да, аның хак мәгънәсе турында элек уйлап та карамаган бит ул, почык борын!

"Чишмә Башы" Газиз бабасы шушы үзе була бит инде! Аның әле үз янәшәсендә таяк очы белән агымсуларны чайпалтып торуыннан файдаланып, малайның инәсе белән ике арада булган бәхәсне чишеп каласы килде.

—Газиз бабай!—Ул тәмам батыраеп китеп, алгарак чыкты.—Газиз бабай, менә син әйт әле, безнең Өязе елгамы, әллә чишмә генәме?

Карт авызын ачкан килеш катып калды.

Ул сораудан тынсыз иде.

—Әйттем бит моның башы Мәскәү Кремле, дип. Мондый сорауга тота-каба гына җавап бирү шүтке түгел.—Карт авыз тирәләрен, сакал-мыекларын сарган тир бөрчекләрен кул сырты белән сөртте. Өянке күләгәсенәрәк ышыкланып, сүзен дәвам итте.—Ну, рәхмәт. Эр-рәхмәт, йәме! Безнең авылдан миңа мондый сорауны биргән беренче кеше әле син. Күр дә тор, Минсылу карендәш, мондый сорауны биргән кеше бик зур кеше булачак!..—Ул малайга якын килеп, күзләренә текәлде. Аның белән бергә Канәгать янына тирбәлә-тирбәлә картның буш җиңендәге көмеш кылганнар учмасы да килде.—Менә син үзең әйт әле, кияү белән кәләш... гаиләме, түгелме?

—Син бигрәк инде, Миңлегазиз абзый,—дип каршы төште инәсе.—Сигезенче яше белән барган бала каян белсен инде аны?

—Тукта, карендәш, тукта. Алай димә. Зиһен көчәнергә тиеш. Ул шунда гына эшли, ялкау булмый. Йә, йә!..

—Г-а-и-л-ә,—диде малай авазларны авызыннан берәм-берәм сытып чыгарып.

—Түгел шул, түгел, мин сиңа әйтим! Кияү белән кәләш—алар бары тик кияү белән кәләш кенә! Кечкенә сабыйлары... ягъни мәсәлән, синең кебек малайлары-кызлары булгач кына әйләнә алар гаиләгә. Әгәр шулар булмый икән, алар кияү белән кәләш булып картаялар, мин сиңа әйтим. Вәт!..

Миңлегазиз бабасы авыр итеп тын алды.

—Елгалар да шулай. Чишмә ялгыз акканда ул әле чишмә генә... Аңа

башка чишмәләр дә кушылгач, елгага әверелә. Менә безнең Өязе дә үзенә нәкъ сез бара торган Җидегән авылын яңгыратып утырган Аюлы Кул, Әнәч Кулы, Тукмак Кулы чишмәләре кушылгач кына елгага әверелгән. Чишмәләрнең суы никадәр мул, саф булса, елгалар да шулкадәр мул, саф сулы була... Өязе!..—Карт ниндидер тирән сагыну белән уфырып тын алды.—Җир йөзендә бу кадәр алыплар, акыллы кешеләр үстерә торган бүтән бер генә елга да юк! Бу ни өчен шулай дип уйлыйсыз? Аның суында адәмзатның миенә кирәк булган сирәк металлар күп... Алтын-көмеш күп!.. Өязе, безнең Өязе... Безнең өчен иң зур елга ул. Ул безнең диңгез, дәрья...Юк, акиян!.. Аны буган буаларда тегермән куласалары әйләнә, еликтыр станцалары эшли. Әгәр теләсәк, без анда парахутлар да йөздерә алабыз!..

—Әйттем бит! Әйттем бит!.. Өязе безнең өчен иң зур елга, дәрья!..—Малай кулларын чәбәкәйләп Миңлегазиз карт тирәләй биеде.—Чишмәләр каян барлыкка килә?

—Чишмәләрме? Алар да кешеләр кебек туалар һәм үләләр. Аларны да Ходай Тәгалә яраткан...—Бабай бераз уйланып торды.—Коръәннең “Бәкарә” сүрәсенең алтмышынчы аятендә чишмәләр яратылуы турында менә нәрсә диелә: “ Муса пәйгамбәр таягы берлә ташка орды, таштан унике чишмә агып чыкты, чөнки алар унике кавем-кабилә иделәр. Һәр кабилә үзенең чишмәсен белде...” Менә синең чишмән—шушы Өязе була инде. Син аны белергә, мәңге хөрмәтләргә һәм мәңге онытмаска тиешсен...

Болар барысы да Канәгать өчен серле китап укуга тиң иде.

—Бабай, ә бабай! Әйт әле, менә... иген ничек үсә? Кешеләр үзләре үсә, шулай бит? Иген бит ул үсәргә кеше түгел? Шулаймы?

—Житте инде сиңа,—дип җинелчә битәрләп алды улын ана.—Бер сораша башласаң, чиген белмисең. Миңлегазиз бабаң бит сиңа прафисыр да, Әфләтүн хаким хәзрәтләре дә түгел...

—Бәрәкалла, улым! Кешеләр үзләре генә үсә алмый. Менә сине, мәсәлән...—Карт малайның инәсенә караш ташлады,—инәң үстерә, шулай бит? Инәңне дә, сине дә, мине дә, игенне дә Ходай Тәгалә яраткан һәм Ходай Тәгалә үстерә. Иген бөртеге дә кеше кебек тере җан ул. Аның да әнисе бар.

—Кем?

—Җир- Ана. Шуңа күрә Җиргә Җир-Ана диләр дә.

“Мәктәптә нигә бу хакта сөйләмиләр икән?—дип уйлап алды Канәгать—Шушы хакта гына сөйләсәләр дә, дәресләр күпкә мавыктыргычрак үткән булыр иде...”

—Кешеләр җирне беренче тапкыр сука белән сөргәндә Җир-Ана бик нык җылаган, ди. Авырткан аның тәне. Ходай Тәгалә аңа әйткән: Син әлегә түз. Кешеләрне азыкландыр. Аякка бастыр. Җылыт. Ашат. Киендер. Үстер. Яшәсеннәр, матур, батыр булсыннар, ата-инәләренә, Ватаннарына ырыс-бәхет китерсеннәр. Үз көннәре житкәч, алар барысы да сиңа мәет булып кайтырлар һәм синдә балчык-мәтегә әйләнерләр...” Бу чынлап та шулай, улым. Кеше дөньяга килә һәм китә...

Канәгатькә эссе көндә суык булып китте.

—Үләме?.. Кеше барыбер... үләргә тиеш мени? Кеше үлемсез булып калалмый мени? Минем үлемсез буласым килә!..

—Тәүбә, диген! Адәм баласы бары тик җан иҗтиһаты, эшләгән эшләре белән генә үлемсез була ала.

Малайның йөзе яктырды.

—Тәне белән—юк, үлемсез булалмый.

Малайның йөзе карангыланды.

—Үлемсезлекнең кызыгы юк, улым. Үлемсез кеше имансыз кеше булган булыр иде. Үлеме бар кеше тормышта—тереләр алдында, әхирәттә—Ходай Тәгалә алдында бурычлы. Шуңа күрә адәм баласы үз гомерендә кешеләрне рәнҗетмәскә бурычлы... Бурычсыз тормыш мәгънәсез... Барыгыз, бар, юлыгызда булыгыз!—дип куа башлады карт аларны кинәт кенә уянып киткәндәй.—Мин сөйләрмен ул, тел сөяксез ул!.. Кхе-кхе...

Өянке күләгәсеннән чыгып, ул үзе дә авылга таба юнәлә башлады. Әмма аны инәсенең соравы туктатты:

—Гает намазы кайчан икән, Минлегазиз абзый?

—Бүген сишәмбе мәле? Сишәмбе. Быел ике бәйрәм рәттән туры килә икән бит. Гаетне җомга алдыннан, атнакич иртән укыла диделәр, кардәшем. Бәйрәмнәребез мөбарәк булсын!

—Шулай була күрсен, Газиз абзый!

—Исән бул, Газиз бабай!

—Сау бул, Канәгать улым. Сәламәт бул. Хәерле юл сина!..

### III

Газиз бабасы белән сөйләшүдән ифрат та тирән шаукым алган малай үзе белән инәсе дә барлыгын онытып, алга торып олакты. Бераз киткәч борылып караса—бабасын гүя җир йоткан, ә менә инәсе уң кулындагы ак төенчеген ак болыт сыман култыклап тугай юлыннан килә ята...

Канәгать бабасы турында уйланды. Гаҗәп кызык кеше икән бу "Чишмә Башы" Газиз карт. Чалгы сабын сул кулының буш җиңенә бәйләп куеп, бер кул белән печән чаба, ялгызы сыер асрый, сава, сөтен аерта, маен яза, дип сөйлиләр иде—хак икән, әй. Бу кылганнар учмасын бер кулы белән ничегрәк итеп җиң очына төйнәде икән ул? Мондый чакларда ул төенне теше белән төйни, теше белән чишә, имеш. Никадәр могъҗиза, ә? Сөйләүләренчә, шул исән кулы белән арбага печән, утын, бүрәнә төйи, печән йөгеи хәтта бер ялгызы бастырыклап арканлый икән. Анысы да дөрестер—тәмам ышанды Канәгать. Якыннанрак кызыксынсаң, чабатасын да үзе тукыйдыр әле ул. Җәен-кышын буш вакытларында күрше авылларга йөреп, әйтем-мәкальләр, төрле риваятьләр, шәҗәрәләр җыя дип тә сөйлиләр иде—монысы да ырас икән. Әй, бу өлкәннәр!.. Авылда Газиз карт турында нинди генә сүз йөретмиләр! Анын хатыннан уңмавы турында да сүзләр ишетелгәли. Шул ук Җидегәндә менә егерме ел инде бер килеп, бер китеп йөри, тагын да шул яман телләр сөйләвенчә, ни ашатмый, ни яшәтми торган хатыны да бар, имеш. Әйе, өлкәннәр халкын аңлап бетмәссең, аларның күңел ишекләре Канәгатьләр ишеге кебек чыбык белән генә бикләнми шул. Аларның йозак эчендә йозак, тозак эчендә тозак. Ә менә Газиз бабасының күптән түгел дөньяда бер мөслимә артыр дип күрше чуаш авылыннан хатынлыкка бер чуаш хатынын алып килүе чыннан да дөрес. Дөресендә дә чын. Аларны бергә моннан берничә көн элек авыл лафкасында Канәгать үз күзләре белән күргән иде. Авылда "Татардан хатын табалмаган Газиз" турында чираттагы мәзәк чыккач, бабалары, имеш, чуашлар чукынмаган халык, алар шул ук төрки-татар, дип җавап биргән, имеш. Газиз бабалары чуаш хатыны белән никах укыткан, имеш. Барысын да белә бу халык, белмәгәне юк бу халыкның!..

Йөгергән уңайга малай "Безнең авылда нинди кешеләр бар!" дип горурланып куйды. Канәгатьләр буыны алар кебек нык һәм максатчан була алырмы?

Өязе ярлары җәясеннән ук булып атылып чыккач та, Канәгать алдында ике яктан да таулар култыклап алып барган тугайның иркен күренеше ачылды. Малай тыны кыса башлаганчы чапты-чапты да, туктап, инәсен көтте, хәле беткәнче чапты-чапты да, туктап, инәсен көтте. Шулай итеп үтәсе юлы да сизелмичәрәк үтә торды. Кайчандыр сугышка кадәр киндер ашы, җитен чәчелеп, чөгендер, суган, мал тормасы утыртылып, үзендә дөрес чәчү әйләнеше саклаган җир, сугыш һәм анардан соңрак чорда чәчелми торып нәселсезләнгән, әле булса нәкъ сугыштан чыккан кешеләр кебек аншайган, урыны-урыны белән үзен урман кебек басып киткән кырлы курай, ат кузгалагы, әче гөрләпәләр, тагын да әллә ниткән эт әчәгеләре, билчән, кузаклы һәм кузаксыз, күзәнәкле һәм күзәнәксез үлән-үсемлек ишараты коллыгында кыргыйлашкан халәттә гомер сөреп ята иде...

Тугайны мең төрле үсемлекләрнең һәм чәчкәләрнең куе хуш исе биләгән.

Тынына шушы хуш исләр капкан Канәгать бары тик аска—аяк астыннан артка сүтелгән юлга карап йөгерде дә йөгерде. Ул җирдә йөкле һәм йөксез кырмыскаларны, купшы күбәләкләрне, үз борындыкларына качкан әкәмтөкәмнәрне күрмичә узып китте дә, туктаган, инәсен көткән арада, аларны кулларына алып, сыйпады, иснәде һәм кеше телендә әңгәмәләште.

Менә юлны урталай кисеп, саран гына саркыган суы белән җирне чиләндереп яткан Тукмак Кулы чишмәсе аша чыккач, юл тауга таба үрли башлады. Канәгать тагын да артка борылып карады: ак төенчекле инәсе әле тугайның уртасына гына җитеп килә икән. Ул, үзен сынап, тауга бер тында йөгереп менү бурычын куйды: менә алса—егет, менә алмаса—җебек.

Ерак арага йөгерә торган йөгерешчеләр кебек терсәкләрен ян-якларына җәпләп очлады һәм "һу!" дигән аваз чыгарып тирән тын алды да тауга үрмәли башлады. Аның белән бергә күкрәгендә леп-леп килеп мидалы да үрмәләде.Ул юлдан читкә карамаска тиеш. Караса—уй бүленә. Уй бүленсә—кәеф үзгәрә. Кәеф үзгәрсә—теләк үзгәрә. Теләк үзгәрсә—хезмәт үзгәрә. Менә аның тыны кыса башлады. Юк, ул тиз генә бирешмәячәк. Тагын йөз адым. Йөз ыргылыш. Тыны тәмам кысты. Юк, ул болай гына чигенмәячәк. Малай күз кырые белән генә офыкның читен сирпеп алды—әле тауның өченче, соңгы артылышы үтелмәгән дә. Тыны кысуын онытырга тырышып, ул Өязенең башта гади генә чишмә булуы, аннан аңа Аюлы Кул, Тумак Кулы, Әнәч Кулы чишмәләре дә кушылгач, океанга әйләнүе турында уйларга тырышты.

Малай алга, юл артка шуышты. Гүя алар сабантуйда аркан белән тартышалар иде.

Ун ыргылыш. Тагын ун ыргылыш.

Тирләгән йөзен, чәчләрен сафландырып җиләс җил исте.

Туктады. Карашын юлдан күтәрде. Күзләрен ачты.

Канәгать тауга менеп җиткән һәм кызыл ыштаны белән аның түбәсенә кызыл әләм булып кадакланган иде.

Ул ат юлыннан чыкты, тауның чокәймәле үзәгенә басып, карашын еракларга-еракларга юнәлтте—аңардан дистә чакрымнарда офыклар ачыла һәм бу офыклар боҗрадан боҗрага күчеп алышына иде. Кайдадыр сулда—Смородин, Олы Кәркәле, турыда—Таукай-Гәйнә, Тәтер-Арыслан, уңда—Хлебороб, Корманай, Кыргыз-Миякә, артта—Өязебаш, Өршәкбаш-Карамалы, Әнәч авыллары, аларны уратып алган карурманнар, елгаларкүлләр аша карашын ерак-еракларлардагы Ырымбур тарафларыннан үзенә таба түгәрәктән-түгәрәккә тарайтып, кечерәйтеп килде-килде дә, туган авылы Колтамакта тукталып, тирән итеп тын алды.

Аның өчен Җирнең кендеге нәкъ шушы Колтамакта иде.

Әнә шул кендектән чыккан һәм яшел яланнар аша нечкә генә тасма булып сузылган юлдан кулына ак болыт кебек тоткан ак төенчегендә алга-артка атынып, шушы түгәрәк дөньяның хуҗасы булган инәсе—җыйнаклардан да җыйнак, тыйнаклардан да тыйнак, уймаклардан да уймак, матурлардан да матур инәсе килә.

Болар барысы да Канәгатьнең байлыгы иде.

Аның күкрәген сихри хисләр биләп алды.

Ул кулларын җәйде һәм Колтамактагы Миңлегазиз бабайлары ишетелерлек итеп кычкырып җибәрде:

—Әс-сә-лам-әга-ләй—ке-е-ем!..

Җавап бирүче булмады.

Нинди иркен, нинди кин, нинди матур иде аны тудырган-үстергән Туган Иле!..

Бераз гына түбәндәрәк кемдер нәзек кенә итеп сызгырды.

Тирә-ягында беркем дә юк иде.

Сызгыру башка тарафлардан да кабатланды.

Малай бар гәүдәсе белән очлыкүзгә әйләнде.

Ни күзе белән күрсен, йомраннар, берсе нәкъ ул килгән юлның читендә, икенчесе алар белән ике арада, нәкъ кеше, нәкъ Канәгатьнең үзе кебек, юк, дөрес түгел, намазга азан әйткән азанчы картлар сыман, кул яссулары

белән колак яфракларын ышыклап, тегендә һәм монда арт аякларына басканнар да, йомраннар, якты соры йомраннар, гүя малайның үзенә үк сызгырып, үзенә үк исәнлек авазы салып, бер-берсе белән хәбәрләшепме хәбәрләшеп маташалар!

"Биредә йомраннар ятуы икән".

Форсаты һәм янында дуслары булган булса, ул элеккечә, гадәттәгечә, елгадан су ташып, аларны ояларыннан гөргеләп чыгарган, әһ дигәнче тунаган һәм тиресен иске-москы, сөяк-санак җыючы Суфиян бабаларына тапшырып, ун тиен акча да юнәткән булыр иде.

Бу йомраннар да аның байлыгы иде.

Канәгать ике бармагын авызына тыгып, әче итеп сызгырып җибәрде.

Йомраннар шундук гаип булды.

Тагын сызгырды. Аскы теш казнасының алдагы бер сынык теше күренеп калды. Аны быел кыш таудан чана шуганда баганага бәрелеп сындырган иде ул.

Талгын гына җил исте. Дала тирбәлеп алды. Канәгатьнең шәрә балтырларын нәрсәдер, бая елгадагы вак балыклар сыман, кытыклап куйды. Малай еракларга түгел, үзе басып торган түгәрәк даирәгә, үзе яшәп азапланган түгәрәккә илтифат итте һәм үзенең ачышына таң калды.

Әнекәйгенәм!

Таулы дала бер офыктан икенче офыкка Газиз бабасының буш җинсәсендәге миллионлаган көмеш учмалар белән кыйралып тирбәлә иде!

Кылганнар чәчкә аткан!

Синең бәрәңге чәчкәләрең генә нәрсә ул!

Биек нәселле, эре төпле кылганнар арасыннан башы белән генә калкынып күренгән малай үзен бер караганда аксыл-яшькелт, икенче караганда тулаем аксыл-куе яшел, өченче караганда яшькелт-соры көмеш булып дулкынланып, тирбәлеп, алга, аннан артка мәтәлгән, бер-берсен әбәкләп куышкан, сөеп һәм сөешеп, алга йөгергән, аннан артка чигенеп чайкалган диңгездә итеп хис итте.

Бу дала диңгезе сабын күбеге белән күбекләнгән иде.

Түгәрәк-түгәрәк сиртмәләр белән сиртмәләнгән, бөҗралар белән бөҗраланган, бөдрәләр белән бөдрәләнгән нәзек кыллы мамыклардан йомшак нурлар ургылып-ургылып чыга да, кылган очларының мамык каурый, әтәч койрыгы сыман солтаннары барлык тарафны сабын күбеге белән күбекли. Сабакларның астагы һәм өстәге буыннарыннан боргаланып-сыргаланып күтәрелгән, як-якка бүселеп чыккан йомшак-зәңгәрсу кыллар, солтаннар, чуклар, калфаклар, чачаклар көмеш рәшә булып бар тарафларга чайкала. Бу солтаннарны, бу чукларны, бу калфакларны кызлар нигә чәчләренә каламый да, нигә алар белән чәчләрен чачакламый икән? Хәтерлерәк булырлар иде. Аларның да чәчкә аткан кылганнарны күргәннәре юктыр әле!

Сабаклардан як-якка ниндидер сөрмәле сызык булып суырылып чыккан нәзек кылларны кояш якты бәрхет чүкечләр белән чүкегән дә, тамчылы нурлар, алтынсу зәркән, көмеш нәкыш белән каеган. Нурларда төсләрен үзгәртеп, бу зәркәннәр әүмәкләшеп уйнаклый, күзгә күренмәс төсләрдә бер-берсенә кагылып зеңлиләр, чеңлиләр иде!

Кызык икән бу дөнья дигәнең! Бер бөгәле икенче бөгәл эченә керә дә утыра. Чәчкә аткан бәрәңге бөҗрасыннан чәчкә аткан кылганнар бөҗрасына кереп чумарга бер адым икән! Кем уйлаган?! Менә сиңа Җидегәнгә сәяхәт!.. Сәяхәт булды бит инде, хәзер кайтса да була!..

Шушы көмеш моңнар, шушы көмеш сөрмәле кыяклар, җепселләр аталамы чәчкәләр дип? Кылганнарның чәчкәләре кая? Кая бу чәчкәләрнең таҗлары? Таңда яшәү мирасы алып килә торган чыкларны тотыра торган күңел савытлары кая?

Канәгать үзе дә сизмәстән куллары белән кылганнарны өерелдерде. Кыяк кыякка, зәркән зәркәнгә кагылып зеңгелдәде. Иелеп иснәп карады— кылганнар коры дала, бераз гына сусыл тамыр исеннән башка бернинди ис белән дә аңкымый иде.

Шулчак малайның кылган чәчкәләрен кемгәдер бик тә якын, бик тә якын кешесенә бүләк итәсе килеп китте. Инәсенә! Инәсенә, әлбәттә! Йөзе житдиләнеп калды. Сәбәбе дә бар икән шул. Аның бит әле инәсенә бер тапкыр да чәчкә бүләк иткәне юк икән. Шулай да бу гына аз тоелды. Инәсе бит аның янында, янәшәсендә! Аның чәчкә бүләк итәрлек берәрerактагырак якын кешесе юкмы? Шулчак... теге, аннан бер генә партага алда утырган чем-кара Балкыз исенә төште. Әйе, Балкызга да бүләк итәргә тиеш ул чәчкәләрне! Иseme ничек кызык, ә? Балкыз. Аның балы бар микән ни? Малай көлемсерәде. Аның шул Балкызга гел генә карап торасы, гел генә аның белән әбәкле уйнысы, гел генә майлап тараган чәчләреннән тартасы килә. Нигә шулай икән ул?

Ул Балкызга да кылганнар гөләндәме жыярга карар итте. Теләсә чәченә такыя итеп үрер, теләсә калфак, чук-чачак итеп кадар, теләсә, Газиз бабай кебек, савытта тәрәзә төбенә куяр.

Аның йөрәге күкрәгеннән атылып чыгардай булып типте.

Ул бүләк өчен саклык белән генә капшанып һәм сыйпанып, иң матур, иң бөдрә, иң йомшак, иң сыгылмалы, иң купшы, иң көмеш зәркәнле, тагын да әллә нинди "иң-иң" нәрне өзеп карады. Әмма сабаклар сүс тегәрҗеп кебек ныклы булып чыкты. Өзелеп бармый иде алар. Алар сыек сынлы, тыштан мамык кебек йомшак күренсәләр дә, эчтән ифрат та үзәкле, нык, каты бәдәнле, һич кенә дә бирешмәс жан икәннәр. Малай аларны сабакларыннан бер омтылышта сындырырга итте. Эш болай да барып чыкмады. Ниһаять ул сабакларны-солтаннарны сул кулы белән өстән тотып, уң кулы белән астан "черт" итеп кенә сындыра башлады. Озак та үтми аның күкрәге ниндидер сабырлык белән тирбәлгән көмеш солтаннар белән тулды. Ул жыелган гөләндәмне икегә бүлде һәм шул ук кылганнарның үзле сабаклары белән божралатып бәйләде. Ике кулында ике гөләндәм барлыкка килде.

Шулчак сискәнеп, тирә-якка колак салды. Гүя кемдер аны күзәтә иде. Кылган төпләре мең төрле авазларда чекерт-чекерт килеп чекерти, зеңгелди, зенли, сайрый, сыкрый, гөрли—жырлый икән! Ходайның йөзләгән төр үләннәре, үсемлекләре һәм чәчкәләре, йөзләгән төр чикерткәләре, кетнәкичләре, үрмәкүчләре, күбәләкләре, кырмыскалары, нечкә билләре, энә караклары—барысы да, барысы да нәкъ укытучы Гаяз абыйлары кебек нечкә билле мандолиналарда уйный һәм кояшлы гомерен кичерә икән!

Бу куанычтан аның йөрәге галәмгә ашты.

Ул күккә карады.

Малайның алгы теш казнасындагы сынган теше тагын да кояшка күренде...

Күктә, нәкъ Канәгатьнең баш очында, өстә, бик өстә, кара нокта булып бер кара козгын эленеп алган да, кымшанмыйча бер урында тора да, тора. Ул шаккатты: аны күзәткән бу козгынны күк гөмбәзендә гүя ниндидер бер чит көч тотып тора. Гүя ул бар дөньяны үзенә карату, алдау өчен мәңгелек тирән уйда йотылган. Аңа киләчәкнең барысы да билгеле, шуңа күрә ул юк-барга илтифат итеп вакланып та, канатларын кымшатып та маташмый. Гүя бу Козгын аша исемсез, яшерен, кара битлек кигән кемсәләр Канәгатьләр әле ишетеп тә белмәгән ерак Парижлар, Нью-Йорклардагы акча биржалары, караңгы бүлмәләрдән пышын-пышын килеп, шушы миллион Канәгатьләрнең генә түгел, миллион йомраннарның, кылганнарның, барча үләннәрнең һәм тере жаннарның язмышларын, аларның бәхетле, йә бәхетсез булачагын алдан ук хәл итә иде...

Малай янадан күккә карады.

Козгын урынында иде.

Гүя шушы козгын кыяфәтендәге гыйфрит, иреннәрен чатнатып ураза тоткан инәләрен һәм аларның бердәнбер гает бәйрәмнәрен урларга килгән...

Аның инәсен тиз генә житәкләп кире өйгә алып кайтып китәсе килеп китте.

Әмма ул тыныч, шөбһәсез һәм...шунысы кызык, бу козгыннан һич кенә дә курыкмый иде. Әйтерсең, ниндидер икенче бер көч аңа ышаныч өсти

һәм бу ышаныч аның мангаеннан нурлар булып нурланып чыга.

Көтелмәгән бу борчылу аның ашказанынын тегермән ташларын әйләндерде. Өзелеп-өзелеп ашыйсы килеп китте. Кылганнар арасында тамак ялгарлык бернинди үлән әсәре—кымызлык, кузгалак, балтырган, сарана, җиләк сыман нәрсә күзгә чалынмады. Тау кырлачында аларнын булуы мөмкин дә түгел иде. Ул кылганны төбеннән үк өзде. Сытылып яшел сөте чыкты. Тәмләп карады—үлән сөте төче баллы иде. Аның янәшәсендә сарут һәм кылган кыякларыннан, үлән төкләреннән талгын искән җилләрдә аксыл серкәләр оча, алар берьюлы тын алып, дулкынланып, баллы җил, баллы дулкын хасыйл итә һәм ашау теләген тагын да көчәйтә иде.

“Тизрәк Җидегәнгә,—дип уйлады ул.—Анда кунак малаен кунак итми калмаслар.”

Инәсе килеп житеп киләдер. Юлга чыгарга кирәк.

Әмма аның бу матурлыктан аерыласы килмәде.

Аяк очларына басып, тау астына караш ташлады. Инәсенең сыерчыклатып бәйләгән ак яулыгы тау түбәсеннән калкына да югала, калкына да югала. Менеп житеп килә икән шул. Ике кулына да көмеш гөләндәм тоткан малай, уйнаклап алга чабып барганнан соң, кире чаптырып килеп, тәртә арасындагы инәсенә иркәләнгән колын кебек, кылганнар арасыннан саркылып чыкты да инәсенә килеп сыенды:

—Инәй, инәй! Кылганнар чәчкә аткан!..

—Ярар, атса,—диде инәсе аңа карамыйча да авыр тын алып.—Әйбәт булган.

Их, шушы өлкәннәр! Бигрәк житдиләр инде. Инәсенең җавабы аны һич кенә дә канәгатьләндермәде. Ул аның икенче ягына сикереп чыкты.

—Кылганнар чәчкә аткан,—дим.—Кылганнар!..

—Сөйләмә юкны. Кылганнар чәчкә атмый. Мыек кына чыгара.

—Чәчкә ата! Аларның шул мыеклары чәчкә бит инде!..Газиз бабай дөрес әйткән! Менә!..—Малай бер гөләндәмне инәсенә сузды.—Монысы сиңа!..

Авыл җирендә туып-яшәгән анасының—яшьлекләрендә хәтта кияүләреннән дә чәчкә алу гадәтенә өйрәнмәгән авыл кызларыннан булган анасының—авызы ерылып китте. Аның күңеле өзелердәй булып нечкәрде.

—И-и-и, сабыем!—Ул көмеш кылганнар гөләндәмен кулына алды да, малаенын аркасыннан дөпелдәтеп сөйде.—Инәсенә чәчкәләр җыйган бит ул!.. Рәхмәт инде! Ә монысы кемгә?

—Монысымы? Монысы... Монысы Балкызга!..

Инәсенең йөзенә кызыллык бәрде.

—Яратасың мени?

Инде малай да пешкән алма кебек кып-кызыл булды. Ул бу сүзне тоя, тик аңламый иде.

—Кит әле, әллә нәрсәләр сөйлисең!..

—Кайтканда җыяр идең әле.. .—дигән булды инәсе юри генә.

—Анысы бит аның кайтканда, ә монысы—барганда.

—Монысын Миңзыя түтигә бирик тә, Балкызга кайтканда җыярсың.

—Юк. Кайтканда җыймыйм.

—Ул чакта Миңзыя түтигә минекен бирик тә, кайтканда миңа җыярбыз.

—Ярар.

Инәсе белән килешүенә куанган малай үзенең гадәттәге сорауларын бирә башлады.

—Кылганнарның исеме нигә “кылган” икән ул, инәй? Алар нәрсә кылган? Ә нигә “кылмаган” түгел? Алар нәрсә “кылган” да, без нәрсәне “кылмаган”?

—Житә калды инде сиңа, хәзер башымны катырырсың. Колтамакка кайткач, Миңлегазиз абзыйдан сорарсың, яме.

Ана белән бала менә шулай чөкердәшә-чөкердәшә Өязе буйлап “Т” хәрефе рәвешендә тезелгән уймак кебек кечкенә, җыйнак өйләре, хәтта урман авызына капланып ук утырган өйләренең салам түбәләре белән дә нурланып яткан Җидегән авылына килеп керделәр.

Биредә әле чишмәлегән дә югалтмаган, елга да булып җитмәгән Өяздә ике су тегермәне тоткан кечкенә авылга кергәч тә, сулга борылып, түбән таба төшә башладылар. Кинәт аларны ләң-ләң килеп сыер имчәге чаклы зур имчәкле инә эт озата барды, тора-бара бу ләңгә ияреп, аларны инә этнең барлык нәселе—кызлары һәм уллары,оныклары һәм онычкалары, картәтәй һәм картинәйләре, кайнеш һәм кайнегәчләре уратып алып, колакны вау-вауга салды.

—Китегез, кит!—дип кулындагы чыбык белән куарга итте аларны инәсе үзалдына сөйләнә-сөйләнә.—Кара нинди хәлле, кара ничек өскә менеп баралар!.. Калхуз этләре түгел, калхузга кермәгән этләрдер болар!..

Этләр артта торып калуга колак яфракларын икенче бер илаһи шау, икенче бер бөек дөпелдәү басты. Гүя бу көч югарыдан аһылдап, лаф орып түбәнгә сикерә һәм үзен-үзе кызганмыйча челпәрәмә килә иде.

—Инәй, нәрсә дөпелди ул?

—Боларның чишмәләре шулай дөпелди. Аюлы Кул чишмәсе. Миңлегазиз бабаң әйткән чишмә менә шушы була инде...

—Барып карыйк.

—Тукта инде. Соныннан.

—Ә нигә Аюлы Кул? Аюның кулы... Әй, кулның аюы була мени?

Килеп җитүләреннән кәефе килгән малай әнисе янәшәсеннән аю кебек лап-лап атлаган уңайга шаркылдап көлде.

—Уф, бетмәс сорауларың булды инде! Ичмасам, кеше авылында тынгы бирер идең... Безнең якларда урманлы тау, үзән битләүләрен "кул" диләр. Кул аясы...—Анасы уч төбен күрсәтте.—Кул яссуы кебек ачык җир, аңладыңмы? Бу урманнарда аюлар булганга күрә "Аюлы Кул" дип атаганнар...

Инәсенең соңгы сүзләреннән соң малай күзгә күренеп үсте.

—Аюлары... әле дә бармы?

—Бар, ди. Баллы табаклар күтәреп, сине көтәләр, ди.

—Әйдә, барып карыйк!—Канәгать сикергәләп куйды.—Балын ялыйк!

—И-и-и, исәр!..

Малай рәхәтләнеп, авызын колагына җиткереп көлде.

Инәсе аны яратканга гына "исәр" ди бит ул.

Алар читән ихаталы, җил капкалы йортка җитеп килгәндә генә тирә-ягындагы бер көтү тавыкларын "көш-көш-шү"ләп, кулына болгау чүлмәге күтәреп һәм ике каш арасындагы кара төрткеле миңе белән бар тирә-якны яктыртып, бер апа килеп чыкты.

—Минзыя түтки!

—Минсылу сеңлем!

Бер мизгелгә югалып калган Минзыя түтки нишләргә белмичәрәк торды да, һушына килеп, болгаулы чүлмәген җиргә куеп, алъяпкычының арты белән кулларын сөрткәләде дә, инәсен кочаклап алды:

—Уч төбендә торып та күрешә алмыйбыз, илаһым! Исәнме-саумы Минсылу сеңлем!..

Ул елап җибәрде.

—Исәнме, Миңзыя түтки!.. Үзең дә килеп чыкмыйсың, ичмасам!..

—Исәнме, Миңзыя түтки,—диде чак кына ишетелерлек итеп Канәгать тә.

Инәсенә ияреп инәсенең тутасын Канәгать тә түтки, ди.

Түткие моңа бер дә ачуланмый. Киресенчә, бу Минсылу түткиенә бары тик ошый гына бугай.

Авыллары чынлап та күршедә генә ятса да, авыр калхуз эшендә изелеп, теләгән чакларында очрашудан да мәхрүм сеңелкәшләр кочаклашып күрештеләр һәм керфек очларындагы яшь тамчыларын күрсәтмәскә тырышып, аларны кул аркалары белән җилгә express.

Алар күрешкән-исәнләшкән арада Канәгать җиргә сеңешеп таушалган читән аша түткиләренең бәрәңге бакчаларына күз ташлап өлгерде. Башка бакчалардан аермалы буларак, боларның каракучкылланып, ниндидер бер

ятимлек белән монсуланып яткан бәрәңгеләрендә бер генә чәчкә дә күзгә чалынмады. "Йә чәчкә атканнар, йә ата да башламаганнар".

—Рәхмәт инде, Минсылу,үзең белән төпчеген-колынчагыңны да иярткәнсең. Бигрәкләр генә дә Гыйззетдин кияүгә охшаган бит әле ул, тьфу-тьфу, күзләре дә кияүнеке кебек зәңгәр, тажыраеп торалар... Кара әле, гирруй бит бу, гирруй! Күкрәгендә мидал!—Түткиләре аны йөзе белән алдына каплатып сөйде дә сөйде. Аннан инәсенә карап алды.—Юк, юк, борчылма, минем күзем каты түгел, минем күзем тими. Сөбханалла, машалла!.. Бүдәнәдән—май, ябалактан—йон, эткә-кошка тоттырма!.. Атасы гына бу көннәрне күрәлмәде, мәрхүм... Йә, нишләп урамда торабыз әле без, тиле кеше шикелле? Әйдәгез, керик!—Ул борылган унайдан бармак очы белән чеметеп кенә җирдәге болгаулы чүлмәген элэктереп алды.—Әйдәгез, өйгә!..

Алар җиргә ярым яткан капка аша үтеп болдырга күтәрелделәр.

—Йә, улым, чәчкәләреңне түткиеңә бир инде,—диде инәсе.

Канәгать ун кулындагы гөләндәмен түткиенә тапшырды.

—Бу сиңа, Миңзыя түтки!..

—И-и-и, илаһым! Рәхмәтләр инде сиңа, колынчагым!.. Кылганнар шул кадәр чачакланган мени инде? Яратам мин чачаклы кылганнарны! Нинди матурлар!.. Эш өстендә сәхрәгә дә чыгып булмый. Ярый әле бүген бригадир гает көненә дөньяларыгызны юыштырыгыз дип көн биргән иде, рәхмәт төшкере... Сез киләсе булган икән. Менә әле йорт-җиремне бераз юыштыргандай иттем дә... тавыкларыма кычыткан төеп, болгау сибеп керим әле дип чыккан идем—сез!... Рәхмәт төшкереләр!..

Түткиләре алар килгән шатлыктан нишләргә белми, туганнарын өерелтә-өерелтә дүрт почмаклы бүрәнә өйнең әллә саманнан, әллә таштан салынып акшарланган алгы ягына алып керде.

Анда җәннәт салкыны иде.

Юлдан арып килгән малайның бу җиләслектәге бүкән утыргычка утыруы белән үтереп йокысы килә башласа да, түткисенең эчке яктан чикыл-чикыл китереп чыгарган кашык-табак тавышы аны шундук айнытты, инде тагын ашыйсыны китереп эче боргалана башлаган Канәгать күз аяларын киереп бер могҗиза көтте. Менә Миңзыя түткие инәсе белән сөйләшә-сөйләшә базларының авызын ачты, лапылдап базларына сикереп төште, нииндиләр кызыл чүлмәкнен—әйе, Канәгать белә, чүлмәк кызыл булырга тиеш!—капкачын күтәрде, калак тавышлары чыгарып, тагын да чупылдый, чикылдый башлады.

Түткие сөйләгән сүзләрнең кайберләре баз авызында йотылып кала да, кайберләре өлешләтә генә ишетелеп куя. Әмма Канәгатьнең барлык күңел гамәле теге чикылдаган савытларда иде.

—Балалар исән-саулар, шөкер... Олысы трахтырда сабанчы-плугар... бәләкәйсе ындыр... (Сүзе ишетелми калды.) Җизнәң өчен... чакырткалыйлар шул... (Сүзе ишетелми калды.) Нишләсәләр дә нишләсеннәр... Сбулычлар инде...

—Чү, түтки...

—Мин болай гына бит. Баздан гына бит.

—Гыйззетдиннең пинсәсен алалмыйбыз шул. Фрунтта үлгәнлегенә ыспрафкы китерергә кушалар. Әллә һәлак булган, әллә булмаган, диләр. Пахарункасын югалтканбыз, ләбаса!.. Күчермәсе үзләрендә калмады микән ни?..

Монысы—инәсе.

Менә, ниһаять, Миңзыя түтки теге кара миң төрткесе белән дөньяны яктыртып баз авызыннан килеп чыкты. Ул ап-ак, каты ярмалы, ишелергә торган, өстенә әле үзләнеп-куерып та бетмәгән сыек каймак та салынган катыклы әлүмин савытны Канәгать алдына китереп куйды. Малайның авыз сулары килде. Катыкка тыгып куелган агач кашык унга-сулга янтаймый туры басып тора иде. "Вәт, катыгы да катыгы, ичмасам. Боларның сыерлары да бар икән. Безнеке былтыр кыш зыянлады. Аксыз калдык".

Ашарга ярый микән, дигәндәй, ул тирә-ягына каранды.

—Аша, колынчагым, аша,—диде түткие, аның алдына бер түтәрәм кара ипи дә куеп.

Катык белән кара ипине җәһәт кенә урынына менгезеп куйгач, аннан аерым бер канәгатьлек белән кикереп тә җибәргәч, бу җәннәт салкынында аны тагын йокы басты. Бер якка тәмам кыйшая, читкә янтая барган малайны инәләре шундук күреп алды.

—Габделәхәднең толыбы... Фрунтка китәрдән алда гына Яңгырчы остасыннан тектергән иде.—Ишетелер-ишетелмәс кенә әйтелгән "Габделәхәд" дигән сүзендә "б" һәм "д" авазларына ләззәтле басымнар ясап сөйләнә-сөйләнә Миңзыя түтки инде сүнеп үк барган малайга шундагы сәке сыман ятак өстенә урын түшәде. Инәсе аны күтәреп килгәндәй алып килде дә, урын өстенә салды.—Менә монысы кыска туны... Бәрән тиресеннән тектергәниек. Балалар алмашлап кия...

"Балалары бар икән,—дип уйлап алды Канәгать үзен басып барган йокысы аралаш.—Нәкъ безнең кебек икән. Без дә әтәйнең бәрән тунын алмашлап киябез бит..."

## IV

Әүвәлдә аның колагына инәсе белән Миңзыя түтки сөйләшкән нәрсәләр, баздан ишетелгәндәй, кергәләп-чыккалап алды. Алар бу Габделәхәд дигән кешенең—аңлашылуынча, ул Миңзыя түткинең ире була, күрәсең,—нииндидер "плингә" төшеп, нииндидер әмрикләр кулына эләгеп, безнекеләргә тапшырылуы, аннан безнекеләрнең аны ун елга төрмәгә утыртулары турында пышын-пышын сөйләштеләр. Кеше-кара ишетә калып, юк өчен баш китә күрмәсен, дигәндәй, Миңзыя түтки ихатага чыгып, тәрәзә капкачларын ябып, ишек бауларын нygытып керде. Алар бу тынлыкта да үз сүзләренә үзләре ышанмаган аһәң, шик-шөбһә саклап, ярым билгеле ымлыклар, пышылдаулар, күзләр һәм кашлар, ишарәләр ярдәмендә дә аңлаша иделәр...

Ниһаять малай йокының тирән упкынына чумды. Аның белән бергә йөгереп һәм чабып, тауларга менеп һәм таулардан төшеп арыган кечкенә йомры аяк чәлтерләре дә, бүген иртәдән бирле табигать көмешеннән чыга алмаган нәзек кенә бармаклы зифа куллары да, хәтта куе ат кылы кебек елтыр кара, юан чәч бөртекләре дә, күкрәгендә сары мидалы да чалшаеп йокыга талды.

Аның колагы төбендә генә үзенә чакырып дөпелдәгән Аюлы Кул чишмәсен дә, инәләре сөйләшкәнен дә ишетми иде ул хәзер.

Бала йокысы! Сабый йокысы! Фәрештә йокысы!

Көмеш моңнар! Көмеш томаннар! Якты хыяллар!

Бала йокысы кебек тирән, бала йокысы кебек нәзберек сизгер, бала йокысы кебек татлы нәрсә тагын да бар микән дөньяда?!

Менә ул тынычсызланып куйды. Нык талчыккан чакларында аякларын көзән җыера торган гадәте бар иде. Җыерчыкланып тынычсызлану йөзендә дә чагылып алды.

Бүген бик тә күпне күргән, бик тә күпне ишеткән малай саташа да, төшләр дә күрә башлаган иде...

Нииндидер өмә, имеш. Читән үрәләр. Талчыбыклары көмештән. Талларның яфраклары да көмештән. Газиз бабасы буш күлмәк җинен җилләрдә җилфердәтеп исән кулы белән казык кага, имеш. Канәгать атасына талчыбыклар биреп тора. Атасы, әйе, аның йөзен дә күрмәгән атасы, үзе хәрби димнәрүчке, гәлифи* чалбарда, көмеш талчыбыклардан көмеш читән үрә. Үргәндә талчыбыклардан көмеш яфраклар коела. Шунда ук быгыр-быгыр килеп казан кайнап утыра. Анда үтә күренмәле су, имеш. Кинәттән

---

*Гимнастер(ка), галифе (француз.)—үткән гасырның 20-80-нче елларында совет Армиясе кигән хәрби форма.

атасы өстеннән димнәрүчкеләрен сала башлый.

—Нигә чишенәсең, әтәй?—ди, имеш, аңа Канәгать.

—Бәй, сезгә ашарга кирәк бит,—ди атасы.—Чумып карыйм әле, төбендә берәр бәрәнгесе юк микән...

...Шунда ук караңгы төн, имеш. Йомры Гарифның никтуган Әгъләметдине казаннан чүмеч белән кайнар су алып жиргә сибә, жирне пешекли башлый. Газиз бабасы тагын да монда, имеш. Ул Әгъләметдинне тотып алып, кычыткан белән чактыра, имеш: "Төнлә йоклаганда башкача Жир-Ананың өстенә кайнар су сипмәссеңме? Аның тәнен пешермәссеңме?—дип әйтә, имеш.—Ул да синең кебек йокыда бит!"

Апа белән сеңел ихатага чыгып йорт-жир, бакча-ихаталарны караштырып, үз мәшәкатьләрен күреп, кергәндә кочакларында коры-соры утын да күтәреп керделәр. Учак астына ут алып, өйлә намазларын да укып алдылар.

Малай йоклады да йоклады.

Аның борынына өйнең эчке ягыннан ачык ишек аша чыккан куе тәмле ис кергәндәй итте. Бу ис аның үзәкләренә төште. Йокысының шактый тирән булганы күрә ул бу истән уяна да һәм анардан котыла да алмый иде. Бу хәләт аны тагын да саташтыра башлады. Әнә... әб-бәү!.. Ниндидер жен-пәриләр күрше малае Зәригатьне ишек алларындагы баганага бәйләгәннәр дә, каеш чыбыркы белән яралар. Шунда ук бертуган абыйсы Мөхәммәт Зәригатьнең телен сандалга чыгарып салган да, төя: "Бүтән урлашмыйсыңмы? Бүтән урлашмыйсыңмы?"

Әйе, быел язын Зәригать чолан тәрәзәсе аша эчкә үтеп, Канәгатьләрнең бәрәнге кәлжемәләрен сыпыртып чыккан иде шул. Шуның өчен Мөхәммәт абыйлары аны арбага бәйләп каеш чыбыркы белән яргән иде... Канәгатькә кызганыч ул Зәригать, бик тә кызганыч... Ул йөгереп бара, ут-күршесен коткарырга итә, әмма Мөхәммәт абзыйлары, күзләрен алартып, Канәгатьнең үзенә ташлана: " Ят әле менә монда! Ызаннарыңны күмеп бетермәгәнсең! Катыкка дип аертылган сөтне урлап эчкәнсең!..Безнең кишерне урлап чыккансың!.. "

Малай уянгандай итеп, төптән, исерек карашы белән бик төптән тирәякны сөзеп ала. Йокының вак күзле ятьмәсе аша инәсенең мөлаем тавышы саркылгандай итә. Әллә чытыр-чытыр янган учакка каршы, әллә унайсызрак утырган Минзыя түткинең тавышы начаррак ишетелә...Сөйләшкәндә ниндидер авазлар ниндидер "мба-мба"лар хасыйл итеп, йотыла, аңлашылмыйча уалып юкка чыга... Шунда ук кайсыдыр үксеп тә куя...

—Миңсылу сеңлем... Мин бит Габделәхәдне сигез ел... сигез ел юньләп күргәнем юк! Кем өчен жир сөргән дә, кем өчен кан койган ул?...М-ба... м-ба... Башта кахул жирләрен, аннан латыйш жирләрен, аннан фин жирләрен азат итте, аннан бу сугышка китте... Балалар да аталарын күрмичә үсте бит, илаһым!.. М-ба-мба...

—Синеке исән әле, Минзыя түтки... М-ба-мба... Көткәнсең—көт... Исән булса, бер кайтыр. Әнә, тере булгач, кара солы... жиде елдан да... алабута житмеш елдан да жир тырмап чыга, ди... Мба-мба...

—Без бит, Миңсылу сеңлем, кара түгел—ак солы! Ак солы! Маңгаем агындагы минем генә кара минем... Мин үзем ап-ак, сеңлем!... Безгә кешенеке...юк!.. мба-мба...—Ул тагын үксеп куйды.—Без алабута түгел—ак бодай күмәче идек!..

—Шулай да бит... Нишләргә соң...

Малайның сикереп торасы килә—тик ниндидер тимер гер аны жибәрми. Ул иң матур, иң сөйкемле булган инәсен, каш араларындагы кара миңе белән бар дөньяны яктырткан Минзыя түткиен яклап дөньяга "Юк, без кара солы түгел, без—Ак Солы, без алабута түгел—без Ак Күмәч!" дип сөрән сала, тик нишләптер тавышы гына чыкмый.

—Габделхәмид соңгы хатын Колыма дигән жирдән... мба-мба... Ун елын утырып чыккач... мәңгелеккә шунда сөргенгә калырга тиеш икән... (Минзыя түтки тыела алмыйча тагын да үксеп алды.)... И-и, сеңлем...Мба-мба... Анда

безләрне дә чакырырга ярый, ди... Барырга микән?... Мине дә, балаларны да төрмәгә тыкмаслар микән?

—Юкны сөйләмә, безнең илебез моңа юл куймас. Бармый, диме, түтки! Бармый, диме! Син ир, балаларың ата кадерен күреп үсәр, түтки... Рөхсәт ителсә, тай, ычкын, сыпыртып сал син моннан, түтки!.. Мба-мба... Колымада... алтын комы иләрсең. Алтын комы юган җирдә... моннан да начар булмас әле...

Канәгатьнең тын юлларындагы һәр төктә теге баягы татлы, ашказанын әйләндерә-тулгандыра, талак бизләрен суыра, зиһенне томалый торган хыялый серле ис тагын да янарып көчәйде. Башта ул йокы аралаш үзенең яңа, кабатланмас, кителмәгәнчә булуы белән бимазалады, аннан торганы белән үзләренеке, якыннан, касык астыннан чыккан таныш, гадәти булуына инандырды да, аннан тагын бу иснең бүген, бу минутта мөмкин була алмаска тиешле булып та булуы белән гаҗәпсендерде. Чыннан да, эчке өйнең мич арасыннан, казан тирәсеннән юл алып, авыр томан сыман идәнгә сарылып, салкын һава белән кушылганнан соң тагын да куерып, түзеп тора алмас дәрәҗәгә җитеп сагындырган ис иде ул.

Ис кенә дә түгел, бер могҗиза һәм маҗара иде.

Бу ис шулкадәр якын һәм ул аны шулкадәр ярата иде ки, әмма шунысы: никадәр якын күргән һәм яраткан саен, ул аның нинди ис, нәрсә исе булуын шулкадәр аңлата алмыйча газаплана иде.

Бу тәм, бу бәһасез ямь һәм гамь, яшәү белән үлем арасындагы урталыктан үтә торган бердәнбер гомер җебе иде. Бу җеп һәм бу тәм яралган җирдә үлем чигенә. Бу җеп һәм бу тәм күзгә күренми, телдә тоелмый башласа, иң тәүдә телнең, аннан илнең үзен үлем биләп ала. Бу җеп һәм бу тәм юлчы аркасындагы капчыкта да, кесәдәге янчыкта да, туфракта да, балчыкта да үлемсез, ул кипкән-коры килеш тә, чиле-пешле, дымлы-юеш килеш тә, хәтта кара туфракта черегән килеш тә адәм баласын үтерми саклый торган могҗиза иде... Бу ис ашказанындагы барча бизләрне кояшка күрсәтеп барлый, актара, күңелләрне били, авыз суларын китерә иде...

Малай уянды.

Күзләрен ачарга итте дә, беравыкка түзеп, ачмыйча ята бирде. Үзе өчен гадәти булмаган җылы йоннар, йомшак тиреләр арасында май кебек эреп ятуының ләззәтен озайтасы килде. Шулчак үзенең кайда ятуын исенә төшерде. Колак салды: тышта Аюлы Кул чишмәсе гөрелди, ябык ишек аша тавыклар кыртлавы, әтәчнең, адашып, кытаклап куйганы, инәләренең эчке якта һаман-һаман быдырдаганы ишетелә.

Аның тәкате калмады. Чыдамы чыгырдан чыкты. Ниһаять, танау тишекләреннән йөрәк тамырларына кадәр үтеп йөдәткән, алгысыткан һәм ярсыткан, идән буйлап ишек аша авыр, әмма нечкә, нәзек йөк булып килгән бу җанга якын, газиз, кадерле, сөйкемле исне тагын бер кат күкрәге тулганчы, тыны җиткәнче иснәде дә, тун астында киерелеп, кычкырып җибәрде:

—Бәрәңге пешердегез мәллә?!

—Әйе, колынчагым,—диде Миңзыя түткие.—Пешердек шул. Яңа бәрәңге пешердек...

Өстендәге тунны җилгәреп ташлап, сикереп торды.

Торуы булды—башы әйләнеп китте: әйе, өй эче, аның бар почмаклары, идән, түшәм ярыклары, тәрәзә янаклары, ташкеләтне хәтерләткән алгы якның чөйләрендәге вак-төяк төенчекләр, капчыклар, кирәк-ярак әйбер, сугым элә торган тияkләр, бер сүз белән әйткәндә, һәр нәрсә яңа, әле генә пешеп өлгергән яшь, беренче бәрәңгенең күнел кылларына кагыла торган әчкелтем-төчкелтем рухияте белән сугарылган иде.

Яшь бәрәңге! Чынмы? Каян? Ничек? Мөмкинме?

Малай кызарынды, бүртенде, бер гарьлегенә, бер куанычына урын тапмый уйланды: ул әле бәрәңгеләрен күмдереп кенә килде, монда исә яшь бәрәңгене инде ашап яталар! Димәк, биредә, Җидегәндә, бәрәңгене анардан да иртәрәк өлгертүчеләр бар?!

Инәсе аны болдырга алып чыгып комгандагы салкынча су белән битен-кулын чайкаттырды.

—Әле бәрәнгене чокып караганыбыз юк иде, инәң белән икәүләп сынамакчы булдык,—диде Минзыя түткие анын алдына тәмле булар бөркеп торган яшь бәрәнгеле коштабакны куеп.—Синең хөрмәтенә! Кул артың җинел икән!.. Әйдә, кайнар килеш тамак туклык ит әле... Мин—хәзер!—Ул мич арасына кереп китеп аннан тирән җәйпегә салынган баягы сыек каймакны алып чыкты.—Менә... манып кына аша әле, колынчагым. Син бит минем туганнан туганым, син бит сеңлемнең улы!—Ул аны тагын бер тапкыр аркасыннан сөеп алды.—Син бит безнең тере Гыйззетдин кияү!..

"Боларнын чынлап та сыерлары бар икән. Ә без аксыз калдык."

Малай авыз эченнән генә бисмилласын әйтеп, азыкны менгезә башлады. Өсләрендәге күлмәк-кабыклары ныгынып та җитмәгән, шуңа күрә кайберләре казанда кайнаганда ук "чишенгән", йә булмаса ала-кола калган зәңгәр, көрән бәрәнгеләр тавык йомыркасыннан эрерәк булсалар да, чынлап та телеңне йотар дәрәҗәдә тәмле иде. Аеруча бәрәнгеләрне каймакка манып ашагач!..

Сусыл, йомры бәрәнгеләрне төелә-төелә тамагына озатканда гүя ана кемдер нидер пышылдагандай булды. Малай югарыга карады. Анда кырып юган сары түшәм генә икән. Бернинди күк тә, козгын-фәлән дә юк. Якгына каранды. Тик нишләптер табында... ул берүзе генә иде. Табакның төбе дә такыраеп килә икән менәтерәк. Унайсыз ук булып китте.

—Инәй... Инәй...—диде ул үзен акларга теләгәндәй мышкылдап.—Утырыгыз инде... суына бит...

"Бәрәнге бетә бит", димәде, "суына бит" дигән булды.

—Без бит уразада, улым...—диде әнисе чак кына ишетелерлек итеп.—Аша, аша, безнең өчен борчылма...

Малай гарьлегеннән телен тешләде. Әй, шулай бит әле, тишек баш. Инәләре уразада бит. Ана арт яклары белән утырып алганнар да, берни булмагандай, кипкән иреннәреннән ялкын коя-коя, куначадагы күгәрченнәр кебек гөрләшәләр дә гөрләшәләр. Табактагы бәрәнгедә генә түгел, мона кадәр булса, ун мәртәбә янартылып эчелә торган һәм әле дә бары тик кунак малае өчен генә үкереп кайнап утырган самавыр да кирәкми иде аларга хәзер.

Ниһаять, Канәгать тамак туклык итеп, аерым бер канәгатьлек белән амин тотты. Анын үз гомерендә бу кадәр тәмле бәрәңге ашаганы юк иде әле.

Кинәт лепкәсеннән нур ташкыны ургылып чыккандай булды. Болай булганы юк иде әле. Тамагына ниндидер төер тыгылгандай итте. Йотып җибәрергә теләп, урынында калкынды да, бөек бер куркуга төшкән һәм илаһи нурга уралган төс-кыяфәт белән йөгереп килеп инәсен кочаклады:

—Инәй!... Инәй, дим!..

—Нәрсә булды, балам?—диде ана шөбһәгә төшеп.

—Мин дә синең белән ураза тота башлыйм!..

—Кара син аны, рәхмәт төшкере!—диде Миңзыя түткие куанычын кая куярга да белмичә.—Хәерле сәгатьтә, колынчагым!..

—Нәрсә, бер-бер хәл булды мәллә?—дип сорады инәсе әле һаман да төшенеп җитә алмыйча.—Берәр яман төш күрдең мәллә?

—Төш тә күрдем... Тик яманын яман түгел. Әтәй бәрәңге эзләп суы кайнап утырган казанга чумды...

—Тәүбә-тәүбә, балакаем, ни сөйлисең син? Төш—убыр, ди, түтки, әллә Гыйззетдин исән микән?! Гает намазыннан соң, атап хәер бирергә кирәк...—Инәсе улына сиздермичә генә түткиенә баш какты.—Каян килә сина мондый уйлар? Ураза тәмамланып килә бит инде... Гает намазына бер генә көн калды, ләбаса.

—Калса ни. Бер генә көн булса да тотам. Бүген кич синең белән авыз ачам да...

—Ярар, улым, ярар. Бергә авыз ачарбыз...—Күзләре дымланган инәсе

киң итеп елмаеп җибәрде.—Ходайга рәхмәт, синең нигезеңдә балама иман керде бит, түтки!... Синең тупсаңда!.. Яңа бәрәңгең белән!...

Канәгатькә рәхәт булып китте. Аның күзләренә яшь тамчысы бәрде.

Күзләре яшәреп очкынланган Миңзыя түтки куанычыннан ни әйтергә дә белмичә, теленә килгән бер сүзне тәкрарлады:

—Ә син бездә кал, Канәгать! Минем өч улым бар! Уйнарсыз, төнлә лапас башындагы куышта кунарсыз!.. Әкиятләр сөйләп!.. Йолдызлар санап!..

Ул елмаерга итте. Әмма бу елмаю авызы читендә катып калды.

Әйе, як-якларына канатлар үсеп чыккан Канәгатьнең уенда хәзер Җидегәндә калу түгел, тизрәк Колтамакка кайту иде. Ул үзен бик тә көчле тойды. Аның күз алдына үзләренең калтайган такталы капкасы, җимерек ташкеләте, җимерек кар базы, авып-түнеп барган лапаслы абзарлары, келәсенә чыбык тыгып киткән өйләре килде. Аның тәрәзә аша кош булып очып чыгасы һәм барлык туган авылларны йорт почмакларыннан күтәреп, урамнары-урамнары белән тагын да матуррак, тагын да иркенрәк, тагын да яшелрәк—беркайчан да бернинди пычрак, бернинди нәҗес алмаячак урынга күчереп утыртасы килде... "Без үлә торган халыкмы?—дип кычкырасы килде аның галәмгә.—Без—үлемсез халык!"

—Инәй, кайтабызмы?—диде малай, хәзер үк өзелеп кайтасы килеп.—Кайтыйк инде!..

Моннан биш чакрымда гына аның Ватаны, тарихи Ватаны бар иде. Ул чынлап та биш чакрымда торып калган туган нигезен, каен чыбыгы тыгылган ишеген, газизләрдән газиз Ватанын мәңге күрмәгәндәй сагынган иде. Аның күкрәге нур белән тулды. Бу нур аны киң галәмгә чакыра иде.

—Менә хәзер, түтки белән үзебез алып килгән мамыкны гына караштырып алабыз да... Бар, булмаса, урамга чыгып йөрештер...

—Аюлы Кул чишмәсенә барып киләм?

—Бар, бар. Тик урманнын эченә керәсе булма, яме.—Әнисе ярымшаяртып өстәде.—Анда аюлар бар.

—Коштабакларындагы кәрәзле бал белән мине көтәләр, әйеме?

Малай урамга чыгып ычкынды.

Аны чишмәнең колак тондыргыч симфониясе каршылады.

Инде менә юл таягы кебек туры, төзек, көн чилләсендә янган, какча, каракучкыл, иптәшләре шуңа күрә дә "кырмыска" дип йөреткән малайның гәүдәсе баюга таба барган кояшның нурлары астында сорау билгесе сыман шәүлә калдырып, түбәнгә, колак яфракларында галәмнәр шавы булып яңгыраган Аюлы Кул чишмәсенә таба җилдерде.

Аның белән бергә кызыл ыштан да һәм күкрәгендә "Безнең эшебез гадел, без җиңдек" дип язылган бакыр мидал да җилдерә иде...

*Азнакай, Чалпы.*
*март, 2003.*

# ТЕГЕ МАЛАЙ

*"Әлифба" китабы авторлары—*
*Рәмзия апа Вәлитова һәм*
*Сәләй җизни Вәгыйзов истәлегенә*

Малай уянды.

Күзләрен ачыр-ачмастан колак салды: четерт-четерт... черт-черт... четерт-четерт... черт-черт...Яна икән. Ул белә: тузлы каен утыны гына шулай четертәп яна. Инәсе мичне ягып та җибәргән икән. Тан

аткан, күрәсең. Юк, атып житмәгән шикелле. Кургаш кебек авыр күз кабакларын көч-хәл белән берсен-берсеннән аерып, Канәгать керфекләрен күтәрә төште һәм йокылы карашын тәрәзәләргә ташлады. Аз булса да суыктан, ярсу җилләрдән саклар дип, төнгелеккә ябыла торган капкачларның ярыклары аша өйгә таң яктысы саркылмаган иде әле. Озакламый, менә-менә сызылачак ул якты. Батачак төн белән атачак таң арасы шулай сизелмәстән, күз ачып йомганчы алышына да куя. Мич авызыннан төшеп стеналарда уйнаган ялкын шәүләләре урынында оеп яткан малайның сул күз кырыенда чагылды, колагына инде гүләп яна башлаган мич алдыннан пышын-пышын сөйләшкән авазлар шәйләнде.

Шул инде, шул. Мәрфуга түтиләре кергән. Тулы исеме Гөлмәрфуга. Инәләренә ияреп, алар да Мәрфуга диләр. Инәсенең әхие, җан дусы, димәк. Мондый әхирәт дусларны бу якта шулай кыскартып "әхи" генә диләр. Алар өйдәш хатыннар кебек гел бергә.囗Эштә дә, аштa да. Көненә берничә мәртәбә очрашып, чөкер-чөкер килмәсәләр, аларның халыкта "Минсылу Мәрфугада, парлап бара суга да",—дигән даннары да таралмаган булыр иде. Хәер, ике ихата аша гына гомер иткән бу ике гаиләне бергә, бер гаилә булып яшиләр, дип тә әйтеп булган булыр иде, әгәренки хуҗалыклары аерым булып, салымны аерым, "җан башыннан һәм мал башыннан" түләмәсәләр. Минсылуның өч, Мәрфуганың ике сугыш ятиме—барысы да балтырган ашап үскән бәләк кебек тыгыз малайлар—кайчагында кайсыларында уйнап "котырсалар", шул йортта кунып та калалар. Күрше малайлар кичәге кичке суыкта тышка чыгып йөрмичә, үзләрендә кунып калганнар да, инәләре исә, менә таң атар-атмастан, караңгыда күзен тырнап, хәл белешергә, авылда төн эчендә булып өлгергән яңалыкларны уртаклашырга кереп тә җиткән...

—Әйкәем!.. Гыймранның "Теге Малае" кайтып төшкән, ди...

—Сәфәргали мени? Кит аннан!—диде инәсе.—Авылыгызга төкермим дә дип чыгып киткән иде, тәки кайткан диген, ә?

—Әйе, җиде-сигез ел чамасы кайтмаган, ди, әйкәем.

—Шул чама бардыр шул. Болай да мактанчык Гыймранның бүресе улый икән болай булгач. Бай кайткандыр инде... Аны бит әрмедә макарун*га калган, дип сөйләгәннәр иде.

—Макарун? Анысы кем тагы-ы-ын?—диде инәсе сузып.—Әллә нәрсәләр беләсең син, әхи. Ашый торган нәрсәме соң ул?

—Ашый торгандыр инде, корсак артыннан хәрби хезмәттә калгач ,—дип Гөлмәрфуга түти бар белгәнен бушата башлады.—Әрмегә егерме биш елга ялланып, өстәмә хезмәткә калучыларны шулай атыйлар икән ди бит, әйкәем. Аларга акчаны да, без күрмәгән макарун дигәннәрен дә төяп бирәләр, ди... Мактанчык Гыймранның былтыр печән өстендә сөйләп торганын үз колакларым белән ишеттем, әйкәем. Теге Малайдан хат килде, ди бу, макарунга калдым, ваянныйлардан ваянныйларга акча, сикрит пушты ташыйм, тамак тук, өс бөтен, мул яшим, мул ашыйм, дип язган, ди. Кигән киемем күн дә хыр-рум, командирлар белән бергә дваятажный* йортта тор-рам, дип язган ди. Теге Малаеның авылда йөреп киткән кызы Гөлчирәгә ишеттерсеннәр дипме шунда, ярманы бик эредән ярдырды Гыймран. Теге Малай: "Авылга кайтып булырмы-юкмы, өйләндем, исеме Мәрия Мәкәриевна, бик тә кулютурнай хатын, ата-анасы бик бай кешеләр, бакчаларында ун төрле йөзем, әфлисун, хөрмә, алма агачлары сыгылып утыра,"—дип язган ди бу...

Малайның авыз сулары килде.

—Бай кайттымы икән соң?

—Анысын ук белмим,—диде Мәрфуга түти.—Шул маржасы белән кайткан, ди.

—Бай кайткан инде, алай булгач. Гыймран ерылган авызын җыеп та

* Макарон (итальян.) – суыртылган бодай оныннан ясалган камыр азыгы. Макаронник (жаргон) – совет заманнарында өстәмә хәрби хезмәткә калучыларны шулай атыйлар иде.

* Двухэтажный – ике катлы.

алалмыйдыр инде... Кара әле, әхи, синең шул макарун дигәннәрен ашап караганың булдымы? Нindirәк нәрсә икән ул?

—Юк. Нindiдер бик шома итеп ясала торган тишекле тукмач дип ишеткәнем генә бар.

—Алай булгач, Теге Малай аны вагуны белән апкайткандыр инде, әйеме?

Канәгатькә болар житә калды. Аның тирә-ягын елтыр кәгазьләргә төрелгән йөземнәр, әфлисуннар, хөрмәләр, алмалар, манпачилар, кәнфитләр, беренче тапкыр ишеткән һәм, уйлавынча, тәмле, бик тә тәмле булырга тиешле маржалар, макаруннар биләп алды. Аның фикеренчә, Теге Малай бу кадәр азыкларны ваянный машиналарга төяп алып кайткан булырга тиеш иде...

Канәгатьнең бер генә минутка ди кичектермичә Теге Малайны күрәсе һәм аңардан үзенең кайтуы хөрмәтенә сөенче күчтәнәче аласы килде. Әйе, бар алар ягында кайткан кунак куанычыннан сөенче алу йоласы. Сөенчене хәбәр иткән кешегә—балаларга инде аеруча—беркем караңгы йөз күрсәтми, киресенчә, куанычыннан нишләргә белмичә, татлы ризык, тәм-том белән рәхмәтли.

Теге Малайларга барырга кирәк!

Ул шундый карарга килде.

Йокысын куып, кат-кат киерелде.

Моның өчен барлык гадәти һәм гадәттән тыш сәбәпләр дә бар иде.

Беренчедән, аның Теге Малайны күрәсе килә. Моның гаебе бармы? Юк. Күрергә тиеш. Әйткән-беткән. Теге Малаен авызыннан да төшермәгәне, аның хәрби хезмәттән язган һәр хәбәрен халыкка түгәллек, алай гына да түгел, хәтта күпкә арттырып, күпертеп житкереп торганы өчен авылдашлары моңа кадәр "Мактанчык Гыймран"дип йөртелгән Гыймранның инде үзен дә "Теге Малай" дип атый башладылар. Теге Малайның дәрәжәсе, атасы сөйләвенчә, генералдан да ким булмаска тиеш. Бу макаруннар һәм генераллар ничегрәк киенә, сөйләшә икән? Югыйсә, Гыймран бабай, язын һәм көзен, жәен һәм кышын, урамда һәм ындыр табагында, урманда һәм яланда, капка төбендә һәм кәнсәләр каршында нәзек кенә итеп махрасын төреп авызына элә, дөньяга күркә чукышы сыман очлы, күркә кикриге сыман кызыл танавы буйлап карар һәм кәефе килгән саен черек тешләре аша "черт" тә "черт" төкерек сиптереп һаман да шул бер сүзне сөйләр: "Теге Малайдан хат килде. Ай-бай, бик кирәкле кеше булгач, Теге Малайны урыннан урынга күчереп кенә торалар. Үзе дә ничек өлгерә, диген. Кичә генә Вәрүниждә иде, бүген Мәскәүнең үзендә хезмәт итә..." "Теге Малайның командирыннан хат килде. Маладис, әтис, выстафка кебек малай растили, дигән. Ваш сынук так харуш, так харуш, нихту такы ни харуш, дип тә өстәгән..." "Теге Малайның хәбәре бар иде әле... Монысын Владивәстүктән язган, шайтан алгыры. Һич кенә дә бер урында тотмыйлар үзен. Ә кәкже? Учениеләрдә беренче урынны алган өчен маршал Жуков Теге Малайны сәгать белән бүләкләгән бит..."

Кыскасы, авыл Теге Малайның һәр адымын, һәр тын алышын Теге Малайның үзеннән дә алдарак белеп, сизеп тора иде. Шуңа күрә ул беркатлы авылдашлары, бигрәк тә, тизрәк үсеп житеп, Теге Малай кебек булу турында хыялланган малайлар өчен бер әкияти каһарманга әверелгән иде. Шуңа күрә Канәгатьнең Теге Малайның үзен күрергә хыяллануы һәм, һич кенә дә икеләнмичә, аларга барырга карар итүе, бик тә табигый, бик тә дәрәжәле бер адым буларак бәяләнергә хаклы иде.

Мондый катгый адым өчен икенче бер хәлиткеч сәбәп тә бар иде шул. Бу инде Канәгатьнең үз нәфсесенә кагыла. Ул бүген якшәмбе—ял, мәктәп эшләми торган көн икәнен искә төшерде. Чырае караңгыланып алды. Аның әле бер тапкыр да кимәгән, дус малайлары, авылдашлары күрмәгән яңа чабаталары бар бит. Дөресен генә әйткәндә, кичен йокларга яткач, әле Теге Малайның кайтып киләсен бөтенләй белә дә алмаган Канәгать, моны алдан сизенгән кебек, иртән торгач, яңа чабаталарын ничегрәк киярга, тулаекларын ничегрәк сыдырып салырга, аларны кешелек дөньясына ничек

матуррак итеп күрсәтергә дип планнар, хыяллар корып ята-ята йокысын качырган иде. Ул төне буе уяулы-саташулы булып, төшендә сарык бәрәнедәй ап-ак, йомшак тулаекларын бер астан, бер өстән сыдырды, балавыз кебек сары, яңа чабаталарын нәзек, нечкә киндерәләреннән бер бәйләп, бер чиште, бер киде, бер салды...

Яңа чабата кию—Канәгать өчен үзе бер зур бәйрәм. Өлкән абзыйсы Ташкент якларына бәхет эзләп чыгып киткәч, ана чабата ясаучы калмады. Уртанчы абзыйсы чабаталарны үзе өчен генә тукый да, алар тәмам тузып, мыекларын маршал Буденный кебек тирә-якка җибәреп чачаклангач кына бирә энекәшенә аякларыннан салып. Әле ул абзыйсы сәкенең үрге очында өстенә чүпрәк палас ябынып, мышный-мышный йоклап ята. Инәсе Канәгатькә чабаталарны Галимулла бабасыннан ясата. Бер дистә йомырка—ике пар чабата. Галимулла бабасы аңа чабаталарны вак атламлы, солдатлар кебек тигез рәтле итеп тукый. Аннан, кулдан сатып алынган чабаталар бөтенләй икенче төрле матур була бит ул, җәмәгать!..

Күрсен Теге Малай, күрсен бар авыл Канәгатьнең яңа чабаталарын!..

Әгәр бүген, якшәмбе көнне дә күрсәтмәсә, иртәгә—дүшәмбегә кадәр ничек түзмәк кирәк?!

Теге Малайны барып күрү, сөенчесен алу өчен әле без белмәгән өченче сәбәп тә бар иде. Монысы—Балкыз. Алар менә икенче ел инде бергә укыйлар. Балкыз әнә шул Теге Малайның сугышта һәлак булган абзасының кызы. Ни сәбәпледер ул Дим буендагы Канбәк авылында инәсе белән түгел, ә менә Өязе буенда урнашкан Колтамак авылындагы карттасы Гыймранда яши. Аларның тәрәзә төбендә Канәгатьнең үткән җәйдә Җидегән тугаеннан алып кайтып биргән кыганнар учмасы көмешләнеп утыра. Балкызның инәсе, сөйләүләренчә, ел саен ялланып китеп кайдадыр Урал урманнарында торф чыгара, урман кисә икән дә, аннан кызына матур-матур күлмәкләр, чәчүргеч тасмалар, кечкенә елтыр галошлар җибәрә икән. Шулайдыр шул. Балкыз бигрәк матур, бигрәк купшы киенә. Кайбер чакта, яңа күлмәкләрен күрсәтеп өлгермәгәч, ул аларны озын тәнәфестә дә алыштырып киеп килә. Инәсе аның янына килеп-китеп кенә йөри. Ешрак кышкы якта килә ул. Күптән түгел, ай күрде—кояш алды, дигәндәй, тагын да күренеп китте әле ул.

Балкыз инәсе Тәнзилә түтигә бигрәк тә охшаган икән. Икесе дә чутыр кебек яндырып торган чем-каралар, эре кабаклы күзле алар. Сумаладан кайнап чыкканнар, диярсең. Балкыз турында уйлауга Канәгатьнең кәефе тагын да күтәрелеп китте. Әгәр Теге Малай "Нигә килдең?" дип сораса, ул "Балкыздан өйгә бирелгән эшне белергә килдем",—диячәк.

Боларына өстәп, инәсе дә, хәтта беркем дә уйламый торган дүртенче бер сәбәп тә бар иде. Канәгатьнең әтисе—авыл мөгаллиме, сугышка киткәнче авылның барлык балаларын укыткан бит. Теге Малайны да. Аны атасына охшатып таныр микән? "Кара әле, син минем укытучым Гыйззетдин абзый улы түгелме?" диячәк ул менә, күр дә тор. Аны да бит атасына суеп каплаган кебек охшаш диләр, югыйсә.

Канәгать тагын да тәрәзәләргә күз сирпеп алды. Тәрәзә капкачы ярыклары аша таң зәңгәре саркылып керә башлаган иде. Рамнарны сарган бәс тә агарып күренә. Тышта мотлак зәмһәрир суыктыр. Ул колакларын сагайтты. Мич аралыгыннан пышылдашкан тавышлар ишетелми иде. Мәрфуга түти чыгып киткән, күрәсең.

"Вакыт!—диде малай үзенә.—Нәрсә йокы симертеп ятасың?"

Ул атасыннан калган ак тун астыннан чыгып, чирканып кына өйнең боз кебек суынган сайгакларына басты. Ул өстенә аксыл күлмәк, эчтән озын балаклы киндер ыштан, тышыннан үткән җәйдә генә үз җилкәсендә тау кырлачларында үсә торган челектән себеркеләр бәйләп, аларны иске-мосҡы жыючы Суфиян картка тапшырып, шул акчага тектергән һәм ярсу җилләрдә җилфер-җилфер килеп торган кара сатин шарабарын киеп алды. Аннан сәке өстенә менеп, спут башында песигә түшәк булып хезмәт иткән оекбаш, тулаекларын алды, сәке астыннан өф итеп саклаган, яңа акча,

затлы күн кебек шыгырдап торган чабаталарын тартып чыгарды һәм көчәнә-көчәнә киенә башлады.

Анын мыш-мыш киенүен абайлап, инәсе сагаеп калды:

—Кая жыенасын?

Малай киенүен дәвам итте.

Инде тулаекларын сыдырып салган, киндерәләрен бәйләп, тулаек бөкләме астында купшы итеп яшереп калдырган, шарабар балакларын егетләрчә тышкарак чыгарып жилфердәтеп куйган һәм, хәзер килеп, идәндә яңа чабаталарына шыгырдата-шыгырдата сынау үткәргән, монысы гына житмәгәч, эченнән такмак әйтеп, биеп тә азапланган төпчек улына инәсе мич арасында ялкынланып янган йөзен яктыртып, соравын яңадан кабатлады:

—Кая жыендың, дим? Мәскәү тарафларына... кәнсирт куярга бармыйсындыр бит?

Шулай киная белән үзәккә үтә белә анын инәсе.

Әмма Канәгатьнең әле кинаялап торырга вакыты юк.

—Теге Малай кайткан бит,—диде ул яңалыкны күптән ишеткән кыяфәт белән.

—Каян белдең әле аны?

—Ишеттем инде,—дигән булды малай эре генә.—Сөенчесен алырга барам.

—Кит, аннан! Йөремә, кысыр көек булып. Чабата туздырып!..

—Барам.

—Сөенчене бит аны кайтып килгән кешедән алда йөгереп барып алалар. Теге Малай кайткан бит инде. Хәзер өендә гырлап йоклап та ятадыр әле...

—Барам.—Канәгать агач чөйдәге малахай бүреге, кыска сырмасын алып кия башлады.—Минем Теге Малайны үз күзләрем белән күрәсем килә.

Баласының алдына алганын эшләмичә калдырмаганын белгән ана артык сүз көрәштермичә кул гына селтәде.

Канәгать яңа чабаталарының шат шыгыртауларыннан ләззәтләнеп, өй алды аша тышка чыкты. Аны тышта коры йолдызлары белән шыгыртап торган күк йөзе һәм куяннарны сикертерлек ыжгыр суык каршылады.

Атасыннан соң хужасыз калып, бер якка янтаерга да өлгергән урыс капканың туң тимер келәсен кулларын өттерә-өттерә күтәреп, ары-бире, сирәк-саяк кына тычкан утлары белән мезелдәп торган урамга чыкты, кисәк кенә унга борылды, йон бияләйләрен кия-кия көнбатышка таба атлады.

Бар дөньяның, үзен әйләндереп алган тирә-якның гамәлдә ап-ак булып, вакытлы төн караңгылыгының әлегә эреп өлгермәве аркасында , ахрысы, караңгылыкның үзеннән дә караңгырак күренә торган бер илаһи мизгеле иде.

Күк йөзендә кояш барлыкка бар, ул булырга тиеш, тик әлегә анын яктысы Колтамакка килеп житмәгән кебек.

Чынлап та суык икән шул. Читән каертмаларындагы талчыбыклар да шартлап ярылган сыман. Февральнең нәзек телле көмеш чүкече казыкларның көрт өстеннән төртке-төртке булып калкып торган очларын зифа итеп чүкеп, кар эченә сендергән. Читән ихаталар эчендәге салам түбәле, кечкенә, уенчык сыман жыйнак өйчекләрнең кайберләрендә генә элже-мелже килеп янгалаштырган крәчин утлары жемелдәшә.

Күк гөмбәзе Канәгатьнең баш очында гына икегә ярылган иде: көнчыгышы коры, көмеш серкәләре коелып торган йолдызлар белән тулган; каяндыр кылыч кебек ак чарларда чарланып чыккан ай Шәрифжан картлар күпере тапкырында туктаган да, гүя, Өязедән чыгып, Тукайның "Су анасы"н укый-укый күкнең шыгрым тулган һәм шылт та итми катып калган йолдызлы яртысын ятьмә итеп тартып бара; көнбатышы исә, әйтерсең, бары тик югары катламнарда гына яратылган жилләр-агымнар астында ниндидер фажигаи төсләргә кереп, секунд саен рәвешләрен шайтаный үзгәртеп, тагын да фажигалерәк, тагын да каракучкыл-карарак, тагын да куркынычрак сурәтле болытлар белән каплана бара...

Канәгатькә бу болытлар хәзер үк күкнең гөмбәзен басып китәр һәм

анда сыңар йолдыз да, бер караганда кылычка, икенче караганда, инәсенең алтын алкасына охшаган ай да калмас кебек тоелды. Аңа куркыныч булып китте. Читтән караганда, ак карлар өстеннән атлар салган чана юлында яңа чабаталарын сайратып, аларның сыкрау моңнарына сокланып атлаган малай гүя хәзер инде үзе шул айны һәм йолдызларны ятьмә итеп тартып, фаҗигале болытларның шайтаный авызына кереп баргандай күренә иде...

Көйдереп-көйдереп алган суыктан котылырга теләп, ул бияләйләре белән бит алмаларын капларга тырышты. Шәрифҗан карт күпере аша чыккач та, аны эре өянкеләр, меңләгән чыбыклары белән кар эченнән һавага кадалып торган таллыклар каршылады. "Балыклар кышын кайда яши икән?—дип уйлап куйды ул. Аннан үзенә-үзе аңлатты.—Боз астында, әлбәттә. Боз астында... Алар анда ничек үлми икән соң?" Аннан үзен тынычландырды: "Яшиләрдер инде берәр ничек итеп. Менә мин яшим бит.Үлмим бит."

Шушы бәләкәй Камиләләр яныннан үткәндә аның хәтерендә гел генә бер истәлек янара. Былтыр язын бер галәмәт күренешкә тап булды ул монда. Кояш җылыта башлау белән бу таллар шундук балалыйлар—сап-сары песибашлар чыгарып чәчкә аталар. Ул песибашларны Канәгатьнең күп тапкырлар ашаганы да бар—баллы алар. Шулай бер тапкыр, борылыштан үтеп барганда... караса, инде кояшта агарып, шикәр кебек эреп, җепшеп яткан кар өсте, әле генә песибашлар чыгарып чәчкә аткан таллар сап-сары булган! Аларны кемнендер кышкы баздан кояшка чыгарып куйган ач бал кортлары чормап алган! Таллар баллы песибашлар белән чәчкә атып, кортларны алдатып тора, ач бал кортлары исә алданып, ак карларга килеп егыла тора, егыла тора!..

"Исәннәр микән әле ул кортлар?—Караңгыдагы талларны күз карашлары белән капшап, ул тагын да үзен тынычландырды.—Кая китсен ди алар, исән булмыйча. Менә мин исән бит әле."

Көнбатышка таба барган, Өязе елгасының таулар белән каелган үзәненә кергән саен гүя ай белән йолдызлар артта калган, ә караңгылык көчәйгән сыман тоелды. Бу таң караңгылыгының соңгы көчәнүләре иде, күрәсең. Җәһәт адымнар белән Теге Малайларга якынлашып барган Канәгать Гыймран бабасына бәйле бер вакыйганы исенә төшереп, көлемсерәп куйды. Аны авылда мәзәк итеп сөйлиләр. Кайчандыр сугышка кадәр була бу вакыйга. Гомумән алганда эчкерсез, кешегә зыянсыз, әмма сөйләгәндә мактанырга, артыгын шыттырырга яраткан Гыймран бабалары, җитмеш чакрымлык юл үтеп, чирле үгезен авыл исәбеннән салымга дип Раевка ит комбинатына алып бара. Авыл советыннан кәгазь дә юнәтә. Баргач, карасалар, писер кәгазьгә "үгез" дип язасы урынга "Гыймран" дип язган, ә Гыймран аны укып та чыкмаган булган икән. Баксаң, анда " ...авыл советы Сәйфелмөлеков Гыймранны...халык исәбеннән иткә тапшыра",—дип язылган!..

Тәгәрәп-тәгәрәп көләләр сугымчылар, әмма суеласы малны да мондый көлке документ белән кабул итмиләр. Нишләргә? Тәртәдә килгән үгезне шул ук тәртәгә мичәүләп, кеше көлдереп, кире Колтамакка алып кайтып йөреп булмый бит инде. Арба белән өстерәлеп тә булмый. Гыймран абзагыз, җигүле атын, үгезен Раевкадагы авылдашларына калдырып торып, тиешле кәгазь артыннан башта Әкчин станцасына кадәр поездда, аннан җәяүләп кайтып килмәсенме!..

Яктыра. Яктырып ук килә. Тәмам яктырып килә икән инде. Әнә Теге Малайларның морҗасыннан чыккан төтеннәре дә шәйләнде. Күктән әле генә коела башлаган ярмалы сыкының ап-ак тукымасында тегеләр морҗасыннан күтәрелгән төтен аеруча төз, аеруча туры, сабан артыннан калган буразна кебек, аеруча чем-кара күренде. "Төтеннәре туры чыга, чынлап та бай кайткан бу". Ике якларында да утлары яна. Балкыз торды микән әле?

Теге Малайларның салам түбәле, алты почмаклы, җыйнак кына зәңгәр рәшәткә белән уратып алынган йортларының болдыр келәсе, куанычка, эчке яктан бикле түгел иде. Чабаталарындагы карларын тупсадагы чыптага каккалап, үзенең артыннан тышкы келәне челтердәтеп элдертеп, Канәгать

эчкә үтте. Аны тәмле итле аш, нининдер кәнфитле-манпачилы ят хуш исләр, иренеп кенә янган куыклы лампының сүрән яктысы каршылады.

Алгы якта беркем дә юк иде.

Эчтә кемнәрдер кыштырдашты һәм мыгырдашты.

Күп тә үтмәде, уртадагы асылмалы ишекнең ике канатын да шәррәнярра ачып, аннан түгәрәк ак ипи сыман имчәкләре күкрәгенә асылынып төшкән, шешенке йөзен йокы баскан, бәрәңге танаулы юан бер хатынкай килеп чыкты.

Хатын-кызның мондый сурәтен беренче мәртәбә күргән Канәгать оялышыннан карашларын түбән төшерде. Хатынкайның кулында бернинди әфлисун да, хөрмә дә күренми иде.

Хатынкай үзенең артыннан ишек канатларын тыгыз итеп япты да, кулларын артка куеп, малайга карап катты. Гүя ул аны җеп итеп энә күзеннән үткәрә иде. "Сөенче әфлисуннары бәлки аның артка кушырылган кулларындадыр?"—дип уйлап куйды малай.

—Исәнмесез...

Хатынкай җавап бирмәде.

—Сөенчегез котлы булсын!..

Бүреген кара күмердәй кашларына кадәр үк төшереп кигән, ямьшек танаулы, өстендәге изрәп беткән сырмасын аеллы хәрби каеш белән кысып буган, ап-ак тулаекларын шарабар балаклары өстенән сыдырып салып кигән, инде хәтфә карларның чабаталарында эри башлап, идәнгә сала башлаган эзләрен кая куярга белми торган малайны ул, күрәсең, тагын да нәрсә быкылдар, нәрсә сорар, нәрсә булыр, дип көтте. Дөресен генә әйткәндә, бөтенләй таныш булмаган татар мохитына кичә кичен генә килен булып төшкән бу хатынкай, көтмәгәндә генә, шул ук иртәдә, җитмәсә, таң атар-атмастан, шушындый очрашудан бераз югалып та калган иде бугай.

Малай исә, сөенче күчтәнәче алырга килгән кеше буларак, сүзне һәм гамәлне аңардан көтте.

Хатынның карашы чабаталарда туктап калганлыгын чамалаган Канәгать аның белән, үзен күршеләре Сәхап карт урынына куеп, күңеленнән генә бәхәсләшеп тә алды. "Юк, апа җаным, күзләреңне тождырайтма, безнең халык элек беркайчан да чабата кимәгән,—диде ул Сәхап картның халыкта канатлы сүзгә әйләнгән сүзләрен кабатлап.—Без итекле-читекле идек тә бит...Чабатага безне калхуз гына куып кертте". Шушы сүзләре өчен гаиләсе белән Себер киткән һәм әле дә булса әйләнеп кайтмаган Сәхап бабасы турында бу хатынга әйтәсе дә килеп китте. Әйтмәде. Әйтәлмәде.

Түшләренә ишелеп төшкән имчәкләрен әле булса җыештырып алмаган һәм бу хакта уена да кермәгән хатынкай һаман да аңа карап тора иде.

—Балкыз уянды мәле?—диде Канәгать, ниһаять һушын җыеп.—Өйгә бирелгән эшне белергә дип килгән идем...

Хатынкай иңбашларын сикертте:

—Саша, тут твои пришли...*

Һәм кереп тә китте.

Ишекләр яңадан шап итеп ябылды.

"Марҗа дигәннәре, Мәрия Мәкәриевнә дигәннәре шушы буладыр инде. Бу бит бер дә ашый торган нәрсә түгел.".

Фәйрүзә әбисе белән Гыймран бабасы кайда иделәр икән? Нишләп алар өйдә күренмиләр? Әллә Теге Малайлары киленнәре белән кайткач, күршеләренә кереп кунганнармы? Үз өйләренә сыймаганнармы?

Канәгать көтәргә, атасының укыткан укучысын күрергә булды. Теге Малай чыкмыйча булмас. Әнә бит эчке якта тагын да мыгыр-мыгыр килделәр. Әгәр ул үзе күренмәсә, аның янына Балкыз булса да чыгарга тиеш ләбаса!..

Малай аякларын алыштырып басты.

Эчке якта кемдер чыштыр-чыштыр, шыгыр-шыгыр килеп киенеп мәшәкатьләнә иде. "Минем яңа чабаталар кебек шыгыртый бу. Әллә Теге

* Саша, монда синекеләр килде (урыс.)

Малай армиядән дә яна чабаталар киеп кайтканмы?" "Юк,—дип үзенә каршы төште Канәгать.—Болар чыштыр- чыштыр китереп кучтәнәчкә дигән елтыр кәгазьле кәнфитләрен актаралар булыр."

Ишек катында басып торган һәр минут малайга көннәр, айлар кебек озын тоелды.

Ниһаять, канатлы ишекләр янадан киерелеп һәм күгәнендә чыелдап ачылып китте, аннан көзгедәй караеп ялтыраган күн итекләрендә шыгыртый-шыгыртый, кыска буйлы, нәселсез бәрәңге кебек соргылт кабыклы, шыткан күзле, сирәк сары мыеклы адәмзат күренде. Аның өстендә ике рәтенең һәр төймәсе каптырылган хәрби китель. Аны шулай ук көзге кебек ялтырап торган аеллы каеш белән буган. Ул гәлифи чалбарының бүлтәйгән канатлары белән ишек арасын тутырды да куйды. Төрле мидал, ялтыр-йолтыр тимер-томырлар белән тутырган күкрәге һава житмәгән сыман гыжгылдап тын ала. Тулы формада булыйм дип, ахрысы, башына биек кикрикле хәрби фуражка да эләктереп алган. Гүя ул күргәзмәгә, хәрби смотрга буй күрсәтергә әзерләнгән сыман, барча киеме, барча гәүдәсе-ние белән бергә үтүкләнгән иде.

Кулы буш иде.

Теге Малай Канәгатькә, исәнләшмичә генә, борын буеннан гына сөзеп карады.

Бу малай да сәлам бирмәде.

Бу малай Теге Малайны игътибар белән күздән кичерде.

Ул аның сугыш яланнарында ятып калган газиз атасының шушы авылда туып үскән укучысы иде. Хәрби дәрәжәләрдә, чиннарда аңышмаса да, авылга килә башлаган хәрби кинолардан погоннарның нәрсә икәнен чамалаган ир бала, Канәгать, Теге Малайның иннәрендәге нәзек кенә ике сызыкны шәйләп алды. " Йолдызлар түгел, нәзек сызыклар,—дип нәтижә ясады ул үзенә.—Әфисәр погоннары гына йолдызлы була. Макарун дигәннәре шушылар буладыр. Нибары ике сызык."

Яшь, Теге Малайдан күпкә яшь, хәтта аңа уллыкка да яраган Канәгать бу соргылт кабыклы адәмзатның, кайчандыр, аның кебек үк малай булган бәндәнең, моннан егерме еллар элек, авыл мәчетен кисүче әтрәгәләмгә астан арканга бәйләп ар балта-пычкы бирөп торуын, манара кисеп кайтышлый Кәлимулла хәзрәт ихатасына кереп:

*Яңаны алга куйыйк!*
*Искелекне без тыйыйк!*
*Муллаларның күзләренә*
*Кургаш эретеп койыйк!—*

дип жырлаганын белми иде, әлбәттә.

Жиде ел буе тарткан хәрби хезмәтеннән соң туган авылына беренче тапкыр һәм, өстәвенә, беренче тапкыр маржа хатыны белән кайтып, әле беренче иртәдә беренче булып авылдашлары алдында күренүенә искиткеч зур әһәмият биргән Теге Малай, үз көязлегеннән үзе ләззәт алгандай, ишек катында керфек тә какмыйча торды-торды да, борын буеннан гына сөзеп карап эндәшкәндәй итте:

—Ты... пошто... пришла, мәльчик?

Бу малай бу сүзләрдән бернәрсә дә төшенмәде. Әле икенче сыйныфта гына укып маташып, урыс телен бары тик бишенчедә генә өйрәнә башлаячак иде шул әле ул. Аның күзләре яшь белән тулды. Гүя ул олы һәм кече телсез, кояшсыз калган иде. Канәгать һава житмәгән балык сыман, авызын киң ачып нәрсәдер эндәшергә итте, әмма тамак төбеннән, кисеп алынган кызыл ит кисәге булып, "әә!" итеп кече теле генә күренеп калды. Чыгып китәсе килсә дә, китми торды, түзде—ул чыгып китүне әдәпсезлеккә санады. Әле яңа гына башланып килгән гомерендә күпкә иртә өлгереп, ул беренче тапкыр кеше хатасы өчен кешене түгел, инде турыдан-туры үзен, бары тик үзен гаепләде.

—Ти пәйми, мәльчик, әтнәке...—дип аңлата башлады соргылт кабыклы

адәмзат.—Птамушты я бит сим лит ни бивал нә рудинә... Па татарсеки забил бит*...

Канәгатьнең җанында нәрсәдер өзелде.

Ул ишекне ябып та тормыйча тышка атылды.

Инде яктырып килгән һавада тырпаеп күренгән рәшәткәләр аша акбарс сыман урамга сикерде.

Урам буш иде. Күк гөмбәзендәге болытлар тагын да алгарак күченеп, тагын да караеп ачыкланганнар. Көн инде шактый яктырган булса да, йолдызлар һәм ай әле һаман да югалмаганнар икән.

Ул үзенең ни эшләгәнен, нигә йөгергәнен, кая йөгергәнен белмичә йөгерә башлады. Гүя аның колакларында аяклары түгел, йөрәкләре дөпелди иде. Кинәт ул тимерлек каршында менге атлар бәйли торган куш өянке төбенә туктады да, өянкене кочаклап, бәргәләнеп һәм үксеп елап җибәрде:

—Минем әтәй укытучы иде!... Минем әтәй укытучы иде!...

Күпме вакыт үткәндер, ул үзенең сырма кесәсенә кемнендер тыгылуыннан айныды.

Әйләнеп караса—Балкыз.

—Сиңа сөенче кучтәнәче...

Канәгать кулын кесәсенә тыкты һәм аннан елтыр кәгазьгә төрелгән бер кәнфит һәм ике кечкенә керәндил чыгарды.

Малай аларны карга ыргытырга итте дә, тукталып калып, Балкызның уң кулын үзенә тартып алды һәм кучтәнәчләрне яшен тизлеге белән учына салды:

—Мә, кәнфит-керәндилләреңне!.. Теге Малаегызга бирерсең!..

Һәм авыл урамы буйлап түбәнгә таба йөгерде.

—Канәгать, тукта-а-а-а! Тукта-а-а-а!..

Өстендәге бишмәтенең сәдәпләрен дә эләктереп, башына яулык та ыргытып өлгермәгән кыз бала ачык изүләрендә, иңенә таралып төшкән шомырт-кара чәчләрендә җил уйнатып, Канәгать артыннан көнчыгышка чаба иде.

... Ул заманнардан инде исәпсез-хисапсыз сулар акты. Фәйрүзә әби белән Гыймран бабай дөньяда күптән юклар. Авылда аларның каберләрен яд итәрлек балалары да калмаган бугай.

Теге Малай да, Мәрия Мәкәриевнә дә шул кайтуларыннан авылга бүтән кайтмадылар. Исәнме Теге Малай,—түгелме, нәселе бармы—юкмы, бу хакта моңа кадәр беркем бернәрсә белми иде. Күптән түгел, авыл хакимиятенә Хабаровски каласыннан Мәрия Мәкәриевнәнең үзеннән хат килгән булган икән. Имеш, Мәрия Мәкәриевнә "Сәфәргалине җен сукты, ярты ягы йөреми, мондый хәлдә аны тәрбияләргә минем дә, балаларның да хәленнән килми, туганнары, чыбык очлары исән булса, килеп алсыннар, югыйсә Сәфәргали Гыймрановичны картлар йортына тапшырачакбыз",—дип язган диделәр.

Теге алты почмаклы, салам түбәле бүрәнә өй дә юк инде. Аның урынында телевизор антеннасын күккә тырпайтып яңа кирпеч йорт утыра, анда Теге малайларны белмәгән яңа затлар яши.

Куш өянке, инде бик нык картайса да, исән әле.

Әмма аңа хәзер беркем дә атлар бәйләми.

*Азнакай, Чалпы.*
*27 март 2003 ел.*

* Син шулай да аңла мине... Ни өчен дисәң, мин җиде ел туган илемдә булмадым Татарчамны оныткандыр бит...(Урыс.)

# ТРОФЕЙ

*Жырчы Таһир Якупов истәлегенә*

Кояш баюга таба килә иде инде. Көч-хәл белән эчкә үтеп, ишек янагына сөялгән инәсен, билләһи, таный алмый торды Канәгать: йөзе качкан, күз төпләрен божра-божра карасу-зәңгәр түгәрәкләрураткан иде.

—Нәрсә булды, инәй?

Инәсе исә, җавап бирәсе урында, кулындагы төргәген тавышсыз-тынсыз гына сәке өстенә почмакка томырды һәм:

—И-их, улыкаем!—дигән сыман җан өзгеч аваз чыгарып, сыгылып төште дә, үксеп елый башлады.

Инәсенең елаганын авыр кичерә малай. Мондый чакта гүя өйнең бүрәнәләре дә ыңгырашкан кебек.

Бу юлы да өйнең эчен авыр халәт басты.

Кабат сорашудан телен тыйды—гарьлеге үтә төшсен, дип уйлады ул. Моны гына аңларлык яшьтә иде инде. Күрәсең, кемдер аның газиз әнкәсен рәхимсез рәнҗеткән дә, йөрәген кузгаткан, шуңа күрә аңа бу мизгелдә һич кенә дә комачауламау, туйганчы елау, рәнҗешне, эчендә тупланган ярсуны тулаемы белән яшькә чыгару кирәк иде...

Малай берүк вакытта үзе дә газаплы уйларга талды. Инәсе белән бу арада нәрсә булуы мөмкин? Алар бит бүген иртән генә шактый күтәренке кәеф белән йорттан чыкканнар иде. Әйе, әйе, бүген иртән генә. Атасының инәсенә бүләк итеп сугышка кадәр үк тектергән, әмма соңгы елларда, атасы сугышта һәлак булганнан соң, бөтенләй бер тапкыр да өстенә салмаган эре чәчкәле яшелсу күлмәген, күлмәге өстеннән өч бәби итәк типчелгән алъяпкычларын да сандык төбеннән чыгарып кигән, хатын-кызларга мөмкин булганча, киенеп-ясанган, бөтәнеп-төзәтенгән—Канәгать инәсенең бу кадәр матур икәнлеген күз алдына да китерә алмый иде!—инәсе үзе кебек солдатка Мәрфуга әхирәте белән күрше авылга Бөек Җиңү бәйрәменең бер еллыгы унаенан үткәрелгән җыелышка дип киткән иде. Яулардан исән-сау кайтучыларга, ирләрен, туганнарын югалткан тол хатыннарга, ятимә аналарга, җиңги-җиңгәчиләргә Германиянең үзеннән килгән контрибуция малы—трофей бүләкләр дә таратыла икән, дигән хәбәр күз ачып йомганчы таралгач, ул гына дисеңме, бу хәбәрне раслап, авыл советыннан мөһер басылган махсус чакыру да төшерелгәч, түбәндәге кече авыл умарта күче кебек гөж килде. Менә бүген, иртә таңнан торган авыл, аеруча солдатка хатыннар, алтын тавы көткәндәй, урыннарыннан кубарылып, олы авыл белән ике арада яткан тауның сукмакларына сибелде...

Беренче үргә кадәр барып, Канәгать аларны озатып калган иде җитмәсә. Анысы шулай. Әмма менә әлегесе гаҗәп бит әле аның. Канәгать хәтерли, инәсе ишектән чыгар алдыннан гына:

—Мондыен җыелышка... болай актан, бәйрәмчә киенеп бару да ярамый торган эштер инде ул, адәм тәганәсе...—диеп кисәктән генә туктап калды.—Маржалар сыман, кайгы арасыннан киенеп барсаң, бездә, татар-мөселманда, андый йола юк... Ирем һәлак булганга куангандай, бәйрәмчә киенеп, тантанага барыйм микән ни...—Аның дәһшәт белән янган күз карашлары як-якка йөгереште.—Бар әле, улым, янадан укып кара әле, бәлки чакыруларында "тантаналы җыелыш" түгел, "кайгылы җыелыш" дигәннәрдер?

Канәгать өстәл өстендә яткан чакыруны янадан укып чыкты.

—Монда "тантаналы җыелыш" дигәннәр...

—Тантаналы дисең инде...—Инәсе ишек төбендә таптанды.—Чынында кайгы... матәм җыелышы да инде... Бармаган да булыр идем, һаман да шул депутатлыгым бар шул... Кем килмәгән дисәләр, депутат Минсылу килмәгән, диярләр. Сайлау житкән саен, еландай телемне чыгарып, инде бу чираттан үткәрегез әле, дип инәләм, тагын сайлыйлар да гөнаһка кертәләр, илаһым...

Бөек Жинү бәйрәменең бер еллыгы иртәсендә менә шулай нәрсәнедер алдан сизенеп, өзгәләнә-өзгәләнә юлга чыккан инәсе менә хәзер шул ук Бөек Жинү бәйрәменең кояшы инде баюга якынаеп барганда, как сәкегә капланып алган да, кулбашлары белән тартыша-тартыша һәм, авылдашлары сизмәсен-ишетмәсен, дигәндәй, тыела-тыела елап ята... Нәрсә булган?

Малай көтте дә көтте.

Бу минутлар аңа бик озын тоелды.

Ниһаять, инәсе урыннан күтәрелде, мышык-мышык килеп, борын, күз тирәләрен алъяпкычының эчке ягы белән сөрткәләде, аннан, өйдә Канәгатьнең барлыгын да оныткандай, карашларын бер ноктага текәп уйга талды. Аның күп тапкырлар игътибар иткәне бар: ниндидер әһәмиятле мәсьәләне чишәр, җаваплы адымны ясар, гомумән, ниндидер бер хәлиткеч карарга килер алдыннан инәсе менә шулай тере сын сыман катып кала да, тирән уй чоңгылына чума. Бу уй гына түгел, бу җанның зары, җанның чыгы коелган, йөрәкнең шулай итеп сәҗдәгә киткән мизгеле була, күрәсең; бу минутта ул гүя үзен уратып алган һәр кемсәне, һәр нәрсәне онытып, ниндидер Бөек Рух белән киңәшә; бу минутта ул гүя җиргә, дөньяга, тормышка аларның йөзләгән шартлылыклары, катламнары, чоңгыллары аша туры, чәнчеп карый, хәятне моң аша, үтә күренмәле итеп күрә һәм ниндидер хиссияти истәлекләр, ядкарьләр кайнарында яңартып алып, яңа фикер, яңа уй, яңа акыл туплау ләззәте кичерә...

Мондый хәләттә аның керфек очлары калтыранып-калтыранып ала, йөз чалымнары нечкәреп, хисләнеп китеп, якты сагышка чума, булган матурлыгы тагын да матурая, маңгай агы тагын да яктыра, күз аллары, карашлары аны богаулаган богаулардан арынып киткәндәй була.

Малай көтте.

Хәзер. Менә хәзер. Барысы да чишелер. Ачыкланыр. Кебек.

Шулай булды да. Уй сәҗдәсеннән арынып, инәсе, ниһаять, теге тормыштан бу тормышка—чынбарлыкка кайтты һәм өнсез карашын Канәгатькә төбәде:

—Нигә алай карыйсың, улым?

—Һы. Нәрсә булды икән дим.

Инәсенең авыз читләрендә горур елмаю яралды, ул сүзсез генә урыныннан күтәрелде, иңбашларында җыерыла төшкән итәкләрен чеметә биреп рәтли-рәтли, сәке өстенә бая үзе атып бәргән аксыл тукыманы гүя бер кыргый җанварны—козгын баласын, чукый күрмәсен дигәндәй, курка-курка гына аягыннан эләктереп алгандай итте дә, бер омтылыш белән җилпеп җибәрде. Кат-кат бөкләнгән аксыл тукыма инәсе кулында талпынып җилпенде һәм аннан тирә-якка канатланып хасыйл булган алтынсу-сары путаллы, чит-читләре кыска-кыска чуклар белән чукланган кижеле ашъяулык май кояшының кичке шәфагы йөзгән өй эчен яктыртып җибәрде...

—Менә бит алар безгә, җиңүчеләргә, нәрсә бүләк иткәннәр!..

—Нинди матур!...—Куанычын кая куярга белмәгән малай кычкырып җибәрде.—Нинди матур, ин-нәй!..

Әнисе төсеннән үзгәрде, аның күзләре аларып киткәндәй булды.

Эсселе-суыклы булып, улын утлы караш белән көйдереп алды:

—Матур ди сиңа!.. Шуны да күрмәскә... Күзең чыкмагандыр бит!...—Гомерендә бер мәртәбә улына болай каты бәрелмәгән ана, бу сүзләреннән соң нишләргә белми, телен тешләде һәм гаебен йомшартырга теләп булса кирәк, тукыманы янадан бер тапкыр җилпендереп, кояшка күрсәтте.—Менә бирегә кара, улыкаем! Үзәккә кара!.. Уртасына кара... Германнан безгә бүләккә дип шушы тишек чүпрәкне алып кайтканнар... Атаң башы бу!.. Атаң башы хакына... Башкомандующий Сталин исеменнән... Күрәселәрем бар икән, Илаһым!..

Канәгать игътибар белән тукыманың үзәгенә карады һәм аның аша кояшның үзен күреп тынсыз калды: алтынсу-сары путал белән йөгертелгән ашъяулык-эскәтернең нәкъ уртасы гүя бер җанварның үткен тешләре белән чәйнәлеп өзгәләнгән һәм умырып алынган иде...

—Ыә!—Нәрсәдер эндәшергә иткән Канәгатьнең авызыннан әйтәсе сүзе бары тик бер мәгънәсез ымлык булып кына чыкты.—Ыә!..

Инәсе ул арада янадан сәкегә бөгелеп төште һәм инде бер нинди тыелусыз сыктый-сыктый елый башлады...

Әнкәсенең тынлыкта өзгәләнгән тавышы һаваны шартлар хәлгә житкерде. Гүя кемдер йортның нигез ташларын селкетә иде.

Канәгать инәсенең чыңравын тыныч кына тынлый да, аны ташлап, нигез ташларын карап керергә дип чыгып та китә алмый иде.

—Мондый бүләкләре белән ярама тоз салмаган булсалар иде дә бит... Ул бит болай да әрни!.. Әрни!.. Аһ, әрни!.. Миннән, фронтта ирен җуйган солдаткадан... ятим балалар анасыннан... болай көләргә кем аларга нинди хокук биргән?!.. Мин бит аларга бүләк сорап бармадым... Нигә алар миннән көләләр?.. Нигә алар минем соңгы кояшымның да эчен тишеп, эчәгеләренә кадәр актарып чыгаралар?!.

Идән уртасында бөрешеп калган малай башындагы сигез өлгеле кәпәче белән гүя кара эшләпәле кадакка охшап сайгакка сеңешкән һәм инәсенең тозлы күз яшендә бөртенеп күгәргән иде. Анын инәсен елавыннан туктатасы килде. Бик тә. Бик тә. Әмма мондый чарасы юк иде. Шулчак ачык ишек аша тыштан майның кызган һавасын өстерәп Мыштым килеп керде. Канәгатьләрнең ак мыеклы ата песие. Бер тавыш-тынсыз йөри, хәтта тычканнарны өннәрен дә чыгарырга өлгермичә тота белгәнә өчен аңа Канәгать Мыштым дигән кушамат таккан иде. Мыштымны барлык авыл белә. Дөньяларын тычкан-күсе баса башласа, күрше-күлән, хәтта түбән очтан да килеп, Мыштымны кунакка алып китәләр. Ләкин ул анда озак кунакламый, бурычын үтәгәч, мыштым гына кайта да керә. Менә әле дә, тупса ашы үтеп, үзенең тамагын туйдыручысының фаҗигалы хәләттә булуын аңлап алгандай, җәһәт кенә сәкегә сикереп менде һәм тартыша-тартыша елаган хуҗабикәсенең кулбашына сырты белән сөйкәлеп ятты.

Канәгатькә рәхәт булып китте. Гүя инәсенә күкләрдән ярдәм килде. Алар инде икәү генә түгел, өчәү иде.

—Бер умачлык оны да булмаган ач-ялангач өстәлемне ниместән таланган тишек ашъяулык белән каплатһырырга итәләрме, имансызлар? Гитлерына ләгънәт! Сталиннан бүләк, имеш. Сталинына ләгънәт!.. Ирләребезнең башына җиттеләр!..

—Чү, инәй!..

—Силсәуитен, Зөлкарнәен әйтер идем!.. Ашары булмаган ачларга ашъяулык тарата!.. Анысы да... черек!.. Шушы балага берәр күлмәклек сәтин бирер иде, ичмасам...

Ямау өстенә ямау салынган күлмәге эчендә әле генә янган-пешкән Канәгать бу сүзләрдән соң өши башлагандай булды.

Инәсе һаман елый, песи һаман аңа елышып йокымсырагандай итә иде.

—Контрибуция, имеш! Троф-фей, имеш! Таланган чүпрәк! Кирәкми ул миңа... Кайгырмыйм—гарьләнәм!.. Үз сандыгымда күпме бирнәм тасланган килеш ята... Көнгә чыгарырга сәбәбе генә юк!..

—Инәй... Инәй...—диде чак кына ишетелерлек итеп Канәгать.—Тынычлан...

Ләкин инәсе көтелмәгән рәнжештән тәмам ярсыган иде шул.

—Һичкемнеке түгел, шул силсәүит Зөлкәрнәй этлеге генә бу... Ул да халык җилкәсен байтак кимерде дә симерде... Бәй, тишек чүпрәк белән авызымны томаларга итәләр... Томалатырмын мин!.. Фронтовик Гыйззетдин хатыны әле мин!.. Бәй, узган сессиядә безнең авылда чучка фермасы оештыруга каршы чыккан идем, яратмадылар!.. Үзеңне өстен күрсәтмә, күрсәтмә өстән төшкән, диләр. Төшсә ни! Өстән төшсә, без аны астан... их!.. Бакчаларны кистерүгә каршы чыктым—яратмадылар! Өстәмә заемга каршы чыктым—яратмадылар!.. Өязе ярны ашап, йорт нигезләренә житеп килә, ярны ныгытыйк, тегермәнебез юк, су тегермәне салыйк, дидем—яратмадылар!. Сайлауларда депутат итәләр дә, авызымны бикләп, сүз әйттермиләр!..

—Инәй... Инәй... Тынычлан...

Малай песиләре Мыштым кебек мыштым гына килеп, инәсенең уң як инбашына сарылды. Алар хәзер сәкедә өчәү иде.

—Без ятимнәр өстеннән, башлары киткәннәрнең изге хәтереннән көлгән өчен телләре корысын! Аяк-куллары, тән әгъзалары череп аксын бәдбәхетләрнең!.. Ярабби, ярабби, Илаһым!.. Кылган явызлыклары үзләренә кайтсын!.. Ашаган ризыклары тамакларына аркылы торсын!.. Яткан урыннарын хур кылсын, мал-туарларын мур кырсын, Илаһым!..—дип бәргәләнде инәсе. Аның белән бергә гүя малай үзе дә бәргәләнә иде.—Муеннары асларына килсен!.. Оятсызлар, җир битләр!.. Үзләре көнлеккә, атлары көрчеккә калсын!.. Ярабби, ярабби, Илаһым!.. Ләгънәт, ләгънәт, ләгънәт!..

Инәсенең сыктавына түземе бетеп, үзенә урын тапмаган малай, ялт итеп урыныннан күтәрелде. Гаиләгә килгән кайгыны гүя анардан да тирәнрәк аңлаган Мыштым инәсенең инсәсенә сеңешеп, аны һаман да юаткан һәм җылыткан сыман иде. Канәгатькә нидер булды. Малай баһадирларча олыгаеп турайды. Тышка карады. Күзе утынлыктагы түмәр өстендә баюга барган алсу кояш шәфагында ялкынланып янган балтага төште. Аның башына бик тә куркыныч, баш китәр уй килде: ул, Ватан азатлыгы өчен сугышларда батырларча һәлак булган, атасының үлемтек кәгазенә кул куйган полковник Борисов язуынча, "иң кискен минутта батальонны һөҗүмгә күтәргән" лейтенант Гыйззетдин Сабирҗановның улы Канәгать, менә хәзер шушы балтаны кичке шәфакъның алсу баткагыннан суырып ала, силсәүиткә бара, атасының һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булган башка авылдашларының изге хәтерен җиргә салып таптаганы, аларның ата-аналарын, балаларын, хатыннарын рәҗеткәне өчен, силсәүитнең тәрәзәләрен, өстәл-урындыкларын вата-кыра, бинасыннан утынлык ясый һәм сәүит рәисе Зөлкәрнәйнең башын түмәргә сала да эһ тә итми чаба да өзә...

Малай яшен тизлеге белән тышка атылып чыкты. Ишек алдында җим эзләп интеккән чыпчыклар өере пырылдап һәм артларыннан тузан туздырып, һавага күтәрелде.

Ул күпне күреп-кичереп ташка әйләнгән түмәрдәге балтаны бер омтылыш белән суырып чыгарырга итте, әмма сигез яшьлек сабыйның моңа көч-куәте җитмәде.

Шулчак каяндыр килеп чыккан этләре Матрос, түмәр янында маташкан дусты, яшьтәше Канәгать янына чабып килде, койрыкларын болгаштырып, сырпаланды һәм, берәр афәт сизенгәндәй, ярсып-ярсып өрә башлады.

—Пыш-шул!..

Малай тагын көчәнде һәм, ниһаять, балтаны тартып чыгарды.

—Син нәрсә, юләрләнденме, мәллә?!

Инәсе аның кулыннан балтасын тартып алды, утыннар арасына ыргытты. Йомшак җиренә сизелерлек итеп тамызып та алды:

—Ягыласы булма! Тәүбә диген!..

Кеше-кара ишетә-күрә күрмәсен, дигәндәй, инәсе аны бөтереп алып, тавышсыз-тынсыз гына артыннан этәли-төртәли, өйгә алып керде һәм сандык өстенә утыртты:

—Шушында гына утыр! Кузгаласы булма!.. Безгә болай да каныкканнар, күрмисең мени?.. Заманы нинди—кешеләре шундый... Алла сакласын!..

Песи әле һаман сәке өстендә, хәзер инде теге трофей ашъяулык өстенә сузылып яткан иде. Күзләре йомык. Йоклый, имеш. Малай белә, ул шулай кыйланган гына була. Чынлыкта исә ул аларны тыңлап ята. Канәгатьнең күнеленә җылы керде. Инәсе тынычланган иде. Аны бит утынлыкка нинди дер үзе белештермәгән көч шул инәсен тынычландыра алмаганга күрә генә урыныннан күтәреп ыргыткан иде...

—Алла сакласын!.. Алла сакласын!..—Үзенең гадәти халәтенә кайтып, чынлап та тынычланган инәсе, белгәнен укына һәм инде үзе бар дөньяны тынычландыра башлады.—Бер гаепсез кешеләрне каргыш, гөнаһлар батырдым бит!.. Сугышын әйтер идем!.. Бу гөнаһта Зөлкәрнәйнең нинди генеләр гаебе булсын инде? Ул нинди мир җилкәсен кимергән кеше булсын

инде, ә? Мин дә инде... Авызын ачса, үпкәсе күренеп тора бит, мескенкәемнең... Коры таякка калган каммун бит ул!.. Минем Гыйззетдинем белән бергә сугышка китеп, кулын өздереп кайтты. Ифрат та һәйбәт кеше, шулай бит, улым? Аның бәләкәйсе синең белән укыймы әле, улым?

Инәсе ана карамый да. Ул шулай аңа эндәшкән булып үз-үзе белән сөйләшә генә.

—Катырак бәрелдем, бугай... Әгәр анавы тишек чүпрәк...—Ул сәке өстенә канатларын җәеп очып төшкән алтынсу-сары ашъяулыкка караш ташлады.—Германның үзеннән, Сталинның үзеннән үк килгән икән, димәк, аның тишек-тошыклы булуында Зөлкәрнәйнең бернинди катнашы да юк. Кем белә, бәлки аны силсәүит сәркәтибе Зөлхәбирә алыштырып куйгандыр? Аның бит Минсылу урынына, ай-яй ничек кенәләр депутат буласы килә!.. Алсын үзенә, әнә германның черек чүпрәгендә безнең песиебез йоклый, шулай бит, улым!..—Инәсе җинел генә кеткелдәп алды.—Кара әле, бер кызгач, юлбашчыбыз Сталинга да өлеш чыгардым бит әле...—Инәсе бераз уйланып торгандай итте.—Ысталин булмаса, бар, мондый сугышта җиңеп чыгар идең! Тоттырдылар ди сиңа мондый бөек җинүне. И-и-и, Ходаем, бер гаепсезләргә каргыш органым өчен үзең ярлыка!... Зөлкәрнәйгә дә, даһи Сталинга да озын гомерләр, тиешле җир-җиһаннар, каргышсыз маллар бир!.. Исән генә була күрсеннәр!..

Инәсе мич арасына кереп, голт-голт су йотып, сусавын басып чыкты.

Инде ачуы тәмам басылгандыр дип торганда гына ул йокымсырап яткан Мыштымны өстеннән җилләп төшереп, ашъяулыкны янадан алды һәм игътибар белән карый-капшый башлады.

—Бәй, бәй, ничек була икән инде ул? Германнан Мәскәүгә, Мәскәүдән Уфага, Уфадан Кыргыз-Миякәгә, Кыргыз-Миякәдән олы авылга алып кайтканда, олы авылда тапшырырга әзерләгәндә бу бүләкләрне юньле-рәтле тикшермәделәр микән ни?—дип аптырады инәсе.—Әллә киресенчә, шулай кулдан-кулга күчә-күчә, тикшерелә-тикшерелә тишелеп беткәнме ул? Әллә бу тишек эскәтерне төргәккә чынлап та пумалабаш Зөлхәбирә тыкканмы?

Ә нигә Минсылу төргәкне Зөлкәрнәй кулыннан алгач та, шундук сүтеп карамады? Шунда, клуб залында? Кешеләр, бигрәк тә районнан килгән нәчәлникләр алдында унайсызландылар хатыннар. Башкалар ачып карамагач, Минсылу да карамады.

Солдатка хатыннар алган бүләкләрен, клубтан чыгып, кайтыр юлга чыккач, "Бүләк" урманы үренә җиткәч кенә карарга булдылар. Түземнәре җитәрме, имеш. Тол хатыннар бу сирәк мизгелне мөмкин кадәр сузарга, бу ләззәтне мөмкин кадәр озынайтырга тырыштылар. Һәм менә... Минсылу өчен ул түзем дигәне шул "Бүләк" урманына кадәр житте дә һәм шунда ук бетте дә. Һәр солдатканың исем-фамилиясе язылган төргәкләр эченнән шальяулыклар, ефәк шарфлар, күлмәклек тукымалар, бәйләм оеклар һәм башкаларны күреп куанганнан соң, Минсылуның карап торуга иң затлы бүләк саналган алтынсу-сары путаллы ашъяулыгын таратып җибәрүенә, ашъяулыкның нәкъ уртасыннан бала башы сыярлык тишек килеп чыккач, Минсылуның йөрәгендә нинди-дер җеп өзелде. Аһәңе йотылды. Шул "Бүләк" үрендә ятып елады ул. Бу гаделсезлектән ярсыган хатыннар олы авылга кире барырга, районнан килгән нәчәлникләр, Зөлкәрнәйнең битенә төкереп, бүләкләрен йөзләренә бәреп кайтырга кирәк дип тавышланып та маташтылар, югыйсә. Кирегә борыла да башлаганнар иде. Юк, бу бәладән, бу гыйсъяннан Аллаһу үзе коткарды аларны. Бу башкитәр тәкъдимгә Минсылу үзе каршы төште. Үзе туктатты. Юк, куркудан түгел. Әхирәтләрендә чүпрәк хакына кешелек инабәте какшанудан, вакланудан шикләнде. Ул бит... алар үзләре сайлап куйган, аларны үзе сакларга тиешле булган иң ышанычлы кеше—депутат иде...

Аның хәле бетте, дәрманы таралып, тез буыннары өзлекте.

Әхирәтләре Минсылуны күтәреп диярлек алып кайттылар.

Менә шулай алды Минсылуның тынычлыгын германнан килгән трофей бүләк.

Тишек ашъяулык өстеннән әле генә Минсылу үзе җилгәреп төшергән

песиләре Мыштым сандык өстенә күчкән икән... Күчкән дә, сыртын шул ук сандык өстендә утырган Канәгаткә терәп яткан икән... Әгәр дә күзе песиләренә төшмәсә, ул улының монда икәнен бәлки абайламаган да булыр иде. Уңайсыз булып китте. Атасының тере сыны булып каршысындагы бирнә сандыгы өстендә сүзсез генә утырган улын күргә аның куллары үзләре дә сизмәстән тәүбәгә кушырылды...

Ачуын, нәфрәтен кая куярга белми кайнаган, соңгы чиккә җитеп, кемне дисез, халыклар атасы Бөек Сталинның үзен каһәрләгән, аннан, бәлки бөтенләй гаепсез булган, фронттан кулсыз кайтып, тол хатыннар белән бергә җигелеп, авыл сукасын бергә тарткан Зөлкәрнәй кардәшенә урынсыз бәддога укыганы өчен үкенгән хатынның гарьлеге килеп, бит алмалары яңа, кызыша башлады. Күзләреннән тәгәрәгән яшьләре аның йөзен пешерде. Һәлак булган ире өчен ничә ел Гитлерны, фашизмны каһәрләгән тол хатын шушы ашъяулыкның бала башы кадәр тишеге аша кояшны күргәннән соң үз гомерендә беренче мәртәбә бөек юлбашчыны, "авызын ачса, үпкәсе күренеп торган" авылдашы, иренең дусты Зөлкәрнәйне, аның нәселен каргады, ләгънәтләде түгелме? Ләхәүлә вә лә куәтә!.. Булган хәлме? Тәүбә вә тәүби, Илаһым!..

Ул калхуз коллыгыннан азат минутларында гына, башкалардан качып кына намаз укый торган урынына басты, кыйбласына борылды, бер сәҗдәгә китеп, бер рокугъка торып, ләгънәтен кире кайтара башлады:

—И, Ходаем! Гөнаһларга батырдылар бит... Хаксызга ләгънәтләдем, каргадым, гөнаһаларымны үзең ярлыка!.. Гөнаһаларымны гафу әйлә, җәһәннәм утыннан сакла, дөньяга вә әхирәткә бөтен гамәлләребезне дөресләә!.. Ләгънәтләремне кире кайтар, кәлимәсен кәлимәгә аер, юкка чыгар!.. Мине, атамны вә анамны, хәләл җефетем Гыйззетдинемне вә балаларымны, вә барча мөселман өммәтен кыямәт көнендә рәхмәтең илә гафу әйләә!.. Корьән шәрифнең йөз дә ундүрт сүрәсе, алты мең дә алты йөз дә алтмыш алты аяте берлә иман китерәм!..

Инәсенә ияреп, малай да амин тотты.

Инәсе аягына басты.

—Төшегез.

Канәгать сандык өстеннән шуып төште.

Аның артыннан Мыштым да идәнгә сикерде.

—Моны болай калдырырга ярамый,—диде ниндидер катгый карарга килгән инәсе.—Бу дәүләткүләм җинаять.

Нишләргә итә ул?

Минсылу биксез сандыкны киң ачып, капкачын диварга терәде һәм актарына башлады. Сандыктан озак еллар хәрәкәтсез яткан тукыма, киемсалымга хас булган нафталин, хушбуй, иннек-кершән исләре бөркелеп чыкты. Озак та үтми сандык янәшәсенә атасының киелми сакланган күлмәкчалбары, мамык һәм көзге бәрән йоныннан бәйләнгән оекбаш, биялипирчәткеләре, ак һәм кара шарфлар, тасланып куелган чүпләмле сөлгеләр, тәрәзә башлары, чыбылдыклар, чаршаулар, тәрәзә пәрдәләре, тастымаллар, ашъяулыклар, мендәр каплары, дебеттән чигелгән кульяулыклар, кечкенә келәмнәр, япмалар, күкрәкчәләр, бала искеләре—тагын да әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр өелә барды...

Сандык янына кара чәйнүк кебек утырып алган Мыштым ниндидер ялынган тавыш чыгарып мияулады.

Минсылу ниндидер икенче бер кадерле нәрсәне эзли иде, күрәсең. Менә ул сандык эченнән, астан, иң астан кузнең явын алырдай ап-ак, иң вак тәрәш аша тукылган чүпләмле ашъяулык тартып чыгарды. Аның шикәрдәй ак төсеннән барлык йорт эче яктырып киткәндәй булды.

—Менә алар!.. Мин аларны үземнең күз нурларым белән эрләдем дә, суктым да, чиктем дә!.. Мин аларны Гыйззетдинем кайткач кына җәярмен дип саклый идем—болай булгач, кайтасы юк икән!..—Инәсенең күкрәгендә нәрсәдер "Ыэ!" итеп куйды.—Безгә Гитлердан калган тишек ашъяулык кирәкми, шулай бит, улым?!.. Без аларга үзебезнекен җибәрәбез, шулай

бит, улым?!.. Мина, татар хатынына, башкача ярамый!.. Монда Германына да, Мәскәвенә дә житәрлек!..

Ишек алдында Матрос әллә үзен уратып алган чыпчыкларга, әллә баеп барган кояшка өрде дә, тынып калды.

Минсылу әле үзе белеп житкермәгән, соңгы сугыштан соң яралып кына килгән күренеш—ике дөнья, ике система бүләгән: үзенең ирен үтерүчеләр иленнән килгән тишек трофей ашъяулыкны һәм һәлак булган ирнең Туган Ватанындагы хатынының үз куллары белән чәчкән, үстергән, суккан, талкыган, эрләгән, салкын чишмәләрдә юган, киптергән, тукыган житен тукымадан тегелгән ашъяулыкны, аларга өстәп Гыйззетдиненең бер пар оек-биялиен, ак шарфын да бергә бер төргәккә бисмилла әйтеп төрде.

Аны төнлә йокысы алмады.

Иртәгә авыл советына баргач нәрсә әйтәчәген кат-кат уйлады да, тагын бер кат уйлады. Уйлый торгач, уйлары берсе өстенә берсе божраланып, һаман да шул элеккеге фикергә урап кайта торган булдылар.

Менә 1946 елның 10 май таңы атты.

Көтү кугач, ана баласын уятты. Алар корыдан гына чәй эчтеләр.

Төенчеген тотып чыгарга әзерләнгән инәсенә Канәгать аптырап калды.

—Син кая?

Инәсе эндәшми-тындашмый елтыр кәвешләрен кия башлады.

Малай соравын кабатлады.

—Бәй, мин сиңа әйтмәдем мени әле?—диде инәсе аптырагандай итеп.—Силсәүиткә барабыз, улым. Ярлы булсам да, буем гарьле!.. Әйдә, җыен. Синнән дә ышанычлы дуәкәмәт, синнән дә яхшырак шаһит булмастыр. Кирәк икән, бу төенчек белән силсәүитенә генә түгел, Мәскәү Керимеленә дә, Германына да барырбыз. Безнең төенчектә атаеннын Верховный Башкомандыщий Сталиннан алган рәхмәт хаты һәм медале дә бар!..

Канәгать куанычыннан инәсенә карады. Аларнын карашлары очрашты. Инәсенең йөзе беркайчан да булмагандай нурлы, инсафлы иде. Малайга көч инде. Бу мизгелдә инәсе аның өчен жирдән гүя Алып Батыр булып күтәрелгән иде.

Улын житәкләгән ана арт капкадан гына чыгып, кулдан чокылган, әмма әлегә орлыгы булмау сәбәпле чәчелми яткан бәрәңге жирендә берсе эрзин кәвеш, икенчесе ялан аяклы пар эз калдырып, Кәркәлетау аша олы авылга илткән текә сукмакка таба юнәлделәр.

Канәгать артына борылып карады.

Моңа кадәр беркайчан да борчаклары пешмәгән Мыштым белән Матрос, тупсага менеп утырып, койрыклары белән тактага суга-суга, Минсылуны һәм Канәгатьне тупса түреннән озатып калган булганнар икән.

—Әйдүк, кара чәйнүк!—дип ирештерде аларны малай.

Аннан, тауга менә башлагач, елмаеп, кулын болгады.

Ни дисән дә, Матрос Канәгатькә атасыннан мирас булып калган, житмәсә, аның белән бер елгы да булган жан иясе иде. Песиләре Мыштым исә анардан биш яшькә бәләкәйрәк иде.

Тауга менеп житкәч, Канәгать әнисенә сиздермичә генә, Теге Малайларнын теге оч ягындагы йортын эзләгәндәй итте. Балкыз күрми микән аларны?

Аның тәрәзе төбендә Канәгатьнең былтыр бүләк иткән кылганнары чәчкә атып утырырга тиеш әле. Кылганнарның көмеш божралары беркайчан да сулмый ди бит Минлегазиз бабасы.

Менә шул гына.

*11 август 2003 ел.*



## Наис Гамбәр

# ЯШӘҮ АГАЧЫННАН—ШӘҖӘРӘҢНӘН...

***

**Мин җәйләрдән көзгә кереп киләм,—**
**Карап калам киткән кошларга;**
**(Таянырлык дустың булсын икән,—**
**Таянырлык микән дусларга?)**

**Салкыннары тышта декабрьнең,—**
**Туңар инде калган кошларым;**
**(Таянырлык иңең булсын икән,—**
**Таянырлар микән дусларым?)**

**Мин кышлардан язга чыгып барам,—**
**Ояларын барлыйм кошларның;**
**(Җан атарлык җаннар ерак, ерак,—**
**Колагымда өне шуларның!)**

***

**Кырын-кырын гына сугылып үтә**
**Дусларыма килгән кайгылар;**
**Әйтәм:**
**—Сезнең кайгы—минем борчуларым!..**
**(Күкрәгемдә олуг кайгы бар...)**

**Көн-таң атса—Яшәү һәм Үлем бар,**
**Уянам да—Сезгә түгеләм!..**
**Яшәү агачыннан—Шәҗәрәңнән!—**
**Бер "яфрак" та артык түгел лә...**

***

**Бу юлларның чиге булыр микән?—**
**"Юк!" дисәң дә, бәлкем, чигенмәм;**
**Каешланып беткән күлмәгем дә**
**Урман гөле белән чигелгән:**
**Ак күлмәген чиккән сатиннан!**

Наис ГАМБӘР (1947) — *шагыйрь, тәнкыйтьче; «Кояш» һәм «Күзләрем яфрак коя» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Юлларыма чыксам, юлларымда
Юлчылардан калган эз булыр;
Бер гөнаһым булса, мине саклап
Изгеләрдән калган сүз торыр:
"Авыр булыр, ләкин сатылма!"

***

Морҗам ярык иде...
һәр эзенә
Янык чыкты—диклоскопия;
Күкрәгем дә шулай—һәр ярадан
Көек кала—бер эз!—копия...

Уйлый идем: янган кирпеч кенә
Яна-яна түзә... ишелә;
Янган утка карап утырам да:
"Утын һәм ут үзенең эшендә!"
...Көле төшә ялан өстемә.

***

Дәфтәреңнең соңгы битләрен дә
Ябып куйгач, тугры сүз калыр;
(Ләхетеңә якты бәхет булып
"Сөю" дигән изге Сүз тамыр.)

Ләкин болар... Ләкин болар әле
Соңгы сүзе булмас Ходайның;
Яшәү дәвам итәр... Ә барыбер
Бохарадан килмәс бодаең.

***

Иттифакый дуслар арасыннан
Аны сайлап алдым—белегез...
(Сез чибәр дә түгел... бигрәк,
Бигрәк моңсу иде күзегез.)

Кеше җаны—әгәр күзләр булса,
Сөйкемлесе сездә—иншалла!
Тәрәзәләр ачык... Ачып куйдым—
Таң җилләре керсен, машалла.

***

Үләр идем... Булмый! Сезнең өчен
Кереп ятар идем ләхеткә!..
Мине бары берәү генә сөя,
Кагылмагыз минем Бәхеткә!..

Күзләрдән дә язлар эзләп йөргән
Чаклар—
Булса, буладыр ул яшьлектә!
Мондый уйланулар—гаҗәпләнмә!—
Язылып калган хәтта "Тәүхит"кә...

***

Бу юлдан—мин дә үткән,
Бу юлдан—син дә үткән;
(Туфрак шул ук, кешеләр—
Кешеләр генә бүтән.)
Туфанның* җыйдым баланын,
Арырак... түргә үтәм!

***

Ишекме?.. Ачык ич ул!—
Бикләдең, бикләмәдеңни,
Дусларың бәреп керерләр;
Телим шикләнмәвеңне...

Йөрәкме?—
Ачык ич ул!
"Киләсе"—
Сузылган кул!

***

Ачык калган тәрәзәм,—
Җилгәреп, җилләр бәрә;
Идәндә уйный ак нур,—
Йөриләр тәгәрәп лә.

Армасын бәдән... Адәмнең
Юлларга чыгасы бар;
(Килер юл киңчә булса да,
Китәсе юл тардан тар.)

Кичәдән калган эзләрнең
Йөзе киткән агарып;
(Атыңны иртән җиксәң дә,
Кичен дә куй тугарып.)

Ачык калган—япмаган
Көнкараш тәрәзәңнән
Җил өрә; бу—хәбәрдер,
Идәндә—хәрабәләр.
Уйный да көлә бер нур—
Ачык шул тәрәзәләр!

***

Яңгыры үтте чылатып...—
Агачлар өсләреннән
Тама да тама тамчылар
Керфегем очларына.
(Очланып бетә бит инде
Керфекнең соңгы очы...)

Егет белән кыз шикелле
Имәнне каен кочып

Утыра...
Кеше—бигрәк көнчел!

***

Сүнсә дә Көннең күзләре,
Урманның бетми сүзе!—
Йокларга, диеп, ятсаң да
Колакка керә үзе.

Сизеп ятасың...—
Күзеңне
Йомган булсаң да үзең!

Күзеңне йомган булсаң да,
Ишектәге ярыктан
Җил исе керә, гөл исе...—
Ачыл күңел!... Тарыкма!

---

*Туфанның Аккош күлендәге балан куагы күздә тотыла.

***

“Йоклама!” дигән шикелле
Тавышлар өйгә керә;
Агач флейталарда
Урман—моң-көйләр өрә.

Кушыла алар баздагы
Чикерткә зеңләвенә;
Кешеләр йоклый булырлар,
Бу көй бер бездә генә!..

***

Иртәсен ачылды пион,
Төнендә сүнде күзе;
Тамырга бәреп канаттым—
Яралы тезем...
Үзем
Тотындым чәчәкләргә лә,—
Чәчәкләр сабагына;
Бу миңа авыр чагымда
Сулмаска сабак кына...

***

Яшьнә әле, Яшен!
Түләп алган яшем—
Түләрмен...

Күкрә әле, Күкрәү!
Күкрәк тулы күкрәү—
Үләрмен...

Ачыл әле, Күгем!
Яшәү ялган түгел—
Бүләрмен...

***

Яшьнә әле, Яшен!—
Бу минем теләп алган яшем...
Болытлардан коелдылар утлы чаткылар,
(Утлардан качтым; югыйсә, чактылар, чактылар.)
Күкрәгем тулы уй; утлы яшен-чаткылар—
Хисләрем; нишләрем—яшендә чаткы бар.

Күкрәү әле, Күкрәү!—
Бу бит милләти инрәү...
Таралып килә болытлар (шәмемдә—уйлар!),
Кайларга карама—күкләрдә тимрәү, тимрәү;
Агачлар тын тора нигәдер, моңаеп
Сеңә ул тамырга үзенчә тиң күкрәү.

Ачыл әле, Күгем!—
Тере бит инсани бүген...
Кырмыскалар чыгар өннәреннән тулып,
Туабашы да килер (күршедәге!) сый сорап;
Әле генә үтте керпе (ул да сөт сорар),
Бүген бал яуды, юкса...
Соңрак, соңрак!..

***

Авырдым көн буе,—
Чәчәкләр шиңмиләр;
Әйтерсең, терел, абый,
Без бергә, диделәр.



**Мөсәгыйт Хәбибуллин**

# АЙБИБИ

ТАРИХИ РОМАН

## I

—Ислам... Ислам дим! Син кая югалдың?! Нигә мине ташлап киттең? Мин хәзер елыйм. Яисә сакчыларым чакырам, күреп тор, чакырам...

—Айбиби, Айбиби, мин монда, монда! Мин сиңа көмеш кыңгырау чәчкәсен тутырып чык суы китерәм. Әнием әйтә, шушы чәчкәгә тутырган чык суын эчсәң, үлемсез буласың, ди.

—Ислам, тизрәк кил. Мин куркам. Бу урманда аюлар, урман мәчеләре, барслар йөри, диләр.

—Курыкма, курыкма, хан кызы. Мин хәзер... Менә чәчкәм касәсен чык суы белән тутырам да...

Ниһаять, уң кулына кыңгырау чәчәк тотып ул аланга килеп чыкты. Бала итәкле күлмәген җәеп, алан уртасында утырган хан кызын күрде дә исе-акылы киткән берәүдәй туктап калды. Куе үлән һәм төрле төстәге чәчкәләр белән күмелгән алан уртасындагы Айбиби, зәңгәр күлдәге төнбоек чәчкәсен хәтерләтә иде. Бу манзарага сокланмаслык та түгел иде, ул тәмам сихерләнде. Алан уртасында гүяки хан кызы түгел, күктән иңгән алиһә утыра кебек иде. Аңа таба бер генә адым ясаса да, һәм ни дип кенә дәшсә дә, бу гүзәл-сурәт юкка чыгар кебек иде. Шушы сихри көчкә ия күренеш, җәннәт-оҗмахларда гына була торган әкияти-чын алан, аланны тутырып, итәгенә зәңгәр тасма тарткан күлмәген җәеп утырган хан кызы аны чынлап та бермәлгә әкияти дөньяга алып кереп китте. Җитмәсә, хан кызы күкбаш чәчкәләрдән үреп, башына таҗ кигән иде.

—Айбиби, хан кызы Айбиби, мин сиңа үлемсез итә торган чык суы җыйдым,—дип, ниһаять, кыюсыз гына хан кызына таба кузгалды Ислам.

—Минем үлемсез буласым килми, җыйган суыңны үзең эч...—Хан кызы маңгаена төшеп торган чәчкәләрдән үргән таҗын күтәрә төште, егетнең күзләренә карады.—Нигә озак йөрдең?.. Мин курыктым, беләсең килсә, бик курыктым.

—Әйтәм бит мин сиңа, хан кызы, кешене үлемсез итә торган чык суы

---

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН— *(1927) прозаик; "Чыңгыллар", "Кубрат хан", "Илчегә үлем юк", "Хан оныгы Хансөяр", "Атилла" һ.б. романнар авторы. Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

жыйдым, тамчылап диярлек, һәр чәчкәдән, һәр яфрактан. Аннары анда, Идел култыгына, аккошлар төшteләр. Көтүләре белән.

Аккошлар сүзен ишетүгә, хан кызы егеткә кулын бирде.

—Минем ул аккошларны күрәсем килә. Алып төш мине Идел култыгына,—дия-дия аягына басты, үзе үк алдан елгага таба кузгалды. Аптырабрак калган Ислам кулындагы чык тулы чәчкәне кабып йотты да хан кызына иярде. Ни гаҗәп, елгадан качарга теләп, болын ягына ерып кергән култыкка чынлап та аккошлар төшкән иде. Калганнары очканнармы, култыкта өч кенә аккош калган. Икесе парлы, берсе бер читтәрәк ялгызак. Аккошлар су төбеннән җим эзлиләр иде. Кешеләрне күрүгә, сагая калдылар. Әмма шундук тәүге хәлгә килеп, җим эзләүләрен дәвам иттеләр. Пар аккош камышлар арасынарак үтеп, сөешә башлады. Муеннарын-муенга урыйлар, томшыклары белән шыкылдатып, бер-берсенә нидер әйтәләр кебек иде. Ялгызак аккош бертын аларга карап торды да, башын кырын салып, су читенә үк килеп баскан Айбибигә күз салды. Айбиби моңа кинәнде һәм кулындагы бер чәчкәне аңа ташлады. Аккош янә бер тапкыр Айбиби ягына башын кырынайтты—карап алды. Һәм чәчкәгә таба йөзеп килә башлады. Айбиби үзе дә сизмәстән суга ук керде. Аккош ул ташлаган чәчкәне томшыгына элде дә су өстенә үк чыгып, биеп алды. Айбиби аңа чәчкәләрдән үргән таҗын ташлады. Аккош янә башын кырын салып, аңа карап алды, ахыр йөзеп килеп, таҗны килер җайда ук муенына элде. Элде дә шундаен кинәнеп бии башлады ки, хәтта канатларын җәеп җилпенеп алды. Пар аккошлар да моңа игътибар иттеләр, сөешүдән тукталып, шул якка карап тора башладылар. Айбиби ап-ак күлмәк кигәч аккош кебек иде, аякларында кызыл болгари читек, муенында зәңгәрсу тасма, башында кызгылт-сары өрфия яулык, яулык астыннан аксыл бөдрә чәчләре чыгып тора, шуна күрәме, болай да гүзәл хан кызы, кошлар гашыйк булырдай тагы да гүзәлләнеп киткән иде. Сарай табибы улы Ислам бу тамашага мөкиббән китеп, сихерләнгән килеш ни кылырга белми тора. Ни тамаша, аккош Айбибигә таба йөзеп килә башлады, шул хәлгә сихерләнә төшепме, хан кызы да суга керде—аккошка каршы китте. Ислам тәмам курка калды. Аккош Айбиби янына ук килеп җитте. Янә канатларын җәйде, гүя Айбибине суга—кочагына чакырды. Айбиби суга керә, инде су аның балтырларына җитте, аккош белән адәм баласының иң гүзәл заты менә-менә кочаклашырлар һәм Аллаһының оҗмах кошы аны күтәреп алып китәр сыман. Ислам дәшәсе итте, тавышы чыкмады, ул чынлап та бу хәлгә әсәрләнгән, сихерләнгән берәүдәй катып калган иде. Парлы аккошларга ишләре кылган гамәл ошамады булса кирәк, алар ялгыз аккошны чакыргандай каңгылдашып алдылар да очарга җыена башладылар һәм су өстеннән йөгереп, канатларын киң җәеп, кузгалып та киттеләр. Хан кызы Айбибигә бер адым килеп җитәр-җитмәс калган ялгыз аккош ишләренә таба карады һәм каңгылдап алар артыннан кузгалды. Ул кем беләндер саубуллашкандай монсу итеп каңгылдады, аккошның хәсрәт тулы монсу-сагышлы тавышы Айбибинең йөрәгенә үзе дә аңлап житкермәгән сагыш хәсрәте салды.

—Сау бул, сау бул, аккошым, сау бул оҗмах кошым!..—дия-дия, Айбиби бер тын су буйлап барды, ахыр туктады һәм бермәлгә инде күздән югала башлаган аккошына карап торды. Бары тик шуннан соң гына судан чыкты һәм Ислам янына килеп, күкрәгенә капланды. Капланды да сызланулы вә әрнүле тавыш белән:

—Ул китте, китте, минем аккошым китте,—дип елап җибәрде. Кичәлебүгенле тулышкан күңеленең буасы ерылды Айбибинең. Аны бит иртәгә, нәкъ менә иртәгә, Аккалага каһан кырына алып китәчәкләр, Хазар каһаны сараена.

Ислам кызны тынычландырырга теләде, инбашларыннан сөйде, күкрәгенә кысты, ахыр ике кулы белән йөзен сыйпап хан кызының күзләренә карады. Карады һәм хан кызының күзләрендә яшь күреп, шул чиккә житеп тәэсирләнде ки—хан кызының яшь белән сугарылган битләренә, дымлы иреннәренә тартылганын сизми дә калды. Иреннәренә кагылып кына

узды, яшьле битләреннән үпте. Әнә шул үбүдәнме, кинәт, хан кызына нәрсәдер булды, ул сискәнеп китте, тәне буйлап үзе дә аңламаган тетрәнү узды, шундук башына шаулап кан саугандай итте. Хан кызы тәмам буынсыз калды, сыны китеп, ишелеп төшә башлады. Бу хәлгә югалып калган Ислам хан кызын кулына күтәреп яр өстенә таба кузгалды. Ә яр өстендә аларны хан кызының өч сакчысы көтеп тора иде.

—Ни булды хан кызына?!—дип сорады баш сакчы коры гына. Артык койты сорагангамы, Ислам каушый калды, хан кызын аягына бастырды да сүзсез торды.

Ул арада хан кызы исенә килде, баш сакчыга карады да шактый кырыс төстә:

—Берни дә булмады, баш сакчы, барыгыз, кайта торыгыз! — дип боергандай әмер бирде.

—Минем сезне ташлап китәргә хакым юк, хан кызы,—диде баш сакчы һәм Ислам ягына ым кагып:—Әллә сарай табибы улы...

—Мин сабый бала түгел, баш сакчы. Мин буйга житкән хан кызы. Мине иртәгә Аккалага алып китәчәкләр, Аккалага! Кахан тарттыра мине, үз сараена. Ә табиб улын миңа бәйләп атакаем жибәрде, баш сакчы... Ишетәсеңме, атакаем!..

—Аккалага?!—дип өчесе дә бергә кабатладылар сакчылар һәм күзгә-күз карашып алдылар. Бу хәл сакчыларга көтелмәгән хәбәр иде булса кирәк.

—Хан кызы!—дип кычкырды баш сакчы.—Атларыгыз аланда, тышауда...

—Яхшы, баш сакчы, яхшы, атларны табарбыз,—диде, ниһаять, Ислам, батыраеп. Һәм, елмаеп, хан кызына күз төшереп алды, чөнки бу куәтне аңа нәкъ хан кызы биргән иде.

—Миңа ни булды, Ислам?—диде хан кызы егет кырына ук килеп.—Ни булды миңа, Ислам?..

—Сезне аккош сихерләде, хан кызы,—диде Ислам һәм кызның кулыннан алды да атларын калдырган аланга таба әйдәде.

—Синең атаң минем белән Аккалага барачак, Ислам,—диде хан кызы.—Озата барачак. Син дә атаң белән мине озата барыр идеңме?

—Мин атамнан сабак алам, хан кызы. Минем бөтен хыялым кешеләрне терелтү, сәламәтләндерү, аларны бәхетле итү. Сәламәт тәндә—сәламәт акыл, дигәннәр борынгылар.

—Һәр адәм баласының да язмышы Тәңре кулында. Тәңре ни язган, һәммә жан иясенә дә—шул булачак.

—Сезне Аккалага алып китәләр, хан кызы. Бу да язмышмы?

—Бу Аллаһ теләге. Язмыштан узмыш юк. Димәк, Аллаһ миңа шул язмышны юраган, әйе, фәрештәләре аша.

—Хан кызы, әйтимме бер сүз?

—Әйт.

—Атаң Талиб исән булса, хан кызы, ул сине кахан кырына жибәрмәс иде. Аның болай да кырык хатыны бар, диләр ич.

—Мин каханга кырык беренче хатын булып тартылам. Ә кырык беренче хатын баш хатын вазифасын үтәячәк, диде атам Мөхәммәд хан.

—Әйе, мин дә бу хакта ишеткән идем.

—Син минем Мөхәммәд атама тел тидермә. Атам Талиб хан мин тугач та вафат була, яшь хатын булып килгән хан сараендагы анама Мөхәммәд хан өйләнә. Ул мине үз кызы итеп үстерде, укытты, белекле итте.

—Минем исемем Ислам, димәк, мин пәйгамбәрләр сакчысы, минем сезне саклыйсым килә, хан кызы.

—Пәйгамбәрләр сакчысы икәнсең, син мине исән-имин атама кайтарып тапшыр. Бар, атымны китер!

Күрше аланда утлаган атларның тышауларын чишеп, Ислам хан кызына жете кара бияне китереп, йөгәнен кулына тоттырды. Хан кызы бала итәкле күлмәген күтәрә төшеп, кызыл болгари читек кигән аягын өзәңгегә куйды да, очып кына диярлек ияргә менде һәм елдыр гына аланнан чыгып та чапты.

—Мин аккошымны куа киттем, аккошымны! — дип кычкырды. Урманнан чыккач кына Ислам Айбибине куып житте. Алар икесе дә күзгә-күз карашып алдылар һәм, атларын тыя төшеп, янәшәдән атлатып киттеләр.

Хан кызы Айбиби янә-янә егеткә карап ала һәм үзалдына нәүмизләнеп, елмая.

—Рәхмәт сиңа, син бик яхшы юлдаш икәнсең.

—Синең аккошың булсаммы,—дип, якын итеп, хан кызына дәшә башлады Ислам,—канатларыма утыртыр идем дә мин сине, хан кызы Айбиби...

—Һәм кай тарафларга алып китәр идең? Әйтче, кай тарафларга?—дип эчке бер самими киная белән елмайды Айбиби.

Ислам бермәлгә югалып калды. Ул белә иде инде, кызлар, яшь кызлар үз үсмер ишләрен бик үк тиң күреп бетермиләр, "кызлар, гадәттә, иртәрәк өлгерәләр", дигән иде бер тапкыр атасы аңа. Ә менә яшь бикәләр, киресенчә, яңа мыегы шытып чыккан егетләрне куеннарына сыендыруны тәмам изге гамәлгә саныйлар. Монысын инде Ислам үзе дә бик яхшы белә иде.

Икенче мәлдә инде хан кызы ат тезгенен тарткалап алды:

—Рәхмәт, Ислам, мең рәхмәт. Тик минем язмышым хәл ителгән инде. Атам Мөхәммәд хан хәл итте аны. Ул миннән бик үтенде, сине олуг илбашы көтә, балам, диде. Атам миңа әйтте, кахан сиңе кырык хатыны булса да рәнҗетмәс, чөнки син баш хатын сыйфатында булырсың, диде. Минем бер дә кахан белән тәмсезләнәсем килми, балакаем, диде. Чөнки Болгар Хазарстанның аркадашы, шул сәбәпле мин сине аңа җибәрми булдыра алмыйм, балакай, диде. Моны атаңның каханга биргән изге анты дип кабул итә күр, диде. Хак булса, баш хатын буларак мин һәрдаим кахан кырында утырачакмын—илчеләр кабул иткәндә дә, раввалар табынында да. Мин Аккалага тартылгач, кахан Болгарга ташламалар ясаячак. Һоп, аракошым, һоп...

Хан кызы атын куалый-куалый алга ыргылды, Ислам бермәлгә югалып калды, җитмәсә, хан кызы бу сүзләрне аңа түбәнсетеп тезде кебек тоелды. Ә бит хан кызының аты аның аты белән ияргә-ияр, тезгенгә-тезген барганда Айбиби тарафыннан хуш исләр килә һәм аның зиһенен томалый башлаган иде.

—Хан кызы, хан кызы, тукта! Каханны Ханбалыкта утырмый диләр ич?!

Айбиби кузгала башлаган атын тыя төште һәм артка каерылып, Исламга карады.

—Кахан Идел елгасы уртасындагы утрауга салынган Аккалада утыра. Ул каланы гарәпләр Ай-Балда дип йөртәләр. Аккалада каханның варислары гына түгел, хатыннары да, раввалары да яши. Шунда ук карачылары, куштаннары, тагын әллә кемнәре... Аккошлар булыйкмы, сарай табибы улы Ислам?!

—Булыйк, булыйк, хан кызы, булыйк!

—Без аккошлар!—диделәр дә калага таба чаптылар.

Ислам ни теләсә дә хан кызының атын куып җитә алмады. Хан кызы күзгә күренеп аңардан ерагая бара иде. Аның ак күлмәге күктәге ак болытларны хәтерләтеп кабарган, кыз гүя аккош үзе иде. Тик ул җирдә, әллә нигә күккә генә күтәрелә алмый изалана кебек иде. Ислам исә, калага кереп барган хан кызы артыннан атын ни куса да җитә алмады гына түгел, ерагайганнан-ерагая барды. Ислам басу капкасына җиткәндә, хан кызы биредән әллә кайчан узган, юл тузаны гына зәһәр еландай сузылып калган иде.

Чарасыз калган берәүдәй, Ислам атын тыя төште, күп тә үтми өйләре утырган тыкрыкка борылды. Кинәт кенә аңа кыен булып китте. Хан кызының кыланышын ни дип юрарга да белмәде. Көлә идеме хан кызы аңардан, яшьсенә идеме, әллә соң бөтенләй баласындымы?.. Алай дисәң, нигә кочагына инде дә, нигә үзен үбәргә һәм сөяргә бирде, хәтта һуштан язды кебек. Әллә соң юри генә кыландымы?.. Ләкин ни генә булмасын,

Ислам шат иде, көтмәгәндә ул хан кызы белән урманга чыкты, Идел буена төште һәм, таң калып, аккошлар белән сөйләшкән хан кызы янында булды, кочагына иңдерде, зифа буен, кайнар тәнен тойды. Тагын да гаҗәбрәге, хан кызы, ялгыз аккошка гашыйк булгандай, суга ук кереп китте. Аккошы да кеше телен белгәндәй аңа таба йөзеп килеп, канатларын җәеп, хан кызын кочарга теләде кебек. Аккошның муенында хан кызы ташлаган такыя, томшыгында ал чәчкә. Кем сихерләде җырларда гына җырлана торган аккошны—хан кызымы, әллә соң аккош үземе?.. Ислам күрде ич, күрде, аккошның күзләре тагы да кызарыбрак киткәндәй булды, ә хан кызының йөзендә әсәрләнү хисләре аша туган соклану тойгысы. Моны ни белән аңлатырга да белмәде Ислам һәм бу хәлне гомумән аңламады, чөнки ул атасыннан азмы-күпме дөньяви фәннәрдән генә түгел, кош-корт һәм хайваннар, җанвар-җәнлекләр турында да сабак алган иде. Кошларның кеше белән аралашуын күз алдына китерә алмый иде ул. Бүген исә шуңа шаһит булды. Аккош белән хан кызының сөйләшкәнен күрде. Ләкин ул шушы булган хәлне беркемгә дә сөйләмәс, һич булмас димә, диванага санаулары бар. Ә менә әнисенә сөйләр. Юк, үбүләре хакында аңа да сөйләргә ярамас. Хан кызын үптем, хан кызы кочагымда һуштан язды дисә, әнисе ничек кабул итәр. Ул да җүләргә санамасмы?! Хан кызы ич! Кемнең аны үбәргә, кочагына иңдерергә хакы бар?! Җитмәсә, хан кызы артыннан бер тотам калмый сакчылары йөри. Ханга җиткерсәләр, сарай табибы улы сәнең кызынны кочаклады, һуштан язгач, яр өстенә күтәреп меңгерде, дисәләр.

Атын, иярен дә алмый, абзарга җибәрде дә өйгә керде, аяк киемен салып, түргә узды, сәкегә утырды һәм уйга калды.

Мич ягыннан әнисе чыкты, башын иеп утырган улын күрде дә туктап калды.

—Карале, улым, кайларда йөрдең? Атаң кайтты, сине эзләде. Нигә күзгә карарга кыймый торасың, әллә соң ул-бу булдымы үзеңә, аттан егылмагансыңдыр бит?.. Юкмы!

—Хан кызы белән урманга чыккан идек. Идел буена төштек, аккошлар култыгына. Аккошлар төшкәннәр иде.

—Шуннан-шуннан, улым, ни булды инде?—Ананың күңелен тәмам кызыксыну басты, ул чарасыз калып, улы кырына киез җәйгән сәкегә утырды.

—Аккошлар анда һәр елны ике-өч тапкыр төшәләр. Җәйләп калганнары да булгалады. Ә синең нигә сөмсерең коелды соң әле?.. Аккошлар хан кызын күтәреп алып китмәгәннәрдер бит?

Ислам сәерсенеп, әнисенең күзләренә карады, әнисе күз төпләре белән әкрен генә елмая һәм елмаюы шулай ук әкрен генә иреннәренә таба күчә бара иде.

—Хан кызын күтәрерлек аккош буламы соң, әнием?

—Нигә булмасын, ди, була ул, була. Әкиятләрдә кызларны һәрчак аккошлар канатларына утыртып алып китәләр. Ә ул аккошлар арасында, мөгаен, Йосыф каханның да аккошы булгандыр. Хан кызын канатына утыртып алып китәргә иткәндер.

—Көлмә, инәй, беләсең килсә, хан кызын иртәгә Аккалага озаталар.

—Әтиең әйтте инде, озаталар. Кызганып куйдым әле балакайны. Атасы Талиб хан да яшьли диярлек вафат булды, Айбиби балага исем кушканнар гына иде, тәхеткә килгән Мөхәммәд хан Талиб ханның яшь сараена—үз кырына алды, никахлар укытып, улым, никахлар укытып... Чөнки Талиб ханның яшь хатыны күз алмастай чибәр вә сылу иде. Ирләр алдына чыкса, барысы да “аһ!” итәрләр иде. Ләкин ул, бичара, Талибын үтә яраткан иде-ме, озак яшәмәде, Тәңребез үз кырына алды. Әнә шулай, анасының күкрәк сөтен тәмләп кенә калган бала, сарай абыстае Рәшидә кулына килде. Мөхәммәд хан, рәхмәт аңа, баланы үз кызыдай карап үстерде, гарәпләрдән, фарсылардан мөгаллимнәр китертте, баланы белемле итте. Хәзер әнә, буйга җиткәч кенә каханның раввалары күреп алганнар, балакайны... Яраткан кешесе булдымы икән соң балакайның!?.

—Бүген ана мин гашыйк булдым, инәй, мин!

— Йә-йә, улыкаем, сабыр бул...

—Хан кызы минем кочагыма инде, мин аны сөйдем, үптем, мин шул мәлдә гүя күккә аштым, инәй, күккә! Беләсең килсә, мин аны урларга барам. Бүген үк, төнлә белән...

Исламның әнисе Гөлзифа кечкенә кызларга мәдрәсәдә сабак бирә, абыстай сурәтендә йөри торган кеше иде, улы хан кызын "урлыйм" дигәч, кинәт йөзе үзгәрде, бермәл ни әйтергә белми яна гына мыек төртеп чыга башлаган улына карап торды.

—Саташасың инде әллә, улыкаем. Алла диген. Сөйләмә юкны, әйткән сүзең фәрештәләрнең амин дигәненә туры килүе бар. Хан кызы ла ул! Безгә тиң баламы?! Бу сүзләреңне Мөхәммәд ханга җиткерсәләр, һич булмас димә, еланнар базына ташлатыр үзеңне. Атыңа ышан, ханга ышанма, дигәннәр борынгылар.

—Ә мин аны яраттым, инәй, битләреннән үптем, күзләреннән...

—Әстәгъфирулла, ни сөйлисең син! Борын астыңа яңа өч бөртек йон чыккан, ә ул хан кызын урларга җыена. Мөхәммәд хан ишетсәме бу сүзләреңне, балакаем...

—Ишетсен, мин аны кочагымда тоттым, битләреннән тозлы яшьләрен үптем. Яраттым, яраттым мин аны, инәй, ишетәсеңме, яраттым.—Ислам кинәт кенә урыныннан купты да әнисенең алдына төште.—Бир миңа фатихаң, инәй, бир!

—Һай Аллам, балакаем, чарасыз итмәсәнә мине?! Сакчылары да ишеттеләрме синең ни... хан кызын, дим...

—Юк, сакчылар күрмәделәр дә, ишетмәделәр дә, инәй.

—Йа Аллам, Ходай бар икән әле, бар икән! Саклаган минем диванамны зинданнан. Бу сүзләреңне хан ишетсәме, таш атып үтертер, таш атып, балакай. Хан кызы Айбиби илгә бер чибәр бит ул, илгә бер. Үзе акыллы, үзе укымышлы, өч-дүрт телдә сөйләшә, үзе күз алмастай гүзәл. Мөхәммәд ханны да әйтер идем инде, борынына ис керә башлаган малайга ышанып кызын биреп җибәргән.

—Мин җиткән егет инде, инәй, җиткән егет! Һәм мин хан ышанмастай кешенең улы түгел, атам сарай табибы, анам балаларга сабак укыта, калада бер абыстай.

—Карале, улым, сиңа кызын биреп җибәргәндә Рәшидә абыстай да анда идеме? Ул да ризалык бирдеме?

—Рәшидә абыстай анда юк иде, анда булса, ул да ризалык бирер иде, инәй.

—Мөхәммәд ханны әйтәм, соңгы көндә булса да аккошлар култыгын күреп кайтсын дигәндер инде, бичара. Атасы да бичара, кызы да...

—Нигә бичаралар, инәй?

—Бичара булмыйча, кем булсыннар соң алар, каханга баш иеп торалар лабаса! Мөхәммәд хан икенче кызын җибәрә бит инде ул хатын-кызга туймас каханга, икенче кызын. Айгөле үз кызы иде, бара-баруга йөккә узды да бер бала табып вафат булды. Раввапарга баш бирмәгән ул бала, дип җиткерделәр. Горур, тәкәббер бала иде Айгөл кызы.

—Миңа ничә яшь инде, әнием—унҗиденче языма аяк бастыммы?! Хан кызы да!..

—Хан кызы башка ул, балакай, кызларның яшен санамыйлар. Мөхәммәд пәйгамбәр тугыз яшьлек Гайшәгә дә өйләнгән, никахлап, олылап.

—Барыбер мин хан кызына гашыйк, әнием! Йөрәгем белән гашыйк. Хан мине елан базына ташлатса да, илдән куса да минем хан кызы Айбибигә булган гыйшкымны йөрәгемнән уеп ала алмаячак, инәй-инәкәем!

—Гашыйк булдың?! Бер син генә гашыйкмы ул балага, улыкаем! Баҗайлар ханы Түрә дә яучыларын җибәреп карады, Айбибине кайсыдыр улына тарттырмакчы булды. Тын елгасы буенда җәйләгән кыпчак ханыннан да яучылар килде, Кара Болгардан да. Бирмәде Мөхәммәд хан Айбибине, берсенә дә бирмәде.

—Ә мин яучы җибәрсәм, әнием?

—Тиле дигән саен тигәнәк буе сикермә әле, улым. Ул бала илгә бер гүзәл. Беркөнне шулай, шәехне очраттым. Һәй, гүзәл зат, сарай табибы Хәбибулла бикәсе, ди, бу. Туктадым. Шәех кадәр шәех дәшә ич. Хан кырында киңәшче йөзендә утыра. Әйе, киңәш-сабак биреп. Килде олуг башы белән кырыма. Ни, ди, әйт әле җәмәгатеңә, җибәрмәсен Айбиби баланы кахан кырына, ди. Безнең үзебезгә дә акыллы балалар кирәк, ди, улыкаем. Хәбибуллаңа шул хакта әйт әле, шәех бик үтенде дип, атаң тыңлап та тормады. Чалмага төренгән бар кеше акыллы дигән сүз түгел, анасы, башымны катырып йөрмә, Мөхәммәд хан ни кылганын бик яхшы белә дип кенә ташлады. Хан аның үзен дә Ханбалыкка озатмакчы була әле, анасы, диде атаң, улыкаем. Хәер, шәех тә, хан да, атаң да, син дә, мин дә—барыбыз да Аллаһ колларыбыздыр, барыбыз да Тәнре ярдәме белән яшибез вә көн күрәбез. Рәшидә абыстай әйтә, һәр туган балага рух шәмен Аллаһ фәрештәләре куя. Ә шәех исә, атаң әйтә, Аллаһ фәрештәләренең җирдәге шәүләсе генә. Шулай дигән Сөләйман пәйгамбәр. Буең җитмәстәйгә үрелмә, көчең җитмәстәйгә тотынма, дигәннәр борынгылар. Син, улым, хәзер күңеленне гыйшык-мыйшыкка түгел, белемгә беркет. Бу дөньяда фәрештәләрнең белем шәме—китап вә белемдер. Хан кызының үз язмышы, синең үз язмышың. Күңеленне юк-бар белән алгысытма. Кыз бирү кемгә кайгы, кемгә шатлык китерәдер. Минем дә гүзәл кыз Айбибине яше кырыкка җиткән каханга бирдертәсем килми. Мөхәммәд хан ул гүзәл кызын комсыз каханга җибәреп барыбер уңмас кебек миңа. Чөнки угызлар безгә якынрак, ә алар инде Хазарстан җирләренә кереп җәйли башлаганнар. Бер дә борчылма, улым, син яшь әле, гашыйк та булырсың, хатын-кыздан гарык та булырсың. Хатын-кыз шулай ул, башта кочакка иңә, аннары өйгә керә, ахыр ир белән идарә итә башлый. Хан кызына гашыйк булдым дип башың диванага сала күрмә тагын. Үтәр, яшьлектәге мәхәббәт язгы ташу гына бит ул. Кар сулары китүгә үк үз эзенә төшә, кар сулары үтүгә үк. Беренче мәхәббәт әнә шул синең күңелеңдә туган язгы ташу гына бит ул. Чын мәхәббәт өйгә атка атланып керми, чын мәхәббәт өйгә мүкәләп керә, мәңге шунда калам, итәк тотырып бала табам дип.

—Әйе шул, әнием, миңа калса, хан кызы Айбиби аккошка гашыйк булды. Сукыр кеше шикелле аккош дәшүгә суга кереп китте.

—Суга?! Бу ни дигән сүз инде тагын, улым?..

—Аккош аны кочагына алды кебек. Һәрхәлдә, миңа шулайрак тоелды.

—Аккошлар алар кызларга охшаган, балакай. Кияүгә чыгалар да, туган якларын мәңгегә ташлап китәләр... Ул аккошлар култыгына без дә җыелышып төшәдер иек. Ап-ак күлмәкләр киядер иек. Безне күргәч, култыкка төшкән аккошлар беравыздан каңгылдаша башларлар иде. Һәй сөенерләр иде дә соң. Әле су өстенә үк чыгып биергә, әле чума-чума уйнарга, берберсен куышырга тотынырлар иде. Араларында әле шул уеннарга катнашмыйча, боек кына бер читтә торучы ялгызаклар да булырлар иде, улым. Димәк, нииндидер бер явыз җан аның ишен уктан алган. Аккошлар шулай бит алар, бер кавышкач, мәңгегә бергә булалар. Инде теге, йә бусы ишен югалта икән, мәңгегә ялгызак гомер итәләр. Йә, ярар, улым, акыл сатып утырмыйк, бар атларны эчереп кер. Ат караучы "хатыным бәбәй китерде, абыстай, атларны улыныз гына эчерер" дип сорап киткән иде. Һәй, улым-улым, менә син дә үсеп җиттең. Анан белән кызлар турында сөйләшеп утырасың.

Гөлзифа улының аркасыннан ләпи-ләпи сөйде дә, Исламны ишеккә таба этәреп җибәрде, үзе исә, тамак төбенә килеп тыгылган яшь төерен йотып җибәрә алмый, күз кабакларын әчеттереп куйган шатлык вә башына кайгы китерергә җыенган улына карап калды. Йөреше, кыяфәте, атлап китүләре тач атасыныкы иде. Сөйгән сөяк сөйгән сөякне бирер, дигән бугай Мөхәммәд пәйгамбәр, хак икән... Ни хәл итмәк кирәк, әнисенең җан җылысы, эчкерсез үз итеп сөйләшеп утыруы, күрде ич, улына да күчте. Һәм улының да күзләре дымланды бугай, әмма ир-егет буларак күз

яшен әнисенә күрсәтергә теләмәде. Димәк, ил халкына вә ватанга янә бер ир-егет терәк булачак дип кинәнде ана.

***

Ислам төш күреп ята иде. Имеш, ул һаман Айбиби белән Аккошлар култыгында, ә аларны аккошлар уратып алган, гүзәл кошлар хан кызы Айбибине сөяләр, суга таба сөйриләр. Имеш, Айбиби аккошлар белән суга кереп тә бара инде, Ислам аңа таба атлыйсы итә, әмма аяклары гүя җиргә ябышкан, кузгала да, дәшә дә алмый. Ә хан кызы Айбиби чыр-чу килә кебек, көлә дә сыман һәм инде суга кереп бара. Аккошлар кинәнәләр, кангылдашалар. Айбиби аны да үзе белән чакыра, кул изи, хәтта дәшә сыман...

—Ислам, Ислам улым, дим! Тор, әллә саташып ятасың инде?! Кемгәдер дәшәсең кебек тоелды. Тор дим, кояш чыгып килә. Ашыйбыз да сарайга барабыз. Хан дәшә.

Ислам тәмам уянды, “хан дәшә” сүзен ишетүгә уянды, хәтта торып утырды.

—Ни булды, әтәй?

—Хан сине сарайга дәшә, дим. Башта Айбиби кызы белән мине җибәрәсе иткән иде, кинәт кенә фикерен үзгәрткән—Айбиби кызы мине Ислам табиб озатсын дигән. Мөхәммәд хан Айбиби сүзен тыңламый буламы?

Ислам барысын да үз колагы белән ишетте. Айбиби онытмаган, ул аны Ханбалыкка кадәр озата барачак, атасы Хәбибулла урынына.

—Хакмы бу, әтәй?

—Әйе, хак.

—Бүген үкме?

—Өйләдән соң кузгаласыз. Юын, аша да сарайга барабыз.

—Мин Ханбалыкка барам, әтәй, Айбибине озатырга?!

—Әйе, хан кызы Айбибине озатырга, улым. Айбиби атасыннан үзе үтенгән. Мина әйтте хан, улың риза булса, мин риза диде.

—Мин риза, риза, әтәй, риза!

Икенче бүлмәдән әнисе чыкты, тыз-быз киенеп йөргән улына карады да:

—Ни булган моңа тагын, корт чаккандай өтәләнә. Атасы дим?

—Ашарга әмәллә, анасы,—диде Хәбибулла.—Мөхәммәд хан малайны табиб йөзендә Айбиби кызын озатырга җибәрә...

—Нәмәрсә, нәмәрсә дидең син, атасы?.. Җиткерделәр дә микәнни инде?! Харап иттең Хәбибуллам, баланы, харап иттең шул сарайга иятләштереп. Имеш, ханның хатыннарын оста дәвалый.

Ислам ул арада юынган, киенгән, табын җәелгән сәке башына килеп утырган иде инде.

—Нәрсә җиткерделәр тагын?—дип сорады Хәбибулла.

—Безнең дивана кичәгенәк хан кызын, әйе, ниткән...

—Ничек ниткән?!—дип курка кала сорады ир-канаты.

—Әйе, ничек, ничек. Кочаклаган, үпкән, гашыйк булган хан кызына безнең дивана.

—Кабат әйтәм, безнең диврананы Мөхәммәд хан кызын озатырга җибәрә, мине түгел, улыбызны.

—Харап иттек, харап иттек, баланы, Хәбибуллам, харап иттек!.. Баш салырга чыга улыбыз... Моны Мөхәммәд хан юри эшли. Сакчыларыннан бер-бер сүз ишеткән дә.

—Ни ишеткән?

—Безнең Ислам кочаклагач, хан кызы һушыннан язган, Ислам хан кызын ярга күтәреп алып менгән. Күтәреп, атасы, кулына күтәреп. Егетләр кочагына кергән һәр кыз һуштан язмый, атасы. Бер-бер яман эш кылган безнең дивана. Шул сәбәпле Мөхәммәд хан улыбызны Ханбалыкка дип җибәреп, ансат кына котылмакчы була.

—Үз акылындамы син, анасы! Минем угылымны юк итәргә Мөхәммәд ханның башына тай типкәнме?!

—Менә шул улыбыз хан кызы Айбибигә яучы җибәрергә тора иде әле. Урлап качам дип тә янады.

—Бар әле, улым, чыгып тор әле. Атлар сайлый тор,—диде коры гына табиб Хәбибулла.—Монда анаң чуаш сырасы эчкән бугай...

Ислам ялт кына чыгып китте. Гөлзифа сәкегә утырды да ике учына башын салып, селкенеп тора башлады.

—Атасы, атасы дим...

—Сөйләмә миңа тузга язмаганны! Башы яшь булса да малайның акылы үзе белән, андый юләрлеккә бармас, иншалла.

Ислам ишек артында тыңлап тора икән, ишек ачып:

—Хак әйтәсең, әтәй, бармыйм. Мин әнием әйткәнчә үк дивана түгел.

—Кер әле, алай булса, анасы, ә син тиз генә табын хәстәрлә, Ислам син дә булыш. Ризык янында киңәшик, ипләп кенә,—диде Хәбибулла. Ире шулай диюгәме, Гөлзифа урыныннан купты, ризык-нигъмәт чыгарды һәм авызын яулыгы белән каплый төшебрәк табынга утырды.

Тәүге сүзне ялгап җибәрер өчен булса кирәк, Ислам анасына карап алды да:

—Мин дивана түгел, әтәй, хан кызын рәнҗетергә минем башым да ике түгел.

—Хан үзе дә Исламны ошаткан. Ипле табиб аякланып килә, диде.

—Ошаткан,—диде кырыс кына пәрәмәчкә үрелә-үрелә Гөлзифа.—Ошаткандыр шул. Теге кәнтәй жариясен дәвалады бит, малаең. Ятакка калган кәнтәй икенче көнне үк йөреп киткән, диделәр. Имеш, безнең менә бу күзле бүкән чиренә күрә дәва тапкан.

—Анасы, табибның сүзе генә түгел, кулы да дәвалый.

—Кулы гына дәваласа ярый да бит, малаең шуннан соң күпереп мыек чыга башлады.

—Сөйләмә юкны, кеше сүзе кеше үтерә, диләр. Ханга җиткерсәләр. Ә хан ул яһүдә жариясен ярата.

—Түшәккә калган жария Ислам дәвалагач та сикереп торып бии башлаган, шулаймы?!

—Беләсең килсә, анасы, ул хатынын дәваларга Исламны хан үзе җибәрде. Һәм рәхмәт улыбызга, сарай куштаннары алдында йөземә кызыллык китермәде.—Хәбибулла мыек астыннан гына бер гамьсез рәвештә пәрәмәч ашап утырган улына күз төшереп алды.—Ә син тизрәк аша да ат-дирбияләрең карап куй. Ханбалык якын җир түгел.

—Мин ашадым инде. Рәхмәт әнием, рәхмәт әтием.

Уллары чыгып киткәч, Гөлзифа амин тотты һәм җилле генә ишеккә таба үтте, ишекне ачып, малай тыңлап тормыймы дип урап килде. Килде дә иренең амин тотканын көтте, тиз арада табынны җыештырды һәм янә ир каршында пәйда булды.

Авыр булса да сөйләшү барын сизеп алган Хәбибулла:

—Гөлзифа, утыр әле яныма. Утыр-утыр. Күрәм ич, әйтер сүзең бар.

—Юк инде, утырмый гына әйтәм, утырсам күңелем йомшарыр дип куркам. Менә нәрсә, атасы, алай булгач, мин дә улым белән Ханбалыкка китәм.

Хәбибулла нидер әйтергә дип авызын ачты, вә ләкин кисәк тыелып калды. Ат дуласа түзәргә була, тыярга да, туктатырга да әмәле табыла, ә менә сыер дуласа ил белән дә туктатып булмый, диләр.

—Ачулы кеше белән сөйләшүе авыр, анасы. Ә малай өчен бер дә кайгырма, озатып та йөрмә, барыр ул анда, барыр да әйләнеп тә кайтыр, иншалла. Ханбалык Рим түгел.

—Бердәнбер баладан мәхрүм итәсең бит мине, атасы!

—Бәй, кайчан гына әллә нишләп күремем юк, балага уздым ахыры, дип шәбәеп йөргәниең түгелме!

—Узса соң, иш янына куш ярап торыр. Әнә шәех әйтә, бер генә бала

тапкан ананы фәрештәләр оҗмах капкасына якын да җибәрмәячәкләр, ди.

—Шәехне тынласаң, оҗмахны күреп кайткандай кылана ул. Сез хатыннарга җитә кала инде... Ә малайны Айбибигә ияртеп җибәрергә хан үзе үтенде, анасы, үзе!

—Хан кушты дип коега төшәр идеңме?

—Төшәр идем! Ханга минем генә түгел, беләм ич, синең дә рәхмәтең зур. Аннары хан сараенда хезмәт итәм ич мин. Кайчак синең кочагыңнан аерып, җылы түшәктән дә дәшеп алалар.

—Ханның улың дәвалаган кебек кәнтәйләреме?..

—Сөйләмә әле булмастайны. Минем аларга колагым да селкенми.

—Колагын селкенмидер анысы... Балалар дим, кайчан кузгалалар?

—Бүген өйләдән соң. Шуна малайны ашыктырам. Барысын да үз вакытында хәстәрләргә кирәк. Табибка үзенә бер олау бирелә. Болай хезмәтчегә барысын да әзерләп куярга кушкан идем дә... Җәй айлары бит, туктыйтуктый барырлар дигән булды хан хәзрәтләре.

—Әйт әле, атасы, нинди кыз бала кырык хатын куенында яткан ир янына ашкынып барсын инде. Каханның раввалары да килгәннәрме?

—Айбибидән күзләрен дә алмыйлар. Яраннары белән сөннәтле казаклары да шунда. Тәмам корычка төренгәннәр. Унлап равва, берсеннән-берсе тәкъва, берсеннән-берсе тәкәббер. Кырык беренче хатын булып тартыла бит бала. Имеш, бу йола Сөләйман пәйгамбәр заманнарыннан ук килә.

—Бездән тагын кемнәр озата бара инде хан кызын?

—Рәшидә абыстай. Зарланды әле ул. Мин аннан кайта алмам инде, хушлашыйк, Хәбибулла, дигән була. Мин әйтәм, олау-олау кайтырсыз әле, олау-олау.

—Нигә алай дисең, атасы?

—Угызлар теш кайрыйлар.

—Кемгә?

—Хазарстанга. Угызлар белән без дә кардәшләшеп беткән инде. Әнә шулай, Мөхәммәд хан ике ут арасында калып бара. Кахан кул астында ич без. Угызлар да канкардәшләр, Йосыф кахан да кияүлеккә йөз тота. Угыз ханы да улына Айбибине сораган иде. Мөхәммәд хан Йосыф каханны сайлады.

—Тагын, тагын кемнәр озата?

—Алпар йөзбаш. Айтуган йөзбаш та озатырга җыена дип ишеттем. Имеш, Айбиби исән-имин Йосыф кахан кулында булырга тиеш. Ә бит Айбибине бәҗәйләр ханы Түрә дә улына сораткан иде.

—Һәй, атасы, ул бәҗәйларның бер дә кыйблалары юк диләр ич. Әле тегеләргә ялланып сугышалар, әле боларга.

—Әйе, кәҗәнең маллыгы—бәҗәйнең кардәшлеге... Тик бит бәҗәйләр дә безнең төрки кардәшләребез, анасы. Иншалла, барысы да әйбәт булыр. Мин, әйтик, үзем бик борынгы төркиләрдән. Нәсел тамырым Идел буе Болгарын аякландырып җибәргән Кодрак ханга барып тоташа.

—Ә минем атам-бабаларым Түрә ханнан. Шуннан ни, атасы?

—Кодрак ханның орлыгы Атилла ханга барып ялгана.

—Түрә ханның орлыгы атаң башынамы. Әллә ниләр сөйләп утырма әле, атасы. Орлык, имеш.

—Гөлзифам, Гөлзифам дим. Ничә тапкыр әйткәнем бар сиңа, хатынкыз бер генә баласын да су буеннан, кишәрлектән, йә әрәмәдән табып алып кайтмый.

—Беләм,—диде Гөлзифа. Кайнарланып, торып, йөрәп килеп, ир каршына басты.—Беләм, беләм, атасы, беләм. Тик менә син соңгы көннәрдә миңа, хатыныңа орлык салырга оныта башладың. Әллә соң ханның кәнтәйләренә сала башладыңмы ул орлыгыңны?..

—Сөбханалла, ни дигән сүз инде ул тагын! Малайның тынлап торуы бар.

—Әйтсәм әйтим инде, атасы, күрше Мәйсәрә югароч чишмәдән ике кыз табып алып кайтты. Өченчесенә җыена.

—Надан карчыклар сүзен сөйләмә әле, анасы. Кемгә кирәк ул синең иләк авызлы Мәйсәрәң?!

—Һи-и, атасы-атасы, башыңны җүләргә салып утырмасана. Мәйсәрә кебекләрне ил бетереп эзлиләр. Чөнки ел саен бер бала таба. Әле әрәмәдән, әле...

—Әрәмәгә син дә йөргәлә...

—Жир уба сине, атасы, билләһи, жир уба! Күр әле, чәчәктәй күрше хатынына ни әйтә. Колмак җыярга төшә ул әрәмәгә, ипекәй камырын кабартырга чүпрә ясарга...

—Шуннан кабарып кайтамы?

—Яһүдләргә сата ул колмакны, яһүд сәүдәгәрләренә.

—Урман-әрәмә тулы шүрәле бездә, шүрәләләрдән дә курыкмыймы Мәйсәрәң? Шүрәләләр бит кети-кети уйнарга ярата.

—Минем әрәмәдә ул шүрәләләрне күргәнем булмады, атасы. Күргән булсам, бәлкем, кети-кети уйнап алган булыр идем. Әйе, мин кемнән ким.

—Син, анасы, калада бер абыстай, хан табибы хатыны. Хан табиблары чуер таш түгел, җирдә сибелеп ятмый.

—Алай бик борының чөймә әле, атасы. Куй әле шаяртуыңны. Малайга кайсы атыңны бирәсең?

—Туры айгырны алыр.

—Юк, атасы, туры айгырың бия күрдеме күзе-башы тона. Син аңа алмачуарны бир. Былтыр Сабан туенда икенче булып килгән атны. Ул иплерәк...

—Ярый, шулай итәрмен.

—Карале, атасы, туктале-тукта. Әллә соң синең дә күрше Мәйсәрәгә күзең төштеме?

—Күз—шайтан, уй—йолдыз. Мәйсәрә болай ирләр күзе төшмәслек хатын түгел кебек, анасы.

Гөлзифа бермәлгә мутланып киткән иренә ни әйтергә белми югалып калды. Болай да калку янбашлары тагы да калкып киттеләр, ул да түгел, ишекле-түрле йөреп килде.

—Җүләрем Хәбибулла, мине беләсең килсә, тилергән аккоштан башка берәү дә кочмады. Хак, Хөршидә туенда Мөхәммәд хан билемә кулын салган иде, сыптырмадым инде, ханыбыз ич...

—Хан кадәр ханның кулы сина тартылган икән, димәк, син, Гөлзифакаем, баллыларның баллысы, татлыларның татлысы.

—И-и-и атасы, без синең белән үртәшеп торабыз, ә Мөхәммәд хан ут йотадыр. Йосыф каханга икенче кызын озата бит инде, икенче кызын, алма кебек кызларын. Кахан дигәч тә ни хакы бар аның бер көтү хатын белән торырга?!

—Бусы баш хатын булып бара, баш хатын булып!

—Баш хатын булмагае таш булып барсын—кырык хатынга бер ир, әйтсәм әйтим инде, кырык хатынга бер ир, кырык тавыкка бер әтәч кебек бит ул.

—Айбибидә абыстайлар акылы бар, анасы, кайгырма, бирешмәс. Шәех тә ул баланы мактап бетерә алмый. Каханны ничек кул астына алырга җаен табар, табар ул бала. Хатын ир белән, ир ил белән идарә итә.

—Безнең Исламны да шул шәехкә сабак алырга бирә алмадың, атасы.

—Дөнья үзе мулла, анасы, дөнья өйрәтә адәм баласын ничекләр яшәргә. Белем белем белән, тормыш тормыш белән.

—Балакаем, Айбибине әйтәм, атналар элек кенә бер гамьсез уйнап йөридер иде, шул баланы кахан кадәр каханга богаулап алып китсеннәр инде.

—Кайгырма, анасы, киләчәктә һәр кыз бала бары тик үзе сайлаган егетенә генә кияүгә чыгар.

—Кайчан буласы инде ул көннәр, атасы?

— Ахырзаманнан соң, ахырзаманнан соң.

—Ә халыкның бер дә хан кызы Айбибине Хазарстанга җибәрәсе килми, барысы да кызганалар.

—Бала ата-анага гына түгел, барча халыкка да газиз, Гөлзифа.

Гөлзифа тынычлана төште, ире кырына килеп утырды.

—Карале, атасы, ул бала аркасында безнең дивана ул-бу яманлык кылып ташласа? Хан кызы безнең улыбызның күнеленә ут салган булса?

—Нинди ут тагын ул?

—Мәхәббәт уты. Кашан кызлар тавында син җүләрне күргәч, миңа да кабынган иде ул ут. Күлмәгем яна дип торам.

—Очраштык, сөйләштек, вәгъдәләр бирештек, нигә шунда күлмәгем көйри башлады дип әйтмәдең соң?..

— Һәй, сиңа сөйләдеңни дә, сөйләмәдеңни, башыңны җүләргә салып утырма ләбаса. Үзең дә имчәк бозавыдай тагылдың ич үземә. Гашыйк булу яман гамәл бит ул, бигрәк тә яшь чакта.

—Гашыйк булу бәхет ул, анасы, кеше башына ишелеп төшкән бәхет.

—Безнең дивана хан кызын урлап бажайларга качса?..

—Көтүдән качкан атка тышау салалар, анасы. Йә, мин углан янына чыгыйм әле, ни кырып ята икән.

Шулай диде дә табиб Хәбибулла, торып, ишеккә таба китте.

Гөлзифа тәрәзәгә барып капланды. Бала газиз иде анага. Ә ул угылын да, ирен дә ярата иде.

## II

Карачы апа һәм Рәшидә абыстай һәрдаим хан кызы Айбиби кырында булдылар. Сарайда хезмәт иткән барча хатын-кыз хан кызын озатырга чыккан иде. Айбиби утырып китәсе арбадан ерак түгел Мөхәммәд хан, аның янында атын йөгәненнән тоткан җансакчысы тора. Димәк, Мөхәммәд хан басу капкасына кадәр озатачак, бәлкем әле, арырак та барыр. Сарай ишегалдында күпсанлы олаулар, мичәүләп җигелгән беришләр. Беришләргә җигелгән атлар икесе дә бер төстә. Атлар талымсызланып ыргыла, кучәрбашлар аларны тыя төшеп, дилбегәләрен еш-еш тартып куя. Иң алда, кирмән капкасы янында диярлек, түбәсе рум чүпрәге белән капланган үтә бизәкле арба—хан кызыныкы. Арба янына һаман хатын-кыз агыла. Хатын-кызлар, гадәттәгечә татар-төркиләргә хас чуар киемнәрдән, кызыл читекләрдән. Читекләренә төрле чәчкәләр чигелгән. Ярата хатын-кыз матурлыкны. Мөхәммәд ханга хатын-кызларның чуар киемнәре ошый—бала итәкле күлмәкләре дә, берьякка авып төшкән алтын-көмеш җепләр белән укаланган калфаклары да. Хан кызының башында да шундый ук калфак, өстендә алтын җепләр белән тукылган җилән, муенында сандугач күкәе хәтле гәрәбәләрдән җыелган муенса, кулларында көмеш беләзек, бармакларында җемелдәп торган зөбәрҗәт ташлы йөзекләр. Барысының да күзләре хан кызында. Яшь ич, гүзәл ич, сылу ич кыз! Хан кызы үзен ураган хатыннар белән сөйләшә, ә күзе, чак кына арырак басып торган атасы ягында. Очар кошлар туган якларына әйләнеп кайтсалар да, кияүгә чыкканнан соң кызларның бик сирәкләре туган туфракларына кабат аяк баса, бигрәк тә хан кызлары, чөнки алар күп очракта чит ил ханнарына кияүгә чыга. Айгөле дә мәңгегә киткән кебек бәхилләшкән иде. Һәй елады да мәрхүмә. Аңа карап Мөхәммәд ханның да күзләре яшь белән тулышкан иде. Бусы нигәдер бер дә сыкранмый, елмаякөлә, әле тегенә шаяртып дәшә, әле монысына. Кыз янында авызына керердәй булып Рәшидә абыстай басып тора—баланы үстерүче, аңа дөньяви хәлләрдән белем бирүче. Әмма Айбиби аны тыңламый, күз карашы белән кемнедер эзли, тапмый булса кирәк, арба баскычына баса, аяк очларына күтәрелә. Аяк очларына басканда хан кызының чигүле читекләре күренеп китә, артык үрелеп карагангамы, башындагы калфагы кузгалгандай итә, хан кызы кемнедер эзләвен дәвам итеп, калфагын җай гына төзәтеп куя, һәм янә атасы Мөхәммәд хан ягына күз ташлап ала.

Мөхәммәд хан кызына ияк кагып кына җавап бирә. Имеш, рәхмәт кызым, сер бирмисең. Ханның уйлары әллә кайда. Ә бит Айбибине сорап, Өрәк елгасы буйларында җәйләгән бажайлар ханы Түрә дә килгән иде,

үзенә түгел, улына сорап. Ике ай элек кенә булды бу хәл. Ислам динен яңа танып ята икән Түрә хан, башта Дала ханын шуның белән котлады Мөхәммәд хан. Ачык далада йөри-йөри ханның йөзе тутлаган, чәче көл төсенә кергән. Улының исеме-аты Айдар диде. Матур исем. Иседе җисеменә туры килсә, Мөхәммәд хан ике дә уйламый биргән булыр иде егеткә Айбибиен. Һәм Түрә хан яучы йөзендә килеп киткәч, шулайрак ниятләгән иде дә. Тик насыйп булмады кыз Түрә хан улы Айдарга. Кахан раввалары өлгеррәк булып чыкты. Әле дә булса күз алдында: Түрә ханның китүенә көн дә үтмәде, Болгарга өерләре белән яһүд раввалары килеп төште һәм, табынга утыруга, Мөхәммәд ханның Айбиби атлы кызын Йосыф кахан Йортына тарттыру турында сүз башладылар. Һәм үтә кыю рәвештә, хәтта Мөхәммәд ханга авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Халык теленә бажайлар дип кергән бөҗәнәкләр ханы Түрә белән бер-берсенә ярдәмләшү, теге йә бу явыз ният белән ил өстенә килгәндә аркадаш булу турында да вәгъдәләшкәннәр иде югыйсә. Ләкин соңгы елларда биш анадан туган бажай-бөҗәнәкләрне мәҗүси угызлар көнбатышка таба кузгатты, шул сәбәпле күпсанлы угызлар Хазарстан җирләренә кереп җәйли башладылар. Әмма угызларга кахан аркылы төште. Мөхәммәд хан кардәше буларак угыз ханына ярдәм дә итә алмады, каханга ярдәмгә гаскәрен дә җибәрмәде. Әмма каханга тиешле ясакны һәрдаим түләп торды. Әрсезләнеп киткән кахан Болгар халкыннан гаскәриләр таләп итте, ул гынамы, җиткән бер кызын сараена тарттыра башлады. Бабалары Алмас хан, мәрхүм, Хазар каханы кул астыннан чыгу өчен Багдад хәлифенә мөрәҗәгать итә, ахыр Ислам динен дәүләт дине дәрәҗәсенә күтәрә, әмма хәйләкәр хәлиф Болгарга ярдәм акчасын җибәрә алмый, ә менә дине илгә ябышып кала. Ил вә халык инде күптән Ислам диненә йөз тота. Вә ләкин бүген Мөхәммәд ханга аркадашлар кирәк иде. Бик кирәк. Явыз рәвештә Әскәр каханны үтереп, баскынчы варяг Хельг Кара Болгарны үз кулына төшерде. Ә бит Ислам дине Кара Болгарга да кереп бара иде инде. Әнә шул баскынчы Хельгнең дәвамы бүген Дунай буе кардәшләрен туздырып йөри. Дунай буйларында көн күргән кардәшләребез мишәрләрне рәнҗетә. Шушындый буталчык чорда Мөхәммәд хан кемгә йөз тотарга тиеш?.. Каладыр бер кеше—Йосыф кахан. Яһүд раввалары кул астында ил белән идарә итсә дә Йосыф кахан төрки җанлы, углан канында төркиләр каны ага иде. Димәк, Мөхәммәд хан яраткан кызын каханга биреп җибәреп дөрес эшли, хаталанмый.

Мөхәммәд хан янә-янә кызы утырып китәсе арба ягына күз ташлап ала. Аңа яраткан кызы елмаеп кул изи, шатланган кебек кылана, ә бит бөтенләйгә китә балакай, бөтенләйгә...

Соңарды, соңарды бажайлар ханы Түрә, ике-өч ай алданрак киләсе калган. Хәзер соң инде, һични кылып булмый. Чарасыз иде Мөхәммәд хан. Туганые Талиб ничәмә еллар тәхеттә утырды, бер генә кызын да кахан Йортына җибәрмәде, бер генә кызын да. Ә менә анардан кахан кызлар таләп итә, ясак түләтү генә җитмәгән, кызларын да сараена тарттыра. Хан акылына сыя торган гамәл түгел иде бу. Бер-бер хәл булыр ул каханга, булмый калмас, әмма хәзергә Мөхәммәд хан сабыр итәргә, тешен кысып булса да барысына да түзәргә тиеш. Бәхәссез, бу кызы да туган ягына әйләнеп кайтмаячак. Моны Мөхәммәд хан гына түгел, кызны озатырга килгән һәммәсе дә белә. Тик хан кызы үзе күрше ыстанга утырмага барган кебек кылана иде. Юри кыланамы бу бала, әллә булмаса ихтыяр көче олыданмы?.. Иненә ишелеп төшкән кайгыны бар кеше дә яшерә белми, ихтыяр көче нык булган кешеләргә генә хас сыйфат бу. Әнә шул көчне күрде Мөхәммәд хан Айбиби кызында. Ялгышмаса, күңеле хак тәгаләдән ерак йөрмәсә, бу кызы апасына охшамас, бара-баруга каханга тышау салыр, иншалла. Димәк, кызның көлү-елмаюында ниндидер сәбәп бар. Халык кына түгел, атасы Мөхәммәд хан да күреп бетермәгән сәбәп. Ни? Нинди сәбәп? Олуг сәясәткә йөз токтан сәбәпме, әллә соң самими балалык халәте генәме?.. Тукта, тукта, кемне эзли бу кыз бала карашы белән?.. Күрче, Алпар йөзбаш янында торган табиб Хәбибулла улына кул изи ич бу бала!

Йа Хода, моны ничек аңларга инде тагын? Кичә үзе үк егет белән урман аша чыгып, аккошлар култыгына чыгарга рөхсәт бирде ләбаса!.. Китәр алдыннан булса да жилләнеп кайтсын дип кенә жибәргән иде югыйсә. Әллә соң шул арада табиб Хәбибулла улына гашыйк булдымы кыз? Һич булмас димә. Яшьлектә була торган хәл ич! Менә монысы кирәкмәс иде. Мөхәммәд ханның бер дә Йосыф каһан белән бәхәскә керәсе килми иде. Әлегә кадәр шөкер итә, кул-аяк богаударак булса да барысы да әйбәт кенә бара иде шикелле. Хан буларак ил-халкы белән ару гына идарә итә. Хак, як-ягына шайтаннар кебек каһан карачылары баскан, кайчак хәтта борылырга да бирмиләр, һәр адымын күзәтеп торалар. Әнә, яраткан кызын да Түрә хан улына ярәшергә өлгермәде, көне белән диярргә була, каһан раввалары калага килеп життеләр. Фәрманга каһанбәк үзе кул салган. Имеш, Айбиби кызын үсеп-исәеп житкән икән инде, син аны каһан кырына озат. Имеш, каһанның кызны күрәсе килә. Күрәсе генә килсә бер хәл, каһан аны кырык беренче хатын йөзендә баш хатыны итмәкче. Ә кырык беренче хатын һәрдаим каһан кырында аерым тәхеттә утырачак. Хазарстан төркиләре арасына килеп, ил дилбегәсен үз кулларына алган яһүд раввалары үзләренә бер мәһабәт сарайда яши башладылар. Гарәпләр ул каланы ак кирпечтән күтәрелгәнгәме, Ай-Балда дип язалар, гади халык Аккала дип йөри. Ә гади халык—мөселманы, христианы, мәҗүсие—Иделнең сул ягындагы Ханбалыкта көн күрә. Шул исәптән каһан гаскәрбашы Сабир да шул калада утар тота, әмма аңа каһан кирпечтән өй салырга рөхсәт иткән, калган халыклар исә өйләрне сәмәннән генә салалар. Сабир каһанбәк тә яһүдә хатынга өйләнгәнгәме, балаларын каһан сарае мәдрәсәсендә укыта.

Айбиби кызын Алпар йөзбашка озатырга тапшырып дөрес эшләде Мөхәммәд хан. Күр әле, йөзбаш кырында алмачуарга атланган кем ул?! Сөбханалла, Хәбибулла улы ләбаса! Шул үзе, кичә Айбибине Аккошлар култыгына алып төшкән егет. Инде нишләргә? Егетне алып калыргамы, әллә соң барысына да кул селтәп, һични кылмаскамы?.. Әйе, барысына да күз йомарга... Шулчак Мөхәммәд ханның гүя зиһене ачылып китте: кызны каһан раввваларына исән-имин биреп жибәрдем, калганын Тәнремә тапшырам, ни язганы булыр. Шул уй башына килүгә, Мөхәммәд хан атына атланды һәм камчысын күтәрде:

—Кузгалырга, юлга!

Иң алдан киң итеп ачып куелган кальга капкасына таба хан кызы арбасы кузгалды. Алпар йөзбаш үз яраннары белән капкадан чыгып ук бара иде инде. Хан кызы арбасы артыннан бер тотам калмый бирнә байлыклары төялгән олау кузгалды. Мөхәммәд хан иелеп, атның ял астын сыпырды. Имеш, сабыр ит. Ат иясен аңладымы, бермәлгә шым булды, юкса, олаулар кузгалуны күреп тыпырчына башлаган иде. Шулай да яхшы ат буларак, иясенә канәгатьсезлек белдергәндәй көмеш тәнкәләр тезгән иярен зеңләтеп алды. Кеш тиресе белән каймалган, аю тиресе салган иярдә утырган хан жансакчысына:

—Аллага тапшырдык!—диде дә, атын жилле генә юырттырып, кальга капкасыннан чыгып китте.

Шәһәр капкасына житкәч кенә олау туктады, хан кызы арбасыннан төшеп, атасын көтеп алды. Мөхәммәт хан кызына житә-житүгә атыннан төште, ат тезгенен жансакчысына ташлады да кызын кочагына алды.

—Кызым-бәгырем, рәнжеп китмә атаңа, зинһар рәнжи күрмә...

Ханның тавышы калтырап куйды, күзенә яшь пәрдәсе эленде. Мөхәммәд хан ни кылырга белми, бертын кызын кочаклаган килеш торды да, бераз тынычлангач, арба кырында басып торган шәехкә һәм абыстайга күз яшен күрсәтмәскә теләп булса кирәк, атына таба борылды һәм барыр жайда:

—Кузгалыгыз!—дип кулын күтәрде. Шул мәлдә хәтере аша бер вакыйгага узды. Сарай табибы Хәбибулланың улын беренче тапкыр сарайда күргәч, егетне ошатып булса кирәк, уенын-чынын бергә кушып: "Кияүләр үсә, Хәбибулла",—дигән иде. Әмма табибы дә югалып калмады: "Сәнең кызла-

рың дөньяда бер гүзәлләрдер, хан. Хәер, чибәрләрне бакчада су сибеп үстермиләр, алар ханнар кочагын татыган гүзәл хатыннардан туалар",—диган иде.

Чибәр, сылу һәм үтә зифа сынлы Айбиби Мөхәммәднең күз каршында үсте. Бу балага, бу баланың сөйкемлелегенә, акылына, гүзәллегенә сарайда сокланмаган кеше юк иде. Айбиби бала чакта да, буй алгач та, житкән кыз булгач та гүя сарай бакчасы гөле иде. Әнә шул бакча гөлен, ил бакчасы гөлен диярга була, Мөхәммәд хан Йосыф кахан кырына биреп җибәрде. Хан борылып киткәндә ни әйтте соң әле яраткан кызы Айбиби?

—Сау бул, атам, сау булыгыз туганнарым, җанкайларым!..

Үзе атасы һәм халык белән саубуллаша, үзе елмая-көлә, йөзендә шатлык нурлары бии. Мөхәммәд хан кызын аңлады да, аңламады да. Хак, кыз бала сугым түгел, пычак астына алып китмиләр, әмма нигә алай шатлана, көлә-елмая ул?..

Мөхәммәд хан калага таба борылды, кайтыр юлда ул җансакчыларына берсенә бер кәлимә сүз әйтмәде. Кәефе кырылудан түгел, күз алдында торган кыласы хыяллары тормышка ашмаган өчен. Яратмады ул үз кырындагы Йосыф кахан шымчыларын, яратмады һәм бер тапкыр да алар белән ачылып сөйләшмәде, чөнки сөйләшер, киңәшер сүзе юк иде. Сатлык җан һәр чорда да сатлык җан булып калачак, хәтта теге дөньяга киткәч тә иблискә йөз тотачак ул адәм, ди торган иде атасы. Талиб хан чорында каханның бер генә шымчысы да сарай түренә узырга кыймады, чөнки Талиб хан аларны үтәли күрер, бер тапкыр да тәхет ягына уздырмас иде. Һәр илбашының сер сөйләрлек үз кешеләре була, ә сезнең белән минем боткам пешми, дип кенә әйтер иде. Ә бит баштагы мәлдә Хазарстан белән Идел буе Болгары тиңдәш рәвештә кушылганнар иде, еллар үтә-үтә каханат көчәеп китте һәм Идел буе Болгар дәүләтен үз канаты астына алды, дөресрәк итеп әйтсәк, буйсындырды. Әле ясакны арттырды, әле гаскәриләр сорый башлады. Бу инде каханатның узынуы иде. Ләкин кайчанга кадәр барыр бу узыну?.. Бәлкем, Хазар каханатына нәкъ менә Мөхәммәд хан тәхеттә утырганда нокта куелыр. Бик мөмкин ич, чөнки каханатка башкалар да баш бирми башладылар. Сукыр түгел, моны гына күрә иде Мөхәммәд хан. Заманында Мөхәммәд хан канкардәшләре бәҗәнәкләргә өмет иткән иде, барып чыкмады, күчмә халык буларак, көчәеп килгән угызлардан куркып, алар көнбатышка таба күченделәр. Бөҗәнәкләрнең җәйләүләрен угызлар биләде. Хазарстан яһүдләре сөннәтле казакларга таянып, угызларны ил-җирләренә кертмәскә иткәннәр иде, тегеләр сорап та тормадылар—йөзем бакчаларына кадәр таптап уздылар, әйе, өермәдәй. Сөннәтле казаклар каханны ташлап китеп, кара урманга кереп постылар. Угызлар киткәч, шуннан торып, каханга хезмәт күрсәтә башладылар. Кара урман эчендә үзләренә кала күтәрделәр, хәтта Идел буе Болгары белән сәүдә итә башладылар. Бу хәлдә, әлбәттә, поскан сөннәтле казакларга яһүд сәүдәгәрләре ярдәмгә килде. Болгарга килеп оялаган гарәп имамнары угызларны мәҗүсиләргә саный, алты мең ел буе төркиләр табынган Тәңрене мыскыл итүгә кадәр барып җитәләр иде. Сараена кереп оялаган имамнарның бу хәле дә Мөхәммәд ханга ошамый. Әмма кала-салаларга мәчетләр күтәреп, иртәнге якта азан әйтә башлаган имамына кагылудан куркып, башбаштаклыкларын күрсә дә күрмәс булды. Имамнар гына түгел, Йосыф кахан яһүдләре дә аның һәр адымын күз угында тота. Мөхәммәд хан Айбиби кызын Йосыф каханга үзе кодалады. "Кызым, кызыкаем, сине анда хөрмәт итәрләр, кахан сине күрү белән гашыйк булыр, сине беренче көннән үк баш хатыны итәр. Тора-бара акыл белән эш итсәң, син каханның уң кулы булырсың, хәтта ил белән идарә итә башларсың. Чөнки борынгы бабаларыбыз: "Хатын ир белән, ир ил белән идарә итә", дигәннәр. Күрде ич, Айбиби кызы моңа бер дә гаҗәпләнмәде, ничек кирәк шулай кабул итте. Кыз гүя үз сәләтенә вә көченә ышана иде. Моны күреп Мөхәммәд хан: "Бирсен Ходай",—дип кенә әйтә алды. Шул ук вакытта әрнүле бер кимсенү тойды—икенче кызын озата бит инде. Айгөл кызы, бичара, ка-

ханга угыл бала таба, ә үзе баласына күкрәк сөтен дә бирә алмый вафат була. Бусы белән ни булыр?.. Айгөл кызының улы исән, баланы тәрбиягә Йосыф каханның анасы Сара ала һәм, ни сәбәпледер, Аккаладан Таман тархан төбәгенә күчеп китә. Углан канкардәше Гали тархан карамагында үсә. Аты Гаязетдин диделәр. Угланны һәм әбисе Сараны Мөхәммәд хан Болгарга да дәшеп караган иде, әмма анакай: "Балигъ булгач, балигъ булгач..."—дип әйтеп әйткән, дип ирештерделәр Мөхәммәд ханга.

Хазарстан каханының канат астына хатыннар җыю гамәле белән килешмәде. Мөхәммәд хан киявенең бу гамәлен кыргыйлыкка, гафиллеккә кайтарып калдырды, гәрчә үзе мөэмин-мөселман буларак өч-дүрт хатын белән торырга хаклы булса да. Ислам диненең бу чарасы белән килешеп җитмәде Мөхәммәд хан. Ләкин ул идарә иткән халык, халыкның тоткан дине Ислам дөньясы кануннарына йөз тотарга мәҗбүр иде. Ни генә булмасын, Мөхәммәд хан өчен мең еллар элек кагыйдәләштерелгән йолакагыйдәләр, тәртипләр, кануннар бүгенге көнгә кадәр үз көчендә кала аламы? Ә бит кешелек һәрдаим тәрәккыяткә омтылган һәм шунда ихласи хакыйкать тапкан. Әйтик, ничек анларга Мөхәммәд пәйгамбәрнең: "...кемнәр хак юлга керәләр, алар минем карендәшләрем булыр, кемнәр исә каршы төшәләр, алар минем дошманнарым булырлар», дигән сүзләрен? Моны ничек анларга, ничекләр башка дингә табынган халыкларны дустанә-тату яшәргә өндәргә? Хазарстанга кылыч белән Ислам динен китергән Мәрван сәргаскәр гамәле беләнме? Кан коеп. Кяферләр, имансызлар ич дипме?! Тарихта билгеле, сонрак Хазарстанга яу килгән сәргаскәр Маслама Биләмҗир каласын ала. Кан коюю шул чиккә җитә ки, ир-ат әсирләрне вә үсмер ир балаларны кылычтан уздырта, әсирләр үтә күп булу сәбәпле меңнәрчә кешене Сулак елгасына батырып үтерергә әмер бирә. Шушы кешеме Ислам дине варисы?! Бу буладыр милади белән 723 елда. Багдад хәлифе милади белән 735 елда инде картаеп килгән сәргаскәр Масламаны янә Хазарстанга яу белән җибәрә. Хәлиф сәргаскәре башкаланы ала, кахан далага кача. Сәргаскәр Маслама каханның гаиләсен вә куштаннарын әсир итә һәм каханга шарт куя: ил-дәүләтең белән үзең идарә итәсең, гаиләнне-куштаннарыңны да кайтарырмын, тик Ислам динен генә кабул ит. Кахан риза була. Маслама шундук Далага качкан каханга үзенең имамнарын җибәрә... Әлбәттә инде, Ислам дине әкренләп каханның аркадашы булган Идел буе Болгарына да үтеп керә. Бары тик шул гына. Ләкин бит дин аркасында Болгардан йөзләрчә гаилә башка илләргә күчеп китә. Болгар дәүләте өчен бу да зур югалту. Мөстәкыйль Болгарны кул астына алгач, Йосыф кахан яучылары Мөхәммәд ханга Айбиби кызы өчен алтын таулар вәгъдә итте. Мөхәммәд хан мона ышанды да, ышанмады да. Империя куәтенә ирешкән Хазарстан үз кулы астындагы ил-халыкларга вәгъдәләр биргәләде инде, вә ләкин берсен дә үтәмәде, барысы да ялганга корылган булып чыкты. Кахан исеменнән Болгарга ташламалар ясарга вәгъдә иткәндә Мөхәммәд хан яучы раввaларга бер сүз дә әйтмәде, яучыларны рәнжетүдән түгел, ә вәгъдәләрнең үтәлми калуын яхшы белгәнгә дәшмәде ул. Бары тик ирен чите белән көлемсерәп кенә алды. Тарихта булган хәл, Хазар каханы 922—923 елларда Ханбалыктан мөселман сәүдәгәрләрен куа. Алар Идел буе Болгарына олау-олау күчеп киләләр. Алмас хан исә аларга каладан урын бирә—Ага Базардан. Болгар халкы өчен кулай гамәл иде бу. Тик күп тә үтми Хазар каханы Харәзем сәүдәгәрләрен Идел буе Болгарына уздырмый башлый. Бу хәл исә Мөхәммәд ханны янә кыен хәлгә куйды.

Харәзем аша Идел буе Болгары базарларына чиннар гына түгел, фарсы-согдиан һәм гарәп сәүдәгәрләренең кәрваннары да килә, аларның күбесе хәтта Казан төбәгенә хәтле узалар иде. Бәлкем, Айбиби кызы Йосыф кахан кырына барып җитеп, каханның баш хатыны булып киткәч, раввалар Харәзем сәүдәгәрләрен дә Болгарга уздыра башларлар. Бу хакта Мөхәммәд хан җай китереп, Айбиби кызына читләтебрәк булса да әйткән иде.

Сарай-кальга капкасына җитәрәк, асма күперне төшергән арада, Мөхәммәд хан үзенә таба чаптырып килүче җайдакны күреп, атыннан төште һәм

тезгенен җансакчысына ташлап, җәяүләп асма күпергә таба китте. Килеп җитәр-җитмәс, хан кальгага кереп китәр дип булса кирәк, җайдак кычкыра ук башлады.

—Олуг хан, олуг хан!

Мөхәммәд хан туктады, җайдак исә, килеп җитәр-житмәс атыннан сикереп төште һәм, хан янына йөгерә-атлый килде дә, бер тезенә төште.

—Йә?—диде аңа Мөхәммәд хан.—Әйт, әйтер сүзеңне?

—Олуг хан! Дунай Болгары кардәшләребез Пәхлеван ханның улы Шәмгун капкадан кереп ята. Углан Болгарга зур йөк белән килә, Сез галиҗәнапләре каршына.

—Сөенчеме, көенечме китерә углан?

—Ханнар сере—Аллаһ сереләр, ханым-солтаным! Сөенечен дә, көенечен дә үзе җиткерер.

—Зур йөк беләнме?—диде Мөхәммәд хан һәм җансакчысына атын китерергә ишарә ясады.—Пәхлеван хан христиан динен кабул итеп ята дип ирештерделәр миңа, димәк, улы атасы белән килешмәгән,—дия-дия сөенче китерүчегә бөтенләй игътибар итми, атына атланды да, күпергә таба кузгалды.

Пәхлеван кардәшенең христиан динен кабул итүе Мөхәммәд ханга ошамады, ләкин ул моңа ышанып та җитмәде. Ата-бабаларыбыз гасырлар буена табынган Тәңре диненә хыянәт иткән үз бабаларына да рәнҗүле иде Мөхәммәд хан. Бит Тәңре дине дә Күктәге Тәңре алласы аша гаделлекне эзләгән. Аллаһны да имамнар күктә дип расларга тырышалар. Мөхәммәд хан бу ике диндә һәрдаим уртаклык эзләде һәм күп очракта кайбер кануннары тәңгәл килүгә кинәнер дә иде. Христиан динен кабул иткән төрки туганнары исә бер Аллалыктан баш тартып, үзләренә Иисус Христос язмышы хикәятен уйлап таптылар һәм шул пәйгамбәрне өч йөздә күрә башладылар. Әнә шулай Византиянең епископлары, императорлары Аллаһының җирдәге илчеләренә әверелде. Бу хакта да яхшы белә иде Мөхәммәд хан. Тик менә буласы кияве Хазар каханы уздырган сәясәтне генә аңлап бетерми иде. Әмма күп очракта аның белән дә килеште, бер халык ич. Чөнки раввалар урап алган кахан үз илендә диннәргә ирек биргән, әйе, элегрәк бу гадәти хәл була, вә ләкин заманалар үзгәрә ич, кахан да, гәрчә үзе төрки телдә сөйләшсә дә яһүдиләр диненә өстенлек бирә башлый. Бусын инде Мөхәммәд хан үз күзе белән күреп торды. Әмма, янә гөнаһка санамады, чөнки кахан һәм раввалар Аккала дигән сарай-утрауга кереп бикләнсәләр дә буйсындырылган халыкка үз диннәрен көчләп такмадылар, ә бит христиан руханилары, шул исәптән мөселман руханилары да диннәренә түндерү өчен кылычка ябыштылар. Кая монда гаделлек?! Гаделлектән ерак хакыйкать иде бу. Иллә хан буларак ул ил халкыннан аерыла алмады, аерылырга да теләми. Димәк, кардәшен якларга Мөхәммәд хан дөрес кузгалды.

Әнә шундый уйлар узды юлда барганда Мөхәммәд хан башыннан. Бүген һәр халык үз диненә таянып, үз кыйбласын сайлый. Ахыр килеп, кайсы дин хакыйкатькә якынаеп, башкаларыннан өстен чыгар—монысын бер Аллаһ үзе генә беләдер.

Әле булса хәтерендә, бу юлдан бик күп төрки кавемнәре көнбатышка таба кузгалган. Шундый чорлар да, булган. Алмас ханның оныгы Арпат, мажарлар кавемен җитәкләп, көнбатышка таба юнәлә. Ерак бабаларының җирләренә барып утырырга итә. Тик менә ни өчендер, Арпат углан үзләренең кардәшләре Дунай буе Болгарына ябырыла, илбашы Сәмигъ ханны елганың уң ягына чигенергә мәҗбүр итә. Бу хәлгә аны Византия императоры котырткан, дигән фаразлаулар да бар-барын. Ахыр чиктә Дунай буе Болгар ил-халкын талагач, Паннониягә юнәлә, әмма мин монда төпләндем инде дип, халкын Дунай буенда калдыра. Чигенсә дә көч-куәтен югалтмаган кардәше Сәмигъ хан, көтмәгәндә мажарларның елга буенда калган халкына ябырыла. Ил-халыкларын сакларга калдырган гаскәриләрне тар-мар итә, әсир төшкән бала-чагаларны Арпат хан талап киткәннән соң, ялгыз калган ир-егетләренә өләшә, бик күпләрен кол итеп, Византиягә

илтеп сата. Әнә шулай үч-үчкә илтә, кардәш халыклар кардәшләр белән сугыша, ә моның нигезендә Византия императоры сәясәте ята: "Бүлгәлә, үзара ызгыштыр һәм идарә ит." Гаскәр белән Паннониядән әйләнеп кайткан Арпат хан таланган ил-жирен күреп, кире борынгы бабалары Атилла хан нигез салган Гунстанга (Бүгенге Будапешт) таба борыла. Ил-халкын югалткан Арпат хан каны кайнаудан юл өстендә яткан Моравия илен талый, ир-атларын үтереп, хатын-кызларын үзе белән алып китә. Менә нишләткән империя сәясәте бертуган халыкларны, гасырлар буена бертугандай күрше-шабра булып яшәгән мажар-төрки халыкларын...

Яуга чыгар алдыннан алай да, табын жыйганчы ук, Мөхәммәд хан углан Шәмгунны кабул итәргә булды. Ни әйтсәң дә бер анадан туган халыклар ич. Шәмгун углан әйткән вакытка килеп тә житте. Мөхәммәд хан һәр мөселман түрәсенә хас садәлек белән аны тәхетеннән торып, хәтта аңа таба ике-өч адым ясап, ике куллап күреште.

—Исән-имин килеп життегезме, углан?

—Шөкер кылам, шөкер кылам кардәшем. Мин Идел буе туганнарым хозурында булуыма бик шатмын. Миңа юлда ук ирештерделәр, Айбибине кахан үз кырына тарттырган икән.

—Тарттырды,—диде Мөхәммәд хан, кымызчыга касәсен сузып.—Тарттырды, Шәмгун углан, тарттырды. Кызны үз ризалыгым белән биреп жибәрдем. Айбиби дә сынатмады, бер дә аһ ормады.

—Минем атам Кияли кенәзе Сарманай белән ызгышып ята. Византия империясе безгә ясак түлисе иде, шул ясакны үзем жыям, бу төбәктә үзем түрә булып калам дип оран салды.

—Үзе генәме?

—Бөҗәнәкләрнең ялланып сугышулары бер бүген генә түгел, алар минем аркадашым угызларга да кахан белән бергә каршы чыкканнар иде. Угызлар үзләрен Өрәк елгасына кадәр кудылар, Өрәк елгасына кадәр, углан. Кһм, димәк, син, углан Идел буе Болгар ханыннан ярдәм сорарга килден?

—Атам христиан динен кабул итмәде, хан, булмады ул хәл. Мин сездән ярдәм алырга килдем, гаскәриләр сорарга... Атам әйтте, Мөхәммәд хан каханга да баш бирми ята, иншалла, ярдәм кулын сузар, диде.

—Алай-алай,—диде Мөхәммәд хан.—Кыюсың, углан, артыгы белән кыюсың. Мин үзем дә кеше кешесе ич, минем өстән кахан раввалары күзәтә, житмәсә, икенче кызымны Аккалага биреп жибәрдем. Хуш, углан, тоткан динең нә соң?

—Тәңребездер, хан, Тәңребездер. Калагызны күрдем, хан, хозурдыр кала, кая карама мәһабәт биналар, мәчетләр вә мәдрәсәләр. Бер сүз белән атам сезне көтә, хан, сезне!

—Мәнем нә якын кешем, нә тәхет йөген күтәрерлек угланым юк, Шәмгун углан. Идел буе Болгары илен якларга кем калыр соң? Мин атаңа ярдәмгә кузгалсам дим?..

—Мин, Мөхәммәд хан, мин!

Мөхәммәд хан, авызына китергән касәсен кире өстәлгә куйды, башын кырын сала төшеп, Шәмгун угланга карады, текәлеп дияргә була, хәтта сынап, ышаныр-ышанмас бер караш белән.

—Күрәм,—диде, ниһаять, Мөхәммәд хан.—Зиһенең саф, акылың үзең белән. Тик бит син әле мәжүси, мәжүси, углан.

—Мин иртәгә үк ислам динен кабул итәм, хан, иртәгә үк. Сарманай кенәз узынды, бабалары кәсебен дәвам итәргә кереште. Әле бер халыкка яу йөри, әле икенче халыкка. Хәтта Патшакаланы үзенеке итмәкче. Тик бит яман кенәзнең юл өстендә без ятабыз...

—Сарманай кенәзгә кахан да ачулы, ишеткәнем хак булса, ул да Сарыкалага төнлә яу килгәне өчен кенәзне акылга утыртмакчы. Мин дә шул тарафларга кузгалсам...

—Безгә берләшергә кирәк, хан, бергә булырга! Атам сезне көтә, хан, сезне!

—Аксакаллар ни әйтер бит әле, углан, аксакаллар...

— Алар да килешерләр, хан.

Мөхәммәд хан янә бер тапкыр сәерсенеп угланга карап алды.

—Әйе, мин барысын да көткән идем синнән, углан, әмма...

—Мин үзем белән атамның барлык байлыгын алып килдем, хан, барлык байлыгын, кызларыбызны да, асыл егетләребезне дә. Сарманай кенәз бездә берни дә таба алмас, берни дә...

— Ә картлар, ә халык?!

—Менә шул халыкны коткарырга чакырып килдем дә инде мин сезгә, хан. Баш иеп, атамның барлык байлыгын төяп.

—Хөрмәтеңә рәхмәт, углан.

—Барысына да император гаепле, хан. Үзеннән ясак түләтеп яткан атам өстенә Сарманай кенәзне җибәрмәкче. Яу йөрү өчен Сарманай кенәзгә илчесе Калакир аша унбиш кадак алтын җибәргән. Ә теге башкисәр кенәз шул алтынга алданып, үз күршеләренә яу йөрергә җыена. Император Никифор Фоке да бер дә ышанычлы һәм сүзендә тора торган кеше булмады. Бердәнбер өмет сездә, хан.

—Мин кеше кешесе ич, углан, бу яуга Йосыф кахан аркылы ятса?!.

—Тәхеттә түгел, Идел буе Болгарын сакларга мин калам, хан. Сез юлга чыгуга ук мин каханга бер генә кеш тиресе дә җибәрмәячәкмен. Каханга ясак түләү, гомумән, булмаячак.

Шәмгун углан шулай диюгә, Мөхәммәд хан бу егеттә Атилла бабаларының горурлыгын һәм кыюлыгын күреп, аркасын турайтыбрак утырды һәм көлемсерәп куйды. Яшерми, ошады аңа Шәмгун углан. Һәм бар ягы белән дә. Ләкин кешене вә батырлыкны орыш кырында сыныйлар, чәй өстәле янында түгел. Моны да яхшы белә иде Мөхәммәд хан. Шуңа карамастан, ул иртәгә үк табын җыярга булды.

—Яхшы, углан. Мин синең кинәшенне тотармын. Ахыр чиктә, угызлар белән мин солыхта, бертуктаусыз кызлар алышып вә бирешеп торабыз. Ә Йосыф каханның үз кайгысы үзенә бик җиткән. Ул да император Никифор белән Сарманай кенәзне акылга утыртмакчы, нинди юллар белән, миңа хәбәр итмәде, мин белмим. Иң мөһиме, безнең максатлар бер, углан, максатлар—узынганнарны урынына утырту...

Мөхәммәд хан вәгъдәсендә торды, яу олавын вә гаскәриләрен тиз җыйды. Табын түрендәге аксакаллары да кардәшләре булгангамы, Дунай буендагы кардәшләре дәшкәнгәме, берсе дә каршы килмәде, бары тик башына тавык оясы кадәр чалма ураган имам хәзрәтләре генә:

—Углан имандамы соң?—дип сорады.

—Углан мөслим-мөселман, имам хәзрәтләре, мөслим-мөселман!—Хан кадәр хан шулай дигәнгәме, табында бу хакта яңадан сүз кузгатмады.

Атна дигәндә җыенып, кул астына ике төмәнгә якын гаскәр туплап, юлга кузгалгач һәм ил идарәсен Пахлеван хан улы Шәмгунга тапшырып, имамнан фатиха алгач кына, Мөхәммәд хан тынычлана калды—нәкъ менә юлда, ат өстендә барганда соңгы айда булган хәлләргә, кылган гамәлләренә исәп-хисап бирә башлады. Кем алдында? Әлбәттә инде мөэмин-мөселман буларак, Аллаһысы алдында, күзгә күренмәгән, әмма һәрдаим аның күңелендә булган Аллаһы алдында...

## III

“Мин Идел елгам белән саубуллашам, мин туган туфрагым белән саубуллашам, мин аккошлар кебек туган якларыма кайтырмын, кайтырмын”,—дия-дия үз-үзен юатты Айбиби каладан чыгып, олы юлга төшкәч. Алпар яугирләре чак кына алдан бара, күк йөзендә күнел өчен генә булса да бер болыт әсәре юк. Аны хәтта болытлар да озатмый, димәк, бу аның язмышы. Тик үзе сайлаган язмыш түгел, Йосыф кахан сызган язмыш. Идел тамагындагы утрауга урнашкан Аккалада илбашы булып торган Йосыф кахан кем дә, сарай табибы улы Ислам кем аңа?.. Әнә шулай, уйлана-уйлана, Айбиби сиртмәле арбада йокымсырап китте. Колак барысын да ишетә,

юк-юк та арбалар шыгырдавы килеп ирешә. Кемнәрдер көлешә, шунда ук Айбиби колагына жыр моны килеп иреште...

*Хан кызы, ач ишегең мин керәем,*
*Сине зифа буйлы диләр, мин күрәем...*

Айбиби сискәнеп китте, һәм хәтта торып ук утырды, үзе дә сизмәстән тыенкы гына, жырчыга жавап бирде:

*Минем буем зифалыгын син белерсең,*
*Сазлардагы сары камышларга күз ташласаң...*

Жыр иясе хан кызын ишеткәндәй дәвам итте:

*Хан кызы, ач ишегең мин керәем,*
*Кашкайларың кара диләр мин күрәем.*

Айбиби тагын аңа жавап бирде:

*Минем сачем каралыгын килсә беләсең,*
*Базарларда кара ефәк күргәнсеңдер...*

Жырчы ары таба дәвам итте:

*Хан кызы, ач ишегең, мин керәем,*
*Синең кашың кара диләр, мин күрәем.*

Айбиби жырчының сүзләренә янә жавап тапты:

*Минем кашым каралыгы нидән димсең?*
*Шагыйрьләрдә кара каләм күргәнсеңдер...*

Жырчы туктады. Айбиби ни кылырга белми, түбәсе ябык сиртмәле арбаның япмасын ачып карады. Һәм арба артыннан атын атлатып кына барган Исламны күрде дә шатлыктан түзәр әмәле калмагач, арбага бәйләгән атының тезгенен чишәргә һәм арба кырына китерергә кушты. Ат караучы егет шундук тезгенне малкайның муенына ташлап, арба кырына китерде, Айбиби арбадан ук атка атланды. Хан кызының атка атлануы булды, аның янына бер уч дала әреме тоткан Ислам килеп житте, алар күзгә-күз карашып алдылар. Менә шунда, егет белән кыз йөрәге бер-берсен аңлашып, атларын далага юнәлттеләр. Хан кызының әрфия яулыгы жилферди, күлмәге күпергән, аның артыннан ат муенына ята төшеп, сарай табибы улы Ислам элдерә. Ул арада, хан кызының ачык далага чыгып чабуын кахан сакчылары күрде, раввалар кычкырыша башладылар. Кахан сакчыларының йөзбашы булса кирәк, Алпар янына чапты, барып житүгә, ачык далага чыгып чапкан хан кызына таба камчысы белән күрсәтте.

—Кайтырлар,—диде аңа Алпар.—Кайтырлар, борчылма. Бераз жилләнерләр дә кайтырлар.

Әмма Алпар йөзбашның соңгы сүзләрен ишетмәде бугай кахан сакчысы, артыннан килеп житкән ишләрен ияртеп, егет белән кызны куа китте.

Йөзбаш Алпар янына ат менгән өч равва килеп туктады.

—Кем жибәрде хан кызын, Алпар йөзбаш?—дип сораучысы баш равва булса кирәк. Равва йөзгә алышынган, кипкән иреннәрен кыскан, күзләре кахан яугирләре киткән якта.

—Мөхтәрәм равва,—диде Алпар, баш түбәсенә генә чәпләшкә каплаган раввага күз ташлап.—Кайтыр хан кызы, бераз жилләнеп аласы килгәндер.

—Кайтмаса?!—дип сорады равва кырыс төстә.

—Мөхәммәд хан йөзбашы кыз өчен башы белән жавап бирәчәк, равва, башы белән...

—Һы,—диде равва һәм түш кесәсеннән кульяулыгын чыгарып, шаулатып борынын тартты.

—Йөзбашы хан кызы арбасыннан күзен дә алмаска тиеш,—диде равва кузгала башлап.

Ул арада инде каханның яугирләре егет белән кызны борып китергәннәр иде.

Өлкәнме, баш раввамы әүвәл хан кызына, аның муенына уралган әрфия зәңгәр яулыгына һәм гүзәл мөлаем йөзенә карап алды, ахыр карашын Исламга күчерде, равванның ни соравын белгән кебек хан кызы әүвәл яулыгын рәтләп бәйләде, күзләрен генә калдырып, йөзен каплады, шуннан соң тыенкы гына сорады.

—Ни булды, равва? Нигә бу шау-шу?

—Кем бәендә бу егет?—дип сорады равва.

—Минем бәйдә, равва,—диде аңа Алпар йөзбаш.

—Бу егет минем табибым, аңа шикләнеп карамасагыз иде, равва,—диде хан кызы һәм атын арбасына таба бора башлады.

Равва йөзбаш Алпарга күз ташлады һәм кырыс кына:

—Йөзбаш Алпар, егет сезнең бәйдә икән, сезнең бәйдә булсын, хан кызы тирәсендә уралмасын!—диде боергандай һәм китеп тә барды.

—Ишеттенме,—диде башын түбән иеп ни әйтергә белми торган егеткә йөзбаш Алпар.—Син ут белән уйныйсың сарай табибы улы Ислам, ут белән!..

## IV

Хәрбиләр кулына күчкән хакимият, телиме моны теләмиме, тора-бара сугышка йөз тота башлый—яу йөрү, сугыш аның төп максатына әверелә. Йосыф кахан ашыкты, нәрсәгә генә тотынмасын өлгермәм дип курыкты. Яу чыкканда барысын да исәпкә алып, барысын да алдан күреп эш итәргә кирәк. Империя буларак, Хазар каханаты кул астында дистәләрчә халыкларны тота, аларга чамалы гына ясак сала, ә инде баш бирмәүчеләргә куәтне күрсәтер өчен шул тарафларга яу кузгала. Бу хәл һәр ел кабатланмаса да шактый еш булгалый иде. Ни сәбәпледер, Йосыф каханның әлегә хәтле төшенә алганы юк—ни өчендер, аның кул астына кергән һәр халык мөстәкыйльлеккә, бәйсезлеккә омтыла, ул гынамы, ташламаларга йөз тота, хөрриятккә өмет итә. Ә Йосыф кахан моңа бара алмый, чөнки халыкларны бәйдә тоту өчен аңа көчле гаскәр кирәк, гаскәр өчен исә гаскәрбашлар акча таләп итә. Акча җыю гомум керемнән тора, халыклардан кергән ясактан, сәүдәгәрләрдән җыйган салымнан. Канат астына бабалары җыйган халыкларны күз угыннан ычкындырмас өчен Йосыф кахан һәр илдә шымчыларын тота. Алар теге йә бу илдә барган сәясәт турында каханга һәрдаим хәбәр итеп торалар. Бу гаять җитди мәсьәләне империядә нигездә раввалар хәл итә. Теге йә бу халык баш калкыта башласа, Йосыф кахан Византия императоры кебек гаскәре белән баш калкытучылар өстенә ташланмады, раввалары аша ул халыкка ташламалар ясады, түрәләренең гүзәл кызларын сараена тарттырды.

Бу хәл үзенә күрә империя канаты астына кергән түрә белән кардәшләшү иде. Бу чараны аның бабалары да кулланган һәм Йосыф кахан да читләтеп үтә алмады. Әйтик, заманында көчле вә куәтле булган Идел буе Болгары ханнарының кызларын Аккалага тарттыру күптән инде сәяси вә кардәши гадәткә әверелеп киткән иде. Идел буе Болгары аша империягә затлы тиреләр агыла, бакыр-тимер, иң мөһиме, гаскәри егетләр килә. Болгар төркиләренә сөннәтле казакларга өйрәткән кебек тел өйрәтеп торасы юк иде, шул исәптән бөҗәнәкләргә дә. Хак, Йосыф кахан беркайчан да сөннәтле казакларга ышанып җитмәде. Акчаны вакытында түләмәгәндә сөннәтле казаклар сакларын ташлап китәргә дә күп сорамыйлар иде. Диннәре аша Йосыф кахан аларга тәэсир итә алмады. Христианнар—христиан булып калды, мөселманнар—мөселман, мәҗүсиләр—мәҗүси. Вә ләкин каханнар тарафыннан борын заманнардан ук өстенлек яһүд диненә бирелә килгән, Йосыф кахан да бу канун—гадәтне бозарга теләмәде. Шул ук вакытта ил белән идарә итүне үз кулларына ала барган раввалар да эчен пошыра башлаган иде. Җитмәсә, раввалар коточкыч хәйлә уйлап тапканнар—каханны ефәк бау белән буып сорыйлар. Имеш, тагын ничә ел хаким булып торасың?.. Бу коточкыч чараны күптән белсә дә, моңа кадәр Йосыф кахан бу хәл-чарага игътибар итмәгән иде, кырык яше якынлаша башлагач, ул кинәт кенә уйга калды: ә бит аны да раввaларның ефәк бау белән буып сораулары бар. Бу яман гадәтне туктату өчен нишли ала ул?! Шул хакта киңәш-сабак сорап, Испаниядәге кардәше Хасдай ибн Шафрутка да хат язып карады, әмма хәйләкәр кардәше хаттагы ул юлларны гүя укыма-

гандай каханның бу соравына гомумән җавап бирмәгән иде. Хак, Исраилдән килгән вә чакырылган раввалар Хазарстанда синогоглар, мәдрәсәләр салдылар, яһүдә хатыннардан туган балаларны Талмудка, Мишәгә тугры калырга укыттылар. Бу чараларны үз чорында Булан кахан кертеп калдыра. Аның хакында тарихчылар: "Ул гадел, тугры хаким булган",—дип язып калдырган. Ә мөселман имамнары аның хакында: "Ул Аллаһудан курыкты, ил кануннарын саклады, яшәү рәвеше өчен борынгы бабаларыбызның васыятьләрен үрнәк итеп алды",—дип язып куйганнар. Шуңа карамастан, бу чорда каханат авыр көннәр кичерә. Ни сәбәпледер, 922—923 елларда көчәеп киткән раввалар Биләмҗирдән мөселманнарны куа башлый. Хәер, бу хәлләр элегрәк тә булгалаган. Әйтик, 910 елларда кахан сарайдагы имам Шәмси Тәбирне куа. Олуг имам белән йөзләрчә мөэминнәр Киялигә күчеп китә, Айдар хан канаты астына. Менә кайчан Кияли каханаты көчәя башлый. Болгар төркиләренә ияреп, Киялигә гарәп миссионерлары, сәүдәгәрләре, һөнәрчеләре юнәлә. Киялидә мөселманнар колониясе барлыкка килә, кахан белән килешеп, гарәп-төркиләр үзләренә баш гарәп сайлыйлар. Идел буе Болгарыннан Киялигә таба зур сәүдә юлы ачыла. Киялидә кахан белән килешеп, акча суктыра башлыйлар. Бу хәлгә хазар каханының да эче поша башлый.

Әмма норман короле Хельг хәйлә юлы белән Киялине кулына төшерә. Хазар каханы моның өчен аңа рәхмәт укымый укуын, мәгәр әмер-үтенеч кебегрәк фәрман белән илчеләрен Киялигә җибәрә: мөселманнарга каршы берләшик, ә мин сиңа ясак салуда ташлама ясармын. Канунг Хельг хазар каханы белән килешә. Әнә шулай, канунг Хельг хазар каханы үтенече белән, мөселман илләренә яу артыннан яу йөри башлый. Ләкин баскынчы варяг үз йөзендә кала—элек Хазарстанга ясак түләп яткан кайбер халыкларны канат астына җыя. Хак, канунг Хельг хазар каханы алдында аклану йөзеннән милади белән 912—922 елларда кахан рөхсәте белән Хазар диңгезенә чыгып, Күрә елгасы буйлап гарәпләрнең Барда башкаласына ябырыла һәм бик күп байлыкларын талап, кире борыла. Бу хәл хакында гарәп сәяхәтчесе әл-Масуди дә телгә ала. Ләкин Йосыф кахан тәхеткә менгәч барысы да үзгәрде. Баскынчы Хельг Киялидән куылды, Идел буе Болгарында үлемен тапты. Ил тәхетенә канунг тарафыннан үтерелгән Әскәр каханның оныгы Әнвар утырды. Йосыф кахан аңа көне белән илчеләрен җибәрде—ясак таләп итте. Әмма нишләмәк кирәк, Кияли каханы тәхеттә озак утыра алмады. Аны ясакчы германлылар[1] үтерә. Тәхеткә хатыны Ольга менә. Ольга үлгәч, ил башына аның улы Святовит килә, ягъни Сарманай Мәҗүси кахан Хазарстанга бөтенләй баш бирми башлый. Менә Йосыф каханның кем ачуын китерә иде. Тәхеткә килүгә менә кемгә теш кайрый башлады ул.

Ләкин Йосыф каханның бүген сәясәт турында уйлыйсы килми иде. Ул Мөхәммәд ханның гүзәл кызын көтә. Яңа көн тууга, Йосыф кахан хан кызына юлда ул-бу булмагае дип, үз кырына сөннәтле казакларның атаманы Кушбугазны чакыртты. Кирәкмәгән калын тавышы өчен Кушбугаз кушаматын алган атаман килеп кергәч, ул аны кече өстәл янына дәште, бармак шартлатып кына бавырчысына кымыз китерергә кушты, ләкин Кушбугаз ике кулын күтәрде.

—Минем аш түгел ул, галиҗәнабем, минем аш түгел. Минем кымыздан сару кайный, эч күбә. Миңа грек шәрабы килешә төшә,—диде.

Грек шәрабен кунакка көмеш кубокны тутырып китерделәр. Кунак сусаган булса кирәк, кубок кулына эләгүгә, аны күтәреп эчеп тә куйды. Йосыф кахан шәрабчесенә янә бармак шартлатты, янәсе, кубокны тутырып куй. Икенче кубокны эчеп куйгач кына, сөннәтле Кушбугаз озын мыекларын сыпырып, каханны тыңларга җыенды.

—Чын атың ничек, исемең дим?

—Кушбугаз мин, галиҗанәбем, Кушбугаз. Туа-туганнан бирле Кушбу-

[1] Германлылар – Русия тарихчылары бу халыкны древляннар дип язалар.

газ. Атам кушкан исемем хәтерләмим, бәләкәй чакта әнием Карун дигәнне азрак хәтерлим.

—Карун атаман, сиңа мин зур йөк йөклим. Син бүген үк хан кызын каршы алырга кузгаласың. Яраннарыңны ал да элдер. Мөхәммәд хан кызы сараема тартыла, ул хәзер юлда, ә ул гүзәл затка бәҗәйлар ханы Түрә үз малаена дип кармак салган булган икән, ягъни ярәшергә теләгән. Тик минем равваларым җитезрәк булып чыктылар. Кызны илдә бер гүзәл диләр... Аның исән-имин сарайга килеп җитүе зарур. Дала бүресе бәҗәйлар ханы Түрә улына кызны чамалаган икән, тик ятмыйдыр, юлга төшеп, кызны урлап алып китүләре бар. Син аларга аркылы төш. Иң елгыр егетләреңне ал, хан кызын исән-имин минем сараема кайтарып тапшырсаң—буш итмәм.

—Хәзер үк кузгалыйммы, каханым?

—Хәзер үк, алар ярты юлны узганнар булса кирәк инде.

Кушбугаз атаман торып басты, камчысы белән болгари итегенә сугып алды.

—Мин киттем, каханым. Атна дигәндә хан кызы синең куеныңда булыр.

—Ак юл сиңа, Куш... Карун атаман,—диде Йосыф кахан һәм атаманга китәргә ишарә ясады.

Ишеккә җиткәч, Кушбугаз атаман туктады, борылып, каханга:

—Гадәттә төрки бабаларыбыз кызларын олау-бирнә белән озаталар иде, каханым.

— Гадәтләр генә түгел, диннәр дә алышына, атаман. Юлыңда бул!

## V

Айбибигә җиде яшь тулгач, Хазар каханы Идел буе Болгарына килде, Мөхәммәд хан белән бабалары төзегән килешүне яңартты. Хан кызларын да шунда күрде һәм икесенә дә зөбәрҗәтле алтын балдаклар бүләк итте. Айгөл апасының аркасыннан сөйде, Айбибинең башыннан сыйпады. Мөхәммәд хан каханның кызлар белән сөйләшеп торуын күрде дә Рәшидә абыстайга тиз генә аларны алып китәргә кушты. Балдаклар нәкъ аларның бармакларына ясалган иде. Айбиби моңа игътибар итмәде, кинәнде, ә менә унөченче язына аяк баскан апасы Айгөл, балдакны уч төбенә кысты да бик озак бер ноктага текәлеп карап торды. Айбиби үз балдагын апасына күрсәтте, шатланды, әле бер бармагына, әле икенче бармагына киде, кулларын әйләндереп, көзге алдында уралды. Шуннан дүрт-биш ел да үтмәде, кахан Айгөлне сараена тарттырдылар. Һәй елады да соң апасы, күзләре кып-кызыл булды, Айбибине кочып, мыштым гына кемнендер исемен кабатлады, шул исем белән тәрәзәгә карап дәште. Айбиби аңлады да, аңламады да. Кем бар анда, апасы кемгә дәшә дип кат-кат тәрәзәгә барып карады. Сарай ишегалдында да, бакчада да, кирмән капкасына таба сузылып яткан юлда да беркем юк иде. Ахыр апасы янына килеп сарылды.

—Нигә елыйсың, елама, син еласаң, мин дә елыйм,—дигән булды.

Айгөл апасы бер сүз дә әйтмәде, аны кочагына алды да селкенә-селкенә такмаклый башлады.

—Минем анда барасым килми, килми, апаем Айбиби, килми!..

—Кая, кая, апам?

—Аккалага, Аккалага, кахан кырына. – Һәм шунда чәнчә бармагына кигән кахан балдагын салды да тәрәзәне ачып, ишегалдына атты.—Кошлар, алыгыз, алып китегез шул балдакны, алып китегез дә явыз каханга илтеп бирегез!..

Менә кайчан барып житте үсмер Айбибигә—апасы Айгөлне Аккалага хазар каханына хатынлыкка тарттыралар икән. Һәм иртәгә үк аны Аккалага алып китәчәкләр, аны, ягъни Айбибине апасыннан аерачаклар. Әнә шунда Айбиби чырыйлап елап җибәрде.

—Җибәрмим мин сине явыз каханга, җибәрмим, апам, җибәрмим. Әйдә, атама әйтәбез, җибәрмәсен сине Аккалага, явыз каханга, җибәрмәсен!

Хәзер инде Айгөл апасы идәндә тәгәри-тәгәри елый башлаган Айбибине үзе юата башлады.

—Чү, чү, Айбиби елама, мин аннан тиз кайтырмын, менә күрерсең, әйләнермен дә кайтырмын. Тукта әле, карале күзләремә, карале,—апасы аның битләрен ике учына алды, яшьле күзләренә карады,—мин аңа "сине яратмыйм», дип әйтермен. Яратмаган кеше белән торалармыни? Ул мине җибәрер, син мине шәһәр капкасында каршы алырсың. Мин аннан сиңа матур-матур чәчкәләр, ефәк күлмәкләр, яулыклар алып кайтырмын. Аннары без синең белән кулга-кул тотынышып, Аккошлар култыгына төшәрбез, аккошларга җим ашатырбыз...

Айгөл апасының һәр сүзе Айбибинең йөрәгенә үтеп керде. Менә апасын шәһәр капкасында каршы ала, аны яугирләр озата килә, менә алар кулга-кул тотынышып аккошлар култыгына төшә, горур кошларга җим ташлыйлар, кинәнәләр.

Айбиби тынычланды һәм бераздан арып, йокыга китте.

Ул уянганда Айгөл апасы юк иде, аны Хазарстанга алып киткәннәр иде инде. Айбиби тагын нигә мине уятмадыгыз дип еларга тотынды. Аны юаттылар, тынычландырырга тырыштылар, ахыр Мөхәммәд хан үзе кызны Аккошлар култыгына атка атландырып алып төшеп китте. Атасы аңа: "Без аккошларга Айгөл апаңа сәлам юлларга кушарбыз, алар безнең сәламебезне апаңа тапшырырлар һәм ул шатланыр".

Айбиби моңа да ихластан ышанган иде.

Ә бит бөтенләй алай булмаган, Рәшидә абыстай әйтте: апасын бәйләп салган кебек арбага салып алып киткәннәр—кахан раввалары.

Апасы елаган-елаган да тәмам һуштан язган. Һәм шунда Рәшидә абыстай Айгөл апасының бер бала табып, вафат булуы турында да әйткән иде. Имеш, ул углан баланы каханның анасы Сара анакай тәрбиягә алган һәм углан белән Таман тарханы Гали кырына күчеп киткән.

Хәзер әнә шул ук каханга хатынлыкка Аккалага Айбибинең үзен алып баралар. Тик нигәдер, Айбиби, апасы кебек һуштан язар хәлләргә килеп еламады. Моңа атасы Мөхәммәд хан да, Рәшидә абыстай да, сарай куштаннары белән хатын-кызлар да игътибар итте. Дөнья күргән хатын-кызлар үзара: "Ятим үсте ич, шуңа бер дә исе китми",—дип сөйләнделәр. Тик бит Айбиби бер дә ятим үсмәде, атасы Мөхәммәд хан аны якын күрде, үз итте, ахыр килеп, Айбиби биредә үзен бер дә ятим тоймады, хәтта үсеп-исәйгәч, үз атасы Талиб хан булуы хакында белгәч тә, Мөхәммәд атасына ят итеп карамады, аны беркайчан да чит күрмәде.

Айбиби япмалы арбаның чаршавын күтәреп, далага күз ташлады. Юлдан ерак түгел, үрә каткан йомран аны күрде дә әче итеп сызгырып җибәрде һәм күз ачып йомганчы өненә кереп югалды. Ул арада йомран өне янындагы биек әремгә уткойрык кунды, бу кошчык та кемнедер үз кырына дәшә, койрыгын селкә-селкә сайрый башлады. Әйе, ялгыз калу, ялгыз яшәү һәр җан иясенә ямандыр. Айбибигә дә кырыннан Исламны алып киткәч, нигәдер ямансу булып китте. Йосыф каханның кырык беренче хатыны булу теләген мизгел эчендә дала җиле алды. Юлга кузгалганнан соң беренче тапкыр хан кызының ямансу күңелен сагыш хисе биләде. Ул үзенең сарайдан чыгып китүен янәдән күз алдыннан уздырды. Әйе, ул үзен гамьсез тотты, моны барысы да күрде, гаҗәпләнделәр, хан кызын аңламадылар, аптырабрак калдылар. Атасына да Айбибинең бу халәте, үзүзен тотышы ошамады. Әмма кызы янына килеп, шул хакта сүз әйтергә кыймады, киресенчә, Айбибидә ихтыяр көче күреп горурланды хәтта. Бер сагышлана башлагач, Айбибинең күз алдына Идел буенда таралып үскән шомырт агачлары килде, шау чәчәктә утырган шомыртлардан соң көннәр җылытып җибәрер иде, Идел балыкчылары зур-зур җәеннәрне тотарга балан чәчкә атканны көтәрләр иде. Үз гомерләрен су төбендәге чоңгылда уздырган җәеннәр балан чәчкә атуга, ниндидер могҗизаи сиземләү белән төптән чыгалар, ишләрен эзлиләр, теләсә нинди җимгә дә кабалар иде. Айбибине кармак белән җәен тотырга атасының алостазы Мирхәйдәр бабакай алып

төшәр иде. Ул, җәеннәрнең кай тарафларда саташып йөзгәнен белгәндәй, кармакларын салыр һәм калкавычларны карарга гүя Айбибине сакка куяр иде. Җәен вак-төяк балык кебек чиртеп маташмый, җимне зур авызына каба да өненә алып китә, ләкин кармаклы кыл аны җибәрми, нәкъ менә шунда Айбиби кинәнеп кычкырып куяр иде: "Бабакай!"

Кармакка капкан балыкларны сарай хезмәтчесе килеп алыр. Чәбәләнеп яткан җәеннәргә карый-карый бавырчылар өенә туктарлар, шул мәлдә, җир астыннан калыккандай кечкенә малаен җитәкләп, сарай табибы Хәбибулла килеп чыгар, кечкенә малай исә, арбада яткан җәеннәргә игътибар итми, ни сәбәпледер Айбибигә карап торыр, аның һәр хәрәкәтен күз угында тотар иде. Айбиби аны күрмәде һәм аңа карамады да. Андый малайларны күргәне бар инде аның—бер дә исе китми иде. Һәм хәтта соңрак та ул аларны күрмәде, күрсә дә исе китмәде. Тик менә иртәгә китәбез дигәндә, атасының үсмер егет белән урманга җибәрүен янә гадәти бер хәл дип кабул итте. Кабул итте, тик елганың Аккошлар култыгында аның белән әллә ни булды, күлмәк тукымасына сеңгән, моңа кадәр беркайчан да иснәмәгән,ниндидер тансык ис аңкыган егетнең кочагына инде. Әллә булмаса табигый затны затка тарту һәр адәм баласына Аллаһ биргән мәхәббәтме?.. Ни булды аңа Аккошлар култыгында? Нигә ул әлегә кадәр бер дә исе китмәгән егетнең күкрәгенә капланды да алсу битләрен үбәргә рөхсәт итте, хәтта иреннәренә кадәр тартылды егет, гәрчә җаны көеп китүен тойса да аның кочагыннан чыга алмады, тәмам буынсыз калды.

Әллә соң шулай башланып китәме кызлар күңелендә егетләргә карата булган мәхәббәт?.. Әгәр дә шулай икән, нигә ул Йосыф каханга кырык беренче хатын булып тартылырга риза булды да, нигә мин аны яратмыйм, мин башкага гашыйк булдым дип атасына әйтмәде?.. Кем моны аңа аңлатыр? Ни бу? Гашыйк булумы, әллә булмаса яшьлектәге бер хис дулкынында тибрәлеп алу гынамы?.. Әйе, ул Ислам кочагында әнә шул хис дулкынында тибрәлде, чак кына көймәдән егылып төшмәде—хис дулкыны көймәсеннән. Тик бит бу хис бик тиз үтте, мизгел эчендә... Икенче мәлдә инде Айбиби үз халәтенә кайтты—хан кызы халәтенә.

Әйе, аларны һәрчак сарай табибы Хәбибулла дәвалады һәм әллә ниткән үләннәр белән. Сарай кешеләре авырганда табиб үләннәрдән төнәтмәләр кайнатыр, шуларны авырып киткән сарай кешеләренә эчерер һәм аның янында һәрчак әнә шул улы Ислам булыр иде.

Күзләре дымланып ук тора иде, ни сәбәпледер Айбибине яр өстенә күтәреп алып менеп, аягына бастыргач, иң гаҗәбе, хан кызы сурәтенә кереп, сакчыга кырыс кына боерык биргәч, әнә шул егет тәмам каушый калган иде. Ахры, егет әле генә булган хәлне аңламады—төшендә дип кабул итте бугай. Бит ул хан кызын үпте, бит ул хан кызына кагылды, җитмәсә яр өстенә күтәреп алып менде, ул гынамы, хан сакчылары моны күреп торды...

Айбиби үзалдына елмаеп куйды. Менә хәзер Ислам атлы егет аның кырында булса, ул аның һич тә тартынмый битенә кагылып алыр иде, хәтта битеннән булса да үбәр иде, хәтта рәхмәт әйтер иде.

Менә кайчан хәтер йомгагы сүтелә башлады Айбибинең. Бит ул Исламны күптәннән белә, тик игътибар гына итмәде. Үсмер егет еш кына атасына ияреп, сарай хатын-кызлары ягына керде. Атасы теге, йә бу авыруны караган арада, бигрәк тә яшь хатыннар егетне үртәргә керешерләр иде. Имеш, кайчан инде бу егет хан кызы Айбибигә яучы җибәрә, кайчан өйләнә инде. Имеш, хан кызын хатының булгач, бушка дәваларсың инде, безне дә онытмассың, айга бер булса да ашка дәшәрсең... Айбиби синеке инде, табиб улы, синеке... Әнә ул авырып китте әле. Салкын тигән диме, җофар юрганы астыннан да чыкмый. Бу хәл чынлап та шулай иде, Айбиби авырып урында ята, хатыннар үртәүгә табиб улы бит очларына кадәр кызарынды, колаклары яна ук башлады, хәер, Айбиби дә боларның барысын да күрмәс өчен юрган астына кереп поскан, аның да бөтен тәне ут янды. Һәм, ни гаҗәп, шул көнне берни булмаган кебек сәламәтләнеп киткән иде. Шунда тәҗрибәле үтә чая бер хатын:

—Бу балакайны мәхәббәт сәламәтләндерде,—дигән иде.

“Нинди мәхәббәт, кемгә булган мәхәббәт?”—дип сорыйсы килде Айбибинең, тик сорый алмады, оялды. Чөнки ул табиб улына ичмасам бер тапкыр да кызыксынып карамады. Ул гүя аның өчен юк иде, сарайдагы һәр кеше кебек, ул бары тик табиб улы гына иде.

Тик менә балачактагы өтек кебек кенә күренгән малай үсмер булгач, ахыр атасының яһүдә хатынын тәмам үләргә яткан җирдән аякландырып җибәргәч, табиб улына Айбиби дә кызыксынып карап алган иде. Ә инде Аккошлар култыгына төшкәч булган хәл күз алдына килүгә, Айбибинең бит алмалары кызышты. Ә бит ул чынлап та һуштан язды, чынлап та Ислам атлы егет аны үпте һәм сөйде, ә ул шуңа гүя эреп китте. Әнә шундый хиссияти уйлар һәм уйланулар белән Айбиби йокыга киткәнен сизми дә калды.

Иртән уянуга, Айбиби арбасына Рәшидә абыстай күчеп утырды, олау туктап калгач, Айбибине ашка дәште. Ашап-эчеп, олау янәдән кузгалып киткәч, Рәшидә абыстай хикәятләр сөйләргә кереште. Элек абыстаеның хикәятләрен тынлар-тынламас утырыр иде, әмма ошбу юлга чыккач, гыйлем галимәсен дикъкать белән тыңлады. Рәшидә абыстай әллә ниткән маҗаралы могҗизалар белә иде. Абыстай сөйләм тәменә керер алдыннан әүвәл күлмәк итәкләренә кадәр җыя төшәр, баш яулыгын чишер һәм ике кулын күтәреп Аллаһыга дога кылыр иде. Шуннан соң гына: “Йә, балакаем, ничек йокладың бүген? Һәйбәт йокласаң, тәнеңә вә жанына-рухына йокыннан көч-куәт алган булсаң инде мине тыңла. Ниндәен төш күрдең бүгенге йокыңда, балакай?..”

Айбиби аңа хәтерендә калган төшне сөйләде. Чынлап та бүгенге йокысында иртәнге якта гына үзен аккошлар белән кай тарафкадыр очканын күргән иде. Имеш, аңа җинел-җинел һәм ул оча ала икән ич! Һәм ул күтәрелде дә аккошларга ияреп очып китте.

“Синең Аккалага күчеп китүеңә ишарә бу, балакай”,—диде абыстай.

Аннан соң арба пәрдәсен ачып, иксез-чиксез далага күз ташлап алды, шуннан соң гына: “Борын-борын заманда, әле безнең ерак бабаларыбыз, Идел буйларына күчеп килә башлаган вакытларда, ошбу төбәктә һичкемгә буйсынмаган тархан яшәгән. Көннәрдән бер көнне күктән Тәңренең ярдәмчесе төшкән дә: “Сиңа бу язда мәхәббәт килер, Тәңрең сине ташламас”,—дигән. Шуннан соң тархан язны зарыгып көтеп ала. Ниһаять, табигать уяна башлый. Елгалар таша, гөрләвекләр ага, болын-тугайлар шау чәчкәгә әверелә, сайрар кошлар ашкынып берсен-берсе әзли-эзли өздереп сайрыйлар, елгаларга арып төшкән казлар каңгылдаша. Һәр җан иясе, һәр тереклек бер-берсенә тартыла, иш-ишен тапканнары дошманнары көнләшерлек итеп сөешәләр, назлашалар.

Ә тарханга Тәңре җибәргән мөлдерәп тулган мәхәббәт килми дә килми. Тархан Идел яр өстенә кырын төшеп яткан да мөлдерәп торган Идел өстенә нурлы чаткыларын мулдан коеп торган манзарага, хәйрани төсләргә мөкиббән калып ятканда аңа кемдер әкрен генә дәшә: “Гунныяр, Гунныяр!” Тархан егет як-ягына карый, дәшкән кешене эзли, зәңгәр күккә бага, әмма анда чәчри хәлләргә килеп сайраган тургайдан башка берни дә күрми. Егет яткан урыныннан сикереп тора, атына сызгыра, аты утлаган җирдән жилле генә иясе янына килә. Шулчак егет кырында күктән төшкән алиһә пәйда була һәм әйтә: “Мин Чин * патшасы кызы, мине башка берәүгә, яратмаган кешегә кияүгә бирәләр—Ил түрәсе Юсигә. Ә мин сине күрдем дә сиңа гашыйк булдым, сине яраттым. Син ирекле кеше, син беркемгә дә баш имәгән егет, диделәр миңа...”

Егет ни кылырга белми аптырап кала. Чөнки аның Идел буена күчкәннән бирле бер генә адәми затны да күргәне булмый. Һәм төшемдә түгелме бу күренеш, дип, алиһәгә үрелә. Тархан булып бу төбәккә килгән Гунныяр атын йөрткән бу егетнең кулы кызга тиюгә, кыздан якты нурлар коела

*Чин – Кытай.

башлый, йөзе айга, күзләре йолдызга әверелә. Егет кызны кочаклый, кулына күтәреп алып китәсе итә, әмма шул мәлдә үк кыз юкка чыга. Егет колагына: "Көнчыгышка таба кузгал, көнчыгышка таба, мине шунда табарсың",—дигән моңлы тавыш ишетелә. Гуннияр сикереп атына атлана да тавыш килгән якка таба чаба. Тик алиһәнең тавышын куып җитә алмый. Егет Алтай тауларына житкәч кенә туктый, хәйран калып, биек-биек тауларга карап тора. Һәм егет колагына янә Тәңре тавышы ишетелә: "Син үткән җирләр дә, син туктаган таулар да синең җирләрең булыр. Шунда үзеңә ишләрең дә табарсың",—ди.

—Безнең бабаларыбыз Алтайдан килмәгәннәр, ә Алтайдан кайтканнармыни, Рәшидә абыстай?

—Кайтканнар, балакаем, кайтканнар. Идел буйларына кайтканнар, аннары баһадирыбыз Атилла аларны кояш батышындагы илләргә алып киткән, чөнки андагы безнең асыл кызларыбызны базарларында сатканнар, егетләребезне атлы гаскәриләр итеп алганнар. Шул явызлыкка түзми, безнең бабаларыбыз шул дәүләтләрне туздырып кайтканнар. Батыр гаскәриләр башында ата-бабаларының нәсел җебе Гуннияр атлы баһадирга барып ялганган Атилла бабабыз торган. Атилла баһадир, шулай итеп бабаларыбызны коллыктан коткара.

—Мин кем соң, Рәшидә абыстаем, колмы, әллә...

—Син кол түгел, балакай, син Хазар каханы кырына тартылган хан кызы.

Шул сүзләрне әйтте дә Рәшидә абыстай хан кызын кочагына алды һәм аркасыннан сөя-сөя матур-матур сүзләр тезде. Тик моның белән генә Айбибигә тынычлану килмәде, ул күз яше белән елый башлады. Нигә аны әтисе Мөхәммәд хан кырык яшьлек каханга биреп җибәрде, бит ул үзе дә олуг хан, ил ханы, ил терәге?..

—Чү, балакай, чү-чү, күз яшең чыгарма, әнә синең кырыңа Гунниярың килә, сине коткаручың,—диде.

Абыстай шулай диюгә, Айбиби күз яшен яулык очына сөртте дә арба япмасын ачып, аның арбасына таба җилле генә юыртып килгән ир-егеткә, Рәшидә абыстае әйтмешли, ир-атка карады.

—Хан кызы, хан кызы Айбиби. Атың китердем, арбадан төшеп янә бер җилләнеп киликче!..

—Абыстаем, анакаем, мин китим, китим шул егет белән, даланы әйләнеп кайтыйм, каткан бәгырем йомшармасмы...

—Бар-бар, балакай, каткан бәгырең йомшартып кайт. Егет сөяр, кыз сөелер, шунда туар мәхәббәт, дигән бер шагыйрь.

Хан кызы Айбиби абыстайның күзләренә карый, әле генә моңсулыкка йөз тоткан битләре, тулыкы иреннәре елмаюга җәелә, һәм арба янына ук килеп туктаган егеткә күз ташлый, икенче мәлдә инде очып диярлек, арба кырына ук китерелгән атка атлана һәм, алга чыгып, далага чаба. Ислам аны куа китә. Нигәдер бу юлы алар артыннан раввааларның яугирләре кузгалмый, тик күз карашлары белән генә озатып калалар.

Иллә Айбиби ерак китә алмый, алар каршына каханның елгыр яугирләре килеп чыга. Хан кызы туктарга мәҗбүр була һәм аны кахан җибәргән яугирләр кире олауга борып китерә. Раввалар канәгать, елмаялар, бер-берсенең күзләренә карашалар.

Хан кызының юлына аркылы төшүче яугирләр Карун атаманның сөннәтле казаклары икән. Раввалар моны ерактан ук күреп алдылар, шуңа кинаяле шатланалар иде.

Сөннәтле казаклар киемнәре белән үк башкалардан аерылып торалар иде. Хан кызы арба янына җитүгә, ат тезгенен хезмәтчесенә ташлады да атыннан җиргә төшми генә арбага күчте. Ул арада сөннәтле казаклар килеп җитте аларның атлары арба белән янәшә атлады. Күп тә үтми, үтә чуар киенгән сөннәтле казакларның атаманы килеп җитте. Ул арбага якын ук килде дә камчы сабы белән пәрдәне ачып:

—Хан кызы Айбиби, мин атаман Карун, кахан әмере белән сәне каршы

алырга җибәрелдем, шатланасы ит,—диде.

Айбибигә бу кешенең кыяфәте генә түгел, сөйләшүе дә ошамады, ул дәшмәде, алай да Алпар йөзбаш ягына таба китеп барган Исламга күз төшереп алды. Һәм тынычлана төште бугай, кырыс кына:

—Кахан әмерен үтәдегез, атаман. Инде китә бирегез,—диде.

—Мин бирегә кахан йөген үтәргә дип килдем, хан кызы Айбиби.

—Үтәргә килгәч, үтәгез, хан кызы арбасына тагылып бармагыз, атаман Карун. Карун бит сезнең атыгыз?

—Әйе, Карун мин, Карун, хан кызы.

—Китегез арба яныннан, чарасыз итмәгез мине, атаман Карун!

Ни тәкәббер, үзсүзле булса да атаман Карун арба пәрдәсен төшерде һәм теләр-теләмәс кенә яугирләре янына таба кузгалды.

Айбиби әлләни зур сәбәп булмаса да елап алды, бермәлгә яулык очы белән йөзен каплап торды. Шаярып булса да барган җайда ул Исламга: "Урла мине, урла, сарай табибы улы, Ислам, урла»,—дигән иде. Егет аны әллә чын итеп кабул итте инде: "Атың белән миңа ияр!"—диде дә алдан чапты. Бермәлгә, бары тик бермәлгә генә Айбиби икеләнә калган иде, шул вакытта җир астыннан калыккандай атаман Карун килеп чыкты. Яугирләре күп түгел, ләкин күренеп тора—елгырлар, ут-су кичмәсәләр дә йөзләрендә үк өмет юк. Айбиби табиб улы Ислам артыннан кузгалса, шундук аны уратып алачаклар һәм сак астында диярлек олау янына китерәчәкләр. Шуның өчен Айбиби атын кинәт кире борды һәм олауга таба чапты. Кая булды Ислам атлы егет, ни уйлады аның хакында, ул белмәде. Хәер, моңа бик үк исе дә китмәде, ул аңа: "Урла мине, урла!"—дип шаярып кына әйткән иде, шул ук вакытта белә иде, каханның сөннәтле казаклары килеп чыкмаганда, аның бу гамәленең чынга әверелүе дә бар иде. Тик моның ахыры ни белән бетәсен генә белми иде Айбиби, ул хакта уйларга, гомумән, вакыты калмаган иде. Хәзер инде соң, ул каханның үтә яман казаклары кулында, хәзер анардан күз дә алмаячаклар, болардан равва яугирләреннән качып киткән кебек, качып китеп булмаячак, чөнки бу халык турында Айбибинең атасы авызыннан да ишеткәне бар иде—имансызлар, башкисәрләр...

***

Юлга чыгар алдыннан уены-чыны белән йөзбаш Алпар үзе белән барган сарай табибы улының хан кызыннан күзен алмавын күргәч:

—Урла син аны, урла!—дип котырткан иде. Шуннан соң егетнең бу эшне чынга алырга җыенуын күреп, үзе үк курка калды, егетне орышып ташлады.

—Башың икеме әллә синең, табиб улы?! Мин сине шаяртасың дип торам, ә син, дивана, хан кызын чынлап та урларга иттең бугай. Беләсеңме мине моның өчен Мөхәммәд хан нишләтәчәк?.. Дәшмисең, чөнки бик яхшы беләсең—башым кистерәчәк, башым! Һәм мәйданга чыгарып, бөтен кала халкы алдында. Мине—баһадир йөзендә йөргән йөзбаш Алпарны!..

—Мин беләм, йөзбаш Алпар, беләм. Гашыйк булдым мин хан кызына! Мин чынлап та дивана хәлендә хәзер, чарасыз калдым, чарасыз...

—Ә син өмет ит,—диде йөзбаш Алпар егетнең гашыйк булуына ианып.—Өмет ит. Бәлкем синең мәхәббәтең көчлерәк булып, хан кызы сине сайлар, ә Йосыф каханны җир убар, йә булмаса кахан сараен су басар...

Ислам, гаҗәпсенеп, йөзбашка карап алгач башын түбән иде һәм тыенкы гына:

—Син хаклы, йөзбаш, мин бернәрсә дә кыра алмамдыр,—диде.

—Әйтәм бит, өмет ит, адәм баласы өмет белән яшәргә тиеш. Хан кызына мәхәббәтең саф булса, ихлас күңелдән гашыйк булсаң, сарай табибы улы Ислам, Аллаһы Тәгалә синең теләгеңне күрер һәм бахырга ярдәм кулын сузар.

—Һәй, баллы да соң сүзләрең, йөзбаш. Әйе, син хаклы, мин аны урлый

алмадым. Беләсең килсә, хан кызы моны үзе теләмәде. Күрдем ич мин, сиздем, минем мәхәббәткә җитди карамый хан кызы, бераз баласынып кабул итте. Хак, көлмәде, вә ләкин серле мәхәббәт ташкыны аның күнелендә булып алды.

—Бәлкем хан кызы синнән, синең ашкынулы-ярсу хис белән тулы мәхәббәтеңнән курыккандыр. Чөнки ташкын булып кеше күнеленә килеп кергән мәхәббәт тиз сүнүчән була, дөрләп кабына да бик тиз сүнә. Андый язгы ташкындай килгән мәхәббәтнең нигезе булмый, Ислам, нигез ташы булмый. Ә хатын-кыз бу мәсьәләдә егетләрдән күптапкырга акыллыраклар, алар киләчәк турында уйлый. Шуның өчен сиңа, Ислам, Аллаһыдан ялварырга гына кала. Син шул хакта көн-төн уйла, көн-төн, синең мәхәббәт нурларың вә уй-хисләрең җепләре хан кызына бер бармаса бер барып җитәр, чөнки мәхәббәт адәм баласы өчен мең еллар элек тә, хәзер дә сер булып кала бирә. Мәхәббәтнең серләре бер Аллаһыга гына билгеледер, сарай табибы улы Ислам.

—Бер дә минем атамнан ким кеше түгел син, йөзбаш. Ул да шулай мине дөнья котәргә өйрәтә. Йөзбаш Алпар, әйт әле, безне Аккалага кертерләрме?

—Менә анысы инде Йосыф кахан кулында, теләсә—кертә, теләсә—Ханбалык капкасыннан да уздыртмый. Һәрхәлдә, безне Ханбалыкка уздырырлар дип уйлыйм. Җай чыкса, Ходай мине тархан белән очраштырса, Булат тархан белән дим, мин аңа бу хакта әйтеп карармын, сарай табибы улы Ислам. Хан кызына үлеп гашыйк булган, нәсел җебе Кодрак хан заманнарыннан килгән дәвамлы төрки-болгар егет тә бар диярмен. Аннары әйтермен, ошбу егетне Мөхәммәд хан кызын озатырга табиб итеп җибәрде, диярмен. Анлар ул мине, хезмәтебезне бергә башлаган идек, Талиб хан кул астында, ары таба Булат үсте, хазар каханы аны Аккалага үз кырына алды. Хәзер Булат бәк кулында Аккала гына түгел, Ханбалык халкы да.

—Мин боларның берсенә дә ышанып житмим, йөзбаш. Әмма шуны ачык беләм: мин хан кызына гашыйк.

Шулчак кемдер:

—Аккала, Аккала!—дип кычкырып җибәрде.

Алда, офык читендә, чынлап та әкиятләрдә генә була торган мәһабәт кала күренде. Рәшә дулкынында бу кала күңелне тагын да җилкендереп, үзенә чакырды. Кала күренүгә, олау да адымын тизләтте, ә бериш яугирләр калага таба чаптырып киттеләр һәм берара җирне урап килделәр.

—Аккала, Аккала!..

Күп тә үтми Аккаланың уң ягында очсыз-кырыйсыз Ханбалык шәһәре күренде. Менә моңа чынлап та шаккатырлык иде—зур иде Хазарстанның башкаласы, Йосыф кахан яшәгән Аккала күл өстендәге төнбоек чәчкәсен хәтерләтеп балкып тора. Ләкин бит адәм күзенә һәрчак башта матурлык ташлана, хан кызы Айбибигә дә шулайрак тоелды. Аккала дигән тавышны ишетүгә, ул ат тотучы янына чыгып басты һәм әнә шул күз өстендә чәчәкләрен җәеп торган Хазарстан башкаласының йөзек кашы булган Аккаланы күрде дә үзе дә аңлап житкермичә: "Аккала, Аккала!" дип кычкырып җибәрде. Моңа бик күпләре сәерсенде, хәтта башларын чайкап куйдылар, бары тик раввалар гына күзгә-күз карашып елмаештылар. Әйе, үз дигәннәренә ирештеләр, бөҗәнәкләр ханы улының борын астыннан дияргә була Мөхәммәд ханның бердәнбер гүзәл кызын Йосыф каханнарына алып кайталар. Ә бит сонга кала яздылар. Кызны каладан алып чыгып киткәч, юлда очраган яһүд сәүдәгәрләре ирештерделәр—Түрә ханның улы Айдар Болгар Калага таба кузгалган икән. Килеп житмәде Айдар углан, эләктерә алмады хан кызын, олау инде калага житеп килә. Ә бит далада очрашкан булсалар үтә гаярь бөҗәнәк сугышчылары хан кызын тартып алып киткән дә булырлар иде. Мөхәммәд хан яугирләре бөҗәнәкләр белән сугышмаслар иде—канкардәшләр, мөселманга мөселман каның кою гөнаһ, ул кеше мәңге тәмугъта яначак, ә раввалар кулында бары тик Йосыф кахан яллаган сөннәтле казаклар гына. Бу халыкка да ышану кыен, бу халык сугыш кы-

рын ташлап качарга да күп сорамый. Ләкин нишләмәк кирәк, яһүдләр инде байтактан бер халык белән дә сугышмыйлар, чөнки кан кояр дәрәҗәгә житеп сугышыр жирләре калмаган иде. Моны гына аңлыйлар иде яһүд раввалары. Биредә яшәгән, меңнәрчә еллар шушы төбәкләрдә көн күргән төрки кавемнәре ил-жирле булгангамы, моны аңламыйлар, үз жирләре өчен сугышуны табигый бер хәл итеп кабул итәләр, шул сәбәпле, күп очракларда баш китәр дәрәҗәләргә житеп дошман белән орышалар, кан белән сугара-сугара булса да туган туфракларын саклыйлар иде.

Аккаланы күрүгә сарай табибы улы Исламның тел очына килгән беренче уе: "Димәк, хан кызы Айбиби шушы калада яшәячәк",—булды. Ә бит ул инде хан кызына булган мәхәббәтенең ихласлыгына ышанган иде һәм соңгы мәлгә кадәр нидер өмет иткән иде, әйе, урлап качу турында... Барып чыкмады. Булат бәккә, бәхәссез, йөзбаш Алпар аны хан кызының табибы дип тәкъдим итәчәк. Тик ничекләр кабул итәр Булат бәк бу хәбәрне?.. Ахыр килеп, Йосыф каханны диннәргә битараф кеше дип ирештерделәр. Әмма монысын Ислам аңламады. Ничек битараф булмак кирәк, илбашы ич ул, дин атасы сүзләре белән әйтсәк—ил тераге, ул гынамы, халыкның рухы, иманы, ниһаять. Имеш, әнә шуңа Йосыф кахан битараф.

Ә бит кахан бәге Сабир да, кала бәге Булат та мөселманнар. Атасының әйтүе хак булса, каханбәк тәхет ягына керә-керүгә, аяк киемнәрен сала һәм шуннан соң гына кахан кырына уза икән. Каханбәк Сабир яһүдләр динен кабул иткән бугай дигән дә булды атасы. Чөнки хатыны яһүдә икән. Ә яһүдләр яһүдә хатыннан туган балаларны гына үз милләттәшләре итеп таныйлар. Ялгышмаса, каханбәк Булат жиде суда буталган яһүдә хатынга өйләнсә дә чыгышы белән төрки, ата-бабалары да төрки болгарларыннан булган. Бу хакта да хәбәрдар иде Ислам. Әнисе белән атасы шул хакта еш кына бәхәскә кереп китәрләр иде. Атасы әнисен үртәр иде. Имеш, синең нәсел чыбыгочы яһүдләргә барып тоташа. Әнисе шунда әйтеп ташлаган иде: "Йә, булса ни, әйе, бабамның бабасының бабасы яһүд булган, бөжәнәк ханында табиб булып хезмәт иткән. Шуннан ни, шуннан ни, тәкәббер төрек жан?! Мөхәммәд пәйгамбәребезнең дә бер хатыны яһүдә булган ич!"

Аккаланың аерым биналары ап-ачык күренә башлады, ә Исламның башыннан вә теленнән "яһүд" сүзе төшмәде. Ләкин аның янә бер тапкыр хан кызы Айбибине күрәсе килә иде, күрәсе иде дә күзләренә карап сорыйсы иде—теләп киләме ул Йосыф кахан кырына? Тик хәзер кем уздырсын аны хан кызы арбасы тирәсенә?..

Чынлап та, хан кызы арбасын Карун атаман казаклары уратып алганнар иде. Алтынга ялланган казаклар аны, әлбәттә, арба кырына якын да жибәрмәсләр. Ислам бер ат башына алдан барган йөзбаш Алпарга күз ташлап алды. Аңардан сораса?.. Юк, кирәкмәс, ул да аны аңламас, Мөхәммәд хан аңа хан кызын кахан кулына тапшырырга кушты. Һәм ул моны шулай итәр дә.

Ул арада Ханбалык капкасына життеләр, Карун житәкләгән сөннәтле казакларның беришe алга узды, капкаларны каерып ачтырдылар, беришe хан кызы арбасын божрага алган килеш бөтен кала аша Аккалага таба юл алды. Урамнар тулып халык чыкты, күрәсең, Йосыф каханга кырык беренче хатын итеп Болгар ханының кызы Айбибине тарттырулары хакында халыкка житкән булган инде. Кызны озатучы Мөхәммәд хан ир-егетләре вә кызлары барысы да ыспай киенгәннәр, киемнәреннән күзләр чагыла, алар хан кызы арбасы артыннан бара, алар артыннан раввалар тагылган. Табигый хәл, каханга өч-дүрт елга бер булмаса да яшь хатын тарттыралар һәм һәрчак шулай килен китерүчеләр кала урамнарыннан узалар, утрауга урнашкан күперләрдән генә керергә мөмкин булган Аккалага юнәләләр. Ханбалык халкы өчен бу да тамаша иде.

Идел елгасы аша утрауга үтәр өчен көймәләр тезеп салынган һәм ул-бу була калганда мизгел эчендә икегә аерыла торган күпергә житүгә, олау туктады. Тәбир шәех белән Рәшидә абыстай арбаларыннан төштеләр, аларга раввалар кушылды. Тәбир шәех күпер башында торган сакчыларга баш

иде, тегеләр исә, карусыз гына аларны күпергә уздырдылар. Карун атаман күпер башында торган сакчыга кул изәде дә: "Мин үз вазифамны үтәдем",—дип булса кирәк, сөннәтле казаклары белән борылып китеп барды. Күпергә хан кызы арбасын, бирнәле олауны гына уздырдылар, калганнарын барысын да, шул исәптән Алпар йөзбаш яугирләрен дә, кире бордылар.

Хан кызы арбасы күперне үтеп, Аккалага узуга, сарайга җитәр-җитмәс, тугыз баскычның берсендә өлкән равва пәйда булды. Өлкән равва баш түбәсен ак түбәтәйгә охшаш кием белән каплаган, кулында гәүһәр ташлардан тезелгән дисбе. Хан кызы арбасы килеп туктауга, ул ашыкмый гына баскычтан төште, сак кына атлап, арба янына килде һәм арба япмасының пәрдәсен ача төшеп:

—Сау-сәламәт килеп җиттекме, хан кызы Айбиби!—диде.

—Шөкер кылабыз, өлкән равва. Тик мин хан кызы түгел инде, Йосыф каханга тартылган Мөхәммәд кызы Айбиби, каханның кырык беренче хатыны булачак баладыр.

Менә моны һич тә көтмәгән иде өлкән равва, ул тәмам аптырый калды, һични аңламый як-ягына каранды, әмма хан кызына әйтер сүз тапмады. Каушау түгел иде бу, булган хәлгә, көтелмәгән хәлгә аптырап калу иде.

—Юл бик алҗытты, мине тизрәк кирәк җиргә урнаштырсагыз иде, өлкән равва,—диде аңа Айбиби.

Шулай диде дә Айбиби җай гына арбадан төшә башлады, өлкән равва аңа кул бирергә мәҗбүр булды һәм хан кызы җиргә баскач:

—Йосыф кахан сезне көтә,—дип әйткәнен сизми дә калды.

Ә бит өлкән равва Болгар ханы кызына кул бирү түгел, эндәшергә дә тиеш түгел иде кебек. Әйе, кем өлкән равва да, кем яңа гына кахан сарае ишегалдына аяк баскан кыз бала?..

—Кахан мине көтмәсә, мин шул ук арба белән илемә кайтып китәчәкмен, өлкән равва! Сез тарттырдыгыз мине монда кырык беренче хатын итеп, сез җавап та тотыгыз. Юкса, минем рәнҗүем бар. Ә хатын-кызларны рәнҗетү өлкән ravvаларга да оят, гәрчә Сез, өлкән равва, сарайда хөрмәткә ия кеше булсагыз да.

Шулай диде дә хан кызы Айбиби сарайга таба китте, өлкән равва бермәлгә ни кылырга белми тораташтай катып торды, ахыр, исенә килеп, хан кызы артыннан титаклады. Айбиби баскычлардан менә башлауга, сарай ишекләре ачылып китте һәм ишектә ике хатын-кыз күренде.

—Хуш киләсез, балакай, хуш киләсез,—диделәр алар беравыздан һәм Айбибине култыклап сарайга алып кереп киттеләр.

—Балакай, синең бүлмәң кырык беренче булыр, апаң Айгөл яшәгән иде анда, иң матур, иң зур, һәйбәт итеп җыештырылган вә җиһазланган бүлмә.

—Мин Хазарстанга каханның кырык беренче хатыны булып килдем, абыстайлар.

—Әйе, балакай, кахан кабул иткәннән соң баш хатын булачаксың, баш хатын!

—Кахан хатыннарына кем күз-колак булып тора?

Абыстайлар күзгә-күз карашып алдылар, елмаештылар, әмма икесенең берсе сүз әйтмәде. Ишек янына җиткәч кенә абыстайларның өлкәнрәге әйтә куйды:

—Раввалар, хәрам атакайлар карар сезне, алар хезмәт күрсәтерләр, балакай, алар. Саклыйлар да сезне алар, ашаталар да, хезмәтче вазифасын да үтиләр.

—Раввалар? Хатыннармы?

—Раввалар хатыннарга сабак бирәләр, балакай, сабак.

—Кайчан кахан мине үз кырына дәшәр?

Абыстайлар бу сорауны бөтенләй көтмәгәннәр иде булса кирәк, күзгә-күз карашып алдылар да, икесе дә башларын ия төшеп, көлемсерәп куйды.

—Нәүбәтең җиткәч, балакай, нәүбәтең җиткәч,—диде абыстайның өлкәнрәге.—Ә хәзергә юын-чистарын да ашарга дәшкәнне көтеп тор.

—Мин баш хатын буларак ин түрдә утырырмынмы?

Абыстайның кечесе бот чапты һәм өлкән абыстайның колагына:

—Бусы Айгөл булмас, каханны үзе биетмәгәе әле,—дип пышылдады. Айбиби абыстайның бу сүзләрен ишетсә дә ишетмәмешкә салынды һәм каерып ишекне ачты да бүлмәгә керде. Ләкин нидер исенә төшеп, кире чыкты. Китеп барган абыстайларга:

—Минем абыстаем, шәехем, табибым Ханбалыкта калды. Аларга берегә керергә кем рөхсәт бирер, абыстайлар?—диде.

—Кем булсын, балакай, кахан үзе, булачак ирен,—диде тәмам югалып калган өлкән абыстай һәм терсәге белән ишенең касыгына төртеп алды.

Айбиби шап итеп ишекне япты һәм янадан ачты. Аның бу кыюлыгына исләре-акыллары киткән абыстайлар һаман баскан урыннарында торалар иде. Айбиби аларга:

—Инде китегез, мин сезгә рөхсәт итәм,—диде.

Шунда өлкән абыстай лып итеп артына утырды, икенчесе аны күтәреп бастырырга керешге. Айбиби көлә-көлә ишекне япты һәм бүлмәгә күз йөртеп чыкты.

## VI

Аккалага һәм бөтенбер Ханбалыкка тархан-түрә булып торган Булат бәк сарайда барган һәрнәрсәдән дә хәбәрдар иде. Нәүбәттәге кызны Аккалага кахан кырына тарттыруга аның бер дә исе китмәде. Күп хатыннар белән яшәсә дә Йосыф кахан үз акылында иде. Хак, аңа ирештерә торалар, кахан кайбер хатыннарын бөтенләй дәштерми икән. Шул ук вакытта Булат бәк каханның хәленә дә керергә тели иде. Кырык хатын! Һәммәсенең күнелен күрергә кирәк, ә ул—Йосыф кахан илбашы да ич әле, ил-халык белән идарә итә. Сүз дә юк, аның кырында һәрдаим өлкән равва утыра, вә ләкин тәхетне бит Йосыф кахан били. Ул бирә әмер, ул яу чыга, ул теге йә бу ил белән солых төзи, сәүдә эшләрен җайга сала. Яшь булса да, каханга кырык яшьләр чамасы булуын белә иде ул, ир янында ир иде әле кахан. Аннары үз кул астына кергән бер генә илне дә күздән яздырмый, күз угында тотарга тырыша. Каханның бу сәясәте дә ошый иде Булат бәккә. Соңгы елларда раввалары һәм бай сәүдәгәрләре аша Византия, Рим, Венеция сәүдәгәрләре белән тыгыз элемтәдә тора башлады, хәтта Идел аша төшкән викинглар дип аталган Скандинавия башкисәрләре белән дә тату яшәргә тырышты. Хак, әлегә борынгы кахан Вениямин кебек аларны мөселманнарга каршы котыртмады, Идел аша Хазар диңгезенә чыгарып, яр буйларында көн күргән мөселман калаларын пиратлардан талатмады, әмма Фәләстыйннан, Дәмәшкътан, Чананнан, Хотаннан, Коканнан, Чиннардан килгән сәүдәгәрләрне раввааларына колач җәеп каршы алырга кушты. Һәм раввалары шулай иттеләр дә. Бүген Итил аты белән дөньяга таралган Ханбалыкта Хамадан, хәтта Ктисифон сәүдәгәрләрен дә таба аласың. Заманында Иран шаһиншаһы яһүдләрне иленнән куа, ә алар Итил һәм Харәзем төркиләрен сайлый, чөнки кунакчыл, ярдәмчел, кимсетелгәнне, рәнҗетелгәнне якларга әзер халык. Ни чара кылмак кирәк, Аккалада укыттылар Булат бәкне һәм кемнәр дә түгел, яһүд раввалары. Әнә шулай Булат бәк сарайга үтеп керде, сонра хәтта тархан исемен алды—Итил каласы тарханы. Зур йөк иде бу аның өчен, үтә зур йөк. Ләкин Булат бәк сынатмады, эшне белеп алып барды. Ә менә кахан хатыннары белән кызыксынмады. Әллә бар алар Булат бәк өчен, әллә юк. Әмма көннәрдән бер көнне нәүбәттәге хатыннарны кабул итеп торган абыстай аны шаккатырды. Чираттагы кахан хатыны буласы Идел буе Болгары Мөхәммәд хан кызы Айбиби, килә-килүгә, баш хатын булып ала һәм хәрам аталарны гына түгел, равваларны да биетә башлый. Хак, абыстайның арттыруы да бар иде, арттыргандыр да, ләкин Булат бәктә, ил түрәсе буларак, бу кыз турында кызыксыну туды. Хакмы, чынлап та шулай кыю кыланамы сарайга баш хатын булып килгән Мөхәммәд хан кызы?..

Шул хакта күбрәк белергә теләп, Булат бәк сарайга юнәлде, баскычтан күтәрелүгә, җир астыннан чыккандай, аның каршында өлкән равва пәйда булды.

—Һи, кем, Булат бәк. Безгә Идел буеннан, Болгардан дим, аждаһа китерделәр бит әле, аждаһа. Кахан кырына кермәгән килеш баш хатын йөзендә түр башына менеп утырган.

—Сөйләмә булмастайны, өлкән равва, килешми.

—Ирдәүкә инде, ирдәүкә, кахан кочагында булмас борын ирдәүкә. Куып җибәрер аны кахан, тотмас. Сатып җибәрер дим.

—Сатса, үзем алам,—диде Булат бәк уенын-чынын бергә кушып.

Өлкән равва кырын күзе белән Булат бәккә карап алды, елмайды һәм аяк очына ук килеп кунган күгәрченне куркытты.

—Тик бит кыз гүзәл, күз алмастай гүзәл, Булат бәк. Күзләре йолдыз, иреннәре бал, битләре кояш вә айдыр. Пешкән алма инде менә, тәмам җитешкән, өз дә кап, Булат бәк, өз дә кап.

—Ә син аны каханга күрсәтмә, өлкән равва.

—Бу ни дигән сүз инде тагын, Булат бәк. Кала башы бит син!

—Кала башы булганга әйтәм дә инде. Каханыбызны бозып куюы бар, гарәпләр бар этлекне хатыннардан күрә.

—Без дә хатыннардан күрәбез анысы, Булат бәк, без яһүдләр дә.

—Ә менә без төркиләр, алай дияргә ашыкмыйбыз, өлкән равва.

—Нигә алай дисең, Булат бәк?

—Ирдәүкәләр бездә борын заманнарда да булганнар.

—Булганнар, хак, бу хакта тарих атасы Геродот та яза. Ләкин төркиләр нә куәтле халык булсалар да үз тарихларын язмаганнар, Булат бәк.

—Безнең тарихны башта чиннар урлый, өлкән равва, аннары фарсылар безнең тарихка таянып үз тарихларын яза, ахыр менә сез—яһүдләр безнең тарихны дәвам итәсез, хәтта бит изге китабыгызда да безнең халыкны санга сукмый гына үтеп китә алмагансыз. Булан каханга рәхмәт укыгыз, ул безне сез раввалар белән туганлаштырды, ул булды безне берләштерүче. Тугры хаким, гадел хаким булды, мәрхүм.

Өлкән равва бик озак дәшмәде. Булат бәк хаклы иде. Тарихсыз кала язган төрки халкы дөньядагы һәр халыкка үз тарихларын язу өчен мөмкинлек биргән.

Әйтик, шул ук кытайлар татарлар атлы кавем булмаса нәрсә турында, кем хакында тарихларын язарлар иде. Төп дошманнары вә күршеләре төрки-татарлар булганга тулы канлы тарихларын яза алалар чиннар. Шулай ук фарсылар да. Фарсы шагыйрьләренә нәкъ менә үзләре туран дип атаган татарлар поэмалар язарлык илһам биргәннәр. Бу халыкның бер өлеше яһүдләр арасында гына түгел, гарәпләр арасында да эри. Ә бит һәр халыкка да читтән килгән кан яңа шытым бирә, дөньяви хәлләргә яңа караш китерә.

Булат бәк кузгала башлады.

—Минем Мөхәммәд хан кызын күрәсем килә, өлкән равва.

—Кирәкмәстер кызны күрү, Булат бәк. Тешләк хатын булыр кебек ул. Йосыф балакай түзмәс аңа, чөнки кахан үтә нәзакатьле кеше.

—Кахан, хак, йомшаграк табигатьле, вә ләкин нәкъ шушындый утчагыр хатын җитми иде аңа, өлкән равва. Каханның гына түгел, минем дә күрәсем килеп китте әле Мөхәммәд ханның аждаһа кызын, өлкән равва.

—Киңәш итмәс идем, бәгем. Әүвәл Йосыф үзе күрсен, үзе хәл итсен. Алып каламы, куамы, сатып җибәрәме?..

—Әйтәм бит сатса үзем алам, өлкән равва. Ул бала минем күрмәс борын канымны кыздыра башлады. Үземә түгел, минем үз хатыным, өлкән равва, каханның кырык хатынына торырлык.

—Шулай дип сөйлиләр сөйләвен, ләкин аны күргәнем булмады, Булат бәк. Чибәр хатын җил тубалы бит ул—дала буйлап тик тәгәри, кая таба җил, тубал шунда, чибәр хатын да шулай. Акыл кирәк хатыннарга, Булат бәк, акыл, акыл белән яшәү җитми аларга, бер ир-затка йөз тотып...

—Акыллы хатыннарны олау аты итәләр бу заманда, өлкән равва. Ә ул

хатын чибәр дә, акыллы да, сылу да, зифа да булса ничек?

—Бар син әйткән сыйфатларны да бер затка биргән хатынны ил түгел, мир дә сөймәс, Булат бәк. Мөхәммәд хан кызы да шул көнгә калмагае дим.

—Анысы инде Йосыф кахан эше, өлкән равва. Тели астына сала, тели Фанәгүр базарына чыгарып сата. Тик сатмас ул аны, эчем сизә, сатмас, шундаен хатын житми безнең каханга, утчагыр хатын.

Айбиби бүлмәсенә керергә кыймады Булат бәк, ә хәрам атакайны чакыртып алды һәм каханның булачак хатынын кунак бүлмәсенә дәшәргә кушты.

—Бик күрәсең килсә, мин аны дәшәрмен, тик озак сөйләштермәм,—диде хәрам атакай Булат бәккә таба карамый гына.

—Мин сиңа меңнәрчә рәхмәтләр тезәм, меңнәрчә рәхмәтләр, атакай.

Хәрам атакай бер сүз әйтми китеп барды һәм куп тә үтми Айбибине житәкләп килеп тә житте. Һәм нечкә тавышы белән:

—Мин кырыгызда булырмын,—диде.

—Саумы, хан кызы!—диде Айбиби килеп житүгә Булат бәк.—Исән-имин килеп життегезме?

—Юл имин булды, Булат бәк. Рәхмәт.

—Мин каханның тарханы булам. Аккала да, Ханбалык та минем кулымда, хан кызы.

—Сезнең кулда башыгыздагы бүрек кенә, Булат бәк, анысын да Болгар базарыннан сатып алгансыздыр әле,—диде Айбиби.

Булат бәк хан кызының бу сүзләренә тураебрак басты, тирә-ягына күз ташлады, тагын берәрсе тыңлап тормыймы, янәсе, бигрәк тә өлкән равва, ялт итеп бүреген салып, угаларга тотынды. Бит ул бу ирдәүкә кызга нидер әйтергә тиеш иде, тик тәмам зиһене чуалды, әйтергә теләгән сүзе күнелендә төерләнеп калды.

—Мин китим инде, Булат бәк,—диде хан кызы.

—Әйе, әйе, китегез,—диде Булат бәк баш ия-ия һәм игътибар итте, хәрам ата аңа ирен чите белән генә елмаеп китеп бара иде.

“Аждаһа ук булмаса да, шул тирәдә икән шул”,—дип уйлап куйды Булат бәк, хан кызы белән аның артыннан титаклаган хәрам атакайга карап. Һәм үзе дә кисәк кенә борылып сарайдан чыгып китте. Тәүге кәефе гүя аяк астына төшеп, туфрак-тузанга әверелгән иде.

***

Бер кич аерым бүлмәдә кунганнан соң Айбибине кахан кырына алырга килделәр. Башта кахан аны тәхет ягында кабул итәргә булган икән, хәрам ата шул хакта кереп искәрткәч, ул аңа бер сүз дә әйтмәде, әмма ашыкмый гына киенә башлады. Һәм, сәер хәл, аңа кисәк дулкынлану килде. Ул гасабилануга кадәр барып житте, битенә кершән сөрткәндә кулларына кадәр калтыравын тойды. Нигә булыр бу?.. Әллә соң мин аңардан шулай куркаммы?.. Курыкмыйм ич, курыкмыйм! Шулай дип үзен юатты, әмма күңеле тыныч түгел иде, йөрәгенә кадәр ешрак тибә башлады. Көзгегә кат-кат күз ташлады. Барысы да әйбәт кебек иде, буе-сыны да, йөзе-кыяфәте дә... Тик барыбер дулкынланды... Нindирәк кеше икән кахан? Хатын-кыз күзе төшәрлекме?.. Кырык хатын белән тора ич! Аңамы кыз кадерен белү!.. Курыкма, кыю бул, кыю бул, Айбиби, кыю бул!..

Хәрам ата, ишекне ачып, башын тыкты.

—Балакай, сүзне алдан башлама. Кахан ошатмас. Үзе сорасын. Йомышларың соңынан әйтерсең.

—Яхшы, сез дигәнчә итәрмен, хәрам ата,—диде аңа Айбиби ишек ягына карамый гына, һәм тынычлана төште. Әйе, аңа кем белән булса да сөйләшергә кирәк икән, тынычлану өчен.

Тарлавыкка чыкты, хәрам ата чүәген сөйрәп алдан китте һәм Айбибигә әйләнеп карамый гына:

—Кахан йомшак табигатьле кеше, рәнҗетә күрмә тагын үзен, балакай.

—Ул мине рәнҗетмәсә, мин аны рәнҗетергә тырышмам, хәрам ата.

—Бик әйбәт, бик әйбәт, балакай. Менә тәхет ишеге, мин анда үтмәм, кыю бул, балакай. Кахан кыюларны ярата...

—Рәхмәт, хәрам ата.

Айбиби күренүгә, ишек янындагы сакчылар айбалталарын читкә алды һәм тәхет ягы ишекләре ачылды. Эчкәре ишекләрне ачучылар Айбиби үтүгә, ишекләрне ябып та куйдылар. Айбиби чак кына башын күтәрде һәм түр якта киң терәкле тәхеттә утырган каханны күрде. Ул аңа затлы күренде, һәрхәлдә күңел күзе шулай кабул итте. Айбиби керүгә һәм аңа күз ташлауга, кахан тәхетеннән купты, әкрен генә, бер сүз әйтми, аның янына килде, ияк очыннан алып, башын күтәрде, күзләренә карады.

—Мин сине көттем, Айбиби,—диде. Гап-гади итеп әйтте: "Мин сине көттем". Аннары терсәгеннән алды да берьякта торган кечкенә өстәлгә таба алып китте. Айбибине урындыкка утыртты һәм үзе аның каршына утырды. Менә шунда Айбиби каханның йөзенә күз төшереп алды. Тутсылрак йөзле иде Йосыф кахан, күзләре кара-күгелҗем, Идел ярларында үскән бөрлегән төсен хәтерләтәләр. Кечкенә йомры сакал, төз борын. Киңчә кашлы. Кул бармаклары нечкә, озын. Әмма тыгыз бәдәнле сыман тоелды Айбибигә булачак ире.

—Исем-атың Айбиби бит, шулаймы хан кызы?

Айбибигә аның тавышы, нәзакатьле итеп соравы ошады, ул аңа сусыл иреннәрен җәеп елмайды. Әйе, Идел буе Болгар ханы кызының исеме Айбиби, Талиб атасы биргән исем. Әнә шул бала Йосыф каханга кырык беренче хатын булып тартылды. Кабул итсә, кабул итсен, кабул итмәсә кайтарып җибәрсен. Эчтән шулай дисә дә, ни сәбәпледер, бу сүзләрне әйтергә кыймады, аны нидер тыйды, нидер дәштермәде.

—Мин сине, Мөхәммәд хан кызы, болай ук гүзәл булырсың дип уйламаган идем. Мин өлкән равваны да кисәтеп куйдым, атаңа да кат-кат әйттем, Айбиби кызың баш хатын булыр, дип. Һәм ялгышмаганмын. Син, чынлап та, гүзәл зат, минем аккошларымны хәтерләтәсең.

Йосыф кахан Айбибинең кулына үрелде, кулын-кулга куйды. Ахыр урыннан купты да Айбибинең алдына тезләнде.

—Ни эчә, ни тели, хан кызы Айбиби?

—Чия төнәтмәсе, кахан, чия төнәтмәсе.

Кахан көмеш кыңгырауны зеңләтте. Ишектә хезмәтче күренде.

—Миңа грек шәрабы, хан кызына чия төнәтмәсе китер.

Бавырчы булса кирәк, каханга баш иде дә чыгып китте һәм күп тә үтми, ике кулына ике көмеш бокал тотып килеп тә керде. Бавырчы шул чиккә җитеп юан гәүдәле иде ки, Айбиби аңа кызыксынып карап алды, чөнки теге атлаганда як-якка авыша, ә аяклары йөрми, шуып йөридер кебек иде. Бокалларны өстәлгә куеп киткәч, Айбиби каханнан сорап куйды.

—Нигә ул шулкадәр юан?

—Бирәннәр санында йөри ул, һәр елны беренче урынны ала. Без ел саен бирәннәр ярышы уздырабыз, шул ярышта һәр елны миннән бүләк ала. Хәрам ата ул, алар барысы да юаннар. Аларга ашаудан башка берни дә кирәкми. Минем хатыннарыма да алар хезмәт күрсәтәләр.

—Ә раввалар нишлиләр?

—Раввалар!—дип гаҗәпләнде Йосыф кахан.—Раввалар һәммәсенә дә күз-колак булып торалар, барысына да. Сарайдагы тәртипләрне Булан кахан урнаштырып калдырган. Шул тәртип белән яшибез, көн күрәбез, хан кызы Айбиби.

Шулчак тәхет ягына бер көтү кызлар килеп керде, барысы да өстәлне уратып, каханга килеп елыштылар. Айбиби ни кылырга белми каушый калды. Болар кемнәр? Нинди кыз балалар?..

—Булды, булды,—диде аларга Йосыф кахан.—Булды, китегез.

Кызлар ничек килеп кергән булсалар, шулай чыгып та киттеләр. Айбибинең каханнан сорыйсы килде: "Кемнәр, нинди кызлар болар?", тик теле

бармады. Кызларның яшькелт матур күлмәкләре, башларындагы өрфә калфаклары гына бермәл күз алдында торды.

—Гаҗәпләнмә,—диде ана кахан.—Хатыннарымнан туган кызларым, мәдрәсәдә укыйлар. Улларым да бар, ләкин аларның берсе дә Аккалада юк, төрле биләмәләрдә тәрбияләнәләр.

—Кызларыгызны да равваларыгыз укытамы?

—Равваларым укыта. Равваларны мин махсус чакыру аша Исраилдән тарттырдым.

Ни әйтә ала иде ул аңа. Һични! Бит ил каханы, кахан идарә иткән ил астында уннарча ил вә халыклар, барысы да каханатка ясак түли, шул исәптән Болгар да. Моны гына яхшы белә инде Айбиби. Ул хәзер үк аңа үз таләпләрен куярга тиеш, иртәгә соң булып куюы бар. Хәзер үк. Айбиби каршында грек шәрабе эчеп торган Йосыф каханга карады, елмайды.

—Хөрмәткә ия кахан, мин Хазарстанга үз иркем белән килмәдем, богаулап ук озатмаса да, мине атам сезнең кырга җибәрде. Мине, хөрмәткә ия Йосыф кахан, йөзләрчә кеше озата килде. Шулар арасында минем шәехем, абыстаем, табибым бар. Алар бире килеп йөрерләрме, әллә булмаса миң үзем Ханбалыкка алар янына чыга йөрерменме?..

Йосыф каханның тутсыл йөзенә елмаю галәмәте кунды, башын түбән иеп, бермәл як-якка чайкап торды, шуннан соң гына Айбибинең зәңгәр күзләренә карады. Карады да, ни сәбәпледер, коргаксыган иреннәрен ялап куйды.

—Сарайга бары тик мин биргән мөһерле тәңкә белән генә кереп була, Айбиби. Синең белән килгән гаскәриләр кайтып китәрләр, атаң белән шулай килешенгән. Ә менә абыстаең белән табибың бире керә йөрерләр, аларга кахан мөһере бирелер. Шәехкә юк, шәех Тәбирне мин беләм, аңа иленә кайтып китү хәерлерәк булыр, Мөхәммәд хан кызы Айбиби. Минем әмерем шул булыр...

—Рәхмәт галиҗәнапләре, мин сезнең игелегегезне гомерем буена онытмам.

—Гомер буе,—диде Йосыф кахан һәм бокалын өстәлгә куйды.—Шартнамәләргә гадәттә мин илчеләрне кабул итү бүлмәсендә имзам сала идем, хан кызы. Сиңа ташлама ясарга булдым...

Шул сүзләрне әйтте дә кеткелдәп көлеп алды һәм кесәсеннән ике алтын тәңгә чыгарып бирде.

—Шушымы рөхсәт тәнкәсе?

—Ләкин бер шарт белән, якыннарың син бирегә килгән көннән бер ай вакыт үткәч кенә керә алалар. Бу алтын тәңкәләрне мин үз илемдә суктырам. Алар йөрештә, ләкин Аккалага үтү өчен сугылган тәңкәләрдә минем сурәтем вә исемем язылган.

—Ай эчендә мин авырып китсәм?

—Үзем дәвалармын, үзем,—диде Йосыф кахан көлемсерәп.

—Иншалла, Тәңрем мине ташламас.

—Тәңре мәҗүсиләр алласы, хан кызы. Минем сараемда юк-барга ышанмасагыз иде. Мин илемдә һәм калаларымда барча диннәргә дә ирек бирдем, барча диннәргә дә. Ханбалыкта мәчетләр дә, чиркәүләр дә, синогоглар да бар. Минем илемдә һәр адәм баласы үз динен тота ала, хан кызы Айбиби. Шуның өчен синең мөслимә булып калуыңа мин каршы түгел, әмма нә христианнарга, нә мөселманнарга Аккалага керергә рөхсәт ителми. Бу хакта да белеп торсагыз иде, Мөхәммәд хан кызы Айбиби.

Шул сүзләрне әйтте дә Йосыф кахан янә көмеш кыңгыравын зеңләтте, шундук тәхет ягына өч-дүрт равва керде һәм алар бер сүз әйтми, Айбибине өстәл яныннан култыклап алдылар да тәхет ягыннан алып чыгып киттеләр. Һәм янә бер сүз әйтми, аны үз бүлмәсенә кертеп калдырдылар. Ни гаҗәп, ни өчен шулай дип Айбиби дә сорамады, раввалар да бер кәлимә сүз әйтмәделәр, алып чыгып барганда кечкенә өстәл янында грек шәрабе суырып утырган Йосыф кахан да авыз ачып бер сүз әйтмәде.

Бүлмәсенә кергәч, Айбибигә кинәт ямансу булып китте. Ул күңел күзе

белән карамый гына бүлмәдәге җиһазларны күздән кичерде һәм түр яктагы ятакка барып ауды. Нәкъ менә ауды. Ул һични анламады һәм анлар халәттә дә түгел иде. Ни өчен Йосыф кахан шулай итте. Бит матур итеп кенә сөйләшеп утырганнар иде, югыйсә. Әйе, күзгә-күз карап, елмаешып. Айбиби бермәл өнсез калды. Ни өчен, ни өчен, ни өчен?!. Сорау, сорау, сорау. Әйе, ни өчен аны Йосыф кахан үз кырыннан бик тиз озатты?.. Кинәт атта далага чыгып чапкан Ислам күз алдына килде. "Ислам, бәгырь, кайда син, кайларда йөрисең!.. Син булсанмы, син булсаң, мине..." Әйе, нишли алыр иде Ислам?.. Һични кыла алмас иде, чөнки ул әсир ителде һәм аны—Мөхәммәд хан кызын—Хазарстан каханы Йосыф әсир итте. Каханнан барысын да көткән иде Айбиби, ләкин һич тә болай булыр дип уйламаган иде. Әллә соң акыллы булырга теләдеме?.. Бик ихтимал ич. Нинди ир-зат үзеннән акыллы хатын-кызны яратсын, ул аңардан көне белән читләшә, көне белән... Шулай диде аңа Рәшидә анакае, шулай. Бик акыллы булып күренергә тырышма, акыллы ир-атны үзеңнеке итәргә теләсәң, башыңны беразга юләргә сал. Үзеңнеке иткәч, акылыңны күрсәтерсең... Димәк, мин кахан алдында акыллы булырга теләдем, ә бу хәл каханга ошамады. Хәер, син моны үзең теләгән идең ләбаса! Уен-көлке белән каладан чыгып китсәң дә, күңелең бер дә кырык хатыны булган каханга тартылмады, нигәдер күз алдында һәрчак Ислам торды, Ислам булды. Хак, Йосыф кахан аңа ошады, күңеле кинәт йомшарып, йөгәнсезләнеп китте, ләкин бу хәл шундук үтте.

Айбибинең тамак төбенә төер тыгылгандай булды, күзләре дымланды, бите буйлап яшь бөртекләре ага башлады. Ләкин ул аңа игътибар итмәде. Күз алдына яшь томаны аша әле Ислам, әле Йосыф кахан килде. Икесе дә аны кызганалар, юатырга телиләр сыман. Ә ул аларга үпкәле, елый да елый. Их, кырында Рәшидә анакае булса икән! Юата белер иде ул аны, аркасыннан сөя-сөя юатыр, матур-матур сүзләр тезәр иде.

Айбиби шыңшый ук башлады. Шул вакыт тәүге хәрам ата ишекне кысып кына ачты да, башын тыкты. Элек игътибар итмәгән иде хәрам атага, ә ул чөенке борынлы, мөлдерәп торган симез йөзле, кысык күзле иде.

—Айбиби бала елый,—диде хәрам ата, ишекне киң итеп ачты, әмма бусагадан узмады.—Тиздән сиңа да нәүбәт житәр, балакай, елама. Мин сине ашарга дәшәм, ашханәгә, хатыннар анда инде, сине көтәләр—баш хатынны.

—Мин баш хатын түгел, мин хан кызы, Мөхәммәд хан кызы.

—Менә шулай, ачулан, ачулану белән үз көенә кайтырсың. Хан кызымы син, Йосыф кахан хатынымы, сарайга тартылгансың икән, баш хатын инде син, балакай. Баш хатын. Һәм аста ашханәдә Йосыф каханның кырык хатыны кулларына кашык тотарга куркып сине көтәләр.

—Хәзер үкме?

—Хәзер үк, балакай, хәзер үк. Битеңдәге яшьләрне әнә теге сөлгегә һәйбәтләп сөрт тә, әйдә...

Айбиби чынлап та кыюланып китте, хәрам атага ияреп китте, барыр җайда ул аңардан сорады.

—Атың ничек, хәрам ата?

—Саул идем, хәзер инде миңа ул исем белән бик сирәк дәшәләр.

—Димәк, син, бичара, яһүд.

—Яһүд, балакай, яһүд. Мине Румда шул хәлгә төшерделәр. Халкын христиан диненә өндәп йөргән өчен яман халык тотты да...

—Нинди яман халык?

—Мәҗүсиләр, имансызлар.

—Син аларга каһәр укы, атакай.

—Каһәр укып кына булган әгъзам кайтса икән ул, балакай.

...Аларны күрүгә өстәл янында утырган хатыннар шым булдылар, барысы да Айбибигә текәлде. Хәрам ата Айбибине кулыннан тотып, тиешле урынга утыртты. Айбиби исә, тезелеп утырган хатыннарга күз йөртеп чыкты да, затлы киенгән һәм берсеннән-берсе чибәр күренгән ишләренә сәлам юллады, ахыр:

—Табындагы ашларыгыз тәмле булсын, хатыннар,—диде.

Хатыннар барысы да елмаешты һәм кашык-ризыкларына үрелделәр. Айбиби дә алдына куелган ризыкка күз ташлады. Савытта балык ите иде, сөяксез диярлек. Хатыннар үзара тыенкы гына сөйләшә-сөйләшә ашадылар, хәрам атакайлар китергән һәр ризык тәмле тоелды Айбибигә, ләкин кайбер ризыклардан баш тартучы хатыннарны да күрде. Шунда ул тутсылрак йөзле, зур кара күзле бер хатынга игътибар итте. Хатын Айбибигә карый да елмая, карап ала да елмая. Күлмәге яшькелт-сары, өрфия тукымадан булган яулыгын маңгаена төшереп үк бәйләгән. Яулыкка җәйран сурәте төшерелгән. Хатынның бармаклары нечкә, очлаеп килә. Сулъяк битендә чәнчә бармак очы хәтле генә миң. Әллә ясалма, әллә туа-туганнан килә—белмәле түгел. Күз керфекләре озын, өскә таба кайтарылып тора. Күзләрен күтәреп Айбибигә караган саен баш хатын буласы һәм инде шул вазифаны үти дә башлаган Мөхәммәд хан кызына унайсыз булып китә һәм ул аның тарафына карамас була. Хак, Айбиби бәрәм-бәрәм башка хатыннарга да күз төшереп чыкты, ләкин ахыр чиктә зур кара күзле хатын барыбер аны җәлеп итә төште.

Табынга алма-хөрмә, җиләк-җимеш китерделәр. Нигәдер Айбиби хатыннар йөзендә монсулык күрмәде, хатыннар үзара сөйләшә-сөйләшә ашыйлар, хәтта көлешеп тә алалар, ә менә зур кара күзле хатын берсе белән дә сөйләшми, аралашмый, тик әкрен генә ашап утыра, әмма юк-юк та Айбиби ягына карап ала һәм озын керфекләрен каккалап, күзләрен түбән төшерә иде. “Күр әле, бер гаиләдәй яшиләр икән бит Йосыф каханның хатыннары, ә ана әллә ниләр сөйләп бетерделәр. Әйе, өйдә чакта, сарайда—Болгарында. Имеш, хатыннар арасында төрле хәлләр булгалый, үзара кахан өчен ызгышып та алалар. “Тик бер ирне ничек кырыкка бүлергә була икән?”—дип уйлады Айбиби. Бәхәссез, кахан хатыннары барысы да аны өзелеп яратмыйлар һәм үзләренә тиешле көнне зарыгып көтеп алмыйлардыр. Бит нигездә аларны бикләп тоталар. Хак, еш кына калага алып чыгалар, Идел буена алып төшәләр, көймәләрдә йөртәләр, әмма һаман да шул бер хәрам аталар.

Ашап-эчкәч, хатыннар шау-шу килеп бүлмәләренә таралыштылар. Айбиби дә хәрам ата озатуында үз бүлмәсенә таба кузгалды. Шунда ул кырын күзе белән генә күрде, хәрам атадан кала төшеп, әнә шул зур күзле хатын атлый һәм аңа, нидер әйтергә теләгәндәй, ымсынып куйгандай итә. Һәрхәлдә Айбибигә шулай тоелды. Хәрам ата исә, башын түбән игән килеш атлый да атлый, берәүне дә күрми, күрергә дә теләми сыман. Ана хатыннар оясы ике дөнья бер моржа иде, күрәсең. Хәрам атакайга күз ташлауга хәтер күгендә эленеп калган карт алаша пәйда булды. Андый атлар күбрәк сабашларда, ягъни иген игүчеләрдә, җир сукалаучыларда булырлар иде. Мескен ат сукадан туктагач, арып-алҗуы шул чиккә җитә иде булса кирәк, күз кабакларына кунган явыз чебеннәрне дә кумас иде. Бу хакта ана Рәшидә абыстай да сөйләде, мескен атны адәми затлар кайчандыр рәнҗеткәннәр, бер әгъзасыннан мәхрүм иткәннәр. Тик бу ни була инде?! Кая монда гаделлек?! Ничек Аллаһыдан курыкмыйлар кахан раввалары?.. Рәшидә абыстае бу хакта бик тәфсилләп сөйләсә дә, ул вакытта Айбиби моңа гомумән көлеп караган иде. Монда исә ул кешеләрне үз күзе белән күрде һәм хәрам атаны кызганып куйды.

—Хәрам ата, бар инде, син кит, үз юлында бул. Мин үзем дә бүлмәмне табармын.

—Яхшы, балакай,—диде хәрам ата һәм аягын сөйрәп китеп барды. Айбиби артына әйләнеп карады, зур күзле хатынны көтеп алды.

—Исем-атың ничек?—дип сорады ул хатын килеп җитәр-җитмәс.

—Хәдичә атлы мин...

—Кай илдән тартылдың?

—Гарәбстаннан.

Төрки телдә сакаурак сөйләшсә дә сүзләрне дөрес әйтә иде Хәдичә хатын.

—Атаң-анаң кем иде?

—Хәлиф җариясе идем мин, хәлиф җариясе. Минем сезнең бүлмәгезгә керәсем килә, әйтер сүзем бар,—диде хатын Айбибинең күзләренә карап. Зур кара күзләрдә ниндидер сихер бар кебек тоелды Айбибигә, әмма хатынның кәефен кырырга теләмәде.

—Әйдә сон,—диде ул һәм алдан китте.

Бүлмәгә кергәч, Хәдичә хатын әйтте:

—Бүген безне Аккошлар култыгына алып төшәчәкләр, Йосыф кахан да киләчәк.

—Нинди аккошлар тагын?

—Монда Аккошлар үрчетә торган култык бар, Идел елгасы култыгы, шунда аккошлар төшә, ә без аларны ашатабыз, Айбиби.

—Син минем исемемне дә беләсең икән,—дип "син"гә көчте Айбиби.

—Безгә бу хакта раввалар күптән җиткерделәр инде. Сезгә Идел буе Болгарыннан баш хатын тарттырачаклар, диделәр. Кахан ятагына керергә нәүбәтне дә син куячаксың, диделәр. Минем кахан ятагына кергәнем юк дияргә була.

—Нигә алай, Хәдичә?—Айбиби хатынны кулыннан алды, ятакка утыртты.

—Яратмадым мин аны. Ул үз динен барча диннәрдән дә өстен күрә. Ә бу саташудыр. Аннары мине ул никахсыз алырга теләде. Шуның өчен минем синең белән сөйләшәсем килә. Син дә бит мөслимә. Кахан ятагына никахсыз үтәргә исәбеңме әллә?

Моны Айбиби Хәдичә хатыннан көтмәгән иде, ул аның янәшәсенә утырды, ике учы белән хатынның битләреннән алды, күзләренә карады. Һәм гүя төпсез диңгезгә чумгандай хис итте үзен. Ни бу, ни булды аңа?.. Айбиби аны кочагына алды, назлый-сөя башлады, гүя Хәдичә хатын нәни бер бала иде. Хәдичә калтырана һәм аңа елыша башлады. Ахыр елап ук җибәрде.

—Без бүген өрфия күлмәкләр киеп Аккошлар култыгына төшәчәкбез. Барчабыз да...,—диде шыңшый-шыңшый Хәдичә.

—Син әле дә сафмы?

Хәдичә Айбибинең күзләренә карады, яшьле күзләре мөлдерәмә тулы яшь иде.

—Мин Мөслимә, Айбиби. Мөслимә. Ә ул мине кимсетмәкче, рәнҗетмәкче. Булмас ул, булмас!..

—Тынычлан Хәдичә, сине мин рәнҗетергә бирмәм.

Хәдичәнең зур күзләре тагы да зураеп китте. Ул бер тын ни әйтергә белми торды. Ышанды да кебек ул Айбибигә, ышанмады да, чөнки бит хан кызы каханның ятагында да булмаган әле. Моның өстенә хәрам атакайлар күзәтә, баш хатын булып алган Айбиби кемне дә булса якласа, йә булмаса аңа нинди дә булса ярдәм итсә—Айбибине җәза көтәчәк һәм бик яман җәза. Айбиби белми булса кирәк әле, Хазарстанда ил белән Сабир каханбәк идарә итә, ә каханбәк белән кахан, кахан белән өлкән равва. Хәрам аталар барысы да өлкән раввага буйсына, әйе, сарайдагы казнабашка кадәр өлкән раввага хисап тота. Тәүге өлкән равваның кахан хатыннарының берენә күзе төшә һәм җай китереп, теге бичара хатынны бүлмәсенә алып керә. Ә хәрам аталар бу хәлне каханга җиткерделәр. Кахан исә, каханбәк Сабирны дәшеп алды да барча хатыннары алдында бер-берсен яратышып кавышканнарны кылычтан уздыртты. Гыйбрәт булсын өчен. Менә нинди шартларда яшиләр алар кахан кулында. Айбиби исә боларның берсен дә белми булса кирәк.

—Безне далага да алып чыккалыйлар. Бер тапкыр шулай далага чыккач, кыргый угызлар каханның ике хатынын урлап алып киттеләр, кахан сакчылары кыз урлаучыларны куа барсалар да якын килергә курыктылар, чөнки угыз мәргәннәре оста мәргәннәр, очкан кошның күзенә тигезәләр. Әмма кахан моңа бер дә лаф ормады. Шул хатыннар иленнән вә халыкларыннан тагын икешәр хатын тарттырды.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде. Ул белә иде, яһүд раввалары борын-борын

заманнардан ук күп хатын тотканнар. Әйтик, Сөләйман пәйгамбәрнең тугыз йөз хатыны була. Ә менә Хазарстан каханына тугыз йөз хатын тотарга раввалар рөхсәт бирмәгән. Кырык хатын җитәр, дигәннәр. Һәм шул хакта хәтта канун чыгарганнар. Йосыф кахан да әнә шул канунга таянып яши, ил белән идарә итә.

Шулай диде дә Хәдичә хатын янә Айбибигә килеп сыенды һәм елтырый башлаган күзләре белән хан кызына карады.

—Минем дә кемнәрдәндер сөеләсем килә, Айбиби. Сөй әле, ярат әле мине, мин бичара саф калган кыз баланы, синең кебек кыз баланы, Айбиби ахирәт.

—Ахирәт!—дип гаҗәпләнде Айбиби, ә үзе Хәдичәне кочагына алды, чәчләреннән сыйпады, аркасыннан, янбашыннан сөйде, әнә шуннан соң аның үзенә дә әллә ниткән аңлап та, аңлатып та булмаган якынлык ташкыны килеп орылды. Аның кочагында Хәдичә түгел, гүя сарай табибы улы Ислам ята иде. Юк, кахан үзе. Айбиби Хәдичәнең башын тагы да күкрәгенә кыса төште һәм күкрәгенә елышкан саен мөслимә кызның калтырана башлавын тоеп, ни өчендер кисәк сискәнеп китте. Бөтен тәнен тетрәндереп, сәер бер халәт узды, колак түрендә татлы бер рәхәт зеңләп, йөрәген җилкетеп куйды. Шушы назлау, шушы сөю аңа шул чиккә җитеп рәхәт бирде ки, ул чак кына кычкырып җибәрмичә калды. Һәм шунда зиһене аша курку хисе узды. Кемдер ишекне шакый кебек тоелды.

—Кем бар анда?!

Хәдичә иненә төшкән өрфия яулыгын рәтләде, кызарынып киткән күзләре белән көзгегә барып капланды. Һәм Айбибигә карамый гына:

—Никахсыз каханны янына алма, хан кызы,—диде.

Айбиби торып, ишекле-түрле йөреп килде.

—Ничек инде никахсыз, Хәдичә ахирәт?..

—Мулла чакыртсын да никах укытсын, шуны таләп ит. Син баш хатын буласы кеше, шуны таләп ит. Минем кебек. Без хәзер синең белән ахирәтләр, Айбиби.

—Ахирәтләр,—диде тыенкы гына Айбиби бу сүзнең ахырына төшенми торып.

—Ләкин бит аның мине...

—Әйтмә алай, Мөхәммәд хан кызы, әйтмә,—дип Айбибигә таба борылды Хәдичә. Аның зур кара күзләрендә чаткылар җемелди кебек иде.—Без ахирәтләр, ахирәткә кадәр бергә булырга тиешбез.

—Кахан бар хатыннарын да үзе...

—Белмим,—диде Хәдичә аның янына ук килеп.—Белмим, кайбер булачак хатыннарын хәрам аталар сөяк белән...

—Бу хакмы, Хәдичә?

—Кахан кайбер хатыннарын әнә шул ысул белән эш иткәннән соң кабул итә, диләр. Ләкин мин ышанмыйм. Хәрам аталар миңа кагылмады, гөнаһка керәсем килми.

—Өлкән равва да сабак бирәме?

—Атнага бер, шимбә көнне, шимбә яһүдләр көне.

—Мин аны кайчан күрә алам?

—Белмим, ләкин син аны күрерсең. Ул кайчан Аккошлар култыгына да төшә... Каханга ияреп.

—Нигә?

—Белмим. Өлкән равва һәммәсенә дә баш кеше, хәтта кахан да аңа буйсына.

—Миңа кахан табибым һәм абыстаемны сарайга кертергә рөхсәт бирермен диде. Тик бер айдан соң дип әйтте.

—Табибың кем?

—Җиткән егет, мин аңа гашыйк идем, тик Йосыф каханны күрдем дә ул күңел түремнән китеп, читкәрәк басты кебек.

—Син каханга гашыйк булдыңмы, Айбиби?!

—Юк дисәм, ялганлармын дип куркам, Хәдичә ахирәт. Ул минем алды-

ма тезләнде, башын тезләремә салып торды һәм мин аны, үзем дә сизмичә, башыннан сыйпый башладым. Ошады миңа кахан, Хәдичә ахирәт, кичер мине.

—Абыстаең бу хакта беләме?

—Юк, ул бернәрсә дә белми, алар Ханбалыкта, аларны сарайга уздырмадылар.

—Мин сиңа бернинди дә киңәш бирә алмыйм, ахирәтем, йөрәгең ни тели, йөрәгең ни әйтә—шулай ит.

Шулай диде дә Хәдичә хатын чыгып китте. Айбиби ятагына килеп утырды да маңгаен учларына салып, бер тын уйланып утырды. Ниләр сөйләде ул ком сахрасыннан килгән һәм бөтенләй ят табигатьтә туып-үскән кызга һәм, иң гаҗәбе, нә атасын, нә анасын белмәгән кешегә? Ә бит аның раввалар шымчысы булып куюы да бар иде. Айбибинең бермәлгә зиһене чуалды, ни уйларга белми үзенең самимилегенә исе китеп, бик озак бер ноктага карап торды. Кая караганын ул белмәде, чөнки бөтен уй-хисе күңел түрендә, йөрәген тынлый иде. Шунда ишек шакыдылар, гадәттәгечә хәрам ата башын ишеккә тыкты.

—Мөхәммәд хан кызы Айбиби балакай, өрфия күлмәгең ки. Күлмәгең киштәдә. Аккошлар култыгына төшәбез.

—Ярый, атакай,—диде Айбиби. Һәм, торып, көзге янына килде, битләрен сыйпаштырды, чәчләрен рәтләде, дистәләрчә күлмәкләр арасыннан өрфия күлмәкне табып, анадан тума чишенде, шул күлмәкне киде дә нindидер үзе дә анлап бетермәгән оялу тоеп, көзге алдына килеп басты. Хак, адәм тәнен күлмәк яшерә, ләкин барыбер сын күренә, сихерле бер серләр йомгагы аша күренә иде. Айбиби нечкә биленә, калку күкрәкләренә игътибар итте, эчкә баткан кендегенә, гәүдә-сынына һәм барысыннан да канәгать калып, үзалдына елмайды. Аны шушы күлмәктә күргәч, кахан йә егылып китәр, йә сукыраер. Сукыраймаса да Айбибигә ияреп китkәнен сизми калыр. Кинәт кенә Айбиби бер башка үскәндәй булды. Баш хатын булганы өчен генә түгел, гүзәллеге һәм зифалыгы белән дә, зәңгәр күзләре белән дә, төсе-йөзе белән дә... Тагын ние белән?.. Менә анысын белми иде Айбиби.

***

Аккошлар ашатырга төшкәндә Хәдичә анда иде инде. Хатыннар барчасы да аңа игътибар иттеләр. Чөнки Айбиби аларның барчасыннан да күлмәк төсе белән генә түгел, яшьлеге, сафлыгы белән аерылып тора иде, чөнки аның йөзенә каханның һәммәсенә дә битараф булган гамьсезлеге, хатын-кызга булган мәхәббәтсез генә тартылу халәте кунмаган иде. Ул, чынлап та, хатыннар арасында Идел суы читенә сибелгән гади ташлар арасындагы бәллүр иде. Күзе-йөзе генә түгел, гәүдә-сыны да җем-җем итеп тора, үзенә дәшә, чакыра иде. Моны Айбиби шундук сизеп алды һәм, әлбәттә, ахирәте Хәдичә дә.

Айбибигә аккошлар ашатырга җим китереп бирделәр. Җим вак балыклардан тора, тубалга салынган, су кырына киләсе дә аккошларга ташлыйсы гына. Һәм Айбиби шулай итте дә. Шунда бер могҗиза булып алды. Ике аккош сөешә башладылар һәм беркемгә игътибар итми яратышалар иде. Муеннарын-муеннарына урыйлар, әле чумып китәләр, әле канатларын җәеп кочаклашкандай итәләр дә су өстендә биешә башлыйлар. Хатыннарның күзе сөешкән аккошларда иде. Кошларның сөешүе хатыннарны тәмам сихерләде, алар тып-тын калып, хәтта үзара сөйләшүдән дә туктадылар. Әмма бер читтәрәк торган хәрам аталар бу хәлгә исләре китми генә ком өстендә утыра бирделәр. Хәдичә Айбиби янына килде һәм ахирәтенең кулыннан алды да каты итеп кысты.

—Алар бер-берсенә гашыйклар, алар бер-берсен яраталар, шулаймы, Айбиби?

Шунда хатыннарның берсе:

—Кахан, Йосыф кахан!—дип кычкырды.

Барысы да кахан килгән якка әйләнеп карады. Йосыф кахан чынлап та нәкъ алар янына, ягъни хатыннары аккошлар ашаткан җиргә килә иде. Йосыф кахан җемелдәп торган яшькелт-кызылсу халаттан. Аны хәрам атакайлар каршы алды һәм су буена озатып кузгалдылар. Һәр атакайның кулында озын таяк.

—Таяклар нигә?—дип сорады Айбиби Хәдичәгә карамый гына.

—Таяклар каханга үрелгән хатыннарның кулларына сугарга,—диде Хәдичә.

—Каханга тотынырга да ярамыймыни?

—Ярамый.

—Баш хатын буласы кеше мин тотынсам. Әйе, гәрчә ятагында булмасам да.

—Син, Мөхәммәд кызы Айбиби, башта раввалар кулыннан узарга тиешсең?

—Ничек раввалар кулыннан?

—Алар синең сафлыгыңны тикшерергә тиешләр.

—Сине дә тикшерделәрме?

—Мине дә тикшерделәр. Ләкин мин мөслимә буларак каханнан баш тарттым. Никах укыткач дидем. Кахан килеште, әмма мулланы чакырмый да чакырмый.

—Йосыф кахан төрки ич, нигә ул...

—Атасы төрки булган, диләр, ләкин әнисе Сара Таман тархан кулында, ул анда Айгөл хатынның углын үстерә. Балигъ булгандыр инде ул бала.

—Апамның улы бирегә беркайчан да кайтып күренмәдемe?

—Юк, моны кахан үзе теләми, диделәр. Каханны ефәк бау белән сынагач кына, өлкән равва рөхсәте белән угланны бирегә алып кайтачаклар.

Айбиби каханнан күзләрен алалмады, ә үзе Хәдичә хатынны тынлады, аны Йосыф кахан кызыксындыра башлады. Ул аның кырына кырык беренче хатын булып килде. Кайчан һәм кай көнне мәһшүр кахан аны ятагына тарттырыр? Тарттырган хәлдә ул нишләргә тиеш, каханга Хәдичә хатын кебек шарт куяргамы, әллә карусыз кочагына инәргә тиешме?.. Кем ана бу хакта киңәш бирә ала? Һичкем. Чөнки киңәшчесе Рәшидә абыстай кырында юк, ансыз ана биредә яшәве кыен булыр, бик кыен хәтта.

Күр инде, Йосыф кахан туп-туры аңа таба килә. Туп-туры, һичкемгә игътибар итми. Айбибигә җитәрәк, атакайлар туктадылар, таякларына таянып, нидер көтеп тора башладылар. Кахан Хәдичәгә: "Кит!"—дип кул гына селтәде. Шулчак Айбибигә оялу килде. Бит аның бөтен тәне-җаны хәтта үтәли күренә. Хак, Рәшидә абыстай аңа барысын да өйрәтте, ирләр белән хатыннар арасында булган хәлләрне дә тәфсилләп сөйләр иде. Ни кылырга, ничекләр үзеңне тотарга. Бигрәк тә кыз белән кияү арасында буласы якынлыкны, булганнан соң булган хәлләрне... Тик бит монда ул кияүгә чыкмый, аны көчләп каханга тарттырдылар, көчләп. Ул монда бары тик атасы Мөхәммәд хан үтенече белән генә килде. Бары тик! Һәм ни кылмак кирәк, Йосыф кахан аңа ошады. Юк, ул аңа гашыйк булмады, була да алмады, ләкин инде кахан аны алтын җеп белән булса да үзенә бәйләгән иде. Бу беренче очрашуда ук булды, кахан үзенең башын аның тезләренә салгач та...

Йосыф кахан гадәттән тыш озын халаттан иде, халаты ялт-йолт килә, башында шундый ук алтын җепләр белән тукылган тәкыя. Ярым яһүд, ярым төрек Йосыф кахан ике халыкның да сыйфатын бергә җыйгандай үзен горур тота. Башы чөелгән, ияге алга чыккан, күзләрендә эчке бер хиссият белән тулы елмаю. Ул өстен, барчасыннан да өстен, әле яшь, ир уртасы, ә монда яна табадан төшкән кебек бер кабып йотардай, Идел камышлары арасында үскән чәчкә кебек асыл-зат—япь-яшь кыз бала, җитмәсә Идел буе ханының кызы, аксөякләрдән, борынгы аксөяк нәселләрдән килгән сылу.

Якын ук килгәч кенә тойды Айбиби: Йосыф кахан күрер-күзгә бер дә

хатын-кыз кызыкмаслык ир-зат түгел икән шул. Сарайда чакта каханның буй-сынына ул чаклы игътибар итмәгән иде Айбиби, монда исә кахан бөтен барлыгы белән аның күнеленә кереп оялады. Ул аны күнеле белән кабул итте. Бит-йөзе генә түгел, сызылып киткән кара мыегы да каханга килешеп тора иде. Күз-карашында ниндидер йомшаклык, табигыйлык, эчкерсезлек.

Янындагы Хәдичәне гүя җил алды, Йосыф кахан аның каршына ук килеп басты. Айбиби оялудан (бу ир-ат аның йөрәк тибүен күрәдер кебек тоелды) башын түбән иде, аяк очларына карады. Һәм шунда каханның болгари итек башында бармак башы кадәр зөбәрҗәт таш күреп, күзе чагылып китте.

—Айбиби,—диде килеп туктауга Йосыф кахан.—Аккошлар ашатырга төштекме? Ошадымы безнең аккошлар. Әйе, минем аккошлар?..

—Мин аларга җим ашаттым инде, хөрмәткә ия кахан,—диде Айбиби һәм бер читтәрәк басып торган атакайларга күз ташлап алды. Моңа кахан да игътибар итте, борылды да атакайларга китәргә ишарә ясады.

—Мөхәммәд хан кызы Айбиби, атакайлардан ояламы?—диде Йосыф кахан.

—Мин сездән дә оялам, Йосыф кахан, сездән дә. Алып китегез мине моннан, югыйсә мине җир убар.

—Җир убар,—дип кеткелдәп көлеп алды Йосыф кахан, һәм күз ачып йомганчы Айбибине кулына күтәреп алды да ерак булмаган чатырга таба алып китте. Айбибинең өне алынды, ул курка калып, каханның муенын кысып кочты.

—Менә шулай, шулай кирәк, хан кызы,—диде Йосыф кахан һәм, аны чатырга кертеп, йомшак җофар тиресе җәелгән түшәккә салды. Ә үзе сиздерми генә кырына ятты.

—Миңа оят, миңа...

Йосыф кахан бер сүз әйтми, аны сөя-назлый башлады. Башта Айбиби үзендә аңлашылмаган курку тойды, ахыр сөю-назлауга чарасыз калып, үзе үк аңа тартылды. Кахан аны шундаен сабыр һәм әкрен генә назлады вә сөйде, үпте, яратты ки, Айбиби һуштан язар дәрәҗәгә җитеп, үзе дә сизмәстән татлы итеп ыңгырашып куйды. Шушы халәте, татлы итеп ыңгырашып куюы, торган саен каханга сыена баруы илбашының канын кыздырды бугай, ул сак кына аның күлмәген салдырды, тыгыз күкрәгенә кагылды һәм Айбибине бөтенләй чарасыз итте. Ул инде бернәрсә дә ишетми, ул наз-сөюдән тәмам хиссият дулкынында тирбәлә иде. Ләкин кинәт Айбиби авырту тойды, авырту йөрәгенә ук булып кадалгандай итте, әмма ул инде һични тоймады, һуштан язган иде.

Зиһене аның бик акрын ачылды, сизелер-сизелмәс кенә. Башта ул күзләрен ачмый гына янындагы кешене капшады. Йосыф кахан иде аның кырында. Һәм ул анадан тума шәрә ята, күзләрен йомган, тән-әгъзалары тәмам таралган сыман. Зиһен почмагында ниндидер шәм яна, әмма аңлашып җитми, ни булды аңа?.. Шулай буламы хатын булу? Нигә ул аңа һични әйтә алмады? Бит ул мөслимә, һич югы никах укытсыннар иде... Нигә шулай ул аңа карусыз бирелде. Белде бит ни өчен каханның бирегә алып кергәнен. Белде, әмма һичнинди каршылык күрсәтмәде. Бу ни була инде... Әнә Хәдичә үз-үзен тыя алган, никахсыз каханны үз кырына китермәгән, ә ул хан кызы Айбиби каханның наз-сөюенә чарасыз калып, һуштан язуга кадәр барып җиткән. Нигә соң әле ул булган хәлне сизми калды?! Нигә?!.

Шунда кинәт янә йөрәгенә энә белән кададылар. Булган хәл кисәк яңадан кабатланды. Айбиби янә һуштан язды. Уянып китсә, Йосыф аның битләренә суккалый.

—Уян, уян инде, Айбиби! Ни булды сиңа?!

—Мин белмим, кахан, мин бернәрсә дә белмим. Мин курыктым, мин бит сиңа никахсыз бирелдем, мин бит мөслимә?!

Айбиби кисәк капланды да үксеп-үртәлеп еларга тотынды. Кахан югалып калды, аны юатырга кереште, үзе сөйде-назлады...

Айбиби шактый вакыттан соң гына тынычланды һәм бер сүз әйтми чатыр түшәменә карап ятты.

—Мин хата кылдыммы, каханым?

—Юк, Айбиби жанкай, син хата кылмадың. Син миңа бирелдең, каханга...

—Мин моңа шатланырга тиешме?

—Әйе.

—Чөнки син минем баш хатыным. Бу сарайда сиңа беркем бер сүз әйтә алмас. Беркем, бер сүз дә, Айбиби жан!

Ул аны тагын сөя-назлый башлады, ә үзе тылсымлы сүзләр тезде. Ул аны әле Аккошлар култыгындагы аккошка, әле күлдәге төнбоек чәчкәсенә, әле күктәге айга, әле йолдызларга, әле кояшның үзенә тиңләде. Ахыр әйтеп куйды:

—Син минем бердәнберем!

—Бердәнбер кеше кырык хатын белән тормый, Йосыф кахан.

Йосыф кахан бермәлгә югалып торды, нидер әйтәсе итте, әмма әйтмәде, Айбибине рәнжетермен дип уйлады бугай.

—Син минем иң-иң яраткан хатыным, Айбиби.

Ни гажәп, кахан янә аны сөйде, назлады, үпмәгән җирен калдырмады. Айбиби кабат бөтен тәне буйлап тетрәнү үтүен тойды, назга бирелеп, аңа тартылды. Күр әле, бармаклары тигән бер җирне гүя рәхәтлек уты өтеп ала. Шушымы мәхәббәт?.. Ә Ислам?! Ислам белән ни булды соң?.. Болай ук татлы булмады ич! Ә монда кахан кагылган саен күккә аша, жаны күгәрчен кебек гөрли башлый.

Арып-алжып бертын яткач кына Айбиби аңа әйтте.

—Мин һичкем гафу итмәслек гөнаһ кылдым, каханым. Мин Мөхәммәд хан кызы.

—Шатланасы ит, Айбиби, шатланасы ит!

Шулайдыр, бик ихтимал, ул шатланырга тиештер. Ни өчен? Кахан йөрәгенә үтеп кергән өченме?.. Никахсыз! Нә уйлар, нинди бәһа бирерләр миңа фәрештәләрем...

Ә шулай ятуы рәхәт иде. Бөтен тәнендә тымызык кына уяну хисе, жаны ял итә. Уналты ел буена көткән һәм Аллаһы тарафыннан бирелгән Ана булу йөген алган тән-жан сабырланып калган иде. Хәтта яңа гына йөрәгенә ук кадаган кеше дә инде аңа ят түгел, якын, бик якын булып күренде, гәрчә каханның кырык хатыны булса да, ул аныкы булды һәм ул аңа биреле, һәм үзе теләп...

Айбиби үз йөрәк тибешен тоя, күңел түрендә челтерәп кенә чишмә ага башлаган кебек иде. Чишмә челтери, ә күңел сафлана бара. Бит ул әнә шул сафлыгын югалтты, ә күңел сафланган, агарынып, чистарынып, пакьләнеп киткән кебек. Әллә соң бәхетле мизгел дигәне дә шушымы?..

—Сизденме шуны, Айбиби, син бит мине кочагыңда кысып үтерә яздың. Мин үзем дә күккә ашкандай бер халәттә калдым, кичер. Мин сине яраттым. Инде тор, киен. Идел суында коенып чыгыйк. Мин сине тагын дәшәрмен. Жаның сүрелә төшсен, татлыны тансыклый төш. Син баш хатын ич. Мин дә, өлкән равва да шулай хәл иттек.

Менә кайчан, әнә нинди сүзләрдән соң Айбибинең күңеленә гарьләнү килде. Һәм ул тезләрен кочаклап, торып утырды, бертын як-якка селкенеп алды, үртәлде, кимсенде, әмма дәшмәде. Тик бераз шулай торгач кына:

—Миңа оят, оят, каханым. Атакайлар алдында, кырык хатының алдында син мине көпә-көндез чатырыңа күтәреп алып кердең... Шуннан соң мин аларның күзләренә ничекләр күреним?—диде.

—Сиңа оят булырга тиеш түгел, син горурлан. Бу хәл моңа кадәр бер хатыныма да тәтемәде.

—Никахсыз...

—Дин кануннарын бозмадым мин, Айбиби. Минем дәүләтем үзенә бер сәясәт белән яши. Мин Багдадка да, Румда да баш имәдем, имәячәкмен дә... Хак, мин атам төрки булса да яһүдләр диненә йөз тотам, әмма борынгы

төрки бабаларыбызның Тәңре динен дә күз угыннан ерак йөртмим, ислам динен дә чит күрмим, христианнарга да ук атканым юк. Дәүләтемдә мин аларның барысын да тигез күрәм. Дөньядагы бер дин дә адәм балалары яратып якынлык кылганны гөнаһка санамый. Ә менә һәр дин бу мәсьәләгә карата үз канунын чыгарган. Менә монысы инде зур хатадыр, Айбиби. Миңа уннарча халык ясак түли, мин ул халыклардан гаскәр җыям, шул гаскәр белән дошманнарыма яу йөрим, ил-халкымны яклыйм, аларның тыныч яшәүләрен телим. Синең Аккалага тартылуың аркасында атаң Мөхәммәд ханга мин ташлама ясадым, аны күп кенә ясаклардан азат иттем. Моны мин синең өчен эшләдем, Мөхәммәд хан кызы Айбиби, синең өчен. Мин беләм, сине Мөхәммәд хан тәрбияләп кенә үстерә, синең атаң Талиб хан. Бу хәлгә, исән булса, Талиб атаң да каршы килмәс иде. Мин тынычлык телим, мин тынычлык яратам. Һәм тәртип.

—Раввалар сиңа ярдәм итәләрме, каханым?

—Әйткәнем булыр, раввалрым сиңа ярдәм итәрләр, Айбиби хатын.

—Мин сиңа ышанам, каханым, ышанам... Мин үз нәүбәтемне һәрчак сагынып көтәрмен...

—Яраткан егетең бар идеме? Миңа җиткерделәр, синең кулыңны бөҗәнәк ханы Түрә улы Айдар сораган икән?

—Мин белмим, бик мөмкин, сорагандыр да, ләкин син, каханым, өлгеррәк булып чыктың, синең белән чәчемне бәйләдем...

Йосыф кахан бер сүз дә әйтмәде, Айбибинең битеннән үбеп алды да иңенә халатын салып, чатырдан чыгып китте.

Ул да түгел, Айбиби киенеп өлгерүгә, чатырга өч равва керде һәм өчесе дә хан кызының аягына төштеләр.

—Ни тели, Айбиби хатын?..—диделәр раввалар беравыздан.

—Мин теләгәнемне алдым инде, раввалар, юлыгызда булыгыз... Хатыннарны да алып китегез...

Бу аның беренче боерыгы иде, раввалар ни сәбәпледер, гаҗәпләнә калып булса кирәк, күзгә-күз карашып алдылар, әмма бер сүз әйтми чатырдан чыгып шылдылар. Берүзе калган Айбиби чатыр эченә күз йөртеп чыкты, ахыр хәзер генә кахан белән икәүләшеп аунаган ятакка күз ташлап алды. Күзе ятакка төшүгә, каханның үзен назлавы зиһенендә чагылып үтте. Барысы да шулай хатын булалар микән?.. Айбиби шушы ятакта нәрсәдер тапкан да, югалткан да кебек иде. Ничек булды соң әле? Кахан аны сак кына шушы ятакка китереп салды, аннары назлый-сөя башлады. Айбиби анадан тума шәрә калуын сизми дә калды. Аннары ни булды? Юк, анысын күз алдына китерәсе килми. Җанга рәхәт тулып ятканда кинәт авырту булды. Калганын Айбиби хәтерләми. Ни булды шуннан, ни кылды аның белән Йосыф кахан?.. Хәтерли алмады. Нигә карышмады ул! Бит кул-аяклары да богауда түгел иде...

Шаккатмалы хәл.

Ләкин булганы булган иде инде. Ул көн эчендә хатын булды.

Айбиби бер тын чатыр эчендә басып торды да, япманы ачып, тышка карады. Нә су буенда, нә комлыкта бер кеше дә юк иде, бары тик аккошлар саллы гына арлы-бирле йөзәләр. Матурлар, горурлар, башларын югары тоталар. Айбиби чатырдан чыкты да су буена таба китте, барыр җайдан чүәген салып атты һәм килер җайдан ук чишенә башлап, салган әйберләрен ташлый-ташлый суга җитте, кереп үк китте. Аңа рәхәт-рәхәт булып талгын җил чыгарган дулкын килеп орылды, дулкын аны гүя үзенә дәште, Айбиби колачларын киң җәеп, йөзеп китте. Аккошлар аңа карап туктап калдылар. Менә шунда аръяктагы камышлык кырында Айбиби ялгыз аккошны күрде. Айбибине күрүгә, аккош каңгылдап куйгандай аваз чыгарды һәм күптәнге танышын күргәндәй, аңа таба йөзеп килә башлады. Килеп җитәрәк тәпиләренә басты, канатларын киң җәеп, җилпенеп алды. Айбиби белән уйнарга теләгәндәй чумды һәм аңа таба су астыннан йөзеп китте. Ләкин нидәндер курка калды, кире су кырына таба борылды. Яр кырына җитәрәк Айбиби судан чыкты, башын чайкап, әйләнеп аккош калган якка карады. Аккош аның янәшәсендә иде. Ул канат-

ларын жәеп, Айбибине кочагына алгандай итте дә кинәнә-кинәнә су өстендә биергә кереште. Аның бу кыланышына йөзләрчә аккошлар карап тордылар, ә беришләре, берни булмаган кебек, су төбеннән жим эзләделәр.

Аккош ана килеп сыенуга, Айбиби коты алынып, судан йөгереп чыкты һәм рәхәтләнеп үзеннән-үзе көлә башлады. Аккоштан курыкты ич, аккоштан, үзенең иң яраткан кошыннан!..

Көлә-көлә киенде, ә аккош һаман су өстендә бии, әле әйләнеп килә, әле каңгылдап куя. Өс-башын киде, чуәкләрен эзләп тапты һәм шунда ана рәхәт булып китте, әйтерсең, барысын да Идел суы юган иде, кылган гөнаһын да, мәхәббәтен дә (кемгә икәнен ачыкламады), гүя ул сафланып, пакьләнеп калган иде. Һәрхәлдә, Айбибинең күнелендә шундый хис туды. Чатырны узып, сарайга таба юнәлгән генә иде, аңа каршы өлкән равванын килүен күрде. Бу кешенең йөзе таныш иде инде аңа. Шып туктады, котеп алды. Өлкән равванын баш түбәсендә ак төстәге чәпләшкә, өстендә юка жилән, аягында болгари итек, кулында сырлап ясалган чукмарбашлы таяк. Табак битле, кирәкмәгән зур бөкре борынлы өлкән равваны Айбиби, эндәшми генә узып китмәкче иткән иде, рухани аның юлына таягын куйды.

—Биби хатын, сезне аш кырында кахан көтә.

—Минем исемем Айбиби, өлкән равва.

—Әйе, Айбиби хатын, сезне кахан көтә,—дип кабатлады өлкән равва һәм юл өстеннән таягын алып, ана юл бирде, ә үзе Айбиби белән янәшә атлап китте.

Өлкән равва сөйләде дә сөйләде, Айбиби аны тынлаган саен хәйран кала барды. Бу ни хәл инде, яна сарай йортына аяк баскан хатынга өлкән равва дәүләт серләрен сөйли. Айбиби, әлбәттә, күп нәрсәне аңламады, әмма аңлагандай ияк каккалап барды. Бит ул каханның баш хатыны!

—Айбиби хатын, мина кахан житкерде, синең ике якын кешең Ханбалыкта калган икән.

Дөньяви сәясәттән кинәт кенә табигый тормыш хәлләренә күчкән өлкән равваны Айбиби янә аңламады. Әмма бу хәл аның үзенә кагылганга, колаклары торды, хәтта өлкән равванын каршына чыкты.

—Кахан мина алар бер айдан соң гына сарайга үтә алалар дигән иде, мина алар бүген үк кирәк, бүген, өлкән равва.

—Кахан әйткән икән, бер айдан ул кешеләрең сарайда булырлар, Айбиби хатын, бер дә борчылмагыз. Кахан әйткән сүзендә тора торган кеше. Менә без килеп тә життек,—диде өлкән равва һәм Айбибинең терсәгеннән алып, ишектә торган сакчыларга ым какты.

—Мин бу киемнән кахан янына үтә алмамдыр, өлкән равва.

— Кахан сезне көтә, әйдәгез, алдан узыгыз...

***

Йосыф кахан Айбибине ишеккә каршы килеп алды һәм очрашуда утырган кечкенә өстәл янына утыртты, көмеш кыңгыравын зенләтте. Бавырчысы керде.

—Аш-суны минем ятагыма хәстәрлә,—диде аңа кахан. Бавырчы баш иеп чыгып киткәч, Йосыф кахан ике терсәген өстәлгә терәде дә, ияген учларына салып Айбибигә:

—Баш хатын буларак, мин сине, Айбиби каханбикә, туп-туры ятагыма алып керермен. Гажәпләнмә, күрәм ич, күзләреңне зурайттың. Берсекөннән дә калмый мин яу ук булмаса да, шул максат белән Киялигә таба кузгалам. Ләкин каханбәгем мина башта Византия жирләренә таба кузгалыйк дигән киңәш бирде. Мин килештем. Византия императоры Сарманай кенәзне Дунай кардәшләребез өстенә яу кузгаткан. Әүвәл без шул якка кузгалырга булдык. Тик син, Айбиби жан, үпкәләмәсәң иде, каханбәк Сабир әүвәл Византиянең үзенә яу йөрик, ди. Мин килештем. Шул ук вакытта мин хәл итәргә тиешмен—син минем белән юлга чыгасыңмы, биредә каласыңмы?

—Биредә калам, каханым.

—Мин аны шулай дип уйлаган идем дә, Айбиби җан,—диде Йосыф кахан, торып, Айбибинең кулыннан алды да ятак ягына таба алып китте.

## VII

Айбиби үз дигәнен эшләтте—Рәшидә абыстай белән табибә йөзендә Исламны сарайга уздыруга иреште. Хак, ул табиб Исламга хатын-кызлар киемендә узарсың дигән шарт куйды. Моны ничек аңлагандыр Ислам, әмма аңа ирештерделәр, иртәгәдән дә калмый абыстай белән табибә сарайда булачаклар. Бу хакта өлкән равва хәбәрдар идеме, юкмы, Айбиби белмәде, иң мөһиме, үзе теләгән ике кешесе иртәгәдән дә калмый аның кырында булачаклар иде.

Төшке ашны ашап, бүлмәләренә таралгач, Айбиби кырына Хәдичә хатын килеп керде. Рөхсәт сорады, бүлмәгә уздыргач, Айбиби аңа түрдән узып, утырырга урын күрсәтте.

—Нә йомыш-йөк китерде инде Хәдичә хатынны?—диде Айбиби көлемсери төшә.

—Мин, баш хатын Айбиби, сарайдан качарга булдым. Һәм син, баш хатын Айбиби, мөслимә буларак, миңа бу гамәлемдә ярдәм итәрсең.

Айбиби моны һич тә көтмәгән иде, торып, йөреп килде, Хәдичә хатынга якынрак урындыкка утырды.

—Ни өчен мин сиңа ярдәм итәргә тиеш, Хәдичә хатын? Ни өчен, чөнки үзең дә беләсең кахан белән өлкән равва моның өчен минем башымнан сыйпамаячаклар...

—Син мөслимә, мин дә мөслимә, Аллаһы да әйткән мөслимәләр бербереннә ярдәм итәргә тиешләр.

Айбиби һични анламый, бер тын тәрәзәгә карап торды. Тәрәзәдән зәңгәр күк йөзе күренә, ә анда ялгыз болыт кисәге йөзә. Ул аңлый иде, мөслимә Хәдичә каханның хатыны булудан баш тарткан, әле булса кыз булып йөри, ә Айбиби алай итә алмады, ул кахан алдында ихтыяр көчен югалтып, аныкы булды. Гөнаһ кылды. Ләкин бу гөнаһмы? Бит ул каханны яратты, аның куенында үзен оҗмах кошы итеп хис итте. Ә монда ком сахрасыннан китерелгән мөслимә кыз каханның кочагыннан баш тартып кына калмый, җитмәсә, Аккаладан качарга җыена, һәм аңа, мөслимә буларак, Айбиби ярдәм итәргә тиеш. Тик ничек ? Әйе, теләге булганда да ничек качыра ала ул аны?..

—Аккаладан качу мөмкин хәлме, Хәдичә хатын?

—Бик теләсәң мөмкин хәл, мөслимә Айбиби.

—Хәдичә хатын, иртәгә минем кырыма минем табибым керәчәк...

Шулай диде дә Айбиби соңгы сүзеннән курка калды. Шуннан ни, Ислам ничек качарга ярдәм итә алыр Хәдичә хатынга сарайдан?..

Бит алардан хәрам аталар күз дә алмыйлар.

—Мин биредә бүтән кала алмыйм, баш хатын Айбиби. Тиздән Хазарстанга угызлар ябырылачак, алар болай да инде каханның җәйләүләрен минлекләделәр. Ә кахан чарасыз, һични кыла алмый. Өлкән равва аңа Харәзем әмиренә мөрәҗәгать итәргә кушкан. Кахан икеләнә икән. Менә шунда син ярдәмгә килергә тиешсең, Айбиби хатын. Харәзем әмире Йосыф каханга шарт куйган—Ислам динен кабул ит, дигән. Ә кахан икеләнә икән. Чөнки кахан Ислам динен кабул иткән хәлдә Харәзем әмире шундук Аккалага имамнарын җибәрәчәк, диде миңа бу сүзләрне җиткергән ышанычлы кеше.

—Хәдичә хатын, мин сиңа бүген һични әйтә алмыйм. Син мине тәмам чарасыз иттең. Ул табибә минем туган илемдә чакта ук яраткан егетем иде. Ләкин мин аны каханны яраткан кебек ярата алмадым, ул минем яшьлектәге җиһаннан төшеп сүнгән йолдызым гына булып калды. Аның егет икәнен белсә, кахан беребезне дә кичермәс. Икебезне бер көймәгә бәйләп, Идел буенча агызып җибәрер. Болай да инде мин аны алдадым, табибәгә күренәсем бар дип, сарайга керергә рөхсәт алдым. Ахыры ни белән бетәр, бер

Ходай үзе белә. Мин язмышым белән уйныйм ич, Хәдичә хатын, язмышым белән. Мин кичәле-бүгенле генә сиздем, каханнан балага уздым бугай. Инде шул халәтемдә шушындый ялганга барыйммы, Хәдичә хатын?!

Айбиби ике кулы белән йөзен каплады, бертын дәшми торды, Хәдичә хатын да баш хатыннан моны көтмәгән иде бугай, ни әйтергә белми, каушый калды, Айбибинең алдына тезләнде, башын аның тезләренә салды һәм шыңшып елап җибәрде.

—Мин сабыр итәрмен, Айбиби, сабыр итәрмен. Мин качмам, ишетәсеңме, качмам. Кичер мине, Айбиби, кичер, мин сине каханга шул чиккә җитеп гашыйк булырсың дип уйламаган идем, кичер... Мин сабыр итәрмен, сабыр итәрмен...

***

Илчеләре сөйләшүләр алып барса да ел коры килү сәбәпле, угызлар мал-туар көтүләре белән генә түгел, үзләре дә Хазарстан җирләренә үтеп керделәр, хәтта кайбер калаларны туздырдылар. Чарасыз калган Йосыф кахан Харәземгә илче йөзендә өлкән равванын үзен җибәрде. Китәр алдыннан ул аңа кырт кисеп әйтте:

—Бу сәяси чара, иң әүвәл син әмир имамнары алдында ук Ислам динен кабул ит. Һәм катгый рәвештә әйт: кахан да имамнарың сарайга килү белән Ислам динен кабул итәчәк.

Ни гаҗәп, күпне күргән өлкән равва каханның бу сүзләренә бер дә гаҗәпләнмәде, башын иеп тынлап торды, ахыр: "Дин кабул итү әҗәл алу түгел, кабул итәрмен,—диде. Һәм өстәде:—Вакытлыча булса да. Минем күңелемдә һәрчак бабаларыбызның тәүге Яхвасы калыр..."

Йосыф кахан өлкән раввасын хуплагандай үз итеп елмайды, әмма аның йөзендә елмаю галәмәте күрмәде.

Өлкән равва чыгып киткәч, Йосыф кахан һични күрмәс күзләре белән бер ноктага карап утырды. Хата кылмадымы ул, ялгышмадымы? Бит ул өлкән равва кадәр өлкән раввасын күптән инде Ислам динен кабул иткән Харәзем әмиренә җибәрде. Шул ук вакытта ышана иде, илчелектә азау теше чыккан өлкән раввасы аның теләгән җиренә җиткереп үтәп кайтыр. Шуның өчен аңа тынычланып яуга чыгып китәргә дә була. Ул тарихны яхшы белә иде, яһүдләр беркайчан да үзләренең диннәрен теге йә бу халыкка көчләп такмаганнар. Мондый хилафлыкка беренче тапкыр христиан динен байрак итеп алган Сирия греклары һәм Рим куштаннары керешә. Хак, аларны империянең императорлары кабул итми. Башта, гаҗәп, христиан динен империя тарафыннан гасырлар буена рәнҗетелгән, җәберләнгән гади халык кабул итә. Ә гарәпләр исә, үз диннәрен башка халыкларга тарату өчен, соңрак, кылычка ябышалар. Бит тарихта билгеле—гарәпләрнең сәргаскәрләре Мәрван белән Маслама Хазарстан төбәкләрендә көн күргән халыкларны канга батыралар, каханнарны бу дингә табынырга мәҗбүр итәләр һәм янә кылыч белән. Хазарстан гарәпләр тарафыннан яулана. Биләмҗир халкы тәмам кырыла—кылычтан уздырыла. Сулак елгасына гарәп сәргаскәре тарафыннан меңнәрчә бер гаепсез кешеләр батырылып үтерелә. Мәетләрдән елга буыла, ярларына чыга. Моны хәтта күз алдына китерүе дә кыен. Ә бит сәргаскәр изге диннәрнең берсенә табынган кеше—мөселман була. Мөгаен, Коръәнне дә укыган булгандыр ул сәргаскәр. Ә бит Коръәндә: "...адәми зат ярамаган гамәл кылса, гөнаһның иң яман җәзасына тартылыр", диелгән. Бер гаепсез бала-чагаларны, карт-корыларны вә хатын-кызларны типсә тимер өзәрдәй егетләрчә батырып үтерергә нинди йөз белән боердылар икән? Гарәп сәргаскәре тарафыннан кылынган үтә яман гамәл ич бу. Шушы яудан соң Биләмҗир төбәкләре, Кавтау тирәләре тәмам бушап кала. Моның белән генә тынычланмыйлар: гарәп сәргаскәрләре бушап калган төбәкләргә Сирия тарафларыннан егерме дүрт мең гаиләне күчереп утырталар. Төрле телдә сөйләшкән кавемнәрне. Шушы яман хәлләрне Йосыф кахан беркайчан да онытмады. Инде шул

чорларда кылыч аша Ислам динен кабул иткән харәземлеләр—безнең кан-кардәшләребез, без хазарлыларны Ислам диненә күчәргә мәҗбүр итәләр. Нинди бәһа бирергә тиеш бу хәлгә Хазарстан илбашы. Кая безнең бабаларыбыз көнкүргән Ярыксу, Акташ кебек калалар? Кем аларны җир белән тигезләп китә?.. Шул ук гарәп сәргаскәрләре түгелме?!

Тәхет ягыннан тәмам кәефе кырылып чыкты Йосыф кахан. Һәм кырына Айбиби хатынны китерергә кушты. Баш хатын атын йөрткән Айбиби килеп кергәч, ул аны ишек төбеннән үк каршы алды. Хатын килеп елышуга, тәхет ягына үтеп, өстәл янына утыртты.

—Утыр әле яннарыма, Айбиби җан. Минем синең белән киңәшәсем килә. Син—мөслимә. Миңа да шул динне кабул итәргә туры килер сыман.

—Мин синең кырыңа сине Ислам диненә өндәргә дип тартылмаганмындыр, шәт, Йосыфҗан?..

—Юк, юк, Айбиби. Минем каламда мәчетләр дә, чиркәүләр дә, синогогалар да бар.

—Мин сиңа бу хакта киңәш бирә алмыйм, Йосыфҗан.

—Миңа синең киңәшең кирәкми, Айбиби, миңа синең җаның-тәнең, моңсу күзләрең кирәк.Синең кочагыңда мин юаныч табам, дөньямны онытып торам. Бу да ир-ат өчен зур бәхет.

—Нигә соң сиңа, бәгырь, кырык хатын?..

—Бу гадәт яһүдләрдән килә, Сөләйман пәйгамбәр заманнарыннан ук, Айбиби.

—Син, Йосыфҗан, үз кырыңда ятагыңа бер тапкыр да тарттырмаган хатыннарны да тотасың ич?

—Кемне?

—Әйтик, Хәдичәне. Ә аның илендә сөйгән егете калгандыр...

—Аккошлар гына аерылышкач моң-зарга калалар. Яраткан егетеннән аермадым мин аны, иясе биреп җибәрде һәм яман максат белән, мине мөселман итәргә. Динне мин, Айбиби, үзем теләп кабул итәргә тиешмен. Мин кабул иткән дин, минем калебемә тәңгәл килергә, җан-тәнемә зыян китермәскә тиеш. Хәдичәне иленә кайтарып җибәрү минем дошманнарымны гына арттырыр иде. Хак, минем аны сатып җибәрергә дә хакым бар, ләкин минем моңа барасым килми. Аккошларымны сата алмаган кебек, мин хатыннарымны сата алмыйм, әйе, гәрчә моңа хакым булса да. Мин бүген Харәземгә киткән өлкән раввамны көтәм. Чөнки Сарманай кенәзне акылга утырту өчен әүвәл мин угызлар белән килешү төзергә тиеш. Угызлар Харәзем әмиренә бәйле халык, гәрчә тегеләре әлегә мәҗүсиләр булсалар да. Аннары угызлар бик борынгы заманнардан бирле Идел буе болгарлары белән теләктәшлектә гомер итәләр, Болгар ханнары угызларга кызларын бирәләр, үзләре төрки болгар кызларына өйләнәләр.

—Кем ул Сарманай димим, чөнки Кияли каласы түрәсе икәнен беләм. Нигә син аның өстенә яу белән кузгаласың соң, Йосыфҗан?

—Яратмыйм мин ул сатлык җанны. Ул Византия императорына ялланып, безнең кардәшләребез Дунай буе болгарларына яу йөрде, ил-халыкны талап кайтты. Хәзер янә шул тарафларга яу кузгалырга җыенып ята икән. Мин моңа чик куярга булдым. Бит ул минем ясакчым...

—Кичер мине, Йосыфҗан, зинһар кичерә күр. Бит мин иң әүвәл синең турыңда кайгыртам, исән булсаң иде, ил-халкың саклап, дәүләтең камил яшәтсәң иде дим...

—Абыстаең белән табибәнне күрдеңме соң әле?—дип сорагач, Айбиби кинәттән эсселе-суыклы булып китте. Ни әйтә ала иде ул аңа? Һични!

—Аккошлар култыгындагы агачларга һәрчак каракош төшә, Йосыфҗан. Куркам мин алардан.

Айбиби шулай диюгә, Йосыф кахан аның күзләренә карады һәм елмаеп куйды.

—Курыкма, Айбиби җан, каракошлар аккошларның түшләрен ярмаслар, аларны минем мәргәннәрем саклый. Алар махсус ясалган шалашларда

каракошларны күзәтәләр, әгәр дә мәгәр каракошлар аккошларга ташлана икән, аларны шундук уктан алачаклар.

—Ул мәргәннәр су коенган хатыннарны да күрәләрме?

—Юк, аларның хатыннарга карарга хаклары юк, рөхсәт ителми. Каракошлар түгел, безне бүген христианнар белән мөселманнар йотарга торалар, Айбиби җан. Әлегә кадәр мин ике диннең берсен кабул итмәдем. Әйе, әлегә кадәр, вә ләкин миңа хәзер Ислам динен кабул итми хәл юк. Чарасыз калдым мин, Айбиби, чарасыз...

Айбиби дәшмәде, ул әкрен генә торды да каханны ятакка таба алып китте. Каханның кулы салкын иде. Ләкин ул белә, кахан ятакта кайнар йөрәкле. Һәм ярата-назлый вә сөя белүе белән Айбибине дә үзенеке итте. Мәңгегә!.. Һәрхәлдә каханны кулыннан тотып, ятакка таба барганда шулай дип уйлады Айбиби.

...Иртәнге якта хәрам аталар Айбибине кахан ятагыннан алырга килделәр. Өстенә киеп, көзгегә карап йөзен хушбуй белән югач, Айбиби әле булса иренеп яткан кахан янына килде һәм ир-канатның кулын кысты. Ятак бусагасын атлап чыгуга, хәрам атаның берсе аңа хәбәр ирештерде.

—Сине, баш хатын, бүлмәңдә ике кеше көтә,—диде.

Айбиби чак кына:

"Рәшидә абыстай белән Ислам табиб!"—дип, кычкырып җибәрмәде, кычкырды да кебек, ләкин аның хатасын янәшә атлаган хәрам атакай төзәтте.

—Исламия табибә, Айбиби хатын, Исламия табибә.

Эчке авазын хәрам атакай авызыннан ишетүгә коты алынган Айбиби кисәк туктап калды, хәрам атакайларның күзләренә карады, ләкин аларның берсе: "Исламия табибә, Айбиби хатын, Исламия табибә",—дигәч кенә тынычлана төште һәм адымын дәвам итте.

—Әллә соң ул-бу булдымы, Айбиби хатын?—дип сорады атакайның берсе.

—Ю-юк, атакай, берни дә булмады, әллә нигә эчем...

—Була торган хәл,—диде шул ук атакай.—Була торган хәл, балакай. Йоккә уздынмы әллә?

—Юктыр, юк бугай,—диде Айбиби тәмам курка калып.—Ә йоккә узган булсам ни?

—Берни дә юк, Айбиби хатын. Йоккә узуга, кахан сезне ятагына тарттырмый башлар, бары тик.

Ул арада аның каршында җир астыннан чыккандай Рәшидә абыстай белән Исламия табибә пәйда булды. Айбиби Рәшидә абыстайның кочагына ташланды һәм күз яше белән елап җибәрде. Рәшидә абыстай хәрам атакайларга: "Китегез!" дип кул ишарәсе ясады. Атакайлар киткәч һәм бераз тынычлана төшкәч кенә, Айбиби күзләрен яулык очына сөртеп, "Исламия табибәгә» күз ташлады, ләкин кочагына иңмәде, бары тик күрешергә кулын гына сузды.

—Исәнме, сарай табибы улы Ислам!—диде.

Тагын әллә ниләр әйтергә дип авызын ачты, әмма сүз таба алмады, теле гүя аңкавына ябышкан иде. Чөнки күңеленә үтә сәер тойгы тулды—Ислам мәхәббәт кахан янында тәгаен үсмер малай булып кына калган иде һәм шулай да түгелме соң?..

Айбиби аңа елмайды, әмма янә бер сүз дә әйтә алмады. Борылды да, Рәшидә абыстайның кулыннан алып, бүлмәсенә таба алып китте, һәм барыр җайда ук: "Абыстаем-анакаем, мин аны яраттым",—диде.

—Кемне?—дип сорады гаҗәпләнә төшеп Рәшидә абыстай.

Айбиби җавап бирмәде, бүлмәсенең ишеген ачты һәм аларны бүлмәсенә алып керде. Утырыштылар. Дога кылдылар.

—Сине күрер көн дә булыр икән, балакай,—диде Рәшидә абыстай.

—Кем уздырды сезне, танымадылармы?—диде Айбиби һәм кызарынып утырган Исламга күз төшереп алды. Моны күреп, Рәшидә абыстай:

—Оялды инде, оялды, ләкин нишләсен, башка чара калмагач килеште инде,—диде.

—Кахан белсә?! Кахан белсә, абыстаем?!—диде Айбиби курка калып. Хәер, ул бу хәлгә күптән курка башлаган иде инде. Хәзер исә тәмам аркалары өшеп киткәндәй булды.

—Исламия,—диде Рәшидә абыстай Айбибинең каушый калуын күреп.— Исламия дим, син чыгып тор әле булмаса. Минем Айбибигә әйтәсе сүзләрем бар.

—Ярый соң,—диде Ислам һәм килешсез генә, бер дә хатын-кызларга хас булмаган адымнар белән ишеккә юнәлде. Бүлмәдә калган хатын-кызлар, ишек ябылуга елмаешып алдылар һәм хәтта прых-прых көлешә башладылар.

—Йә-йә, балакай, ничекләр булды соң? Кахан белән дим? Әллә соң чынлап та яраттыңмы үзен?..

—Яраттым, абыстаем-анакаем, яраттым. Миңа хәзер беркем дә кирәкми.

—Һәй, балакай, каханның кырык хатыны бит, синнән башка кырык хатыны!

—Кырык түгел, утыз тугыз гына.

—Нигә алай дисең?

—Хәдичә атлы хатын бер тапкыр да кахан ятагында булмаган, кыз көйгә йөри.

—Ни өчен?

—Кахан Хәдичә кызның шарты белән килешмәгән.

—Нинди шарты белән?

—Ислам динен кабул итмәгән.

—Игелекле бала, димәк.

—Мин игелексезме, абыстаем?

—Син дә игелекле. Чөнки син ихлас күңелдән яратып ятkансың кахан кырына, ә ул каханны яратмаган.

—Мин аны нигәдер яраттым, абыстаем, яраттым. Елга култыгындагы аккош та мине яратты. Аның аккошы ул. Ялгыз калган, ишен үтергәннәр, каракош алган диме...

—Бу ни инде тагын, балакай, нинди аккош та, нинди каракош тагын?..

—Кахан аккошлар ярата, аларны күз карасыдай саклый, хатыннарыннан җим салдыра. Аккошлар арасында парлылары бар, ялгызларын да очратырга була. Бер ялгыз аккош миңа гашыйк булды, анакаем.

—Мин синең анакаең түгел, балам.

—Син мине тәрбияләп үстердең, син мине кеше иттең, миңа белем бирдең, миңа телләр өйрәттең. Аккошларның берсе—ялгызагы мине кочаклады хәтта.

—Сине аккош кочаклады?!—дип гаҗәпләнде Рәшидә абыстай, һәм ни әйтергә белми, чынмы, юриме сөйли дип булса кирәк, күзләренә карады.— Балакай, чын булса да моны кешегә сөйләмә, яме! Сөйләмәссеңме?! Кырык хатын арасында яман ниятлеләре дә бардыр, тилемсерәде баш хатын дип сөйләп йөрүчеләре дә табылыр. Аккошларыңны ашат, кинәндер үзләрен, вә ләкин, балакай, кешегә сөйли күрмә. Ишек артындагы Исламны оныттыңдамыни соң?! Ул синең өчен көннәр буена ут йота, теленнән синең исемең төшми.

—Мин инде бөтенләй башка кеше, абыстаем. Ислам яшьлегемдәге якты бер матур хатирә генә булып калыр. Хәзер мин бөтен отырым белән Йосыф каханга гашыйк. Беләсеңме, анакаем, мин аны Хәдичә хатын белән таныштырам. Бүген үк. Чибәр хатын, мөслимә, саф җанлы. Мин аны Хәдичә хатын бүлмәсенә илтеп калдырырмын да табиб дип таныштырырмын.

—Һай Аллам, балакай, мөмкин хәлме бу. Ул бичара егет сине күрер өчен хатын-кыз киемендә сарайга үтте. Белсәләр, аның башын кисәчәкләр, шул ук хәрам атакайларың. Кахан бу эштә синең дә катнашуыңны белсә нә кылыр?..

—Мине ул гаять зур бәһагә сатып җибәрер, анакаем.

—Ай-һай балакай, сатып торырмы икән ул сине, жаныңны шундук җәһәннәмгә олактырмасмы?!

—Ахыр чиктә ул мине зинданга ташлатыр, анакай.

Айбиби шулай диюгә, ни сәбәпледер икесе дә тынып калдылар, әйтерсең лә кахан аларның мәкерләрен белеп алган иде инде. Рәшидә абыстай бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Бүлмә ялгыз хатынга исәпләнгән, барысын да искә алып җиһазланган иде. Бүлмә зур түгел, түр якта киң генә тахта, тәрәзә каршында тез биеклек кенә өстәл, аның янында ике кечкенә урындык. Урындыклар зәңгәр бәрхет белән тышланган, читләре җофар тиресе белән каелган. Ятакта да җофар юрган, мендәр аккош сурәте төшерелгән тукымадан, ишекъяры җиз ләгән һәм кечкенә җиз комган, шунда ук болан мөгезенә эленгән фарсылар сөлгесе. Ишек эчке яктан шудыргыч белән бикләнә. Каханның хатыннарын хәрам атакайлар саклый, сарайдагы тәртипләрне раввалар күзәтә. Аккошлар култыгыннан кайтканда хатыннарга хәрам атакайлар гына түгел, кайбер көннәрдә раввалар да күз-колак булалар икән. Бу хакта аңа кала сакчысы Булат бәк сөйләгән иде инде. Сарайга үтәргә дә ярдәм итте. Исламның кем булуын белә торып, сарайга уздырды. Ә бит Исламның ир-егет икәне ачылганда кахан аның да башыннан сыйпамаячак. Чөнки бередә барысы да хаким Йосыф кулында, кинәт кенә гашыйк булган Айбибинең ир затында.

Шул мәлдә Айбиби сыдырылып идәнгә төште дә Рәшидә абыстайның тезләреннән кочаклады.

—Анам-абыстаем, мин сине шундаен юксындым, шундаен юксындым!

Рәшидә абыстай аның башына кулын куйды, бермәлгә моңсу бер карашы белән тәрәзәгә карап торды. Шул мәлдә тәрәзә каршыннан бер адәми зат узды, Рәшидә абыстай сискәнеп китте һәм, торып, Айбибине аягына бастырды.

—Утыр әле янәшәмә, балакаем, утыр. Син бу гамәлен белән үзенә генә түгел, атаңа да зыян китерүең бар. Кахан угызлардан курыкса да, аларны төп дошманнары итеп күрми. Әтрәк кавемендәге угызлар әле булса мәҗүсиләр ич. Ислам дине нинди йөздә булса да бире таба узса, Исламның кем икәнен раввалар белсәләр кахан беребезне дә кичермәс. Инде "табибәнең" чын йөзе ачылган хәлдә... хәтта әйтергә дә куркам. Әнә тәрәзә каршында кемдер үтеп-сүтеп йөри башлады да инде. Ул Хәдичә дигән хатын сине сатмасмы соң?.. Син, балакай, очар кошлар кебек фикер йөртәсең. Кошлар һавада оча, ә без синең белән җир адәмнәре, безне бик тиз тотарлар.

—Кошлар да безнең кебек җан ияләре, анам.

Рәшидә абыстай янә бер Айбибинең күзләренә карады, шикләнеп-сагая калып, имеш, син, балакай, барысын да ихластан сөйлисеңме? Айбибинең күзләрендә чаткылар биешә иде. Һәрхәлдә Рәшидә абыстайга шулайрак тоелды. Әнә шунда абыстайның кинәт хәтер йомгагы сүтелеп китте һәм яшьлеге күз алдына килеп басты. Әйе, аның да дивана хәленә җитеп гашыйк булган чаклары бар иде. Әле булса хәтерендә, Талиб ханга гашыйк булды ул. Һәй яратты да соң хан аны, хатыны итеп түгел, сөяркәсе итеп. Рәшидә дә һич ятсынмый һәм курыкмый аңа тартылды. Хан ич ул, кыю, тәкәббер, мәһабәт олуг хан иде. Рәшидәне кочагына индерер иде дә, артык хәрәкәт ясаудан куркып, тынып калыр иде, әйтерсең лә бер-бер сүз әйтсә, йә булмаса хәрәкәтләнсә, нидер җимерелер, йә булмаса елганың буасы ташар кебек иде. Унҗиде яшенә яңа аяк баскан Рәшидә олуг ирнең тән исен һуштан язар хәлгә килеп иснәр иде дә тынып калыр иде. Талиб хан һәрчак йөрәгенә зарланды, шуңамы, Рәшидә аның кочагына инүгә, кымшанырга да куркып торыр иде. Һәм Аллаһудан сорар иде: бир аңа куәт, бир көч, яшәсен ул, яшәсен, ил-халык хакына, ахыр килеп, минем хакка... Шуннан Рәшидәнең, яшь кызның ни теләгәнен белгәндәй: "Синең янда, Рәшидәкәй, минем йөрәгем дә тынычланып китә",—дияр иде. Йөрәге авыру Талиб хан өченче хатыны итеп, аңа өйләнергә дә теләде, әмма Рәшидә моңа үзе риза булмады. Ул болай да бәхетле иде, болай да кануни хатыннардан да бәхетлерәк иде. Аны ул тәгаен яратып сөйде, назлады... Талиб

хан аны вафаты көненә кадәр яшь хатыным минем дип йөрде. Алай гынамы, табибәм дип әйтер иде. Чөнки горур хан Рәшидә белән булганда ичмасам бер тапкыр да йөрәгенә зарланмады. Халык аны "Гали" хан дияр иде, ә Рәшидә аны күктән төшкән фәрештә булмаса да пәйгамбәрләргә тиңләде. Рәшидә сарайда балаларга сабак бирде, ә Айбибине исә бишектә чакта ук үз баласыдай карады. Онытa алмый ул көнне, онытырлык булдымы—Талиб хан йөрәк өянәге тотып вафат булды дип килеп әйткәч, кадалакаплана сарайга йөгерде, ләкин аны сарай имамы вафат булган Талиб хан кырына уздырмады. Рәшидә ике кулы белән йөзен каплады да үксеп-үртәлеп елап җибәрде. Моңа берсенең дә исе китмәде, чөнки сарай гына түгел, халык ил белән елаган иде ул көнне.

Айбибине кочагында тотканда Рәшидә абыстайның күз алдыннан әнә шундый хатирәләр узды, һәм ул үзалдына уфтанып куйды. Ә бит шул чакта ханның кануни хатыннары аның мәете янында иделәр. Ул хан үтенеченә каршы килмичә, мулладан никах укытып кияүгә чыккан булса, имам аны мәрхүм янына уздырган да булыр иде, Рәшидә яраткан затының һич югы нурлы йөзен күреп калган булыр иде. Әйе, аның шушы ир-заты белән үләргә дә риза булуы хак иде, үләргә дә, борынгы төрки хатыннары кебек... Әнә шундаен чикләргә җитеп яратты ул Талиб ханны, әле кочагында тоткан Айбиби баланың әтисен. Тик менә үз кызыдай карап үстергән баланың кырык хатыны булган ир түрәсенә гашыйк булуын, үзе үк: "Мин аны яраттым",—дип әйтүен ни дип юрарга да белмәде. Ә бит син, балакай, кырык яшьлек каханның кырык хатыны арасында кырык чуерташ арасында җемелдәп яткан зөбәрҗәттәй, гүзәлсең, акыллысың. Тинең, язганың, минемчә, балакай, кырык яшен тутырып яткан Йосыф кахан түгел, ә сарай табибы улы Ислам. Тик бу хакта мин сиңа әйтмәм, хакым юк, чөнки мин үзем дә синең атаңа исәрләнер дәрәҗәгә җитеп гашыйк булган идем. Һәм мин аңа никахсыз бирелдем, хәтта Аллаһым алдында үземне гөнаһлы санамадым, чөнки мин аны бөтен йөрәгем-җаным белән яраткан идем. Әйе, минем бу балакайның язмышы белән уйнарга хакым юк.

Укымышлы кеше буларак, Рәшидә абыстай белә иде—кеше язмышы туа-туганнан бирле фәрештәләр кулында гына түгел, иблисләр кулында да. Моның янына Аллаһы аңа аң-белем алырга мөмкинлек биргән. Рәшидә абыстай бик яхшы белә иде—тулы канлы мәхәббәт килгәндә акыл вә аң икенче урынга күчә, иң алга хис ташкыны чыга, ә ул моны үз башыннан кичерде, саф мәхәббәт барысыннан да куәтлерәк, көчлерәк икән.

—Узыйк булмаса, анакаем, Хәдичә янына. Ул мине көтмидер, ләкин ул мине кабул итәр. Без ахирәтләр. Исламны да алырбыз. Таныштырыйк та без аларны үзләрен генә калдырыйк.

—Килешерме соң бу гамәл,—диде Рәшидә абыстай.—Исламның синнән башка берәүне дә күрәсе килми. Һәрхәлдә мин аның тел төбеннән шуны аңладым.

Алар бүлмәдән чыгып, Ислам утырган эскәмия янына уздылар. Рәшидә абыстай егет янына—хатын-кыз киемендә булган Ислам янәшәсенә утырды. Дога кылдылар. Гәрчә яһүдләр сараенда булсалар да мөслимәләр ич. Хәдичә хатын бүлмәсенә уздылар. Янә дога кылдылар. Сөйләшә башладылар, бер-берсенә карый-карый серләрен уртаклаштылар. Айбиби көмеш кыңгыравын зеңләтте, хәрам атакай килеп керүгә, табын хәстәрләргә, җиләк-җимеш китерергә кушты. Чәй янында Рәшидә абыстай юк-юк та Хәдичә хатынга карап-карап алды. Өлгергән алмалар, хөрмәләр, күл тутырып, җәйрәп чәчәк аткан төнбоеклар була, ләкин бу хатын кебек монсу йөзне күргәне юк кебек иде аның. Ирләр кочагын тансыклап, сөю-мәхәббәттән мәхрүм ителгән хатын кебек күренде Рәшидә абыстайга ком сахраларыннан Хазарстанга китерелгән кыз бала. Ул дине вә иманы аркасында барысыннан да ваз кичә һәм хәтта кахан кочагыннан да. Бу мөслимә хатында ихтыяр көче шулхәтле көчле, күрәсең, яһүд кешесе астына ятмас өчен кахан кадәр каханнан баш тарта. Мөслимәләр хакында яман уйдагы раввалар хәлифә җибәргән кыз бала белән һични кыла алмыйлар, ахыр

чиктә Хазарстанга тартылган кыздан кахан үзе үк ваз кичә һәм раввалары-на кызны үз ихтыярында калдырырга куша. Әнә шулай мөслимә Хәдичә, гәрчә кахан хатыны исәбендә йөрсә дә, кырык хатын арасында берүзе кыз булып кала бирә. Шул хакта уйлап утырганда Рәшидә абыстай яңа гына Айбиби сөйләгән хәлләрне күз алдына китереп алды. Әйе, Айбиби каханга гашыйк була һәм... Ә бу мөслимә хатын... Айбиби кебек утка очкан күбә-ләктәй итми...

Ниһаять, Рәшидә абыстай Хәдичә хатыннан сорап куйды:

—Атаң-анаң исәннәрме соң, балакай?

—Юк,—диде Хәдичә гадәти бер хәл турында сүз баргандай.—Мин хә-лифә сараенда үстем. Хәлифә минем атам да, анам да иде. Бире таба озат-канда ул миңа әйтте: "Каханны ислам диненә инандыр"—диде. Мин хә-лифәнең үтенечен гамәлгә ашыра алмадым, абыстай, кахан изге динебезне кабул итмәде, баш тартты.

—Ә син туган якларыңа кайтыр идеңме, балакай?

—Хатын-кызлар очкан кошлар бит алар, абыстай. Хәлифә сараена ми-нем кайтасым килми, ләкин туган ягымны сагынам, шул тарафдарларга юлдаш тапсам, ике дә уйламый китәр идем, абыстай.

—Ә Харәзем әмиренә китәр идеңме? Хак булса, Йосыф кахан Харәзем әмире ярдәмендә баскынчы урыслардан һәм угызлардан котылмакчы.

—Харәземлеләр мөселманнар. Китәр идем, абыстай. Тик мине ничек моннан коткарыр, кем булыр юлдашым?

—Сине, балакай, менә бу егет озатыр,—диде Рәшидә абыстай Ислам ягына ымлап. Баядан бирле Исламның хатын-кыз булуына шикләнеп утыр-ган Хәдичә, егет аңа карауга, яулыгы белән күзләрен генә калдырып авы-зын каплады, сәерсенеп, хәтта гаҗәпләнеп янә-янә Исламга карап алды. Табиб Ислам да бит алмаларына кадәр кызарынып, ни әйтергә белми кау-шый калды.

—Миңа беркем дә кирәкми, абыстай, беркем дә...

—Йә-йә, балакай, бала-чага булма. Сиңа биредән котылырга башка ча-ра юк. Йә Харәземгә китәсең, йә хәлифә тарафларына.

—Миңа ирләр кирәкми, ирләр куенында үләрмен дип куркам, абыстай.

—Ир-ат агач түгел, агач басып кына кеше үлә, балакай.

Хәдичә тәмам югалып калды. Кем бу абыстай, Айбибинең абыстае? Әл-лә соң шымчымы? Бик ихтимал ич, шымчылар сарай тулы.

—Кахан Ислам динен кабул итсә, мин дә Айбиби кебек сарайда калыр идем, абыстай.

Абыстай белән Айбиби күзгә-күз карашып алдылар һәм ни әйтергә бел-ми аптырап калдылар. Сүзне янә Рәшидә абыстай башлады.

—Сине, балакай, ышанычлы табиб егет озатыр. Хак, ул әле хатын-кыз киемендә. Чарасыздан шулай киенде ул, сарайга керү өчен. Без сине баш-та Фанәгүргә җибәрербез—Гали тархан янына, аннан Харәземгә юл алыр-сыз. Айбиби ничекләр булса да каханны күндерер дип уйлыйм мин.—Рә-шидә абыстай Айбибигә күз ташлады һәм ризалыгың бир дип ым какты.—Күндерерсең бит каханны, Айбиби?

—Хәдичә хакына мин утка керергә дә риза, абыстай, чөнки ул минем ахирәтем.

—Миңа табиб кирәкми, мин исән-сау,—диде Хәдичә.

—Бик яхшы,—диде бу юлы Айбиби.—Бик яхшы, ахирәт. Мин бүген үк кахан белән сөйләшәм һәм без сезне Харәземгә озатабыз—Таман тарханы Гали аша.

—Нигә Таман тарханы аша?—дип сорады Хәдичә.

—Колларны Тамандарханда саталар, ә без сине кол исәбендә Харәземгә озатабыз, Хәдичә ахирәт.

Айбиби шул сүзләрне әйтүгә, Рәшидә абыстай яшел атлас күлмәген шау-латып торып басты һәм ишекле-түрле йөреп килде. Айбиби көмеш кыңгы-равын челтерәтте, шундук хәрам атакай килеп җитте. Айбиби аңа савыт-сабаларны алып чыгып китәргә кушты һәм Исламга карап:

—Табибә Исламия минем Хәдичә ахирәтем белән юлга чыгарга туры килер.

—Мин аны озатырмын,—диде моңа кадәр сүзгә катнашмый утырган Ислам.—Тик мин аны кемгә тапшырырмын?

—Әйттем ич инде, син аны Фанәгурия аша Харәземгә алып китәрсең.

—Башкача мөмкин түгелме, Айбиби?

—Мөмкин түгел, ахирәтем. Мөмкин булса мин сине дала аша җибәрер идем, тик Дала хәзер угызлар кулында.

Айбиби ишек бавына кулын салгач, янә бер ахирәте Хәдичәгә карап алды һәм әйтте:

—Табибә Исламия хәзергә синдә кала. Бүлмәңә хәрам атакайларны кертмә. Калганын иртәгә хәл итәрбез.

Хәдичә нидер әйтергә дип аңа таба ымсынгандай итте, әмма тыелып калды, бары табибәсе ягына күз төшереп кенә алды. Ислам ни әйтергә белми, Айбибинең әмерләрен үтәргә ризалыгын белдереп, башын иеп утыра бирде.

Айбиби белән Рәшидә абыстай чыгып киткәч, Ислам, тәрәзә каршына барып басты. Аңа оят та иде, шул ук вакытта Айбибинең әмерен үтәргә әзер дә иде. Ул Айбибидән күзләрен дә алмый утырды, ә менә Хәдичә хатынга карарга да яхшысынмады. Ничектер ошбу киемдә дәшәргә оят иде аңа. Хатын-кыз киеменнән, нииндидер үзе дә аңлап бетермәгән уңайсызлану тоя иде. Беренче булып аңа Хәдичә хатын дәште.

—Безне, Ислам табиб, каханбәк озатачакмы?

—Әйе, каханбәк. Тик каханбәк Сабир түгел, аның ярдәмчесе.

—Мөселманмы ул?

—Мөселман, мөселман, Хәдичә,—диде Ислам һәм беренче тапкыр хатынның күзләренә карады. Карады да тәмам сихерләнгән берәүдәй югалып калды. Хатынның чем кара күзләрендә нииндидер чаткылар уйный кебек тоелды аңа. Ул әсәрләнеп куйды, ни әйтергә белми ишекле-түрле йөри башлады.

—Мин кичке ашка китәм,—диде Хәдичә тора-тора.—Мин сезгә дә ашарга алып керермен, йә хәрам атакаемны җибәрермен. Тик ул кергәндә йөзегез капланган булсын.

—Яхшы, Хәдичә, мин шулай итәрмен. Тик мин сезгә уңайсызламыйммы соң?..

—Һич юк, мин сезгә урынны идәнгә җәярмен, йә үзем идәнгә ятармын,—диде Хәдичә һәм йөзен каплаган яулыкны алып, көлемсерәп алды. Тулынкы иренле иде Хәдичә хатын, күзләре кап-кара, йөзе тутсыл, әмма мөлаем итеп тыйнак кына елмая, ул гынамы, тәҗрибәле хатыннарга хас үзенә бер үзгә булган елмаю белән елмая иде, әйтерсең лә нидер әйтәсе килә, шул ук вакытта кыймый.

—Мин сезне чарасыз итмәмме соң, Хәдичә?

—Сез мөслим бит?.. Мөслим. Мин сезгә, Ислам табиб, туганыма ышанган кебек ышанам.

***

Болгар сараенда күп еллар хезмәт иткәнгәме, Рәшидә абыстай бар нәрсәдән дә хәбәрдар иде. Һәм ул каханның кылган гамәлләрен якларга керешкән Айбибигә Исраил балалары кулындагы Хазарстан сараенда барган сәясәт вә гамәлләрне аңлатырга кирәк дигән фикергә килде.

—Балакай, син шул чиккә житеп Йосыф каханга ышанмасаң иде. Хазарстанга Исраил балалары килеп, ил белән идарә итүне үз кулларына төшергәч, төркиләрдән килгән каханнарны ефәк бау белән буып, сынарга керешәләр. Бу йола-гадәтне кем уйлап тапкандыр, бер Хода үзе белә, вә ләкин төрки бабаларыбызда мондый яманлыкларны кылмаганнар да кылмаганнар. Хазарстанда бу яман гадәтне Исраил балалары канунлаштырган. Илгә теге йә бу яман афәт килсә, каханнарын гаеплиләр, имеш, аның

аркасында ил өстенә афәт килде. Ефәк бау белән буыла башлаган һәм аның жуя башлаган каханнан сорыйлар: “Тагын ничә ел ил белән идарә итәсең?” Кахан ничә ел әйтә, шул вакыт узгач, аны барыбер үтергәннәр. Тәхеткә йә анын улын, йә оныгын утырткаННар.

—Мин бу хакта беләм, анакай. Йосыф кахан үз көчендә, үз куәтендә, аңа кагылырга кыймаслар.

—Чир китә, гадәт кала, балакай. Ничек син алай кистереп әйтәсең, бит равваларның Йосыф каханны да, синең ир-канатыңны да шулай сынаулары бар. Ни өчен дип сорама. Әйтәм: угызлар жәйләүләрне туздырып йөриләр, канунг Сарманай төнлә белән Сарыкалага ябырылган. Башбаштакланып, кала халкына: “Сез бүгеннән мина ясак сала башларсыз”,—дип шапырынып йөргән. Кахан бу яман яуга аны Византия императоры котырткан дип бара. Ә үзе шул тарафларга яу кузгалырга ашыкмый. Тиз арада каханга Византия императорын акылга утыртасы иде, ахыр Кияли Сарманайны. Сарманай безнең кардәшләребез Дунай буе болгарларына яу өстенә яу йөри икән, кардәшләребез Далага качып китә башлаганнар.

—Каханның гаскәре куәтле, ул ана бик тиз чара күрер, абыстай.

—Тимерне кызуында сугалар, балакай.

— Мин аны ашыктырырмын, анакай.

—Моннан бик күп еллар элек, шул баскынчы варяглар токымыннан булган Үләт атлысы диңгез артыннан килеп, хәйлә белән Кара Болгар каханын үлтереп, Кияли тәхетен биләгән булган. Әле дә хәтеремдә, Талиб мәрхүм, Хазар каханы Биньямин куган үзен. Тик бит бүген Сарманай атлысы Дунай буе туганнарыбызга икенче тапкыр яу кузгалган дигән хәбәр йөри.

—Кузгалганмы, анакай, кузгалырга жыенамы? Аты ничек диден әле?

— Сарманай диделәр. Кияleләр кенәз дип дәшәләр икән үзенә. Кара болгар халкына мин Аскал каханның кияве Рюрикның туганы дип игълан иткән, имеш. Кем чиқ куяр үзенә, баскынчы затка, кем? Мөхәммәд ханмы, әллә булмаса синең Йосыф каханыңмы?..

—Йосыф каханымны бер дә яу-сугышка жибәрәсем килми минем, анакай.

—Ил башы булгач, яу йөрми ярамас, балакай. Бит ул кахан. Гәрчә гаскәриләре белән каханбәк Сабир идарә итсә дә Ил башында сәнең ир-канатың утыра, балакай. Сарманай кенәз көчәеп китсә, Хазар каханына ясак салуын туктатуы да бар. Каханың иң башта шул хакта уйларга тиеш, балакай. Бүген Кара Болгар тәхетендә утырган Сарманайның каханына ясак жибәрми башлавы—аның бәйсезлеккә йөз тотуы дигән сүз. Эт симерсә, хуҗасын тешләр дигәннәр.

—Шуларның барысын да истә тотып, Йосыф кахан өлкән равваны Харәзем әмиренә жибәрде, анакай. Ул кыласы бар гамәлләрен дә башта минем белән киңәшә.

—Бик хуш, бик хуш, балакай. Мин өмет итәм әле, өлкән раввага ияреп, Харәземнән имамнар да килер, иншалла. Менә шунда инде бар жирдә дә тәртип урнашыр. Атаң Талиб мәрхүм әйтер иде, сәясәт хатын-кызның йөзен генә түгел, уй-гамәлләрен дә боза дип. Һәй, әллә сиңа артыгын да сөйләп ташладым инде. Ир-баш, хатын—муен, ди бит безнең халык. Ир яраткан хатын булып яшәү дә зур бәхет инде ул, балакай, зур бәхет. Ләкин ир кылган гамәлләрне белеп тору да һәммә хатын-кызга да зарур, бик зарур, балакай, бик зарур.

*Ахыры киләсе санда.*



## Фәйрүзә Мөслимова

# АЛТЫН АЛМА БЕЛӘН ХУШЛАШУ

*Бу айда шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова беренче зур юбилеен каршылый— шигъри җәен... Ул Актаныш районында—Иске Балтач авылында туып үскән, күршедәге Иске Кормаш сигезьеллык, Актаныш урта мәктәбендә белем алган (сүз җаеннан: бу авыл танылган өч рәссам, һәйкәлтарашны тудырган—Васил Маликов, Зилфәт Басыйров, Әсгать Сәфәргалиннарны). Ә инде Актаныш төбәгенең җырга-моңга бай булуын, күп шагыйрьләргә илһам-канат биргәнен беләбез: соңгы елларда нәкъ менә шушы районнан чыккан яшьләребез шигырь, әдәбият капкаларын шактый кыю һәм үзенчәлекле шакый.*

*Фәйрүзә Мөслимова, мәктәбе белән хушлашкач, Казанда—университетның журналистика бүлегендә укый; 1977 елда аны тәмамлагач, балалар матбугатында—башта "Сабантуй" ("Яшь Ленинчы") газетасында, аннан соң "Ялкын" журналында эшли: бүген дә ул анда әдәбият бүлеге мөхәррире вазифасында. Шунысын да әйтергә кирәк: балалар матбугатында чыныгу алган күп яшьләребез соңыннан безнең журналыбыз авторларына әйләнделәр, зур әдәбиятка, шигърияткә аяк бастылар һәм бу күренеш һаман да дәвам итә.*

*Үзе дә шундый үсү юлы узган Фәйрүзә Мөслимова, көндәлек матбугатта чыныгу алгач кына, шигырьләрен 70-80 елларда дөнья күргән "Кызлар җыры", "Бер тауда ун чишмә" исемле, күмәк җыентыкларда бастыра. Соңгы елларда иҗат активлыгы белән күренгән шагыйрә "Ярату яралары" (2001) исемле мөстәкыйль китабы белән сөендерде—матбугатта, шул исәптән журналыбызда да аның үзенчәлекле, фәлсәфи-лирик дөньясы белән аерылып торучы шагыйрә булуын язып чыктылар. Быел исә Ф. Мөслимованың "Апрель кары" исемле, матур бизәлештәге, күләмле яңа шигырь китабы дөнья күрде: тормышчан, хатын-кызга гына хас нечкә кичерешләргә, күзәтүләргә, кызыклы сурәт-фикерләргә бай лирика җыйнамасы ул.*

*Ф. Мөслимова шигырьләренә язылган популяр җырлар да бар: "Күзләреңнән күзем алмыйм" (Л. Батыр-Болгарый көе), "Алкаларым сыңар-сыңар" (И. Дәүләтшин), "Агымсулар", "Җырым сиңа", "Аңларсыңмы серләремне" (боларга музыканы З. Гыйбадуллин язган иде) һ. б. Шагыйрә проза өлкәсендә дә каләмен сыный—хикәяләр яза; тәрҗемә белән дә шөгыльләнә.*

*Ф. Мөслимова—Татарстан Язучылары берлеге әгъзасы.*

*Юбилее белән котлап, бу санда укучыларыбыз игътибарына шагыйрәнең бер бәйләм шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

## Бәйрәм

Чәчләремне буяп, бөдрәләттем,
Яңа күлмәк кидем өстемә.
Иренемә шат елмаю элдем—
Дус-ишләрем күрсен өченгә.

Күзгеләргә багып, сөрмә тарттым,
Күзләремдә чаткы балкыды.
Мин үземне курчак иттем бүген,
Уйны-гамьне сызып аркылы.

Бусагадан атлап чыктым шулай,
Күргәннәрнең теле бәйләнде.
Бер танышым, иҗекләргә салып:
—Әллә,—диде,—берәр бәй-рәм-ме?

Әйе, бәйрәм! Минем күңелемдә!
Үз кәефем үзем күтәрдем:
Чәчәк итеп тойдым үз-үземне
Тормыш дигән олы түтәлнең.

Кыңгыраудай җиргә иелсәм дә,
Көнбагыштай көнгә баксам да,
Чиге булыр гомер җәйләремнең,
Көзләр керер яшел бакчама.

Әлегә мин җәйләремдә яшим
Һәм беләмен аның китәсен.
Шуңа күрә, яшәвемне данлап,
Килде бүген бәйрәм итәсем.

## Кичке уен

Карашыбыз узмый офыклардан,
Иртәге көн әле билгесез.
“Алын алырсызмы, гөленме?”—дип
Каршыбызда биеп йөрисез.

“Алларын да, гөлләрен дә”,—диеп,
Җырлап кына җавап бирәбез.
Яшь чакларда бар да матур, кызык,
Тукталмыйча уйнап-көләбез.

Зәңгәр төннәр, йолдыз җемелдәтеп,
Ал таңнарга кадәр озата.
Көннәр инде безгә гамәлләрне
Һәм юлларны ялгыз сайлата.

Ай-йолдызлы якты хыялларын
Алып китә берәү яшьлектән...
Кара булып туа гамәлләре
Кемнәрнеңдер. Нидән, нилектән?

Аллы-гөлле түгел тормыш юлы,
Ни өчендер аклы-каралы.
Көтмә икән хөсет күңел белән—
Офыгында йолдыз янганны...

Кичке уен исләремә төшсә,
Хәйран калып торам язмышка.
Киләчәкнең үз җавабы әзер
Яхшылыкка, яман, ялгышка.

“Алларынмы, гөлләренме?”—диеп,
Ул чакта соң кемнәр көлеште?..
Баксаң, язмыш үзе бүлә икән
Өлешләргә тигән көмешне.

## Улымның Мисырдан кайткач сөйләгәне

—Чит җирләрдә гөлләр үсә
Бездәгедән үзгә.
Оазислар—җәннәт сыман
Иксез-чиксез чүлдә.

Кызыл диңгез дулкыннары
Сарылалар тезгә:
—Яшермәгез күңелдәген,
Рәхәт монда сезгә!

Безнең якта көз җилләре
Сызгырадыр инде.
Коелып төшкән яфракларны
Туздырадыр инде.

Ә биредә ел әйләнә
Җәйдән тора көннәр.
Кызлар гына салкын сүзле:
—Харам, харам,—диләр.

Рәхәт монда, яшермибез,
Тик өч кенә көнгә.
Ә аннары тарта өйгә,
Үзебезнең көзгә.

Сагындыра сөйгәннәрнең
Елмаюлы йөзе.
Әниләрнең: “Исән йөр”,—дип,
Әйтеп калган сүзе.

Ризыклары экзотик та...
Ашлар тәмле—бездә.
—Сау бул, диңгез, килербез бер...—
Тик өч кенә көнгә!

## Син

Сабыр савытларым тулган чакта
Чайпалдырмый тотып торучы—син.
Иләсләнеп, хисем кузгалганда
Гаеп итми йотып торучы—син.

Эндәшмичә газап өстәүчем дә—
Тилмерепләр синнән сүз көткәндә.
Кытай диварыдай—ышанычлым,
Суга таянгандай—шик-шөбһәм дә.

Ни могҗиза: тоташ каршылык син...
Шул килеш тә—җанның иң түрендә!
Мин таянам сиңа таш дивар дип:
Рисвай итмә авып ил күзендә.

Һәм битараф кына була күрмә,
Тап үзеңдә сыендырыр көчне—
Үзең кебек тоташ кытыршылык,
Каршылыктан торган минем хисне.

## Алтын алма белән хушлашу

*(Яшь егет сүзе)*

—Нәрсә булды? Сине күргән көнне
Йөрәккәем кинәт өзелеп төште.
Мондый халәт илаһи бер өндер,
Йә булмаса, артык реаль төшме?

Син кичәнең бер гүзәле идең,
Тик елмаеп миңа дәштең бары.
Бөтерелеп без биегән чакта
Көнләштеләр егет асыллары.

Бу төш белән өн арасы иде,
Чынбарлыкта булмас андый халәт.
Фәрештәләр килеп, колагыма
Пышылдады кебек: "Ярат, ярат!"

Яраттыммы? Әллә инде язмыш
Сынадымы безне көлә-көлә?
Утлар сүнгәч, дәртләр сүрелә төшкәч,
Аерылырга язган икән менә.

Араларда гади генә киртә:
Мин туганмын бары синнән соңрак.
Барыр юлны бергә итәр өчен
Безнең ара ерак икән, ерак...

Аклый алмам синең өметләрне,
Мин, күрәсең, әле "сары томшык".
Минем белән булмый тормыш корып,
Биеп кенә була очып-очып.

Синең кебек мин дә газапланам,
Алдый алмыйм ләкин хыялларны.
Теге кичә... шундый ымсындырды,—
Өметеңә канат куялмады.

Тиңнәреңне табуыңны теләп,
Башлап үзем синнән китеп барам.
Мин әлегә ачы, яшел бөре...
Бәхетле бул, йә хуш, алтын алмам!..

## Ялтырау

"Туган җир",—дип сыгынганнар...
Туган җирен ташлап китә...
"Милләтем",—дигән дә, кайчак,
Милләтенә хыянәт итә!

Эшкә биреп күңелләрен,
Тып-тын гына йөргәннәре—
Туган җире, милләтенең
Энҗеләре, мәрҗәннәре.

Ялтыравык уенчыклар
Камаштыра күзне ныграк...
Чын энҗеләр—кабырчыкта,
Чын энҗеләр—тыйнаграк.

## Гашыйк

Кулларыңны куйчы маңгаема,
Сизәсеңме, ничек яна башым?
Күзләреңә кереп адаштыммы,
Канатланып, күкләргәме аштым?

Рухым бүген әллә кайда йөри...
Кайнар башым—синең алларыңда.
Күзләреңә карап талпындым да,
Былбыл булдым сөю аланында.

Сүзләр артык, йөрәк кенә сөйли.
Хыялый мин синең яннарыңда.
Их, шул килеш җырга әйләнергә,
Әкияткә барып ялганырга!

Хәйләсездер бу хыялый сөю,
Мөмкин түгел хистә алданырга!
...Мин тезләнеп сәҗдә кылам бүген
Мәхәббәтнең ихлас ялганына...

⁂

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

**Фаил Шәфигуллин**

# СОЛДАТЛАР КАЙТА...

Әй, кәне-тәне солыда гына тотасы иде шушы Акъялны... Тазарып, чибәрләнеп китәр иде атна-ун көн эчендә. Аннары көндез генә җигәсе иде аны. Төнлә йокласын, ял итсен иде. Күр инде, аяк өсте йоклап бара, бичара. Кабыргалары мичкә кыршаулары кебек, бүселеп-бүселеп чыккан. Ыңгырчак астындагы ярыклардан кош очып чыгарлык. Камыты да буш. Тау төшкәндә, муенына аркылы килә.

Кабык төпле арбада—ике малай һәм бер тимер мичкә. Арба тәгәрмәчләренең берөзлексез ыңгырашуларына караганда, мичкә ярыйсы ук авыр булырга охшый.

Малайларның икесе дә яланбаш, яланаяк. Сүс дилбегә уң яктагы малай кулында. Анысы буйга да зуррак, төскә дә олымсарак күренә. Йөзе җитди. Күзләре уйчан.

Сул яктагы малай лаеш шулпасын азрак эчкән, ахры, тирә-юньне илтифатсыз гына күзәтеп бара. Чебиле аякларын селки, курнос борынын югары чөеп, төпсез зәңгәрлектән тургайлар эзли, йә булмаса ерак басудагы ялгыз трактор гөрелтесенә колак салып бара, яисә, чыбыркы сабын тидереп, тәгәрмәч тырнакларын кырдыра, ара-тирә ат тоткан малайга сүз ката. Тегесе теләмичә генә җавап кайтара. Яисә иптәшенең сүзен бөтенләй колак яныннан уздырып җибәрә.

—Хәмис, дим, карале, Хәмис, бер-ике пот солы ашатсаң, мин әйтәм, танып та булмас иде Акъялны, ә!..

—Һе, әйттең, бер-ике пот солы...

—Ярты пот булса да әле, әйеме?..

—Соң... На, Акъял. На... Бөтенләй йоклады, кара!

—Арыган ул, Хәмис. Төнлә тырмага җиккәннәр аны.

—Беләм.

—Ярый инде крачинны апкайтып житкерәлсә...

—Апкайта.

—Акъял ул җенеңне дә тартып кайтыр, диген...

—Соң...

—МТС тагын бер трактор бирсә, чәчү ике-өч көндә бетәр иде инде, име, Хәмис?

—Бирер, тот капчыгыңны... Син генә иең ди...

—Әле бирсен ничек бирделәр, диген, име?

—Син бик күп сөйләшәсең, Бәхи. Җитәр инде.

—Саруны кайнатасың, диген...

—На, на, Акъял, кара инде, бөтенләй йоклады...

—Ишеттеңме, Хәмис, Кайбычта солдатлар кайта башлаган, ди.

—Кайбыч район үзәге бит ул...

—Шуннан атаң кайтып килсә, нишләр идең, Хәмис?

—Үлгән кеше ничек кайтсын...

Хәмис дилбегәне тарткалаган була. Аның керфекләре арасыннан берничә яшь бөртеге сыгылып чыга да ябык яңаклары буйлап иягенә тәгәри...

Һавада берөзлексез тургайлар сайрый. Әле яңарак кына нәфис яшел бөркәнчек ябынган каен урманы артында моңлы итеп поезд кычкырта. Арба тәгәрмәчләре авыр шыгырдый.

—Нимечне дә дөмектерделәр дөмектерүен, безнең әтиләр генә...

—Җитәрсәнә, Бәхи... На, на, Акъял, на!..

Корыган инешкә килеп җиткәч, малайлар, ярым җимерек күперне "хут" белән чыгып китәргә уйлап, икесе ике яктан Акъялны ашыктырырга керештеләр.

Акъял ныгытып баскан саен күпер такталары шыгыр-шыгыр килде, субайлар чайкалды, бүрәнәләр дерелдәде. Ниһаять, Акъял, күпернең теге ягына чыгып, каты

җиргә басты. Ал тәгәрмәчләр дә юл тузанында. Малайлар, күперне хәвеф-хәтәрсез исән-сау чыгып җиттек, дип сөенгәннәр иде дә, булмады, иртәрәк шатланганнар икән: һич көтмәгәндә, күпер башында нәзек бүрәнәләр дөбер-шатыр берсе өстенә икенчесе килеп өелде, һәм арт тәгәрмәчләр икесе дә дырык итеп күпер ярыгына төште. Акъял җилләнеп атлаган җиреннән чак кына егылмыйча калды. Камыт бавы суырылып чыкты, аркалык шартлап өзелде...

Бригадир ашыктырган иде. Тизрәк кайтырга карагыз, малайлар, тракторны гәрүчидән өзмәгез, дигән иде.

Малайлар Акъялны туарып яңадан җиктеләр. Арба артына күсәкләр тыгып, тәгәрмәчләрне кузгатырга тырышып карадылар.

—Менә шулай, менә шулай,— дип тешләрен кысып күсәкне каерды Хәмис.

Бәхи:

—Шулай булса була, диген,— дип ябык иңбашы белән бар хәлгә арбаны этте.

Алгы тәгәрмәчләр җиргә тимичә тартылдылар, камыт баулары шыгырдады. Дуга бөгәҗәләнеп килде. Акъял, әле генә су коенып чыккандай, манма су булды. Аның һәр мускулы кигәвен талаган чактагы шикелле дерелди, калтырана иде.

—На, Акъял, на, дим...

—Сукма, Хәмис, сукма! Күрәсең ич, хәле юк... лутчы мин авылга йөгерәм, кешеләр чакырып килим.

—Син әйләнеп килгәнче...

—Караңгы төшәр, диген... Әй, Хәмис, никләргә генә олы юлдан китмәдек икән?.. Анда кешеләр дә очрар иде. Әйләнгеч булса да, олы юл яхшы, дип тикмәгә генә әйтми шул минем әби...

—Телеңә салынма әле, Бәхи, ачу килгән чагында. Әйдә, күтәр... На, Акъял, на...

—Хәмис, Хәмис, дим, карале, кара!..

Малайлар икесе дә артларына борылдылар: яшь имәннәр күпереп утырган сөзәк үр өстеннән болайга таба яшел киемле бер солдат төшеп килә иде. Пилоткасын салып кулына тоткан. Аркасында капчыкмы, шинельме... Ялтыр итекләре тузанга буялган... Кем булыр бу? Малайлар бер минутка бар дөньяларын оныттылар. Күзләре зур ачылып, керфекләре хәрәкәтсез калды, аяк бармаклары тынычсызланып хәрәкәтләнде.

Менә солдат күпергә керде. Адымнары нинди нык, куллары нинди зур аның. Шулай буладыр инде ул фашистларны чәнчелдергән чын солдат! Шәмәхә күзләрендә йомшак елмаю. Маңгаенда җәрәхәт эзе. Киемнәреннән төтен исе дә, итле токмач исе дә килә сыман. Әллә нәрсә дип кенә эндәште ул, малайлар искәрмичә калдылар.

Капчыгын юл читенә салып куйды. Борыннары йомшарган малайларның башларыннан сыйпап узды, кайсы авылныкы икәннәрен сорашты, баткан тәгәрмәчләрне иелеп карады.

—Нык утыргансыз,— дип бил каешын төзәтеп куйды.

Аннары Акъял янына килде. Учын җәеп атның авызына шикәрме, сохари кисәгеме каптырды. Акъял да, гаҗәпсенеп, чит кешенең гимнастеркаларын, погоннарын иснәде һәм, ияген тәртә башына салып, сез дә йөрисез ир кеше булып, дигәндәй, малайларга тешләрен ялтыратып алды. Малайлар, эчләре-тышлары белән балкып, көлеп җибәрделәр. Солдат көлмәде. Дымланган күзләрен кысып, аз гына уйланып торды да җитез хәрәкәт белән арба астында аркылы-торкылы яткан нәзек бүрәнәләрнең берсен суырып чыгарды. Аны күчәр астына тыкты, бер башын күпернең кай җиренәдер терәп аска таба каера башлады. Баткан тәгәрмәчләр бер карыш чамасы күпер өстенә күтәрелделәр. Акъял, шуны гына көткәндәй, арбаны җан-фәрманга алга сөйрәп алып китте. Малайлар ура кычкырып, солдатка рәхмәт әйтергә дә онытып, Акъял артыннан ташландылар.

—Дилбегәгезне карагыз, тәгәрмәчкә уралмасын,— дип кычкырып калды солдат алар артыннан...

Тургай тавышы белән мөлдерәмә тулы яшел инкүлек буенча ак ялларын сибелдереп ябык ат юырта, тимер мичкә дөбердәп бара, арба артына ябышып такыр башлы ике малай йөгерә.

Әллә тургай җырыннан, әллә тугай яшеллегеннән, әллә малайлар көлүеннән исергән инде солдат—атлаган уңайга чайкалып-чайкалып китә. Үзе бертуктаусыз елмая, зур учлары белән әледән-әле күзләрен сөрткәли.

Офыклар зәп-зәңгәр. Биниһая якты кояш төшлек турысына якынлашып килә.

*1975*

# БЕР МӘХӘББӘТ ТАРИХЫ

Элек мин кызлар белән таныша алмыйча иза чигә идем. Аракыны ташлагач, хәл үзгәрде.

Әле беркөннәрдә Фәнзилләр туенда бик озаклап Нәзирәне күзәтеп утырдым. Чәчләрен дә әллә ниләр кыландырып кырыкка бөтереп бетермәгән, сыра күбеге сыман күпертеп маңгаена гына төшереп куйган. Күзләрен дә башка хатын-кызлар шикелле алан-йолан уйнатмый. Акчасы җитеп бетмәгәнлектән өч борынга керергә базмаган кыюсыз кеше сыман уңайсызланып кына утыра. Үзе ара-тирә дус кызларына сүз каткалап ала. Башлап җырламый. Әмма җыруга бик теләп кушыла. Тавышы зур тизлек белән еракланып барган олаудагы буш шешәләр чылтыравын хәтерләтә.

Туйдан чыкканда Нәзирәне күздән җуймаска тырыштым. Егете-фәләне, озатучысы, көтеп торучысы юк икән, бәхеткә каршы. Багана башларындагы лампалар мөлдерәмә тулы әче бал графиннәренә охшаган. Тротуар буендагы чәчәкләрдән тройной одеколон, ликер һәм дә тагын әллә нинди мин авыз итеп карамаган татлы шәраб исе килә.

Ниһаять, Нәзирәне куып җиттем. Оялып кына сүз башладым:

—Ай-һай, Нәзирә! Син шешә җыючы Гыймраннан да тибешрәк йөрисең!

Дәшми. Биек үкчәләре белән асфальтны шакылдатып баруын белә.

—Гастроном чатына кадәр генә озатыйм әле. Нәзирә?

Шунда Нәзирә авызыннан, шешәдән бөке атылып чыккандай, хәтәр-хәтәр сүзләр барысы берьюлы шартлап чыкты:

—Күрәсем дә килми эчкән кешене, җенем сөйми!

—Гафу ит, Нәзирә, аракыны ташлаганыма ай була бит инде. Әле бүген туй хөрмәтенә генә...

—Сөйләшәсем дә килми, айныгач килерсең.

Нәзирәнең мондый бик үк өметсез булмаган сүзләреннән бөтен җаннарым рәхәтләнеп китте. Махмыр белән бик озак газапланганнан соң бер стакан саф көмешкә эчеп җибәргәндәй булдым.

Атна буе авызыма бер тамчы хәмер капмыйча чыдадым да шимбә көнне киенеп-ясанып клубка таба юл тоттым. Клуб тирәсе, сыра залы шикелле, халык белән шыгрым тулы. Колмак төлгәшләренә охшаган муенса таккан Нәзирәне ерактан ук танып алдым.

Елмаеп сәлам бирдем. Алды сәламемне.

Ләкин минем йөзгә күтәрелеп карагач ук Нәзирәнең яп-якты күзләре ничектер болганчыкланып, Идел суы кушылган вермутка охшап калды.

—Эчкәнсең,— диде ул, яна гына ачылган шампанский кебек чыжылдап.

—Юк, юк, Нәзирә, нәрсә син, атна буе авызыма да алганым юк.

—Борының нигә кызыл?

Мин борынымны учларым белән томаладым һәм аяк очларыма карап:

—Әллә кайчан эчкәннеке бетми,— дип мыгырдандым.

Шулай да Нәзирә акыллы кыз икән—сүзне урманнарга, басуларга, болыннарга борып алып кереп китте. Мин дә сиздермичә генә үрелеп аның кулын кыстым.

Без карт өрәңге төбендә эскәмиягә килеп утырдык. Кич җиләс, һавада җиңелчә генә борыч аракысы исе аңкый.

—Сөйлә инде син дә нәрсә дә булса, югыйсә, һаман мин генә сөйлим,— диде Нәзирә, бераз тынып утыргач.

—Бервакытны шулай Ризван, Дамир, мин, бер яртыны алып, кибет артына борылуыбыз булды...

—Башка нәрсә турында сөйлә. Әтү һаман аракы турында сөйлисең...

—Нәрсә сөйлим?

—Эшең турында, уйларың, үзең турында.

—Аппаратчы булып эшләгәнемне үзең дә беләсең бит. Болай кызыклы эш. Аппарат чистартырга атна саен өч йөз грамм спирт бирәләр...

—Әй, сөйләмәсәнә шул спиртың турында! Әнә, күрдеңме, Зөһрә йолдыз янына тагын бер нәни йолдыз калыкты.

—Кызык, ике генә йолдызлы коньяк була микән?..

Мин шулай уйлаганмын гына кебек иде. Тик, кызганычка каршы, кычкырып әйткәнемне үзем дә сизмичә калганмын икән.

Нәзирәнең керфекләрендә яшь бөртекләре ялтырап китте.

—Мин синең белән чынлап сөйләшәм, Һәнүс абый, ә син миннән көлеп утырасың,—

диде ул һәм иңбашларын калтыратып елап җибәрде.

Ми күзәнәкләрен киереп, мин аны юатыр сүзләр эзләдем. Ләкин кирәкле сүзләр табылмады.

Озак кына сөйләшмичә утырдык. Инде Нәзирә дә елаудан туктады. Әкрен генә ниндидер миңа таныш булмаган озын, моңлы көйгә җыр башлады.

*Сандугачлар гына кайда сайрый,*
*Сарман буйларында тирәктә, шул...*

Мин тагын, буш шешәләр төяп, ераклашып барган олауны күз алдыма китердем. Өрәңге ботаклары арасыннан сары калай бөке сыман ялтырап торган айга карый-карый байтак кына җырлаганнан соң, ниһаять, Нәзирә башын минем якка борды.

—Ярар, Һәнүс абый, юк өчен үпкәләшмик. Әйдә, хәзер син җырлап кара инде, мин үлеп җыр яратам,— диде.

—Җырлый белмим мин.

—Җырның ертыгы юк, белгәнеңне җырла.

Нәзирәне кабат үпкәләтәсем килмәде. Аны-моны уйлап тормыйча, үзем яраткан "Алмагачлары" көенә җыру суздым.

*Айкап җибәр, чайкап җибәр*
*Казакларның камчысын, шул.*
*Ал күтәреп, эчеп җибәр,*
*Калдырмыйча тамчысын.*
*Ал күтәреп...*

Нәзирә капылт кына урыныннан сикереп торды да алагаемга кизәнеп яңак төбенә утыртты. Әйтерсең лә дистәләгән шешә берьюлы асфальтка төшеп чәлпәрәмә килде.

Мин, күзләремне ачарга куркып, оеп утыра бирдем. Таныш аяк тавышлары бөтенләйгә, инде мәңге-мәңге минем янга әйләнеп кайтмаска ераклаша иде.

*1976*

## АЕРЫЛЫШУ

Аерылыштык. Хатын китте. Йокы бүлмәсендә яши. Мин асылынырга бау әзерләп куйдым. Менә әйберләрне бүлешеп бетерәбез дә тәвәккәллим. Суд бүлешкән өчен акча ала, ди. Судсыз гына бүләбез әйберләрне. Хатынга—диван, миңа—кровать, хатынга—телевизор, миңа—радиола. Кадак-чүкеч—миңа, инә-җеп—хатынга. Чәйнек мәсьәләсендә бәхәс купты. Ни өчен, дигәндә, икебезнең дә чәй эчәсе килә. Ә чәйнек бер генә. Кулымнан эш килә минем: анысын да бүлдем. Аркылыга ярып, ямап, бер ягына борын, икенче ягына сап куйдым. Пычакны икегә ярдым. Чүмечне дә. Коридорны бүлдем, кухняны бүлдем. Ванна гына җайсызрак килеп чыкты, бүлгәч кайнар су краны хатын ягында калды. Суны ваннага плитәдә җылытып китереп салам. Хатын, киресенчә, кухнядан салкын су ташый. Бүлешүнең әле тагын бер четерекле ягын әйтмәгәнмен икән. Хатын минем һәр мероприятиегә аяк чалып килә. Пычакның үткен өлешен үзенә алды. Газ плитәсенең дә аңа ике комфоркасы эләкте. Чәйнекнең дә борын ягы хатында. Хәер, чәйнегенә сапны бик хөрт куеп бирдем—озакка чыдамас.

Ниһаять, бүлешеп бетерәбез бугай. Түшәмгә алка кагып, бауны хатын күз алдынарак бәйләп куйдым. Кызганмас микән, дим, ит турагычны, бәлкем, бөтенләе белән үземә бирерие, дим. Юк, бауны күрмәгәнгә салына. Югыйсә элмәген дә ясап куйдым бит инде. Бүл, ди. Ит турагычны да, борыч тегермәнен дә бүл, ди. Тфү, бөтенләй миһербансызланган. Уйлап-уйлап тордым да туалетны бүләргә керештем. Хатынның җен ачулары чыкты. Нервысына чыдаша алмыйча ике чәшкәне идәнгә бәреп ватты. Дәшмәдем. Хатын-кыз белән булышканчы, кухня өстәлен бүлим лутчы, дип, пычкы кайрарга утырдым.

Шулай игәү елатып маташканда ишек шыгырдады. Борылып карасам, бусагада шахтадагы малаем Әсфәндияр, аның янында кулына яшь бала күтәргән сары чәчле, борау күзле бер хатын-кыз кәмәше басып тора. Пычкыны ташлап, яннарына бардым. Күрештек. Хатын инде әллә кайчан болар кочагында. Балавыз сыга.

Оныгыбыз туган, имеш. Бик шатландык. Үзләре дә шатландылар.

—И, әти, син бигрәк инде,— дигән була малай,—каян ишеттегез безнең монда торырга кайтасын, кухняларны, коридорларны бүлеп куйгансың,— ди. Ванна белән туалетны күргәч, эчен тотып көлде. —Боларын сүтеп ташларбыз инде, әти, болары уртак булыр, безгә бер бүлмә, ярты кухня җиткән,— ди.

Әнфисә килен, түшәмдәге бауга төртеп күрсәтеп, шатланып кычкырып җибәрде:

—Әсфәндиярчик, карале, әнә, әткәй Фердинанд бишегән эләргә бау да әзерләп куйган.

Ашап-эчеп малайлар мунчага киткәч, хатын:

—Савыт-саба ватылса, сөенеч була, диләр, тәки дөрес икән,— дип идәннән чәшкә ватыкларын җыеп алды.

Мин уйлап-уйлап тордым да кухня өстәленә тимәскә булдым. Йокы бүлмәсенә кереп хатын диванына сузылып яттым. Озакламый хатын да минем янга кереп утырды. Учын маңгаема куеп:

—Авырмыйсыңдыр ич, атасы?— дип сорады.

Кулы кайнар иде хатынның. Моннан егерме биш ел элек тә шулай кайнар иде аның куллары.

—Менә әби белән бабай да булдык инде,— диде хатын һәм кайнар учы белән йомшак кына итеп пеләшемнән сыйпады.

*1977*

# ИСЕМЕҢ ЛӘЙСӘН БУЛЫР

*Кызым Раушаниягә*

Аның янында тезелешеп торган башка курчакларның да исемнәре юк иде. Шулай да аларны сатып алып бетерделәр.

Иртәнге якта кибеткә әнисенә ияреп коңгырт чәчләренә сары тасма кушып үргән кызчык керде. Прилавка янына килүгә, энҗе тешләрен җемелдәтеп:

—Әни, күр әле, нинди матур курчак!— диде.

Сатучы апа курчакны кызның әнисенә сузды.

—Фи,— диде кызчыкның әнисе, кызыл тырнаклары белән курчакның сандалларына чиртkәләп караганнан соң. —Күбәләк канат җилпегәнгә дә сүтелергә тора. Сандаллары әйбәт булса, күптән алып китәрләр иде аны.

Курчакка каерылып-каерылып караган кызын әнисе ишеккә әйдәде.

Курчак тагын чыга алмады урамга. Кояшлы күк гөмбәзен тагын күрә алмады. Сатылмый яткан китаплар арасында янә бер ялгызы басып калды.

Төш җитәрәк кулына портфель тоткан күзлекле абзый, курчакка ымлап, сатучы апага эндәште:

—Нишләп курчакларыгыз китаплар янында?

Сатучы апаның йөзенә кызыллык йөгерде.

—Курчаклар түгел, курчак кына,— диде ул, уңайсызланып. —Сандалларын матур текмәгәннәр, шуңа күрә алучы юк, уенчыклар янына куясым килмәгән иде…

Калын портфельле абзый артыннан ишек ябылгач, сатучы апа курчакны прилавка астына ташлады.

Нәрсә дә нәрсә, әмма монысын көтмәгән иде курчак. Уйныйсы бар ич әле аның. Берәр нәни кызның көлгәнен күрәсе бар. Курчак үзе көлә белми, кибеткә кергәч тә көлеп җибәргән кызларга кызыгып карый, ә елак кызларны бик кызгана иде. Инде көләч кызларны да, елакларын да күрмәс микәнни курчак? Исеме дә юк бит әле аның. Ә бит, уйлап карасаң, барысы да шул ямьсез сандаллар аркасында.

Җыештыручы апаның елтыр күзле йөнтәс маэмае бар иде. Менә шул шаян маэмай кичкырын иснәнә-иснәнә прилавка астына керде дә курчакны, күлмәк итәгеннән эләктереп, идән уртасына күтәреп чыкты.

Сатучы апа белән җыештыручы апа бер-берсенә карап көлештеләр. Аннары акрын-акрын йөнтәс маэмайга таба килә башладылар. Бик тә шаян иде шул йөнтәс маэмай. Тегеләрнең ниятләрен сизгәч үк, төймәдәй түгәрәк күзләрен хәйләле елтыратып, башын чайкады һәм курчакны күлмәк итәгеннән тешләп капкан көе ачык ишектән урамга атылды.

Курчак бөртек тә курыкмады йөнтәс маэмайдан. Киресенчә, сөенде генә. Сөенми теге, күз аллары бердән яктырып китте аның. Зәңгәр бишектә тирбәлә-тирбәлә офыкка төшеп барган алтынсу кояшны күрде ул, яшел ябалдашлары белән кояш бишеген күтәреп торган мәһабәт агачларны күрде.

Йөнтәс маэмай, үз күләгәсен үзе узарга тырышкандай, тимер рәшәткәле бакча буенча алдына-артына карамыйча чапты-чапты да курчакны сирен куагы төбендә калдырып китте.

Әле көзгә ерак, көннәр генә түгел, төннәр дә җылы иде. Исемсез курчак көндез сирен яфракларының кояшны алкышлавын, ә төнлә карасу-зәңгәр биеклектә исәпсез-хисапсыз йолдызларның серле җиһанга моңсу нур сибүләрен күзәтеп ятты.

Җилле иртәләрнең берсендә курчак сирен ботаклары арасыннан биек ак стена, шунда якты тәрәзә күреп алды. Бераздан тәрәзә ачылды, бакчага тузган чәчле нәни кыз сузылып

карады. Күзләре төнге йолдызлар кебек моңсу иде кызчыкның. Елак кыз икән, дип уйлады курчак.

Ак стена буенда шәмәхә яулыклы мөлаем апа пәйда булды.

—Нигә урамга чыкмыйсың, үскәнем, көн җылы бит,— диде ул тәрәзә төбенә яңагын куйган моңсу кызчыкка.

—Аякларым авырта минем,— диде кызчык, күз яшьләренә төелеп.

—Ә син елама, төзәлә ул, врач әйткән киңәшләрне тотсаң, һичшиксез, савыгырсың, елама,— дип юатып узды шәмәхә яулыклы апа моңсу кызны.

Ачык тәрәзә каршына чал сакаллы, хәтфә түбәтәйле бабай килеп туктады.

—Нихәл, Ландыш кызым!

Курчакның керфекләре дерелдәп куйды. Димәк, бәләкәй кызчыкның исеме бар икән, исеме Ландыш икән.

—Бабай, минем урамга чыгасым килә,— диде Ландыш еламсырап.

—Сабыр иткән—морадына җиткән, бәбкәм. Тиздән савыгырсың да менә урамга чыгарсың. Бакчаларда, су буйларында йөгереп йөрерсең. Ә мин аңарчы сиңа тәти сандаллар тегеп өлгертермен.

Сандал турында сүз чыккач, курчакның кәефе кырылды. Үзенең ямьсез сандаллы курчак булуын онытa язган иде инде ул. Нигә шушы ягымлы тавышлы бабайга тектермәделәр икән соң курчакның да сандалларын? Моңарчы өе булыр иде инде аның, исеме булыр иде. Ландышка охшаган йомшак күңелле кыз җылы кочагында тирбәтер иде аны.

Шул чагында чал сакаллы бабай, сирен куакларын аралап, курчак өстенә иелде, зәңгәрә уңган күзләрен челт-челт йомгалап, курчакны кулына алды.

—Ландыш кызым, карале бирегә…

—Бабай, курчак!— дип шатланып кычкырды Ландыш. —Бабай, китер тизрәк, җирдә ята-ята туңып беткәндер ул… Әллә-ли, бабай, нинди сөйкемле курчак!

—Ашыкма, бәбкәм,— диде чал сакаллы карт дерелдәвекле тавыш белән. —Мин аны менә синең каршыңа, тәрәзә төбенә утыртып куям. Югалткан булсалар, шуннан күреп алырлар. Эзләп килүче булмаса, үзең уйнарсың.

Ландыш курчакка сузылды. Ләкин бабай курчакны аның кулы җитәрлек урынга куймаган иде.

—Исемең ничек синең?— диде Ландыш һәм, башын нәни куллары өстенә салып, курчакка текәлде, елмая биреп дәвам итте. —Исемең дә юкмыни әле? Синең исемең Ләйсән булыр, яме. Син минем янда кал, эзләп килсәләр дә, минем янда кал, яме, Ләйсән. Бабай сиңа тәти сандаллар тегеп бирер. Минем аякларым төзәлгәч, без икәү бергә бакчада уйнарбыз, су буйларында йөгереп йөрербез. Кал, яме, Ләйсән…

Курчак Ландышның куенына атылырга теләде. Тик шунда ук мондый теләгеннән оялып китте. Әгәр дә Ландыш, яңа сандал өчен шулай шатлана икән бу, дип уйласа нишләрсен? Һәй, сандалларның нигә кирәге бар соң әле аңа?! Шундый килешле исемең, шундый әйбәт дусың булганда, ялантәпи дә яшәргә мөмкин ич дөньяда.

*1979*

* * *

*Бай кеше иде Фаил! Хыялга бай иде ул—аның хыялый дөньясындагы хәзинә бик тә мулдан иде. Табигать биргән һәм дә таланты китергән шушы байлыгын арттыруда ул иренмичә чокчына иде, хыял итә белүнең, гыйлемлекнең, тырышлыкның, түземлекнең яшәештә һәм иҗатта беренчел шартлар икәнлеген белә иде. Шуларны белүе аңа:*

*—Җиңелен сайлап күтәрмәдек йөкнең,— дип әйтергә нигез булды.*

*Гел иҗат итеп яшәде Фаил. Авылы Карашәм (Яшел Үзән төбәге) кырында иген үстергәндә дә, диңгездә балык тотканда да, завод станогын зырылдатканда да иҗатка тугры иде ул. Тормыш итүнең иҗат икәнлеген шәп аңлый иде шаян да, моңсу да егетебез Фаил Шәфигуллин, шаянлык белән моңсулыкны бергә үрергә көче-осталыгы җитә иде аның. Рәсем ясарга кулы ябышып тора, балта һәм калай эшләренә дә кулы ятышлы иде Фаилнең.*

*Беркайчан да эштән җирәнмәде, авырыксынып эш эшләмәде ул. Хәтта баш әйләнгән дә (җәфалый иде аны шундый чир) эшләп җиңәргә өметләнә, биек маңгаен учы белән каплап, башын артка ташлап, күзләрен йомып бераз утыргач, авыруын онытырга тырышып, эшенә кабат керешә иде.*

*Күп кенә һөнәрләргә ия булса да, Фаил чирәптән чүлмәк ясарга тырышучы түгел иде.*

*Әдәби иҗатында да беркайчан да ясалмалыкка бармады. Һөнәрне ганимәт—табыш чыганагы итеп карамады, ягъни хөсетләнмәде, һөнәр аның өчен гүзәллеккә соклану, яшәүнең тәмен табып ләззәтләнү иде. Беренче чиратта.*

*Миңа Фаилнең бәхеттән сөенгән чакларын күрергә, ягъни аның иҗат итүенә шаһит булырга шактый туры килде. Мин, аның белән якыннан аралашып, күп кенә хикәяләренең "биография"ләрен белеп калдым. Шулардан укучы игътибарына югарыда тәкъдим ителгән дүрт әсәренең берсе турында искә төшерим әле.*

*...Эш вакытында иҗатың белән шөгыльләнеп булмый, шуңа күрә редакциягә ("Чаян" журналы) иртә—сәгать алтыда ук килеп утыра идек. Фаил бүген алданрак өлгергән, бүлмәсе ишеген ачкач, башын кагып кына куйды—сәламне алуы ягъни. Ашыгып яза иде ул. Ишек ачып борчу кирәкмәгән, әлбәттә. Ә бераздан Фаил үзе минем янга атылып керде. Өстәл башына килеп таянды, карашы тәрәзәдә иде, мине күрмәгән кебек, үзе миңа сүз кушты.*

*—Аерылышабыз!*

*Менә әкәмәт! Иске авыздан—яңа сүз! Өстәвенә әче таңнан! Бер мәлгә аптырап калдым, әмма үземне тиз кулга алып:*

*—Бик шәп!— дидем.*

*Болай "хуплавымның" хикмәте Фаилнең холкын инде шактый белүемнән иде. Аерылышмыйлар алар, яза торган хикәясенә минем мөнәсәбәтемне тикшереп карый хәйләкәр җан Фаилебез!*

*—Судсыз гына бүләбез әйберләрне!*

*—Шулай дөрес! Нигә булыр-булмас хәзинәгезне суд залына күтәреп барырга икән?*

*—Хатынга—диван, миңа—караватт, хатынга—телевизор, миңа—радиола. Кадак-чүкеч—миңа, энә-җеп—хатынга. Чәйнек...— диде дә тукталып калды Фаил. Менә кайда төртелгән икән ул! —Чәйнек...*

*—Чәйне икегез дә яратасыз, кайсыгызга булыр икән соң чәйнек? Урталай бүлсәгез генә инде, ләкин тип-тигез итеп...*

*—Бүләбез!..— дип атылып чыгып та китте Фаил.*

*Һәм, белгәнегезчә, "Аерылышу" исемле кечкенә хикәядә чәйнек урталай бүленә. Шундый күпертүләр кергән көлке хикәянең ахыры бик тә матур лабаса!*

*Әйе, аның һөнәрләре күп иде—тракторчы, слесарь, эретеп ябыштыручы... Шулай да Фаил Шәфигуллинның төп һөнәре—хикәяче. Әйе, аның унбиш елдан аз артык актив иҗаты чорында повестьлары басылды, инсценировкалары байтак, иҗат кешеләре турында мәкаләләре ишле, тәрҗемәләре күп, ул шигырь китаплары да чыгарды. Боларга өстәп, юмористик һәм сатирик хикәяләренең берничә телгә тәрҗемә ителүен дә әйтик. Ләкин татар укучысы аны кыска хикәя остасы итеп белә. Бу исә бик тә дөрес бәя!*

*...Фаил дускайның иҗаты кырык өчендә өзелде. Иртә, аяусыз иртә. Ә бит аңа быел май аенда алтмыш биш кенә туласы иде әле...*

*Акмөгез. Акбай һәм Карабай. Актәпи. Акчарлак та ялгыша. Ак кәҗә һәм карт бака. Аксакал...*

*Фаил хикәяләренең исемнәре болар. Аның "Ак яллы аргамаклар" һәм "Ак маңгайлы бүреләр" исемле китаплары да бар. "Солдатлар кайта" хикәясендәге атның исеме—Акъял.*

*Ак төсне ярата иде ул. Аның әсәрләреннән аклык-пакълек бөркелеп тора. Аның геройларының вөҗданлы, миһербанлы, тырыш, игелекле, керсез күңелле, илгәзәк булуларыннан килә бу яктылык-сафлык. Дөрес, аның әсәрләрендә, аеруча юмор-сатира әсәрләрендә, комсыз, мәрхәмәтсез, илтифатсыз, башкаларга җәбер тидерүче кешеләр дә күп. Болары—ямьсез төсләр. Ләкин бу төсләрне тасвир итүдән дә укучы күңелендә аклык тудырырга теләде Фаил, ягъни ямьсезлекнең, җиңелеп, матурлыкка әверелүен теләде. Ак фикер—изгелек кылу теләге тусын иде ягъни. Аның әсәрләренә шушы игелек хас. Һәм менә шуңа күрә әдәбиятта Фаилнең үз урыны бар. Һәм бу олы урын—Фаилнең иҗат бәхете.*

*Фаил дускай бер әсәрендә ак дөнья турында сөйли. Туктагызчы, ак дөнья буламы соң? Була икән шул—Фаил бөтен иҗаты белән тудырган дөнья ак лабаса, Фаилнең үз Ак дөньясы.*

***Мәгъсум Хуҗин искәрмәсе.***



**Солтан Шәмси**

# КҮК КАПУСЫ АЧЫЛСА...

## ТАРИХИ-ФӘЛСӘФИ БӘЯН

*"Ә сезне күзәтеп торучылар барлыгын онытгыгыз, алар барысын да язып бара. Алар ни кылганыгызны белеп тора."*

(Коръән, 82: 10–12)

*"Земля взяла курс на радикальное изменение направления. Она испытывает ускорение, эволюционный толчок в процессе своей эволюции. Заканчивается определенный цикл, определенная эра существования на Земле".*

Барбара Марсиниак , "Земля"

## ӨЧЕНЧЕ МЕҢЬЕЛЛЫККА КЕРҮ АЧКЫЧЛАРЫ

### БЕЗ НИНДИ ЗАМАНДА ЯШИБЕЗ?

*"Вы пребываете в окне продолжительностью 25 лет (1987–2012), когда человечество находится на испытательной площадке, выбирая вероятный путь в великой Книге Земли".*

Барбара Марсинияк, "Семья Света"

Бүгенге көндә безнең дөньябызда гаҗәеп үзгәрешләр бара. Һәркем күреп тора – замана артык катлауланды, аны аңлау елдан-ел кыенлаша. Күбебез киләчәктә нинди зур вакыйгалар, тетрәнүләр булачагын күңеле белән сизеп яши. Тормышыбыздагы барлык каршылыклар, яшерен барган процесслар кинәт өскә калкып чыкты, гүя алар , тиз арада чын йөзләрен ачып, юкка чыгарга тиешлесен көрәш утында яндырып, чистарынып калып, нинидер яңа баскычка күтәрелергә ашкына. Бүгенге көндә һәркем эчтән генә: "Дөнья гайре табигый юлга кереп китте, болай озак бара алмас",–дип, хафалы уйларга бирелә, заманның асылын аңлый алмаудан гаҗиз булып яши. Җитмәсә, без хөрмәт иткән фән дә, авызына су капкандай, берни әйтә алмый. Хәер, ул да бит адәми затның акыл җимеше – үзеннән биегрәк сикерә алмыйдыр, күрәсең. Кешенең рухи

мөмкинлекләре дә әлегә үткәнне, бүгенгене, киләчәкне бербөтен итеп карау, аннан сабак алу дәрәҗәсендә түгел. Шуңа күрә алга, маңгайны бәрә-бәрә, капшанып атларга туры килә.

Әгәр дә без шушы буталчыклыкка, кискен үзгәрешләргә, мохитның торган саен начарая баруына, табигатьнең гаять көйсезләнүенә, төрле катастрофаларга, зур мәйданнарны камап алган янгыннарга, планетабызның әле бер, әле икенче тарафында күзәтелгән көчле су басуларга, гел кабынып торган кече сугышларга, социаль тетрәнүләргә, газета-телевидение аша аңыбызга сеңдерелеп торган вәхшилеккә күз салсак — чыннан да, киләчәгебез өметкә урын калдырмый дигән фикергә килергә тиеш булабыз кебек.

Әмма андый нәтиҗә ясарга ашыкмыйк әле. Вәзгыять үзгәрә. Бүгенге көндә кешенең аңында гаҗәеп үзгәрешләр бара. Соңгы еллардагы иң зур ачыш, әйтергә мөмкин, тетрәндергеч ачыш — Галәмнең, андагы КЕШЕЛЕК ДӨНЬЯСЫ ТӘРБИЯЧЕЛӘРЕНЕҢ безгә ачыктан-ачык рухи ярдәм кулы сузуы. Әйе, планетабызда барган катлаулы процесслар заманында Алар безгә ярдәмгә килде. Адәми затлар белән турыдан-туры элемтә урнаштырды. Рухи үсешнең югарырак баскычында торган кешеләр белән бәйләнешкә кереп, Алар төрледән-төрле мәгълүматлар бирә, Җирдә барган хәлләрнең асылын ачып сала, кешелек дөньясы алдында торган сынау-имтихан елларында ничек яшәү, үз-үзеңне ничегрәк тоту турында киңәшләр бирә. 1995 елның 18 сентябрендә кабул ителгән хәбәрдә Планетабыз Иерархиясендәге бер Олуг Зат: *"... зур сөенеч һәм шатлык хисләре белән җир йөзендә яшәүче кеше һәм Галәмдәге Затлар арасында ачыктан-ачык диалог алып бару мөмкинлеге ачылуын билгеләп үтәбез"*, — дип белдергән иде.

Кешелек Дөньясы Тәрбиячеләренең максаты — адәми затның күзләрен ачу, аңын киңәйтү, аны булачак сынауларга әзерләү һәм саклап калу.

Әйе, кешелек дөньясы беркайчан да берьялгызы яшәмәгән, үзенең барлыкка килү көненнән үк, аның Олуг Остазлары, Иланы Тәрбиячеләре булган һәм Алар бүгенге көндә дә шушы изге вазыйфаны башкару белән мәшгульләр. Бу затлар хәзер дә кешенең һәм планетабызның эволюциясен күзәтеп торалар, Иланы Планны тормышка ашыру белән шөгыльләнәләр. Әгәр дә бүгенге көндә Алар үткән юлыбызның тирән серләрен ачып салу белән бергә киләчәккә юл да күрсәтәләр икән — димәк, без нинидер гаҗәп заманга аяк басканбыз. Ә бит кеше белән турыдан-туры элемтә урнаштыру, ачыктан-ачык сөйләшү сирәк заманнарда гына була торган хәл. Гадәттә, Иланы Тәрбиячеләр, Остазлар бу эшне сиздермичә генә алып бара. Бүгенге көндә исә Күкләрдән күпләп-күпләп хәбәрләр иңә. Хикмәт шунда ки, адәми зат Яңа Дәвергә шушы мәгълүматлар белән коралланган хәлдә аңлы рәвештә атлап керергә тиеш. Шуңа әзерлек алып барыла.

Адәми затның бурычы — Күктәге Иерархия һәм Планетабыз Тәрбиячеләренең сүзенә колак салып, алай гына да түгел — Алар куйган таләпләрне җитди кабул итеп һәм төгәл үтәп, зур сынаулар вакытында үзенең язмышын җиңеләйтү, эволюциянең башка баскычына күтәрелү.


## ГОМУМИ ВӘЗГЫЯТЬ

Җиһанда һәр нәрсә билгеле бер цикл яисә ритмга көйләнеп яши, тереклек итә. Бу очракта сүз сөекле планетабыз Җир хакында барачак.

Җир — Галәмдә ялгызы түгел, ул башка планеталар белән тыгыз бәйләнештә тора. Беренче чиратта, Җир — Кояш системасы гаиләсендә әгъза булып тора. Ә Кояш системасы үзе Плеядалар йолдызлыгы тирәсендә әйләнә, ул шушы системаның әгъзасы. Плеядалар йолдызлыгы үз чиратында Галактикабызның башка зуррак системалары әгъзасы булып тора. Шулай санап китсәң, һаман зурая-киңәя барган системаларга күчәчәксең. Кыскасы, моның чиге юк...

Бүгенге көндә Җир — Кояш системасы — Плеядалар йолдызлыгын үз эченә алган Зур Система үзенең 26 мең еллык үсеш-эволюция циклын төгәлләргә җыена. Бер үк вакытта Плеядалар системасына кергән безнең Кояш системасы үзе дә Галактика Үзәге тирәли ( Галактиканың Үзәк Кояшы тирәли ) дәвам иткән 230 миллион еллык циклын тәмамларга тора. Плеядалар йолдызлыгы вәкилләре тапшырган мәгълүматларга караганда, безнең Галактикабыз үзе дә, чиксез зур аралыклар аша узып, Галәмнең гаҗәеп

зур спирале буенча хәрәкәт итеп, Җиһанның Бөек Үзәк Кояшы тирәсендәге күп миллиард елларга сузылган бер биниһая циклын тәмамлау алдында тора икән. Кешелек Дөньясы Тәрбиячеләре биргән мәгълүматларда Галәм Спираленең бер боҗрасыннан икенчесенә күчкән чакта барлык планеталар, күпләгән кояш системалары һәм аларда тереклек итүчеләр барысы берьюлы күмәкләшеп үсеш-эволюциянең өр-яңа баскычына күтәреләләр . Галәмдә барган эволюция процессы шулай тәэмин ителә, дәверләр шулай алмашына.



*Безнең Кояш системасы һәм аның тирәсендәге йолдызлыклар (Зодиак).*

Әмма хикмәт шунда ки, бу юлы вәзгыять башкачарак булачак. Бу юлы өч төп цикл – Җирнең 26 мең еллык, Кояш системасының 230 миллион еллык, Галактикабызның миллиард елларга сузылган биниһая циклы – барысы берьюлы, бер үк вакытта тәмамланачак икән *(Ченнелинг. Послания Старших Братьев Человечества. 2-ое изд., "София", Киев, 1998.–С. 35).* Остазлар моны Галәмдә сирәк була торган хәл дип билгели һәм аның тәмамлану ноктасын 2012 елның ахыры – 2013 елның башы дип күрсәтә. Шушы вакытта планетабыз Җир, анда яшәүче барлык тереклек ияләре һәм кешелек дөньясы Яңа Дәвергә аяк басачак, ягни Бөек Күчеш чиген үтәчәк. Бу процесс ничек узар – анысы безгә билгесез. Бәлки ул, Җирдә узган Хисап көне кебек, сизелмичә генә үтеп китәр. (Хисап көне турында аерым бүлектә сөйләнер.)

Күп халыкларның борынгы риваятьләрендә, мифларында, диннәренең төп китапларында сүз нәкъ менә шушы Бөек Күчеш турында бара түгелме? Бәлки, Библиядәге – Суд Божий, Судный День; Коръәндәге – Кыямәт көне, Хисап көне; эзотерик әдәбияттагы – Армагеддон, Час "Х", День "Х", Галактик синхронлашу-тәңгәлләшү һәм башка төшенчәләр әлеге Бөек Күчешкә әзерлек чараларыдыр?

Бүгенге көндә без шушы Олуг Вакыйгага якынлашып киләбез шикелле. Әмма бу әле дөнья бетә, Ахырзаман килә дә кешелек дөньясы яшәүдән туктый дигән сүз түгел. Кеше үлемсез, мәңгелек зат булган кебек, тормыш та мәңге дәвам итәчәк. Ничек, нинди шартларда дәвам итәчәк, кемнәр бу Яңа Дәвергә атлап керергә әзер, кемнәр әзер түгел һәм... әзер булу өчен нишләргә кирәк – бу хакта алда әле сүз булыр. Хәзергә исә вакыйгаларның асылын аңларга тырышып карыйк.

## СОҢГЫ ИКЕ МЕҢ ЕЛ "КАЗАНЫШЛАРЫ"

Хөрмәтле укучым, кулымда *"Уроки о переходе на высшие уровни сознания" ("Узорочье", Рязань, 2001)* дип аталган китап. Аннан бер өзек тәрҗемә итеп, синең игътибарыңа тәкъдим итмәкче булам. Бу текст 1996 елның 30 мартында Остазларның берсеннән контактёр тарафыннан кабул ителгән. Аның белән танышу безгә Җир һәм кешелек дөньясының нинди чиктә торганлыгын, нинди дәвер кичергәнлеген ачык күрсәтер, без яшәгән дөньяны тирәнрәк аңларга ярдәм итәр, аңыбызны киңәйтә төшәр. Менә ул текст:

"Кешелек дөньясы тарихында башланырга торган дәвер күпләрнең, яшәү мәгънәсе дип атап йөртеп, туктаусыз матди байлык туплау, гел дан-шөһрәт артыннан куу кебек нәрсәләрдән торган күзаллауларын тәмам җимереп ташлаячак.

Бүгенге көндә адәм балаларына, аларның рухи асылы, Илаһи Бурычлары ачып салынган заманда, факт буларак шуны кабул итәргә кирәк: Илаһи Зат булган кешене басып-изеп торган, социаль, сәяси һәм рухи яктан аны буйсындырган барлык тормыш структуралары берниндн кызгану хисләренә урын калдырмыйча чынбарлыктан төшеп калачак.

Галәми Гакыл Планы буенча, шушы ачышны үзе өчен кулланма дип кабул иткән

адәми затка бер генә юл кала-ул да булса, бүгенге көндә Җирдә хөкем сөргән КОТОЧКЫЧ ИЗҮ СИСТЕМАСЫНЫҢ шөребенә әверелмичә, үзенең Илаһи Рухын үстерү юлына басу.

Әйе, адәми зат өчен бүген Алтын, Секс, Сатылу, Ярсу-Нәфрәт кебек һәлакәткә алып баручы, Җирдә кабат-кабат гәүдәләнүләргә илтүче юлны сайлау урынына, планетеда Яңа Расаның барлыкка килүен тормышка ашыру мөмкинлеге генә кала.

Гайсәнең Җиргә килүенә ике мең ел тулды, бу хаос, зиначылык, явызлык, ачу-нәфрәт белән тулган бик зур дәвер булды. Шушы вакыт аралыгы кешегә үзенең азгынлык, бозыклык юлыннан баруын аңлау, бу юлның өметсез икәнен күрү, Яңа Баскычка күтәрелергә әзерлек туплау өчен бик җиткән иде. Ул үткән ике мең ел эчендә Илаһи Көчләрнең аны тәрбия кылу буенча алып барган ният-гамәлләрен тәмам аңларга, Рухын үстерү өстендә эшләргә, тән таләпләрен канәгатьләндерүче азык-төлек, җылылык, уңайлыклар кебек нәрсәләрдән файдалануны мөмкин кадәр киметә барырга тиеш иде.

Әйе, Гайсә Җиргә килгәннән соң озын-озак ике мең ел вакыт узды, бу дәвердә Галәм, ифрат зур түземлек күрсәтеп, кешелек дөньясы тирә-юньгә тараткан эманацияләр *(кара энергия — С.Ш.)* агуын кабул итә торды, гәрчә, әгәр теләсә, үлекләгән бу шешне бер хәрәкәт белән төртеп тишеп, Җирнең бөтен массасын һәм анда яшәүчеләрне эретеп юк итә, иксез-чиксез Галәм киңлекләренә таратып та бетерә алган булыр иде.

Галәм Бергәлеге (Космическое Содружество) өчен артык озын тоелган ике мең ел дәвамында Үз-үзләрен Аямаучы Затлар Җир аурасында (*тирәсендә*) яшәделәр һәм адәми зат тирә-юньгә тараткан шушы пычракны чистарту белән шөгыльләнделәр. Ә бит адәми зат яралтылганда аңа, Илаһилыкның барлык орлыклары да салынып, шушы материалдан тора-бара Раббыбызга охшаш һәм Аңа тиң кемсә барлыкка килер дип өмет ителгән, бу кемсә киләчәктә Иң Югары Зат тарафыннан төзелгән Программаны тормышка ашыруда Аңа ярдәмче булыр дип көтелгән иде.

Бөтен Галәм үтә дә авыр ике мең ел буе, үз-үзенә ышанычын югалтмыйча, Раббыбыз тарафыннан яралтылган Кешенең, ниһаять, аңга килеп, үзен бар иткән Иң Югары Зат таләпләре югарылыгына күтәрелер дип көтте.

Шушы гаҗәеп четерекле ике мең ел дәвамында Галәмдә көн дә Аның яшәү нигезләрен какшату-Яхшылык, Үзара Ярдәмләшү, Бер-Береңә Юл Кую һәм Түземлеккә нигезләнгән кануннарны җимерү барды. Ә бит шушы кануннарның тайпылышсыз үтәлүе һәм Бөек Туганлык Рухын аңлы рәвештә куәтләп тору гына, һәркемнең хокуклары сакланып, Җиһанда гармонияне һәм тигезлекне тәэмин итә ала.

Ике мең ел дәвам иткән гадәттән тыш гыйбрәтле сабаклар дәвере узды-инде, ниһаять, Кискен Үзгәрешләр Заманы килде.

Шушы вакыт эчендә адәм балаларының үзләренә сиздермичә, басым ясамыйча аларга ярдәм итүнең бик күп ысуллары кулланылды, кылган гамәлләренең нинди нәтиҗәләргә китерүен аңласыннар өчен, төрледән-төрле чаралар күрелде.

Инде адәми затның кылган гамәлләренә Кырыс Бәя Бирү Заманы килде.

Инде Глобаль Масштабтагы Үзгәрешләр Заманы килде, чөнки фәкать шушы чара гына Галәмдәге хәлне стабильләштерә һәм аның киләчәк үсешен тәэмин итә алачак".

Адәми зат, аның киләчәге турындагы фикерләр әлеге Остазның 1996 елның 5 маенда тапшырган хәбәрендә дә дәвам иттерелә:

"Гайсә дөньяга килгәннән соң кешегә үзенең Рухын Баету, тәкәбберлеген җиңү, көнчелек, саранлык, бозыклык кебек сыйфатлардан арыну өчен ике мең ел вакыт бирелде. Әмма бу озын-озак ике мең еллык дәвердә кешеләр, тәмам пычракка батып, тагын да тирәнрәк түбәнлеккә төштеләр.

Гайсә дөньяга килгәннән соң кешелек дөньясының аз өлеше генә үзендә Саф Уй-Фикер, Намус һәм Хәерхаһлык саклап кала алды.

Гайсә дөньяга килгәннән соң үтеп киткән шушы дәвердә бары тик санаулы кешеләр генә акылга таянып гамәл кылуда ихтыяр көче күрсәттеләр, башкача фикер йөртүче һәм гамәл кылучыга карата түземле булып кала алдылар.

Инде менә нәтиҗә чыгарыр көн килде.

"А" дип әйтмәгәннәр — "Б" дип әйтә алмаячаклар.

Бер адым да ясамаучылар — алга үтә алмаячаклар.

Һәр нәрсәнең башы һәм ахыры бар.

Инде менә һәр тарафтан вакыйгалар якынлаша, бу кемнәр өчендер — Җирдә яшәүнең

тәгәлләнүе булыр, кемнәр өчендер — яшәешнең башка баскычына күтәрелү дәвере булыр. Ул дәвердә дөнья Явызлык һәм Сугыш дигән нәрсәләрне белмәс, анда рух ихтыяҗлары тән таләпләреннән өстен торыр, дөньяда килешеп яшәү, бер-береңне аңлау һәм, үзеңне кайгырткан кебек, бер-береңне уртак кайгырту хөкем сөрер.

Вакыйгалар шундый тизлек белән бара ки, бары 10 еллап вакыт узуга түбән тәгәрәгән һәм деградациягә төшкән кешеләрдән арынып калган Җирдә Яңа Раса торгызылачак, бу Раса — өченче меңьеллыкның чын хуҗасы булачак. Җирдә яшәп калган кешеләргә исә Галәм Бергәлегендә *(Космическое Содружество)* кабул ителгән мөнәсәбәтләрне урнаштыру бурычы йөкләнәчәк".

Әйе, Галактикада рухи үсеш ягыннан шактый артта калган, алай гына да түгел — үзенең түбән тибрәнешләре белән Галәмне пычратып торган Җир һәм анда яшәүчеләр, ягъни кешелек дөньясы, киләчәктә эволюцион үсешенең югарырак баскычына күтәрелергә тиеш булачак. Ни өчен дигәндә, кешелек дөньясына билгеле галәми стандарт югарылыгына күтәрелү өчен бирелгән вакыт инде тәгәлләнеп килә. Илаһи План бездән шуның үтәлүен таләп итә. Ә аның үтәлми калуы һич мөмкин түгел. Әлеге План үтәлмәгән очракта, без, кешеләр — Галәмдәге эволюция барышын тоткарлап торучыларга әвереләчәкбез.

Моннан ун еллар элек, 1992 елның 22 ноябрендә Остазларыбызның берсе бу хакта менә нәрсә әйткән булган: "...то, что производит эта планета, — ее больное, ядовитое дыхание, — мешает нормальному функционированию Мира, являясь гнойной язвой в теле Мироздания. Положение надо спасать. Призывается к этому все светлое, все мыслящее. Будут приняты чрезвычайные меры, которые в масштабе планеты поведут к смене цивилизации, но планету и людей на ней необходимо сохранить".

Шик юк, Галәмдәге эволюция барышын тоткарлап торучылар сыйфатында яшәргә безгә Илаһи Көчләр беркайчан да рөхсәт итмәячәк. Димәк, 1997 елның 24 июнендә Гайсә пәйгамбәр хәбәр иткәнчә: "Кеше телиме, юкмы — аңа барыбер үзгәрергә туры киләчәк. Шунсыз ул Хисап көнендә Галәмнең бер чүбе генә булып калачак. Бу бик җитди һәм котылгысыз таләп..."

Галәмдәге дустанә цивилизацияләр күптән инде безнең, ниһаять, уянуыбызны, алар белән бер сафка басуыбызны түземсезлек белән көтә. Әмма һәр нәрсәнең бер чиге була. Шуңа күрә без, кешеләр, язмышыбызны куркыныч астына куеп яшәгәнче, мөмкин кадәр тизрәк рухи үсеш юлына басарга тиешбез. Күкләрдән иңгән кисәтүләргә колак салырга теләмәгән, һаман элеккечә яши биргән, киләчәктә дә тормыш шулай барыр дип уйлаган кешеләр үзләренә нинди аяныч язмыш әзерләүләрен аңлыйлар микән?

Санаулы гына калган еллардан соң безнең Галактикада синхронлашу-тәңгәлләшү *(Галактическая синхронизация)* дип аталган процесс көтелә, бүгенге көндә шуңа әзерлек бара. Бу процесстан , күк җисемеме ул, әллә инде аерым бер кеше генәме, — беркем һәм бернәрсә дә читтә торып кала алмаячак. Бу — Илаһи План белән алып барыла торган олуг эш. Бу очракта адәми затка Раббыбыз Планын ирекле рәвештә кабул итү һәм үзеңне Аның ихтыярына тапшыру альтернативасы гына кала. Башка юл юк. Карышып маташучылар үзләре утырган ботакны кисә, шәхси эволюцияләрен тоткарлый.

## ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ БӨЕК КҮЧЕШ

Күп тә үтмәс планетабызның бер зур үсеш циклы тәмамланыр һәм кешелек дөньясы Яңа Дәвергә аяк басар. Моны Җир тарихы, аның эволюциясендәге иң зур вакыйга дип атарга мөмкин. Кешелек Дөньясы Тәрбиячеләре җиткергән мәгълүматларга караганда, ул көнгә хәтле һәм Җирнең үзендә, һәм башка күк җисемнәрендә байтак үзгәрешләр булып узачак. Шуңа бу процессны "Галактик синхронлашу-тәңгәлләшү" дип атаганнардыр, күрәсең.

Контакт аша бирелгән хәбәрләрдә сүз нинди үзгәрешләр турында бара соң? *(Ченнелинг. Послания Старших Братьев Человечества. 2-ое изд., "София", 1998.–С. 36).*

**Беренчедән**, планетабызның күчәре авышачак, шул сәбәпле полюслар да күчәчәк. Бу хәл Җирдәге климатик зоналарның үзгәрүенә китерәчәк.

**Икенчедән**, бу процесс Кояшыбызның үзенә дә кагылачак. Ул Плеядалар йолдызлыгы системасына карата торышын үзгәртәчәк, аның да полюслары урыныннан күчәчәк. *(Искә төшереп үтик, моңарчы Кояшыбыз Плеядалар йолдызлыгы системасының үзәк йолдызы Алкиона тирәли әйләнә иде.)*

**Өченчедән**, Плеядалар йолдызлыгы үзе дә Орион йолдызлыгына карата торышын үзгәртәчәк.

**Дүртенчедән**, Галактикабызда барган ка́рмик чистарыну процессы Орион йолдызлыгына да кагылачак, бу йолдызлык та, зур тетрәнүләр, сынаулар аша узып, алардан рухи яктан пакьләнеп чыгачак. Аның да полюслары күчәчәк. Шушы вакыйгалардан соң Орион йолдызлыгы Галактика Үзәгенә Үтү Капкасы *(Портал)* вазыйфаларын башкара башлаячак.

**Бишенчедән**, 2013 елга кадәр Сириус йолдызлыгы, үз эволюциясенең рухи үсеш имтиханын тапшырып, безнең Галактикада рухи үсешне тизләтү үзәгенә әвереләчәк. Эзотерик әдәбиятта моны "Мистерияләр мәктәбе" дип атап йөртү гадәте дә бар. *(Мистерия сүзенең нигезендә грекча "ябык авыз" дигән мәгънә ята. Борынгы заманнарда махсус сайлап алынган яшьләрне, киләчәктә алардан рухи житәкчеләр-лидерлар тәрбияләү өчен, гыйбадәтханә мәктәпләрендә укытканнар. Укуның нинди дер баскычына житкәч, аларга Жиһанның тирән серләрен ачканнар. Бу еш кына спектакль сыман тамаша кую рәвешендә үткәрелгән, укучылар анда төрле аллалар ролен башкарганнар, шулай тамаша барышында күп серләрне истә калдырганнар. Әлбәттә, бу хакта кемгә дә булса сөйләү катгый тыелган. Шуңа күрә бу процесс "мистерия"-"ябык авыз" дигән исем алган.)* Димәк, Сириус йолдызлыгы киләчәктә без яшәгән системада Мистерияләр мәктәбенә, ягни рухи үсешне тәэмин итү мәктәбенә әвереләчәк.

**Алтынчыдан**, Галактикабызда барган шушы глобаль үзгәрешләр нәтиҗәсендә 2013 елга кадәр бөтен Плеядалар йолдызлыгы Сириус тирәсендәге орбита буенча хәрәкәт итә башлаячак. Шулай итеп, Сириус йолдызлыгы Галактиканың бу канатындагы Үзәк Кояшка әвереләчәк, ягъни Яңа Дәвердә Плеядалар йолдызлыгы үзенең җитәкче ролен Сириус йолдызлыгына тапшырачак. Димәк, безнең Кояш системасы да киләчәктә Сириус йолдызлыгына йөз тотып яшәячәк.

Менә нинди глобаль характердагы үзгәрешләр бара хәзер! Һәм бүгенге көндә Җирдә барган процесслар шуның бер элементы гына булып тора. Әгәр дә без бүгенге яшәешебезгә шушы галәми үзгәрешләр күзлегеннән чыгып карый алсак, без җан атып, юкка йөрәк бозып йөргән бик күп нәрсәләр, биһисап мәсьәләләр бер чүп кенә булып калачак һәм ... тормышның асыл мәгънәләре ачылачак. Бу чын мәгънәсендә тормышка реаль караш ташларга ярдәм итәчәк.

Чыннан да, кеше дигәнең, җир өстендә үрмәләгән бөҗәк кебек, үзенең Илаһи Зат булуын бөтенләй диярлек онытты, коточкыч дәрәҗәдә вакланды, үз тормышын әһәмияткә лаек булмаган нәрсәләр белән шыплап тутырды. Ни белән генә шөгыльләнми дә, нинди генә вактан-вак максатлар өчен көчен сарыф итми?

Ә Галәм һәм Заман бездән бөтенләй башканы көтә, юк – таләп итә, зур вакыйгалар күптән инде ишегебезне шакый. Ишетәбезме, күрәбезме, әллә инде һаман ишетмәмешкә, күрмәмешкә салышып яшибезме? Адәм балаларының һаман уяна алмыйча, йокымсырап яшәвен күреп торган Раббыбыз, Кешелек Дөньясы Тәрбиячеләре, Галәмдәге Остазлар бүгенге көндә чаң кага: "Вакытлар төкәнеп килә, инде төкәнде диярлек, күзләрегезне ачыгыз, аңга килегез, рухи яктан тизрәк уяныгыз!" – диләр алар. Шулай безне коткарып калырга, кешене Галәмнең аңлы хезмәткәре, Раббыбызның җир йөзендәге ярдәмчесе дәрәҗәсенә күтәрергә тырышалар.

Контактёрлар аша Алардан күпме хәбәрләр килде, күпме кисәтүләр яңгырады һәм яңгырап тора. Тәрбиячеләребез, Остазларыбызның төрле китапларга, җыентыкларга тупланган күпме вәгазьләре-диктовкалары басылып чыкты. Шуңа да карамастан күпчелек кешеләр аларга һаман илтифат итми, ышанып бетми, шикләнеп карый, ә кайберәүләр андый әдәбият барын гомумән белми. Галәмдә һәм Җир планетасы аурасында нәфис тәндә Кешелек Дөньясы Тәрбиячеләре яшәвен факт буларак һаман кабул итә алмый. Күпләрнең аңы борынгы заманда бирелгән, хәзер инде берничек тә дөньяны аңлата алмый торган дини мифология йогынтысында кала бирә. Тәрбиячеләребезнең гасырлар гына түгел, меңәр, миллион елларга сузылган дәверләр дәвамында кешелек дөньясын кайгыртып яшәвен аңлаудан күпләр әле ерак тора. Мондый аң белән үзенең киләчәккә үтә алмаячагын кеше, ниһаять, аңларга тиеш.

* * *

Алда алты пункттан торган глобаль үзгәрешләр манзарасы тасвирланды. Мин аңлыйм, мондый мәгълүматны кабул итәргә әзер булмаган кешеләрнең хисси яктан шактый кыен хәлдә калулары да бик ихтимал. Аңлашылып җитмәгән нәрсә еш кына күңелдә шик-шөбһә уята, хәтта нәфрәт тә тудыра бит ул. Укучыларымның кичерүен үтенеп, шуны әйтәсем килә: мин бу мәгълүматларны кемнедер шаккатыру өчен китермәдем. Алар барысы да соңгы ун елда басылып чыккан җитди китаплардан алынды. Бу елларда мин үзем өчен бер зур сер ачтым — берәр җитди мәсьәлә белән чынлап торып кызыксына башласаң, сиңа кирәкле китаплар, кешеләр, мәгълүмат үзеннән-үзе килеп керә башлый икән! Ягъни рухи ярдәм килә. Без барыбыз да Раббыбыз һәм Аның күп санлы ярдәмчеләре күзәтүе астында яшибез. Алар безнең һәр адымыбызны, хәтта уйлаган уебызга кадәр белеп тора. Туры юлга баскан һәр кешегә Алардан ярдәм килә.

Әйе, соңгы елларда, дөньяның буталуы сәбәпле, үз юлыңны табу шактый кыен мәсьәләгә әверелде, чөнки юлдан яздыручылар да бик нык активлашып китте. Элекке бик күп кыйммәтләр әһәмиятен югалтты. Күпчелек киләчәктә нәрсә буласын белми, алда яктылык күрми. Бу хәл кешеләрдә зур борчылу, эчке тынычсызлык тудыра, өметне какшата. Һәм шуның нәтиҗәсендә кешеләрдә тискәре хисләр, омтылышлар өстенлек ала.

Чыннан да, киләчәктә ни көткәне ачык булмагач, бүген яшәп калу, алыр нәрсәне теләсә-нинди ысул белән умырып алу, яшәешнең төп мәгънәсен рәхәтрәк яшәүгә кайтарып калдыру философиясе чәчәк ата түгелмени? Телевидение дә нигездә шушы юнәлештә эш алып бара. Бу шартларда дөньяның кая таба юнәлеш тотуын төгәл һәм фәнни рәвештә аңлау, алда торган зур сынаулар чорында үзең өчен ачык перспектива күрү үтә дә мөһим мәсьәләгә әверелә. Остазларыбыз һәм аларның җир йөзендә таралган шәкертләре шуны аңлату эше белән шөгыльләнә дә. Бу — Раббыбызның безгә ярдәм кулы сузуы, чөнки Җирдә һәр нәрсә адәми зат кулы белән башкарыла.

Уйлап карасаң, без чыннан да гаҗәеп кызыклы һәм гыйбрәтле заманда яшибез икән бит, әй! Бәхетле, сайлап алынган җаннарга гына мондый заманда Җирдә яшәү мөмкинлеге бирелә булса кирәк.

## 26 МЕҢ ЕЛЛЫК ЦИКЛ ХИКМӘТЛӘРЕ

Әйтергә кирәк, без хәзер Җир — Кояш системасы — Плеядалар йолдызлыгын үз эченә алган зур системаның 26 мең еллык эволюция циклы тәмамлану алдында торабыз. Кайбер чыганакларда аны Бөек Ел *(Великий Год)* дип тә атыйлар. Бу процесс фәндә "прецессия" дип атап йөртелә. Аның мәгънәсе нидән гыйбарәт соң?

Иң элек Җирнең (Кояш системасы белән бергә) Плеядалар йолдызлыгы тирәсендәге 26 мең еллык юлын ике яктан бераз кысылган кыршау-эллипс рәвешендә күз алдына китерик. Җир күчәре аша үткәрелгән туры сызык прецессияне күрсәтә. Шуның нәтиҗәсендә 26 мең елга тиң озын юлны хасил иткән озын юл-эллипс барлыкка килә. Эллипсның уң ягы Галактика Үзәгенә таба төбәлгән, сул ягы аннан иң ерак ноктада урнашкан. Җир шушы орбита буенча күктә гизгәндә Зодиакның 12 йолдызлыгы аңа чиратлашып тәэсир итә *(Кучкар, Үгезбозау, Игезәкләр, Кысла һ.б.)*, ягъни Җир шушы 26 мең еллык юлын үткәндә һәр йолдызлыкның көчле нурланышын тоеп тора. Шулай без 26 мең еллык циклны 12 йолдызлыкка бүлсәк, һәрберсе 2000 елдан аз гына артык булган (2160 ел) 12 дәвер барлыкка килә. Хәзерге көндә без Балык йолдызлыгыннан Сукояр йолдызлыгына күчтек. Бу хәл нинди үзгәрешләр китереп чыгарачак соң?

Хикмәт шунда ки, һәр йолдызлык Җиргә үзенә хас нурланышлар бирә һәм бу нурланышлар планетага, андагы табигать патшалыкларына, стихияләргә, хайваннар дөньясына, һәр кешегә һәм тулаем кешелек дөньясына үзенчә тәэсир итә. Икенче төрле итеп әйткәндә, һәр йолдызлык, планетабызны махсус нурланышларда коендырып, үзенә хас махсус эш башкара.


Әйтик, соңгы 2 мең ел эчендә планетабыз Балык йолдызлыгы тәэсирендә яшәде. *(Әлбәттә, Җиргә бер үк вакытта башка йолдызлыклар да тәэсир итә. Әмма бу очракта сүз иң көчле, төп йогынты турында бара.)* Балык йолдызлыгыннан килгән нурланышлар кешелек дөньясында нигездә Тугрылык һәм Идеализм хисләре тәрбияләде. Шул сәбәпле

Җирдә хөкем сөргән күпчелек идеологияләр Тугрылык һәм Идеализм хисләре белән сугарылган иде *(коммунизм, фашизм, социализм, милләтчелек, шовинизм, ватанпәрвәрлек, бер динне генә бердәнбер хак дин дип санау һ.б.)*

Башланып киткән Сукояр йолдызлыгы дәверендә *(ул да 2 мең ел дәвам итәчәк)* планетабызга килә торган нурланышлар шартлы рәвештә Церемониаль Тәртип энергияләре дип атала. Алар Җир йөзендәге цивилизациянең йөзен тамырдан үзгәртеп корачак, цивилизациянең яңа формаларын барлыкка китерәчәк. Тормышның зур тизлек белән үзгәрә баруы нәкъ шул хакта сөйли. Һәм иң мөһиме—Сукояр йолдызлыгы дәверендә кешелек дөньясына Йокыдан Уяну һәм Берләшү мөмкинлеге ачылачак. Адәми затның киңәйгән аңы Галәм киңлекләренә чыгачак. Табигый, бу процесслар һәм нурланышларның шулай чиратлашып тәэсир итүе Иләһи План кысаларында алып барыла.

Әмма 26 мең еллык циклның, ягъни прецессиянең тагын бер хикмәтле үзенчәлеге бар (сызымны кара).

Борынгы заманнарда ук акыл ияләре планетабызның Галактика Үзәгеннән ераклашкан чакта ничектер "йокыга талуын", ә якынлашкан чакта исә киресенчә "уяна" башлавын сизеп алган булганнар. Биредә сүз кешелек дөньясы аңының "йокыга талуы" һәм "уянуы" турында бара.




Җир эллипс рәвешендәге шушы орбита буенча Галактика Үзәгенә таба хәрәкәт иткәндә, планетабыз акрынлап яшәешнең рухият чәчәк аткан гүзәл һәм бөек дәверенә якынлаша. Бу чорда Җир гүяки йокыдан уяна, тормыш торган саен камилрәк төс ала. Тулы камиллеккә ул эллипсның Галактика Үзәгенә иң якын торган ягында ирешә. Бу дәвер борынгы чыганакларда Алтын Гасыр *(санскрит телендә—Сатья Юга)* дип атала. Һәм киресенчә, Алтын Гасыр дәверен үтеп, аннан ераклаша барган саен Җирдә рухият сүрелә, тормыш үзе дә, андагы тәртипләр дә кырыслана бара, планетабыз рухи яктан гүя "йокыга тала".

Ә инде Җир үз орбитасының Галактика Үзәгеннән иң ерак ноктасына барып җиткәндә планетада гадәттән тыш кырыслык һәм вәхшәт хөкем сөрә—бу дәвер борынгы чыганакларда Тимер Гасыр *(Кали Юга)* дип атала. Шунысы кызык, Җирдә кискен үзгәрешләр эллипсның капма-каршы урнашкан **А** һәм **Б** ноктaларында түгел, ә аларны узып 900 ел вакыт үткәннән соң гына башлана. Әйтик, Алтын Гасырдан чыгу, Б ноктасын үтеп, 900 ел вакыт үткәч кенә башлана **(Г ноктасында)**. Шулай ук кырыслык һәм вәхшәт тулы Тимер Гасырдан соң планетада кабат рухият уяна башлау да **А** ноктасыннан соң 900 ел вакыт үткәч үз көченә керә **(В ноктасында)**. Бәхеткә, бүгенге көндә кешелек дөньясы, үсешенең Тимер Гасыр дәверен узып, планетабызның "уяну" чорына аяк басты. Планетадагы һәм тормышыбыздагы кискен үзгәрешләр фәкать шуның белән аңлатыла. Без хәзер Галактика Үзәгенә торган саен якыная барачакбыз. Әмма Алтын Гасырга керү өчен кешелек дөньясына әле тагын берничә мең ел кирәк булачак.

Борынгы чыганакларда телгә алынган Алтын Гасыр белән Тимер Гасыр төшенчәләре һич тә шагыйранә чагыштыру түгел, ә Җир тарихында булып узган конкрет дәверләр,

мәгълүм закончалыкка буйсынып алмашынып торган цикллар булып тора. Бер-берсеннән бик зур вакыт аралыгында торулары сәбәпле *(13 мең ел)* кешелек дөньясы аларны оныта барган. Һәр "йокыга талу" дәверендә, кешелек дөньясының акылы шактый саега төшеп, кешеләр ирешелгән бик күп казанышларын югалта, оныта торган булганнар. Элек ирешелгән биеклеккә һәм аннан да югарырак баскычка – Алтын Дәвергә таба хәрәкәт иткәндә яңабаштан күтәрелергә туры килгән. Шулай Галәм безне, бер утта кыздырып, бер суга чумдырып дигәндәй, тәрбия кыла, даими сыный, чыныктыра, иләк аша уздыра һәм шушы имтиханнарны узган җаннарны гына эволюциянең яңа дәверенә үткәрә.

Әйтелгәнчә, хәзерге көндә кешелек дөньясы гадәттән тыш озын һәм авыр тоелган, адәми затны бастырып торган, зур корбаннар таләп иткән Тимер Гасырдан чыкты. Дөресен әйтергә кирәк, кеше аннан гаять кырысланып, кыргыйланып, рухияттан, Раббыбыздан бик нык ераклашып, матдиятчылыкка тәмам кереп баткан хәлдә чыкты. Хәзер Җирдә елдан-ел рухият арта, дөнья торган саен яктыра, камилләшә барачак. Бу яктан бернинди дә шик-шөбһә, өметсезлек, икеләнү булырга тиеш түгел. Безгә хәзер Җир эволюциясендәге шушы закончалыкны аңлап яши башларга вакыт җитте. Бүгенге көндә планетабызда барган процесслар шул хакта сөйли. Яңа Дәвергә керү алдыннан чистарыну, искедән арыну процессы бара. Раббыбыз безне шуңа әзерли. Шик юк, Туган Йортыбыз Җирдә шундый эшләр барганда һәр кешедән аңа үз өлешен кертү, нур чәчеп торучы бер якты ноктага әверелеп яшәү сорала. Шулай булганда әлеге процесс бермә-бер тизрәк барачак.

## АДӘМИ ЗАТТАН НИ ТАЛӘП ИТЕЛӘ?

Шушы сынау елларында адәми зат нинди таләпләргә җавап бирергә, үзендә нинди сыйфатларны үстерергә һәм нинди кимчелекләрдән арынып өлгерергә тиеш соң? Эзотерик әдәбиятта бу таләпләр ап-ачык итеп куела, чөнки үз көченә кергән Планетар канун аларның һәр кешегә җиткерелүен таләп итә.

Һәр кеше сынауларны уңышлы үтү, эволюциянең яңа дәверенә атлап керү өчен ТӨП ДҮРТ ПРИНЦИПНЫ аңларга тиеш. Нинди принциплар соң алар?

**Беренче принцип** – кеше Җирдә яшәгәндә физик үсеш, хис һәм акыл ягыннан мөмкин кадәр югарырак, камилрәк баскычка күтәрелергә тиеш.

**Икенче принцип** – кеше үзенең Илаһи Зат икәнлеген белергә, җанының Раббыбыздан бүленеп чыккан Нур һәм Ярату хисеннән хасил булуын аңлап яшәргә тиеш.

**Өченче принцип** – кешенең ихтыяр ирке Җиһанда беркем тартып алалмый торган универсаль хокукны тәшкил итә. Шуңа да карамастан, Раббыбыз мисалындагы бөек идеал кешене Аның ихтыярына буйсынып яшәргә чакыра, кешедән шуны өмет итә.

**Дүртенче принцип** – аерым кеше таләпләренә җавап бирү-бирмәүгә карамастан, Җиһан – Раббыбыз тарафыннан яралтылган изге нәрсә. Адәми зат моны аңлап яшәргә тиеш.

Кешелек Дөньясы Тәрбиячеләре әйтүенчә, бүгенге көндә шушы дүрт принцип Галәмнән килгән нурланышлар тәэсире белән дә, җир йөзендәге гаммәви мәгълүмат чаралары аша да һәр кешенең исенә төшерелә. Ләкин күпчелек моны күңеле белән сизенсә дә, ачык итеп аңлау дәрәҗәсенә һаман әле күтәрелә алмый. Җирдә эволюциянең төп цикллары тәмамланганда, кешелек дөньясы Хисап көне сынауларын үткәндә боларны һәр кеше ачык белергә-аңларга тиеш. Үтиме, юкмы – аның үз эше. Шулай адәми зат үз язмышын үзе хәл итә булып чыга. Бу очракта Остазларыбызның тагын бер сүзен искә төшереп үтү урынлы булыр: "Кем сүзебезгә колак салмый, шул үз-үзенә каршы бара", – диләр алар. Моны андый кеше һәлакәткә бара дип аңласак та арттыру булмастыр.

Укучылар инде игътибар иткәндер, алда күрсәтеп үтелгән дүрт төп принцип яшәешнең гомуми якларына кагыла. Аларга конкретрак килгәндә, кеше нинди төп кимчелекләрдән арынырга тиеш дип үз-үзебезгә сорау биргәндә – аларның күзгә бәрелеп торган җидесе түбәндәгеләр була:

1. Эрелек, тәкәбберлек, мин-минлек;
2. Берәр нәрсә белән чамадан тыш мавыгу;
3. Берәр нәрсә яки кеше турында алдан фикер чыгарып кую;

4. Дошманлык саклау;
5. Кемне дә булса буйсындырырга омтылу, көчләү;
6. Юкка корбан бирү;
7. Юк нәрсә өчен оялу, гарьләнү.

Тормыштан берничә мисал китереп үтик. Әйтик, бай атасы алып биргән затлы машинада йөргән берәр егет яки кыз хезмәт хакы алалмый интеккән гаиләдә яшәгән яшьтәшенә мыскыллап караса; берәр җитәкче кеше субординация саклау белән артык мавыкса – бу гамәлләр инде эрелек, тәкәбберлек, мин-минлеккә керәдер.

Кемдер кием-салымына, тышкы кыяфәтенә чамасыз игътибар бирсә; икенче берәү эчүчелек , секс, хоккей, футбол, шахмат, балык тоту, бизәнү әйберләре тагу, мал җыю һ.б. белән артык мавыкса; машинасы, дачасы, йорты өчен дер калтырап яшәсә – болар да чамасыз мавыгуга керәдер.

Берәү милләтенә, тышкы кыяфәтенә карап кына башка кеше турында тискәре фикердә булса, укымаган китап, карамаган фильм яки спектакль турында начар фикер әйтсә – моны да алдан фикер чыгару дип бәяләргә туры килә.

Ә дошманлык саклау Россиядә гомумән киң таралган күренеш. Рус булмаган милләт вәкиленә кимсетү сүзләре әйтү яки аңа карата бер сәбәпсез начар мөнәсәбәт саклау; бер дин тарафдарының икенче диндәге кешене өнәмәвен дә чикләнгәнлектән килеп чыккан дошманлык саклау дип әйтергә мөмкиндер.

Ата-ананың баланың теләгеп искә алмыйча аны берәр төрле һөнәр сайларга мәҗбүр итүе; гаиләдә берәүнең башкаларга гел басым ясап торуы да көчләү галәмәтенә керәдер.

Ил эчендә алып барылган сугышларда бер гаепсез солдатларның һәм гражданнарның күпләп һәлак булуы; аучыларның, балыкчыларның кирәгеннән артык кош-корт, җәнлек ату, балык тоту белән мавыгуы, күбәеп киткән машиналарның эт, мәче, кешеләрне таптатуы кебек нәрсәләр дә юкка корбан бирүгә керәдер.

Һәм кимчелекләрнең соңгысы – юкка оялу һәм гарьләнү гадәте. Әле хәтерлибез – теге елларда татар халкына карата яшәгән начар мөнәсәбәт аркасында милләттәшләребезнең байтагы үз телендә сөйләшергә ояла, кайберләре гомумән үзләренең татар милләтеннән булуын яшерә, татарлыгыннан гарьләнә, исемен рус исеменә алыштыруга кадәр барып җитә иде. Бу яман гадәт тә юкка оялу, гарьләнү галәмәте түгелмени? Шулай ук илдә байлар белән ярлылар катламы арасында артык зур аерма барлыкка килү сәбәпле соңгыларының үз фәкыйрьлегеннән оялып яшәве дә юкка оялуга керә.

Бер сүз белән әйткәндә, һәм кеше, һәм җәмгыять арынасы кимчелекләр – үзебез күреп җиткермәгән яки күреп тә арынырга теләмәгән яман гадәтләр бездә әле буа буарлык. Һәм шушы елларда мондый чүп-чардан котыла барырга, күптән җыелып килгән мәсьәләләрне хәл итәргә, кармик төеннәрне чишәргә кирәк. Яңа Дәвергә кеше пакь зат буларак керергә тиеш, диелә Остазларыбыздан алынган хәбәрләрдә.

*Дәвамы киләсе санда*

*Хәтер*

Тәлгат Галиуллин

# ФИДАКАРЬЛЕК

Татар әдәбиятына талантлар элек төрле төбәкләрдән килеп кушылганнар дип, исемнәрне санау Һ. Такташ, Ш. Камал, М. Җәлил, Г. Кутуй, Г. Әпсәләмовлар белән башланып, Самара өлкәсенең Камышлы районына килеп чыга торган иде. Чөнки бу төбәктән татар шигъриятенең аһәненә кабатланмас яңалык өстәгән ике шәхес килә: Әнвәр Давыдов һәм аның укучысы, дәвамчысы Рөстәм Мингалимов.

Беренчесе поэзиягә Г. Хуҗи, З. Мансур, Ш. Мөдәррис, Н. Арслановлар сафында фронтовик-шагыйрь, 1941—1945 ел сугышының бөтен авырлыкларын татыган җинүче укчы булып, буаларны алып ташлаган язгы ташкындай, кинәт килеп керде һәм якты йолдызлар белән бизәлгән татар шигърияте күгендә Әнвәр Давыдов йолдызын кабызып җибәрде. Баксаң, ул инде сугышка чаклы ук шактый катлаулы тормыш юлы үткән икән. Әнвәр яшьли үз көнен үзе күрергә өйрәнә, укытучы, илнең төрле төбәкләрендә татар, рус газеталарында журналист була, соңрак редактор, Казанга күчеп килгәч, Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы секретаре һәм, ниһаять, профессионал язучы... Ул тиз арада үзен проза, драма алымнарын кушып алып бару сәләтенә ия эпик поэзия тарафдары итеп таныта. "Югары уңыш өчен", ""Коммунизм таңы" колхозында", "Беренче бөртек", "Ташу" поэмаларында ул авыл, колхоз тормышын, аларның кешеләрен язмышлар бәрелеше, конфликтлар чишелеше аша сурәтләүгә ирешә. Укучылар Ә. Давыдовның образлы фикерләвенең һәм слүбенең үзенчә булуына, сөйләм теле үзенчәлекләре белән бизәлгән ритмик-интонацион шигырьгә өстенлек бирүенә игътибар иттеләр. Ул, нәкъ остазы Такташ әйтеп калдырганча, көйләү алымын сөйләм интонациясе белән алыштыра, кеше рухының тирәндәрәк яткан хасиятләрен ачу мөмкинлекләрен табигыйлегендә сынландыруның яңа юлларын эзли, татар теленең мөмкинлекләре чиксез икәнлекне исбатлый. Аның омтылышлы, эчке җегәрле, кайнар сулышлы, ярым тоннарны, пышылдап сөйләшүләрне танымый торган слүбен, халыкчан моңын башка шагыйрьләр белән бутавы мөмкин түгел иде. "Әнвәр Давыдов стиле" дигән төшенчә туа. Бу стиль юнәлешенә патетик-тантаналы аһәң белән беррәттән зәңгәр чәчәк күзәнәгендә кешенең моңсу күзләрен күрә белгән тирән лирик хисле, әнисен изгеләштергән, башка милләт шовинистларына туган телен яклап кискен сүзен әйтә алган интонация дә сыеша. Матбугатта чыгуга, "Себер трактында квартал", "Чорлар чатында" кебек урбанистик поэзия ачышларын фәлсәфи тирәнлек, гасыр сулышын йөрәк хисләре белән куша алган шигырь-поэмаларны яшьләрнең, бигрәк тә студент халкының журналны, аннан җыентыкны дәррәү укыганы, фикер алышканы һаман хәтердә.



Үзе исән чагында ул татар һәм рус телләрендә егерме өч китап чыгарып калдыра. Үзе үлгәннән соң, "Дәверләр диалогы" (1969), "Йокысыз төннән соң: роман-симфония" (1972), "Җылы сулыш" (1975), "Кояшлы көн хакына" (1979) исемле китаплары чыга. 1984 елда Р. Мингалимов белән А. Нарбеков әдипнең "Түгәрәк

бәхет" исемле җыентыгын әзерләп бастыралар. Ә.Давыдовның "Муса абый" повестен, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре турында уйлануларын, хикәя һәм скетчларын эченә алган китапны укучы яхшы кабул итте. Кызы белән кияве үз хисапларына *(димәк, иманлы җаннар)*, Р. Мингалимовның садә кереш сүзе белән, "Ташу" (1999) җыентыгын тәкъдир итеп, шагыйрь иҗаты турындагы күзаллавыбызны тулыландырып, рухи дөньябызны баетып җибәрделәр.

Шул хәтлесе дә ачыкланды: Ә. Давыдов каләменнән төшкән һәр сүзен матбугатка күтәреп бармаган, шигырь-поэмалар язу белән беррәттән, прозада, публицистикада көчен сынаган, милләтен дөнья поэзиясенең гүзәл үрнәкләре белән таныштырырга омтылып, бик теләп тәрҗемә өлкәсендә эшләгән.

Ашыккан. Фронттан кайткан яра-җәрәхәтләрнең үзенә озын гомер бирмәсләрен сизенгәндәй бик күп эшләгән. Иҗаты гөрләп чәчәк аткан чорда шагыйрь фани дөньяны ташлап китә. Бай архив калдыра, дидек. Ә. Давыдовның мирасын өйрәнеп, вакыт сынавын узганнарын укучыга кайтару юлында шагыйрьнең туганы—галим, публицист Альберт Нарбеков һәм якташы шагыйрь Рөстәм Мингалимов игелекле эш башкаралар. Шул мәрхәмәтле затлар шагыйрьнең тәрҗемә әсәрләрен җиз иләк аша уздырып, вакыт сынавын узганнарын сайлап алып, "Сукмак салдым" һәм "Урланган кояш" бүлекләренә туплап, "Кинлекләр" исемле җыентык төзегәннәр. Чынында бу китап 1987 елда ук матбугатка әзерләнгән иде, әмма ул чорда илдә килеп чыккан катлаулы вәзгыятьләр нәтиҗәсендә дип уйлыйм, җыентык дөньяга чыга алмыйча калды. Мәҗмуга үз эченә күренекле татар совет шагыйре Ә. Давыдовның төрле чорлардан һәм милләтләр поэзиясеннән тәрҗемә ителгән әсәрләрен эченә ала, шагыйрьнең әлегәчә укучыга бик аз билгеле мирасын *(аның В. Маяковский иҗатыннан тәрҗемәләре генә безгә яхшы таныш иде)* тәкъдим итә.

Иң элек татар җәмәгатьчелеген (ул ике телле башка милләт халыклары өчен дә актуаль проблема) борчыган, туктаусыз игътибар үзәгендә торган мәсьәләгә тукталып үтү кирәк булыр шикелле. Рус телен яхшы белгән, Пушкин, Лермонтов, Блок, Маяковский, Багрицкий, Есенин һ.б. шагыйрьләр иҗаты белән оригиналда таныша алган укучы тәрҗемә әсәрләрне кызыксынып кабул итәрме? Әллә ул тәрҗемәне читкә куеп, шагыйрьләрне үз телләрендә укуны мәгъкульрәк күрерме? С. Маршак Шекспир сонетларын русчага тәрҗемә итеп дан казанган икән, моның сәбәбе бар, ул заманда инглиз телен белүчеләр күп түгел иде, диярләр. Шуның өстенә татар шагыйрьләренең күбесе Байрон, Гете, Беранжеларны турыдан-туры түгел, ә рус теле аша тәрҗемә итәләр.

Ә шулай да шагыйрьләр тәрҗемә эшенә алына, үз укучысын таба тора. Өлкән шагыйрь Ә. Исхакның "Илһам чишмәләре" исемле тәрҗемә әсәрләрдән торган шигъри җыентыгын җәмәгатьчелек заманында яхшы кабул итте. Марс Шабаевның нигездә уңышлы тәрҗемәләре өчен Тукай исемендәге республика премиясенә лаек булганы да мәгълүм.

Димәк, тәрҗемә өлкән буын укучы өчен дә, культура казанышлары белән үзара алышу максатыннан чыгып та, шигъри осталык мәктәбе буларак та яшәргә тиеш. Мәсьәләнең соңгы өлешен генә алыйк. А. Ахматова, Дж. Байрон, В. Хлебников, В. Маяковский, Э. Межелайтис кебек гаять үзенчәлекле, үзләренә бер шигъри дөнья тудырган сүз осталары әсәрләрен башка, шул исәптән татар телендә яңгырату җиңел шөгыль түгел. Бу эш маһирлык, шагыйрьнең иҗат процессына, фикерләү рәвешенә тирәнтен үтеп керүне таләп итеп кенә калмый, үз ана теленнең мөмкинлекләрен белеп эш итүне, аның сурәтлелек мөмкинлекләрен кинәйтүне, тирәнәйтүне таләп итә. Уңышлы тәрҗемә әсәрләр милли тел-стиль бирәмлекләрен, просодияне, ритмиканы баета.

Менә шуңа күрә Р. Мингалимов һәм А. Нарбеков шагыйрь Ә. Давыдовның тәрҗемәләрен бер кульязмага туплап, файдалы һәм кирәкле эш башкарганнар, әйткәнемчә, иң яхшы үрнәкләрне зәвык белән сайлап алганнары да күренеп тора.

Ә. Давыдовның тәрҗемә өлкәсендәге иҗат диапазоны гаять киң. Биредә борынгы төрекмән шагыйре, төрки дөньясы акыл иясе Мәхтүмколый, инглиз, немец, чех, украин һ.б. милләтләр поэзиясеннән үрнәкләр, рус классик һәм совет чоры шагыйрьләре иҗатыннан тәрҗемәләр... Арада гаять уңышлылары да, тагын да камилләштерүне таләп иткәннәре дә бар, әлбәттә. Шагыйрь классиклар иҗатын

татарча яңгыратуга өстенлек бирсә дә, Иван Никитин, Юрий Яковлев кебек бик үк танылмаган шагыйрьләр иҗатында да энҗе-мәрҗәннәрне таба белгән.

Ә. Давыдов үзенең фикерләү рәвешенә, хисси дөньясына якын шагыйрьләрне аеруча дәртләнеп, илһамланып, ялкынланып, аларның рухына тирәнтен үтеп кереп тәрҗемә итә. М. Исаковский, А. Твардовский, Р. Халид, Г. Голәм, Г. Гейне кебек шагыйрьләр үзләре исән булып, тәрҗемәләрне укый алсалар, авторга үпкәләмәсләр, рәхмәт хисләрен белдерерләр иде. Дүрт шагыйрь иҗаты Ә. Давыдов илһамын аерата уятып җибәрә: Мәхтүмколый, Н. Вапцаров, Т. Шевченко, Э. Межелайтис. Һәр шагыйрь аңа үзенчә якын, газиз. Төрекмән поэзиясе классигы Мәхтүмколый аңа афористик фикерләве, әхлак мәсьәләләренә игътибары, болгар шагыйре Н. Вапцаров язмышы һәм иҗаты белән М. Җәлилгә якынлыгы, лиризм белән патриотик пафосны кушып бару сәләте, Э. Межелайтис — олы, масштаблы фикерләве, җир шарының нәкъ уртасына басып, башка галәмнәр белән әңгәмәгә керүе, иркен интонациясе, ассоциатив фикерләве белән кадерле. А. Ахматова, С. Есенин, В. Маяковский кебек XX гасыр рус шагыйрьләрен яратып тәрҗемә итә, аларны үзенең остазлары, укытучылары дип саный, иҗатында да алардан шигъриятенең эчтәлеген һәм бизәкләү чараларын баетуга өйрәнә. Җөмләдән, В. Маяковский аңа фикерен ярым тоннарга, нюансларга, "сихерле тойгыларга" төрмичә, ачык һәм төгәл әйтеп бирә белүе, компромиссыз, ялкынлы пафосы, поэзияне бербөтен һәм хезмәткә якын итеп каравы белән якын иде. Татар поэзиясендә ак, ирекле шигырьне үстергәндә, аның ритмикасын һәм рифмасын баету юлында эзләнүләр алып барганда да, Ә. Давыдов Һ. Такташ белән беррәттән, А. Блок һәм В. Маяковский эзләнүләренә киң таяна.

Күренекле рус совет шагыйре А. Твардовскийның иҗаты да аңа рухи якын. 1961 елда Ә. Давыдов "Чорлар чатында" исемле лирик-фәлсәфи поэмасын бастырып чыгара. Ул үзенең эчке рухы, бәхет һәм кеше язмышы, дөнья киңлеге һәм күңел тарлыгы, күптән көтелгән янарыш процессының башлануы хакында тирән уйлануы белән А. Твардовскийның шул ук елда тәмамланган "Киңлекләр" поэмасына якын тора. Гамьсезлек, ваемсызлык әле дә бар. Әмма кеше, әхлакый югалтулар һәм физик корбаннар аша булса да, пассивлык фәлсәфәсен, язмышка бил бөгеп яшәү хасиятеннән арына барып, кешелеклелек һәм гуманизм юлына чыга. Демократия идеаллары белән рухланып яшәгән әдипләр дөньяның киләчәгенә тирән ышаныч белән карыйлар. Бу поэмалар безнең көннәрнең янарыш пафосына кешелек язмышы турында уйланулары белән якын.

Икесендә дә укучы белән ачыктан-ачык сөйләшү рухы өстенлек итә *("Укучым! Иң яхшы дус һәм кордаш. Бар юлдаштан әйбәтрәк юлдаш",–дип яза А. Твардовский).*

Ә. Давыдов "Киңлекләр"не аерым бер дәрт белән тәрҗемә итә, аның фәлсәфи рухын гына түгел, ә лиризмын, табигый аһәңен ачуга ирешә. А. Твардовский туган җирнең йөзенә "көмеш тасма сыман" сузылып, Идел суына кушылган җиде меңелга турында сөйләмне бер чагыштыруга сыйдыра. Тәрҗемәче аны дөрес ача:

*Һәм үрелеп изге туганлыкта,*
*Бер семьяда бар да сөйкемле,*
*Җир йөзендә алар җәелеп ята,*
*Киң тармаклы имән шикелле.*

Төзүчеләр бик кирәкле һәм мөһим эш башкарганнар дигән идек. Төзәтмәләре дә бик корректлы һәм зәвыклы. Үзәккә хаклы рәвештә әлифба тәртибе алынган. Төрле гасырларда яшәгән шагыйрьләрне шул рәвешле урнаштыру аклана. Тарихи-хронологик принципны үзәккә алып, чорларга бүлә башласаң, бүлек саннары бермә-бер артыр иде.

Икенче бүлек балалар өчен язылган шигырьләрне эченә ала. Ул атаклы балалар язучысы, тәнкыйтьче Корней Чуковскийның бер шигыре исеме белән "Урланган кояш" дип аталган. Шагыйрьнең иң яхшы дүрт әсәре Ә. Давыдов тәрҗемәсендә бирелгән. Н. Вапцаров белән Ю. Яковлев иҗатыннан үрнәкләр лаеклы урын алган.

Тулаем алганда, укучыга Ә. Давыдов талантының бер өлкәсен—оста, зәвыклы тәрҗемәче булуын күрсәткән җыентык тәкъдим ителә. Ә. Давыдовның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеген бер сүз белән—фидакарьлек дип бәяләргә мөмкин.

# Әнвәр Давыдов

САЙЛАНМА ТӘРҖЕМӘЛӘР КИТАБЫННАН

## Гай Валерий Катулл

*(б. э. к. 87-54)*
*Борынгы Рим шагыйре*

### Лесбия
(өзекләр)

**72**

**Син кайчандыр әйтә идең, тик Катуллны**
**Яратам дип, Юпитер да сөйкемсез дип.**
**Мин бит сиңа түбән хис белән омтылмадым:**
**Юк, атасы кызын сөйгән кебек сөйдем!**
**Хәзер башка. Дәртем ныграк дөрләсә дә**
**Күңелем өчен син бер чүптәй булып калдың.**
**Ник дисеңме? Бер алданган йөрәк белән**
**Ныграк теләп була, ләкин сөеп булмый.**

**87**

**Бер хатын да мактаналмас Лесбияне**
**Мин сөйгәндәй, көчле сөелүе белән,**
**Бер-беребезгә безне баглап-бәйләп торган**
**Сөю җепләреннән ныграк җеп юк җирдә.**
**Бүген исә йөрәк әрни. Син, Лесбия,**
**Яраладың! Дәрт һәм кайгы яралады.**
**Дус булалмам сиңа, тагын яхшырсаң да,**
**Тик сөярмен, җинаятьче булсаң да син!**

## Француз халык җыры

*(XVII гасыр)*

### Тау

**Иркәм белән арабызда — тау, текә!**
**Без менәбез тауга, хәл бетә-бетә.**

**Тау төшкәндә төшәбез җиңел — йөзеп,**
**Тауда болыт, иркәм кулында йөзек.**

**Иркәм әйтә: арыдык болай йөреп,**
**Ял итик без, бир миңа бераз ирек.**

**Сүзең, иркәм, нинди ирек турында?**
**Сөйдем сине тау булганга юлымда.**

**Тау астында бакчамда бар хин-агач,**
**Иртәнгәчә сайрый анда сандугач:**

Үз телендә аңлата шул, былбылым,
Гашыйкларга дөньяның моңсулыгын.

Берәр кеше тауны күчерсә, казып,
Без икенче тау өярбез — таш ташып...

## Джордж Гордон Байрон

*(1788—1824)*
*Инглиз шагыйре*

### Син бәхетле

(өзек)

Әйе, син бәхетле. Миңа инде
Күнү кирәк шушы язмышка.
Йөрәк җылысы белән карыймын мин
Синең матур, яхшы тормышка.

Ирең бәхетен күрдем, шуңа көчем
Җитте әрнүемне басарга...
Ә ул сине яратмаса, күпме
Нәфрәт саклар идем аңарга.

Балаң көлә. Усал көнләшүне
Сыйдыра алмас кебек йөрәгем.
Тик анасы хакына — елмаючы
Иреннәрен аның үбәмен.

Үбәм, газабымны яшерәмен:
Йөзен атасына охшатам.
Тик күзләре аның синеке бит,
Шуңа күрә аны яратам.

## Александр Пушкин

*(1799—1837)*
*Рус шагыйре*

***

Кирәкмәс бүләк син, тормыш,
Ник бирелгәнсең икән!
Нигә мине яшерен язмыш
Газапка дучар иткән?

Кемнең дошманлык куәте
Бар иткән мине юктан?
Күңелдә дәртләр дөрләтеп,
Уемда шик уяткан?

Юк минем алдымда максат,
Йөрәк буш, уй тик тора.
Тормыш һаман бер моң саклап,
Эчкә сагыш тутыра.

## Николай Некрасов

*(1821—1878)*
*Рус шагыйре*

***

Тынчу! Бәхетсез һәм ирексез төн
Иге-чиге бетмәс чүл кебек.
Давыл дуылдатсын иде җир өстен!
Ил кайгысы тулы күл кебек.

Кузгал, давыл! Диңгез-күлләрне
Урман-кырларны яңгырат.
Илнең ташып торган хәсрәтләрен
Бөтенләйгә тарат...

***

Нигә шулай ярсыйсың син, йөрәгем,
Тукта! Син күп күргән идең лә
Кар түмгәгедәй гайбәт тәгәрәвен
Безнең хакта туган илемдә.

Кайгырма, зурайсын ул гайбәт, күбәйсен,
Кайгырма син, түз;
Үлгәч безнең хакта да әйтер әле берәрсе
Яхшы, җылы сүз.

## Иван Никитин

*(1824—1861)*
*Рус шагыйре*

***

Тагын бер көн әкрен генә сүнә
Кызганусыз озатып каламын.
Тыныч төннең җиңел шәүләсенә
Өмет белән каршы барамын.
Тик беләм мин аның кочагында
Тынлык табу мөмкин түгелен.
Көне буе хәсрәт учагында
Янып ярсыды инде күңелем.
Ял итәсе килә йөрәгемнең
Усал телләрнең пычрак сүзеннән,
Качасы иде коллык өрәгенең
Мәкерле һәм керле күзеннән.
Син тынычлык эзләп маташма да...
Таң чыклары кипкәч тирәктә,
Тагын кичәгедәй көн башлана,
Кичәге ут кабына йөрәктә.
Тагын шул ук җан газабы синең
Күкрәгеңә сыкрау китерә.
Көчкә барып җитеп егыласың
Зәңгәр төн диңгезе читенә.
Мыскыл һәм кимсенү гарьлегеннән
Үксеп-үксеп яшьләр коясың,
Баш очында — килер керле көннең
Тынчулыгын тагын тоясың.

## Велимир Хлебников

*(1885—1922)*
*Рус шагыйре*

### Балакай

Балакай!
Күзләрегез зур булудан арсалар,
Риза булсагыз "туган" сүзенә,
Мин, зәңгәр күзле абыегыз, ант итәмен,
Тормышыгыз чәчкәсен югары йөртүне
бурыч итеп куям үземә.
Мин дә шундый ук бит, күктән төшкән,
Миңа күп усаллык эшләделәр,
Алар көткән кеше булмаганга,
Кыргый булганга,
Сөелмәгәнгә...
Телисеңме, абый-сеңел булыйк,
Без бит азат җирнең азат кешеләре,
Үзебез канун чыгарабыз, кануннардан курку кирәкми,
Гадәт балчыгын үзебез изәбез.
Беләм, бик гүзәл сез, зәңгәр төснең чәчкәсе,
Һәм миңа да шундый рәхәт, көтелмәгәнчә,
Сезнең Сочи турында сөйләвегез,
Һәм зурая мөлаем күзләрегез.
Бик күп нәрсәләрдә шикләнүче
Мин ышандым кинәт мәңгегә:
Булырга тиеш булачак,
Юкка селти урман кисүче үзенең балтасын!
Без күп артык сүздән котылырбыз,
Мин сиңа гыйбадәт укырмын,
Озын яллы йөнтәс рухани күк,
Сафлыкның зәңгәр чишмәләрен эчәрмен,
Һәм без курыкмабыз ямьсез исемнәрдән.

## Анна Ахматова

*(1889—1966)*
*Рус шагыйрәсе*

### Илһам

Ничек торыйм бу хәсрәт белән,
Җитмәсә әле үзен рәхәт диләр,
Ул бит диләр, моңлы саз диләр,
Аңа тиңләр җирдә аз диләр.
Болытларда моңы йөри диләр,
Ул сихерле һәм ул серле диләр...
Ә ул, бизгәк кебек калтыратып,
Бер үтә дә бөтен хәлне алып,
Тагын бер ел йөрим телсез калып.
Фәкать йөрәк кенә яна, янып...

## Михаил Исаковский

*(1900—1973)*
*Рус шагыйре*

### Ялгыз гармун

Тагын таңга кадәр бар да тынды,
Ишек шыгырдамый, ут янмый,
Тик кайдадыр ялгыз гармун гына
Моңланудан һаман туктамый.

Бер тыңласаң кырга чыгып китә,
Бер тыңласаң кайта яңадан,
Гүя эзли кебек кемнедер ул,
Ләкин таба алмый һаман да.

Кырдан төнге җиләс җил искәли,
Алмагачтан чәчкә сибелә.
Кем кирәк соң сиңа, яшь гармунчы,
Нигә йокламыйсың син генә?

Бәлки шатлыгың да бик якындыр.
Кайдалыгын гына белмисең,
Ник төн буе ялгыз йөрисең син,
Ник кызларга йокы бирмисең?

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

Азат
Әхмәдуллин

# ҮРНӘК ГЕРОЙЛАР САГЫНДЫРА

Матур әдәбиятның тормышны һәм яшәешне чагылдыру, дөньяны, кешене, аның табигатен өйрәнү хасияте, укучыга сәнгатьле тәэсир итү һәм анарда зәвык тәрбияләү көче, уйларга өйрәтү, фантазияне баету сәләте h. б. якларын-вазифаларын караганда әдәби герой проблемасы мөһим урыннарның берсен били. Чөнки югарыда аталган вазифалар матур әдәбиятта нәкъ менә кеше образы, ягъни әдәби герой ярдәмендә тормышка ашырыла. Шуңа күрә дә бүгенге әдәбиятыбызда каһарманның урыны һәм дә аны чагылдыруның торышы турында сөйләшү башлап "Казан утлары" бик дөрес эшли.

Күпләргә таныш нәзари карашлар буенча беләбез: матур әдәбият, һәм гомумән сәнгать, тормыш-яшәешне асылда ике төрле чагылдыра, сурәтли. Бер төр әсәрләрдә чынбарлык ничек бар шулай, үз рәвешендә чагылдырыла. Икенче төр язучылар һәм сәнгатькярләр тормышны авторның карашы буенча ничек (камилрәк, яхшырак, матуррак) булырга тиеш, шулай сурәтлиләр-чагылдыралар. Боларны, гомумиләштереп, беренче төр әдәбиятны— "реалистик" дип, икенчесен исә "романтик" дип атап йөртү кабул ителгән. Әдәбият тарихындагы аерым чорларда боларның йә тегесе, йә бусы өстенлек итә. Димәк, андый чорларда йә реаль, яки идеаль әдәби геройлар күпчелекне тәшкил итә.

Бик тә мәгълүм булган боларны сөйләү ни өчен кирәк булды соң әле? Чөнки "безнең заман герое" дигән сөйләшүне киңрәк планда алып карау сорала. Әдәбиятның өлгергәнлек дәрәҗәсен, аның активлыгын һәм җитлеккәнлеген, сәнгати йөзен анда өстенлек алган геройлар, образлар билгели. Ләкин заман герое төшенчәсен үзен дә бер генә төрле кабул итмәскә кирәктер. Әнә, М. Ю. Лермонтов дөньяда яшәүнең мәгънәсен таба алмаган, кешеләрнең язмышы белән уйнаган, салкын эгоцентризм корбаны булган Печоринны да үз заманының каһарманы дип тәкъдим итә ("Безнең заман герое" романы). Бу герой үз буыны дворян яшьләренең кимчелекләрен туплаган, шул чор җәмгыятенең тәрбия җимеше булып тора. М. Шолоховның совет әдәбияты күрке саналган "Тын Дон" әсәрендәге Григорий Мелехов образы шулай ук ил халыкларының икегә бүленеп кара-каршы канга батып сугышкан елларындагы характерлы герое, ягъни заман герое булып тора. Безнең заман герое дип дискуссия уздырганда без исә заманыбызның алдынгы тенденцияләрен, замандашлардагы гүзәл якларны үзендә туплаган персонажлар галереясен, ягъни уңай геройларны күздә тотабыз булса кирәк. Сөйләшүне ачып җибәргән мәкалә дә шул рухта (Р. Шәрәфиев—"Киләме, күрәбезме?" // Казан утлары, 2004, 1- сан).

## 1

Әдәбиятлар тарихында бер чорны икенчеләре, бер агымны икенче төрләләре, бер төр геройларны башкалары алыштырып, еш кына үстереп килә. Шуңа күрә дә бүгенге әдәби хәрәкәтебезне, шул җөмләдән геройлар образларын да кичәге үткәнебез белән чагыштырып карау үзеннән-үзе соралып тора. Шул җәһәттән безнең кичәгебез булган совет әдәбияты бүгенгәниләр калдырды? Аерым алганда, замандашлар образларын иҗат итүдә аның нинди

казанышлары булды, аларны бүген дә үрнәк итеп куеп буламы? Булмаса, ни өчен?

Әйе, һәр чорның үз кешеләре булган кебек, һәр чор әдәбияты да үзенчәлекле үз каһарманнарын күтәрә, алгы планга чыгара. Аларның ни дәрәҗәдә чынбарлыкны дөрес чагылдыруы, җәмгыятьтәге үзенчәлекләрне сәнгатьчә тирән сурәтләве мәсьәләләре бүгенге сөйләшүнең дә нигезендә ята.

Безнең җәмгыятебез узган гасырның сиксәненче еллары урталарыннан башлап тамырдан үзгәреш кичерә. Башлангыч чорларында җәмгыятьне яхшырту, демократик дәүләт оештыру, хезмәт ияләренең тормышын җайлау өмете белән сугарылган "үзгәртеп кору" менә инде ике дистә елга якын "чалулый", үз эзенә төшә дә, тиешле нәтиҗәләргә ирешә дә алмый. Алай гына да түгел, җәмгыять торган саен кыргый капитализм баткагына, бик аз санлы бераүләрнең котрынып баюы, зур күпчелекнең хәерчеләнә баруы мохитенә керә бара,— аннан чыгу да әлегә тиз булмас кебек. Әлбәттә, "үзгәртеп кору"ның майлаган кебек кенә баруына өмет итү беркатлылык булыр иде, шулай да ул бик озакка сузылды, көтелмәгән авырлыклар белән бара. Бу шартларда шәхеснең үз урынын билгеләүдә, рухын сынауда, психологик кичерешләр казанында кайнауда булган үзенчәлекле сыйфатларын әдәбиятта чагылдыру "перестройка"ның серләрен, максатын, бурычларын, үзенчәлекләрен тирән күзаллауны һәм, әлбәттә инде, зур талант көчен сорый. Татар язучысына болар ят түгел, билгеле, шулай да тулы мәгънәсендә һәръяклап заманның уңай герое дип әйтерлек персонаж табылды инде дип әйтә алмыйбыз. (Әйе, мин монда аның уңай герой дип әйтерлеген күздә тотам). Ә бит Зөлфәт Хәкимнең "Карак" драмасындагы (автор үзе аны комедия дип атаган) профессиональ карак та, Т. Галиуллинның трилогиясендә сурәтләнгән Сәет Сакманов та—безнең көннәр геройлары, аларны заманыбыз, гаделсез җәмгыятебез тудырган. Һәм аларда үрнәк алырлык сыйфатлар да аз түгел. Мәсәлән, Сакманов—кыю, яшәешебездә торган саен урын ала һәм ныгый барган гаделсезлеккә үзенчә каршы чыга, заман үзе барлыкка китергән ысулларга таянып көрәшә, саф мәхәббәтне зурлый белә һ. б. Икенче сүзләр белән әйткәндә, андыйларны заманыбыз үзе тудырды һәм алар—тоткан урыннары һәм уйнаган рольләре ягыннан шулай ук безнең көннәр герое. Мондыйлар агымдагы әдәбиятыбызны басып баралар, хәтта төп урынга дәгъва кылалар, төрле, еш кына кызыклы ситуацияләргә куеп сурәтләнәләр, төрле яклап гәүдәләндерелгән, күпчелеге кабатланмас шәхесләр буларак күрсәтеләләр. Әлегә кыргый булган җәмгыятебездә исән-имин калырга, баю юлларына өйрәтәләр. Ә менә укучыны тәрбияләү ноктасыннан, укучы үрнәк төстә кабул итү җәһәтеннән алар әдәбиятыбызда төп урынны ала алырлыкмы соң? Ягъни әдәбият иң беренче шундыйларны үз кыйбласы итәргә тиешме? Гәрчә безнең көннәр җәмгыятендә алар, кызганыч ки, еш кына хәлиткеч роль уйнасалар да, әдәбиятта һәм сәнгатьтә үзәктә торырга тиешләрме?..

Ә бит совет чоры әдәбиятында үрнәк алырлык геройлар табылган һәм алар төп урында торалар иде. Аларның күпчелеге—тормыш таләп иткән геройлар булды, ә тормыш коммунизм идеологиясенә буйсындырылган иде. Әсәрләрнең сәнгатьчәлек ягыннан мөкаммәлләрендә әдәби каһарман укучы күрергә теләгәнчә калку һәм ачык итеп сурәтләнде, ә укучы үзе дә сыйнфый көрәш идеологиясе һәм интернационализм, пролетар гуманизм рухында тәрбияләнгән иде. Бүген без кичәге каһарманның күп кенә кимчелекләрен табабыз: социализм идеяләренең җиңүе өчен көрәштә миһербансыз ул, үз замандашларына карата мәрхәмәтсез (бигрәк тә алар таза тормышка ия, яки дин әһелләре булсалар), аерым шәхеснең кайгы-хәсрәтенә шактый ук битараф, чөнки аның бар кайгысы—күпчелекне бәхетле итү...

Шулай да мондый геройлар укучыны тәрбияләүдә зур роль уйнады. Еш кына сокландырды, үрнәк булды. Мәсәлән, Аркадий Гайдарның совет балалар әдәбиятындагы гүзәл геройлардан берсе булган "Тимур һәм аның командасы" повестендагы үзәк персонаж бөтен илдә ярдәм итү хәрәкәте башланып китүгә сәбәп булды, үрнәк булды. Безнең буын "тимурчылар" булып уйнап үсте, уйнап кына да күпме ярдәмгә мохтаҗларга җиңеллек китерде. Татар укучысы Г. Әпсәләмовның "Алтын йолдыз" романындагы каһарманнарга охшарга һәм иярергә тырышты. Социалистик реализм принципларыннан чыгып иҗат ителгән, бөтендөнья әдәбиятлары шедеврларыннан булган "Хәсрәт чигеп йөрү" (А. Толстой), "Корыч ничек чыныкты" (Н. Островский), "Кеше язмышы" (М. Шолохов), "Ут" (А. Барбюс) романнарында, В. Маяковский һәм А. Твардовский шигъриятендә, Б. Брехт драматургиясендә һ. б. әсәрләрдә шул заман геройларының гүзәл образлары барлыкка килде. Алда да әйтелгән фикер шул: бүгенге заманның уңай геройларын иҗат иткәндә кичәге тәҗрибәгә таяну һич тә зарар итмәс.

Әлбәттә, кичәге уңай геройлар еш кына тормыштан аерылган итеп, идеаллаштырып

сурәтләнде һәм бу—аларның, гомумән совет әдәбиятының, төп кимчелеге. Шулай да без, бүгенге укучы, Акбирдин ("Кандыр буе") һәм Галияләргә ("Тапшырылмаган хатлар"), Гаяз, Артыкбикә ("Агыйдел") һәм Нәфисәләргә ("Намус"), Миңлекамал ("Миңлекамал") һәм Галим Урмановларга ("Алтын йолдыз") тартылабыз. Алар бүген дә безне намуслы һәм фидакяр, эш сөючән булырга һәм кешеләрне яратырга өйрәтәләр. Болар—кагыйдәдән чыгарма, дияргә, совет әдәбияты еш кына тормыш чынбарлыгын тулы һәм реаль дөреслегендә сурәтләмәде, күп очракта социалистик җәмгыятьнең тәти кәгазьгә төрелгән сурәтен генә бирде, дияргә мөмкин. Дөрес. Беренче адымнарында тарихи перспективасы һәм кешене, җәмгыятьне, дөньяны сурәтләүдә принципиаль төстә яңа булган, бөтендөнья әдәбиятын үстерүгә тәэсир иткән социалистик реализм алга таба тоталитар система кысаларына эләгә һәм норматив эстетика принципларына буйсындырыла. Нәтиҗәдә тормыш дөреслеген реаль чынбарлыкка туры килерлек итеп чагылдырудан тайпыла.

Җирдән аерылган геройларны сурәтләгәндә социалистик реализм асылда романтика ысулларына таянды. Ә бит романтик күтәренкелек, әдәби каһарманның иң күркәм сыйфатларын тасвирлаганда матурлап сурәтләүгә, гиперболага мөрәҗәгать итү әдәбиятлар тарихында аз түгел. Романтизмның күренекле вәкиле Виктор Гюгоның, мәсәлән, "Читкә тибәрелгәннәр" ("Отверженные") романындагы Жан Вальжан образы, Гаврош кебек геройлар шулай ук күтәреп, хәтта идеаллаштырып сурәтләнгәннәр. Һәм алар кешедәге иң матур сыйфатларны идеал итеп алуда бүген дә укучыга үрнәк булып торалар. Татар совет язучылары да мондый ысул-алымнарга еш мөрәҗәгать итте. Г. Әпсәләмов, М. Әмир кебек әдипләр "кирәк булганда, без уңай геройларны пьедесталга бастырырга тиешбез" дигән характердагы чыгышлар ясадылар. Ләкин шунысы бар: В. Гюго кебек романтиклар геройларны югары күтәргәндә гомумкешелек кануннары ноктасыннан торып эш итсәләр, Совет чоры әдәбиятында андый геройларны сыйнфыйлык, партиялелек, пролетар гуманизм принципларына нигезләп күтәрү төп урынны алды.

Димәк, әдәбиятыбыздагы кичәге уңай геройларның укучыны тәрбияләүдәге зур ролен таныган хәлдә дә, без аның аерым кимчелекләрен күздә тотып эш итәргә тиешбез.

## 2

Безнең заман герое турындагы сөйләшүне мин һәр төрле җыелышларда, бәхәсләрдә, дискуссияләрдә, алай гына да түгел, матбугат битләрендә дә күләгәдә калдырыла торган драматургия төре мисалында дәвам итәм. Һәм түбәндәге сорауларга хәл кадәренчә җавап бирергә тырышачакмын: бүгенге пьесаларда, театр сәхнәләрендә нинди геройлар өстенлек алды, алар укучыны һәм тамашачыны тәрбияләүдә, рухландыруда, күңелен күтәрүдә үзләренә йөкләтелгән вазифаларны үтиләрме, үтәсәләр, ничек үтиләр?..

Бәхәссез ки, герой проблемасы сәхнә әдәбияты өчен бигрәк тә мөһим. Әдәбиятның башка төрләрендә—шигърияттә һәм прозада—герой образы һәр очракта да конкрет гәүдәләнмәскә дә мөмкин. Прозада эпик вакыйгалар сурәте укучы игътибарын җәлеп итсә, шигърияттә лирик геройларның психологик кичерешләре алда тора. Аларда әдәби герой белән укучы арасында автор тора, ә ул образларны сурәтләүдә төрле ярдәмче алым-ысулларга таяна ала. Ә сәхнә өчен, иң әүвәл, герой образының аныклыгы, тормышчан билгеләргә якынлыгы һәм җанлы характер сыйфатларына ия булуы зарур. Кешелек сыйфатлары, кешене шәхес иткән, аны җанландырган тормышчан мәгънәви һәм матди билге-сызыклар драма герое өчен бигрәк тә мөһим. Заманның фәлсәфи, иҗтимагый һәм әхлакый нигез-фикерләре дә, үткәннәр турындагы бүгенге фәнни иҗтимагый аң-караш биеклекләре дә драматургиядә барыннан да ачыграк һәм сиземлерәк чагыла. Бу яктан сәхнә әдәбияты өчен герой проблемасы—әйе, иң актуаль, катлаулы, авыр һәм кирәкле булып кала бирә. Шуңа күрә дә хәзерге драматургиябезнең фикер һәм сәнгати өлгергәнлек дәрәҗәсен, уңышларын һәм кимчелекләрен ачыклаганда замандаш геройлар образларына мөрәҗәгать итү бик табигый. Шулай, янә сорыйбыз: мондый геройлар бармы соң бүгенге сәхнәдә? Яки сорауны беркадәр үзгәртеп куйсак: нинди геройлар анда өстенлек итә? Аларны нәрсә характерлый? Алар укучыга һәм тамашачыга ничек тәэсир итә, тәрбиялиме, үз артларыннан ияртерлекме алар?

Иҗат талантлары совет чорында формалашкан, ачылган яки ачыла башлаган күпчелек драматурглар, тышаулар алып ташлангач, төп игътибарларын кешенең җирдәге урынын ачыклау, гомумән кешенең рухи дөньясын тирәнрәк ачу ягына юнәлттеләр. Һәр заманда да актуаль булган "кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәте" читтә торып калды, чөнки авторлар бүгенге җәмгыятьнең нинди икәнен үзләре дә ахыргача аңлап һәм белеп бетермиләр булса

кирәк. Соңгы көннәргә кадәр бу күчеш чорында җәмгыятьнең кешегә ниләр китергәнен, мондый буталчык һәм кешелексез җәмгыятькә нинди мөнәсәбәттә булырга кирәклеген төшенеп-ачыклап җитмиләр. Кыскасы, кыйбласызлык урын алды. Мондый шартларда иң әүвәл үзе күргәнне язу, әйләнә-тирәсендәгеләрне ничек бар, шулай сурәтләү төп урынны били. Язучы замандашын гел чынбарлыктагыча гәүдәләндерә, аның нинди сыйфатларын алга чыгарганда үрнәк булачагын белми. Дөресрәге, уңай-үрнәк характер билгеләрен ачарлык ситуация тапмый, чөнки яшәешнең үзендә андый мөмкинлек күрә алмый. Икенче сүзләр белән әйткәндә, кыйбласын таба алмаган җәмгыятьтә идеалсыз геройлар образлары белән эш итәргә тиеш була. Андый геройлар адәм балаларының катлаулы характер сыйфатларын күрсәтә-ачыклый, язмышларын чагылдыра ала, ә үрнәк була, замандашыбызның укучы үзе өчен үрнәк алырга теләгән эре әдәби характеры роленә дәгъва итә алмый. Моңа ышану өчен соңгы ун-унбиш елда язылган пьесаларны күздән кичерү җитә.

### 3

Бүгенге әдәби хәрәкәтебезнең башында баручылардан берсе һәм иң күренеклеләреннән берсе—Туфан Миңнуллин. Аның иҗатында заманыбызның күп кенә сыйфат-үзгәрешләрен, мөһим якларын күрергә мөмкин. Күчеш чорында урын алган үзенчәлекләрне, эзләнү-бәргәләнүләрне, аерым табышларны без, иң беренче, шушы драматург әсәрләрендә күрәбез. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрне дә драматургиядә иң башлап ул үз әсәрләренең нигезенә сала башлады. "Җан газабы" (соңгы исеме—"Үткән еллар, күткән юллар") драматик хикәясендә яңалыклар алдында аптырап-югалып калган райком секретаре Рәшит Тимергазин образы үзәктә тора. Бу әсәр язылганда җәмгыять үзгәртеп кору процессына кереп бара иде әле. Күп санлы сораулар туган көннәр, иң мөһиме, эшне нәрсәдән башларга, бу шартларда намуслы кеше үзен ничек хис итә һәм тотарга тиеш кебек уйлар биләгән чор. Чын демократиягә ирештек дип, күпчелегебез эйфориягә бирелгән вакытлар. Драматург алгарак караган, совет җәмгыяте төшкән баздан чыгу юлларын табуның катлаулы, газаплы, каршылыклы булачагын күбебезгә караганда әүвәлрәк аңлаган икән. Дөрес, аларның никадәр бормалы, авыр булачагын автор да ахыргача төшенеп, баздан чыгуның дөрес юлларын күрсәтеп бирә алган дип әйтеп булмый. Һәм моны әдиптән таләп итү дөрес тә булмас иде. Ул әсәре белән мәсьәләне куя гына, укучыны сискәндерә, уйланырга этәрә. Шуңа да без Тимергазин образын шул заманның кайбер үзенчәлекле якларын чагылдырган, замандаш герой дип әйтә алабыз. Ләкин ул да укучыны үз артыннан ияртә алырлык герой образы түгел.

Бүгенге яшәешебездә туган күп кенә проблемаларны Т. Миңнуллин моннан соңгы әсәрләрендә дә күтәрде һәм күтәрә килә. Мөстәкыйльлек өчен көрәшнең яңа дулкынына килеп кергәч, соңгы елларда аерата актуальләшкән татар милләтенең язмышы мәсьәләсе аның "Илгизәр+Вера" һәм "Шәҗәрә" драмаларында тормышчан кискенлек белән, сәнгати ышандырырлык итеп куела. Беренче әсәрдәге вакыйгалар сурәтләнешеннән укучы һәм тамашачы моңарчы совет чорында ике милләт арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытырга һәм үстерергә тиешле дип каралган һәм расланган катнаш никахларның аз санлы халыкларның язмышына балта чабу икәнен аңлый. Татар руханиларын, Гаяз Исхакый кебек язучыларны һәм зыялыларны күптән борчыган бу проблеманы шулай ачык итеп сәхнәгә чыгаруда бу тәүге уңышлы адым булды. Мондагы персонажлар да—безнең замандашлар. Әмма боларны, яшьләребезне тәрбияләүдәге ролен таныган хәлдә дә, безнең заманның үрнәк уңай геройлары дип атап булмас. Чөнки, иң әүвәл, алар бездә оптимизм тудырмыйлар, мондый никахлар хөкем сөргән чорда милләтнең киләчәге якты булырына өмет уятмыйлар. Бу җәһәттән икенче драма—башкачарак. Аның нигезендә Г. Камал театрында куелган спектакльдә милләтебезнең зыялы катламы дучар ителгән тарихтагы фаҗигале язмышларны гәүдәләндергән дистәләрчә персонажлар бар. Алар арасында авыл малае Сәет Шәрәфетдиновның якты образы, яшь Сәимә Сәетбәкованың мөлаем сурәте киләчәгебезгә беркадәр ышаныч уята, сокландыра, тәрбияли. Шулай да алар кичәге ГУЛАГ тоткыны булган өлкән Сәлимә Сәетбәкова (спектакльдә—актриса Наилә Гәрәева), тормышка хыялый ышанычын җуймаган Юныс Сәетбәков (артист Рәсим Сәләхов), бүгенгенең төп фигурасы булуга дәгъва кылган коммерсант Азат Сәетбәков (артист Рамил Төхфәтуллин) образларыннан, танылган актрисабыз Нәҗибә Ихсанова тудырган, яхшы мәгънәсендәге аксөяклеген саклый алган аристократка Халисә Сәетбәкова образыннан,—сәнгатьчә эшләнеш ягыннан да, эре итеп типиклаштыру ноктасыннан да,—күпкә кайтыш.

Шуңа да алар чын мәгънәсендәге бүгенге уңай геройларның гомумиләштерелгән характерларын чагылдыра дип әйтеп булмас. Боларда уңай геройларның кайбер аерым билге-сызыклары гына чагыла.

Драматург заманыбызның уңай героен тудыру җәһәтеннән эзләнүләрен дәвам итә. Һәм моны ул әдәби каһарманның рухи дөньясын катлаулы һәм бай итеп күрсәтү юнәлешендә алып бара.

Филология фәннәре кандидаты Рәшит Фәтхерахманов дискуссиядә катнашып язган "Татарга сатма матбугат..." исемле мәкаләсендә соңгы елларда мөселман рухани әдәбияты белән кызыксынуның бик нык артуын, дини һәм ислами календарьларның кайберләре дистә һәм йөз меңләгән тиражлар белән таралуын искә ала да, шундый фикер әйтә: "Татар язучысына, ихтимал, утырып уйланырга, йөзен ялган кыйбладан чын кыйблага борырга вакыт җиткәндер,—ди ул.—Чын татар романының герое булырдай типларны, мөгаен, милләтнең менә шушы татарлыгын югалтмаган һәм сакларга омтылган катламы арасыннан эзләргә кирәктер. Моның өчен, әлбәттә, шушы катламның тормышына үтеп керү, гыйбрәтле язмышларны шулар арасыннан эзләү кирәктер. Шәхеснең адашудан туры юлга чыгу процессы катлаулы һәм авыр, әдәбият менә шушы өлкәдә, шушы процесста актив катнашучы инструмент булырга тиештер" ("Казан утлары", 2004, 3-сан, 148-149 битләр).

Мондый фикер Т. Миңнуллин башында да туган икән. "Сөяркә" исемле драматик хикәясендә аның үзәк геройлары Әнисә һәм Хәбир ситуациядән дөрес чыгу юлын эзләп динебезгә мөрәҗәгать итәләр. Рухи кичерешләрен мөселманлык яссылыгында хәл кылырга омтылалар. Ике ут арасында калып гаиләсенә карата да, сөяркәсенә мөнәсәбәттә дә чын кешелек кагыйдәләреннән чыгып эш йөртүче Хәбир симпатия уята, аның үзе өчен бик четерекле мәсьәләне ислам кагыйдәләре буенча хәл итәргә тырышып хәзрәткә баруы яклау таба. Геройларның эчке кичерешләре, алар кабул иткән карарларның динебез кысаларында баруы сәхнә әдәбиятыбыз өчен шулай ук яңалык булды.

Яки Т. Миңнуллинның икенче әсәрендәге герой, Чечен сугышыннан аяксыз калып кайткан, рухы да тәмам гарипләнү чигендә торган Рәхимҗанның эчке бәргәләнүләре тамашачыга шулай ук гаять көчле тәэсир ясый ("Эзләдем, бәгърем, сине"). Каһарманның төшенкелек чиген уңышлы узып, мәхәббәттә генә түгел, яшәүдә дә кыйбласын һәм бәхетен табуы сөендерә. Бу да—безнең заманның матур герое.

Ләкин бит геройларның бай рухлы, әхлакый саф булуы гына җитми, укучы һәм тамашачыга үрнәк булсын өчен тагын да нәрсәләрдер кирәк...

Күрәсең, әле тагын башкаларга файдалы, кирәкле булуы, күпләрнең бәхете өчен, язмышларын җиңеләйтү өчен гамәл кылуы да кирәктер, шул юнәлештә укучыны һәм тамашачыны сокландырырлык, кызыктырырлык итеп файдалы эш күрсәтүе кирәктер. Әнә, шул ук "Сөяркә" драмасындагы баш каһарманнардан берсе булган Хәбир яңа, кешелексез шартларда пенсиясе җан асрарга да җитмәү сәбәпле урам чатына чыгып утырып, сагыз, сигарет сатып көн күрергә мәҗбүр булган Хәбирә әбине үз янына чакыртып ала, аның белән кешеләрчә, хәленә керергә тырышып сөйләшә, акчалата ярдәм итә. Һәм аның гамәле укучыга-тамашачыга көчле тәэсир ясый. Хәбирә әби әйтмешли, "ходайга шөкер, мондый кешеләр дә калган икән әле" дип, күңелдә сөенеч хисен уята. Бу факт заман геройларын кай тарафтан эзләргә кирәклегенә ишарә итә түгелме?!

Әйе, соңгы вакытта әдәбият, шул җөмләдән драматургия дә, кеше шәхесенә игътибарын бик нык арттырды. Совет әдәбиятына, сәхнәсенә җитми иде бу, чөнки анда коллектив интересларын яклауга гына игътибарны юнәлтеп, шәхес мәнфәгатьләрен сурәтләү каядыр артта калдырыла иде. Инде бу яктан тышаулар юк, кеше шәхесе әдәбиятта үз урынын ала бара. Ләкин шәхес артында гомумкешелек, безнең өчен бик тә мөһиме—гомуммилли мәсьәләләр, шуларны хәл итүдә фидакярлек күмелеп калмасын иде. Тагын да ачыграк итеп әйткәндә, шәхеснең теләк-омтылышлары белән күпчелек (коллектив) ихтыяҗларын, халык мәнфәгатьләрен үзендә берләштергән геройлар образлары иҗатта төп урынны алсын иде. Хәзерге заман геройларына нәкъ менә шул җитми. Шәхес буларак тагын да бөегрәк һәм сокланып үрнәк булырлык булсын өчен геройны халык язмышы, әйләнә-тирәдәгеләр интересы белән ныклы бәйләнгән итеп күрәсе килә. (Икърар итәм, бу таләпләрне куюда, бәлкем, безнең—бүгенге укучының—совет чорында өстенлек иткән коллективчылык мәнфәгатьләре белән артык сугарылган булуыбыз да тәэсир итәдер?! Димәк, бу очракта да совет әдәбиятыннан үрнәк алырлык мөмкинлек бар...). Шунсыз заманның үрнәк уңай герое образы тулы ук булмас...

Хәзерге бүтән драматурглар иҗатында да замандашлар образларын сурәтләү киң урын ала (хәер, булмый мөмкин дә түгел, чөнки, инде алда да әйтелгәнчә, сәхнә үткән белән

генә яши алмый, аңар бүгенге геройлар да кирәк). Мәсәлән, Зөлфәт Хәким яшәешебезнең төрле якларын, бүгенге шартларда җан асраучы кешеләрне төрле жанрларда чагылдыра. Ләкин аның күпчелек пьесаларында сурәтләнгән персонажларны, гәрчә безнең көннәр үк тудырган геройлар булсалар да, кайсыдыр якларыннан укучы һәм тамашачы үрнәк алырлык образлар дип әйтә алмыйбыз. Аларның күпчелеге—канатлары сынган, совет яшәешендә рухи яктан бөлгән кешеләр. "Җүләрләр йорты" трагикомедиясендәге Вәли Галиевич һәм Халит Хәбирович та, Алсу һәм Шәүкәт тә, "Күрәзәче" трагикомедиясендәге Хәнәви һәм Галәветдин дә—шундыйлар. Мондый геройларны драматурглардан Илдар Юзеев тә ("Ак калфагым төшердем кулдан"), Ризван Хәмид тә ("Актамырлар иле"), Данил Салихов та ("Алла каргаган йорт"), Мансур Гыйләҗев та ("Сафиулла"), Фәүзия Бәйрәмова да ("Вакыйга җүләрләр йортында бара"), Гафур Каюмов та ("Юбилей") белеп сурәтлиләр. Ркаил Зәйдулланың "Адашкан сандугач", Ю. Сафиуллинның "Йөзек һәм хәнҗәр" драмаларында исә гамәлдәге яшәешебез тәрбияләгән геройларның язмышын тасвирлау үзәккә куелган. Андый рухы гарипләнгән кешеләрне бүгенге көннәрнең характерлы билгесенә әверелә барган эчүчелек, наркоманчылык та күпләп "житештерә". Драматургларыбыз бу бәлане дә бөтен ялангачлыгында тасвирларга омтылалар. Мәсәлән, Д. Салиховның "Яшьлек хатам—йөрәк ярам" исемле драмасында электә халкыбызга ят булган аракыга хирыслыкның нинди аяныч нәтиҗәләргә китерүе ышанычлы һәм тормышчан ситуацияләрдә сурәтләнә. Аек акыл белән яшәү традицияләре яктылыгында ике сәрхүш—архитектор Әхмәт һәм аның шешәдәше Әбүзәрнең аянычлы язмышы күрсәтелә: әгәр дә беренче герой дәваланып эчкечелек чиреннән котыла алса, икенчесе тормышын элмәк белән өзә. Ләкин Әхмәтнең язмышы барыбер дә бәхетсезлек юлында булып чыга, ул мәңгелек мәхәббәтен җуя.

Бүгенге драма әсәрләренең күпчелегендә, шулай итеп, кешенең рухи дөньясын чагылдыру алгы планга чыкты. Кешене үзенчәлекле шәхес иткән, аның рухи ныклыгын, кирәк икән, шәхес буларак бөеклеген раслауга хезмәт иткән сыйфатларга игътибар артты. Ахыр чиктә драматургиянең дә, һәм гомумән әдәбиятыбызның да, төп юнәлеше менә шунда—шәфкатьсез һәм намуссыз җәмгыятебез упкынына батып, күмелә барган Кеше өчен чиксез ачыну, аны әхлак ягыннан күтәрү. Чөнки гуманистик әдәбиятның иң мөһим вазифаларыннан берсе дә шул: әхлакый сәламәт кешене тәрбияләү, аны кеше өчен кайгырту рухында тәрбияләү. Әйе, авторларыбыз бик яхшы беләләр ки, шундый кайгыртуы булмаган адәм чын КЕШЕ хисаплана алмый. Т. Миңнуллинның "Хушыгыз" драмасындагы Галимулла, "Эзләдем, бәгърем, сине" мелодрамасындагы Рәхимҗан, И. Юзеевнең "Гашыйклар тавы" пьесасындагы Мөнирә, З. Хәкимнең "Үтермә..." драмасындагы Сәүбән, "Күрәзәче" трагикомедиясендәге Хәнәви, Д. Салиховның "Чукрак" драмасындагы Нуриәхмәт, Аманулланың "Әле кичә генә яз иде" дип аталган романтик драмасындагы баш персонаж—шул юлда торучы бүгенге геройлар.

Кыскасы, гомумиләштереп әйткәндә, хәзерге драматургиядә безнең заман геройлары урын алды һәм ала. Хәзерге сәхнә алар ярдәмендә бүгенге болганчык, кеше өчен мәрхәмәтсез һәм миһербансыз, гаделсез җәмгыятебезне күпмедер күләмдә дөрес чагылдыра. Әмма драматургиягә һәм сәхнәгә яктылык һәм күтәренке рух җитми, оптимизм хас түгел. Мин бер мәкаләмдә танылган артистыбыз Ринат Таҗетдиновның бу хакта әйткән сүзләрен китергән идем инде, тагын кабатлыйм. "Мин, үз ихтыярымнан торса, тормышның әшәке, кара якларын күрсәтә торган спектакльләр эшләмәс идем,—ди ул.—...соңгы елларда телевидениедә дә гел кара якны гына күрсәтү китте. Кая карама—үтереш, атыш, эчү, сугышу, наркотиклар... Ә театрларда якты спектакльләр күбрәк булырга тиеш: сәламәт, дөрес, иманлы яшәү, саф мәхәббәт, таза тормыш турында" ("Мәдәни җомга", 2003 ел, 10 гыйнвар). Моның өчен иҗатчыларны гына гаепләү дә дөрес үк булмас, чөнки заманы шундый—оптимизм рухыннан мәхрүм. Ә алар, инде алда әйтелгәнчә, иң башта чынбарлыкны дөрес чагылдыруны максат итәләр.

Совет әдәбияты ялган оптимизмга нык ышанып, бүген дә сокландыра торган шактый әдәби геройлар иҗат итте. Чөнки аларда, һәрчакта да һәм тулы ук булмаса да, гомумкешелек кыйммәтләре дә чагыла иде. Монда аңар югарыда әйтелгән, "революцион романтика" исемен алган иҗади ысуллар һәм алымнар ярдәмләште. Бәлкем безгә дә "революцион" дигән кушымчасы төшереп калдырылган романтика мөмкинлекләреннән иркенрәк файдаланыргадыр? Заманында советлар иленең беренче мәгариф комиссары А. В. Луначарский тарафыннан әйтелгән: "безгә Шиллерлар җитми, Шиллерлар кирәк" дигән фикер, бәлкем, бүген дә үз көчен саклыйдыр?!..

**Зиннур Мансуров**

# КАЛӘМЕБЕЗ ИЛАҺИ АНТКА ТУГРЫМЫ?

## Бүгенге шигъри әсәрләрне укыганда туган уйлар

Әдәби хәрәкәт аерым «бишьеллык», яисә «җидееллык»лар белән чикләнә алмый—ул бары тик үзенә генә хас булган вакыт исәбе буенча яши. Галимнәребез билгеләгән теге яки бу үсеш чорлары да шартлы бүленеш баскычлары рәвешендә генә каралырга тиештер. Без инде беләбез, әдәбиятта яңа традицияләр, тенденцияләр, һәртөрле «изм»нарның тууы өчен еллар кысасына сыешмаган дәвамлы вакыт кирәк. Әмма адәм баласының табигате шундый инде: аерым бер ел бусагасын атлап чыккач ук ул үзенең үткәндәге эш-гамәлләрен барлый башлый. Бу җәһәттән еллык иҗат эшчәнлегебезне күздән кичерү дә безнең өчен, барыбер, кирәкле гамәлгә кайтып кала, чөнки киләчәккә төбәлгән әдәби хәрәкәтнең хәл-әхвәлен кыска вакыт аралыгында да ачык чамаларга мөмкин. Шуңа күрә, әдәбиятыбыз Әнкәсенә: «Хәлең ничек, шигърият?»—дип эндәшкәләп торуыбыз, шагыйрьләребезнең: «Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?» -дип үз-үзләрен тикшергәләп яшәве бик табигый. Һәм кирәк тә.

Гареп әдәбиятчеләре шулай искәртергә ярата: синең ничек язганыңны иңбаш аша кем дә булса һәрвакыт карап тора—Ана, Остаз, Шекспир, Аллаһ... Иҗат иткән чакта безне Шекспир күзәтәдерме, анысын белмим, әмма өлкәннәребез һәрчак сынап багадыр кебек. Ни аяныч, соңгы елларда татар прозасын тотып торган байтак олуг язучыларыбыз бер-бер артлы диярлек арабыздан китеп барды. Ә менә шигъриятебезгә язмыш беркадәр мәрхәмәтлерәк булды—өлкән шагыйрьләребез сафы, Аллага шөкер, әле алай ук сирәкләнмәде. Урта буын вәкилләре арасында да хафага төшәрлек өзеклек сизелми. Алар артында торучы яшьрәк шагыйрьләр дә дәвамлылыкны тәэмин итәрлек дәрәҗәдә ишле. Һәрхәлдә, янәшәңдә өлкәннәр иңен сизеп язу безгә рәхәтлек белән зур җаваплылык та йөкли.

*Уяныгыз, йокламагыз,*
*Әй, Казан ятимнәре, -*
*Бабагыз язган язмышның*
*Булыгыз хакимнәре...*

(«Әче җил...»).

Бүгенге көндә дә нәтиҗәле иҗат итүче олпат шагыйрьләребезнең берсе Илдар Юзеев сират күпере аша кичкән татар халкы варисларына әнә шулай эндәшә. Әлеге шигъри хитап—әдипнең зур тормыш тәҗрибәсе җирлегендә шанлы үткәнебезгә караш ташлавы, киләчәк турында борчылып, яр-упкын читләренә төртеп чыккан милли тамырларыбызны барлавы... Шөкер, Илдар абыебызның һаман да иярдә чагы. Әлеге дә баягы тәҗрибә, осталык һәм зирәклек аны тирәннән киңлеккә омтылучы шигъри дулкын өстендә тота. Бу, мөгаен, шагыйрьнең лирикага гомере буе тугры булуыннан да киләдер, чөнки нәкъ менә тирән лирика рухи әзерлекнең һәрдаим баеп торуын таләп итә. Моның шулай икәнен Илдар Юзеевнең узган ел «Казан утлары» журналында (1-сан) басылып чыккан «Кәккүккә гомерләр юрыймын» исемле шигъри шәлкеменнән дә, «Идел»дә (3-сан), «Мәдәни җомга» гәзитендә (1-сан) дөнья күргән шигырьләреннән дә ачык чамаларга мөмкин. Күптән түгел миңа аның өр-яңа драматик поэмасын кульъязма хәлендә укып чыгарга туры килде һәм янәдән шуңа инандым: Илдар абый әлеге әсәрендә дә шигъри жанрның чын остасы булып кала.

Аксакал дәрәҗәсендәге икенче бер шагыйребез Шәүкәт Галиевкә яшьрәк каләмдәше Рафис Корбанның үзенчә билгеләмә биргәне хәтердә. «Шәүкәт абыйда дүрт «мин» бар,—дип искәрткән иде ул.—Аларның берсе—лирик шигырьләр авторы, икенчесе—юмористик һәм сатирик шигырьләр иҗат итүче, өченчесе—балалар шагыйре һәм дүртенчесе—прозаик».

Бу юлы шагыйрьнең бер ягына гына кагылып үтәргә телим. Дөресен әйткәндә, Шәүкәт Галиев соңгы вакытта үзенең беренче «мин»ен, ягъни лирик шигырьләр остасы булуын

шактый калкытып күрсәтә алуга иреште. Әйтерсең, ул моңарчы түл җыеп яткан. Көндәлек матбугат басмаларында даими рәвештә дөнья күреп килүче житди тупламаларында шагыйрьнең тагын да киңрәк офыкларны колачлавы, тирәнрәк катламнарга үтеп керүе, зуррак гомумиләштерүләргә ирешүе сизелеп тора. Аның «Казан утлары» (11-сан), «Мәйдан» (12-сан), «Идел» (3-сан), «Сөембикә» (11-сан) журналларында басылып чыккан лирик әсәрләре әнә шундый нәтиҗә ясарга нигез бирә. Күрәсең, талант иясе бердәй осталык белән үзләштерә алган иҗат юнәлешләрен әледән-әле төрләндереп торырга тиештер.

Шәхсән үземне Әхсән абый Баянның шигърияттә олы төшенчәләр турында фикер йөртергә омтылуы, иҗади эзләнүчәнлеге, югары сәнгатьлелеккә дәгъва кылуы һ.б. шундый сыйфатлары һәрвакыт сокландырып килде. Кем әйтмешли, ул тормыш прозасыннан да зур осталык белән тормыш поэзиясен чыгара ала. Шигъри теле тыгыз, сурәтле һәм музыкаль, һәрбер әсәре гамьле моң белән сугарылган. Аның яңа гасырга мөрәҗәгать итеп язылган шигыреннән бер өзекне генә укып карыйк:

*Дөнья—чиксез, анда юк кем генә -*
*Ни күрәсең килә, бары да бар;*
*Матурлык бар, әмма ул коткармый,*
*Бәхет тә бар, әмма урыны тар...*

(«Яңа гасыр»).

Шигъри иҗат өлкәсендә бүген дә яшьләрчә эшләүче Әхсән Баян быелтыр үз укучыларын «Казан утлары»нда (10-сан), «Мәдәни җомга»да (51-сан) чыккан шигырьләре белән генә түгел, Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Сайланма әсәрләр»енең биш томлыгы белән дә сөендерде.

Үткән елгы матбугат басмаларында иң зур урын, мөгаен, шагыйрь Равил Фәйзуллин иҗатына бирелгәндер. Моның сәбәбе дә бар: былтыр ул, шәхес һәм әдип буларак, өлгергәнлек чорындагы иң күркәм юбилеен билгеләп үтте. Алай гына түгел, шагыйрь турында газет-журналларда басылып чыккан күпсанлы мәкаләләр, башкалабыз Казанда, шулай ук аның туган ягында үткәрелгән юбилей тантаналары татар шигъриятенең зурлыгын күрсәтүче гомуми бәйрәм чараларына әверелде. «Равил Фәйзуллин—чын мәгънәсендә халык шагыйре, һәм ул бу югары исемне аклый да,—диде Президент Минтимер Шәймиев каләм остасының юбилей кичәсендә.—Аның совет чорында язганнары да, кичә һәм бүген язганнары да бердәй дәрәҗәдә талантлы. Җитмешенче елларда шул чактагы зур ил халыклары татар шигърияте белән якыннан танышсын өчен алар буыны бик күп көч куйды».

Инде искәртеп үткәнемчә, былтыр көндәлек матбугатта, атап әйткәндә, «Казан утлары» (3; 8-саннар), «Идел» (7-сан), «Мәйдан» (10-сан) журналларында, «Ватаным Татарстан» (155-156-саннар), «Мәдәни җомга» (37-сан) газетләрендә һ.б. басмаларда Равил Фәйзуллинның олы шагыйрь икәнен раслаучы шигъри әсәрләре, Татарстан китап нәшриятында «Мәхәббәтнамә» исемле җыентыгы һәм «Мәгариф» нәшриятында «Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес» дип исемләнгән үзенчәлекле китап дөнья күрде. Соңгысының төзүчесе буларак, шуны әйтәсе килә: мондый басманы чыгарыр өчен зур иҗат җирлеге кирәк, һәм бу китап татар шигъриятенең дә югары дәрәҗәсен күрсәтеп тора. Шагыйрь бу очракта да хаклы:

*Вакыт белән хезмәте тау*
*Ирләр генә алыша ала.*
*Заман, иелеп, җиңүченең*
*Шанлы исемен алып кала...*

(«Яу-дауларны күргәннәр күп...»).

Бездә каләм әһелләрен аерым буын-обоймаларга бүлеп карау гадәте яши. Ничектер шулай килеп чыккан, шагыйрь Роберт Әхмәтҗан аларның берсенә дә сыешмады кук, ул шигъриятебезнең үзенә башка «оазисы» кебек яши бирә. Юк, шагыйрьнең «аерым хуҗалык» сыман гомер кичерүе аның шәхесен һич тә кечерәйтми, киресенчә, беркадәр читтәрәк тору иҗатчының шигъри дөньясын тагын да зурайтып кына күрсәтә... Әгәр әдәбият галимнәре «шагыйрьлек—шигъри образлар белән фикерләү ул», дип кабатласалар, мин иң беренче чиратта Роберт Әхмәтҗанны искә төшерәм. Һәм татар теленең шагыйрьләр теле булуын искәртсәләр дә аның шигырьләре сихри кәрван рәвешендә күңелемнән уза.

Күз тимәсен, Роберт Әхмәтҗанның каләме бүген дә талчыгуны белми: узган ел аның «Казан утлары» (4-сан), «Сөембикә» (7-сан), «Идел» (9-сан), «Мәйдан» (1-сан) журналларында, «Ватаным Татарстан» (223-224-саннар), «Мәдәни җомга» (11; 37-саннар) газетләрендә зур-зур шигъри шәлкемнәре дөнья күрде. Китап кибетләрендә аның яңа җыентыклары сатылып ята. Аларны битләре арасына болын чәчәкләре кыстырган китапны актаргандай хушланып укыйсың. Без еш кына шагыйрь Роберт Әхмәтҗанга карата

«табигатьтән бирелгән талант» һәм кайчак хәтта «табигать иркәсе» кебек гыйбарәләрне кулланабыз. Әмма шунысын онытып җибәрәбез: табигатьне саклаган кебек саклыйк без андый талантларны, табигатьне кадерләгән сыман кадерлик...

Безнең арада күбебезгә җитешмәгән фидакарьлек белән иҗат итүче шагыйрь бар: ул—Фәнис Яруллин. Кайвакыт без кулыбызга шырпы керсә дә, туктаусыз сыкранып, үзебезне кызгандырыр өчен һәрдаим җай эзлибез. Бу уңайдан Фәнис абыйның нинди хәл-халәттә эшләвен күпләребез күз алдына китерәдер. Әмма җан-тән торышы нинди генә булмасын, шагыйрь башкаларга үрнәк булырдай нәтиҗәлелек белән язуын дәвам иттерә.

*Йодрык кадәр генә калдым инде,*
*Бу тормыштан һаман нидер көтәм.*
*Йөрәгенә алып салса берсе,*
*Бөтенләем белән сыеп бетәм...*

(«Йодрык кадәр генә...»).

Гадәттә, талантның зурлыгы күләм-сан мәсьәләсендә дә карала, ягъни бу очракта сүз яхшы әсәрләрне күбрәк яза алу мөмкинлеге турында бара. Иҗат потенциалына кагылышлы әлеге кагыйдә, минемчә, Фәнис Яруллинга бик туры килеп тора. Быелтыр ул «Казан утлары» (2-сан), «Идел» (1-сан), «Мәйдан» (2-сан) журналларында, «Ватаным Татарстан» (27-28-саннар), «Шәһри Казан» (14-15-саннар) газетләрендә һ.б. басмаларда үз укучыларына өр-яңа шигырьләрен тәкъдим итте, ә «Мәдәни җомга»да (6; 43-саннар) «Йөрәгемдә барам күтәреп» һәм «Мендек мәхәббәт тавына» исемле тематик цикллар чыгарып, шигъри жанрның поэмадай укылырлык бу төрен үзенчә яңартып җибәрде.

Поэма, дигәннән, «Казан утлары» журналының узган елгы саннарында мондый эпик әсәрләр бөтенләй күренмәде. Бүгенге язучылык иҗаты торышын югары профессиональ кимәлдә яктыртып баручы абруйлы журналыбызда бер генә дә поэма басылмаган икән, димәк, әдәбиятыбызның да, шагыйрьләребезнең дә зурлыгын, тирәнлеген һәм перспективасын гасырлар буе күрсәтеп килгән әлеге жанрга нидер булган?! Дөресрәге, поэма жанрына түгел, ә шагыйрьләребезнең иҗат мөмкинлегенә...

Хәер, башка матбугат басмаларында зур полотнолы шигъри әсәрләр яки алардан аерым өзекләр күзгә чалынып китте. Үзләренең эчтәлек һәм формалары ягыннан бер-берсеннән аерылып торучы дистәләрчә поэма иҗат иткән шагыйрь Ренат Харис быелтыр «Исемсезләр» дип аталган шигъри романын төгәлләде. Аның аерым өзекләре «Мәдәни җомга» газетенең 29-31 нче саннарында дөнья күрде. Инде искәртеп үткәнемчә, әгәр әдәбиятебез тарихына күз салсак, без анда иң әүвәл зур күләмле шигъри әсәрләрнең—дастан, кыйсса, поэмаларның аерым биеклекләр булып торуын күрербез. Гасырдан гасырга шулай дәвам итә... Ни гаҗәп, зур эчке мөмкинлеге булган татар әдәбиятында шигъри романнар бик тә аз язылган икән. Хәтта алар «роман» жанры барлыкка килгәч тә туарга ашыкмаганнар кебек. Дөрес, без инде үтеп киткән соңгы гасырда шагыйрьләр Салих Батталның «Чирмешән якларында» һәм Әнвәр Давыдовның «Йокысыз төннән соң» исемле шигъри романнар иҗат иткәнлеген беләбез. Әмма әлеге әсәрләрнең дә төрле сәбәпләр аркасында тәмамланып бетмәве мәгълүм. Һәм менә Ренат Харисның «Исемсезләр»е пәйда булды. Яшәешебезнең биниһая якларын колачлаган әлеге күпкатламлы әсәр, һичшиксез, яңа әдәбиятыбыз тарихында үзенә лаеклы урын дәгъваларга хаклыдыр. Әлбәттә, иң әүвәл ул саллы журналларыбызның берсендә дөнья күреп, әдәби җәмәгатьчелекнең әтрафлы бәясен алырга тиеш, дип уйлыйм.

Шуңа игътибар итмичә мөмкин түгел: үткән елгы әдәби тормышыбызда Марсель Галиев шагыйрь буларак шактый җанланып китте. Һәрбер әдәби жанрда да шагыйрьләрчә образлы фикер йөртә алучы әлеге каләм иясенең шигърияттән берազга читләшеп торуы безнең өчен үзенә күрә бер югалту шикеллерәк кабул ителгән иде. Инде менә кичерә белүче Музабыз аны яңадан кочагына алсын — Марсель Галиев быелтыр «Казан утлары» (4-сан), «Сөембикә» (4-сан) журналларында, «Мәдәни җомга» газетендә (27-сан) аерым тупламалар бастырды һәм шигърият сөючеләргә «Җиһангир» исемле поэмасын («Мәдәни җомга», 8-сан)» тәкъдим итте. Җыйнак һәм тыгыз булуы белән аерылып торган әлеге әсәрдә автор, Чыңгызхан образы аша, төрки халыкларның каршылыклы язмышына үзенчә бер караш ташлый. Белүебезчә, Марсель Галиев бу темага үзенең тарихи мәкалә-эсселәре, тәрҗемәләре белән килде, һәм аның яңа поэмасында әлеге мәгълүмати-рухи әзерлекнең авторга нык ярдәм иткәнлеге сизелә.

Поэма жанрын үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән шагыйрь Әхмәт Рәшитнең Татарстан китап нәшриятында үзенчәлекле җыентыгы дөнья күрде. «Фидаилар» дип исемләнгән әлеге китапка авторның өч тарихи поэмасы туплап бирелгән. Шагыйрьнең аерым тарихи шәхесләргә багышланган эпик әсәрләрен, минем уемча, шигъриятебезнең яңа буыннарны да кызыксындырырлык уңышы итеп карарга кирәктер. Гомумән, Әхмәт Рәшит үзенең төп шигъри жанрларына һәрвакыт тугрылыклы булып кала. Узган ел аның «Казан утлары»

(10-сан), «Мәйдан» (4-сан) журналларында басылып чыккан әсәрләре — шушы ихлас бирелгәнлек мисалларыдыр.

Шундый ук тугрылыкны көтмәгәндә язмыш сынавына дучар булган шагыйребез Рөстәм Мингалимнең яхшы мәгънәдәге иҗади үҗәтлегендә дә күрмичә мөмкин түгел. Ул тырышып-тырмашып эшләвен дәвам итә. Былтыр аның «Казан утлары» журналында (4-сан), «Мәдәни җомга» газитендә (40-сан) үзенчә контрастлы обазларга һәм фикри метаморфозаларга бай шәлкемнәре һәм Татарстан китап нәшриятында «Дәрт чүлмәге» исемле җыентыгы дөнья күрде. Бирсен Ходай, Рөстәм абыйның «дәрт чүлмәге» тулы торсын!..

Безнең шигърияттә Зөлфәт белән Мөдәррис Әгъләм иҗатлары, ничектер, янәшә чабып баручы акбүз атларны хәтерләтә. Аларның йөрәк кагышларында да, ыргылыш ритмнарында да уртаклыклар шактый. Әлеге шагыйрьләребезнең язганнарын укыганда шуңа тагын бер мәртәбә инанасың: иҗатчы камиллеккә ирешә барган саен аның миллилеге арта гына төшә. Үткәнне, бүгенгене, киләчәкне колачлаган милли гамь... Аларның әсәрләреннән әнә шундый уртак гамь саркып тора кебек. Узган ел «Казан утлары», «Мәйдан» журналларында (2; 5-саннар) саллы-саллы тупламалар чыгарган Зөлфәт үзенең бер шигырендә һәрбер татар кешесен уйга салырлык сорау белән мөрәҗәгать итә:

*«Нишләдек?»—дип, без ачынган чакта*
*Сүнгәч соңгы учак-ялкыннар,*
*Үткәненә—безгә колак салып,*
*Киләчәктән безне кем эзләр?!*
(«Хәерлегә булсын!»).

Чыннан да, әгәр теге яки бу шагыйрьнең иҗатында халык язмышына бәйле уй-гамь калку чагылмаса, аның тулаем язганнары киң җәмәгатьчелектә әллә ни зур әһәмияткә ия була алмый. Бу яктан Айдар Хәлимнең әсәрләрендә милләт өчен өзгәләнү артыгы белән бар. Хөр-ирекле фикер гадәти шигырь үлчәмнәренә генә сыеша алмый, шашкын хис исә өермә агымыдай бөтерелә-бөтерелә алгарак ыргыла!.. Минемчә, Айдар Хәлим шигърияткә менә шундый язу холкы белән килеп керде, һәм аның төп үзенчәлеген билгеләгән әлеге хасият бүген дә җетелеген җуймаган. Бу сүзләргә шагыйрьнең былтыр «Казан утлары»нда чыккан «Кичке җайдак» циклы (1-сан), «Рухият» нәшриятында дөнья күргән «Тилергән сирень» исемле саллы китабы ышандыргыч дәлил була алыр дип уйлыйм.

Рухи яссылыктан караганда, шагыйрьләрдә иммунитет дигән нәрсә гомумән булмыйдыр—алар милләтнең һәрбер авыру-сызлануларын, гадәттә, үзләренең җаннарына кабул итеп алучан. Менә шундый олы хис-кичерешләрнең бихисап төсмерләрен без «Аңлыймчы, җикән, моңнарың!..» дип ялварган Марс Шабаевта да, «Татар кешесе», дип өзгәләнгән Гәрәй Рәхимдә дә, «Йокы юк шагыйрьгә», дип аһ орган Рәдиф Гаташта да, халык санының ким чыгуына хәсрәтләнгән Роберт Миңнуллинда да, «Керсен бәйрәм татар өенә», дип иҗтиһат кылган Разил Вәлиевтә дә әледән-әле күреп торабыз.

Милләт гаме белән янып яшәү Илдус Гыйләҗевнең дә һәрбер шигырендә диярлек ачык төсмерләнә. Шагыйрь бердәй маһирлык белән актив иҗат итә, газит-журналларыбызда игътибарга лаек тупламалар чыгара. Шулай ук Харрас Әюп, Рим Идиятуллин, Шамил Маннапов, Әхмәт Гадел, Нур Әхмәдиев, Госман Садә, Факил Сафин, Мөхәммәт Мирза, Рафис Корбан, Вазыйх Фатыйхов кебек шагыйрьләребез дә халкыбыз турында гасырлар дәвамында языла торган кумәк «шигъри рухнамә»гә үзләренә генә хас күзаллау рәвешендәге кыйтгаларын һәрдаим өстәп киләләр. Бу җөмләдән Рашат Низаминың шигъри жанрга зуррак игътибар бирүе дә сөендерә. Былтыр ул «Казан утлары» (3-сан), «Идел» (4; 12-саннар), «Мәйдан» (8-сан) журналларында, «Мәдәни җомга» газитендә (5; 4-саннар) үзенең үсеш-камиллек юлында булуын күрсәткән шигъри шәлкемнәрен тәкъдим итте. Узган елгы шигъри уңышларыбыз рәтенә, минемчә, Гарифҗан Мөхәммәтшинның зирәклек югарылыгында язылган робагыйларын да кертергә мөмкиндер («Мәдәни җомга», 42-сан).

Бүгенге шигъри хәрәкәттә үзләренең иҗат үзенчәлекләре белән нииндидер аерымлыкта торган бер төркем каләм ияләре бар: Рәфикъ Юныс, Акъегет, Мөдәррис Вәлиев, Шәүкәт Галиелша, Рәмис Аймәт, Габделнур Сәлим, Марат Закир, Хәмит Латыйп... Бездә бит укучы да төрле. Һәрхәлдә, талымсак шигърият сөючеләр санап үтелгән каләмдәшләребезнең әледән-әле күренеп килүче әсәрләреннән канәгатьләнү алалардыр дип уйлыйм.

Инглиз эссеисты Роберт Линдның «Ир-атлар сакал-мыек йөрткән чакта яхшы шагыйрьләр чоры башлана» дигән сүзләре искә төшсә, нилектәндер, үзебезнең егетләребез Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Ләис Зөлкарнәй, Ләбиб Лерон, Наис Гамбәр, Җәүдәт Сөләйман күз алдына килеп баса. Гадәти очраклылык, дисәм, үткән гасырлар томанында көрәк сакаллы Кол Гали, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, Мәүлә Колый,

Габдерәхим Утыз Имәни, Габделҗаббар Кандалый, Акмулла, Дәрдемәндләр шәйләнгәндәй була. Безнең яшь «сакалбай»ларны аларга һич тә тиңләштермичә, мондый уртаклык билгесендә нииндидер сер булуын гына искәртеп үтәм. Хикмәт сакал-мыек йөртүдә генә түгел, алар теләсә нинди кыяфәттә дә элгәрләрен лаеклы дәвам иттерүче талантлы буын вәкилләре булып калалар. Әлеге каләмдәшләремнең югары шигырь культурасы биеклегендә торуы, иң әһәмиятлесе, шушы биеклектән милли тамырларыбыз тирәнлегенә төшә алуы һәркемне сөендерәдер. Бу уңайдан милләт гамьле егетләребезнең берсе Газинур Моратның бер шигыреннән өзек китерү белән генә чикләнәм:

*Үткәннәрен эзләп табар халык*
*Киләчәккә кайтыр юллардан.*
*Тарих безгә сөер сер калдырган:*
*«Татар тугач, яһүд елаган...»*

(«Тарих безгә сөер сер калдырган»).

Хикмәтле китапларда хатын-кызлардан гына торган кешелекне күз алдына китерергә мөмкин икәнлеге, әмма ирләрдән генә торган кешелекне күзаллап булмавы турында искәртелә. Табигый ки, ир-ат шагыйрьләрдән генә торган шигърият тә никадәр күңелсез булыр иде. Бу инде хакыйкать: хатын-кыз шагыйрьләрнең образлы фикерләвендә хискичерешләр гаммасы беркадәр баерак, шигъри тел тукымасына салынган җылы чагыштырмача мулрак, уй-моң агышындагы көтелмәгән контраст-борылышлар ничектер күбрәк кебек тоела. Алар өчен материянең шигъри эчтәлексез бер генә атомы да юктыр шикелле. Күз алдына китерик: безнең бүгенге шагыйрәләребез Флера Гыйззәтуллина, Лена Шагыйрьҗан, Клара Булатова, Эльмира Шәрифуллина, Салисә Гәрәева, Бикә Рәхимова, Нәҗибә Сафиналарның язганнарын. Аларның шигырьләреннән нииндидер илаһи ут җылысы бөркелеп тора сыман. Чыннан да, әлеге ут синең күшеккән җаныңны җылыта, кайчак пешереп-өтеп ала, күңел-кальбеңне эчтән яктыртып күрсәтә. Бу җәһәттән Гөлшат Зәйнашева, Энҗе Мөэминова, Резеда Вәлиева, Марзия Фәйзуллина, Роза Хафизова кебек өлкәннәребезнең шигырь утын исән-аман тотулары өчен сөенергә генә кирәк. Халык язмышына кагылышлы олы төшенчәләрне Шәмсия Җиһангирова, Фирая Зыятдинова, Флера Тарханова, Сәйдә Зыялы, Асия Юнысова, Фирдәвес Әһлия, Фәүзия Солтан ише шагыйрәләребез үзгә шигъри интуиция төсмерләре белән баеталар икән, димәк, безнең шигъриятебез кешеләр күңеленең төрледән-төрле үлчәмдәге дулкын-тирбәлешләренә тәңгәл җавап кайтарырга сәләтле дигән сүз.

Чыннан да, хатын-кыз үзенең кабатланмас интуициясе белән хәтта чиста-ак битләрдән дә нидер укый ала. Нәкъ менә шушы сыйфаты белән ул кайчак шигырьдә сине сискәндереп тә куя. Әйтик, Рифә Рахманның ошбу юлларын гына укып карыйк:

*Пәйгамбәрләр,—диләр бездә,—ирләр генә,*
*Ә Алланың юк җенесе һәм өммәте.*
*Әйе! Булса ул да әгәр ирләр кебек,*
*Кылыр идемени чиксез мәрхәмәтне?!*

(«Элек һәм хәзер»).

Хикмәти хода, мондый хәтәр олы уйлар Рифә башына гына килгәнме, дисәм, Халисә Мөдәррисова да бу хакта гөман итә икән:

*Үз илендә пәйгамбәрләр булмый,*
*Булмасам да мин дә пәйгамбәр, -*
*Минем авыр йөктән хәзинәсен*
*Үзе алыр үзенә тигәннәр...*

(«Үз илендә...»)

Әлеге шигъри өзекләрдә чагылып үткән «пәйгамбәрлек мәсьәләсе»н төрлечә шәрехләргә мөмкиндер, әмма шәхсән үзем шул рәвешле күзаллауда шагыйрәләребезнең олыдан кубып фикерләү галәмәтен, үзләренең тагын да зуррак рух потенциалына ия булуларын сиздертү омтылышын күрәм. Гадәттә, уйда мескенләнсәң, гамәлдә дә кызганыч хәлдә каласың. Һәрхәлдә, шагыйрәләребезнең күнегелмәгән яңа фикри катламнарны ачуы аларның шул ук үзгә шигъри интуициясеннән киләдер.

Әле генә телгә алынган каләмдәшләребез узган елгы әдәби хәрәкәттә эшчән-өлгер булдылар. Әйтик, Рифә Рахман «Казан утлары» журналында (5-сан) һ.б. басмаларда шигырь бәйләмнәрен, ә «Мәгариф» нәшриятында «Мине генә уйла» һәм «Сиңа» исемле китапларын чыгарды. Шул ук Халисә Мөдәррисованың да барлык татар басмаларында диярлек шигъри тупламалары дөнья күрде; Татарстан китап нәшрияты аның «Шәмәхә төн» исемле җыентыгын бастырды. Тынгы белмәүче Нәҗибә Сафина да, гәзит-журналларыбызны шигырьләре белән биләп алып, үзенең күркәм юбилеена бик матур якынлашты. Бүгенге

әдәбият дөньясында күпмедер бертөрлелек хөкем сөргән заманда, Лена Шагыйрьҗан «Казан утлары»нда (7-сан) «Япон шигъриятенең асылташлары» исемле цикл чыгарып, югары зәвыклы һәвәсмәннәрне затлы тәрҗемә үрнәкләре белән дә сөендерде. Моңарчы ул шушы ук журналда татар укучысын — Бертольт Брехт, Байрон «Мәдәни җомга»да Габриела Мистраль һәм Анна Ахматова әсәрләре белән таныштырган иде.

Гомуми шигъри иҗатыбыз белән танышканда мин шуңа игътибар итеп гаҗәпләндем: соңгы берничә дистә елны күздә тотып әйткәндә, шагыйрәләребез арасында буыннар өзеклеге бөтенләй дә күзәтелми икән. Әйтик, шигърияттә үз урыннарын алган Фәйрүзә Мөслимова, Илсөяр Иксановалар артыннан кыю адымнар белән Фирүзә Җамалетдинова, Рәзинә Мөхияр, Таңчулпан, Лиана Әмирханова, Ләйсән Кәшфиләр килә. Әлеге буынның көчле дәвамы булган Луиза Янсуар белән Гөлназ Вәлиева, минемчә, үзләренең әдәбиэстетик өзерлекләре ягыннан аерым игътибарга лаек. Шуңадыр да, аларның яңа шигырьләрен уку күңелдә һәрчак зур өметләр уята.

Беркемгә дә сер түгел, һәрбер буын шагыйрәләре иҗатында сөю-ярату темасына зуррак өстенлек бирелә. Күзәтүләрдә еш искәртелгәнчә, хатын-кызның «мәхәббәткә куып кертелүе» бик табигый. Нишлисең, Нәҗибә Сафинача әйткәндә, «Дөньядан китү юлында Мәхәббәт—ныклы киртә». Әлбәттә, шагыйрәләребезне башка маузуг-мәсьәләләр дә бердәй борчый. Шул ук милләт гамен дә алар бездә, ягъни ир-атларда булмаган ниндидер алтынчы тойгы төсмерләре белән ачып күрсәтү осталыгына ия. Мәсәлән, Флера Гыйззәтуллина шигырьләре тукымасында сөю-ярату җепләре кырыс чынбарлыкның җәте җирлегендә ничектер күмелебрәк калган кебек тоела. Юк, аның бу темага багышланган күпчелек әсәрләре, әйтик, борынгы грек шагыйрәсе Сапфоның якты-аяз лирикасына охшамаган. Моның сәбәпләре аңлашыла, чөнки язмыш шигъри җанлы кызны гамьсез балачактан назлы-якты мәхәббәткә түгел, ә, гомумән, сабыйлык яшеннән үк миһербансыз ятимлек-үгилеккә кысрыклап керткән, үсә төшкәч, билдән су ерып йөрешле Себер шахталарына төшергән, җиде кат тир чыгарырлык юл төзү эшләрен башкарырга мәҗбүр иткән. Әмма могҗизалы шигърият аны барыбер саклап калган. Тән-җанга кысан булган килешсез «язмыш кулмәкләре»н үзенчә үзгәртеп җөйләүгә ирешкән Флера Гыйззәтуллина илһамлы иҗат аша сулыш алып яши, дөньясын онытып дигәндәй, көннәр, атналар, айлар буена өзлексез бер тында күпләрнең «язмышларын дәваларлык» шигырь-поэмаларын кәгазь битләренә төшерергә ашкына. Әсәрләрендә ил-көн гаме сагышлы кырыс мәхәббәтнең алдынарак чыга шикелле.

*«Син бәхетлеме?»—дип сорамагыз!*
*Үз бәхетем өчен җан атмыйм мин:*
*Җир тирәли очкан чал бөркетнең*
*Канат кагышларын кабатлыйм мин.*

(«Сорамагыз!»).

Шундый ук уй-борчуларны Бикә Рәхимова да мәхәббәтле йөрәк аша үткәрә кебек:

*Бер менгәч биек офыкка,*
*Җан киңлекне ташламый;*
*Бу—җырның иңрәп иңүе,*
*Бу—салават башламы...*

(«Биеклектә калу»).

Ә Клара Булатова исә, хатын-кыз иңенә бик күп көянтәләр белән асылган йөк-вазыйфаларны күзаллап, өлкәннәр зирәклеге аша ачы тәҗрибә авазын ишеттерә:

*Хәерчелек тетә, изә, сыта,*
*Бөтерелә фәкыйрь дөньяларда...*
*«Фәрештәләр һаман яланаяк,*
*Итекләрен шайтан урлаганга...»*

(«Диңгез кызы...»).

Инде шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер: соңгы елларда әдәбиятыбыз, шөкер, матбугат мәйданына кытлык кичерми. Күпчелек гәзит-журналларыбызда шигъриятккә киң урын бирелә. Иң яхшы иҗат үрнәкләрен укучыларга тәкъдим итүдә, әлбәттә, «Казан утлары» төп профессиональ басма булып кала. Тезмә әсәрләрне сайлап бастыруда «Идел», «Мәйдан», «Сөембикә», «Татарстан» кебек журналлар да зур таләпчәнлек күрсәтә. Шулай ук «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» гәзитләрендә дә кульязмалар җиз иләктән үткәрелә. Бирелеш формалары да төрлеләнеп бара. Бу уңайдан «Мәйдан» журналының әзләнүләрен аерым билгеләп үтәсе килә. Кем ничек кабул итәдер, журналның теге яки бу шагыйрь иҗатына багышланган саннары минем өчен тулы бер энциклопедик басмалар кебек тоела. Мәсәлән, һәр төрле мәгълүматка тартылучы укучылар «Мәйдан»ның Фәнис

Яруллин, Әхмәт Рәшит, Роберт Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Шәүкәт Галиев кебек шагыйрьләребез турындагы саннарын яратып кабул иткәндер.

Журналларыбызның тагын бер игелекле гамәлен күрсәтеп үтмичә мөмкин түгел: ул — яшь каләм ияләре иҗаты белән таныштырып бару. Узган елда гына да «Танышу», «Яңа исемнәр» һ.б. шундый рубрикалар астында «Казан утлары» журналында — 9, «Идел»дә — 14, «Мәйдан»да — 40, «Сөембикә»дә 4 яшь авторның шигырьләре тәкъдим ителгән. Яшьләргә хәерхаһлык күрсәтеп, аларга фатиха бирү, беренче китапларына бәяләмәләр язу җәһәтеннән мөхтәрәм шагыйребез Рәдиф Гаташ чын мәгънәсендә остазлык вазыйфаларын башкарып килә.

Шунысы да сөендерә: еш кына басма сүзнең, бигрәк тә шигъри җыентыкларның кадере төшүеннән зарлансак та, соңгы елларда әдәби-нәфис китаплар нәшер итүдә беркадәр үсеш күзәтелә. Бу эштә әйдәп баручы Татарстан китап нәшрияты гына да бүгенге тотрыксыз заманда шигъри басмалар күләмен нигездә элекке «китап бумы» чорындагы дәрәҗәдә саклап кала алды һәм узган елда җәмгысе 29 шагыйребезнең әсәрләрен бастырып чыгарды. Алар арасында Әхсән Баянның биш, Гәрәй Рәхимнең ике томлыгы, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллин, Клара Булатова, Эльмира Шәрифуллина, Мөхәммәт Мирза һ.б.ларның китаплары бар. Хөкүмәт ярдәме белән күптомлыклар чыгаруга да башка күп кенә халык әдипләре көнләшеп карар иде. Шулай ук «Мәгариф» нәшрияты да шигъри басмаларыбыз киштәсен әледән-әле баетып тора. Былтыр әлеге нәшриятта «Милли әдәбият китапханәсе» сериясеннән «Татар шигърияте. 1980-2000 еллар» исемле зур томлык дөнья күрде (төзүчеләре — Тәлгат Галиуллин һәм Нурфия Гафиятуллина), шагыйрь Җәүдәт Сөләйманның «Кизләү» дип исемләнгән күркәм җыентыгы басылып чыкты. Татар милли китабын аерым игътибар үзәгендә тотучы «Матбугат йорты», «Рухият», «Идел-пресс» нәшриятлары, шулай ук Чаллы басмаханәләре шигърият сөючеләргә 31 китап, аерым алганда: Фәнис Яруллин, Гәрәй Рәхим, Факил Сафин, Вазих Фатыйхов, Галимҗан Гыйльман, Мидхәт Миншин, Илсөяр Иксанова, Рәзинә Мөхияр, Чулпан Зариф, Ләйсән Кәшфи җыентыкларын тәкъдим итте.

Шөкер, шигъриятебезнең хәле алай ук зарланырлык түгел, күңелләребездәге шигырь уты исән-сау. Әмма форсат чыккан чакта кайбер күзәтүләрем белән дә уртаклашып үтәсем килә.

Минем карашымча, соңгы елларда шигъриятнең профессиональ дәрәҗәсе бераз төшә башлады шикелле. Без поэтика кануннарына игътибарны киметеп барабыз. Үзләренең язганнарын сәнгатьлелек ягыннан камиллек дәрәҗәсенә җиткерә алмаучылар, аерым редактор ярдәменә мохтаҗ авторлар ишәя төште.

Һәммәбезгә мәгълүм, хәзер әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр бермә-бер артты: балалар да, яшүсмерләр дә, урта яшьтәгеләр дә, өлкәннәр дә, картлар да тырышып-тырышып шигырь яза. Әлбәттә, бу — күңелле фал. Әмма, икенче яктан караганда, иҗатта үзешчәнлекнең чамадан тыш көчәеп китүе зур шигъриятькә күләгә төшерә башлады. Профессиональлек белән үзешчәнлек нисбәтен табигый хәлгә кайтару өчен бер генә юл бар: шигъри кульязмаларга карата таләпчәнлекне арттыру, бәяләү критерийларын катгый саклау. Кайчак шулай да була: уртакулдан да түбән әсәрләр авторы күккә чөеп мактала, ә әдәбияттә төпкә җигелеп тартучы кайбер каләм әһелләре игътибардан читтәрәк кала. Шул рәвешле халыкның зәвыгы түбәнәя, рухи ориентирлар бозыла...

Классик әдипләр искәртеп килгәнчә, даими үсеш, даими камилләшү юлында булу чын талант билгесен күрсәтә. Гомумән, шигъриятьтә яңалыкка омтылу — зарури шартларның берсе. Кызганыч, менә шушы кагыйдәләрне иҗатта раслап, яңача фикерләүгә омтылучы яшьләребез алай ук күп түгел икән. Кайберләренең язу өслүбе шулкадәр бер төрле, хәтта почерклары да бер-берсеннән аерылмый кебек.

Санап үтелгән әлеге җитешсезлекләрнең барысы да, минемчә, бер асыл башлангычка кайтып кала: бу — каләм әһеленең иң беренче чиратта телгә бәйле булуы. Телгә бәйлелек дәрәҗәсе турыдан-туры аның әдиплек дәрәҗәсен билгели. Әгәр без язучылык сәнгате стиль белән билгеләнә, дибез икән, стиль үзе барыннан да элек телгә бәйле рәвештә күзаллана. Менә шушы хакыйкатьне тирәнтен аңлап иҗат иткәндә, иманым камил, безнең әсәрләребезнең сәнгатьчә дәрәҗәсе һәрвакыт югары булачак. Кыскасы, кулга каләм алу җаваплылыгын яшьләр дә, өлкәнрәкләр дә һәрдаим истә тотсын иде. Мәшһүр Тукаебыз искәрткәнчә:

*Каләм — бөек, каләм — дәрәҗәле,*
*Ходайның телендә ант урынында ул!..*

**Гаяз Исхакый**

# ИСЛАМ МӘМЛӘКӘТЛӘРЕНДӘ*

* * *

Мин хәзер тагын Фәләстинга барып, аннан Сүриягә чыгып, Бәйрутта пароходка утырып Тагуктан Италия юлы берлә Аурупага кайтачак идем. Искәндәрия-Яффа, йә Искәндәрия-Хәйфа юлы пароход берлә бик бәһале, бик озын булганга, мин тимер юл берлә генә китәргә мәҗбүр булдым. Монда Фәләстин берлә Мисырны баглый торган бер генә тимер юл булганга, килгән юлымнан киттем. Сүәеш каналы аша чыгып, Кантарада инглиз-Мисырның уртак гүмрүген *(таможнясын)* үтәргә кирәк иде. Бу араларда монда инглиз лирасы төшү-очсызлану дәвере булганга, аңа бағланган Фәләстин һәм Мисыр лиралары да төшеп килә һәм шуның аркасында алтын бәһасе күтәрелә иде. Төрле җиңелдән мал табарга өйрәнгәннәрнең кулында алтын спекуляция малы булып килә иде. Кәгазь акча төшкәнне белмәгән халыктан алтынны җыеп алып, чит илләргә сату итүчеләргә киң юл ачылган иде. Ләкин Мисыр хөкүмәте алтын алуны хәзинәнең генә *(бу очракта—банкларның.)* хакы итеп игълан иткәнгә, Мисырдан алтын чыгаруны тыйганга, алтынны чыгарыр өчен болар качак юлларына керешкәннәр иде. Шуның өчен гүмрүктә тикшерүләр бик нык була дип, гәзитәләрдә укыганга, минем алтыным-фәләнем булмаса да, гәзит һәм мәҗмугаларым бик күп булганга, боларны актаруларыннан шактый курка идем. Гүмрүккә керү берлә мин әйберләрне караучыга: "Ислам корылтае башкарма әгъзасы" дип язылган картамны тоттырдым. Ул шуны укыр-укымас олыграгына китеп күрсәтте. Ул әфәнде үзе килеп, тәфәззуллу *(рәхим итегез!)* дип, һичбер карамыйча, чемоданнарыма "рөхсәт" кәгазьләрен ябыштырып, паспорт мөгамәләмне дә җиңеләйтер өчен, минем берлә бер мәэмүрне *(хезмәткәрне.)* дә күндерде. Аннан минем паспортымны күз ачып-йомганчы эшләп бирделәр. Мин беренче юлчы булып вагонда урын алдым. Мөселман һәм мөселман җәмгыятьләренең әгъзасы булганым өчен бик күп вакытлар төрле мыскыллар, хөрмәтсезлекләр күрергә өйрәнгән миңа мөселманлыкның болай шәрәфле-хөрмәтле булуы бераз гаҗәбрәк тоелды. Без Мисыр мәэмүренең миңа шәхесем өчен түгел, мөселман корылтаеның әгъзасы булуым өчен кылган хөрмәтенә чын күңелемнән сөендем. "Мөселман"лыкның әле кыйммәте югалмаган җирләр дә барлыгын, мөселман җәмәгать хадименә хөрмәт итәргә кирәк дигән игътикадның *(ышанычның)* яшәгән урынның бар икәнен күреп, мөселманлык хиссиямә һавалык та керде.

Китәргә әле бик күп вакыт булганга, гүмрүккә тагын бер кереп, шул кешенең йөзен танып калыйм дип, бер карадым. Юлыбыз моннан соң бик тыныч үтте. Тик вагоннар бик тар булганга, йокларга имкян *(мөмкин)* булмады. Яффага иртүк килеп житсәм дә, отель табу бик җиңел булмады. Җуынып, киенеп бер автомобиль яллап Кодеска киттем. Максадым: безнең корылтайның сайлап калдырган башкарманың эшләрен һәм нинди карарларының вөҗүдкә чыгарылганын күз берлә күрү һәм ул әгъзалар берлә контактка килү иде. Башкарманың рәисе мөфти Әмин әл-Хөсәйни хәзрәтләрен мәҗлестә очраттым. Аның берлә озын-озын сөйләшкәннән соң, "Ләҗнәту тәнфизия"нең *(Башкарма комитетның.)* башкармасын карарга киттек. Сәркятиб итеп сайланган әгъзаи сабикъ *(элеккеге)* Иран баш вәзире Зыйаэддин Табтабаи бәк әле Аурупадан килеп җитмәгән булганга, Кодесның олуг мөфтисе Әмин әл-Хөсәйни башкарманың рәисе сыйфаты берлә бюроны идарә итә иде. Корылтай беткәнгә озын бер вакыт үтмәгән булса да, бюро да инде тәмам юлга куелган бер хәлдә иде. Бик күп кизүдәге эшләр тәртипкә куелып өлгергән, карарларны эшкә ашыруга керешелгән иде. Без күргәндә—бюрода эшләр кайнап тора иде. Бер тарафта корылтайда сөйләнгән нотыклар тәртипкә куелып, бер хисап

**Ахыры. Башы 4, 6 саннарда.*

төсендә нәшер ителергә хәзерләнә. Икенче якта—кабул ителгән карарлар төрле ислам халыкларының телләренә тәржемә ителә. Өченче тарафта—мөселман эшләре берлә галякалы (бәйләнешле) Аурупа дәүләтләренә һәм җәмгыяте әкъвамга (халыкара җәмәгатьчелеккә) күндерер өчен, алар Аурупа телләренә тәрҗемә ителеп, рәсми бер вәсыйка (документ) хәленә сугыла иде. Шулай ук корылтайга катышкан мөселман милләтләр хакындагы материаллар җыелып, мөселман дөньясының бөтен тормышыны өйрәнәчәк үзебез эшләгән яңа бер институтның нигезе корыла иде. Корылтайның эчке һәм тышкы дошманнары тарафыннан "Ләҗнәту тәнфизия"нең эш эшли алмаячагы хакында таратылган төрле мәгънәсез сүзләрнең ялган икәнлеген күзем берлә күреп сөендем. Шул эшне эшли алган Фәләстин олуг мөфтисе Әмин әл-Хөсәйнинең гайрәт һәм уңганлыгы алдында башны идем.

Кодеста шактый күп танышларым булса да, аларның барысы берлә дә күрешергә вакытым юк иде. Шуңа "Әл-җәмигату әл-гарабийә" идарәсен зиярәт итеп, безгә бик зур ярдәм иткән Мөниф бәк әл-Хөсәйнигә рәхмәт укып, дуст-ишкә гәзит аша бер тәшәккер хаты язып, юлыма китәчәк булдым. Хәйфа шәһәренә бергә дәгъватле *(чакырулы)* шәйх Ягъкуб әфәндене зиярәт итеп, аның тәмле чәен эчәргә киттем. Анда тагы бик күп таныш-белешне очраттым. Аларның сораулары берлә бер көн Кодеста калырга мәҗбүр булдым. Кичне шәйх Ягъкуб әфәнде өендә Бохара пылавы, Казан чәе янында уздырып, үзара сөйләштек, дәрдләштек.

Икенче көнне Яффага кайтыр-кайтмас, яһүдиләрнең бөтен дөньяга мактанган шәһәрләре Тел-Абибны *(Тель-Авивны)* зиярәткә киттем. Бу шәһәр Яффаның күршесендә генә. Ике шәһәр арасында бер тар гына юл үтә. Кайбер җирләрен әфлисүн бакчалары аера. Мин бу шәһәр хакында бик күп ишеткәнгә, аны мактау берлә пароходта вакытта колакларым тонганга, мин Париж, Берлин кебек булмаса да, Прага, Варшау, Дрезден, йә Анкара кебек бер шәһәрне күрергә хәзерләнгән идем. Юлны яхшы белмәгәнгә, бер арбачы алдым һәм Тел-Абибның мәркәзенә илтергә куштым. Яффадан чыктык кебек булдык. Яффанықына караганда урамнары кинрәк, бер авыл дисәң—авыл түгел, бер бистә кебек. Авыл Казанның Яңа Бистәсе төсле дә булып күренә, Бишбалта кебек тә булгалап куя. Кайбер җирләре зур шәһәрләр тирәсендәге җәйләү *(дача)* җирләре төсле дә булып ала иде. Арбачыга акрын барырга кушкан булсам да, 10-15 минуттан соң арбачы торды: "Килдек",—диде. Мин ачуланыбрак: "Кая килдек? Мин сиңа шәһәрнең уртасына илт дидем. Син мине кырыендагы дачаларга туктатасың!"—дидем. Ул моны шәһәрнең уртасы булганын, әнә почтаханә, әнә кибетләр, әнә каһвәләр *(каһвәханәләр)* булганын күрсәтә башлады. Мин тирә-юньгә карадым. Чынлап та шул нәрсәләрне күрдем. Аттан төштем. Ләкин арбачыга ышанмаганга, бер очраган яһүдидән урысча шәһәрнең мәркәзен сорадым. Мондагы яһүдиләрнең 80 проценты урысча белгәнгә, ул миңа урысча җавап бирде. Ул берничә урамнарның исемнәрен сөйләп, кулы берлә күрсәтте. Шәһәрнең иң зур ресторанннарыннан "Казино"ны бик мактады. Мин акрын гына иң олуг урам буйлап киттем. Күзем һаман зур-зур өйләр, зур магазиннар, мәктәпләр һәм театрлар эзли иде. Ләкин күзгә бәрелгән биналарның йөз дә туксаны бер йә ике катлы урамга өч-дүрт тәрәзәсе берлә караган өйләр генә иде. Һәрбер өйнең асткы каты бер кибет төсенә куелган һәм аларга яһүдичә вывескалар язылып, аларда нәрсәләр сатылганы белдерелгән иде. Тик бу кибетләрнең барысы да кечкенә өяз шәһәрендәге кибетләр кебек кенә иде. Тәрәзәләргә куелган товарлар да Аурупада модасы чыгып беткән маллар иде. Ләкин аларның күбесе иске кибет иде. Зур урамны йөреп чыктым. Мин ялгыш китермәделәр микән дип шөбһәләнеп, тагы бер яһүди хатыннан сораштым. Дөрес икән. Яһүдиләрнең Сөләйман пәйгамбәр сарае ватылганнан бирле беренче итеп корган бер шәһәрләрендә йөрим икән. Йөри торгач, Тел-Абиб өчен махсус эшләнгән вокзалга килеп чыктым. Тагын киттем. Ләкин һичбер яна мәһабәт бай бер шәһәрне таба алмадым. Шәһәр читенә килеп чыктым. Анда өелгән бина, бина эшләре өчен китерелгән тимер-томыр, асфальт, таш, агачларны очраттым. Ләкин анда һичбер хәрәкәт күренми, нә боларны ташучы бар, нә алучы бар *(ягъни "юк" мәгънәсендә)*. Барысы да өелгән дә куелган. Берсенең янында бер каравылчыны күреп: "Болар нәрсә?",—дип сораштым.

—"Болар Америкадан килгән, бина салыр өчен хәзерләнгән материаллар иде, хәзер менә шулай череп яталар",—диде. "Ник соң биналар салмыйлар?"—дидем. Каравылчы шуңа миңа гөнаһлы иттереп карап: "Акча кая?"—диде. Яңа биналар салынып-салынмавына дикъкать итәргә тотындым. Аурупа шәһәрләрендәге кебек зур биналарның салынуына очрамадым. Шәһәр читендә берничә ике-өч бүлмәле өйләрнең эшләнеп ятканын һәм кайбер җирләрдә үткән ел башланып та бетми калган бинаны бетерергә маташуларын күрдем.

Ике сәгать буе җәяү йөреп арганга, ашарга кирәргә булдым. Иң зур ресторан дигән "Казино"ны сорап таптым. Ул диңгез өстенә салынган, Истанбул Бугаз эчендәге йөзләп-меңләп ясалган ресторааннарның берсе кебек бер ресторан икән. Мин кергәндә аш вакыты булса да, бер генә мосафир бар иде. Миннән соң ике егет берлә бер кыз керделәр. Мин, әҗнәби сәйях *(чит ил сәяхәтчесе)* төсе бирер өчен, французча сөйләргә тотындым. Бик мактый торган Фәләстин шәрабы берлә аш сорадым. Аларның иң мактаган балыкларын бирергә куштым. Аштан соң кафвә сорап, гарсунга *(гарсон; официантка)* чәйлек бирдем дә, шәһәрнең зур, мәшһүр җирләрен сорашырга тотындым. Мин һаман әле үземне адашып, Тел-Абиб дигән пайтәхетнең тирәсендәге бистәләрдә генә йөримме дигән шөбһәдә идем. Гарсун бик рәхәтләнеп мин кичкән урамнарны, мин күргән биналарны сөйләде. Ашап чыккач, килгән юлымнан киттем. Былчырак урамнар эчендәге кечкенә, фәкыйрь яһүди өйләре арасына килеп кердем. Анда борылдым, монда борылдым—10-15 минут үтмәде—тагын Яффага килеп чыктым.

Әле вакытым күп булганга, Яффа шәһәрен карарга керештем. Бу шәһәр бик иске булганга, монда гаҗәп урамнар бар. Андый тар урамнар хәзер Мисырда да, Истанбулда да, Римдә дә калмаган. Шул урамнарның берсенә кереп, берсеннән чыгып йөргәндә, бер җирдән ачык госманлы шивәсендә бер нотыкмы сөйләнгәнен, конферансмы бирелгәнен ишеттем. Тирә-юньгә карандым: бу тавыш бакча эченә салынган, тәрәзәләре ачык бер бинаның эченнән чыга икән. Монда төрекләрнең бер мәктәбеме, клубымы бар күрәсең,—дип, капканы ачып кердем. Тавыш ишетелгән бинаның ишеген ачып, акрын гына өйгә дә аяк бастым. Карангы гына бер өйгә урындыклар куелган. Бер тарафка егерме-утыз хатын утырган, бер тарафта —шул кадәр дә ирләр. Өйнең түрендә кара киенгән бер кеше көрсигә *(бу очракта—трибунага)* чыккан да, сандугач кебек төрекчә сөйли. Минем керүем бераз гаҗәбрәк тоелды күрәсең, һәркем бер-берсенә каранды. Мин бер буш урындыкка утырдым. Тышта калган күзем ярты карангылыкка өйрәнеп өлгергәч, мин үземне хачлы *(тәреле)* бер өйдә икәнемне аңладым. Сөйләүче дә: "Менә хәзер Мәтинең *(Матвейнең.—Г.И.)* "Инҗил"нең фәләненче аятен укыйбыз",—диде. Иске госманлы шивәсендә берничә юллык "Инҗил"нең бер аятен укыды, ул Хәзрәте Гайсәнең авыруларны терелтүе хакында иде. Ул шуны аңлатырга кереште. Сөйләгән сүзләре, мохакәмә *(фикер)* йөртүе, Хәзрәте Гайсәнең могҗизаларын фән ягыннан тәфсир итәргә тырышуы—бу кешенең Аурупа тәрбиясе күргән икәнен күрсәтә иде. Озын мисаллар берлә Хәзрәте Гайсәнең биредән алган саз берлә бер сукырның күзен ачканын сөйләгәннән соң: "Монда ачучы куәт ул саз да, йә аның эчендәге матдәләр дә түгел иде, авыруның үзенең әхвале рухиясендә иде. Ул "Хәзрәте Гайсәне күрсәм, анардан дога алсам, күзем ачылачак",—дип, иман әйтеп куйган иде. Аның күзен саз ачмады, менә шул иман ачты",—диде.

Мин озын (озак) торырга вакытым булмаганга, акрын гына торып чыктым. Минем артымнан бер кеше дә чыкты. Ул шул чиркәүсымак өйнең сакчысы, имеш. Сораштым. Бу төрекчә "Инҗил" укучылар әрмәниләр, имеш. Болар әрмәни телен белмәгәнгә, бөтен гыйбадәтләрен төрекчә кылалар икән. Үзләре христианлыкның реформатор бер мәзһәбенә ияргән булганга да вә телләре, гадәтләре берлә әрмәничә сөйли торган әрмәнләргә башка булганга, аларга катышмыйча аерым бер тормыш берлә яшиләр икән. Мине төркияле дип уйлаганга: "Төркиядә хәлләр ничек?"—дип сорады. "Яхшы, сез ник кайтмыйсыз?"—дидем. "Анда бит хәзер әрмәннәрне яратмыйлар",—диде. Мин: "Анкараның үзендә сезнең кебек төрекчә сөйли торган әрмәннәр аерым бер мәхәллә булып яшиләр. Фәкать алар католик мәзһәбендә. Аларга һичкем бер сүз әйткән юк. Сезгә дә шулай булачак. Монда төрле чит халык арасында яшәгәнче, дин аерым булса да, үзеңнең ана телендә сөйләгән төрекләр берлә яшәү җиңелрәк, күңеллерәк булыр",—дидем. Ул: "Шулай инде. Ләкин бит төрекләр берлә әрмәнләр арасында бу хәлләр булып үтте... Без дә монда калдык",—диде, үзе дә аптырап куйды.

Әрмәни попларның тәлкыйни *(вышандыруы)* буенча, үзен әрмәни дип уйлый торган бер төрек углы төрекнең әрмәнләрнең милли эшләренә өмәче булып йөреп, иленнән адашып, халкыннан аерылып калган бу кан кардәшнең авыр хәленә чын күңелдән кайгырдым, кызгандым. Ләкин моның берлә минем арада ялганнан оештырылган бик биек коймалар халыкның бу ике углының аңлашуына мәнигъ (киртә) булганга, эчемнән яныпп—"Кемләргә безнекеләр корал булмадылар, нинди агымнарга безнең төрекләр өмәче булмадылар!"—дип, төрк халкының үткәнен, хәзерге хәлен һәм киләчәген төшенә-төшенә отелемә юналдем.

Икенче көнне шәйх Ягъкуб әфәнде берлә Хәйфага киттем. Акрын гына йөри

торган тимер юлы берлә дүрт-биш сәгать юлда калып, Хәйфа шәһәренә килеп життек. Вокзалда безне илдәшебез Габдулла әфәнде Тимур һәм бер төркем йирле гарәб җәмәгать хезмәтчеләре каршы алды. Безне алдан хәзерләп куелган Габдессәлам әфәнде исемендәге бер яшь сәүдәгәрнең өенә мосафир иттеләр. Габдулла әфәнде хакында мин Кодес-Мисыр сәяхәтләремдә бик күп ишеткән, аның берлә инде берничә мәртәбә хатлашкан булсам да, бу вакытка кадәр күрешергә насыйп булмаган иде. Ул да мине ишеткән, минем хакымда укыган, гарәп гәзит-журналларында рәсемнәремне күргән булса да, Русиядә вакытта очрата алмаган икән. Ул безнең тәмам якташ: күрше авылдан булып чыкты. Спас өязе, Салман авылы хәзрәтенең углы булган бу зат элгәреге тәхсилне *(укуны)* Уральск шәһәрендә кылып, сугыштан элек Мисырга килгән вә андагы дини мәдрәсәләрдә тәхсилен дәвам иттергәндә, сугыш башланып китеп, иленнән өзелеп калган икән. Ул Фәләстиндәге югары баскыч дарелмөгаллимне *(укытучылар институтын)* бетереп, Фәләстиндә мөгаллим булып йирләшкән. Эзчелек өйрәнеп, Фәләстиндә беренче эзче *(? спортның бер төре, скаут, следопыт)* оешмасын тудырган. Тәхсилен тәмамлар өчен Лондонга барып, андагы тәрбия вә эзчелек институтыннан шәһадәтнамә алган. Кыяфәте, гадәте берлә тәмамән безнең тирәнең мишәре булса да, ана теле ачык Чистай шивәсе булса да, хәзерге көндә гарәп мәдрәсәләрендә гарәп егетләренә гарәпчә әдәбият вә фәсахәт *(сәнгатьле уку һәм сөйләү; риторика)* дәресләрен өйрәтә вә Фәләстиннең зур бер өлешендә эзчеләрнең командылыгын ясый. Үзе вакытның кадерен белә торган бер зат булганга, безнең кыска вакытыбызны тулы үткәрер өчен көне көненә бер программ да ясап куйган. Өй хуҗалары берлә танышып, аш ашар-ашамас, программ буенча, йөрергә тотындык.

Беренче иттереп Хәйфаның өстендә хаким булып тора торган вә Хәйфаның җәйге эссе көннәрендә тын ала, хәл җыя торган җәелге (?) булган "Әл-Кәрмәл" тавына киттек. Берничә йөз метр югарылыкка бер зур тау бөтен Хәйфага вә аның лиманына *(портына)* хаким бер хәлдә булганга, төрекләр заманында монда шәһәрне саклый торган кальгъә булган. Бу йир диңгездән бик югары булып, урман берлә капланганга, җәй көннәрне һавасы могтәдил *(уртача)* булганга, бу йир бөтен ерак кешеләрнең җәйләүлекләре булган. Тауның өстеннән диңгезгә вә тирә-юньгә киң манзара ачыла. Монда бик күп җәйлек өйләргә башка, тирә-юньнән килгән мосафир өчен отельләр, пансионлар да бик күп. Ләкин бу матур йирне соңгы елларда яһүдиләр баса башлаганнар. Бөтен әтрафны *(тирә-юньне)* югарыдан карап йөреп, озын итеп йөреп, өйгә кич кенә кайттык. Кичке аштан соң безнең берлә күрешергә бөтен шәһәрнең олуглары килде. Боларның барысы да гарәп булса да, бик күбесе төрекчәне бик яхшы сөйли иде. Зыялыларының күпчелеге төрек мәктәпләрендә укыганнар иде. Эчләрендә һичбер төрек дошманлыгы күренми иде. Безне зиярәт итүчеләрнең арасында бик күбесе тәрәккъкыйпәрвәр сәүдәгәрләр иде. Бик күбесе үзенең дөньяга карашы, тирә-юнен аңлавы берлә безнең сугыштан элеккеге тәрәккъкыйпәрвәр сәүдәгәрләребезгә бик охшаган иде. Безнең яшь сәүдәгәрләр кебек, болар да бик җанлы, бик тырыш вә бик иманлы иде. Икенче көнге күрешүләр вә шәһәр берлә танышуларымда мин моның сәбәбен аңламадым. Хәйфа сату-алу өчен бик мөһим урын булганга, монда шактый күп яһүди сатучысы килеп тулган вә гарәп яшьләрен дә алар берлә ярышу хисен уяткан. Болар яһүди сәүдәгәрләре берлә ярышыр өчен сәүдә юлына бил баглап керешкәннәр. Хосусан, боларның бу эштә хәлфәләре булган зыялы булган сәүдәгәр Габдеррәшид Ибраһим әфәнде—искитәрлек бер кеше. Бу зат бөтен Фәләстиндә "Гарәп банкасы" ачучыларның беренчеләреннән. Ул Хәйфадагы гарәп банкасының мөдире вә андагы мөселманнарның бөтен икътисади вә мәдәни оешмаларының әгъзасыдыр. Ачык фикерле, халкын сөюче бу зат үзенең икътисади төшенчәсе берлә безнең Мәскәү сәүдәгәрләрен хәтерләтә. Бик хәммиятле *(сизгер; зирәк)* бер зат булганга, ватаны Фәләстинне яһүдиләргә каптырмас өчен, икътисади бик зур тартыш алып бара. Гарәпнең мал көчен бергә җыеп, аны гарәп файдасына кулланырга тырыша. Гарәп сәүдәгәренә, гарәп авыл халкына кирәк вакытта акча бурычка бирү берлә, гарәпне сату-алу базарына яһүдигә бирелмәслек хәлгә китерергә җан-тәннән хезмәт итә. Кич буе бик озын сүзләр сөйләшеп вакытны кичердек. Кызыгы шул: бу Фәләстин гарәпләренең яшьләренең бик күбесе безнең Салман авылы Габдулла әфәнденең шәкертләре булган кебек, боларның картлары да миңа, Чистай мишәренә, үзләренең уртак мөселманлык йөген тартышучы бер кеше дип карыйлар; тәмамән кардәшчә мөгамәлә итәләр; һич бер яшермичә кайгылары-шатлыклары берлә бүлешәләр иде. Мин дә үземне Казанда, Мәскәүдә, Истанбулда үзебезнең халкыбызның арасында кебек хис итә идем.

Икенче көнне иртүк торып "Әл-Кәрмәл" гәзитенең мөхәррирен зиярәткә киттек.

Бу гәзитә Фәләстиндә чыга торган гарәп гәзитәләренең ин картыдыр. Мөхәррире—христиан гарәп булса да, эше-көче берлә чын мәгънәсендә хәммиятле бер гарәп. Безне күктән төшкән кадерле кунак кебек каршы алды. Каһвә берлә сыйлап кына калмыйча, чәй дә ясатты. Ул мине гәзитәләрдә укып таныганга, бик озын сөальле мөзакәрәләргә керешге. Гәзитәсе өчен миннән бер интервью да ясады. Бу гарәп хезмәтчесе үзе христиан булса да, Хәзрәте Мөхәммәд галәйһиссәламне бик зур хөрмәт итә вә Коръәнне гарәп даһасының *(дөньясының)* зур әсәре дип карый. Сөйләгәндә дәлил итеп Коръәннән бик күп аятләр китерә. Гарәпләрнең хәзерге көндәге хәлгә төшүләренең сәбәбен Хәзрәте Мөхәммәд г.—мнең тәгълиматен тотмауларыннан дип тәфсир итә. Безнең тарафтагы мөселманнарның хәлләрен бик тәфсилле иттереп сораша. Гарәп теленең никадәр таралуын белергә тырыша. Андагы мәдрәсәләрдә гарәпчә уку-укытуны сөйләгәндә, балалар кебек чын күнелдән шатлана. Бу да үзләренең Фәләстин өчен вә гарәп йорты өчен тартышуларында мине бер юлдаш иттереп карый иде. Күрешеп чыкканда, калтыраган, тәэсирләнгән тавыш берлә: "Карлы-бозлы Идел буйларында, меңләр чакрымлык Урал тауларында сезнең кебек безгә якын калебле затларның йителүе гарәпнең олуг даһисе Хәзрәте Мөхәммәднең онытылмас Коръәненең йимешләредер. Бу безнең гарәп даһиебызның могжизасы!"—диде. Күрешеп аерылыштык.

Аннан соң Габдулла Тимур әфәнденең гарәпчә укыта торган мәктәбен зиярәт иттек. Мөгаллимнәр берлә күрештек. Боларның күпчелеге төрекчә сөйли, аңлый торган затлар иде. Сыйныфларны карарга киттек. Зур сыйныфта мөдир мине балаларга зур сүзләр берлә таныштты: "Халкының кяферләр тарафыннан җәберләнүен безгә аңлатырга килгән. Сез дә шундый зур гая *(олуг теләк, максат)* артыннан йөрүче булырга тырышыгыз!"—диде. Габдулла әфәнде бер сыйныфта балалардан Коръән укытты. Бер Идел буе төрк-татарының пәйгамбәрләрнең туган йире булган Фәләстиндә гарәп балаларына Коръән өйрәтүе тагын гаҗәп төсле булып китте. Безнең Идел буе егетләре кемләргә өмәгә йөрмиләр *(ягъни хезмәт итмиләр)*. Үз илең булмагач, үз халкың үз ихтыярында булмагач, шулай итеп мәгънәви чегән булып каласың, күрәсең.

Туп-туры "Мәҗлесе исламия"гә киттек. Бу мәҗлес—мондагы Хәйфа мөселманнарының милли-сәяси мәркәзләре. Ишек янына килеп житкәч, тар гына баскычтан берсе арты берсе төшеп, менеп килә торган бик күп гарәп хатыннарына очрап, аларның төшкәннәрен көттек. Ул арада тагы берничә чаршаулы *(бөркәүле)* ханымнар килеп чыкты. Бу юлы без, бераз нәзакәтсезлек булса да, ханымнарны көтмичә икенче катка менеп киттек. Бер кин генә салонга кердек. Анда безне җәмәгате исламиянең рәисе берлә берничә әгъза каршы алды. Монда килгән хатыннарның ник күплеген сорадым: "Бу бина безнең үз бинабыз. Икенче тарафта бер могаянә ханәбез бар: фәкыйрьләргә бушлый, хәллеләргә бик очыз *(очсыз) (алтын акча берлә 12 тиен)*. Күбрәк мөсафирләре һәрвакыт ханымнар булганга, юлда сезгә көтергә туры килгәндер, диделәр. Озак та үтмәде, могаянәхәнәнең яшь докторы Рөшди Тәмими әфәнде дә килеп, безнең берлә күреште. Бераз сөйләшкәннән соң, аны карарга чыктык. Аның көтү бүлмәсендә әллә никадәр мөселман хатыннарын очраттык. Доктор бер елда алты мең хаста килеп-киткәнен вә боларның зур бер өлеше хатыннар булганын сөйләде. Шунда ук бер мөселман акушерка берлә дә таныштырды. "Мөселман хатыннары бу ханә ачылганга кадәр тыйбби *(медицина)* ярдәмсез иделәр. Шуны игътибарга алып, "Җәмгыяте исламия" үз хисабына моны ачты вә, хатыннарга жиңеллек булсын өчен, бер мөселман акушерка да булды. Ләкин хатын докторыбыз әлегә юк. Сезнең тарафта хатын-кыз докторлар күп диләр. Безгә килсәләр, бик зур хезмәт итәрләр иде",—диде. "Җәмгыяте исламия" рәисе: "Хәзер менә алдыбызда бер хастәханә ачу мәсьәләсе тора, ләкин бинабыз житәрлек түгел; шуның өстенә тагы бер кат үстереп хастәханә ачачакбыз. Сез икенче килгәндә хастәханәбез дә булачактыр. Безнең мөселман хатыннары ирләргә күренүдән тартыналар. Безгә сезнең доктор ханымнардан берәрсен жибәрегез",—диде. "Җәмгыяте исламия"дә каһвә эчеп, аның шул елларда гына салдырган мәсжеден карарга киттек. Бу мәсжеднең урыны элек бер әүлиянең зыяраты *(кабере)* булган. Бу тарафны яһүдиләр баса башлагач, шәһәрнең уртасында калган бу зыярат йиренә "Җәмгыяте исламия" ике катлы зур бер мәсжед салдырган. Аның астакы *(астагы)* катына кибетләр эшләнгән. Өсте мәсжед ясалган. Зур-кечкенә кибетләрнең саны гына 26. Урын тәмам базар уртасында булганга, бөтен кибетләр тулган. Болар китергән меңнәрчә лиралык файдага "Җәмгыяте исламия" берничә мәктәп, могаянәханә тәрбия итә вә киләчәк биналарына да акча жыя бара. Жамигъ бик зур, бик якты, бик яхшы. Без аннан "Шөббанел-мөслимин" *("Мөселман яшьләре",)*

җәмгыятенә киттек. Бу җәмгыятнең бөтен ислам мәмләкәтләрендә барлыгына, яшьлекне мөселман рухында тәрбия итәргә хезмәт итүче бу оешманың һәр йирдә зур рәгъбәт күргәнен үткән мәкаләләремдә язган идем. Мондагысының төзелүендә, тәрбия ителүендә безнең илдәшебез бик зур хезмәт иткәнгә, миңа бусы тагы якынрак күренде. "Шөббанел-мөслимин"дә үзенең бинасында йирләшкән. Бу да күптән түгел генә йирле хәммиятлеләрнең һиммәте *(тырышлыгы)* берлә салынган ике катлы бер таш йорт. Бу да элгәре бер шәйхнең төрбәсе булган. Моның да астки катында кибетләр. Өсте "Мәҗлеснең идарәсе"ндәге төрле-төрле бүлмәләр, салонлар. Диварлар бик күп эзчеләрнең рәсемнәре берлә бизәлгән. Салонлары хәзерге җәмгыятнең үсүенә җитәрлек булмаганга, бинаның бер ачык тарафына бер салон ясарга хәзерләнәләр вә шуның өчен кирәкле салу материалларын китертеп яталар. Җәмгыятьнең эшләрен, көтепханәләрен карап, гарәп банкасын күрергә китәбез. Анда безне банканың мөдире Габдеррәшид Ибраһим әфәнде каршы ала. Банканың хәленнән, гарәпләргә иткән хезмәтләрен бәхәс итә.

Көн буе шулай мөселман оешмаларын күреп йөреп, өйлә ашыны махсус хәзерләнгән Габдулла әфәнденең бер шәкертендә ашыйбыз. Мәҗлестә шәһәрнең бөтен олуг хазыйр булды *(катнашты)*. Мин боларга: "Бөтен эшләрегезне икътисади нигезгә корырга сезне кем өйрәтте?"—дип берсөаль бирдем. Казан татарындагы бу табигатьнең монда гарәп илендә, пәйгамбәрләр чыгара торган Фәләстиндә кайдан килүен белсәм, килеп җавап көтәм. Арадан берсе: "Яһүди мөһаҗирләре!"—дип җавап бирә. Башкалары да бу җавапны гөблиләр *(җөблиләр; куәтлиләр.)*. Димәк, яһүдиләрнең Фәләстинне үз кулларына алырга теләүләре йирнең хәзерге хуҗалары гарәпләрдә үзен үзе саклау хисен уяткан. Яһүди коралы икътисад берлә ул да коралланырга керешкән. Димәк, сионизм гарәпләр өчен файдалы бер камчы да булып чыккан.

Программа буенча аштан соң Гакка шәһәрен күрергә дип, автомобиль берлә киттек. Бу ике шәһәрнең арасы 30-40 чакрым гына икән. Гакка шәһәре—Хәйфа кебек үк диңгез кырына корылган бер шәһәр. Ләкин мондагы култык пароходлар туктарга тагы да уңгайрак булганга, гасырлар буе бу шәһәр бу тирәнең порты булып килгән. Төрекләр дәверендә бу бер кальгъә булып торган. Шәһәрнең тирә-юне бик зур биек таш койма берлә әйләндерелгән. Кальгъәнең эчендә зур гөнаһлы усалларны саклар өчен бер төрмәсе дә булган. Солтан Габделхәмид дәверендә салына башлап тәмам ителгән. Хиҗаз тимер юлы менә шул Гакка шәһәреннән башланып китеп, Мәдинә шәһәренә барып кергән. Бу тимер юл солтан Габделхәмиднең планы, ислам галәменең иганәсе вә төрек мөһәндисләре *(инженерлары)*, осталары һәм эшчеләренең кул көче берлә эшләнгән бердәнбер ислам вакыф тимер юлыдыр. Ул вакытларда хаҗиларның күпчелеге Гакка шәһәренә пароходлар берлә килә торган булганнар да, шунда тимер юлга утырып, рәхәт-рәхәт өч көн эчендә хаҗга барып җитә торган булганнар. Сугыш вакытында бу юл шактый бозылган. Хәзерге көндә бу юл Хиҗаз, Шәркыл-Әрдән, Фәләстин, Сүрия дәүләтләрен арасында бүленгән вә бик күп җирләре харап ителеп, эшкә яраксыз ителгән вә уртак мөселман вакыфлыгыннан чыккан. Мөтәмер *(корылтай)* бу тимер юлыны элгәреге кебек ислам вакыфы итеп калдырыр өчен карарлар алды. Әмир Сәгыйд Әл-Җәзаиринең риясате *(рәислеге)* астында шуның берлә шөгыльләнергә махсус бер комиссия дә аерган иде. Менә хәзер без шул тимер юлның башланган Гакка шәһәрендә. Шәһәр хәзер ташландык хәлендә, сүнгән. Сату-алу һәммәсе Хәйфага күчкән. Хаҗилар килү беткән, төрек вәлиләреннән *(мэрларыннан)* Әхмәд паша исемендә бер зат тарафыннан салдырылган иске бер зур җамигъ *(мәчет)* тә бар икән. Аның әтрафы мәдрәсәләр һәм шәкертләргә хөҗрәләр берлә әйләндерелгән. Әле дә булса шул мәдрәсәләрдә гарәп егетләре дәрес укыйлар вә мәрхүм төрек пашасының калдырган вакыфыннан бушлай бүлмәгә башка, айга 60 грошлар *(алтын берлә—4,5 сум)* ярдәм дә алып торалар икән. Гарәп шәкерте безгә ярдәмнең азлыгыннан зарланды. Мин дә моның сәбәбе сугыштан соң гарәп дөньясы арасына кергән ходуд *(чик)* мәсьәләләре икәнен сөйләп торуның лозумен *(кирәклеген)* тапмадым.

Бу шәһәрнең хәзерге көндә минем өчен иң кызыклы булган җире монда бәһаиләрнең башы булган Бәһаулла зыяраты вә аның янына салынган бәһаи мөсафирханәләре иде. Шунарга бу мәсҗед тирәсендә без озак туктамыйча, шәһәрдән бераз читтә булган бәһаиләр мәркәзенә киттек.

Мәгълүм ки, 19нчы гасырның соңгы яртысында ислам дөньясында яңа бер мәзһәб дөньяга туа. Бу мәзһәбкә баби мәзһәбе дисәләр дә, күп вакытта шул сүзне аурупалаштырып бабизм дип тә йөртәләр. Бу исем мәзһәбнең чын башы Сәйд Гали Мөхәммәд әш-Ширази дигән иранлы бер галимнең "Баб" дигән кушымта исеменнән

алгандыр. Сәйд Гали Мөхәммәд әш-Ширазиның мәзһәбе Иранда бәд *(начар, бозык)* мәзһәб булып кабул ителгән вә мәзһәб башлыгы төрмәгә ябылган вә ахырдан аттырылып үтерелгән. Аның башлаган мәзһәбенең 1260 һиҗридә *(милади белән 1844 тә)* Тәһран шәһәрендә туган Бәһаулла, үзләренчә әйтсәк, Хәзрәте Бәһаулла дәвам иттергән. Ул шуна мәзһәб төсе биреп, аның гадәтләрен вә җолаларын эшләткәндер. Бу мәзһәбнең төп фикере: дөньяда булган бөтен диннәрне берләштерү һәм һәрбер дин әһеленә үзенчә гыйбадәт итү юлларын тәэмин итүдер[1].

Хәзрәте Баб та, Бәһаулла да ислам дөньясыннан чыккан кешеләр булганга, алар үз мәзһәбләренең нигезе итеп исламиятне алганнар. Аларда да намаз да, ураза да бар. Ләкин намаз көнгә өчкә генә вә руза да бер айдан унтугыз көнгә индерелгән *(киметелгән)*. Үзләренең догалары да бар. Үзләренең бер китаплары да бар. Ләкин бу китап үзе дә Корьән Шәрифнең бозынтысы гынадыр. Менә шул Хәзрәте Бәһаулла Иранда үзенең мәзһәбен тарата башлагач, Иран хөкүмәте аны мәмләкәттән куган. Бәһаулла Төркиягә сыгынган. Солтан Габделмәҗид *(? Габделхәмид)* үзенә хөрмәт күрсәткән вә аның утырыр җире итеп Гакка шәһәрен билгеләгән. Хәзрәте Бәһаулла 1309нчы елда *(милади белән 1892 дә)* үлгәнгәчә Гаккада калган; үзенең мәзһәбен шуннан тараткан. 19нчы гасырда ислам дөньясында дини нигездә ислахать *(реформа)* ясау вә дини юлда эзләнүләр бик актуаль эшләр булганын без үзебезнең илдәшләребез Габденнасыйр әл-Курсави һәм Шиһабеддин әл-Мәрҗаниләрнең хәрәкәтләрен берлә танышканда ук белә идек. Бу хәрәкәтләр ул вакытларда ислам дөньясының башка йирләрендә дә булган. Җамаледдин әл-Әфгани, мисырлы Мөхәммәд Габдәләрнең эшләре берлә дә безгә мәгълүм иде. Баб, Бәһаууллаларның хәрәкәтләре дә без ислам дөньясындагы тормышның шул сәвальләренә җавап төсендә эшләнгән бер хәрәкәт дип карый алабыз. Ләкин, ничек кенә булмасын, бу мәзһәб вакытында ислам дөньясына бик күп фетнәләр чыгарган, ахырдан Иран һәм Һиндстанда шактый күп таралган булып, Бәһаулла үзенә бик күп мөридләр җыя алган иде. Аның берлә генә калмыйча, бу хәрәкәт Аурупа һәм Америкага күчеп, "бабизм" төсендә анда да үзенә уртаклар таба белгән, имеш.

Безнең күрергә теләгәнебез, менә шул мәзһәб башлыгы Хәзрәте Бәһаулланың зыяраты. Бу зыярат—ислам дөньясында күренмәгән рәвештә гаять бай иттереп эшләтелгән бер төрбә. Төрбә генә түгел—зур бер сарай. Идәннәре бик кыйммәтле паласлар берлә өртелгән *(түшәлгән)*, диварлары бик күп матур язулар берлә бизәкләнгән. Кабер тирәсенә матур шәмнәр тезелгән. Кабернең тирә-юненә бик күп гөлләр, чәчәкләрдән зур бер чәчәк бакчасы эшләнгән. Болар һәммәсе дә Шәрык ысулында түгел, Аурупача иттереп һәм дә бик күп акча сарыф иттерелеп эшләтелгән. Шуларның әтрафы бик пөхтә иттереп эшләтелгән зур бер бакча берлә әйләндерелгән. Икенче тарафта берничә катлы зур бер таш өй. Өй генә түгел—бер сарай. Шул сарайның бер тарафында Хәзрәте Бәһаулланың кызлары-кияүләре яши икән. Икенче тарафы—мөридләр өчен мосафирханәгә әверелгән. Хәзрәте Бәһаулланың утырган урыны да бу мосафирханә эчендә калдырылган. Мосафирханә бик пакь, бик пөхтә. Аурупа шәһәрләренең икенче дәрәҗә отельләре төсендә. Ятак бүлмәләре аерым, язу бүлмәләре аерым, ашау бүлмәләре аерым, хаммамнары *(юыну урыннары)* аерым, көтепханәләре аерым. Шунарга башка, бәһаилеккә каратып язылган бөтен телдәге китаплар, гәзитәләр һәм мәҗмугаларны эченә алган картотеклы бер көтепханәсе дә бар.

Монда әллә ничә йөз җилдлек *(томлык)* төрле телдә бабизм хакында язылган китаплар саклана. Алар тарафыннан чыгарылган рисаләләр, китаплар өстәл өстендә укучыга хәзер тора. Мосафирханәдә бик күп бүлмә бар. Бу бүлмәләр һәрвакыт бәһаи мәзһәб мөридләре өчен бушлай ачык. Анда килгән мосафирларга ашау-эчү дә бушлай икән. Безгә боларны бер Иран азәрисе (азәрбәйҗаны) күрсәтеп йөрде. Үзе азәри шивасендә төрекчә бик һәйбәт сөйли. Тәбризи *(Тәбриз шәһәренең)* бер бәһаие икән. Хәзрәте Бәһаулланың үзе утырган бүлмәсене дә махсус күрсәтте. Анда аякларыбызны салып кердек. Аның кул язуларын, китапларын күрсәтте. Болар һәммәсе дә бик тәмиз *(чиста, пөхтә)* иттерелеп сакланып киләләр.

—Боларны кемнәр карый,—дип сорадым.

—Бәндәгез һәм дә монда бәһаи мәзһәбле бер япун конты *(гаррафы) (изге заты; диндары)* бар. Ул!—диде.

Моны идарәгә *(идарә итәргә)* бик күп акча кирәк булуын күздә тотып, моның вакыфы булып-булмавын һәм мәсарифларының *(чыгымнарының)* кайдан чыгарылуларын сорадым.

---

[1] XIX гасырда Сарытау сатучысы Курамшин дигән бер кеше дә шундый бер мәзһәб корам дип йөргән вә үзенчә бер китап та язып чыгарган иде (Г.И.).

—Мөридләребезнең ярдәменнән. Хәзрәте Бәһаулланың зыяратыны саклау һәрбер мөриднең бурычыдыр!—диде. Бу сарайдан чыгып килгәндә, карт кына өч ямьсез инглиз хатынына очрадык. Алар берлә япун кыяфәтле бер кеше сөйләшеп тора иде. Азәри: "Болар Америкадан килгән. Хәзрәти Бәһаулланың мөридләре",—диде. Япунда чәчәк мәракалысы, имеш. Ләкин мондый елларда мондый зур бер нәрсәнең мөридләрнең ярдәме берлә генә торуына ышанып бетә алмаганга, "акча кайдан алалар?"—дигән сөалемә җавап таба алмадым. "Мөтәвәвәллисе *(дәвамчысы)* кем?"—дидем.

—Хәзрәте Бәһаулладан соң аның угылы Гыйас әфәнде калган иде.—Хәзер Шәукый әфәнде исемендә кызының углыдыр, Хәйфада яши,—диде.

Минем юлдашларым:

—Гыйяс әфәнде исламият берлә галякәсене *(бәйләнешен)* кисмәгән бер зат иде. Һәр җомга көнне мәсҗедкә җомгага килә, фәкыйрь-фокарага ярдәм итә иде. Хәзерге Шәукый әфәнде Аурупада укыган, исламият берлә галякасен кискән бер гәнеж *(егет)*,—диделәр. Шул бәһаиләр хакындагы бөтен күрәсе йирләрне күреп бетерер өчен, Әл-Кирмәл тавының итәгенә эшләтелгән Хәзрәте Бабның зыяратына киттек. Бусы да бик зур бер бакча эченә салынган, бер гыйбадәтханә кебек бина. Бик күп Иран халилары *(паласлары)* берлә сөрелгән *(бизәлгән)* зиннәтле бер бүлмәнең уртасына Бабның ләхеде куелган. Монда да шәмнәр. Ләкин байлыкта болар беренчесеннән дә баерак. Бер бүлмәдә Бәһаулланың кием-салымнары, язулары саклана икән. Диварларда фарсыча-төрекчә-гарәпчә бик матур язу берлә язылган ләүхәләр *(элмә такталар)* тагылган. Бу язулар Иранның 19нчы гасырдагы мәшһүр хәттаты *(каллиграфы)* "Миске Каләм"нең язулары икән. Моның тирәсендә бик зур гөл бакчасы. Күрәсең, бабилар гөлне бик сөяләр. Шәукый әфәндене дә күреп зиярәт итәчәк булдык. Ләкин өйдә тугъры китерә алмадык.

Монда күргәннәрем дә бик зур акча берлә эшләтелгән, бик күп акча берлә дәвам иттерелә торган эшләр икәне күренеп тора. Ләкин акча килә торган юллар бер дә күренми иде. Мөридләр дисәләр дә, мөридләр исемендә беркемгә дә очрамый идек. Гарәбләр арасында боларның мөридләре юк. Иранда бар имеш тә, Һиндстанда бик күп, имеш. Һиндстанда Исмәгыйлия мәзһәбенең башлыгы саелган *(хөрмәтле)*, Лондонның мәгъруф бер һиндле принцы Ага хан ди боларның мәзһәбенең бер шәхсияте *(әгъзасы)*, имеш. Америкада Чикаго шәһәрендә бабиларның алты ишекле, алты мәзһәбкә гыйбадәт өчен салынган бер гыйбадәтханәләре бар, имеш. Боларның кайсылары дөрестер—белеп булмады. Ләкин акча алалар дигән сөалемә җавапны белә алмадым.

Шәһәргә кайткач, шуларның хәлләрен сораша-сораша сугыш вакытында боларның арасында зур инглиз хәфияләре *(яшерен оешма вәкилләре, агентлары)* яшәгәнлеген вә төрекләр тарафыннан тотылганыны сөйләделәр. Бу минем сөалемә дәрхаль *(шунда ук)* яна сөальләр куштьы. Минем хәзер генә күреп йөргән биналарым, зыяратларым, аллы-гөлле бакчаларым ислам дөньясынын дошманнары тарафыннан исламиятне бозарга, аерырга корылган микроб лабораторияләре *(лабораторияләре)* түгел идеме? 19нчы гасырдагы ислам дөньясының уяну дәверендәге эзләнү хисене ислам дөньясы үзенә файдалыга бора белмәсә дә, ислам дөньясыны таратырга теләүчеләр аның бер көч булуына сонгы йомрыкны *(йодрыкны)* орырга теләүчеләр, шул хисеннән файдаланып, сонгый *(ясалма)* рәвештә шул хәрәкәтне үстермәделәрме? Баблар, Бәһауллалар вә башкалар аңлап-аңламыйча ислам дошманнарынын кулына корал булмадылармы? Бабизм 19нчы гасырның "аля лявиринс" *(? буталчык)* бер хәрәкәте генә булмадымы? Бу сөальләр минем башымны биләп алып, җавап эзләргә тотындылар. Сөаль артыннан сөаль китеп, шунда күрсәтеп йөргән гаҗәм *(иран)* тәрбияле азәринең кыяфәте алдыма килеп басты. Аны моннан элек тә бер җирдә күргән кебек булдым. Фикер йөри-йөри мине Берлиндагы бер гаҗәм ашханәсенә илтеп җиткерде. Шунда аш ашаганда, күршебездәге урысча, алманча, төрекчә, әрмәнчә, фарсыча сөйләшә торган егетләр берлә уртак бер нәрсәсе бар кебек тоелды. Әйе, шуларга охшаган, ләкин бу бераз картрак. Мөгамәләләре, кыланышлары да шәрыкчарак. Тегеләр—яшьләр. Тегеләр—модерн. 19нчы гасырның дин ислахяте фикере берлә йөрелмиләр. Болар, 20нче гасырда куәт алган милләтчелек фикеренең көчәюеннән файдаланып, милләтләрнең капитализмның пәнҗәсеннән *(тырнагыннан)* коткару гына түгел, бөтендөнья милләтләрен берләштерү гаясенә хезмәт итәләр.

Шул тулы "Шәркый азатлыгын" дөньяга чыгарыр өчен, рус большевизмының кассасыннан файдаланып, руслыктан бизар булган *(йөдәгән)* милләтләрнең милләтчелек җәряннарын *(хәрәкәтен)* кырырга хезмәт итәләр. Ленинны фарсычага, төрекчәгә тәрҗемә итәләр. Большевизмны чәчәкләндереп, балландырып Шәрыкка

кертергә, таратырга, Шәрыкта уянган милләтләрнең милләтчелекләрене рус истилясына *(басып алуына; изүенә)* каршы киләчәк бер куәтеннән чыгарырга хезмәт итәләр. 19нчы гасырның бабилары берлә 20нче гасырның ленинчылары икесе дә бер юлга хезмәт итмиме? Бу хәрәкәтләрнең сугарыла торган чишмәләре аерым-аерым булса да, болардан чит халыклар, чит җәряннарның көткән нәтиҗәләре бер түгелме?—Бу сөальләр мине Фәләстиннән киткәнче борчыды. Әле дә борчый. Җавапны әле дә таба алмадым. Бәлки киләчәк бирер.

***

Фәләстин белән Сүрия арасында иң кыска юл автомобиль юлыдыр. Ике арада тимер юл булса да, бик борылып-урап йөргәнгә, вакытны кызганмаган юлчылар автомобильне ихтыяр итәләр. Мин дә шул соңгысын ихтыяр иттем. Ләкин автомобильчеләргә бер генә юлчы йөртү эшләренә килмәгәнгә, алар юлдаш эзләп йөдәп беттеләр. Мисыр төрәне *(поезды)* килеп, мин төрәнгә утырырга булгач кына, төрән бәһасенә ялгызымны гына алып китәргә булдылар.

Ике сәгатьтән соң Табәрия исемендәге зур күл башына утырган, шул исемдәге шәһәргә килеп җиттек. Монда минем ямчым *(шоферым)* яңа юлчы эзләргә кереште. Зур күлнең буена салынган бу шәһәрнең тирәсе Фәләстиннең байлары, бигрәк тә әҗнәбиләрнең *(чит ил кешеләренең)* җәйлекләре икән. Шәһәр кечкенә булса да, күл буенда матур-матур биналар бик күп. Ямчы ике сәгать эзләсә дә, бер юлчы да таба алмады. Мин тагын ялгызым гына киттем. Озак бармадык, Фәләстин-Сүрия чигенә җиттек. Монда инглиз түрәсе минем паспортыма үзенең тамгасын басты. Тагын утырып киттем. Биш-ун чакрымнан без күпердән чыктык. Бу күпернең исеме "Җәрбәнате Ягъкуб" *("Ягъкуб кызларының күпере")* икән. Аның икенче ягында, бер капка янында туктадык. Ямчы минем паспортымны алып бер өйгә керде. Берничә минуттан соң аннан бер яшь француз чыгып, минем нинди гәзитәдә язуымны, нәрсә өйрәнү өчен Сүриягә килүемне, кайсы отельдә торачагымны сорады. Җавап бирдем. Визам җирендә булганга, җиңеллек берлә ходудны *(чикне)* үтеп киттек.

Вакыт бик кич булмаса да, һава бик суынды. Бик каты суык җил исәргә тотынды. Ямчы, башы гына түгел, итәкләре дә кар белән капланган, бик биек Җәбәлүш-шәйх *(икенче исеме—Хермон)* тавын күрсәтте:

—Кар яуган, суык шуннан килә!—диде. Французларның гүмрүкләре Канитарә дигән шәһәрдә икән. Сәгать дүртләрдә шунда килеп җитеп, гүмрүк алдына туктадык. Безнең әйберләребезне карарга тотындылар. Минем чемоданнарга сыймаган бик күп гәзит төргәкләрем дә бар иде. Гүмрүк түрәсе бер чиркәс: "Болар нәрсә?"—дип сорады. "Гәзитәләр",—дидем. Шуларны караганда, берсендә минем рәсемемне күреп, астына язылган язудан минем мөэтәмәр *(корылтай)* әгъзасы булуымны белде һәм караудан туктап: "Боерыгыз, боерыгыз! Мин сезне танымадым",—дип, ачарга хәзерләнгән чемоданнарымны ачтырмады.

Бу Канитарә шәһәре күпләп чиркәс мөһаҗирләре тора торган шәһәр икән. Минем карап йөрергә вакытым булмады. Шамга баручы өч юлчы табылып, китеп бардык. Җәбәлүш-шәйхнең суыгы монда тагын артты. Бик туңып, кояш баеган чакларда Шамга барып кердек. Өмәвиләрнең пайтәхете булган һәм ислам тарихында бик зур роль уйнаган Шам-шәриф *(Дәмәшкъ)* менә инде шул үзе.

Отельгә төшеп, җирләшеп, ашарга чыктым. Аннан соң мөһаҗирләр мәхәлләсен сорап, шул тарафларда булырга тиеш булган үзебезнең Идел буйлы иптәшләребезне эзләргә киттем. Мин аларның берсенең дә адресын белми һәм үзләрен дә танымый идем. Ләкин алай итеп, болай итеп, табуыма-тануыма каһәгатем бар иде. Мөһаҗирлек мәхәлләсенә барып җитсәм дә, кич бик суык булганга, бөтен кибетләр һәм каһвәләр ябылган иде. Урамда һичбер йөрүче юк иде. Очраган кешеләрдән сораштыргаласам да, барысы да суыктан качып өйләренә ашыкканга, бер төрле дә мәгънәле җавап ала алмадым. Өйгә борылып киттем. Гарәпләрдән таныганнарым булса да, аларны эзләргә вакыт соң булганга, бүлмәмә кайтып яттым. Төн буе җил улаганга, минем бүлмәмнең тәрәзәләре дә шалдыр-шолдыр килеп йокы тынычлыгымны бүлделәр. Суык җил дә юрганымның астына кадәр кереп уятты. Иртүк торып, үземнең чәй машинамны тишеп, чәй эчкәч кенә кеше төсенә кереп, шәһәргә чыгып киттем. Һичбер көтелмәгәндә урамда мөэтәмәрдә Сүрия әгъзасы булган адвокат Шәфыйк Сөләйман бәкне очраттым. Ул миңа шәһәрне күрсәтергә, барачак кешеләр һәм җирләремне өйрәтергә булды. Беренче иттереп Әмир Сәгыйд

әл-Җәзаирне зиярәт иттек. Ләкин Әмир өендә юк иде. Без Өмәви җамигын *(мәчетен)* карарга кердек. Бу—Шамның иң иске, иң тарихи бер җамигы. Ул христианлыктан элек бина ителгән бер мәҗүси гыйбадәтханәсе икән. Шамны христианлар алгач, аны чиркәүгә, мөселманнар алгач, җамигъка әверелдергәннәр. Инде 1250 еллар чамасы мәсҗед булып тора. Өмәви хәлифәләрнең тарихы берлә бик баглы булганга вә алар заманында җамигъка әверелгәнгә, ул Өмәви җамигы дип йөртеләдер. Дүрт почмаклы итеп эшләтелгән, дүрт якта дүрт капкасы бар. Бу җамигъ үзе капкаларын япкач, шәһәр эчендә бер кала булып кала аладыр. Бик күп сугыш вакытларында, эчке баш күтәрүләрдә ул шул калалык хәлен алып килгән. Йортның тирә-юнендә шәкертләр өчен бик күп хөҗрәләр бар. Болар иске заманнан бирле үк укучыларның тора торган урыннары булып килгән. Җамигъ үзе безнең мәсҗедләрнең хилафына *(киресенә)*—гаребтән шәрыкка таба озын иттереп эшләтелгән. Михрабы урта бер җирендә. Җамигъ эчендә челтәр берлә тотылып алынган зур бер кабер бар. Моны "Хәзрәте Яхья" кабере дип йөриләр. Бу никадәр дөрестер—анысын белә алмадым. Җамигътан Гарәп көтепханәсенә һәм Гарәп музәханәсенә кердек. Боларның икесе дә төрекләр дәверендә эшләнгән мөәссәсләр *(корылмалар)*. Гарәпләр аларны зур гайрәт сарыф итеп алып баралар вә тарихи әсәрләрне чит халыкларның урлауларыннан коткарып калдырырга тырышалар. Музәдәге Мисырның мәгъруф пашаларыннан берсе тарафыннан һәдия ителгән иске акчалар коллекционы бик кыйммәтле асаре гатикадандыр *(борынгы әсәрдер)*. Болар эчендә бөтен өмәви вә габбаси хәлифәләренең акчалары мәүҗүддер *(бардыр)*. Иң иске ислам акчасы бу музәдә Габделмәлик бин Мәрван акчасы. Тарихы һиҗри берлә 79 *(милади белән—698)* ел дип язылган. Шунда ук Һулакуның *(Чыңгыз нәселеннән килгән хөкемдар.)* бер бакыр акчасы да саклана. Тарихы бу тарафларны Һулакуның алу тарихы диделәр *(654-663 һиҗри) (Ягъни 1256-1265нче еллар.)*. Ләкин акчаны алып, дикъкать берлә карый алмадым. Янымда зурайта торган пыялам да юк иде. Монда бик күп тарихи, мәдәни әсәрләрне зиярәт итеп, Шәфыйк бәк берлә каһвә эчеп, аерылдык. Мин тагын мөһаҗирләр мәхәлләсенә илдәшләремне эзләргә киттем.

Мөһаҗир мәхәлләсе элек Шамның кырыенда бер таулык кына булган бу җирләр Солтан Габделхәмид вакытында чиркәс, арнауд, бошнак *(боснияле)* һәм татар мөһаҗирләренә бушлый бирелгән булган. Һавасы бик яхшы булганга, бик тиз бу җирләр үсеп китеп, зур, бай бер мәхәллә булып өлгергән. Хәзер бу җир Шамның иң аристократ бер җире. Мин тауның югарыларына кадәр чыгып, өстеннән бер карадым. Шәһәр тәмамән аяк астында кебек калды. Төрле тарафларны карап мәхәллә эченә төштем. Һәрбер кибет вә каһвәгә кереп татар мөһаҗирләрен сорашырга тотындым. Йөри торгач бер икмәкче кибетеннән: "Әнә шунда!"—дип күрсәттеләр. Миңа кушып җибәрелгән икмәкче малай берлә бер өйнең капкасына килеп туктадык. Кактык. Аннан төрекчә: "Кем вар?"—дигән бер хатын тавышы ишетелде. Мин: "Казаннан килгән бер юлчы, монда Казанлы мөһаҗирләр тора дип ишеттем",—диюемә өйдән: "Аннә, һәмшәһрең *(ватандашың, якташың)* килде!"—дигән бер кыз тавышы ишетелде. Миңа "Хәзер, хәзер, аннә чаршафны гына *(пәрдәне; киемне)* кия",—диде. Ишек ачылды. Өйгә кердем. Карт кына бер хатын: "Боер, боер!"—дип мине ак өенә кертте. Пөхтә бер бүлмә. Казандагы кебек пыялалы шкафка бик күп чынаяклар, чәйнекләр тезелгән. Казан ысулы мендәрләр өелгән... Бер урта татар гаиләсенең өе. "Кем буласыз соң?"—диде. Мин дә әйттем. Абыстай үзе Бөгелмә өязе, Каратан *(Каратай ?)* авылыннан Хәсәнулла дигән бер абзыйның Миңлелбанат исемле кызы икән. Атасы Шамда үлеп калгач, үзен мондагы илдәшләре Хәсән исемендә харбутлы *(Хорватиядән)* бер төреккә кияүгә биргәннәр. Инде аңа утыз еллап вакыт үткән. Абыстайның угыллары җиткән. Кызлары кияүгә чыккан. Бер кызы Шамны төрек гаскәре ташлап чыкканда булган патырдида *(? ыгы-зыгыда; сугышта)* үтерелеп ташланган. Абыстай шуларны берәм-берәм аңлатырга тотынды. Үзе сөйли, үзе көлә, үзе җылый иде. "Кызым Хәдичә *(кечкенә кызы)* бүген төш күргән. Иртә белә: "Сиңа әни, бер шатлыклы хәбәр килә",—дигән иде. Инде дөрес чыкты. Туганымны күргән кебек булдым. Әй, сөйли-сөйли оныттым. Кызым, Хәдичә, самоварны куй!"—диде. Аның артыннан: "Куйдым, аннә, куйдым!"—дигән җавап килде. "Килүенә рәхмәт, туганымны күргән кебек булдым. Безнең авыл менә шундый, мондый...",—дип сөйләргә тотынды. Сөйләгән саен абыстайның телендә аннан-моннан йоккан госманлычалыклары бетә бара. Чистайны сөйли башлаганда инде ул тәмамән Каратан авылының Миңлелбанат абыстай булып калган иде. Сугыштан элек кенә абыстай илгә дә кайтып, кардәш кабиләсен күреп килгән икән. Хәзер дә бик күрәсе килә. Ләкин хат язса—хатка җавап юк. Хәбәр күндерсә—җавап юк. Урыс бик баскан икән дип кенә ишеткәли икән.

—Бездә бит урыс көчләп чукындыра, дип сөйлиләр иде. Мәрхүм эти дә шуннан куркып, ислам йортына һиҗрәт иткән иде. Әллә шул көннәр килдеме?—диде.

Мин дә андагы хәлләрне аңлаттым. Абызтай:

—Ай, мескеннәр! Ай, мескеннәр!—дип куя. Күзеннән тәгәрәгән яшьләрен яулык очы белән сөртә иде. Чәй килде. Чынаяклар, чәйнекләр тәмамән Казанча булуга башка, чәй дә чын чәй иде. Чәй янына куйган вареньесе дә безнеңчә кайнатылган иде. Чәйне татып карагач: "Сез әле, абызтай, чәй эчүне онытмаган икәнсез, чәегез бик һәйбәт!"—дидем. "Онытаммы соң, онытмадым. Менә илемнән аерылып 38 ел яшим, Аллага шөкер, телләренә дә, гадәтләренә дә өйрәнмәдем. Бөтен бала-чагама чәй эчәргә өйрәттем, онытаммы соң—онытмадым!..."—диде. 38 ел буена төрек, гарәп мәдәнияте эчендә юарланган бу абызтай, ник утка янмас, суга батмас татар булып калуы мине бик тирән уйларга төшерә иде. Вә татар гонсырының *(кавеменең)* никадәр куәтле икәненә алдымда тагы бер җанлы шаһиты күрсәтеп тора иде.

—Халык артыннан йөрисең икән, рәхмәт, Алла әҗереңне бирсен! Туган илемне күргән кебек булдым, сезгә дә туган илләрне күрергә язсын иде, куыгыз инде шул кяферләрне!—диде дә, тагын күзеннән аккан яшьләрне корытырга тотынды. Үзенең кардәш кабиләсеннән, таныш-белешеннән бик күп сорашты. Чынаяк өстенә чынаякны ясады, мин дә эчтем, ул да эчте. Аш ашарга калырга чакырды. "Рәхмәт, абызтай, вакытым тар бит, тагы башка илдәшләрне дә күрергә телим",—дидем.

—Ярый алай булса, ярый. Рәхмәт килүенә, әйдә алай булса!—дип мине алып башка илдәшләрне күрергә урамга алым чыкты. Юлда үзе бер туктамыйча сөйли иде.

—Төрекләр ташлап чykканда бит монда бик көчләделәр. Кызымны ике вагон арасына кысып үтерделәр. Төрек диделәр дә, үтерделәр... Изгелекнең кадерен белмәделәр, монда бит җәннәт иде, җәннәт! Хәзер генә кяфер басты. Кызымны үтерделәр шул, Алла җәзаларын бирсен. Үз илең түгел шул, куркып кына торабыз,—диде. Сүзене ишетмиләрме дип тирә-юненә каранды.

Менә бер өйнең алдына килеп туктадык. Абызтай ишеккә шакыды. Аннан килгән тавышка татарчалатып: "Мин, мин, кунак китердем, ач тизрәк, туган илебездән килүче, Алла мосафиры!"—диде. Ишек ачылды, өйгә кердек. Мине ак бүлмәләренә керттеләр. Бусы да тәмамән Казанча иттереп җыелган иде. Бу өй Уфаның Гыйзззеддин Хаҗи гаиләсенең өе икән. Хаҗи әфәнде үзе вафат иткәнгә абызтай угылы, кызы белә яши. Казанның мәшһүр Җиһаностазбикәсенең кызы икән. Без танышып өлгерә алмадык, угылы Әхмәд Сәгыйд әфәнде дә кайтып житте. Ул да монда әукафта *(вакыфлар идарәсендә)* мохасәбәче *(тикшерүче)* булып хезмәт итә.Элгәре болар Мәдинәдә яшәгәннәр, аннан төрекләр куылгач, Шамга күчеп килгәннәр. Угылы Русиядә булынган, Төркиядә булынган. Аңлы, тәрбияле бер егет. Бик күп уртак таныш-белешләр дә чыкты. Сөйләшеп торганда, Әхмәд Сәгыйд әфәнде: "Үзебезгә генә пешерелгән ашыбыз бар, гаеп итмәссез",—диде. Бергәләп аш ашадык. Шулпасы тәмамән безнең Казанның лапшалы шурпасы иде. Аштан соң якташ миңа шәһәрне күрсәтергә булды. Абызтайлар белә күрешеп чыгып киттем. Кичкә кадәр шәһәрне карап йөрдек. Хәмидия чаршусында *(базарында)* сату итүче Нури әфәнде дигән бер кеше бар икән. Бу әфәнде безнең чистайлы икән. Аның белә күрештек, ләкин үзе бик озын фалиж *(паралич)* белә хәстә ятканга, рәтләп сөйләшә алмадык. Аннан соң төркестанлы мөһаҗирләрдән Әхрам җәмигыйнең имамы Салих вә Мөхәммәд Гали Ясәвиләрне зиярәт итеп чыктык. Болар монда тәкиядә шәйх булып, мәктәп ачып, балалар укытып торалар икән. Үзләре Төркестан мәсьәләләре вә бөтен Русия мөселманнарының эшләре белә бик якыннан таныш булып торалар икән. Мине Бохара пылавы ашарга бик чакырдылар, сүз бирә алмадым. Сәгыйд әфәнде шәһәрнең зур җаддәләрене *(олы юлларын; проспектларын)*, җамигъларын күрсәтте. Өмәви җамигысыннан соң иң мәшһүр җамигъ солтан Явыз Сәлимнең җамигысы икән. Моның вакыфлары бик күп, янында шәкертләр торыр өчен ясалган хөҗраләр дә бик күп икән. Аларны хәзер бераз яңы юлга куйганнар. Хөҗраләрнең бер бүлегене төзәтеп тыйббия *(медицина)* шәкертләре өчен лаборатор ясаганнар. Бер тарафына хәстәләр карый торган йир ясаганнар. Бер кыйсемендә һаман әле укучылар тора. Мондагы шәкертләрдән бүлмә өчен, ягу-яктырту өчен акча алынмауга башка, боларга ашау-эчү дә бирелә. Укучылар тәмамән үз эшләре белә генә мәшгуль була алалар икән. Бу масрафлар (чыгымнар) һәммәсе дә мәрхүм солтан Явыз Сәлимнең вакыфыннан капланып килә икән. Җамигъның бер тарафында бакчалык. Шуның эчендә кечкенә генә бер каберлек. Монда соңгы солтан Вәхидеддин дәфен ителгән *(җирләнгән)*. Һәм дә күптән түгел генә вафат иткән Зиннәт солтан да шунда күмелгәннәр. Зыяратлары тәмиз *(чиста)*, пөхтә иттерелеп тора. Мәсжед эченә кердек.

Анын идәненә җәелгән паласлар—һәммәсе төрек эше. Гомумән, Шамда төрек асаре бик күп. Төрекләрнең тәэсире дә монда бик зур. Һәркем төрекчә сөйли. Һәркем төрекләрне сагынып кайгыра. Зур кышлалар *(казармалар, өйләр)* монда солтан Габделхәмиднең дәверендә эшләтелгән. Вокзалның башында солтан Габделхәмиднең туграсы әле дә ялтырап ята. Урамнарның исемнәре Җәмал паша, Әнвәр паша; чаршулары *(базарлары)*: Хәмдия чаршусы, Мидхәд паша чаршусы... вә һәказа *(шул рәвешле)*. Бер мәйданы Хиҗаз тимер юлы ачылуының ядкяре итеп эшләтелгән. Бер багана һәйкәлнең янына Хөррәме Шәриф сурәте ясалып куелган. Багананың дүрт тарафына бу тимер юл солтан Габделхәмид дәверендә фәлән тарихта эшләтелде, дип төрекчә язылган язулар бар. Боларның икесе төрекләр куылгач, әллә нинди бер кара буяу белә буялган булган. Инде аннан бирле шактый вакыт үткәнгә, ул кара буяу үзеннән-үзе уңып, сүзләре тәмамән чыккан.

Шул иске гыйбарәләр дә яңадан мәйданга чыккан. Хәзерге көндә Сүрия төрекләрдән аерылып тора башлавына 14 ел булганга, ул вакыттагы өмидләрнең барысы да сулып беткәнгә, бу язуларны карарга, буярга теләүче беркем дә табылмаган. Вә моннан соңра да аның табылуы бик еректыр. Төрек идарәсе дәвере монда инде буллыклы *(мул)*, бәхетле чак булып калган. Сагынып сөйли торган бер дәвергә әйләнгән.

Кичне мин чиркәсләр белән үткәрдем. Сүриядә болар 35 мең чамасы—һәммәсе солтаннар вакытында бонда утырганнар, барысы да төрекчә сөйли. Ләкин исламияткә бәйләнешләре төрекләрдән куәтле. Болар йирләрене урыс алгач, Төркиягә ислам йорты дип мөһаҗәрәт иткәннәр вә һәрвакыт Төркияне исламият мәркәзе итеп күреп килгәннәр. Араларында сарай берлә бәйләнешле шактый күп шәхсиятләре һәрвакыт булып килгән. Чиркәс пашаларының һичбер вакытта да Төркиядә саны азлык итмәгән. Соңгы Төркия инкыйлабының ялгыз милләтчелек юлыннан китәргә теләвене гомум чиркәсләр аңлап та бетермиләр, кабул да итә алмыйлар. Шуңар күрә Төркия берлә чиркәслек арасында элгәреге замандагы дуслык шактый зәгыйфьләнгән. Истикъляль *(бәйсезлек)* сугышы вакытында кайбер чиркәс башлыкларының мәгънәсез хәрәкәтләре бу мөнәсәбәтне тагын авырайткан. Ләкин аларның Сүриядәге гарәпләр берлә дә мөнәсәбәтләре шәптән түгел. Французлар бу чиркәсләрне жандармлыкта һәм дә чик саклаучылыкта кулланалар. Гарәпләр чиркәсләрнең, хәятене кичерер өчен, мәҗбүрият берлә алган шул вазыйфаларыны үзләренә дошманлык дип карыйлар. Үзләре йирле-йортлы булганга, иленнән-йортыннан аерылган бу чиркәсләрнең тамак туйдыру өчен бер эш эшләргә мәҗбүр икәнлекләрене аңлап бетермиләр, аңларга да бик теләмиләр. Шуның өчен араларында һәрвакыт аңлашылмаулар булып тора. Мин күрешкән чиркәс зыялылары [берсе Сүриядә чиркәс мәбгусе *(депутаты)* Әмин бәк, берсе "Мазәҗ" исемендәге чиркәс газитәсе баш мөхәррире, бер зур бер мәктәпнең мөдире] бу мәсьәләләрне бик яхшы аңлыйлар. Үзләре халыкларыны бик сөючеләр булганга, шул авыр вазгыятьтән чыгарга да юллар эзлиләр. Төрекләргә каршы да, гарәпләргә каршы да чиркәс халкының дошман булырга һичбер сәбәбе булмавыны вә бу ике халыкка чиркәсләр һаман дус икәнлекләрене бик күп дәлилләр берлә исбат итәләр, кулларыннан килгән кадәр аңлашылмауны бетерергә тырышалар. Боларның халыклары эчендә исламият бик тирән урын тотканга, болар ислам сәясәте берлә бик мәшгульләр. Безнең мөэтәмәрдәге *(корылтайдагы)* эшләребезне, Мисырдагы чыгышларыбызны бик якыннан тәгъкыйб итеп *(күзәтеп)* барганнар вә шулардан зур өмидле эшләр көтәләр. Боларның күбесенең Кафкас һиҗрәтенә инде 50-60 ел үткән булса да, яшьләр Кафкасны һичбер күрмәгән булсалар да, Ватан хәмияте *(тойгысы)* үзләрендә бик куәтле, һәммәсе диярлек беренче имкянда *(мөмкинлектә)* кайтырга торалар. Бик күп яшьләр Ватаннарыны коткарыр өчен җаннарыны фида итәргә хәзер торалар. Шуңар күрә Шимали Кафкас истикъляль хәрәкәтенә зур әһәмият бирәләр, аны тәмамән үз эшләре итеп карыйлар, кулларыннан килгән бар көч берлә шул хәрәкәтне куәтләндерергә телиләр. Үзләренең бөтен дөнья чиркәсләре берлә бәйләнешләре шактый куәтле. Араларындагы вак-төяк аңлашылмаулардан өстә дә тора белә торган башлыклары чыкса, шөбһәсез, болар Кафкас мәсьәләсендә зур бер роль уйный беләчәкләр.

Икенче көнне җомга булганга, мин Өмәвия җамигында җомга намазы укырга киттем. Җамигъ бик зур булса да, халык шыгрым тулы иде. Ләкин җомга намазы һич тә Өмәвия җамигысына мөнасиб *(туры килешле, лаек)* түгел иде. Хотбәсе искереп беткән бер хотбә; хәзерге әхвал берлә һичбер мөнәсәбәте, бәйләнеше юк. Безнең илдәге надан авыл муллаларының хотбәсе кеби бер нәрсә. Шуңарга кәефем бик китте. Җомганың фарызыны *(тиешлесен)* бетергәч тә, бер гөруһ *(төркем)* халык

тагын имамга оеп бер нәрсә укырга тотынды. Мин бонарга аптырап калдым. Ул ихтиятыз-зоһр *(өйлә)* намазы икән. Жомгадан сон Әмир Габделкадыйр әл-Жәзаиринен музәханәсене карадык. Бу музәне Әмир Сәгыйд [Әмир Габделкадыйрнын хәфиде *(оныгы)*] ясаган вә мөмкин кадәр бабасына гайд *(мөнәсәбәтле)* бөтен коралларыны, бөтен киемнәрене, бөтен вәсикаларны *(материалларны; мәгълуматларны)* тупларга тырышкан. Жәзаир *(Алжир)*-француз сугышыннан берничә Аурупа рәссамнарынын рәсемнәре берлә дә диварларыны зиннәтләгән. Музәгә бик күп көч, бик күп акча сарыф ителгән. Музәнен, шөбһәсез, кыйммәте дә бик зур. Ләкин музәханәнен каралуы, саклануы бик мөселманча куелган: теләгән кеше кереп карый ала, теләгән каракка кыйммәтле тарихи нәрсәләрне угырлау да бер дә авыр түгел.

Аннын сон Әмир хәзрәтләре Шамны күрсәтергә булды. Автомобиленә утырып шәһәр гизентесе ясарга чыктык. Беренче уларак Мөхеддин әл-Гарәбине зиярәт иттек *(Ибне Гарәби—1165-1240 елларда яшәгән мәшһүр философ, суфый. Ул аеруча үзенен "вәхдәтел-вөжүд"—"яшәешнен берлеге һәм бердәмлеге" турындагы карашлары белән тарихка кереп калган. Ибне Гарәбине еш кына "бөек шәех", "Әфләтүн угылы" дип тә йөртәләр. Ризаэддин Фәхреддинен бу зат хакында махсус монографиясе дә бар.—Х.М.)*. Бу ислам галименен зыяраты бонда мокаддәс хисап ителә. Башына зур бер жамигъ та бина ителгән. Шул жамигънын йортында Жәзаир каһарманы Әмир Габделкадыйр хәзрәтләре дә дәфен ителгән *(күмелгән)*. Дөнья сугышыннан сон гарәп илләрендә башланган каргашалык *(ыгы-зыгы; буталыш)* эчендә шәһид ителгән Әмир Сәгыйднен борадәренен дә *(туганынын да)* зыяраты шунда икән. Бу зат хакында мин бу сәфәремдә бик күп ишеткән идем, бу ике борадәрнен төрек-гарәп арасы ачылмас *(бозылмасын)* өчен никадәр зур каһарманлык берлә чалышулары *(хезмәт итүләре)* хакында берничә тарихи вәсыйкалар да күреп, икесенә дә зур хөрмәт биләгән идем. Шул ике бөек ислам шәһиденен рухына Коръән укыдык. Аннан сон әмирнен шәһәр читендәге гареб стилендә салынган күшегене *(сараен)* карарга киттек. Бу күшек хакыйкатән *(чыннан да)* бик матур, бик стильле иттереп эшләнгән.

Мин Шамда Русия мөселманнары хакында бер конферанс *(лекция)* бирәчәк булган идем. Ләкин бондагы дусларнын сорашу-белешүләреннән бондый конферанска французларнын мөсагадә (булышлык) итмәүләре беленде. Гизле (яшерен) бер мәжлестә конферанс бирү хатрәле (тыелган) дидекләреннән, мин дә ваз кичәргә булдым. Шул бушлыкны тутырыр өчен Әмир Сәгыйд хәзрәтләре шәһәрнен олугларыны, хәмиятлеләрене чакырып бер аш мәжлесе ясады. Без дә 3-4 сәгать шунда дәрдләштек. Вакытым аз калганга, иртәгә китәргә тиеш идем. Шунын өчен Шамдагы дуст-ишләр берлә күрешеп аерылдым вә икенче көнне Бәйрутка киттем.

Бәйрут—безнен сонгы еллардагы Уяну дәверебездә шактый зур роль уйнаган бер шәһәр. Безнен Уяну дәверендә мәктәпкә омтылучы, Аурупа гыйлемене тәхсыйльгә *(өйрәнергә)* тырышучы бик күп яшьләребез мәйданга атылган иде. Боларнын зур бер кыйсеме мәдрәсә шәкертләре булганга, рус мәктәпләренә кереп укырга яшьләре үткән була иде. Руслар үзләре дә боларга дуст карамаганга, Русиядә боларнын гыйлем вә фәнгә сусауларыны бастырырлык бер мәктәп тә юк иде. Шуларнын зур бер кыйсеме Төркиягә китә. Истанбулнын дарелмөгаллимендә *(педагогия уку йортында)*, дарелфөнүнендә үзләренен эзләгәннәрене табып, гыйльми хәзерлекләрене арттырып илгә кайталар иде. Бер кыйсеме Бәйрутта Америка миссионерлары тарафыннан ачылган Бәйрут көллиясәсенә *(колледжына)* кадәр китәләр вә аннан инглизчәгә өйрәнеп, тәкиянен шәкертләре арасына керәләр, инглиз теле аша Аурупа мәдәниятләрене өйрәнәләр иде. Бондый яшьләребезнен саны сугышка кадәр күбәйгәннән-күбәя бара, аннан тәхсыйлене бетереп илгә кайткан яшь зыялыларыбызнын саны ел саен арта бара иде. Болар арасында безнен мәктәп, мәдрәсә ислахында *(реформасында)* зур роль уйнаган Нияз Максудый, Казый Габдулла Сөләйман, петрол мөһәндисе *(нефть инженеры)* Кәмал Локман кеби бөтен милләт тарафыннан танылган затлар юк түгел иде.

Бонарга башка, Бәйрутнын мөфтисе безнен мәктүб берлә мөрәжәгатебезне эшкә ашырып, Русия мөселманнарынын большевик идарәсендәге авыр хәлләре берлә халыкны таныштырып, Рамазан гаетендә зур хотбә сөйләп, безнен туганнарнын бу золымнан котылуы өчен дога да кылган иде. Бонарга рәхмәт уку да минем вазыйфам иде. Шунын өчен Бәйрут минем өчен күреләчәк бер йир иде. Мөтәмәрдә күрешкән, танышкан бик күп гарәп жәмәгать хадимнәре дә бонда яшәгәнгә, мин боларны эзләргә булдым. Мөтәмәр тарафыннан китабәт һәйәтенә *(секретариатка; редакцион*

*комиссиягә)* сайланган Рияз әс-Сәлах бәкне эзләп таптым. Гарәпләрнең милли мөҗадәләсене *(мәсьәләләрен; каршылыкларын)* тәмамән каураган *(өйрәнгән)* бу зат үзе яшь, үзе эшчән, үзе тәмиз *(саф)* калебле булганга, шөбһәсез, киләчәктә зур роль уйнаячак бер шәхсияттер.

Аннан соң Тәрабулүс *(Триполи)* мөҗаһәдәләреннән *(дин өчен тырышучыларыннан)*, иске төрек забитларыннан *(аксөякләреннән, түрәләреннән)* Бәшир әс-Сәһдави берлә күрештем. Аның берлә Бәйрутны карарга вә дустларны эзләргә тотындык. Олуг мөфтине зиярәт иттек. Мин халкыбыз исеменнән тәшәккер иттем. Мөфти—анлы, киң карашлы бер зат. Гарәп гәзитәләреннән "Ән-нидан" *(тавыш; чакыру)*, "Әл-Бәлаг" *(матур сөйләм; риторика)* гәзитәләрене дә зиярәт итсәк тә, идарәдә адәм гакыллы бер мөхәррирне дә очрата алмадык. Өйләдән соң "Әш-Шәрык" гәзитәсенең мөхәррире, мөэтәмәр әгъзасы Гуни әфәндене урамда очраттым. Аларның идарәханәләренә киттек. Гәзитәләре басыла торган матбагада бер әрмәни гәзитәсе дә басыла икән. Гуни әфәнде мине бер әрмәни мөхәррире берлә дә таныштырды. Моның берлә сүзгә керешеп киттек. Әрмәни мөхәррире:

—Без сезнең мөэтәмәрдәге *(корылтайдагы)* бөтен эшләрегезне тәгъкыйб итеп *(күзәтеп)* килдек. Бөтен рапорларыгызны *(язмаларыгызны)*, бөтен нотыкларыгызны гәзитәбездә нәшер иттек. Безнең арабызда бик күп кафкасияле әрмәни булганга, бик зур дикъкать берлә андагы мөселманнарның авыр хәлләрене тәгъкыйб иттек. Безнең Русиядәге халкыбыз сезнең берлә бергә; без дә Русиянең парчалануын телибез, сез дә шуны телисез,—диде. Сүриядә йөз меңгә якын әрмәни яшәгәнне аңлатты. Мин бондан чыгып, Бәйрут көллиясәсене карарга киттем. Ләкин вакыт соң булганга, башка бианаларны кереп карап йөрергә мөмкинлек булмады. Шәһәрнең төрле йирләрене гизеп, үзебезнең бондагы бердәнбер илдәшебез, бонда мөгаллимлек итүче ханымны эзләргә киттем. Адресым начар булдымы, никадәр кыдырсам да *(теләсәм дә)* таба алмадым. Рияз әс-Сәлах бәк берлә күрешеп, Русия мөселманнары хакында бер конферанс укырга теләдем. Ләкин француз полисеннән мөсагадә *(ризалык; ярдәм)* алу мөмкин булмаячагыннан, ваз кичәргә мәҗбүр булдым. Хосусый күрешүләрдә, зыяфәтләрдәге *(очрашулардагы)* фикер алышулар берлә генә канәгатьләнергә мәҗбүр булдым. Киту көнем дә житте. Мин билетләремне алып Берлинга телеграмм бирергә киттем. Төрекчә язган телеграмманы алмас өчен мәэмүрләр *(хезмәткәрләр)* япмадыкларыны *(эшләмәгәннәрен)* калдырмадылар. Ахырда "Төрекчә Аурупада аңлашылмас, сүзләр бозылыр",—диделәр. Телеграммны алмадылар. Мин мөдиренә чыгып, шикаять иттем. Ул:

—Бу сезнең мәнфәгатегезгә, сүзләр бозылыр дип куркабыз, фәлан,—диде.

—Минем мәнфәгатем гаиб улмадан *(юкка чыгудан)* курыкмагыз, бән разыем (ризамын), бән Аурупаның бөтен шәһәрләрендә төрекчә телеграфләшерем, нәдән сездә төрекчә мәмнугъ *(тыела)*—дидем.

—Хәер *(юк)*, әфәндем, мәмнугъ дәгел, фәкать төрекчә аңлашылмаз ки!—диде.

Әсрарле *(тырыша торгач)* телеграммымы төрекчә бирдем. Бонда төрек тәэсирене бетерү өчен эшләнгән бер сәясәт булырга кирәк. Төрек консуллары, төрек бәкләренең бондый кечкенә эшләргә дикъкатләрене җәлеп итәргә, әлбәттә, вакытлары юк...

Вапурга *(пароходка)* киттем. Паспорт контроле башланды. Кырык төрле сөальләр берлә башымны катырдылар. Соңыннан үзләренең гизле *(яшерен)* бүлмәләренә кертеп бик озак тоткач кына "вапурга утырырга ярый" дип виза суктылар. Отельдә вакытымда ике мәртәбә полис килеп, паспортымны язып-сызып, сорап киткән иде.

8нче март төнлә вапурыбыз калыкты *(кузгалды)*. Мин өч ай ярымлык мөэтәмәр *(корылтай)* сәфәремнән өйгә таба борылдым. Шул ук Русия мөселманнарының эше берлә әле Румага *(Римгә)* керергә мәҗбүр булсам да, анда да хәрәкәтләрдә булынсам да, алар ислам дөньясына гаид булмаганга *(карамаганга)*, хатирәләремне шунда бетерәм.

*Гарәп хәрефләре белән язылган текстны*
*тиешле шәрех-аңлатмалар белән хәзерге графикага күчерүче*
*профессор Хатыйп Миңнегулов (Х.М.).*

Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ГЫЙЛЕМ ӘН-НАСИХ ВӘ-Л-МӘНСУХ*** *г.* – Юкка чыгаручы һәм гамәлдән чыккан нәрсәләр турындагы гыйлем. Бер-берсенә каршы килә торган аятьләрне тикшерә. Мондый аятьләр 225 исәпләнә. Алар арасында гамәлдән чыгарылган һәм Коръәннән төшереп калдырылган аятьләр, үзгәртелгән аятьләр һәм хөкеме бетерелгән, ләкин Коръән мәтенендә сакланган аятьләр аерып карала. Л.И.Климович, "Гыйлем ән-насих вә-л-мәнсух"ка таянып, Коръәннең 40 сүрәсендә хөкеме бетерелгән аятьләр бар дип күрсәтә. Мондый капма-каршылыкларны "Сыер" сүрәсенең 106 нчы аяте аңлата: "Әгәр кайбер аятьләрнең хөкемнәрен үзгәртсәк яки оныттырсак, ул аятьләргә охшашлы аятьләрне яки яхшыракны бирербез."

Әиммәи әрбагыйлардан *(дүрт имамнан)* берсе *Әхмәд бине Хәнбәлнең* (780/174–855/241) "Гыйлем ән-насих вә-л-мәнсух" исемле хезмәте бар.

"Гыйлем ән-насих вә-л-мәнсух"ны үзләштерү һәм хәтердә тоту бик үк ансат эш булмаса кирәк. Шуның аркасында дәһриләр арасында моннан көлеп гөнаһка батучылар да табыла. Мәс., Шәехзадә Бабичның: "Кайсы мәнсух, кайсы насих? Ансын инде син аер," – дигән төртмә сүзләре билгеле.

***ГЫЙЛЬМЕ ЙАКЫЙН*** *г.* – Акыл һәм дәлилләү юлы белән алынган гыйлем. Мәс., Шәригать хөкемнәре.

Әлбәттә, барлык гыйлемнәр дә Аллаһы Тәгаләдән, ләкин шәргый гыйлемнәр кешеләргә рәсүл яки мәләкләр аркылы ирештерелә, ә гыйльме-ләдүн турыдан-туры Аллаһыдан иңә *(вәхий кылу, илһам кылу).*

Тагын кара: ***ГЫЙЛЬМЕ-ЛӘДҮН.***

***ГЫЙЛЬМЕ-ЛӘДҮН*** *г.* – Аллаһыдан килгән белем, ләдүн гыйльме. Коръән-кәримнең "Кәһәф" сүрәсендә (18:65) Алла колларыннан берсенә *("Ногмани тәфсире"ндә: Хозур галәйһиссәламгә)* илаһи гыйлем бүләк ителгәнлеге әйтелә. Кол Шәриф әсәрләренә язган комментарийларында Ә.Шәрипов ләдүн гыйльме – "метафизик *(реаль булмаган)* галәмне өйрәнү гыйльме" дигән искәрмә бирә. // *Ләдүн гыйльмен күңлигә ниһаятьсез сыгдырган* – Аллаһ гыйльмен күңленә иксез-чиксез сыйдырган. Кыйссаи Хөбби Хуҗа.

Тагын кара: ***ГЫЙЛЬМЕ ЙАКЫЙН.***

***ДАВЫЛБАЗ*** *бор.* – Кош чакыру өчен күннән ясалган барабан. Чүлмәк рәвешле итеп эшләнгән, музыка коралы булып та исәпләнгән. Кош чакыру өчен махсус быргы да булган, аны *далбай* дип атаганнар.

Язылышта *тубалбаз* варианты да очрый, коралның асылын *тубал* сүзе дөресрәк чагылдыра шикелле.

***ДАЛБАЙ*** *бор.* – Ау кошын чакыра торган быргы. // ***Далбай алып чакырдым, әйләнеп кошым кайтмады.*** "Идегәй" дастаны.

Ә кош чакыру өчен хезмәт иткән барабанны *давылбаз/тубалбаз* дип атаганнар.

***ДАР (АГАЧЫ)*** *ф.* – Фарсы телендә бу сүзнең беренчел мәгънәсе – *агач, багана.* Русча "дерево" сүзе дә шул тамырдан. Моннан борынгыларның хөкем ителгән кешеләрне үсеп утырган агачка асканлыклары аңлашыла.

***ДАРЫ*** – Фарсыча *дару (лекарство)* сүзеннән. "Дару" сүзе "Древнетюркский

*Дәвамы. Башы журналыбызның алдагы саннарында.*

словарь"га да теркәлгән. Русча *ружейное зелье*—мылтык даруы, ягъни дары. Халык медицинасында ярага дары сибеп дәвалау да булган. Татар теленә гарәпчә *баруд (дары)* сүзе дә кергән. "Дары исеннән шайтан кача имеш" дигән мәкаль бар. Электә шушы сүзләрне әйтеп, килен төшкәндә мылтыклар атып каршылау гадәте булган, ягъни утлы коралның мифик көченә ышанганнар *(Нәкый Исәнбәт буенча)*.

***ДӘВАТ*** *г.*.—Кара савыты. Электә Казан дәүләтендә диванханәдә һәм базарларда язу-күчерүчеләр рәте булып, алар дәватләрен бау белән муенга тагып, каурый каләмнәрен колак артларына кыстырып торганнар *(Н.Исәнбәт буенча)*. "Дәват" сүзе "Древнетюркский словарь"га да теркәлгән. "Татар теленең диалектологик сүзлеге"нә (1969) караганда, кайбер сөйләшләрдә "дәвәт" дип фарфор кара савытына әйткәннәр. Себер татарлары сөйләшендә—*тәүәт*.

***ДӘҖҖАЛ*** *г.*—Ялганчы, аздыручы, диннән яздыручы, ялган мессия (мә- сих), Антихрист. *әл-мәсих әл-Кәззаб* һәм *әл-мәсих әд-Дәҗҗал* дип тә атыйлар. Дәҗҗал Коръәннең үзендә телгә алынмый. Хәдисләрдә Дәҗҗал Һинд диңгезендәге бер утрауда кыяга богаулап куелган һәм аны җеннәр каравыллыйлар, ашатып торалар дип тасвир ителә. Утрау янынннан узып баручы кораблар аннан музыка тавышлары ишетәләр икән. Дәҗҗал—кыямәт булыр алдыннан кузгалып, үзен Гайсә пәйгамбәр яки Мәһди дип күрсәтергә маташачак. Үзенә ияргәннәрне ул оҗмахка кертә, ләкин аның оҗмахы тәмуг булып чыга икән. Дәҗҗал үз юлындагы мәчетләрне туздырачак, мөселманнарны куачак. Аның хакимлеге 40 көннән *(яки елдан)* артмаячак, аны дүртенче кат күктән төшкән Гайсә пәйгамбәр *(Гайсә ибн Мәрйәм)* берүзе яки Мәһди белән бергәләп җиңәчәкләр һәм үтерәчәкләр. Нәкый Исәнбәттә дәҗҗалны "сыңар күзле, бик зур буйлы, җен көчле булып, ахыр заман булыр алдыннан гармун тартып, юлдан яздырып йөрер имеш" дигән аңлатма очрый. Хәдисләргә караганда, Дәҗҗал сыңар күзле, кызыл тәнле, аның маңгаенда *кяф* хәрефе яки *кяфир* сүзе тулысы белән язылган була. Аның һәрвакыт ишәккә атланып йөргәнлеге сөйләнә.

"*Өммәтем өчен дәҗҗалдан бигрәк азгын имамнар куркынычлырактыр*" дигән хәдис бар. Чөнки дәҗҗалны азмы-күпме белергә һәм аның явызлыгыннан сакланырга мөмкин, ә тәкъва булып йөрүче азгын имамнарны тану кыенрак.

***ДӘРВИШ*** *ф.*—Капка ачучы, фәкыйрь *(ярлы, хәерче)* мәгънәсендә. Суфилар брадәрлеге әгъзасы. Дәрвишләр дөнья рәхәтләреннән ваз кичеп, төрле мәхрүмлекләргә түзеп яшиләр. Дәрвишлек башта Сүриядә, Мисырда һәм Гыйракта таралган, соңыннан суфи һәм суфичылык термины кулланыла башлаган. Иранда, Урта Азиядә, Һиндстанда һәм Төркиядә "дәрвиш" сүзе таррак мәгънәдә—хәер эстәп тукланучы сәйяр суфи мәгънәсендә кулланылган. Гомумән, урта гасырлар башында дәрвишләр 2 төргә бүленгәннәр дип карарга була: бозык әхлаклы сәйяр дәрвишләр һәм галим дәрвишләр—суфилар.

Бохарада, Мервта, Һиратта дәрвишләр саны кайчагында берничә меңгә, хәтта уннарча меңгә җиткән, бу исә илнең нормаль икътисади тормышына комачаулый торган булган.

***ДӘРД*** *ф.*—Авыру, газап; дәрт. Татар теленә бу сүз теләк, омтылыш, дәрт мәгънәсендә кергән. Шуңа күрә *дәрт бар, дәрман юк* дигән гыйбарәне *теләк бар, чарасы юк* мәгънәсендә генә аңлаталар. Ләкин аның асыл мәгънәсе *"чире бар, даруы юк"* булуы бик мөмкин *(кара: дәрман)*. Татар диалектларында "дәрт" сүзе "кайгы, хәсрәт, борчу, ваем" мәгънәләренә дә ия. // *Әйлә дәрман дәрдемә сән, Кылмагыл бәне хәраб.* XVIII гасыр бәетеннән.

Суфилар өчен дәрд (дәрт)—хакыйкатькә ирешү кайгысы, илаһи гыйшык. // *Дәрт әйләмәк*—хәсрәткә төшү.

***ДӘРМАН*** *ф.*—**1.**Дәвалау; дару *(кайбер чыганакларга караганда, русча дурман үләне исеме дә шифалы дәрмана үсемлеге исеменә барып тоташа)*. Димәк, "дәрт бар—дәрман юк" дигән әйтемнең асыл мәгънәсе "чире бар, даруы юк" булып чыга. **2.**Әмәл, чара, көч-куәт.

***ДӘСТАР*** *ф.* — Чалма, сәллә (*ф.*) Дәстарның шигъри антонимы — *"пайи бәнди"* (аяк чолгавы). Дәстар сүзенең тастымал (кара: *дәстымал*) мәгънәсе дә бар: *дәстар башы тоту* — мәет җирләгәндә тастымал белән мәетне берничә җирдән тотып тору. "Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә (1993) соңгысының мәгънәсе башкача аңлатыла: *"дастар баш дыту* — мәет юганда өстендә җаймә тотып тору." Һәр ике мәгънәсе дә дөрес, әлбәттә. Аннары татар телендә шарфка охшашлы баш яулыгын да *тастар* дигәннәр. Бу сүз каракалпакта, кыргызда, башкортта, чуашта да бар.

***ДӘФТӘР*** *г.* — Борынгы төрки телдә — китап, диван (канцелярия, амбар) кенәгәсе, дәфтәр.

Бу сүзнең тарихы грек теленә алып бара. "Башта борынгы греклар язу тиресен *дифтера* дип атаганнар (Чаг.: дифтерит — тире авыруы). Бу сүз греклардан гарәпләргә һәм фарсыларга күчкән, ә фарсылардан аны борынгы төркиләр һәм монголлар үзләштергәннәр. "Древнетюркский словарь"га да теркәлгән. Алтын Урда чорында *тәптәр* (ягъни "дәфтәр") сүзе белән салым-йолым түләүчеләр исемлеген һәм яркә-сурәт (кагыйдәләр, законнар) җыентыгын атаганнар." (Р.Әхмәтьянов.) "Дефтер", "девтер" (басым беренче иҗектә) салым-җыемнар турында хан ярлыгы яки грамотасы мәгънәләре белән Владимир Дальнең "Толковый словарь живого великорусского языка" сүзлегенә дә кергән. Элегрәк бу сүз, бүгенге телдәге гадәти мәгънәсеннән тыш, туу, үлү, никах һәм аерылу, хисап эшләрен, исемлекләрне язып бару өчен указлы муллалар кулында булган "*метрика дәфтәре*" (тәвәллед дәфтәре) мәгънәсендә дә йөргән (кенәгә, журнал). *Типтәр* атамасын да дәфтәр сүзе белән бәйләп аңлаталар.

// *Фәләк дәфтәре*—язмыш дәфтәре, язмыш китабы. *Дәфтәр ябу* — сәүдәнең барышы турында еллык хисап ясау.

*Дәфтәр*-нең күплек саны шәкеле — *дәфатир.*

***ДИВАН*** *ф.* — **1**.Шигырьләр җыентыгы. Күплек саны шәкеле: *дәвавин*. **2**.Дәүләтнең югары идарәсе, шурасы; министрлык; салым идарәсе. Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында хан сараендагы канцелярия. Ул дүрт *карачыбәктән* (карачы биләрдән) торган, аларның берсе *бәкләрбәге* дип аталган. *Диван би* — хан канцеляриясенең башы. Баш вәзирне, диван башлыгын *сахибед-диван* дип тә атаганнар. *Диван әл-инша* яки *диван әт-тугра* — сәлҗукыйлар чорында финанс министрлыгы. *Дивани язуы* — рәсми кәгазьләр язуы. Бу төр язу стиле (өлгесе) Бохара, Хәрәзем якларында кулланылышта була, бездә дә гамәлдә йөргән (Исмәгыйль Рәмиев буенча). *Диван-яргу* — монголлар заманында яргу мәхкәмәсе. *Дивапе гаскәри* — хәрби трибунал. // *Бер вакыт мине төрек җасусы дип дивапе гаскәригә мәхкәмәгә дә бирделәр.* Г.Исхакый.

"Диван" термины руслардагы элекке *приказ* һәм *присутствие* сүзләренә дә туры килә.

***ДИВАНА*** *ф.* — Тиле, тинтәк, юләр; алла бәндәсе. Фарсы телендәге *дию* сүзенә *-ана* аффиксы ялганып ясалган сүз ("җенләнгән, дию иялләшкән" мәгънәсендә). // *Япьлек — диваналыктан бер ботакдыр.* Хәдистән.

Ләкин суфилар мохитендә *дивана* сүзе фәкать экстаз хәленә керә ала торган кешеләргә карата гына әйтелгән. Аларда *дивана* — Аллаһы Тәгаләнең серләренә төшенгән, диндарлыкта камиллеккә ирешкән, экстазда яшәүче кеше. Шагыйрь Колшәриф тә үзен "дивана" дип атый.

***ДИВАНИ ЯЗУЫ, ДИЙВАНИ ЯЗУЫ*** — Гарәп язуында иң еш кулланыла торган язу шәкелләреннән берсе. Башкалары — *куфи, нәсх, рокъгә, нәстәгъльйк* һәм *шикәстә*. Дивани язуы — рәсми кәгазьләр язуы, ягъни аны диван хезмәткәрләре кулланган. Бохара, Хәрәземдә киң таралган, безгә дә үтеп кергән.

Дийвани язуының бер төре *җәлийү дийвани* дип атала. Гадиләштерелгән дийвани стиле еш очрый.

***ДИМЛЕ АТ*** *тар.* — Чабып барышлый борылган якка бөтен гәүдәсе һәм җайдак-сыбай белән бергә авышып тиз генә борылырга өйрәтелгән ат. Борынгы төркиләрдә мондый ат кыйммәт торган. (Р.Әхмәтьянов буенча).

***ДИМШЫК КЫЛЫЧ*** *тар.* – Борынгы заманда *Димәшекъ* шәһәрендә яхшы сыйфатлы корычтан эшләнгән кылыч.

***ДИҺКАН*** *ф.* – Игенче, крәстиән. Мәктәп дәресләкләрендә бу сүзнең русча язылышына (дехканин) ияру аркасында *дехкан* сүзе тамыр җибәргән. Хәлбуки рус телендәге әдәбиятта *дихкан* сүзе дә очрый, ләкин ул, *дехкан* белән бер тамырдан булса да, башка мәгънәләргә ия: 1)урта гасырларда ярымпатриархаль-ярымфеодаль Иранда югары катлау вәкиле һәм 2) дастанчы. Татар телендә дә бу сүзне бер-берсе белән сыешмый торган өч мәгънәгә ия дип санау төрле кыенлыклар тудыра.

***ДӨББЕЛӘКБӘР*** *г.* – *Зур Җидегән* (йолдызлык), атаманың туры мәгънәсе – *Зур Аю* (Большая Медведица). "Гарәпчә – татарча – русча алынмалар сүзлеге"ндә "Җидегән йолдыз" дип тагы *Сөрәйя,* ягъни Өлкәр ("Иләк йолдыз") күрсәтелгән, әмма монда хата киткән булырга тиеш. Фарсы телендә Зур Җидегән – *Һәфт үрән,* ягъни *Җиде тәхет* (татарча атама да Җиде хан мәгънәсендә).

***ДӨББЕЛӘСГАР*** *г.* – *Кече Җидегән* (йолдызлык), туры мәгънәсе – *Кече Аю.*

***ДУҢГЫЗ*** I – Гарәпчәсе – *хинзир,* фарсыча *хук(ъ).* Исламда дуңгыз нәҗес хайван дип, ә аның итен ашау мөселман кешесенә гөнаһ дип карала (Коръән, 2: 272,273). Яһүдиләр дә дуңгыз итен ашауны тыялар, ә аларның дини кануннары исламияттән өлкәнрәк тә. Библиядә, мәсәлән, түбәндәге сүзләр бар: "Ә дуңгыз, пар тояклы хайван булса да, күшәүчеләрдән түгел, сезнең өчен ул пакь булмас; аның итен ашамагыз, үле гәүдәләренә дә кагылмагыз" (Библия, XIV: 8).

Исламда дуңгыз итенең напакь булып исәпләнүе турында Ш.Монтескье үзенең "Персия хатлары" дигән әсәрендә түбәндәгеләрне яза. Нух (Ной) туфан вакытында үзенең көймәсендә йөзеп йөргәндә барча хайваннар пар-пар алынган көймәдә бик күп тирес җыела. Дуңгыз гел шул шакшыда казына, аннары бер көнне, сасы искә үзе дә түзә алмыйча, төчкереп җибәрә. Шул чагында аның борын тишегеннән бер күсе атылып чыга да ни күрсә шуны кимерергә тотына. Борчуга төшкән Нух, Алла киңәшен тотып, көймәдәге арысланның башына нык кына суга. Моңардан арыслан да төчкереп җибәрә һәм аның авызыннан мәче килеп чыга. Шуннан соң бу хайваннарны напакь дип әйтмәскә буламы соң? Бу сорауны, Монтескье язуынча, Мөхәммәд Пәйгамбәр биргән.

Әлеге тыюның сәбәбе чучканың тирес арасында аунап, шакшы ашап яшәвендә генә түгел.

Трихиниллез дигән авыруны трихинелла дигән паразит суалчан китереп чыгара. Авыру кешене бизгәк тоткандай була, мускуллары сызлый, эче китә. Бу авыруны кеше әлеге паразит суалчаннарның личинкалары (уыллары) белән зарарланган дуңгыз һәм кайбер кыргый хайваннар (аю, бурсык, тюлень, морж һ.б.) итен ашаганда йоктыра. Хайван тәнендәге личинкалар саклагыч тышчага төренгән була һәм шунлыктан алар итне пешергәндә дә исән калырга мөмкин. Менә шуңа күрә дә сатудагы дуңгыз итенең медицина тикшерүе аша үткән булуы мәҗбүри санала. Зарарланган ит ашаган очракларда трихинелла личинкалары берничә атна эчендә үрчи, алары мускул тукымаларында туплана, ә җитлеккән суалчаннар нечкә эчәктә яши.

Бу авыру Борынгы Мисырда да таралган булган. Мәс., моннан 1200 еллар элек үлгән кешенең мускул тукымаларында (мумияләрдә) әлеге паразитны тапканнар. Борынгы Мисырда яһүдиләр дә яшәгән (куылганга кадәр) һәм, күрәсең, алар бу куркынычлы авыруның дуңгыз ите ашаудан булуын яхшы белгәннәр. Ә гарәпләр үзләре белән аралашкан халыклардан файдалы һәм кирәкле мәгълүматларны алып үзләштергәннәр.

Борынгы Мисыр халкының дуңгызга мөнәсәбәте турында "Тарих атасы" Геродот түбәндәгеләрне язган: "Мисыр халкы дуңгызны напакь хайван дип исәпли. Һәм әгәр берәр кеше үтеп барышлый гына дуңгызга орынып киткән булса да, шундук су буена төшеп, өстен салып та тормыйча, суга керә. Шулай ук дуңгыз көтүчеләргә дә, Мисыр чыгышлы булуларына карамастан, бер генә Мисыр гыйбадәтханәсенә дә керергә рөхсәт ителми. Берәү дә аларга кыз бирми яки аларның кызына өйләнми, шуңа күрә алар үз

араларында гына никяхка керәләр. Селенадан һәм Дионистан башка аллаларга мисырлылар корбан итеп дуңгыз китермиләр, хәтта бу аллаларга да билгеле бер вакытларда – атап әйткәндә ай тулган көннәрне генә китерәләр. Аннары, корбан китергәннән соң, алар дуңгыз итеннән авыз итәләр. Аларның башка бәйрәмнәрдә нигә дуңгыздан йөз чөерүләре, ә бу бәйрәмдә аларны корбан итүләре хакында мисырлыларда риваять бар. Мин бу риваятьне беләм, ләкин, оят булганга, аны сөйләп бирергә телем бармый. Дуңгызларны Селенага китерү түбәндәгечә эшләнә. Дуңгызларны чәнечкәч, каһин аның койрык очын, талагын һәм маен янәшә куеп, боларның бөтенесен хайванның эч мае белән каплый. Аннары бөтенесен утта яндыралар. Калган итен ай тулган көнне корбан китергәндә ашыйлар. Икенче көнне инде берәү дә дуңгыз итенә әйләнеп тә карамый. Фәкыйрьләр, тереклек итәрлек байлыклары җитмәгәнлектән, дуңгыз сыннарын бодай камырыннан ясыйлар да, утта пешереп, корбан итеп китерәләр."

1918 елда бөтен дөньяда таралып, миллионнарча кеше тормышын өзгән грипп авыруы ("испанка") да дуңгызлардан йоккан дип исәпләнелә.

Гомумән, дуңгыз 450 төрле авыруга дучар була һәм шуларның 200 е кешегә йогарга мөмкин икән. Бу авыруларың бер төрлесе дуңгыз карап үстергәндә һәм аның түшкәсен ит комбинатларында эшкәрткән вакытта йога (йокы авыруы, туберкулез, тасма суалчаннар, себер язвасы... – барысы 32 гә җитә). Икенчеләре дуңгыз ите һәм дуңгыз салосы ашаган кешеләрдә булучан (анемия, вульгар паралич, төче авыруы, эчәк суалчаннары, япон менингиты, корчаңгы һ.б.).

Кыскасы, Исламның дуңгыз ите ашауны катгый тыюы асылда кешеләрнең сәламәтлеген саклауны күздә тота.

Мөселманнарның дуңгыз маена карашы да шулай ук тискәре. XIX гасырда Казан шәһәрендә беренче су колонкаларына су китерүче чуен торбаларны дуңгыз мае белән майлыйлар икән дигән сүз таралгач, шәһәр мөселманнары колонкалардан су алмый башлыйлар һәм хакимиятләр торбаларны алмаштырырга мәҗбүр булалар.

Дуңгызның тиресе дә эшкә ярамаган, шулай да дуңгызның сырт кылы итек тегүчеләргә җеп очына куярга бик кирәк булып, мәнфәгатькә яраганга, сырт кылын йолкып алып эштә файдалануга юл куелган (Н.Исәнбәттән).

***ДУСТКАНИ*** *ф.* – Тустаган, стакан. Ләкин кайбер сөйләшләрдә *тустаган* – "агачтан чокып ясаган савыт"; табак; тәлинкә. "Әнмүзәҗ" ("Өлге", "Үрнәк" мәгънәсендә) дип аталган татар грамматикасы китабында (Казан, Университет типографиясе басмасы, 1895; кабат басмасы – Казан, 1975) Каюм Насыйри "дустакан" сүзенә түбәндәге аңлатманы бирә: "Фарсы гыйбарәтедер, дустлар мәҗлесендә шәраб савытига чак итдереб бер-беренә орырлар (тус), лөгатемездә тустаган мондан мөхаррәфдер." (*мөхаррәф* – бозылган мәгънәсендә – *А.Т.*) Моннан рус телендәге "стакан" сүзенең, татар теле аркылы кереп, ике тапкыр бозылганлыгын чамалыйбыз. Тагы шунысы кызык, "дусткани" сүзенең аңлатмасы "Әнмүзәҗ" китабының соңгы басмасында – русчага тәрҗемә өлешендә – бөтенләй төшереп калдырылган. Сәбәбе аңлашылмый. "Чәкештерү" сүзеннән курыкканнармы?

Кайберәүләр "дусткани" – тустаган сүзе белән "тост" сүзе арасында чыннан да уртаклык күрергә тырышалар. Объективлык хакына шунысын да искәртик: "Поле чудес" ("Могҗизалар кыры") телетапшыруларының берсендә "стакан" сүзенең рус теленә көнбатыштан кергән булуына басым ясап әйтелде. Аннары рус телендә "тост" сүзен XIX гасыр башларында ук Н.М.Карамзин кулланган инде ("Письма русского путешественника"). Б.М.Аристова аны рус телендәге "англизм"нар исәбенә кертә.

***ДУХАН*** *г.* – Тәмәке үләне. Халыкта тәмәкене куллануда яфрагын уып борынга тарту (нәсвай иснәү), тел астына салу, чәйнәү һәм төреп яки төребкәгә тутырып төтенен суыру ысуллары яшәп килгән. Мәүлана Мөхәммәд Али "духан" сүзенең "төтен", "афәт", "үлем", "ачлык", "корылык" мәгънәләренә ия булуын күрсәтә.

Мәүла Колый тәмәке турында: "Ләгыйнь шайтан хезмәтедер, бел, тәмәке, Тәмәкене тартмыш кеше, бел, нә паки," – дигән.

Татарча чыганакларда *дохан* язылышы да очрый. // *Доханкәш* – тәмәке тартучы.

# САЙАДИНЫҢ "ДАСТАНЫ БАБАХАН" ӘСӘРЕНДӘ ЯЗМЫШ МӘСЬӘЛӘСЕ

Мәгълүм булганча, Ислам фәлсәфәсе, дини мотивлар һәм сурәтләр дастаннарга да тирән үтеп кергән. Дастан—фарсы сүзе. Төрки телләрдә ул «тарих» хикәя, үткән эшләр хикәясе мәгънәсендә йөри. Яшәү һәм үлем фәлсәфәсе дастаннарда еш кына турыдантуры изге китап—Коръәнгә ияреп формалаша. Һәрбер кешенең фани дөньяга килүе, бәхете, бәхетсезлек, ахыр чиктә бу дөньядан китүе—барысы да Тәнре ихтыяры белән хәл ителә. Язмышны дастанда Тәнре билгели. Тәнре—төрки телләрдә Аллаһ сүзе белән бер үк мәгънәдә кулланыла. Аллаһы Тәгаләнең гарәпчә исемнәре арасында Тәнре атамасы кулланылмый. Чөнки килеп чыгышы ягыннан бу—саф төрки сүз. Сайадиның "Дастаны Бабахан" әсәренә килсәк Тәнре исеме шактый ук еш очрый. Бу хәл аеруча игътибарга лаек. Бер яктан ул төркиләрнең иң югары дәрәҗәле Алласы булган Тәнрегә табынуда да бераллалык тенденциясе булуын раслап торса, икенче яктан, Урта Идел мөселманнары ышануынча, күрәсен, борынгы Тәнре ислам мифологиясе белән бәйле.

"Дастаны Бабахан" әсәрендә Аллаһы Тәгаләнең берничә исеме кулланыла: Хода, Хак, Халикъ, Күк, Тәнре... Аллаһы Тәгалә һәрбер затны җанлымы яисә җансызмы, тик изге, соң дәрәҗәдә яхшы, гүзәл, матур рәвештә генә ярата, барлыкка китерә. Шул ук вакытта Алла көчле, гайрәтле, игелекле хөкемдар да, ул җиһандагы бердәнбер һәм кодрәтле хөкемдар булгач, аңа һәрбер җанлы һәм җансыз затлар берсүзсез буйсынырга тиеш. Аллаһы Тәгалә һәркемне ярата, аңа тәкъдир бирә, адәм баласы дөньяга килгәнче үк дөньяда булачак барлык вакыйгаларны, аның башыннан үтәчәк хәлләрне Аллаһы алдан белеп, язып, билгеләп куя.

Таһир белән Зөһрәнең фаҗигале мәхәббәтен тасвирлауга багышланып, легендага әверелгән сюжет төрки халыклар әдәбиятында бик яратып укылган әсәрләргә нигез булып яткан. Бу әсәр татар әдәбиятында да үзенчәлекле урын алып тора. Дастанның сюжеты, әсәргә нигез булып ятканчы, берничә гасыр буе фольклор әсәре булып, халык дастаны рәвешендә йөргән.

Дастан әкият кебек башланып китә:

*Айа дустлар, ишетең бер хикәят,*
*Ичендә сүзләре бар биниһаять;*
*Бабахан дигән әүвәл бер шаһ ирде,*
*Аның шәһренең шәһре татар ирде.*

Күп кенә әкиятләрдәге кебек, дастаннарда да баласызлык темасы күзгә ташлана. Баласызлык барлык халыкларда да бәхетсезлек булып санала. Бала булмау, димәк, синең эшеңне, нәселеңне дәвам итүче юк дигән сүз. "Шәһренең шәһре татар" булган бер җирдә Бабахан дигән шаһ яши, аның Баһир исемле вәзире була. Аларның кайгысы—"Ләйлә вә Мәҗнүн", "Фәрһад вә Ширин"дәге кебек, баласызлык. Шактый таралган бу мотив борынгыдан килә. Мона безнең эрага кадәр XX—XVII гасырларга караган "Һәлакәткә очраган кораб турында хикәят" һәм XIII гасырга караган, "Мәхкүм ителгән патша улы" дигән борынгы Мисыр һәйкәлләрен кертергә мөмкин. Баласызлык мотивы шулай ук борынгы грек һәм һинд мифологиясендә дә очрый, әмма анда ул әсәр сюжеты үсеше өчен кирәкле рольне уйнамый. Тора-бара һинд дастаннарында үсеш ала, мәсәлән, "Рама турында хикәят" (б. э. к. III – II г.г.) Дашаратхиның нәселен дәвам итәргә кеше юк, ул бик борчулы, чөнки дәүләт һәм хакимлекне кемгә биреп калдырырга да белми. Баласызлык мотивын без әкиятләрдә дә очратабыз. Мәсәлән, "Камыр батыр"да.

Сайадиның "Дастаны Бабахан" әсәрендә Бабахан бик гайрәтле хан булып сурәтләнә, дошманнарын һәрдаим җиңеп килгән, баһадирлары да күп икән, Аллаһы Тәгалә дә аны чын яр, дусты, ди. Әмма ханның бер хәсрәте бар: баласы булмау сәбәпле күп елый ул. Бу мотивның эстетик вазифасы—геройның могҗизалы рәвештә дөньяга килүен күрсәтү, ягъни эпоска хас идеаллаштыру, каһарманлаштыру тәсмерен ала.

Дөнья фольклорында геройның могҗизалы туу мотивы киң таралган мотивларның берсе булып санала. Ул тарихи-этнографик күренешләр, йолалар, гадәтләр белән генетик яктан бик нык бәйләнгән күп төрле эпизод һәм детальләрдән тора. Геройның могҗизалы тууы фольклордан алда барлыкка килә. Ул камил булмаган, примитив диннәрдән алып

дөньякүләм диннәргә кадәр таралган. Шулай итеп, баласызлык турындагы легендалар зур һәм катлаулы үсеш юлы үтәләр. Бу мотив-сюжетларның барысы да дөнья әдәбиятында һәм халыкара фольклорда, хәтта Тәүрат белән Коръәндә дә яктыртыла. Мәсәлән, геройның могҗизалы тууы турындагы мотив—Мәрьям кыз килеш Гайсәне тудыра. Мәрьям—Коръәндәге персонаж, Гайсә пәйгамбәрнең әнисе (Тәүратта— Дева Мария) Гимранның кызы. Ул Зәкәрия тәрбиясендә яши, ана көн дә Аллаһы Тәгаләдән ризык инә. Фәрештә килеп Мәрьямгә улы туачагын белдерә. Кыз, аптырап, ничек инде ир-ат кагылмаган килеш минем балам булсын, ди. Аллаһ нәрсә әйтсә, шул була, ди, фәрештә һәм Гайсәнең туганнан соң башыннан үтәчәк могҗизаларын сөйләп күрсәтә.

Икенче бер дәлил, Зәкәриянең баласы юк, хатыны кысыр булып чыга. Зәкәрия Аллаһыдан мирасчы угыл сорый. Ягъкуб нәселенә дәвамчы кирәк. Аларның картлыгында балалары була, ана Яхья дип исем кушалар ("Мәрьям" сүрәсе, 19/4-10).

Гимран белән хатыны Хөннәнең балалары юк, үзләре картлыкка ирешкәннәр инде. Хөммә бер көнне агач күләгәсендә утырганда бер кошның балаларын ашатканын күреп, минем дә балам булсачы дип зарлана. Раббыга: бер бала бирсән, ул баланы мәсҗид Әкъсага дин хезмәтенә куяр идем, дип нәзер әйтә. Аллаһ аның теләген кабул итә һәм Мәрьямгә йөкле була. Кызын мәсҗид әһелләренә бирә, Зәкәрия пәйгамбәр тәрбияли (Гимран сүрәсе, 19/35—41).

Ибраһим галәйһиссәләмнең дә озак еллар баласы булмый. Ул әгәр минем углым булса, мин аны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен корбан итәр идем—дип нәзер әйткән була. Улын чалырга алып барганда, Җәбраил фәрештә ярдәмгә килә һәм шуннан соң корбанга сарык сую гадәте керә (Һуд сүрәсе, 11/71).

Баласызлык бөтен халыкларда да, кайсы гына чор булуына да карамастан, зур бәхетсезлек булып санала. Бала туарга тиеш, ул буламы, кызмы—анысы Ходай эше. Баласызлык—кайгы, бәхетсезлек, әмма аның ахыры матур булырга—бала дөньяга килергә тиеш. Бала тусын өчен нинди мөһим чаралар күрергә кирәк соң? Борынгы чорда адәм балалары потларга, җаннарга табынганнар, соңрак дога белән Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать иткәннәр (Коръән тәфсире. Тәзүчесе—Н. Мөфлихунов. Сүрәләр: Мәрьям 19/4-10; Гимран 3/ 35-41; Һуд 11/71; Урманчеев Ф. И. Рождение героя (к типологии Казахского героического эпоса) EGER.—1982.—С. 255).

Бабахан белән Баһир да күп елыйлар Вәзир Баһир шушы хан Бабахан белән үзенә дә бала тели, күп кенә догалар вә мөнәҗәтләр укый, юынып, йокыга тала һәм төш күрә. Шул рәвешле, әсәргә төш күрү мотивы килеп керә. Төшләр—серләр дөньясы, әмма аның әһәмияте шунда: алар киләчәкне һәм үткәнне берьюлы чагылдыралар. Монда төш күрү мистикасы алга чыгарыла һәм аның Аллаһыдан изге хәбәр икәнлеге белдерелә. Төшендә Вәзир Баһир Бабахан белән бергә Аллаһының тупсасына, ягъни каршысына киләләр... Аларның теләкләрен Хак Тәгалә кабул итә. Шулай итеп, бала туасын автор төш ярдәмендә кисәтә һәм геройның могҗизалы тууын алдан белдереп куя. Бу—китап традициясенең үзенчәлеге.

Хан белән вәзир "әгәр дә балаларыбыз булса, аларны һич тә бер-берсеннән аермабыз" дип вәгъдәләр бирешәләр. Дастандагы балаларны сабый чактан ук ярәштереп кую эпизоды дастаннарның гомуми сюжетыннан алынган. Бу мәсьәлә монда хәтта балалар дөньяга килгәнче үк хәл ителә:

*Угыл булса, икәве дуст булсын,*
*Икеве бер тән, бер буст (җан) булсын;*
*Икәве бер-берләрегә махрәм (сердәш),*
*Ки булсыннар бу шәһәр ичендә мәрһәм (ярдәмчел);*
*Әгәр кыз булсалар, булсын дәкәнә (тиң),*
*Бер-берегә булганлар җанәкә (җанаш).*

Бабахан шушы рәвешле шарт куя, хан белән вәзир икесе дә моның белән килешәләр...

Сүз бирешү—Ислам динендә киң таралыш алган һәм хупланган гамәлләрдән санала. Әмма аның бер шарты бар: бирелгән сүз үтәлергә тиеш. Үтәлмәсә, хәерсез буласың, Аллаһының шәһренә (ачулануына) юлыгачаксың. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйткән: вәгъдә биргәч, вәгъдәгездә торыгыз. Әлбәттә, кеше кыямәт көнендә вәгъдә үтәлеше өчен җавап тотачак. Вәгъдә—иман дип юкка гына әйтелмидер. Кеше үтерү, зина кылу, ким үлчәү, ятим өлешенә керү кебек зур гөнаһлар арасында вәгъдәдән кайту да бар. Ислам дине буенча, биргән вәгъдәне җиренә җиткереп үтәү—дини бер вазыйфадыр. Дастанда исә вәгъдәдә тормау күренә. Ханның кыз баласы туа, ләкин ул кызын вәзир улына бирергә теләми. Ничек инде хан "кызын вәзир улына, ягъни "кара улына" кияүгә бирсен, булмаганны, аннан бит бөтен хакан иле көләчәк". Димәк, вакыйгалар олуг ханга буйсынган ханлыкларның берсендә бара.

*Тигез йөрмәс вәзире белән ханы,*
*Кода булса, борчылыр аның җаны;*
*Килер башыма йөз төрле борчулар,*
*Һәм хакан иленнән оят шул болар.*

Алда язып үтелгән юлларда тәкәбберлек тә күренә. Бабахан үзен башкалардан өстен күрә, вәзир улына түбәнсетеп карый. Ислам динендә шулай ук тәкәбберлек тә харам санала. Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә болай диелгән: "Тәкәбберләнгән кешене Аллаһы түбән төшерер, ихлас күңелленең дәрәҗәсен арттырыр".

Балалар тумаган әле, алар сүз бирешәләр. Шушы юллардан ук аларның язмышы хәл ителә. Монда каршылык алдан ук сизелә, берсе хан, икенчесе вәзир, димәк, алар туганлаша алмыйлар. Балаларны киләчәктә авыр язмыш көтә.

Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, биш яшьтә вакытта Таһирның әтисе үлеп китә. Бабахан биргән вәгъдәсеннән баш тарта.

*Тәвәккәл кылды солтан, бераз торды,*
*Онытты ант шарын һәм гамьсез булды.*

Бабахан кызының чибәрлеге әсәрдә купшы детальләр белән сурәтләнә, хәтта аның чибәрлеге мифологик элементлар белән баетыла. Кызны халык "Зөһрә" исеме белән атый. Бу бала, һичшиксез, бәхетле булырга тиеш тә бит, югыйсә, әмма кызның атасы Бабахан, ни хикмәт, вәзире Баһирга биргән антыннан ваз кичүне алдан ук ниятләп куйган. Вәзирнең улы туса, башына җитәрмен, дип күңеленә беркетеп куя:

*Угыл бирсә аңа, фикер итәрмен,*
*Ятим калса, башына мин җитәрмен.*

Дастан дәвам итә. Таһир белән Зөһрә бер мәктәпкә укырга керәләр, бер-берсе белән шигъри хатлар язышалар һәм бер-берсенә гашыйк та булалар. Бу хәлләрне бөтен халык белеп тора. Уйларында бернинди яманлык юк. Таһир башта ханның әтисе белән сүз куешуын белми әле. Көннәрдән бер көнне Таһирга бер диндар хатын очрый һәм гарипләр догасына колак салуын үтенә. Таһир сөяк белән уйнап килә икән, ул аны хатын ягына шаяртып ыргыта, сөяк аңа барып тия. Шунда бу гарибә хатын Таһирга Зөһрәсе белән шаярырга куша. Таһир аның ни өчен алай әйткәнен белергә тели, әмма хатын әйтми, үз әнисеннән кайтып сорарга куша.

Таһир өенә кайта, кыздырылган бодай ашыйсым килә, дигән сәбәп белән ашлык куырта. Әнисе аның үтенечен җиренә җиткереп үти. Шуннан ул синең учыңнан ашыйсым килә дип иркәләнгәндәй итә. Әнисе кыздырган бодайны учына ала, әмма Таһир аның кулларын ачтырмыйча кысып, теге диндар хатын Зөһрә хакында ни әйтергә теләгән икәнлеген сөйләмәсә, ычкындырмаячагын белдерә. Кыздырылган бодайдан кулы пешкән ана чарасыздан барысын да сөйләп бирә. Монда ислам диненә каршы фикер ята. Бала анасы белән ни өчендер каты мөгамәләдә сурәтләнә.

Курмач мотивы "Дастаны Бабахан" әсәренең тирән тамырларын халык эпосы һәм әкиятләренә илтеп тоташтыра. Курмач мотивы Себер татарларының "Алпамша" версиясендә очрый. Бу мотив башкорт хикәятләрендә дә бар (Әхмәтова Ф. В. Дастаны Бабахан // Татар әдәбияты тарихы.—I том.—Казан, 1984.—Б.).

Ике яр күркәм бакча почмагында очрашалар һәм бер-берсенә газәлләр әйтешәләр. Ләкин күрәчәк күренеп килми, аларның шулай утырганнарын бакчачы күреп ала һәм Бабаханга барысын да сөйләп бирә. Бу хәбәрдән соң Бабахан шаһ Таһирдан ничек булса да котылырга уйлый. Сандык ясатып, аңа бераз су һәм ризык куялар. Таһирны шунда салып, Хубанның һәм Зөһрәнең, бәкләрнең аһ-зарларына игътибар итми, үтенечләрен тыңламый, дәрьяга ташлата. Таһир газап һәм җәберләр күреп, сандык эчендә төрле маҗаралар кичереп, ниһаять, ике олы кошка юлыга. Алар аны үз ояларына алып менәләр, агач башында калдыралар. Егет шунда язмышының авыр булуына зарлана. Аллаһыдан ярдәм сорый. Җилдән Зөһрәгә сәлам җибәрүен һәм хәленнән хәбәр бирүен үтенә. Күренгәнчә, монда җил җанлы бер мифологик образ итеп бирелә, эпик геройга ярдәмгә килә. Әмма моның белән каһарман үзенең көчен һәм дәрәҗәсен югалтмый. Аның догалары кабул була. Язгы җил аны кош оясыннан суга төшерә, ул тагын язмыш сынавын үтеп исән кала.

Кошларның ярдәме һәм җилнең хәбәр җибәрүе—әкият мотивы. Билгеле булганча, безнең борынгы бабаларыбыз кешеләрнең генә түгел, дөньядагы һәрнәрсәнең дә җаны, теле, аңы бар дип уйлаганнар. Әйтик, хайваннарның, үсемлекләрнең, ай-кояш, җил-яңгырларның... Мондый ышанулар фәндә анимизм дип йөртелә. Халык иҗатында чагылыш тапкан гореф-гадәтләр, карашлар шул ук анимизмга, һәрнәрсәнең җаны бар дип ышануга барып тоташа.

Дастанда могҗизалы, тылсымлы төшләр белән бәйле күренешләр гаҗәеп дәрәҗәдә

зур роль уйный. Алар геройның киләчәген алдан ук билгеләп куялар. Багдад патшасының Маһым исемле бик чибәр кызы бар икән. Ул төш күрә. Төшендә бер шаһзадә белән сөйләшеп утыра, имеш, аннан кай тараф кешесе булуын, нәселен, кемнең яры икәнлеген сораша. Ана җавабында егет үзенең Таһир исемле булуын, Татар шәһәреннән мосафир икәнлеген, әмма монда килүе Маһымга җәбер-җәфа китерәчәген белдерә. Маһым шунда йокысыннан уяна, елый, тәрбиячесенә төшен сөйли. Әнкәсе бу егетнең чыннан да киләчәген, әмма Маһымның күңеленә газап салып китәчәген юрап бирә. Төш символикасы урта гасыр әдипләре тарафыннан әсәр каһарманнарының киләчәк язмышын алдан ук белдереп кую өчен хезмәт итә. К. Сайадига да бу фәлсәфә чит түгел. (Фәрит Яхин. Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология—Казан: Тат. Дәүл. Гум. Инст-ты. Нәшр.,—2000.—б. 82-199.).

Сандык Таһирны дәрья буйлап Багдад шәһәренә китерә һәм ул шулай итеп Маһым кулына барып эләгә. Кызлар аның сандыкка ничек керүен һәм кайдан килгәнлеген сораштыралар.

*Күземне ачтым исә—бер яхшы сандык,*
*Җиде алма һәм бүтән ни-нәрсә юк.*

Җиде санына килгәндә, ул халык иҗатында, аеруча дастан-әкиятләрдә киң таралган эпик сан. Аны изгеләштерү, эпиклаштыру катлаулы һәм бик борынгы карашлардан килә. Изге сан буларак, җиде халык иҗатында һәм Урта гасыр әдәбиятында киң таралган.

*Бу сарайга килгәнем, дуслар, тәкъдиремнән булды,*
*Гүзәллеген күрүем, дуслар, тәкдиремнән булды.*
*Бу дәрья эчендә кэю, янә һәлакәт-җәфалар күрү,*
*Синең алда җан бирү, дуслар, тәкъдиремнән булды.*
*Тәкъдирдән икән, дуслар, моның кебек судан файда,*
*Төшеп башка файдалар, дуслар, тәкъдиремнән булды.*

Таһирның кызларга биргән җавабыннан түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин. Бәндәнең тәкъдире Алланың тәкъдиреннән узмый. Димәк, әле аның гомере бетмәгән, алда тагын күрәселәре, яшиселәре бар.

Маһымга өйләнсә дә, Таһир Зөһрәгә тугрылыклы булып кала. Аларның арасында һәрвакыт үткен кылыч ята, шулай кыз белән егет булып кала бираләр, әмма серне һичкемгә белдермиләр, Тәңре тарафыннан Таһирга күктә ике никах язылган була (Маһым һәм Зөһрәсе белән кавышу). Күктә укыганны җирдә күпме генә каршылык кылсалар да беркем дә боза алмый.

Әнкәсенә дә ялгыз яшәү тәкъдиренә язылган, күрәсең. Хубан—ирен югалта, улыннан аерыла, әче сагыш эчендә яши. Баласын югалту хәсрәтендә яна-көя, ул да дөнья куя. Ана да тәкъдир вакытсыз үлем язган.

*Мәкерле Күк, ни үчлек итеп син,*
*Ни максат һәм морадыңа җитеп син?*
*Ялгызлык утына кэю тәкъдирдән өлеш булды,*
*Кавышу шаменә яну тәкъдирдән өлеш булды.*

Монда төрки-татарларның Ислам диненә кадәр булган Тәңрелек динендәге илаһилаштырылган күк күздә тотыла, ул Күк исә Аллаһы Тәгаләгә каршы куела.

Зөһрә бер ялгызы кала, мәхәббәте сагышыннан атасын да анасын да оныта. Атасы кызын сөт карендәше Кара Баһадурга бирергә ниятли. Кара Баһадур мона бик сөенә. Әмма Зөһрә Таһирны юксына, аны эзләп хәбәр тапшыручыны җибәрә (җырчы-касыйдны). Ул шәһәрдән-шәһәргә йөреп, мәхәббәт хакында касыйдәләр сөйли. Ахырда Багдадка килә һәм Таһирны таба. Таһир Зөһрә хәбәрен ишетеп, шаһтан китәргә рөхсәт ала, Маһым белән хушлашып кайтырга чыга. Юлда төрле каршылыкларга, каракларга очрый. Хәтта тау да ана каршы булып юл бирмичә газаплый. Таһирның горбәт-гариплектә йөрүендә суфичылык мотивлары да бар.

Юлда аны гашыйк яр булганы өчен генә таламый-кимсетми җибәрәләр. Язмыш бу очракта да Таһирга мәрхәмәтле.

Көттергән кавышу көннәре килеп җитә. Таһир белән Зөһрә очрашалар. Алар бер хатыннан никах укытып кавышалар, ләкин шаһ моны белеп ала. Таһирны китертеп башын кистерә.

Сөйгәне янына ашкынып кайтып та, язмыш аларга кавышу—бергә яшәү насыйп итмәгән. Күрәчәк күз йомдыра, дип хак әйтә халык мәкале. Үлеме аны туган җирендә сагалап торган икән.

Таһирның җәсәден алып кайтып, юып күмгәннән соң Зөһрә тагын да зуррак хәсрәткә төшә. Кара Баһадурга туйга әзерләнергә куша. Таһирның каберенә килә һәм, күкрәгенә хәнҗәр кадап, үзен-үзе үтерә.

Җан кешегә бер әманәттер. Җанны бирүче Аллаһыдыр. Вакыты җиткәч, ул әманәтен кире алачактыр. Үз-үзләрен үтергән кешеләр Аллаһының әманәтенә хыянәт иткәннәре өчен зур гөнаһлы булырлар. Динебез катгый тыйган нәрсәләрнең берсе—үз-үзенә кул салу. Андыйларга җеназа намазы да укылмас диючеләр дә бар. Зөһрәне тәнкыйтьләп тә булмый, үзенең яраткан кешесе, мәхәббәте хакына үлүе аның язмыш тактасына туганда ук язылган булган, күрәсең.

Зөһрәнең дус кызлары һәм ата-анасы канлы яшьләр түгәләр. Каберләре янына Кара Баһадур килә, ул да Зөһрәне яраткан икән, үзен-үзе чәнчеп үтерә. Таһир белән Зөһрә уртасына Кара Баһадурны күмәләр, тагын ике гашыйкны аералар.

*Уңда—Зөһрә, ә сулда—Таһир,*
*Алар уртасында Кара Баһадур.*
*Берсе гөл булды, берсе—сабагы,*
*Икесе чормашып—сирәкләр хәле.*
*Әмма Кара Баһадур һәм күгәреп,*
*Чыгыптыр икесен аерып-ярып.*

Гашыйкларның үлеменнән соң чәчәккә әверелүе хакында миф бүтән язма әдәби әсәрләрдә очрамый. Бу бәлки бик борынгы ышануларга барып тоташадыр. Әсәрдә ул миф шигъри-поэтик алым буларак аклана һәм шактый символик мәгънәгә ия. Димәк, Кара Баһадур Зөһрәне чын күңелдән яратмаган, кыз өчен җанын фида кылырга әзер торса, ул Кара тигәнәк буларак сурәтләнмәс иде.

К. Сайадиның "Дастаны Бабахан" әсәрендә мифологик кыйссалар ахырынача җиткерелә. Бабаханның төшенә кызы керә һәм ул үзе белән Таһир арасында күмелгән Кара Баһадурны урталарыннан алырга дөньялыкта булмаса да, инде Ахирәттә яратканы белән кавышырга комачауламавын үтенә.

Бабахан шушы төшеннән соң, кызының каберенә килә һәм тигәнәкне йолкып ташлый, Кара Баһадур җәсәден Зөһрә белән Таһир арасыннан алдыра, һәм ата-анасын да үз янынннан кудыра.

Таһир белән Зөһрә рухлары символы булган чәчәкләр арасында тагын да тигәнәк үсеп чыкса, аны йолкып ташларга әмер бирә.

Маһым да бу хәлләрне ишетеп, дөнья куя. Ул үлемен Ходайдан сорап ала. Кабере гөлбакча була. Маһымның да әти-әнисе кызларының Таһир белән кавышуын төшләрендә күрәләр. Төш күрү—язмыштан хәбәр ул. Ислам динендә төш күрү Аллаһы Тәгалә белән рухның бәйләнешеннән чыгып аңлатыла. Димәк, Аллаһы Тәгалә үз колларына төш күрүне киләчәк язмыштан гафил булмас өчен бирә.

Бабахан—каты күңелле, явыз ата булып сурәтләнә. Аны кабат баласызлык, ачы язмышлы тәкъдир көтә. Аллаһы яраткан иң өстен зат—кеше. Кеше—вәзир улымы, колмы ул, кем генә булса да яшәргә хокуклы. Адәм баласын ярату да, үтерү дә Аллаһы эшедер.

Егет белән кызның фаҗигале язмышы тормыштагы гаделсезлекләрнең, каты күңеллелекнең аяныч нәтиҗәсе буларак кабул ителә. Таһир бер тапкыр үлемнән котылып кала, икенчесендә башын чабалар. Димәк, ана шулай язылган булган, язмыштан качып котылып булмый. Язмыш—ул өстен көч. Ислам мифологиясе буенча кеше үзе туганчы ук аның язмышы күптән Аллаһы Тәгалә тарафыннан билгеләп куела. Борынгы әдәбиятта язмыштан узмыш юк дигән фикер еш чагыла.


Язылганнардан нәтиҗә ясасак, XX гасыр башына кадәр татар әдәбияты тарихында Таһир белән Зөһрә мәхәббәте темасына язылган мәгълүм әдәбият истәлекләре бары Сайадиның "Дастаны Бабахан", Әхмәт Уразаев-Кормашиның "Таһир илә Зөһрә кыйссасы" әсәрләре белән генә чикләнә. Шулар тәэсирендә сюжетның төрекмән һәм казакъ телләрендә әдәби вариантлары да барлыкка килгән. Таһир белән Зөһрә мәхәббәте турындагы сюжет кыпчак халыкларының "Кузы Күрпәч белән Баян Сылу" дастанына якын тора.

Урта гасыр төрки-татар әдибе Сайадиның "Бабахан дастаны" татар яшәгән һәрбер төбәктә диярлек халык китабы буларак мәгълүм. Тугандаш төрки халыклар иҗатында уртак сюжетка корылган күләмле әсәрләр бар. Аларны "эпос" дип тә, "дастан" яисә "хикәят" дип тә атыйлар. Киң таралу тапкан, "Алпамыш", "Кобланды батыр", "Гайсә улы Амәт", "Күр углы", "Кыйссаи Йосыф", "Түләк һәм Сусылу", "Кузы Күрпәч белән Баян Сылу", "Бүз егет", "Шәһсәнәм һәм Гариб", "Сайфелмөлек", "Идегәй" кебек эпик ядкярләрне бер генә халыкка нисбәтләп булмый, алар бер үк вакытта татар, башкорт, казакъ, нугай, үзбәк, әзербайҗан, төрекмән һәм башка төрки халыкларның әдәби-мәдәни мирасын тәшкил итәләр.

**Гөлнар БАЗАРОВА,**
Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты

# "ШИГЫРЬ ЯЗЫП КЫНА ЯШӘП БУЛМЫЙ"

Розалина Шаһиева җыентыгындагы* шигырьләр татар поэзиясенең бөеклеген, сафлыгын—Тукайлар, Такташлар, Туфаннар күтәргән дәрәҗәне саклаучыларны битараф калдырмас дип ышанам. Билгеле, яңалык һәр очракта әдәбиятның үсүенә уңай этәреш ясый торган кискен бәхәсләр уята. Бу китап чыгу уңаеннан да кылычка кылыч бәрелгән риясыз турнир тавышларын ишетеп куанырмын дип өметләнәм.




Төрки әдәбиятта Р. Шаһиева шикелле язу-алымнар яңалык түгел. Парижда, француз мәдәнияте мохитендә тәрбияләнгән Назыйм Хикмәт керткән яңалыкларга аваздашлыкны җыентыкны укый башлау белән сизеп аласың. Тагын шуны да искә алу зыян итмәс: Шәрыкънең һәм чал Ислам культурасының утилитар Европа прагматизмы белән глобаль бәрелешен чагылдырган әлеге җыентыкның эчтәлеге Ислам культурасы ягындагы татарлар өчен чиктән тыш зур әһәмияткә ия.

Бу әле Розалинаның икенче генә китабы. Җыентыкка кергән шигырьләрне күңел күзеннән үткәреп, анализлап чыкканнан соң аңлыйсың: бәлки шагыйрәнең шигырь язам дип махсус утырулары да әз булгандыр. Һәр җөмләне, һәр сүз бөртеген, һәр уй-фикерләрне яңа көн, яңа вакыйгалар алып килгән. Укучыны битараф калдырмастай шигъри аваз бәгырьгә бәрелгәннән соң гына кәгазь битенә килеп яткан.

Ә инде җыентыкны колачлаган эчтәлекнең кинлекләре мондый:

*Плащ кигән гөлле урамнарың, Париж.*
*Хушбуй исе... Көяз карчыклар...*
*Монмартрда мең кат тиражланган*
*Дега-Ренуарлар,*
*Балконнарда—мәшһүр*
*"чыпчыклар"...*

---

*...Булон урманына*
*ап-ак оек кигән атлар чума...*
*Онытылып, көнчыгышка*
*һаман каерылам...*
*Анда—Бальзак...*
*Экипажда—дама!*
*Эшләпәсе кара каурыйдан.*

Интеллектуальләр Мәккәсе—Париж белән кызыксынып, гасыр башында Сорбоннада белем алган татар зыялыларының эзләрен эзләп, Европаның татар мәдәниятенә керткән өлешен чамаларга тырышып йөргән чакта, кинәт:

*Черек күл,—"шигъри Академия!"*
*Ах, тарих, синең икейөзлелегең!*
*Упкының, тамугъ, җәннәтең,*
*тош күрүләрең!..*

Сәяхәтләр, фикер-карашлар да һәрдаим Казан аша үтеп, сугарылып торалар. Шуңа өстәп, Казан—эталон-үлчәү берәмлеге дә, милли космосның эчке мохитен, тышкы чикләрен тоташтырган бер символ да. Шул ук вакытта Сөембикә каласының теләсә нинди урында, бөтенләй көтелмәгән ситуацияләрдә пәйда булуы мөмкин.

* Розалина Шаһиева. Ниса. – Казан: Мастер Лайн, 2003. – 288 б.

Бу—Розалинаның иҗатында табигый хәл.

Әле яңа гына Парижда идек. Менә хәзер без бөтенләй башка мәдәният үлчәме, цивилизациянең яшерен кодын кулланып кына аңлап була торган дөньяда:

*Бозра-бозра*
*ашты сүзләр,*
*күккә-йолдызларга табан...*
*Тау астында*
*фил сөяге—*
*курчак-курчак манаралар:*
*кара күзле, энҗе тешле Амман...*

Иорданияне Гыйрак алмаштыра. "Мең дә бер кичә"нең сихри төнендә Багдад күгенең эре йолдызларына карап, әкияти хисләр дөньясында ләззәт алган бабайларыбызның бүген чәчләре үрә торыр иде. Шагыйрәнең күрәзәчелеге аның һәр шигырендә диярлек сизелә:

*Төнге Багдад урамында*
*Зөләйханы күрдем...*
*Кара күмер кебек көеп беткән*
*нурлы йөзе,*
*Бармаклары—тал камышы. Яңагында—*
*яшен тамгасыдай афәт эзе...*
*Кабалана карчык, бәргәләнә—җирдә*
*ауный—*
*тәлгәш-тәлгәш балалары.*

Бу шигырьне язганда әле бит Американың авианосецлары төяп килгән корыч козгыннары Гыйракның моңлы ярлары янында һөҗүмгә приказ көтеп тормыйлар иде. Берләшкән Милләтләр мандаты белән бу илнең астын-өскә китереп тентеп йөрүче инспекторлар да юк иде әле шигырь туган чакта. Көнбатыш илләренең Гыйракка каршы кулланган кара җинаятенең нәтиҗәсен генә сурәтли шагыйрә:

*Нигә ач бу фәрештәләр,*
*кем талаган аналарын?*
*Кем таптаган, җәберләгән Аллаларын?*

Шагыйрәнең тоемлап күрүе көнкүреш аңыннан бөтенләй үзгә. Шагыйрәдә борынгы Рим весталкалары, сивиллалар күрүе бар. Җыентык авторы Истамбулдагы соңгы елларда һаман көчәя барган Көнбатыш тәрәккыятенә таба авыша баруны гаҗәп төгәл эләктереп алган:

*Тубыгымнан—дөньям, һәлакәтем*
*вак уйларым, соры мәшәкатем,*
*ыгы-зыгы шәһәр, сәүдә бәрәкәте,*
*калҗа-калҗа кибет, кара ирләр*
*арасында һаман синең сының,*
*кулым сузам, югала тылсымың.*

Илленче елларда күргән төрек дөньясын бүгенге көндәге төрекләр иле белән чагыштырып карыйм. Европа илләре белән чагыштырганда шактый артта калган, бик тә ярлы, цивилизация чытырманында нигәдер каушап, югалып калган ил иде Төркия. Шул ук вакытта күзәтә, анализ ясый һәм аңлый белгән кешегә илленче еллар Төркиясе аша, татар тарихының егерменче гасыр башындагы бик күп реалийларын күрергә, милләтебезнең һәм бүгенге кичерешләрен тирәнрәк, ачыграк аңларга була иде. Мин икенче бөтендөнья сугышыннан соң бәхет эзләп читтә йөргән төрекләрне күп күрдем, җентекләп күзәттем. Аларда михнәт эчеп читләрдә йөргән татарлар белән охшашлык шактый иде. Һәм шул Европа илләрендә, нефть байлыгына яшь торган гарәпләр җирендә эшләп тәҗрибә туплаган төрекләрнең Рәсәйнең башкаласындагы төзелешләрдә эшләп йөргән балалары белән чагыштырып карадым. Мәскәүдә эшләп йөрүче төрек осталары—тәрәккыйят учагы аша үткән прагматик европалылар инде. Әле яңа гына социализм торгынлыгыннан чыгып азапланган урыслар белән чагыштыру төрекләр өчен тагын да отышлырак. Бу лирик тайпылуым Розалинаның төрек мохитен читтән тыш җете һәм гаҗәеп оста, үзенчәлекле метафоралар белән бирә алуын күрсәтү өчен иде. Бар идеме әле әдәбиятыбызда "калҗа-калҗа кибет" дип, бер селтәнүдә Стамбулның тәнен генә түгел, җанын да сурәтли алу очраклары?!

Рәсем сәнгате, әдәбият, театр һәм башка барлык культураны күтәрүче көчләрне тудыручы һәм аның үсүенә-камилләшүенә этәреш ясап торучы учак саналган Парижны безнең шикелле иң артта калган, күбрәк сугыш өчен генә яшәүче төбәкләрдәге культура белән чагыштырып күрсәтүен көткән идем китап авторыннан. Ул башка ысул, парадоксаль алым тапкан. Без моны Розалинаның Самосырово чүплегенә багышланган шигырендә ачык күрәбез:

*Өстә—"иләмәннәр", түрә—ханнар,*
*аста—килмешәкләр, хайванәт.*
*Талашалар дәррәү урын өчен,*
*тотылган чүп, соңгы мал өчен,*
*Хихылдыйлар,*
*чүлмәк төпләреннән*
*фәхешләнгән ачы бал эчеп...*

*Яна чүплек. Шигырь. Йөрәк яна.*
*Йортлар, этләр шыңшый үзара,*
*XX гасыр азагында*
*ахры*
*Галәм шулай яңара...*

Җәдитчеләр чорында тәрәккыятьтән күпне көткәннәр. Ул чакта әле культура яуланышларыннан туган тәрәккыятне (цивилизация бу сүзгә тәңгәл түгел) адәм балаларын культурага ирештерер, яшәү шартларын җиңеләйтер, бәхетле тормыш алып килер дип инанганнар. Бүгенге көндә фән һәм культура яуланышлары тәрәккыятькә юл ачып җибәрү белән, тәрәккыять тудырган машиналар, көнкүреш җайланышлары яшәүне җиңеләйтү урынына бик күп катлаулыклар алып килә. Бер яктан, экология шартлары көннән-көн начарая барса, икенче яктан, стресс тудырган куркынычлар үсә тора. Розалина Шаһиева иҗатында бу чиктән тыш җитди проблемага тирән анализ ясалган.

Розалинаның шигырьләрендә—вулкан шикелле кайнап торган темперамент. Һәр әйтелгән сүз кайнар хискә, тылсымга сугарылган һәм укучының йөрәгенә ургылып килеп керә. Җыентыкка кергән шигырьләрне аларның үзенчәлеге, ихласлыгы берләштерсә, аларның яңгырау диапазоны сокландыргыч киң алымлы ысулларны берләштергән.

*Кол ит мине, сөю,*
*Кол ит,*
*Көн ит, төн ит,*
*Җил ит, гөл ит,*
*Күкләргә илт,*
*Тамугка керт,*
*Тилерт, тилмерт,*
*Сөйдерт, көйдерт...*

Бу шигырь мәҗүсилек чорындагы көйләүләрне хәтерләтә. Ритм-интонация, антропоморф ихласлык, мөрәҗәгатьнең чиктән тыш динамика һәм адәм баласының тәкъдирен хәл итә торган илаһи көчләргә мөрәҗәгать итүнең табигыйлеге—барысы да фольклордан.

Ә менә бу шигырь Европаның классик ысулында язылган:

*Бауманда... Кызыл чиркәү ышыгында—*
*трень-трень уйный гүзәл*
*рок-оркестр...*
*Музыканың иң беренче борымына,*
*мәйданчыкка—*
*килеп куна зырылдык бер*
*чор корбаны—"бомж хатын".*
*Элеккеге танцплощадкалар "күбәлә"ге—*
*Тормыш аны әйләндергән "үрмәкүчкә".*
*...Сәрхүш гәүдәләре белән түнә-түнә*
*әйләнә ул—*
*әйтерсең лә Штраус монда, йә*
*"Щелкунчик"?*
*Әнә чиркәү!...*
*Сувенирлар кайный-ташый...*
*Җир бөгелә.*
*Әнә картлач урам себеркесе—"Кармен",*
*елый-елый, көлә-бии,*
*бөтерелә!*

Әйтерсең, шигырь Шарль Бодлер кулы белән язылган. Шул ук вакытта, бары тик Розалина шигырьләрендә генә очрый торган шигъри лексика һәм аңынча күрү, тою үзенчәлеге. Бодлерның иҗаты Франциядә "кыргый капитализм" хөкем иткән чорга килә, нәкъ бүгенге көндә Рәсәйдәгечә байлыкның киң катлам халык массаларының хәерчеләнү бәрәбәренә барлыкка килгән чагы. Үзара охшашлыкны бәлки шул тудыргандыр?

Җыентыкка татар әдәбиятында вакыйга булып калырлык дүрт зур әсәр кергән (поэма дип атасам күпмедер дәрәҗәдә примитивлаштыру булыр иде): "Ефәк юлы", "Әбелхәят яки мәңгелек чарасы" ("Чыңгызхан"), "Әбелһәүл" (Кеше йөзле арслан—Сфинкс) һәм "Таш язуы. Ниса".

*Тырнак асларында—түгәрәк Җир...*
*Мыгырдана шәһәр, дәүләтләр,*
*Комлыкларда кайный күбәләкләр*
*кых! кых! Көлә аста маләкләр!*

*Меңьеллыклар сары кәгазь булып*
*алдан-арттан уза куышып...*
*Орынып китә—яугир, башкисәрләр,*
*Пәйгамбәрләр үтә шуышып...*

Соңгы куплетына кадәр Мисырдагы пирамидалар янында сакта торучы Сфинкс турында сүз бара дип ышанып укыйсың.

*Җилләр үбә! Гөрли гомер, вакыт...*
*Мәңге сакчылыкта торасым!*
*Әбелһәүл мин...*
*Адәм йөзле арыслан...*
*Тешләп саклыйм милләт мирасын!*

Шушы юллар һәр милләтнең язмышын саклаучы Сфинкс—Әбелһәүл булуын исбатлый. Димәк, татар язмышын саклаучы Әбелһәүл дә булырга тиеш. Кайда соң ул? Бәлки Сөембикә манарасы шул бөек миссияне башкара торгандыр? Яисә, әле суверенитет көрәше сүнә башлагач, азатлыкка омтылуның мәңге туктамас омтылыш икәнлеген исбатлар өчен калкып чыккан Колшәриф мәчетенең манаралары "Тешләп саклый торгандыр милләт мирасын?".

*Кылычлардан башлар үтте, Ниса,*
*Баш урынына канат үсте, Ниса,*
*Бөтен гомер бер талпыну булды*
*Моңнар бөкте канатларны, Ниса,*
*Синең кебек—мәңге канат, Ниса!*
*Күп кагындык, юлны белми, Ниса,*
*Бөтен акыл ашкынуга китте,*
*Шигырь булып узды гомер, Ниса.*

*Шәһәр умырткасы "шарт-шырт!" килә—*
*әбүҗәһил кабыгыннан чыгып, Ниса...*
*Шамакайлар, зәһәр җаннар, Ниса*
*Без яшәгән бәйрәм илен, Ниса,*
*Бағыреннән—тамырыннан кисеп*
*Кубаралар—аударалар, Ниса!*

Коръәндә хатын-кызларга багышланган "Ниса" сүрәсе бар. Бер караганда, поэма шуңа багышланган шикелле тоела. Бер үк вакытта шагыйрә: "Гүзәл Юнан сыны Ника сыман, мин үзем дә гариб моңдыр исә..."—дип шул мәшһүр җиңү алиһәсен безнең милли чынбарлыкка тоташтыра—"Гыйльмениса, Хөббенисаларның тамырын алып, исем куйдым "Ниса", дип, укучыга аңлата. Чыннан да, бу кыска гына поэмада Коръәндәге "Ниса" сүрәсенең эчтәлегенә тәгаенләштерелгән татар язмышы сурәтләнә:

*Нечкә җанлы мескен халкым, Ниса—*
*Яфрак кебек очып йөри икән,*
*Бу дөньяның мәхшәрендә, Ниса...*

Һәм бүгенге көндә милләт өчен иң мөһим, иң хәлиткеч үзәк мәсьәләне көн тәртибенә куеп, лирик геройдан җавап сорый:

*Әгәр иман сүнеп, бары матдә генә*
*хөкемдарлык итсә җир йөзендә, Ниса,*
*Киләчәкнең салкын бушлыгында*
*Ни дип очып йөрер, халкым, Ниса?*

Татар милләте юлында иң тирән, үтү өчен иң куркыныч упкын барлыкка килде. Үтеп чыга алырбызмы без аны? Теләрбезме үтеп, чыгып исән калырга? Әдәбиятның төп вазифасы—халык язмышының хәлиткеч борылышларында нәрсә буласын белер өчен сорауны дөрес бирә белүдә: "әгәр иман сүнеп, бары матдә генә хөкемдарлык итсә... ни дип очып йөрер халкым, Ниса?" Кызганыч, яшәешебезнең бик күп тармакларында инде күптән бары тик матдә генә хөкемдарлык итә. Бу хәл елдан-ел көчәя, кинәя бара. Укучылар саны бары тик чын шагыйрьләр елдан-ел азая барса да, шигырь язучылар саны кимеми, кебекләр генә азая.

Розалина Шаһиева шигырьләрен анализламыйча гына, тукталып кат-кат укырга, уйланырга, бүгенге чынбарлыкның яшерен тирәнлекләрен күрергә, катлаулы проблемаларын ачыкларга ярдәм иткән аерым метафораларга, сурәтләргә генә тукталасым килә. Мине бу иҗатның чиктән тыш үзенчәлекле булуы шатландыра. Татар шигъриятендә шигырьне рәсем ясаган шикелле сурәтләп язучылар бар, сүзнең музыкаль яңгырашына басым ясап, сүз тылсымы белән укучының күңелен яулаучылар очрый. Розалина Шаһиева бу ике ысулны бергә куллана. Шуңа күрәме, аның шигырьләре трибунадан укырга да, аулаграк җирне сайлап, эчтәлектәге философиянең үзенчәлеге белән ләззәтләнергә дә мөмкинлек бирә.

Җыентыкта оригинальлеге, яңалыгы һәм тирәнлеге белән тетрәндерә торган метафораларга адым саен юлыгып торасың: "Ялгыз калдым, мәйдандагы Ленин бабайдай..." Чыннан да, бу һәйкәлдән дә киеренке, килбәтсез ялгызлык бармы икән бу дөньяда? Узган җәйдәге бер эпизод искә төшә: Сретенкадагы Крупскаяга куелган һәйкәл янына барып утырдым да, янымнан узган кешеләрдән: "Кем һәйкәле бу?"—дип сорыйм. Ярты сәгать чамасы вакыт эчендә янымнан житмеш өч кеше узды. Шуларның бары тик дүртесе генә һәйкәлнең кемгә куелганын әйтә алды.

*Читән өсләрендә шешәләр,*
*Мич алдында кисәү-шөпшәләр...*

Бәләкәй генә, беренче караганда берниндн әһәмияткә ия булмаган шикелле ике деталь—һәм татар авылы шундый ачык, газиз булып күз алдына килә дә баса. Әтисе турында Розалина менә ничек әйтә алган:

*Һәйкәлләрдә түгел, йөрәкләрдә*
*Сырланып калган бөеклегең...*

Хисенең сафлыгын, тирәнлеген һәм миллилеген исбатлаганда ул:

*Күңелемне "әллүкиләр"*
*Белән тоташтырды...*—дип яза.

Яшәешне сурәтләгәндә менә нинди чагыштыру белән чикләнә җыентык авторы:

*Илаһи талпынуның*
*Бер тамчысы—гомер...*

Икенче бер урында шул ук фикерне хислерәк, кайнаррак итеп әйтә ул:

*Хуш, зиннәтле җирем,*
*Яшәү—бары йотым.*
*Сүнә утым.*
*Безне сагынмагыз!*

Ил турында сүз чыкканда татар язучыларының күпчелегенә хас булган хатаны: Рәсәйне—Татарстаннан, Татарстанны Рәсәйдән аерып алмаслык итеп язуны автор беркайчан да ычкындырмый. Исемен атап әйтмәгән очракта да, татар илен берничек тә козгын белән бутап булмый:

*Ук тимәсен,*
*Ут тимәсен илгә,*
*Гакылым тулы,*
*Телем төз калсын!..*

Ватаныбызның башкаласы Казан һәм шул калада калган яшьлеге турында сокландыргыч романтик хисләр ярдәмендә менә нинди моң сурәтен һәм аның музыкаль яңгырашын тудыра ул:

*Күңел шул җәйләрдә*
*Шакый җилләр булып.*
*Сөю исе сеңгән*
*Төнге капкаларга...*

Шигъри табигатьле кешегә Казанның студентлар каласы икәнлеген дә, фестивальләр, конгресслар үткәрү урыны икәнлеген дә, җир йөзенә чәчелеп беткән татар диаспорасының Мәккәсе икәнлеген дә аңлатып торасы юк. "Сөю исе сеңгән" шәһәрнең моннан биш гасыр элек халкын кырып, йортларын, гыйбадәтханәләрен җир белән тигезләп киткәннәр. Монда Шәрык белән Көнбатыш, Төньяк белән Көньяк кына очраша торган урын түгел! Тарихның иң каһәрле вакыйгалары эз калдырган җирдә сөю белән сөелүне очраштырыр өчен дә яратылган булган икән бу изге урын.

Чын әдәбиятның җавап түгеллеге, ә яшәештәге иң катлаулы, иң аңлашылмас һәм каһәрле мизгелләр тудырган сорау икәнлеге турында без инде искә алган идек. Шундый сорауларның берсе:

*Бу ямьсез, үксез,*
*тарихсыз дөньяның*
*хуҗасы кем?*

Җыентыкны дикъкать белән укыган очракта боз булып йөрәккә килеп бәреләторган шушы сорауның каян тууын да табарга була:

*Һәркөн Казансу өстендә,*
*Шыксыз мәеттәй,*
*Узган михнәт чайкала...*

Без бу турыда көчебез җиткән кадәр сирәгрәк искә алырга, яисә бөтенләйгә оныткан булып кыланырга тырышабыз: чөнки бу калада каннары коелганнар белән кан коючылар бергәләп, канга чыланган ташларга басып йөриләр, бер үк һаваны сулыйлар, канга сугарылган туфракта үскән икмәкне үзара бүлешеп ашыйлар... Ә адәм баласы тыныч яшәр өчен, бәхетле булыр өчен туа. Шуңа күрә, коелган кан турында уйламаска тырышып яши. Әмма барыбер, шагыйрә әйткәнчә, телибезме-юкмы: "Һәркөн сулар, урамнар, йортлар өстендә, күңелебезнең яшерен бер почмагында узган михнәт чайкала..." Розалина Шаһиева михнәтне чайкалудан туктальш булмауны менә ничек аңлата:

*Юлыксам шуларга,*
*абынам үткәнгә,*
*чумам кайтмаслыкның*
*коесына...*

"Кайтмаслыкка чуму"—безнең соңгы таянычыбыз Казан ханлыгын, дәүләтчелегебезне югалтуыбыз, соңгы еллардагы мөстәкыйльлек көрәшендә кабат җиңелүебез турында сүз бара. Шушы кайтмаслыкны җыентык авторы шигырьләренең күбесендә төрле вариантларда күрсәтә:

*Пәйгамбәрләр ташлаганга,*
*нурсыз кышларда*
*сулкылдый, елый*
*нәүмиз Казан-кала...*

Жыентыкның авторы өчен Казан республика дип аталган (барлык Европа телләрендә "республика"—мөстәкыйль, ирекле дәүләтне аңлата) территориянең башкаласы гына да, дөньяга чәчелгән татарларның мәдәният, рухият үзәге генә дә, милләт өметен үзенә тартып торган татар Кәгъбәсе генә дә түгел. Розалина үз китабында башкалабызны, моннан биш йөз илле ел элек канга батуын, тапталуын, таланып имгәнүен әле һаман тоеп яшәүче тере, җанлы организм итеп сурәтли алган. Җыентыкка кергән шигырьләрнең һәммәсендә диярлек лирик герой Казан символы, аның аһәңе белән тулысынча аваздаш:

*Кибә тамак...*
*Туфрагына егыл,*
*Ватаныңның,*
*Газиз илеңнең.*
*Ирекле рух—үзе гавам, дәвам,*
*Мин табынмыйм потка.*
*Чи-ген-мим!*

Милли теманы колачлаган шигъри юлларның мәгънәсен төгәл аңлар өчен җыентыктагы "Татар җаным" дигән шигырьне дикъкать белән укырга, анализларга кирәк. Бу шигырь җыентыкның коды, шифры хезмәтен үти шикелле. Шигырьнең эчтәлеге дә сүзләр арасында тавыш биреп яткан мәгънәне үзләштергәннән соң гына укучыга серен ача башлый шикелле тоела:

Заман күрке—машинадан хикмәтлерәк
Фән-уй тулы бу заманда—
Каһәр сөю,
Чиксез гайрәт, акыл тулы—
Үлемсез бу моң чишмәсе—
Минем газиз татар рухым,
Татар җаным...

Шигырь буыннарның тоташ икәнлеген: бездән элек яшәгәннәрнең гөнаһлары өчен дә без җавап бирергә тиешлекне һәм безнең гөнаһларның да киләчәк буыннарга кагылачагын искәртә. Шунлыктан без туган җирнең игелекләрен генә түгел, аның җәзаларын да кабул итәргә, ярлыкауга ирешкәнче тәүбә гамәлләрен кылып яшәргә тиешбез:

*Туган җирем. Сиңа шуңа күңел пәрвәр—*
*рәхмәт газап—*
*баскан кайнар күмер өчен.*
*Үсәр уллар, тугаеңда туйлар гөрләр,*
*күбәләкләр, атлар уйнар,*
*үлеп терел, үлеп терел—безнең өчен.*

Бу җыентык татар җанлы укучының берсен генә дә битараф калдырмас дип ышанасы килә...

**Миргазиян ЮНЫС**

## 86—ТАРИКЪ (ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ) СҮРӘСЕ

*(Тарикъ сүрәсе 17 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Тарикъ—соңга калып, кич белән ишек кагучы мәгънәсендәге сүз. Ләкин сүрәдәге бу сүз якты йолдыз, кичен Күктә балкый торган Чулпан йолдызы кебек чагыштырмада кулланылган.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Күк иseме белән һәм Тарикъ белән ант итәмен ки. **(2)** Тарикъның ни икәнен син каян белер идең? **(3)** Тарикъ ул—Күкне балкытып торучы йолдыз. **(4)** Өстеннән күзәтүчесе булмаган бер генә нәрсә дә юктыр. **(5)** Хәзер инде кеше үзенең ничек яралтылганы турында уйлансын һәм гыйбрәт алсын. **(6)** Ул атылган су тамчысы кебек сыеклыктан, **(7)** *(ир кешенең)* арка кимегеннән һәм *(хатынның)* күкрәк кимегеннән чыккан сыеклыктан хасил зат. *(Бу аятьне төгәл тәрҗемә итүе шактый кыен, бәс, төрле нөсхәләрен укучының үз ихтыярына тәкъдим итәбез.* **(8)** Шик юк, аны *(яңадан терелтергә)* Аллаһның кодрәтеннән килә. **(9)** Ул Көндә яшерен серләр мәйданга чыгачак. **(10)** *(Гөнаһлы кешенең)* анда көче дә, ярдәмчесе дә булмас.

**11.** Хактыр ки, кире кайта-кайта яуган яңгырның хуҗасы—Аллаһ исеме илә, Күк исеме илә, **(12)** *(үсемлекләр үссен өчен)* ярылган *(сөрелгән)* Җир исеме белән әйтәм, **(13)** хакыйкатән, ул *(Коръән яхшыны яманнан аерыр өчен)* катгый әмер сүзләредер. **(14)** Коръән—ул шаяру сүзе түгел. **(15)** Хактыр ки, кяферләр *(Коръәнгә каршы)* мәкерле тозаклар кора. **(16)** Мин дә аларның хәйләләрен хәйләм *(җәзам)* белән каршылармын. **(17)** *(Ий, Мөхәммәд)* син хәзер инде ул кяферләргә форсат бир, вакытны беразга кичектер.

## 87—ӘГЪЛӘ (БӨЕК) СҮРӘСЕ

*(Әгъләә сүрәсе 19 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Әгъләә—бөек, дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Раббының бөек исемен мактап, тәсбих әйт. **(2)** Аллаһ бөтен нәрсәне юктан бар итеп, тәртипләде. **(3)** Тәкъдир итеп, юл күрсәткән дә—Аллаһ. **(4)** Яшел үләннәрне үстергән дә—Ул. **(5)** Ахырда кап-кара, коп-коры халгә китергән дә—Аллаһ.

**6.** *(Ий, Мөхәммәд)* аз-азлап сиңа Коръән укытырбыз. Син аны онытмассың. **(7)** Онытырсыз бары тик Аллаһ оныттырганны гына. Аллаһ яшеренне дә, ачыкны да белеп тора. **(8)** Синең эшләреңне кулай-уңышлы итәчәкбез. **(9)** Шулай булгач, син үгет алып, файда китергәннәрне үгетлә. **(10)** *(Гөнаһ эшләүдән, җавап бирүдән)* курыкканнар үгетләнер. **(11)** Бәдбәхет булганнар гына үгеттән качар. **(12)** Андыйлар хәтәр утка атылачак. **(13)** Алар анда үлмәячәк һәм терелмәячәк тә. **(14, 15)** Хактыр ки, яхшылап пакьләнгән һәм Раббыны зикер иткән, намаз укыган кеше морадына ирешер.

**16.** Әй, кяферләр, сез дөнья тормышын өстен куясыз. **(17)** Гәрчә, Ахирәт тормышы тагын да хәерлерәк һәм ул—мәңгелек. **(18)** Хактыр ки, бу турыда әүвалге китапларда да, **(19)** Ибраһим белән Мусага иңдерелгән китапларда да язылган иде.

## 88—ГАШИЯ (БӨЕК ВАКЫЙГА) СҮРӘСЕ

*(Гашия сүрәсе 26 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Гашия—каплаучы, томалап алучы дәһшәт, ягъни Кыямәт-Мәхшәр мәгънәләрен үз эченә алган сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** *(Ий, Мөхәммәд дәһшәте белән бар нәрсәне томалап алучы)* Кыямәт турында сиңа хәбәр килдеме? **(2)** Ул көнне чырайлар хурлыклы рәвештә түбән иелгән булыр. **(3)** Ул көнне йончытучы эшләр эшләнер. **(4)** *(Гөнаһкярлар)* шаулап янган утка керәчәкләр. **(5)** Эчәргә бәреп чыккан кап-кайнар су биреләчәк. **(6)** Дари дигән чәнечкеле үсемлектән башка аларга һичбер ризык булмас. **(7)** Ул тамак та туйдырмас, ачтан да үтермәс.

**8.** Шундый матур, канәгать йөзләр дә булыр ул көнне. **(9)** *(Дөньяда игелек кылганнарына күрә)* алар бәхетле. **(10)** Андыйлар югары җәннәттә булыр. **(11)** Анда һичбер буш сүз сөйләнмәс. **(12)** Анда–агып торучы төкәнмәс чишмәләр агып торыр. **(13)** Анда–затлы канәфиләр. **(14)** Алларына кувшиннар куелыр. **(15)** Кабартылган ястыклар тезелеп торыр. **(16)** Анда гүзәл келәмнәр җәелгән булыр.

**17.** *(Гыйбрәт алыр өчен)* алар *(кяферләр)* дөянең, һәм яңгыр болытларының да ничек яралтылганлыгы турында уйлап бакмасలармы? **(18)** Күкнең ничек биек *(чиксез)* итеп яралтылганына карап уйланмаслармы? **(19)** Ул тауларның ничек итеп беркетелгәне турында уйлап, *(Аллаһның чиксез кодрәтенә инанмаслармы)*? **(20)** Җирнең ничек түшәлеп кабартылганына карап сабак алмаслармы?

**21.** *(Мөхәммәд)* син бу турыда өзлексез рәвештә аларның исенә төшереп тор. Шулай итеп, кисәтеп тору–синең төп вазифаң. **(22)** Син алар өстеннән хакимлек итүче түгелсең. **(23)** Ләкин иманнан баш тарткан кешене, *(Аллаһны, Коръәнне)* инкарь итүчене **(24)** Аллаһ хәтәр газапка салачак. **(25)** Шик юктыр ки, аларның кайтышы фәкать Безгәдер. **(26)** Алар хисап алачак.

# 89—ФӘҖЕР (ТАҢ) СҮРӘСЕ

*(Фәҗер сүрәсе 30 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Фәҗер–таң, дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Атып килә торган таң исеме белән **(2)** Ун кичәнең *(Зөлхиҗҗә аеның)* ун көне белән **(3)** җөп саннар, так саннар белән, **(4)** алмашынып торучы көн вә төн исеме белән ант итеп әйтәмен ки: Кыямәт киләчәк). **(5)** Башында акылы булган кешеләр өчен ант итәрлек дәлилләр түгелмени болар?

**6.** Беләсең бит, Раббың Гад кавемен ничек һәлак итте? **(7)** Мәһабәт субай баганалы биек сарайлары һәм Ирәм бакчалары белән *(юк итте)*. **(8)** Ул сарайларның, ул бакчаларның дөньяда тиңе юк иде. **(9)** Кыяларны чокып, шәһәр салган Сәмуд халкының үзәндәге язмышын исеңә төшер.

**10.** Яки *(җәза)* казыкларының хуҗасы, күп гаскәрле Фиргавен турында да онытма: **(11)** аларның барысы да үз илләрендә азгын-бозык тормышта яшәде. **(12)** Һәм шулай итеп, алар дөньяда яманлыкны үрчеттеләр. **(13)** Шуның аркасында, Раббың алар өстендә газап камчысын уйнатты. **(14)** Хактыр ки, Раббың һәрвакыт аларны күзәтеп торыр.

*(«Фиргавен мөэминнәрне казыкка бәйләп җәзалый, кешеләрнең коточкыч интегеп үлгәннәрен карап, ләззәтләнә торган була». Али Өзәк тәфсиреннән.)*

**15.** Ләкин кеше дигән адәми зат, Аллаһ аны сынарга теләп, үзенә байлык бирсә, масаеп әйтер:

–Аллаһ мине генә шәрәфле дусты итеп, байлык бирде,–дип сөйләр. **(16)** Ләкин вакыты җитеп, аны *(сынар өчен)* бирелгән ризыкны кыса төшсә:

–Раббым мине кимсетте,–дип әйтәчәк.

**17.** Хәер, сез *(имансызлар)* ятимнәргә игелек кылмыйсыз. **(18)** Мохтаҗ кешенең тамагын туйдырыр өчен бер-берегезне үгетләмисез. **(19)**–Бу–хәләл, бу–харам,–дип тормастан, мирас малын (тол хатыннарның өлешен, ятимнәргә калган мирасны) ашыйсыз. **(20)** Байлыкны хәттин тыш (кирәгеннән артык) сөясез.

**21.** Юк шул! Җир тетрәп, парча-парча телгәләнеп *(таулар, кыялар тип-тигез җиргә әверелеп)*, тузан халенә килгәч, **(22)** Раббының әмере илә *(Җиргә төшеп)* фәрештәләр сафсаф тезелешкәч, **(23)** алларына җәһәннәм чыгарылгач, адәм баласы ул көнне *(бөтен кылмышларын)* исенә төшерәчәк. Ләкин хаталарын *(соңарып)* аңламаудан ни файда?

**24.**–Аһ, фани дөньяда игелекләр кылган булсам, Ахирәттә бәхеткә ирешәчәк идем бит,–дип уфтаначак.

**25.** Ул көнне *(Аллаһ җәзалаган кебек)* башка берәү дә җәзалый алмаячак. **(26)** Аллаһ богаулаган кебек беркем дә богаулый алмас.

**27.** Әй, максатына ирешкән җан! **(28)** Раббың хозурына кил. Аллаһ синнән разый. Син дә Аллаһтан разый булырсың. **(29)** Башка бәндәләрем белән бергә, **(30)** әй, пакь мөселман. Әйдә, кер җәннәткә!

## 90—БӘЛӘД (ШӘҺӘР, ИЛ) СҮРӘСЕ

*(Бәләд сүрәсе 20 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Бәләд–шәһәр.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Шушы изге шәһәр *(Мәккә)* исеме белән әйтәмен ки, **(2)** бу шәһәр*(не кяферләрдән яулап алу)* сиңа хәләлдер, (чөнки син шушы шәһәрдә туып-үстең). **(3)** Бабаң һәм аның токымы изгеләрдән булсын, **(4)** Без кешене, хактыр ки, мәшәкатьләр *(кыенлыклар)* өчен яралттык. **(5)** *(Кяфер)* адәм баласы: миннән башка куәт иясе дөньяда юк, дип хаталанамы? **(6)** Ул:

–*(Исламны бетерер өчен, Пәйгамбәрне үтерер өчен)* күпме мал сарыф иттем,–дип мактана. **(7)**–Кылганнарымны *(җинаятьләремне, фәхешлегемне)* берәү дә күрми,–дип уйлыймы?

**8.** *(Хакыйкатьне)* күрер өчен Без аңа ике күз бирмәдекме? **(9)** *(Дәреслекне сөйләр өчен)* без аңа бер тел белән ике ирен бирмәдекме? **(10)** Без аңа ике юл күрсәтмәдекме *(берсе–дин юлы–авыр юл, икенчесе–динсезлек юлы–ансат юл)*? **(11)** Ләкин ул авыр юлдан–текә юлдан китмәде. **(12)** Текә юлларының ни икәнен син беләсеңме? **(13)** Колыңны азат итү ул–текә кыя юллары. (14) Яки ачлык килгән вакытларда мохтаҗларга тәгам ашатудыр ул–текә кыя юллары. **(15)** Ятим кардәшеңә ярдәм итү. **(16)** Яки *(заяга)* туфракта казынучы хәерченең тамагын туйдыру ул–текә кыя юллары аша узу. **(17)** Менә шуннан соң сез иманлы булып, сабыр-түзем булып, миһербан өләшүче булып, бер-берегезне игелек кылырга өндәүчеләр булып китәрсез. **(18)** Менә шундыйлар уң яктагылар булыр. **(19)** Аятьләребезне көферлеккә чыгарганнар исә, сулчылар булыр. **(20)** Аларга ишекләре (чыгып кача алмаслык итеп) каты бикләнгән җәһәннәм уты булыр.

## 91—ШӘМЕС (КОЯШ) СҮРӘСЕ

*(Шәмес сүрәсе 15 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Шәмес–Кояш, дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Кояш һәм аның нурлары белән, **(2)** *(аңа ияргүче)* Ай белән, **(3)** яктылык алып килүче көн, **(4)** аны каплаучы төн, **(5)** Күкне корып куючы *(Аллаһка)* һәм Күк, **(6)** ястыктай түшәлгән Җир, **(7)** һәр адәми затка һәм аны *(Җир йөзендә яшәрлек итеп)* яралткан, **(8)** аңа һәм яхшылык, һәм яманлык кылырга ирекле иткәннең исеме белән әйтәмен ки: **(9)** җанын пакь тоткан кеше морадына *(Сәгадәткә)* ирешәчәк. **(10)** Вөҗданын кер каплаган кеше, әлбәттә, хәтәр зыян күрәчәк.

**11.** Азгынлыгы аркасында Сәмуд халкы хак сүзне *(Пәйгамбәребезне)* кабул итмәде. **(12)** Шул халыкның иң бәдбәхет бер башкисәре изге дөяне бугазларга алынды. **(13)** Гәрчә, Пәйгамбәр аларга алдан ук әйтеп куйган иде:

–Аллаһның ана дөясенә кагылмагыз. Ул су эчкәндә аңа комачауламагыз,–диелде. **(14)** Ләкин аның сүзләренә ышанмадылар. Һәм, дөянең бот сеңерләрен кисеп ектылар да, суйдылар. Шуның аркасында Раббы алар өстенә җәза җибәрде, барысын да һәлак итте. **(15)** Аларны шулай һәлак иткәне өчен, Аллаһ һичкем алдында да җавап тотмас.

## 92—ЛӘЕЛ (ТӨН) СҮРӘСЕ

*(Ләел сүрәсе 21 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Ләел–төн, дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Караңгылыгы белән тирә-якны каплаган төн, **(2)** яктылыгы белән ачылган көн, **(3)** һәм ир белән хатын җенесен яралтканның исеме белән ант итәмен ки: **(4)** шунысы хактыр ки, сезнең нәфес һәвәслекләрегез төрлегезнең төрлечә; **(5)** кемдер *(хәер-садәка, зәкят)* бирер, кемдер *(гөнаһ кылудан, харамнан)* куркыр. **(6)** кемдер гүзәллеккә сокланыр һәм аның хаклыгын раслар. **(7)** Без дә андыйларның Сәгадәткә барыр юлларын уң итәрбез.

**8.** Әмма кем *(тар күңелле, матди һәм рухи)* саранлыкта булса, Аллаһка ихтыяҗ тоймаса, **(9)** иң хәтәре–алдашса, ялганласа, гүзәллекне инкарь итсә **(10)** Без андыйларга иң хәтәр җәза иңдерербез. **(11)** Һәлак булганда, дөньяда җыйган байлыгы аңа ярдәм итмәс. **(12)** Шик юк ки, тугры юлны күрсәтү Безнең ихтыярыбызда. **(13)** Әлбәттә, Ахирәт тә, дөнья да безнең әмеребездә.

**14.** Дөрләп, ялкынланып янучы ут җәзасы булачак дип, сезне кисәттем. **(15)** Бәхетсез бәндәләр генә, **(16)** Хакыйкатьне ялганга чыгарганнар гына, йөз чөереп, *(Аллаһ белән Коръәнне)* инкарь иткәннәр генә ул җәһәннәмгә керә. **(17)** Ләкин *(гөнаһ кылудан)* сакланган *(саф мөселман)* кешесе, **(18)** малын *(Аллаһ юлында)* сарыф иткән адәм җәһәннәмнән ерак тотылыр.

**19.** Түләү-әҗер *(садака-хәер башкалар алдында)* яхшы булып күренер өчен генә бирелмәс. Мондый гамәл өчен Аллаһ хозурында һичбер дәрәҗә юктыр. **(20)** Аллаһ ризалыгы өчен кылган игелекләр генә савапка саналыр. **(21)** Һәрхәлдә, ул үзе дә алга таба *(Аллаһтан)* канәгать калачак.

## 93—ДУХА (ИРТӘНГЕ ШӘФӘКЪ) СҮРӘСЕ

*(Духа сүрәсе 11 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Духа–көннең төшкә чаклы булган иртәнге вакыты мәгънәсендәге сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Көннең иртәнге яктылыгы, **(2)** тынычлыкка ирештерүче төн караңгылыгы белән ант итәмен ки: **(3)** *(Ий, мөхәммәд)* Раббың сине ташламады һәм сиңа ачуланмады да.

**4.** Әлбәттә, Ахирәт синең өчен дөньядан хәерлерәк. **(5)** Хактыр ки, озакламый Раббың сиңа әҗер бирәчәк. Һәм син бик тә канәгать калырсың. **(6)** Аллаһ ятим калганыңны күреп, сиңа сыеныр урын бирмәдеме? **(7)** Яшьлегендә кая барырга белмичә, каңгырап йөргәндә, Ул сине тугры юлга бастырмадымы? **(8)** Синең фәкыйрь икәнеңне күреп, баетмадымы? (9) Ятимнәрне очратсаң, аң бул, син чыраеңны сытма, аңа ярдәм ит. **(10)** Мохтаҗларны әрләмә, яныңнан кума, аларга булыш. **(11)** Шуңа күрә, син *(Мөхәммәд)* һичтуктаусыз Аллаһның чиксез юмартлыгы, төкәнмәс кодрәте турында *(кешеләргә)* бәян ит!

## 94—ИНШИРАХ (АЧЫЛУ) СҮРӘСЕ

*(Иншираx сүрәсе 8 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Иншираx–ачылу, киңәю, күңеле ачылып китү, сөенү мәгънәләрендә килә.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** (Ий, Мөхәммәд) сине ачык-киң күкрәкле итеп кылмадыкмыни? **(2)** Сиңа йөкләнгән авырлыкны алып атмадыкмыни? **(3)** Ул шундый йөк иде ки: ул синең җилкәңә бик тә авыр иде. **(4)** Синең даныңны, абруеңны тагын да арттырмадыкмыни? **(5)** Димәк ки, кыенлык артыннан җиңеллек тә килә. **(6)** Хактыр ки, кыенлык белән рәттән җиңеллек тә бар. **(7)** Бер эшне тәмам итүгә үк, икенчесен башларга тырыш. **(8)** Һәр гамәлеңне ихластан бары тик Аллаһыңа багышла.

## 95—ТИН (ИНҖИР) СҮРӘСЕ

*(Тин сүрәсе 8 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Тин–инҗир җимеше һәм изге тауның исеме.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Инҗир һәм Зәйтүн агачлары, **(2)** Сина тавы, **(3)** вә шушы изге, иминлек шәһәренең *(Мәккәнең)* исеме белән ант итәмен ки: **(4)** Без, чыннан да, кешене бик тә гүзәл кыяфәттә яралттык. **(5)** Аннан соң Без аны *(кылмыш яман гамәлләренә күрә)* түбәннәрдән дә түбән иттек *(җәһәннәмгә аттык)*. **(6)** Бары тик иман китереп, игелек кылганнар гына алар янында *(җәһәннәмдә)* булмас. Алар өчен *(җәннәтләрдә)* бетмәс-төкәнмәс нигъмәтләр бар. **(7)** Шушы дәлилләрдән соң да киләчәк җәза көне хакында синең сүзләреңне кем ялганга чыгара алыр икән? **(8)** Аллаһ иң гадел хөкемдарларның да гаделе түгелмени?

## 96—ГАЛӘК (ЯРАЛГЫ ТАМЧЫСЫ) СҮРӘСЕ

*(Галәк сүрәсе 19 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Галәк–кешенең барлыкка килүенең нигезендә ир кеше белән хатын-кызның орлыкларыннан катнашкан бер тамчы сыеклык ята. Бу сүз шул орлык, уылдык, шәһвәт, мәни мәгънәләрендә килә. Мөхәммәдкә иң беренче вәхий ителгән сүрә шушы булыр.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Сине юктан бар иткән Раббыңның исеме белән укый башла. **(2)** Аллаһ инсанны бер галәктән *(аталанган күкәйчектән, күзәнәктән, яралгыдан)* хасил итте. **(3)** Укы! Раббың синең чиксез юмартлык иясе. **(4)** Ул каләм белән язу язарга өйрәтүче. **(5)** Кешегә элек мәгълүм булмаганнарын да өйрәтүче Ул. **(6)** Юк бит, кеше барыбер азгынлыкта хәттин ашар. **(7)** Баеп алгач, мин Аллаһка мохтаҗ түгелмен, дип әйтер. **(8)** Әй, адәм баласы! Җавап тотарга, син Аллаһ хозурына кайтачаксың. **(9)** Намаз укыганда берәүсенең **(10)** икенчесен *(намаздан)* тыйганын күрдеңме? **(11)** Намаздагы кешене намаз укудан тыю дөрес эш булырмы? **(12)** Хәтта ул *(намазны боздыручы)* үзе кешеләрне: Аллаһтан куркыгыз, гөнаһлардан сакланыгыз, дип, өндәргә алынган булса да. **(13)** Күрдеңме, ул Хакыйкатьне ялганга чыгарды да, йөз чөерде. **(14)** Ул бәндә Аллаһның барысын да күреп торганын белмимени? **(15)** Ул мондый эшләрдән саклансын. Бу эшеннән ваз кичмәсә, хактыр ки, аны, маңгай чәченнән тотып, *(җәһәннәмгә)* өстерәп алып барырбыз. **(16)** Ялганчы, гөнаһкярның–маңгай чәченнән. **(17)** Тели икән, ул үзенең якыннарын ярдәмгә чакырсын. **(18)** Без дә зобаниларны чакырырбыз. **(19)** Сак бул! Аңа буйсынма. Сәҗдә ит. Аллаһка якынлаш.

*(«Зобанилар» сүзе урынына тәрҗемәчеләр төрле мәгънәдәге сүзләр куллана: газап фәрештәләре, сакчылар, тәртип саклаучылар...)*

## 97—КАДЕР (КАДЕР КИЧЕ) СҮРӘСЕ

*(Кадер сүрәсе 5 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Кадер кичәсендә Коръән-и Кәрим иңгән, бу кичәдә фәрештәләр җиргә төшә.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Хакыйкать шулдыр ки, Без аны *(Коръәнне)* Кадер кичәсендә индердек. **(2)** Кадер кичәсенең нәрсә икәнен син белмисеңме? **(3)** Кадер кичәсе мең айдан да хәерлерәк. **(4)** Ул көндә фәрештәләр вә Изге Рух *(Җәбраил)*, Раббының рөхсәте илә, Аның әмерләрен җиренә җиткезер өчен, бер-бер артлы инеп кенә торырлар. **(5)** Кадер кичәсе–иминлек кичәсе–таң ата башлаганга чаклы дәвам итәр.

## 98—БӘЙИНӘ (АЧЫК АҢЛАТУ) СҮРӘСЕ

*(Бәйинә сүрәсе 8 аятьтән тора. Мәдинәдә иңгән. Бәйинә–ачык дәлил, исбатлау, аңлату мәгънәләрендәге сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Китаплы кяферләр дә, китапсыз мөшрикләр дә, ап-ачык аятьләр килгәнгә чаклы көферлекләреннән арынмадылар. **(2)** Аллаһ тарафыннан күндерелгән Пәйгамбәр *(Мөхәммәд)* шул пакь сәхифәләрне укыды. **(3)** Ул сәхифәләргә тугъры хөкемнәр язылган. **(4)** Шул тугъры хөкемнән килгәнгә чаклы, китаплы халык үзара талашып аерылмады. Фәкать алар ап-ачык аятьләр килгәч кенә аеры-чөере килеп бетте. **(5)** Гәрчә аларга: Аллаһка, аның диненә ихласлык белән иман китереп, игелек кылып, намазларны калдырмаенча, дөрес укырга, зәкят бирергә кирәк, дип әйтелде. Иң дөрес дин–шушы дин! **(6)** Хактыр ки, китаплы кяферләр дә, китапсыз мөшрикләр дә–бөтен кяферләр дә җәһәннәм утында мәңге яначак. Аллаһ яралткан җан ияләре арасында алар иң ямандыр.

**7.** Иман китереп, игелек кылганнар, һичшиксез, Аллаһ яралтканнарның иң яхшылары. **(8)** Раббы янындагы иң олуг әҗер *(җәннәт)* аларга булыр. Арыкларыннан чишмәләр агып ятучы Гаден җәннәтләрендә алар мәңгегә калачак. Аллаһ алардан разый булыр. Алар да Аллаһтан канәгать калыр. Менә боларның барысы да Аллаһның җәзасыннан курыккан мөэминнәр өчен әзерләнгән әҗер.

## 99—ЗИЛЗИЛӘ (ҖИР ТЕТРӘҮ) СҮРӘСЕ

*(Зилзилә сүрәсе 8 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Зилзилә–җир тетрәү.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Җир үзенә генә хас тетрәү белән айкала-чайкала башлаганда, **(2)** үз эчендәгеләрне *(мәетләрне, казылма байлыкларны, кайнаган магманы)* тышка чыгарып ташлаганда, **(3)** кешеләр:

–Ни булды бу Җиргә?–дип аптырар. **(4)** Ул Көнне *(Кыямәттә)* Җир өстендә ниләр кылынганның барысы турында да Җир үзе хәбәр итәр. **(5)** Аллаһның әмере илә, Җир барысын да сөйләп бирер. **(6)** Ул көнне кешеләр, нинди гамәлләр кылганлыкларына багар өчен, төркем-төркем булып, хисап бирергә барырлар. **(7)** Кем тузан бөртеге *(зәррә)* кадәрле генә игелек кылган булса, хәтта шул да күренер. **(8)** Кем тузан бөртеге *(зәррә)* кадәрле әшәкелек кылган булса, ул да күренер.

## 100—ГАДИЯТ (ЯУ УЗЫШЫ) СҮРӘСЕ

*(Гадият сүрәсе 11 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Гадият–узышучы атлар, дигән сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Йөрәк кагып, тупырдап чапкан атлар, **(2)** тоякларыннан ут чәчрәтеп узышучы чаптарлар, **(3)** таң атканда *(Җиһад өчен)* яу чапкан аргамаклар, **(4)** *(Күкне)* тузан белән каплаган чабышкылар, **(5)** дошман өеренең уртасына бәреп кергән юргалар исеме белән ант итәмен ки: **(6)** бәндәләр, чыннан да, шөкерсездер. **(7)** Хактыр ки, ул үз көферлекләренә үзе шаһит. **(8)** Хакыйкатән, *(адәм баласы)* дөнья малына бик тә хирыстыр **(9)** Алар шуны аңламыйлармы икәнни соң? Алар каберләреннән кубарылып чыгарылыр. **(10)** Күкрәкләрендә, күңелләрендә нинди хөсетлек яшеренгән булса, барысы да фаш ителер. **(11)** Хактыр ки, Аллаһның барысы турында да белгәнлеге шул көнне ачыкланыр.

## 101—КАРИГА (АФӘТ) СҮРӘСЕ

*(Карига сүрәсе 11 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Карига сүзен төрле мәгънәләрдә кулланучылар бар. Ул–капка кагучы, Кыямәт көне, афәт килү мәгънәләрендә дә йөри. В. Порохова аны, афәт камчылау, җәза бирү, дип ала, И. Крачковский исә: яралаучы, җәзалаучы, тар-мар итүче, кебегрәк мәгънәсен алган. Бу очракта Карига–Кыямәт, ягъни җәза бирү сыйфатында йөри. Аятьләрне укып, аның төгәлрәк мәгънәсен табарсыз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Афәт капкасын кага! **(2)** Ни–ул капкасын кагучы афәт? *(Кыямәт)* **(3)** Афәтнең кайчан капка кагачагы турында Сиңа кем әйтә алыр? **(4)** Ул көнне кешеләр куып таратылган күбәләкләр кебек булыр. **(5)** Таулар да ул көнне тетелеп беткән йон пәрәвезләр кебек булыр. **(6)** Менә, *(шушы көндә кешеләрнең кылган игелекләре, саваплары–үлчәүнең бер төпсәсенә, кылган яманлыклары үлчәүнең икенче төпсәсенә куелыр)* игелекләр ягы авыр басса, **(7)** ул кеше рәхәт тормышта *(җәннәттә)* яшәр. **(8)** Төпсәнең гөнаһлар ягы авыр баскан бәндәнең урыны **(9)** Һавия исемле җәһәннәм упкыны булыр. **(10)** Нәрсә ул Һавия, син беләсеңме? **(11)** Ул–хәтәр кызган ут.

## 102—ТӘКӘСУР (МАЛ ҖЫЮ ҮҖӘТЛЕГЕ) СҮРӘСЕ

*(Тәкәсур сүрәсе 8 аятьтән тора. Мәккәдә һәм Мәдинәдә иңгән, дип санаучылар да бар. Тәкәсур–байлык җыюда ярышу, малым күп, дип артык горурлану мәгънәсендәге сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Байлык туплау, *(хатыннар, балалар күплеге белән)* мактанышу һәвәслеге сезне **(2)** гүр иясе булганга чаклы ычкындырмас. **(3)** Ләкин сез озакламый *(моның гөнаһ икәнен)* аңларсыз. **(4)** Юк, сез аны тиздән аңларсыз. **(5)** Сак булыгыз, әгәр дә сез алда ни булачагын белсә идегез, *(ярамаган бу гамәлләрегездән баш тартыр идегез)*. **(6)** Һичшиксез, сез җәһәннәмне күрерсез. **(7)** Үз күзегез илә күрерсез. **(8)** Аннан соң, әлбәттә, байлыгыгыз *(дөньяда кеше талап, азгынлыкта ничек рәхәт яшәгәнегез)* турында соралачак.

## 103—ГАСЫР (ГАСЫР) СҮРӘСЕ

*(Гасыр сүрәсе 3 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Гасыр–йөзъеллык, гомумән, замана, вакыт, чор, дәвер мәгънәләрен үз эченә ала.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Гасырлар исеме белән ант итәмен ки: **(2)** кеше һәрвакыт уңышсызлыкка очрый. **(3)** Бары тик иман китереп, игелек кылганнар гына, бер-берләренә Хакыйкатьне исбат иткәннәр, түзеп, сабыр иткәннәр алай булмас.

## 104—ҺҮМӘЗӘ (ГАЙБӘТЧЕ) СҮРӘСЕ

*(Һүмәзә сүрәсе 9 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Һүмәзә–гайбәт, нахак сүз, кеше артыннан сөйләнгән хурлау сүзе, кеше арасында яман сүз йөртү.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әче каһәр төшсен кеше артыннан яман сүз йөртүчеләргә, **(2)** байлык туплап, аны кат-кат санап торган саранларга, **(3)** байлыгым-малым мине мәңге яшәтер, дип уйлаганга. **(4)** Хәер, ул кеше Хутәмәгә *(җәһәннәмгә)* атылачак. **(5)** *(Ий, Мөхәммәд)* Хутәмәнең ни икәнлеген сиңа кем аңлатып бирер? **(6)** Аллаһ яндырган хәтәр тәмуг булыр ул Хутәмә. **(7)** Бәгырьләрне яндыручы хәтәр уттыр ул Хутәмә. **(8)** Ул тәмуг бар яклап томаланган булыр. **(9)** Гөмбәзләре озын утлы терәүләр белән терәтелгән булыр.

## 105—ФИЛ (ФИЛ) СҮРӘСЕ

*(Фил сүрәсе 5 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Кәгъбәне җимерер өчен күтәрелгән Әбрәхә гаскәрендә сугыш филләре дә була. Филле гаскәр ташлы яңгырдан һәлак була.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Раббыңның фил хуҗаларын нишләткәнен күрмәдеңмени? **(2)** Аллаһ аларның мәкерле теләкләрен юкка чыгармадымыни? **(3)** Аллаһ аларның өстенә төркем-төркем Әбабил кошларын җибәрде. **(4)** Алар өстенә кызган утлы ташлар яудырды. **(5)** Сонра Ул аларны орлыгы сугып алынган салам кебек теткәләп бетерде.

*(Әбабил–яр карлыгачы, керәшә. В. Порохова тәфсиреннән: Әбрәхә гаскәренең калдыкларын радиоуглерод һәм химия кулланып тикшергәннән соң, бу гаскәрнең ни сәбәпле тулаем кырылганын ачыкладылар. Гаскәрдәгеләрнең кырылуына чәчәк муры сәбәпче булган икән. 4-5 нче аятьләрне шуннан чыгып, шәрехләргә кирәк. Ягъни, гаскәргә чәчәк авыруы йоктыручы кошлар өере һөҗүм иткән. Х. Чантай тәфсирендә дә андый киная бар.)*

## 106—КУРАЕШ (КУРАЕШ) СҮРӘСЕ

*(Кураеш сүрәсе 4 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Кәгъбә әтрафында яшәгән күпсанлы кавем–Кураеш кабиләсе иде.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Кураеш халкының бердәмлеген, **(2)** кышкы һәм җәйге сәфәрләренең уңышлы булуын тәэмин иткән, **(3)** шушы Кәгъбәтулланың Раббысына гыйбадәт кылсыннар. **(4)** Ул аларны ач үлемнән коткарып, тамакларын туйдырып, куркынычтан саклап, аларга иминлек бирде.

## 107—МӘГУН (САДӘКА) СҮРӘСЕ

*(Мәгун сүрәсе 7 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Мәгун–садәка-хәер, зәкят бирү. Бирәр әйберне яки малны бурычка, вакытлыча кулланып тору өчен биреп тору.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Динне ялганга санаган кешене син күрдеңме? **(2)** Андый кеше ятимне яныннан куар. **(3)** Ач кешенең тамагын туйдырмас *(юмартларны хупламас)*. **(4)** Андыйларның намаз укуы–гөнаһ җыю гына. **(5)** Аларның намазы ихлас вә житди түгел. **(6)** Алар намазны кеше күрсен өчен генә, риялык белән укый. **(7)** Алар хәер бирүдән тайчаналар.

## *Укучыларыбыз иҗаты*

*Редакциябезгә килгән хатларда күбесенчә шигырь була. Журналыбызны даими укып баручылар, үзләре дә әдәбиятка, шигырьгә гашыйклар яза; пенсионерлар, хыялый яшьләр, мәктәп балалары... Төрле төбәкләрдән килә шигырьле хатлар: мөһаҗир булып, горбәтлектә яшәп, чит илләрдән (әйтик, Австралиядән, Америкадан һ. б.) илгә сәлам булып килә алар... СССР таркалгач, Рәсәйдән читтә калган республикалардан да, күрше өлкәләрдән дә — кыскасы, халкыбыз яши торган барлык кыйтгалардан шигырь белән хатлар алабыз. Аларны бастырып чыгару өчен махсус кушымта-саннар кирәк. Йәки укучылар иҗатына күзәтү-анализ ясау да журналда күп урын һәм көч-вакыт алыр иде. Шуңа күрә без туган телгә, әдәбиятның чишмә башы, Әнкәсе булган шигырьгә мәхәббәт белән яшәүче, димәк, сәләтле, шагыйрь җанлы милләттәшләребезгә — укучыларыбызга рәхмәт әйтү белән генә чикләнәбез, киләчәктә дә журналыбыздан — милли рухтан аерылмыйча, татарча, үзебезчә уйлап, янып, ил-ватан, "изге сөт" хисе белән яшәүләрен телибез.*

*Бу санда шигырьләре тәкъдим ителә торган каләм ияләре дә — шундый милләттәшләребез. Фоат ага Мортазин — Кырымда, Ялтада яши, сиксән яшен узган сугыш һәм хезмәт ветераны, журнал сәхифәләрендә шигырьләре инде күренгән укучыбыз, басылып чыккан җыентыклары да бар. Миннур Сафиуллин — Балык Бистәсе районыннан, пенсиядәге укытучы; аның да төрле нәшриятларда китаплары дөнья күргән.*

*Гүзәльяр атлы укучыбыз — арада иң яше. Казан татар мәктәпләренең берсендә белем ала, чын күңелдән туган телгә, шигърияткә гашыйк яшь буын, димәк, киләчәк кешесе — әнә шул ягы белән кызыклы... Ә хәзер шигырьләргә сүз бирик.*

# Фоат Мортазин

### Ике гозер

**Җиңел тормыш сорады ул**
**Тәңредән—яшь чагында:**
**Кесә тулы акча, ирек,**
**Шөһрәт, абруй тагын да.**
**Әмма сыер сорасаң да,**
**Тәңре еш кәҗә бирә.**
**Бәхет бит күп очракларда**
**Инә күзеннән килә.**
**Шөкер, гомер кичерде ул**
**Бай да түгел, ярлы да.**

**Сигез дистә тутырганда**
**Төште тирән кайгыга:**
**Ничек китәргә дөньядан**
**Сиздермичә, тын гына?!**
**Калдырып истәлеккә тик**
**Татлы сагыш, моң гына.**
**Ул сорый бүген Алладан**
**Нибары... җиңел үлем...**
**Әйтергә кирәк, бу теләк**
**Кайчан да начар түгел.**

***

**Гаҗәп! Җан сөйгәннәр берсен-берсе**
**Җимерәләр яшәү кырында:**
**Йөрәкләре янып, күмер була,**
**Яшәү әверелә кыенга.**

**Ә беренче булып, иң әүвәле**
**Тавыш-тынсыз гына шул сула:**
**Кемнең җаны нечкә, хисе кайнар,**
**Игелекләр өчен кем туа...**

## Миннур Сафиуллин

### Бер без генә түгел лә

Агымсуның дулкынында
Чайкалсаң да түгелмә.
Сөешеп тә кавышмаган
Бер без генә түгел лә.

Яннарыма килер диеп
Сагынып көтәм көн саен.

Көндезләрен син — кояшым,
Кичләрен — тулган аем.

Насыйп булса, бәлки, без дә
Кавышырбыз бер мәлне...
Ә хәзергә серләшергә
Сердәш йолдыз бар әле.

### Парлы аккош

Талгын гына яңгыр ява,
Күл өсте зәңгәр бишек.
Көмеш суда парлы аккош
Туя алмый сөешеп.

Көн дә киләм серләшергә
Аккошларым янына.
Күлдә сезне парлап күргәч,
Дәва була җаныма.

Парлы аккошларны котлап,
Чәчәк атсын төнбоек.
Алар суда тибрәләләр
Камышларга сыенып.

Кил дә, җаный, күл буена,
Аккошлардан гыйбрәт ал.
Ялгыз адашырмын дисәң,
Гомерлек яр булып кал.

## Гүзәлъяр

### Күңелемдә үзем язган рәсем

Мәхәббәтнең соңгы ыңгырашы,
Соңгы көче, хисе каладыр;
Җан гөлемнең кипте дымы — ул да
Җирдә өмет җуйган баладыр?!
Рәсеме — онытылмаска каладыр?!

Аһ, күзләрем, ник елыйсыз һаман?
Ник, йөрәгем, шашып тибәсең?
Беләм инде: оныта алмыйсың — ләкин
Тагын нигә өметләнәсең?

"Мәхәббәтнең соңгы кычкыруы!" —
Чыннан дамы мин язган рәсем?!

### Онытылмадым, сизәм!..

Сине җибәрдем — оч, "кошым", дидем:
Читлектә яшәү — ярамас сиңа...
Күпме яратсам, сөйсәм дә, беләм:
Минем ярату аз шул, аз сиңа!

Күпме тырыштым — йөрәгеңдә мин
Алиһәң булып кала алмадым.
Күңелеңдә — үлеп, уй-кабереңдә
Күмелмәдем тик — онытылмадым!

Ышанам, сизәм: онытылмамын!

*Бер сорауга—бер җавап*



**Шамил Закиров,**
*Галиәсгар Камал исемендәге*
*Татар Дәүләт академия театры директоры.*

**Шамил әфәнде!**

**Тиздән, 2006 елда Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театры үзенең 100 еллыгын билгеләп үтәргә җыена. Шушы уңайдан, театрда бүген нинди эшләр башкарыла? Алда нинди үзгәрешләр көтелә?**

Театр яшәгән, яши һәм яшәргә тиеш! Ул һаман хәрәкәттә, үсештә. Ул яңара, яшәрә. Репертуарны баету өчен чаралар күрелә. Быел драматургия әсәрләренә конкурс үткәргән идек. Аны оештырып, нәтиҗә ясарга «Казан утлары» журналы һәм аның баш мөхәррире, халык шагыйре Равил Фәйзуллин бик нык булышты. Театр портфеленә бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек яңа пьесалар керде. Алдагы премьераларның берсе — шушы конкурста I премияне алган Зөлфәт Хәким пьесасы буенча куела торган «Телсез күке» спектакле. Ул зур масштаблы, киң колачлы, тарихи әсәр. Аны Казанның меңъеллыгына багышларбыз дип уйлыйбыз. Башкалабыз юбилеена тагын бер әсәр планлаштырып торабыз. Быел янадан драматурглар конкурсы игълан иттек. Анда Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» роман-дилогиясе буенча инсценировка язу таләбе куелган. Шушы әсәр буенча спектакль куясы килә.

Бу сезонда Аяз Гыйләҗевнең «Яра» повестен сәхнәләштердек. Халкыбыз фаҗигасе сурәтләнгән бу әсәр — Аяз абый иҗатының иң югары ноктасы дип бәялим. Спектакльне яшь режиссерыбыз Рамил Фазлыев куйды. «Яра» — аның дебюты.

Кадрлар әзерләү белән шөгыльләнәбез. Быел актерлык-режиссерлык курсы җыябыз. Ягъни, актерлар һәм режиссерлар ГИТИС системасы буенча бер группада бергә укыячаклар. Дүрт-биш елдан театрда яңа актерлар, режиссерлар булачак дип өметләнәбез. Әлеге группаны театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев укытачак. Яңа сезонда тамашачы яңа артистларыбыз белән танышачак: Руслан Низамов һәм Гүзәл Шакировага зур өметләр баглыйбыз, алар труппабызның бизәге булырга тиешләр.

Гомумән, театр киеренке иҗат тормышы белән яши. Хөкүмәтебез соңгы елларда безнең театрга нык кына ярдәм итте. Татарстан республикасы Премьер-министры Рөстәм Миңнеханов безне шефлыкка алды дияргә мөмкин. Театрның утларын алыштыру — Марсель Хәкимовичның хыялы иде. Хөкүмәт шактый күләмдә акча бүлеп бирде һәм без утларны бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек итеп яңарта алдык. Быел тавыш көчәйткечләр, тәрҗемә аппаратларын урнаштырырга җыенабыз. Сәхнә телевидениесе кертергә уйлыйбыз. Залдагы утыргычларны алмаштыра башлыйбыз. Болар барысы да театрның 100 еллыгына әзерләнү кысаларында бара. Барысы да хөкүмәтебез ярдәме. Быел Рөстәм Миңнеханов артистларга гастрольләргә йөрү өчен бөтен уңайлыклары булган өр-яңа автобус бүләк итте. Шушы автобус белән Ульяновскида, Самарада булып кайттык. Яңа сезонда Әстерханга җыенабыз. Әстерхан гастрольләре Марсель Сәлимҗановның 70 еллыгына багышлана. Быел, 7 ноябрьдә Марсель Хәкимовичка 70 яшь тулган булыр иде. Театр аның юбилеен зурлап билгеләп үтәчәк.

*Котлыйбыз!*

# "ДӨНЬЯ БЕЗНЕ МОҢГА УРАГАН..."

ЧЫҢГЫЗ МУСИНГА 70 ЯШЬ



*Акбүз атым, зинһар, өзгәләнмә,*
*Сабыр гына атлап, акрын бар.*
*Без узасы юллар чикләнмәгән,*
*Алда әле бик күп чакрымнар.*

Бу юлларны *("Акбүз атым" шигырен)* язганга, ягъни тормышта, иҗатта үз урынын тапканга, яшәү-гомер фәлсәфәсен ачыклап, инде нәтиҗәләр дә ясаганга кадәр, Чыңгыз Мусин үзе дә күп юллар, шактый чакрымнар узган. Гыйбрәтле һәм үз чорына хас, күп кордашларыныкы кебек авыр, әмма кызыклы—туган җирдән, гади хезмәттән аерылмаган, эзләнүләр, күңел дөньясы биргән шатлыклар тулы гомер юлы ул! Аның бөтен яшәеше Әгерҗе яклары—туып-үскән авылы Мордвый, кичке мәктәбен тәмамлаган Тирсә авылы белән бәйләнгән. 15 яшьтән ул шул авыл МТСында йөк ташучы булып эшли башлый *(шигырьгә дә, бер каләмдәше сурәте белән әйтсәк, "йөк астында туган хисләр"е белән килеп керә!).* Аннан—шофер хезмәте... Соңгы елларда исә—Удмуртия, Ижау шәһәре, "Янарыш" газетасы һәм андагы иҗат көчләре *(аларның да күбесе—Әгерҗе якларыннан)* белән бәйләнеш һәм шигырьләр, шигырьләр... Яшәешнең икенче сулышы!

Әгерҗе мохите—һәр татар зыялысы өчен кадерледер дип беләм: Иж-Бубый мәдрәсәсе, аннан чыккан галимнәр, дин эшлеклеләре... Яки гражданнар сугышында аклар тарафыннан үтерелгән шагыйрь Даут Гобәйди исеме... Ә Тажи Гыйззәт кебек классик драматург? Әле бит аннан чыккан Юныс Әминев та бар иде. Ләбиб Айтуганов, Эльс Гаделевлар да истә. Исәннәрдән дә күп каләмдәшләребез—бәрәкәтле шул нигездән, шул тамырдан... Шигъри матур төбәк бу!

*Тоя белсәң әгәр, дөнья безне*
*Илаһи бер моңга ураган.*
*Әле дә шөкер, җирдә үз моңым бар,*
*Үз җырым бар, шуңа куанам,—*

дип язды Чыңгыз Мусин шуна да. Район газетасында күренә башлаган, соңрак шигырьләре республика газета-журналларында басылган, күмәк җыентыкларда дөнья күргән шагыйрь 90 елларда активлашып, ачылып ук китте: "Язмышым үзәннәрдә" (1993), "Тамырлар" (1997), "Кадер кичендә" (2000) кебек китаплары дөнья күрде; "Чаян"да юмор-сатира шигырьләре дә еш чыга; матур җырлары да яңгырый... Кыскасы, иҗат бәхете белән янып яши дия алабыз.

2003 елда "Матбугат йорты" нәшриятында дөнья күргән "Баганалы юллар" исемле күләмле китабына әтрафлы, матур кереш сүзне Фоат Галимуллин язган иде. Язучылар берлеге рәисе шагыйрьне гади "рядовой" итеп кенә күрмичә, шигырьдә "гел борчылып яшәгән тынгысыз җан" итеп таный, аның милли хисләр, туган тел, заман турында уйлар белән янучы актив иҗатчы булуын әйтә. Моңа без дә кушылабыз; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь Чыңгыз Мусинны ихлас котлап, гомеренең һәм иҗатының ихласлык уты алга таба да сүрелмәвен теләп калабыз.

**Рәдиф ГАТАШ**

## «Казан утлары» архивыннан



*Әдәбият-сәнгать вәкилләреннән бер төркем. Беренче рәттә, сулдан уңга — Зәки Нури, Маннур Саттаров, Заһит Хәбибуллин, Сафа Сабиров, Зәйнәп Хәйруллина, Гариф Ахунов; икенче рәттә — Екатерина Соколова, Әхмәт Ерикәй, Мәрьям Рахманкулова, Мансур Мозаффаров, Фатих Хөсни; өченче рәттә — Мөхәммәт Садри, Илһам Шакиров, Рәисә Билалова, Фәхри Насретдинов, Хава Хәсәенова, Мәрфуга ханым (Ф. Хөснинең хатыны), Мөршидә ханым (С. Хәкимнең хатыны), Салих Вәлиди, Сибгат Хәким. Матбугат йортындагы Тукай клубы бинасында. 1962 ел.*



*Күренекле галим Әбрар Кәримуллин. Армия хезмәтендә вакытта алынган фото. Ерак Көнчыгыш. Порт-Артур. 1946 ел.*



*Татар эстрадасы йолдызлары Венера Шәрипова, Эмиль Җәләлетдинов. 1980 еллар.*



*Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш президиумы. Уңнан сулга — М. Мөхәрләмов (Әдәбият, тел һәм тарих институты директоры, тарихчы галим), Г. Минский, М. Әмир, С. Хәким, Р. Мостафин (трибунада). 1966 ел.*



*Шагыйрә Рифә Рахман. 2000 ел.*

*Балалар язучысы Госман Бакир (сулда) һәм язучы, тәрҗемәче Мәҗит Рәфыйков. 70 еллар ахыры.*



*Берлекнең яңа әгъзалары*

Журналыбызны дикъкать белән укыганнар яхшы белә: һәр санда диярлек Татарстан Язучылар берлегенә яңа кабул ителгән әгъзалар белән даими таныштырып киләбез. Мәгълүм булганча, язучылар оешмасының билгеле бер өлешен рус телендә иҗат итүче авторлар тәшкил итә. Русча язучылар остаханәсе тәкъдиме белән кабул итү Коллегиясенә шактый гаризалар керә. Соңгы айларда Татарстан Язучылар берлегенә бу остаханә тәкъдим иткән берничә кеше кабул ителде.

## Иван Грай



*Иван Грай (Жданов Иван Александрович) 1939 елда Татарстанның Мөслим районында туган. Сугыш чорында әти-әнисен югалтып ятимлектә үсә. Шулай да, тырышлыгы белән югары белем ала, пединститутта укый, соңрак аспирантура тәмамлый. Белгечлеге—биолог-физиолог. 1974 елда кандидатлык диссертациясе яклап биология фәннәре кандидаты була. Үз өлкәсе буенча фәнни хезмәтләре, уйлап чыгаручы буларак, патентлары бар.*

*Поэзиядә И. Грайның үз казанышлары бар. Ул—тыгыз фикерле фәлсәфи шагыйрь. Бүгенге көнгә төрле нәшриятларда чыккан җиде китап авторы. Аны Татарстан Язучылар берлегенә Н. Беляев, Г. Паушкин, В. Корчагиннар тәкъдим иткән.*

## Михаил Тузов



*Тузов Михаил Викторович 1945 елны Казанда хәрби хезмәткәр гаиләсендә туган. Шәһәрнең 2 нче урта мәктәбен тәмамлагач, ул әтисенең хезмәт юлын сайлый, башта Саратов хәрби училищесына укырга керә, соңрак СССР Эчке эшләр министрлыгының Югары мәктәбен тәмамлый. Унбиш еллап хәрби хезмәттә булганнан соң, сәламәтлеге какшау сәбәпле, бүтән эшкә күчәргә мәҗбүр була. Бүгенге көндә—пенсионер.*

*Михаил Тузов шигырьләр язу белән 60 елларда ук шөгыльләнсә дә, җитди иҗат итә башлавы соңгы елларга туры килә. Ул бик актив иҗат итә, шигырьләре һәм поэмалары көндәлек матбугатта еш басыла. 2001-2002 елларда аның "Раифа" һәм "Сиреневый сон" исемле китаплары басылып чыкты. Тормышта актив, инициативалы кеше буларак, ул әдәби хәрәкәттә актив катнаша, Казанның М. Горький музее каршындагы әдәби берләшмәнең җитәкчеләреннән берсе.*



Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ИҖАДИ, ЭШЛЕКЛЕ ФОРУМ

18, 19 нчы майда Казанда Татарстанның массакүләм мәгълүмат чаралары медиа-форумы булып үтте. Әлеге чара Татарстанның Матбугат көненә багышланган бәйрәм чаралары белән тәмамланды.

Медиа-форум кысаларында семинарлар, "түгәрәк өстәлләр" узды, журналистлар хакимиятнең башкарма һәм закон чыгаручы тармаклары вәкилләре, эшмәкәрләр белән очраштылар, фикер алыштылар. Шул унайдан журналистларның ТР Дәүләт Советы председателе Ф. Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министр урынбасары З. Вәлиева һәм "Татмедиа" агентлыгы генераль директоры М. Моратов белән очрашулары үтте.

19 майда Татарстан Матбугаты көнендә Бауман урамы "массакүләм мәгълүмат чаралары урамына" әверелде. Биредә кунаклар һәм шәһәр халкы өчен музыкаль чыгышлар, күргәзмәләр һ. б. төрле чаралар оештырылды. Бу бәйрәмдә безнең "Казан утлары" журналы коллективы да актив катнашты, күргәзмә-стендлар, нотык-чыгышлар белән халыкка үзен лаек дәрәҗәдә күрсәтә алды.

Җиен "Пирамида" күңел ачу комплексында журналистларның VII республика "Бәллүр каләм" конкурсы җиңүчеләрен котлау белән тәмамланды. Быел журналистлар конкурсында 200 дән артык матбугат хезмәткәре катнашты. Төрле номинацияләрдә җиңүчеләргә дипломнар, истәлекле бүләкләр тапшырылды.

Матбугат көне уңаеннан 7 кешегә "ТР атказанган культура хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелде. 2 журналист РФ Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Форум эшендә Татарстан Президенты М. Шәймиев, ТР Премьер-министры Р. Миңнеханов катнашты.

Матбугат көннәре Республиканың Чаллы, Әлмәт, Мамадыш һ. б. шәһәрләре һәм районнарында да зурлап, истә калырлык итеп үткәрелде.

## МӘЧЕТ ЮБИЛЕЕНДА

Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналар залында Җәмигъ мәчетенең 100 еллыгына багышланган кичә булды. Анда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев катнашты.

Тантанада Россиянең Мөфтиләр советы рәисе Равил Гайнетдин Җәмигъ мәчете тарихының барлык этаплары, аның Мәскәүдә, шулай ук бөтен Россиядә яшәүче миллионнарча мөселманнар тормышында торган саен зуррак роль уйнавы турында сөйләде. Хөкүмәт исеменнән тәбрикләү сүзе белән РФ мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министры Александр Соколов мөрәҗәгать итте. "Россия—күп конфессияле дәүләт, барлык этнослар һәм мәдәниятләр үзара аңлашып яши торган ил. Бүгенге тормышның нәкъ менә дини аңы рухилыкның ышанычлы терәге булып тора. Теләсә нинди конфессия вәкиленең сүзе һәрвакыт изгелеккә, мәрхәмәтлелеккә юнәлешле булыр",— диде министр.

Залда утыручылар Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевне көчле кул чабулар белән каршы алдылар. "Без бүгенге чорыбызга рәхмәтле булырга тиешбез,—диде ул.—Мәскәү үзәгендә, Союзлар йортының Колонналы залында Җәмигъ мәчетенең 100 еллыгы билгеләп үтеләсен күз алдына китерә ала идекме? Әлбәттә, юк. Бу—илебездәге демократик үзгәртүләрнең иң ышандырулы чагылышы",— диде Татарстан җитәкчесе.

ТР Президенты мөфти Равил Гайнетдиннең дини агарту эшендәге зур ролен билгеләп үтте. Ул: "Равил хәзрәт, барлык конфессия җитәкчеләре алдында мөселманнарның абруй казанган ихтирамлы һәм күренекле рухи җитәкчесе буларак, безгә бик тә ошый",—диде.

Тантаналы кичәдә катнашучылар Татарстан Президентының республикадагы дини яңарыш, мәчет-чиркәүләрнең торгызылуы турындагы чыгышын зур кызыксыну белән тыңладылар. "Үзгәртеп коруларга кадәрге чорда Татарстанда нибары 23 мәчет булса, хәзер—1100,—диде ул.—Казанда Россия Ислам университеты эшләп килә. Ул барлык республикаларны һәм Россиянең барлык төбәкләрен югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин итәргә әзер". Президентның Кол Шәриф мәчете төзелеше турында сөйләвен залда утыручылар аеруча зур кызыксыну белән тыңлады.

## ИЛЕШТӘ ОЧРАШУ

Татарстан Президенты аппараты җитәкчесе Ә. Гобәйдуллин Башкортстанның Илеш районында булды. Биредә ул әлеге республика Президенты администрациясе башлыгы Р. Хәбриев белән очрашты. Очрашу барышында ике республиканың үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләре буенча фикер алышу булды. Аерым алганда, Казан шәһәренең 1000 еллыгын һәм Салават

Юлаевның тууына 250 ел тулуны билгеләп үтүдә делегацияләрнең ни рәвешле катнашачагы тәгаенләнде.

Очрашу йомгаклары буенча Татарстан белән Башкортстан арасында дуслык һәм хезмәттәшлек турында килешү кысаларында ике республика халкының мәдәни, фәнни, мәгълүмати элементләрне тагын да ныгыту җәһәтеннән конкрет чаралар эшләү өчен эш комиссиясе булдыру турында карар кабул ителде.

Очрашуда Татарстан Фәннәр академиясе академигы И. Таһиров, Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы Р. Миннуллин, Башкортстан Президенты администрациясенең иҗтимагый-сәяси үсеш мәсьәләләре бүлеге мөдире Ә. Юлдашбаев, Россия Фәннәр академиясенен Башкортстан филиалы Тарих, тел һәм әдәбият институты директоры И. Илишев катнашты.

## УНИВЕРСИТЕТ ГАЛИМНЕ ОЛЫЛЫЙ

Казан дәүләт университеты галимнәре, студентлары, каләмдәшләре күренекле тарихчы, академик Миркасыйм Госмановны 70 еллыгы белән котларга Актлар залына җыелдылар. Гыйльми Советның кинәйтелгән утырышы дип аталган бу тантаналы җыелышны университет ректоры Мәгъзүм Сәлахов ачты. Аннан соң Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов галимнең хезмәт юлы, тарих һәм тюркология өлкәсенә керткән өлеше турында сөйләде. Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева М. Госмановка Президент котлавын ирештерде.

Тантанада Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, Казан шәһәр хакимияте башлыгы Камил Исхаков та катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

## ДӨНЬЯ МӨСЕЛМАННАРЫ КАЗАНГА ҖЫЕНА

Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Дубаи шәһәрендә Ислам башкалалары һәм шәһәрләре оешмасының (ИБШО) X Генераль конференциясе уздырылды. Анда Казан шәһәре хакимияте башлыгы Камил Исхаков һәм ТР мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе мөфти Госман хәзрәт Исхакый да катнашты. Бу оешма 54 илдән 143 шәһәрне берләштерә. Ислам башкалалары һәм шәһәрләре оешмасына 1992 елда Казан шәһәре дә керде һәм ул Россия шәһәрләре арасында бердәнбер. Ислам шәһәрләре конференциясендә чыгыш ясап, Камил Исхаков аның РФ Президенты Владимир Путинның "Ислам конференциясе" оешмасы саммитындагы чыгышыннан соң ук үтүе 20 миллион Россия мөселманнары өчен әһәмиятле булуын билгеләп үтте. Нәкъ менә Малайзия саммитында Россия Президенты ИКО илләрен Россия мөселманнары белән якынаерга чакырды, шулай ук соңгы 10 елда үсеш алган Ислам диненең Россия өчен традицион дин булуын билгеләп үтте.

Генераль конференциядә катнашучыларның Административ советы ИБШОның киләсе сессиясен Казанда үткәрергә һәм аны Татарстан башкаласының 1000 еллыгына багышларга дигән карарга килде.

## "ДИАЛОГ-АВРАЗИЯ" ХАЛЫККА ЧЫГА

3 апрельдә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты бинасында Истанбулда нәшер ителүче ДА—"Диалог-Авразия" журналын таныту тантанасы булды. Мәгълүм булганча, мәдәниятләр хезмәттәшлегенә чакыручы әлеге журнал төрек һәм рус телләрендә кварталга бер мәртәбә чыгарыла. Күптән түгел аның 13 нче саны дөнья күрде.

Быел ул Бөтенроссия каталогына кертелде. БДБ илләрендәге әбунәчеләр өчен тиешле тираж якын арада Мәскәүдә басыла башлаячак.

"Диалог-Авразия" журналы редакциясе төрки халык язучыларының әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итеп бастыру белән дә шөгыльләнә. 4 апрельдә Истанбулда, журнал офисында шундый китапларны җәмәгатьчелеккә таныту тантанасы булды. Анда төрки әдәбиятларның күренекле әдипләре катнашты. Әлеге тантанада Татарстаннан ТР Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

## КЫРЫМ ЙОРТКА СӘЯХӘТ

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы, язучы Фәүзия Бәйрәмова Кырым татарларының илләреннән сөрелүенә 60 ел тулу уңаеннан Кырымда уздырылган матәм чараларында катнашты. Кардәшләребезнең кайгыларын уртаклашырга Төркия, Румыния, Литва һәм башка илләрнең вәкилләре килгән иде. Бу чараларда шулай ук Украина Премьер-министры, Кырым Республикасының рәсми җитәкчеләре дә катнашты.

Фәүзия Бәйрәмова Симферополь шәһәрендә уздырылган матәм митингында чыгыш ясады, шулай ук Кырым татарларының Милли Мәҗлесендә булып, аның лидеры Мостафа Җәмилев белән очрашты, Симферополь шәһәренең И. Гаспралы исемендәге татар китапханәсендә, дәүләт педагогика институтында, милли редакцияләрдә, Бакчасарай шәһәрендә И. Гаспралы "Тәрҗеман" гәзитен нәшер иткән йорт-музейда, "Зынҗырлы" мәдрәсәсендә булды.

## "ХӘЗИНӘ"НЕҢ МӨХӘРРИРЕ—КАЛӘМДӘШЕБЕЗ

Әлмәттә нефтьчеләр өчен татарча чыга торган "Хәзинә" газетасының 10 еллыгын "кара алтын" чыгаручылар гына түгел, киң җәмәгатьчелек тә билгеләп үтте. Бу, чыннан да, зур вакыйга: "Хәзинә" газетасы (баш мөхәррире шагыйрь һәм публицист Нур Әхмәдиев) ана телебезне үстерүгә, аны яңа терминнар белән баетуга, яшьләрне эшкә

өйрәтүгә зур өлеш кертә. Элекке елларда эре сәнәгать эшханәләрендә русчадан татарчага тәрҗемә ителеп (дубляж) чыгып килгән газеталар да ябылып беткән бер заманда "Татнефть" акционерлык җәмгыяте житәкчеләренең үз газетасын саклавы һәм аңа әбүнәчеләрне киметмәс өчен һәрьяклап булышлык итүләре зур ихтирамга лаек.

## "КИТАП ЙОРТЛАРЫ" БӘЙРӘМЕ

Менә инде тугызынчы ел рәттән 27 май көнен бөтен ил китапханәчеләре үзләренең һөнәри бәйрәмнәре буларак билгеләп уздыралар. Шул уңайдан Татарстанның Мәдәният министрлыгы иң яхшы китапханәләрне атап, аларны махсус премияләр белән бүләкләде. 2003 ел нәтиҗәләре буенча быел "Лидер" номинациясендә Казанның үзәкләшкән китапханә челтәре иң алдынгы дип танылды. "Ижади эзләнү" премиясенә исә Лениногорск һәм Теләче районнарының үзәк китапханәләре, Түбән Кама районының Ташлык авылы һәм Балтачның Урта Көшкәт авылы китапханәләре лаек булды.

## КАЗАНДА ИСЛАМИЯТ МУЗЕЕ БУЛАЧАК

Казан Кремлендә Исламият музее төзелә. Бүгенге көндә әлеге музейга экспонатлар җыю дәвам итә. Булачак музейга борынгы китаплар, кулъязмалар, шәмаилләр, революциягә кадәрге Коръән тәфсирләре, татар мәгърифәтчеләренең китаплары, шәхси әйберләре; XX гасыр башында чыккан газета-журналлар, элеккеге мөселман киемнәре, намазлыклары, дисбеләре, элеккеге муллаларның чалма, чапан, читек, таяклары, элек мәдрәсә шәкертләре булган кешеләрнең шәхси әйберләре, киемнәре, дәреслекләр, дәфтәрләр, кара савыты, каләм, шаһәдәтнамә; репрессияләнгән мөселманнарның шәхси әйберләре, документлары, хатлары; мөселманнарны христианлаштыруга кагылышлы материаллар (XVI –XIX гасырлар), совет чорында да шәригать буенча яшәгән мөселман гаиләләренең шәхси әйберләре, хаждан алып кайткан әйберләр кабул ителә.

Исламият музеена экспонатлар китерүчеләрнең исем-фамилияләре язылган альбом музейга да куелачак.

Белешмәләр өчен адрес: Казан, "Казан Кремле музей-тыюлыгы", фән бүлеге. Телефон: 92-60-87

## КЫЗЫКЛЫ БАСМА

Казанның 1000 еллыгына багышланган тагын бер яңа басма дөнья күрде. Ул "Казан һәм казанлылар. Иске портретларга яңа штрихлар" дип атала. Аның авторы—ТР Милли музее хезмәткәре Г. Милашевский. Китапта XVIII гасырдан XX гасыр эчендәге вакыйгалар, шул чорда Казанда яшәгән танылган шәхесләр тормышы тасвирлана. Казан һәм казанлылар турындагы китап 38 документаль очерктан тора. Алар—элеккеге заманда чыккан газета-журналларны укып өйрәнгәч туган язмалар. Очеркларның тематикасы төрле: атаклы медицина хезмәткәре, лингвист, археолог, тарихчы К. Фукс эшчәнлеге хакындагы язмалар, язучы Г. Державин, башка танылган рәссамнар, архитекторлар турындагы очерклар да укучыны кызыксындырырлык. Китаптан беренче трамвай, элеккеге шәһәр урамнары, мәйданнар һәм башка бик күп истәлекле урыннар турындагы дәлилле фактларны табарга була. Язмалар милли музей фондларында сакланган иллюстрацияле фоторәсемнәр белән бизәлгән.

## ЗАМАНЧАГА КӨЙЛӘНЕП

Татарстан Фәннәр академиясенең "Фән" нәшрияте Казан дәүләт университеты галимнәре Ж. Сөләйманов һәм А. Гатиятуллинның "Татар морфемаларының компьютерда структур-функциональ моделе" дигән хезмәтен бастырып чыгарды.

Татар иҗек-кушымчаларын (морфемаларын) компьютерда куллану өчен барлау, аларның структур-функциональ модельләрен системага салу татар телен дәүләт теле буларак куллануны киңәйтүнең гамәли һәм дә фәнни мөмкинлекләрен ачарга булышачак.

Китап тел белгечләренә, ясалма интеллект, текстны автоматик эшкәртү, компьютер лингвистикасы һәм тәрҗемә мәсьәләләре белән кызыксынучыларга, шушы юнәлештә белем эстәүче студент һәм аспирантларга адреслана.

## МӘГЪЛҮМАТКА БАЙ БУКЛЕТ

XVIII йөз азагы XIX йөз башында Казан җирендә туып, соңрак Россиянең күренекле дәүләт эшлеклесе, заманының атаклы шагыйренә әверелгән (чыгышы татар морзалары нәселеннән) Гавриил Державинга багышланган буклет дөнья күрде.

Басмада Г. Державинның кыскача тәрҗемәи хәле, элеккеге Лаеш өязендәге Державиннар утары тарихы, шигырьләре урын алган. Буклетта шулай ук Лаештагы Державин музее һәм аның исемендәге әдәби премия турында да мәгълүматлар бар. Күпсанлы рәсемнәр арасында Державиннар нәселе гербын, утарларының фотосурәтләрен, Татарстан Милли музее фондларында сакланачы мемориаль әйберләрне күрергә мөмкин.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Фән һәм мәгарифне үстерүгә, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә лаеклы өлеш керткәне өчен В. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты кафедра мөдире, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы **Госманов Миркасыйм Габделәхәт улы** Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

# ЭСТРАДАДА ДЕМОКРАТИЯ

Календарьдә–эссе җәй фасылы, ел буена эшләп талчыккан кешеләр отпуск башлануын сабырсызлык белән көтеп ала. **"ТАТАР ҖЫРЫ"** фестивален оештыручылар өчен дә кызу чак башлана. 2005 елның 11-16 январендә Казан шәһәрендә үтәсе юбилей фестивалена әзерлек дәвам итә. Быелгы фестиваль оештыру комитеты өчен икелетә җаваплылык йөкли, чөнки 2004 ел **"ТАТАР ҖЫРЫ"** фестивалена биш ел, ягъни беренче юбилей елы. Ә инде "Яңа Гасыр" һәм "Татарстан" телерадиокомпанияләре һәм "Барс-Медиа" ЯАҖннән оешкан **"ТАТАР ҖЫРЫ"** комитеты өчен, үзенең тамашачыларына һәр елны сюрпризлар һәм яңалыклар кертү күркәм традициягә әйләнде.

**"ТАТАР ҖЫРЫ"**н татар эстрада сәхнәсендә бүтән чаралардан аерып торучы бер үзенчәлек бар–анда катнашкан җырчыларны сайлау мөмкинлеге теләге булган һәркемгә бирелүдә. Фестивальдә катнашкан һәр җырчы, тамашачылардан килгән хатларга, FM-радиостанцияләр, аудио- һәм видеопродукция сатылу рейтингларына нигезләнеп сайлана. Җырчы өчен бу фестивальдә катнашу зур дәрәҗә, шуңа күрә һәр җырчы ел буена халык мәхәббәтен яулау һәм, нәтиҗә буларак, фестивальдә катнашу мөмкинлеге алу өчен барлык көчен салырга тиеш. Таләпчән тамашачы игътибарын үзенә һәм иҗатына җәлеп итәр өчен җырчы, һәрвакыт камиллеккә омтылып, вакыт һәм көч кызганмыйча яңа җырлар табарга, аранжировка ясарга, клип төшерергә, үзе һәм тавышы өстендә эшләргә тиеш.

**"ТАТАР ҖЫРЫ"**нда катнашучы җырны сайлау тәртибе демократик һәм азмы-күпме аңлашыла торган булса, чараның үзен үткәрү тәртибе мәсьәләсенә килгәндә эш башкачарак. Моңарчы оештыручылар, фестивальнең сценарием язу кебек бик җаваплы эшне профессионалларга тапшыралар иде. Бер яктан, моңарчы узган **"ТАТАР ҖЫРЫ"** фестивальләренә йомгак ясап, икенче яктан исә тамашачыларның күпсанлы таләпләрен искә алып, аны тагын да демократик һәм халыкка якынрак кылу максатыннан, оештыру комитеты быел тагын бер яңалык кертергә карар кылды. Безне укучы, тыңлаучы һәм караучы барлык тамашачыларга мөрәҗәгать итәбез:



**"ТАТАР ҖЫРЫ"ның бишенче – юбилей фестивален сез ничек күз алдына китерәсез? Әлеге олуг вакыйгада кайсы җырчылар катнашырга лаек?**

Хатларыгызда, фестиваль эшчәнлеген яхшыртуга юнәлгән һәртөрле объектив тәнкыйтьне күрергә дә шат булырбыз. Милли мәдәниятне сөюче, бәһа бирүче һәм үстерүчеләрдән кызыклы һәм файдалы тәкъдимнәр алачагыбызга шигебез юк. Килгән барлык хатлар да игътибарга алыначак, ә алар арасында иң күренеклеләре, 2005 елның 11-16 январендә Казан шәһәрендә үтәсе бишенче – юбилей **"ТАТАР ҖЫРЫ"** халыкара телевизион фестиваленың сценарием төзегәндә кулланылачак.

**Редакциядән:** оештыру комитетының адресы: **420094, Казан шәһәре, а/т 4.**
**"ТАТАР ҖЫРЫ"** мәгълүмат үзәге.
Телефон/факс: **(8432) 19-14-66**
E-mail: office@barsmedia.ru

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкнын беренче битендә:* «Азнакай таулары». **М. Галиев фотосы.**
*Тышлыкнын дүртенче битендә:* шагыйрь **Җәүдәт Сөләйман**.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Госманов Миркасыйм. Гасырдан—гасырга.** —Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. —488 б. Тиражы—3000 данә.

Узган чорлардан безгә нәрсәләр килеп житкән, нәрсәләр юкка чыккан, онытылган? Тарихи, рухи байлыгыбызны барлауда, саклауда кемнәр тырышлык күрсәтеп, нинди казанышларга ирешкән? Алда, киләчәктә, безне нинди яналыклар, үзгәрешләр көтә? Ниһаять, катлаулы тарихыбызны өйрәнүдә безгә ничек һәм нәрсәләр эшләргә?

Бу сорауларга җавап табуы һич тә җинел түгел, әлбәттә. Тарихчы һәм язма истәлекләр белгече М. Госмановнын бу китабында авторнын шул мәсьәләләр тирәсендә эзләнүләренә, уйлану һәм борчылуларына караган мәкаләләре, әнгәмәләре һәм чыгышлары тупланган. Китап студентларга һәм, гомумән, тарихыбыз белән кызыксынучыларга адреслана.




**Зарипов Рөстәм. Тамчы гөл: Шигырьләр, хикәяләр, пьеса.** —Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. —206 бит. Тиражы—2000 данә.

Рөстәм Зарипов үзенен хикәяләре, шигырьләре белән әдәбият сөючеләргә матбугат битләрендә инде узган гасырнын житмешенче елларында ук күренгәләп килгән исем. Анын “Тамчы гөл” жыры халык арасында аеруча популярлык казанды. Анын милләт язмышына һәм әдәби хәрәкәткә кагылышлы публицистик язмалары безнен журналда да берничә мәртәбә басылып чыкты. Р. Зариповнын бу беренче китабына анын шигырьләре, жырлары, хикәяләре, публицистик мәкаләләре һәм пьесасы урын алган.



Җәүдәт Сөләйман

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**QAZAN UTLARI**
**ОГНИ КАЗАНИ**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)